

РӘШИТ ӘХМӘТҖАНОВ

# ТАТЛЫ САГЫШ, РӘХӘТ САГЫНУ…

РӘШИТ
ӘХМӘТҖАНОВ

# ТАТЛЫ САГЫШ,
# РӘХӘТ САГЫНУ...

Казан
«Рухият» нәшрияты
2020

ББК 84(2Рос=Тат)-5
Ә86

Төзүчеләре:
*Сания Фәйзерахманова, Марат Фәйзерахманов*

Мөхәррире
*Галия Мөхәммәтҗанова*

Ә86 Рәшит Әхмәтҗанов: Татлы сагыш, рәхәт сагыну... [төз.: С.Х. Фәйзерахманова, М.Г. Фәйзерахманов]. – Казан: Рухият, 2020. – 360 б.

ISBN 978-5-89706-208-9

1970–1990 елларда «Адымнар», «Җан яктысы», «Йөрәк бәйрәме», «Ачлык мәйданы» һәм башка күп кенә шигырь җыентыклары белән татар дөньясын шаулаткан, ихласлыгы, туры сүзлелеге белән үзенә карата хөрмәт уяткан Рәшит Әхмәтҗановның тууына 2021 елда 80 ел тула. Шул уңайдан нәшер ителгән хатирәләр китабы шагыйрьнең шәхсән үзен һәм аның йөрәгеннән кайнап чыккан чын иҗатын, тыйнак мәкаләләрен, милли каһарманлыгын күңелләребездә кабат яңартыр.

Каләмдәш дусларының шагыйрь иҗатына багышлап төрле елларда язылган шигырьләре һәм мәкаләләре, замандашларының һәм якыннарының хатирәләре, истәлекләре, фотолар, искә алу кичәсенең сценарие җыентыкны тагын да баета.

ISBN 978-5-89706-208-9

© «Татнефть» Хәйрия фонды, 2020
© Фәйзерахманова С.Х., Фәйзерахманов М.Г., төзү, 2020

# Төзүчеләрдән

Тормыш, тормыш,
Нинди күңелле син!
Әй татлы да синдә моңаю.
Еларга да җирдә өлгермәдем,
Мәңгелеккә бирдең елмаю.
*Рәшит Әхмәтҗанов*

Тиздән, 2021 елның апрель аенда, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстан Язучылар берлегенең Гаяз Исхакый исемендәге әдәби бүләге иясе, татар шигъриятен үз җәүһәрләре белән баеткан, һәр татар кешесе укырга тиешле 100 китап исемлегендә ихлас һәм кыю иҗаты белән лаеклы урын яулаган, Татарстаныбызның мөстәкыйльлеге өчен көрәш юлында фидакяр гамәлләре белән шәхси үрнәк күрсәткән милли каһарманыбыз Рәшит Хәниф улы Әхмәтҗановның (1941—1995) тууына 80 ел тула.

Шушы уңайдан, хөрмәтле укучыбыз, сезнең игътибарга шагыйрьнең кайбер шигырьләре, матбугатта дөнья күргән мәкаләләре, дуслары, замандашлары тарафыннан аның иҗатына карата әйтелгән саллы фикерләр тупланган, фоторәсемнәр белән баетылган истәлек-хатирәләр китабын тәкъдим итәргә булдык.

Һәм иң беренче нәүбәттә үк бу җыентыкны дөньяга чыгаруда ярдәм иткән «Татнефть» Хәйрия фондының «Рухият» программасына һәм аның коллективына тирән рәхмәтебезне белдерәбез! Алар, безне бер сүздән аңлап алып, барыбыз өчен дә кадерле бүләк ясадылар. Рәшит абый да бит халкыбызның нәкъ шушындый асыл ул һәм кызларына дан җырлады, алар белән чиксез горурланды. Өстәвенә Әлмәт шәһәрен төзүдә катнашып, иҗат эшчәнлеген дә шунда башлады. Әлмәт турында зур поэма, шәп шигырьләр иҗат итте.

Китапны төзүгә Рәшит абыйның иҗатын гомер буе зурлаган, аны яттан белгән, сәнгатьчә югарылыкта радио-телевидениедән, зур сәхнәләрдән халкыбызга, чит илләрдә яшәүче милләттәшләребезгә дә җиткергән, вафатыннан соң китапларын, икетомлыгын, Татар әдәбияты үзәге ярдәме белән «Сайланма әсәрләр»еннән төзелгән аудиокитапны (Р. Әхмәтҗанов шигырьләрен йөрәкләргә үтеп керерлек итеп укый ул!) чыгаруда биниһая тырышлык куйган, зур һәм бөек халкыбызның азатлыгы өчен көрәш мәйданында Рәшит абый кебек үк шәхси Матурлык һәм Батырлык үрнәге күрсәтеп, халык күңеленә кергән, Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты, Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, М. Җәлил бүләге иясе газиз абыебыз Илдус Әхмәтҗанов та зур өлеш кертте.

Шагыйрьгә карата халкыбызның олы хөрмәте турында сөйләгән әлеге китап әдәбият һәм сәнгать сөючеләрне битараф калдырмас, фәнни һәм әдәби эшчәнлек белән шөгыльләнүчеләргә файдалы чыганак буларак та хезмәт итәр дигән өметтә калабыз.

*Хөрмәт белән,*
*Сания Фәйзерахманова, Марат Фәйзерахманов*

# Кояш чыккан кайтыр юлларга

*Ил капкасын кагам…*
*Өр-яңадан*
*Өлгердем мин җиргә туарга,*
*Кичерерсез, туры килә хәзер*
*Үз урнымнан сезне куарга.*

*Сез талаган бөтен хәзинәне*
*Кайтарыгыз димим берьюлы.*
*Канун китабына теркәгез, мин –*
*Кай җирләрдә туган, кем улы?!*


*Икенчесе – минем туган телне*
*Кире кайтарырга сез тиеш:*
*Тик карагыз,*
*«Әнкәй» дигән сүзнең*
*Моңы торган булсын шул килеш!*

*Бу ике шарт үтәлергә тиеш,*
*Үтәлергә тиеш бүгеннән.*
*Тереләчәк телем. Үз уллары*
*Коткарачак аны үлемнән.*

*Тереләчәк Иман!*
*Ул әлегә*
*Далаларда йөргән бер качак…*
*Ул адашкан барлык балаларын*
*Үз өенә алып кайтачак.*

*Без куылган идек.*
*Өр-яңадан*
*Өлгердек бит җиргә туарга!*
*Кояш чыккан… халык йөрәгенә*
*Алып кайта торган юлларга.*

*Рәшит Әхмәтҗанов*


13

# Шагыйрьнең тормыш һәм иҗат юлы сәхифәләре

Күренекле шагыйрь, Татарстан Язучылар берлегенең Г. Исхакый исемендәге әдәби премиясе лауреаты Рәшит Хәниф улы Әхмәтҗанов 1941 елның 14 апрелендә Татарстан Республикасының Баулы районы Татар Кандызы авылында туа. Авыл мәктәбендә җиде класс белем алганнан соң, 1957–1958 елларда Бөгелмә шәһәрендә төзүчеләр әзерләү училищесында укый, аны тәмамлагач, нефть районнарында һәм Әлмәт шәһәрендәге төзү оешмаларында ташчы булып эшли. 1961–1964 елларда армия сафларында хезмәт итә. Армиядән кайткач, Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә, 1969 елда аны тәмамлап чыга. Башта Татарстан АССР Мәдәният министрлыгында сәнгать эшләре буенча инспектор (1969–1974), аннары «Яшь ленинчы» (хәзерге «Сабантуй») һәм «Татарстан яшьләре» газеталарында әдәби хезмәткәр булып эшли. 1980 елдан хезмәт биографиясе озак еллар буена «Казан утлары» журналында дәвам итә.

Рәшит Әхмәтҗановның исеме әдәбият мәйданында 1950 елларның ахырларында ук күренә башлый. 1959–1961 елларда «Азат хатын» (хәзерге «Сөембикә»), «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналларында басылган шигырьләре белән әдәби җәмәгатьчелектә ул кызыксыну уята. Х. Туфан, С. Хәким, Г. Хуҗиев кебек тәҗрибәле шагыйрьләр яшь каләмнең поэтик фикерләүдәге мөстәкыйльлеген, табигый сәләтен һәм шигырьләренең тормышчанлыгын билгеләп үтәләр. Авторның 1965 елда басылып чыккан «Хыялларым үзем белән» исемле беренче шигъри җыентыгы да укучылар һәм әдәби тәнкыйть тарафыннан җылы каршы алына, ул поэзиягә хезмәт кешеләре образларын, чынбарлыкны кабул итүдә нечкә милли кичерешләр дулкынын алып килә.

Р. Әхмәтҗанов – бөтен рухы, табигате белән лирик шагыйрь. Аның шигырьләренә тыйнак моң-сагыш, халык җырларына хас җыйнаклык, садәлек хас. Аның лирик герое әхлакый сафлыгы, характерының бөтенлеге белән истә кала. Р. Әхмәтҗанов үзенең шигырьләрендә халык теле бизәкләреннән оста файдалана, фольклордагы традицион образларга, төшенчәләргә яңача яңгыраш төсмерләре бирә белә.

Шагыйрьнең моннан соң бер-бер артлы басылып чыккан «Адымнар» (1969), «Ак канатлар» (1972), «Гомер чишмәсе» (1976), «Алмалы җәй» (1979), «Җан яктысы» (1980) һ.б. җыентыклары әдипнең үзе тоткан юлдан эзлекле рәвештә алга атлавын, дөньяны шигъри образларда сурәтләү чараларының камилләшә, төрләнә баруын күрсәтә.

Шагыйрь поэма жанрында да кыю иҗат тәҗрибәләре ясый. 1980 елда аның «Исәннәр моңы» дип исемләнгән беренче поэмасы дөнья күрә. Сугыш, тынычлык, заман, хәтер, мәхәббәт, нәфрәт кебек мөһим мәсьәләләрне күтәргән әлеге әсәрдән соң аның «Бишташ» (1987), «Аучылар кибетендә» (1988), «Карачкы» (1989), «Язлар быел соңга калды» (1991), «Карга каргышы» (2001) поэмалары басыла.

1990 елларда Р. Әхмәтҗановның тематик эзләнүләрендә милләт азатлыгы темасы аеруча калку чагылыш таба. Бу омтылыш бигрәк тә аның «Ачлык мәйданы» китабында тирән яктыртыла. Авторның милләтпәрвәр көрәштәшләре белән Ирек мәйданында ачлык игълан итеп утырулары, 14 көн буена аның үз башыннан кичкән вакыйгалар, кичергән уй-тойгылары сурәтләнә.

Р. Әхмәтҗанов иҗаты – татар милләте, тел язмышы, дин язмышы өчен борчылган, милләтнең үткәне һәм киләчәген йөрәге аша уздырып, халыкның үзаңын уяту омтылышы белән сугарыл-

ган көрәш поэзиясе. Халыкның азатлыгы, бәйсезлегенә илтүче юллар аның да төп иҗат юлына әверелгән була.

Шагыйрь җыр жанрында да актив иҗат итте. Туган ил, туган тел, мәхәббәт һәм яшьлеккә бәйле темаларга язылган лирик шигырьләре музыкаль аһәңнәре белән аерылып торалар; профессиональ һәм үзешчән композиторларыбыз дүрт дистәдән артык шигыренә көйләр иҗат иттеләр. Алар, – халык арасында таралып, озак еллар буе җырчылар тарафыннан даими башкарыла торган җырлар.

Рәшит Әхмәтҗановка 1991 елда «Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем, ә 1993 елда Татарстан Язучылар берлегенең Гаяз Исхакый исемендәге әдәби премия лауреаты исеме бирелә.

1995 елның 5 гыйнварында шагыйрь бакый дөньяга күчә.

Р. Әхмәтҗанов – 1970 елдан СССР (Татарстан) Язучылар берлеге әгъзасы.

## *Төп басма китаплары*

Хыялларым үзем белән: шигырьләр.– Казан: Татар. кит. нәшр., 1965.– 31 б.– 4000 д.

Адымнар: шигырьләр / автордашлар: Ш. Маннапов, Т. Камалиев.– Казан: Татар. кит. нәшр., 1969.– 142 б.– 2500 д.

Ак канатлар: шигырьләр.– Казан: Татар. кит. нәшр., 1972.– 96 б.– 3000 д.

Гомер чишмәсе: шигырьләр.– Казан: Татар. кит. нәшр., 1976.– 112 б.– 2500 д.

Алмалы җәй: шигырьләр.– Казан: Татар. кит. нәшр., 1979.– 24 б.– 9000 д.

Җан яктысы: шигырьләр, поэма.– Казан: Татар. кит. нәшр., 1980.– 112 б.– 2700 д.

Кавышыр көн: шигырьләр.– Казан: Татар. кит. нәшр., 1985.– 143 б.– 1300 д.

Йөрәк бәйрәме: шигырьләр.– Казан: Татар. кит. нәшр., 1988.– 238 б.– 2400 д.

Моңлану: шигырьләр, поэмалар.– Казан: Татар. кит. нәшр., 1991.– 431 б.– 2700 д.

Ачлык мәйданы: шигырьләр.– Казан, 1993.– 71 б.– 10000 д.

Сайланма әсәрләр.– Казан: Рухият, 1998.– 416 б.– 3000 д.

Без күккә егылырбыз.– Казан: Татар. кит. нәшр., 1998.– 20 б.– 3000 д.

Сәфәр ае: шигырьләр.– Казан: Татар. кит. нәшр., 2001.– 223 б.– 2000 д.

Әсәрләр: ике томда. 1 т.: шигырьләр.– Казан: Татар. кит. нәшр., 2013–319 б.– 2000 д.; 2 т.: шигырьләр, поэмалар, балалар өчен шигырьләр.– Казан: Татар. кит. нәшр., 2014–271 б.– 2000 д.

## *Башка нәшриятларда чыккан китаплары*

*Рус телендә:*

Созвездие Сююмбеки: стихи современных татарских поэтов среднего поколения / пер. с тат.: Людмилы Букиной и Николая Новикова.– Москва: «Современник», 1988.– 361–376 с. – 10000 экз.

*Башкорт телендә:*

Уттан туган уйлар.– Өфе: Башкортостан «Китап» нәшр., 1996.– 208 б.– 2700 д.

*Аудиокитап:*

Әхмәтҗанов Р. Сайланма әсәрләр.– Татар әдәбияты үзәге, 2018.

# I БҮЛЕК.
# «ЯҢА ТӨСЛӘР, ЯҢА БИЗӘКЛӘР»

*Рәшит Әхмәтҗановның төрле елларда*
*республика матбугатында дөнья күргән кайбер мәкаләләре*



# Үзебезнеке[1]

Чит җирдә бит йөрәк кунак кына,
Йөрәктә бит туган җир яши!

Мәкаль булып китәрдәй бу шигъри юлларны, сүз башлар өчен, Рәшит Гәрәйнең башлангыч иҗатыннан сайлап алдым. Шагыйрь турында сөйләгәндә, иң элек аның йөрәген тыңларга, йөрәге кичергән фаҗигаләрне эзләргә, кайгы-хәсрәтен, бәхет-шатлыгын барларга кирәк дип уйлыйм. Шагыйрьләр өлешенә мул тигән әлеге тере ташкыннарны барлау җиңел дә кебек һәм бик авыр да. Җиңеле шагыйрьнең бөтен барлыгы шигырьләренә иңгән була. Укы, өйрән, гыйбрәт ал. Авыры – әсәрләренә керә алмаган, керергә мөмкин булмаган, прозада гына сөйләнә алган, ләкин йөрәк аша узган иксез-чиксез вакыйгалар. Аларны белмичә торып, шагыйрь иҗатының зурлыгын да күреп бетереп булмый. Ә күреп бетермәү – бездә гадәти күренеш. Мәсәлән, тормыш гарасатларын батырларча кичкән Фатих Кәримнең соңгы еллары, соңгы көннәре турында без ни беләбез? Үз чорыбызга якынайсак – Саҗидә Сөләймановaның рухи һәм иҗади батырлыгының сере нидә? Болар турында кемнәр сөйли ала бүген? Әле телгә кергән шагыйрьләр белән беррәттән укучы Рәшит Гәрәй шигырьләрен дә бер үк дәрәҗәдә яратып укый. Әгәр мин сөйләгән теге тере ташкыннарны да шул шигырьләргә кушып укый алсак – шагыйрьләребезнең кадере бермә-бер артыр иде. Ә без, киресенчә, «укып» гомер итәбез шикелле.

Рәшит Гәрәй – шактый гыйбрәтле язмыш кичергән шагыйрь. Гомере буена үз-үзенә, халыкка тугры булып яшәү җиңел булмагандыр аңа. Җирдә кылынган бөтен гөнаһларны белә, күрә торып, ул беркайчан тормышта да, иҗатында да өметсезлеккә бирелмәде. Халык биргән сабырлык белән кешеләрне яшәргә, матурлыкка өндәде. Кара заманнарда да халык белән бергәләп кешеләр өчен яктылык эзләште. Туган җиргә булган мәхәббәте бер генә мизгелгә дә сүрелмәде.

Алсуланып кояш батар-батмас,
Ак нурларын сирпеп чыкты Ай.
И туган җир, синдә кеше өчен
Караңгылык бер дә юк бугай.

Әйе, шагыйрьләр кешеләр өчен әнә шулай яктылык эзләште. Җаннары, ай-кояш шикелле, бар кешене дә тигез күрде. Рәшит Гәрәй иҗатында бу бигрәк тә ачык чагыла. Кешеләргә тигез бүленәсе кайгыларны да үзләренә яшереп яшәгән асыл затларның яшәү кануны шундый, күрәсең.

Мин Рәшит Гәрәйне малай чагымнан ук беләм. Матбугатта чыккан һәр шигырен укып бара идем. Еллар узгач кына очраштык. Сугыш елларының бөтен ачысын ятим малай булып кичергән, мең дә бер газап белән «караңгылыктан – яктылыкка» күтәрелгән шагыйрьнең язганнары миңа якын булды.

Малай чакның авыр итеп, ялгыз гына кичерә торган тойгыларын кичергән көннәремдә, 1960 елның җәендә, Рәшит абыйдан хат килеп төште. Бер генә битлек танышу хаты. Кемдер аңа минем шигырьләр язуым турында сөйләгән, күрәсең. Сәламнәр язган һәм шигырьләремне сораган. Бу минем өчен күк капусы ачылу белән бер. Әле уйлыйм: башка кеше кырыс бу дөньяда моны эшли алмас иде кебек тоела. Шул ук елда шигырьләрем «Казан утлары» журналында басылып та чыктылар. Тормыш чакрымнары кая гына китмәсен, без хат язышып тордык. Ул миннән рухи, хәтта матди ярдәмен дә кызганмады. Бу турыда сөйләми китә алмыйм. Хәсән Туфан, Нури Арсланов, Сибгат Хәким, Зәки Нури, Гали Хуҗиевлардан күчкән игелеклелек бу. Кешене кеше итә

[1] Мәкаләләр Р. Әхмәтҗановның шәхси архивыннан алынды.– *Төз.*



**Сулдан икенче Габдулла Шәрәфи, Рәшит Әхмәтҗанов, Харрас Әюпов**

торган изгелек. Шул изгелекне күрә алмыйча күпме талантлар һәлак булды бездә. Әлеге игелеклелек халыктан килә. Остазлар аша яшьләргә күчә торганы. Остазлар гына киң күңелле булсын.

Рәшит абый тормышта әнә шундый олы җанлы, нечкә күңелле, күңелләр тугаенда һәр иртәдә җыр башлаган тургай сыман яши торган шәхес. Аның шигырьләрен әнә шул югарылыктан торып укыйм, барлыйм. Асыл сыйфатлар күп аның иҗатында. Сугыштан соң чордагы шигъриятебездә иң нечкә, иң халыкчан мәхәббәт лирикасы Рәшит Гәрәйдә. Телебезне белмәү аркасында милли хисләрне дә санга сукмаучы бүгенге композиторларыбыз өчен дистә-дистә җыр текстлары бар Рәшит Гәрәйдә. Шул сәбәпләр аркасында гына «күздән югалып» торган ул җырларның киләчәге – халык язмышы белән бергә булачак әле. Чөнки Рәшит Гәрәй иҗаты – халык иҗатының бертуганы, игезәге. Халык иҗатын зәңгәр күк белән чагыштырсаң – шагыйрь иҗаты андагы йолдызларның таңгача балкып торганы. Аның шигырьләрендә, җырларында халыкның гореф-гадәте, асыл традицияләре, яшәү максаты һәм күңел матурлыгы сыенган. Ул шигырьләр безне тәрбияли, яшьләргә гыйбрәтле тормыш дәресләре бирә. Гасырдан-гасырга сузылган халык гомеренең дәвамы менә шундадыр инде. Бәхетебезгә каршы, андый шагыйрьләребез кайгы-хәсрәттә дә, бәхет-шатлык бүлешкәндә дә һәрчак безнең белән бергә. Андый иҗат – бүгенге көнебез өчен бик тә кирәкле иҗат.

Халык шагыйрьләрне иҗатлары аша үзе сайлап ала, үз баласы була алганнарын гына. Үз баласы була алмаганнарын кире кага яки күршесенә җибәрә. Кешелек өчен, бәлки, синең хезмәтең анда файдалы булыр, дигән шикелле. Ә Рәшит Гәрәй – үзебезнеке. Ул хәтта үзенә тиешле булган, үз өлешенә тигән халык рәхмәтен дә туган як кешеләренә юллый:

Сыеныр урын эзләп йолдызлар да
Җиргә сикереп төшәр төслеләр...
Үлемнәрдән Җирне аралыйсыз,
Рәхмәт сезгә, рәхмәт, кешеләр!

# Әйтеп бетерә алмаган сүзе бар

Бүген без, халкыбызның яралы бәгырендә яткан тагын бер газиз улы – шагыйрь Фатих Кәримнең үлемсез язмышын хөрмәтләргә, аның безгә калдырган рухи васыятьләрен, кылган батырлыгын үз җаныбызда барларга җыелдык.

Чын шагыйрьләр заманалар узу белән ачыла гына баралар. Нинди генә замана килсә дә, аларның рухлары, җырлары, васыятьләре исән кешеләр белән бергә халык сайлаган хаклыкны яклап көрәшүләрен дәвам итәләр.

Бүгенге революцион яңарыш көннәрендә яшьләргә һәм картларга, халык гамен кайгыртып яшәүчеләргә һәм бу юлда икеләнеп торучыларга болай дип дәшәсе килә: Фатих Кәрим кебек шагыйрьләргә, аларның классик иҗатларына, үлемсез рухларына якынрак килегез! Алар үзләренең йөрәкләрен безгә багышлады. Алар калдырган изге мирас – безнеке. Әйдәгез, шагыйрьнең йөрәк тавышын тыңлап карыйк:

Юлбасарлар таптый җиребезне,
Ватан сугышына мин китәм.
Менә – балам. Син – әнкәсе аның,
Балабызны тотып ант итәм:

Синең өчен, шушы балам өчен,
Нәселем өчен, Туган ил өчен,
Мылтык тотып баскан җиремнән
Бер адым да артка чигенмәм...

Чигенүләргә чик куярга чакыра ул безне: бүген, иртәгә, киләчәктә.

Шагыйрь йөрәген халык тудыра. Үзенең үткәнен, бүгенгесен, киләчәген, гасырдан-гасырга исән-имин саклап килгән гамен югалтмас өчен тудыралар. Кешелек тарихы шуны раслый. Фатих Кәрим – шундый шагыйрьләрнең берсе. Шагыйрьнең йөрәге туган җиргә, аның балачагына, гаиләсенә кайтып уйланыйк әле. Әйе, аларның гаиләсенә шагыйрь дөньяга туганчы ук шигърият нуры иңгән була. Халык күңеле иҗатын балалары күңеленә иңдерүче Әнкәгә рәхмәт! Әтисе, апасы шигырьләр яза. Ә абыйсы Ярлы Кәрим – танылган шагыйрь. Фатих әнә шундый гаиләдә туа, шагыйрьлеге шуннан башлана. Бәхетле башлангыч. Туфанның, Җәлилнең, Такташның, Сибгат Хәкимнең һәм башка татар шагыйрьләренең дә юл башлары аныкына охшаш – халык күңеле кырларыннан башлана. Ә гомерләре гел көрәштән, давылдан, җанны тетрәтерлек фаҗигаләрдән тора. Шагыйрьләрнең зурлыгын да шул узган юлларыннан эзләргә, халык күңеле көзгесенә карап бәяләргә кирәктер. Шагыйрьнең үзеннән соң килгән заманнарда иҗатыниләр башкара? Көрәш һәм иҗат. Әгәр беренчесендә юк икән, икенчесендә шагыйрь булалмый, булалмыйдыр.

Туган авылында, туган туфрагында Фатих озак яши алмый. Аңа сигез яшь тә тулмаган чакта әтисез кала. Унөч яшьтә авылдан аерыла. Инде ундүрт яшьтә Казан җир төзелеше мәктәбендә җир фәнен, икмәк игү фәнен өйрәнә. Юкка гына түгелдер бу. Җаны җирсегәндер. Туган җире моң-сагыш булып, мәхәббәт булып күңелендә яшәгәнгәдер.

Егерме яшендә беренче шигырьләр китабы басылып чыга. Ул җитлеккән көрәшче булып яши башлый. Бу урында күңелдә йөргән бер уйны әйтмичә китеп булмый. Җир йөзендә шигырь барлыкка килгәнче үк, аның дошманнары барлыкка килгәндер. Алданрак туганнардыр әле алар. Юкка гынамыни дөнья халыкларының шагыйрьләре үтерелә килгәннәр.

Фатих та китабы басылып чыкканчы ук комсомолдан куыла. Юк, чигенми, яңадан комсомоллар сафына баса. Китабы чыккач, аңа «буржуага хезмәт итүче», «солтангалиевчеләр, җидегәнчеләр юлдашы» дигән нахак исемнәр тагыла. Шигырь дошманы исемнәрне сайлый белә ул. Үтерә торганын сайлап ала. Шагыйрь егерме сигез яшендә эштән куыла, егерме тугыз яшьтә инде

язылган, язылып бетмәгән һәм язылачак шигырьләре белән бергә, «халык дошманы» дигән яңа исем алып, зинданга ябыла. Аны бик күпләр кайта алмый калган сөргенгә сөрәләр. Шигырьдән, шагыйрьдән әнә шулай үч алалар. Дүрт елдан соң палачлар кулыннан котылып, могҗизалар аша гына өенә кайта һәм тагын өч атнадан Бөек Ватан сугышына китә. Иңенә ил таянырлык чагында — утыз алты яшендә, Мәскәүдән алып Көнчыгыш Пруссиягә кадәр канлы сугыш юлларын батырларча узып, безнең гаскәрләр өчен әһәмияткә ия булган биеклекне фашистлардан үз взводы белән яулап алгач һәлак була. Бу сүзләрне кабатлыйсы килә: яулап алгач һәлак була. Шагыйрьнең җисми тормышы шуның белән тәмам. Аның тән һәм җан яраларының сызлавы шунда гына туктый. Ватан үзенең солдатын — шагыйрь Фатих Кәримне һәлак булырына унөч көн кала Кызыл Йолдыз ордены белән, ә үлгәннән соң Беренче дәрәҗә Ватан сугышы ордены белән бүләкли. Шагыйрь:

Мин ант итәм: соңгы тамчы каным,
Күкрәгемнең соңгы сулышын,
Бөтенесен сиңа, сиңа бирәм,
Ватанымның изге сугышы! —

дигән сүзләрен тулысынча аклап һәлак була. Ул соңгы сугышта ике тапкыр яралана. Кулдан коралын ташламый. Димәк, ул әлеге биеклекне үләсен белеп, үләргә кирәк икәнен аңлап яулаган. Өченче — соңгы яраны аласын белгән.

Мин күбрәк шагыйрь гомеренең хәсрәтләрен искә алып үттем. Гомумән, безнең әдипләрнең гомере тоташ ялардан, сызлый торган яралардан тора. Ул чор шагыйрьләре җәзаларның иң катыларын татыды. Халык үз шагыйрьләрен саклый алмаган. Ләкин халык үзе дә шагыйрьләре хәлендә булган. Ә шагыйрь ничек үз халкыннан аерыла алсын соң! Язмыш бергә, янулар бергә, югалтулар — уртак, җиңүләр — киләчәк өчен. Тик Фатих Кәрим язмышы калганнарныкыннан үзгәрәк. Татарда бүтән андый шагыйрь юк, башка әдәбиятларда да булуын белмим. Ул үзенең «Моабит төрмәсе»нең газапларын сугышка хәтле үк татый. Читтә түгел, үз илендә, үзенекеләрдән. Төрмәдән чыгып, туп-туры диярлек шул илне сакларга, аның өчен кан түгеп сугышырга китү өчен никадәр көч, сафлык кирәк булган, мең кат пычрак куллар белән капшалган һәм ак-пакь сакланган җан булган аңарда. Сынмаган рух, дус белән дошманны аера белгән акыл, илгә-җиргә олы мәхәббәт булган шагыйрьдә.

Карбыз кебек кап урталай
Ярыр идем дә бу Җир шарын,
Ике ярымшарны бер-берсенә бәреп,
Кояр идем бөтен чүп-чарын.

Шагыйрь ул елларда менә шундый рухи зурлыкта кала. Аның бер генә минутка да илгә, дөньяга, кешелеккә мәхәббәте кимемәгән. Бу — теге башлангычтан. Сабый чакта әткә-әнкә күңеленнән тамган иман. Сакланган ул, зурайган ул, чыныккан ул. Үз иманын халык гасырлар буе канлы көрәшләр аша саклап килгән. Балаларына тапшырыр өчен. Ә балалар аны югалтамы соң! Шагыйрьнең зинданда язган бер шигырен тыңлап карыйк. Әлеге шигырьдә ул мәхәббәт җиңелмәслек булып яңгырый:

Тимер рәшәткәләр аша
Карыйм югары,
Челтәрләнә күкрәгемдә
Кояш нурлары.

Тынчу төрмәдә каршылыйм
Дүртенче язны,
Яз саен сагынып бу якка
Кайта кыр казы.

Каләм ясап каурыеңнан
Язгы ялкында,
Каныма манчып языйм бер җыр
Сөйгән халкыма.

Җырым аша белсен халкым,
Айнытсын аңын,
Дошманнар богаулап куйган
Улы мин аның.

Әй, кыр казы! Түбәнәйт тә
Очкан юлыңны,
Бүләк итеп китче миңа
Бер каурыеңны.

Атсалар да, ассалар да,
Сөйгән халкымның
Мин кояшым итеп үләм
Йөрәк ялкынын.

Атсыннар, куркытмый чөнки
Мине бу җәза,
Сабыйлар күз яше кебек,
Вөҗданым таза...

Биредә шагыйрь йөрәге, шагыйрь җаны алда булачак канлы көрәшне алдан сизенә, кеше рухы яулап алырдай иң зур биеклекне яуларга әзерләнә. Җырлары узган юллар буйлап шагыйрьнең шул көннәрен эзләп китсәң — ул ноктага килеп җитеп шаккатасың... Кеше җанының мөмкинлекләре чиксез икән!

Сугышның соңына хәтле ул алгы сызыкта, канлы бәрелешләрдә. Монда инде шагыйрь икеләтә, өчләтә көчле. Хәзер аның каршында кан дошманы, илне кол итәргә килгән дошман. Ә тегеләре түгел. Шагыйрь гел алгы сызыкта. Яралана. Бер генә түгел, кат-кат. Яралары савыгу белән, тагын алгы сызыкка — ут эченә керә. Ул — сугыш елларындагы иҗади батырлыгын эшләмәсә дә, җырларда җырланырлык батырлык күрсәткән солдат. Алгы сызыкта сугышмыйча иҗат итсә дә — үлемсез шагыйрь булыр иде.

1944 елда хатыны Кадрия Ишуковага язган хатыннан бер өзек укыйсы килә. «Минә янымда мылтык, автомат тазартып утырган иптәшләр,— дип яза ул,— сезгә үзләренең ялкынлы фронт сәламнәрен язуны үтенәләр. Бүгенге көндә минем бөтен язмышым, дөньяда яшәвем аларның мине чын иптәшләре итеп якын күрүләренә бәйләнгән. Менә минем ярдәмчем Грашин Виктор дигән арыслан кебек Саратов егете. Без аның белән ниләр генә кичермәдек. Бу ике йөрәкле егет ничә тапкыр мине үлемнән коткарды...»

Шагыйрьнең сугыштагы халәтен, аның нинди солдат, нинди командир булуын әлеге хаттан да чамалап, сизеп була. Аны үлемнән саклаганнар. Аның артыннан ут эченә — үлемгә кергәннәр. Шагыйрь, солдат, кеше шәхесе безнең күз алдында тагын да зурая.

Гражданлык батырлыгы да, иҗат батырлыгы да — аның әсәрләрендә. Алар аның каны белән язылганнар. Шагыйрьнең ике батырлыгын җентекләп өйрәнгәндә генә Фатих Кәримнең зурлыгын ачып була. Ә әлегә ничектер, Фатих Әмирхан Тукай күләгәсендәрәк торган кебек, Кәрим Җәлил күләгәсендәрәк кала бирә. Бу хәлгә Сибгат Хәким бик борчылып яшәде. Классик шагыйребез Фатих Кәримне үз биеклегенә күтәрә алганыбыз юк. Моңа без гаепле. Аның үзебезнең Казанда гына да төрле кешеләрдән билгесез әсәрләре табылып тора. Димәк, барлык әсәрләре дә бергә тупланмаган әле. Аннан, сугыш башлангач, Казан Кремле астындагы төрмәдә ике тоткын шагыйрь Хәсән Туфан белән Фатих Кәрим очраша. Алар шунда бер-берсенә үзләренең шигырьләрен укыйлар. Хәсән аганың Рафаэль Мостафинга сөйләп калдырган истәлекләреннән күренгәнчә, Фатих Кәрим төрле төрмәләрдә язган искиткеч көчле, йөрәк өзгеч шигырьләрен укый. «Ул шигырьләр,— ди Хәсән ага,— әлегә беркайда да басылганы юк. Алар, гомумән, сакландылар микән?» Шагыйрьнең билгесез әсәрләре үзләренең эзләүчесен көтмиләрме? Аннан соң шагыйрьнең бигрәк тә төрмәләрдәге тормышы, сугыштагы тормышы турында бик аз беләбез. Шагыйрь турында китаплар язган, иҗатын күп тапкырлар дөньяга чыгарган Зәет ага Мәҗитов алдында баш иеп, бу изге эшләрне аның берьялгызы башкаруын искәртәм. Ә бит Җәлилне дистәләрчә галимнәр, язучылар, эзтабар кешеләр өйрәнде. Кыскасы, Фатих Кәримнең безгә әйтеп бетерә алмаган сүзе бар. Тәвәккәл шагыйрьнең, ватандар шагыйрьнең ул сүзләрен эзли чыгарга кирәк.

Ә бүген, безнең арада Фатих Кәримнәр кебек тәвәккәлләр, алар кебек шәхесләр бармы? Бүген мин бу сорауны куймыйча булдыра алмыйм. Заманы шундый. Андый шәхесләр бар, дисәк тә, Фатих Кәримнәр сагындыра, Кәримнәр җитми. Аның илгә, сөйгән ярына, балаларына, ке-

шеләргә булган кайнар мәхәббәтеме, батырлыгымы — барыбер нидер җитми бездә. Әлеге сорауны куюым өчен кемнәрдәндер гафу үтенергә җыенмыйм. Бары утыз алты яшь яшәп, шагыйрь өч том әсәрләр, беркем дә кабатлый алмас батырлык калдырды... Җирдә үз халкының мәсләген, иманын яшәештә раслап үлде. Уйланырга кирәк. Хәзер бу яшьтә шагыйрьләребез беренче китапларын чыгара, ә шәхесен әле чамалап булмый. Бүгенге көнгә кадәр Фатих Кәрим турында истәлекләр китабы да чыгара алганыбыз юк. Казанда иң кыска урам — Фатих Кәрим урамы. Белүчеләр булмаса — әйтәм: Тукайлар, Такташлар, Каюм Насыйри урамнары тирәсендә. Аның музей-йортын кайчан ачарбыз. Музей дигәннән, шагыйрьнең пулялар белән тишкәләнеп беткән шинелен музейда күргән саен, Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәрләре» күз алдына килә. Хәсән Туфанның тоткынлыктан үзенә үлем сорап язган хатындагы сүзләр күңелгә керә һәм Тукайның «Туган тел» җыры җанны айкый башлый...

И туган тел, и матур тел! Кичер!
Балаларың синең тик ятмыйлар,—
Бер-берсеннән уздырышып алар,
Керфек какмый хәзер мал саклыйлар.

Алар шулай мал саклаган чакта,
Балаларның кемдер телен кискән.
«Кемнәр?» дисәң —
Рухи каракларның
Исемнәрен атыйк — алар исән.

Милли нигилистлар өммәтенә
Берләшкәннәр хәтер караклары,—
Таһирларны суга агызганда,
Сандыкларын шулар кадаклады.

Телне саткан көмеш тиеннәргә
Алган киемнәргә төренгәнне —
Чишендереп шәрә калдырыйк бер,
Үзе булыр — күзгә күренгәне.

Яндыр, телем,
Даным яктылыгын
Каплап торганнарның күләгәсен! —
Имансызлар хәзер ярты сүз дә
Безнең исемнәрдән сөйләмәсен.

Улларыңны уят, и туган тел!
Хәтәр чорны бергә узыйк, хәтер.
Шулай булса гына — яшәүләрнең
Киләчәккә кеше серен әйтер.

Читлекләргә яптырсаң да мине,
Мылтыклардан аттырсаң да мине,—
Бүген менә, Фатих Кәрим кебек,
Атакага мин күтәрәм сине!

И туган тел, и матур тел.

# Остаз

*(Кәшифә Тумашеваның тууына 80 ел)*

Татар хатын-кызларыннан югары белем алган беренче режиссёр, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Кәшифә Тумашева 1903 елның 7 гыйнварында Татарстанның Балтач районы Нөнәгәр авылында туа. Кәшифәне әле сабый чагында ук әтисенең якын туганнары Себергә, Өркет шәһәренә тәрбиягә алып китәләр. 1910 елда рус мәктәбенә укырга йөреп, рус теле һәм арифметика өйрәнә. Аннан соң җәдиди кызлар мәдрәсәсендә укый. Мөгаллимә булырга хыялланган яшь кыз һаман белемгә омтыла һәм Өркеттә гимназия тәмамлый.

Давыллы еллар була бу. Гражданнар сугышының Себердә дөрләп торган чагы. Яңалык өчен кулына корал тотып көрәшкән яшьләр арасында Кәшифә культура-агарту эшләре алып бара. Большевиклар оештырган җирле драма түгәрәгендә исә иң актив катнашучыларның берсе була.

1919 елның декабрь азагында канечкеч Колчак бандаларын эшче отрядлары тар-мар итәләр, ниһаять, Өркеттә совет власте урнаша. Озак та үтми, шәһәрдә беренче профессиональ мөселман театр труппасы оештырыла. Рәхим Тумашев режиссёрлыгында Ш. Усмановның «Канлы көннәр»е, Г. Кариевнең «Артист»ы һәм башка авторларның әсәрләре сәхнәгә куела. Бу спектакльләрдә баш рольләрне башкарып, Кәшифә үзен сәләтле артистка итеп таныта. 1921–1923 елларда Семипалат профессиональ татар театр труппасы куйган бик күп спектакльләрдә төп рольләрдә уйный һәм, театр, сәнгать буенча белем алу нияте белән, 1923 елда Казанга кайта: Кәшифәне Казан театр техникумына кабул итәләр. Аны ул 1926 елда уңышлы тәмамлый һәм шул техникумда укытучы булып кала. Нәкъ менә шул елларда аңарда режиссёрлык таланты ачыла. Үзенең иҗади дуслары белән берничә спектакль куюда катнаша. Радиога эшкә чакырыла. К. Тумашева режиссёрлыгында татар телендә беренче радиоспектакльләр яңгырый башлый.

1931 елда К. Тумашева Мәскәү театр институтының режиссёрлык факультетына укырга керә һәм, аны уңышлы тәмамлап, 1939 елда Татар дәүләт академия театрына режиссёр булып кайта. Биредә ул Х. Фәтхуллинның «Күзләр», Н. Исәнбәтнең «Хуҗа Насретдин», А. Әхмәтнең «Үги кыз», Д. Аппакованың «Тапкыр егет», Г. Камалның «Хафизәләм иркәм», «Беренче театр», «Бүләк өчен» пьесаларын куя. Бу вакытта инде Кәшифә ханым Тумашева татар театрларында эшләүче күренекле режиссёрларның берсе булып танылa. Ул куйган спектакльләр озын гомерле булалар, кайберләре шактый еллар сәхнәдән төшми уйналып килә. Ә «Хуҗа Насретдин», «Тормыш җыры» (М. Әмир әсәре) спектакльләре татар театрында үзенә бер вакыйга булып танылa һәм дистәләрчә еллар уйналып киләләр.

К. Тумашева татар язучылары, драматурглары әсәрләрен сәхнәләштерү белән бергә классиканы да онытмый. М. Фәйзинең «Галиябану», «Ак калфак», Жан Мольерның «Жорж Данден», А. Островскийның «Ярлылык гаеп түгел» һәм башка бик күп кенә классик әсәрләрне сәхнәгә куя. Бу спектакльләр өстендә эшләгәндә ул педагог буларак та үзенең бар белемен, талантын, энергиясен театрның яшь көчләрен тәрбияләүгә бирә. Кайсы гына театрда эшләмәсен, тынгысыз күңелле К. Тумашева иң элек армас-талмас педагог булды. 1955 елда Республика күчмә театрына баш режиссёр булып күчкәч, аның бу эшчәнлеге тагын да киңрәк күләм алды. Актёрлар белән уздырылган һәр репетиция сәнгать дәресенә әйләнә. Биредә ул сигез ел эчендә 30 дан артык әсәрне сәхнәләштерә, театр бу елларда гаять бай иҗат тәҗрибәсе туплый, үз традицияләрен булдыра, чын-чыннан үз иҗат йөзен таба, уннарча яңа талантларны үстерә.




**Укучылар белән очрашуда. Сулдан уңга (беренче рәттә): Нәби Дәүли, ?, ?, Рафаэль Мостафин, Рәшит Әхмәтҗанов**

Кәшифә ханым, режиссёр буларак, драматурглар белән дә бик күп эшли. Ш. Мәҗитовның «Резидәкәй», Г. Насрыйның «Яшел эшләпә», Х. Вахитның «Яшерен эзләр», Ш. Зәйнинең «Хәзрәт үгетләргә килә», «Таң җыры» кебек спектакльләр нәкъ әнә шундый иҗат җимешләре булдылар.

Күпчелеге үзешчән сәнгатьтән килгән яки тәҗрибәсе аз булган актёрлардан торган труппаны К. Тумашева яңа үрләргә алып менә. Н. Хикмәтнең «Сәер кеше», К. Тинчуринның «Сакла, шартламасын», Р. Ишморатның «Үлмәс җыр», Д. Юлтыйның «Карагол» әсәрләре буенча куелган спектакльләре яшь актёрлар өчен осталык мәктәбе булалар.

Татар театр тарихы бик күп фидакярләрне белә. К. Тумашева – шуларның берсе. Иң күренеклеләрнең берсе, дисәк тә хата булмас. Ул тәрбияләп үстергән уннарча талантлы актёрлар бүген театр сәнгатебезнең күгендә үзләре йолдыз булып балкыйлар һәм һәрвакыт тормышка тирән мәхәббәт белән карарга өйрәтүче, киң күңелле остазлары Кәшифә Тумашевага зур рәхмәтләрен әйтәләр, аны сагынып искә алалар.

# Матурлыкны яклап

*(Дэллюс Ильясовның тууына 60 ел)*

Сугыштан соңгы еллар. Бөтен ил сугыш җимергән хәрабәләрне торгызу белән мәшгуль. Сугыш кеше күрә, тоя алган бөтен нәрсәгә кагылган: җиргә-күккә, тәнгә-җанга, үткән көннәргә, киләчәккә...

Республикабыз театрлары да шул халәттә: бик күп талантлы артистлар фронтта һәлак булган, карт буын артистларның кайберләре тормыштан китеп барганнар. Сугыш афәте тимәсә, алар да яшәрләр, иҗат итәрләр иде әле.

Нәкъ менә шул көннәрдә, 1946 елда, Мәскәүдән, А. В. Луначарский исемендәге Дәүләт театр сәнгате институтының (ГИТИС) драма студиясен тәмамлап, республикабыз театрларына бер төркем талантлы яшьләр кайта. Сәнгать дөньясы иркен сулап куя, яңа алмашка өмет белән карый.

Бу яшь иҗатчылар арасында киләчәктә татар совет театрының данлы сәхифәләрен язышачак талант иясе Дэллюс Ильясов та бар иде. 24 яшьлек бу егет иптәшләреннән әллә ни аерылып тормый диярлек. Тик... ул инде рухи яктан корычтай чыныккан, сугыш кырларында утны-суны кичкән, күрсәткән батырлыклары өчен Ватан аның күкрәгенә Кызыл Йолдыз ордены һәм берничә медаль таккан.

Сугыш һәм сәнгать. Беренчесе – коточкыч дәһшәт, икенчесе – мәңгелек матурлык. Дэллюс, әнә шул матурлыкны яклап сугышкан кеше буларак, сәхнәдә дә үз идеалларына тугрылыклы булып кала. Балачактагы хыялы тормышка аша: ул – театрда. Ә алда – иҗат дип аталган иксезчиксез зәңгәр офык!

Иҗат юлына аяк баскан яшь актёрга таяну ноктасы кирәк. Аны төрле кеше төрлечә эзли. Күпләр ялгыша да. Дэллюс бу мәсьәләне дә солдатча хәл итә. Режиссер Гали Ильясов һәм РСФСРның атказанган артисткасы Гөлсем Камскаяларның улы булуын онытмый. Ләкин алардан яклау да көтми. Әти-әнисенә тиң иҗатчы булырга тырыша ул. Рус һәм татар телләрен камил белгән егет Бөгелмә рус драма театрына китә. Берникадәр эшләгәч, Казан Яшь тамашачылар театрына кайтып, күзгә күренерлек берничә образ тудыра. Тик аның күңеленә күптәнге олы хыялы тынгылык бирми. Аның татар сәхнәсендә – Касыйм Шамил, Хәлил Әбҗәлилов, Камал III, Габдулла Шамуков кебек атаклы сәхнә осталары арасында иҗат итәсе килә. Һәм ул моңа да ирешә. Гомеренең соңгы 30 елын Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры сәхнәсенә багышлый. Бу сәхнә аның йолдызлы күге дә, бәхет тапкан җире дә булып кала.

Д. Ильясовның иҗатын барлаганда, аның тормыш юлын күз алдына китермичә булмый. Якты таланты булу өстенә яшьтән үк зур тормыш юлы узган, яшәү тәҗрибәсе туплаган шәхес иде ул. Шуның өстенә олы сәхнә осталары иҗатының иң яхшы сыйфатларын өйрәнә килде. Ә болар үз чиратында аңа классикада һәм бүгенге көн драматургиясе әсәрләрендә бик күп якты образлар тудырырга булышты. Шулар аша актёр театр сәнгатенең югары үрләрен яулады. Ул тудырган бик күп образларга лирик нечкәлек, драматизм хас. Аның геройлары кеше күңелен ниндидер бер йомшаклык, изгелек, сөйкемлелек белән яуладылар. Еллар узу белән, аның иҗат диапазоны киңәйде. Ул бер үк осталык белән кешеләр арасында имгәк булып яшәүчеләрне фаш итүче үзенчәлекле образлар да тудырды. П. Бомаршеның «Фигароның өйләнүе»ндә – Базиль, Х. Вахит-



**Сулдан өченче Рәшит Ягъфәров, дүртенче Рәшит Әхмәтҗанов**

ның «Ике килен-килендәш»ендәге Камәретдин, Т. Миңнуллинның «Диләфрүзгә дүрт кияве»ндә Галим һәм башка образлар күңелдә әнә шул яклары белән саклана.

В. Шекспирның «Отелло»сында Родриго, М. Фәйзинең «Галиябану»сында Хәлил, Г. Боровикның «Канлы күләгәләр» әсәрендә Эрнесто Рохас, Н. Фәттахның «Кол Гали»сендә Актай, Н. Думбадзеның «Борчылма, әнием» әсәрендә Гурген һәм башка бик күп үзенчәлекле образлар тудырган артистны халык үз күрде, үзенең олы рәхмәтен әйтте. Аңа «Татарстанның халык артисты» дигән иң хөрмәтле исем бирелде.

Солдат, коммунист, халык артисты Д. Ильясовның олы үрнәге бүген аның шәкертләре иҗатында дәвам итә.

# Бер йолдызың миннән булыр...

Һәр иҗат кешесе хыялы белән күкләргә менә, җир читенә китә, иксез-чиксез далаларда йөри, узган белән киләчәк арасын бер дәрвиш булып сәяхәт кыла. Адашмый. Яшәешебезнең иң кадерле тереклеге, шигърияте булган Кеше янына әйләнеп кайта. Аның рухи матурлыгына, кылган эшләре зурлыгына сокланып илһамлана, иҗат итә. Әгәр шулай булмаса, бөек Заманга яңа бизәкләр, яңа төсләр өсти алмас иде иҗатчы. Дөнья элеккечә калыр иде, иске төсләре үзгәрмәс иде. Яңа көннәрнең, гомерләрнең кадере кеше иҗаты белән генә арта...

Мин шул уйларым белән халык артисткасы Гәүһәр Камалова өенә якынлашам. Ишекне бөтенләй таныш булмаган кыз бала ачты. Түргә уздым. Гәүһәр апа өйдә икән. Кухня тәрәзәсенең тышкы ягына асылган җим савытына җим сибә. Ул бу эш белән шулкадәр мавыккан ки, миңа аның тәрәзәсе янына җыелган кошлар белән сөйләшкәнен шактый озак тыңлап торырга туры килде.

— Дусларымны сыйлыйм әле,— диде ул тыныч кына.— Кошларда да кешеләрдә булган гадәт-холыклар бар. Карагыз әле, нинди «көрәш» бара! — дип, тәрәзәгә ымлады.

Сүзебез әнә шулай кошлардан башланып китте.

> Кеше барыбер кошлар нәселеннән!
> Төшләремдә очам кош булып.
> Ничә очып, ничә мәтәлсә дә,
> Кеше барыбер сайлый кош юлын,—

дип, онытылмас шагыйрәбез Саҗидә Сөләйманова шигырен сөйләп киттем. Урамда яз иде. Кошларның җылы яктан кайтып килгән көннәре. Гәүһәр апа тыныч кына үз фикерен белдерде:

— Кошлар туган җирләренә кайткан чакта ашкыналар, көне-төне очалар икән,— диде ул,— төнлә юлдан язмас өчен, йолдызларга карап очалар, һәм үзләренә изге саналган җиргә кайтып җитәләр. Көчсезләре генә һәлак була юлда...

Гәүһәр Камалова турында язуы җиңел түгел. Ул — сәнгать дөньясында бик тә танылган кеше. Тормышта да, матбугатта да үз иҗатына күптәннән инде бәя алган иҗатчы. Шуның өстәвенә әтисе Габдулла Камал I — классик драматург Г. Камалның иң олы энесе. Урта Азия республикаларында, Оренбургта, үзебезнең Әгерҗедә, Буада беренче милли театрларны оештыручы күренекле татар артисты, режиссёр, гомумән, сәнгать дөньясында якты эз калдырган театр эшлеклесе. Әнисе Фатыйма Камалова — Татарстанның халык, РСФСРның атказанган артисткасы, татар театр сәнгатенең нигез ташларын үз йөрәгендә, үз иңендә күтәрешкән фидакяр кеше. Гәүһәр әнә шул гаиләдә 1922 елда Ташкент шәһәрендә туа. Бу вакытта Г. Камал I — үзбәк театрында режиссёр, ә Ф. Камалова артистка булып эшлиләр. Яңа үзбәк театрын тудыруда башлап янып йөрүчеләр арасында атаклы шагыйрь-революционер Хәмзә Хәкимзадә Ниязи да була. Камалларның яңа туган кызларына Гәүһәр дигән исемне дә ул табып бирә. Шулай итеп, кечкенә Гәүһәр язмышы белән сәхнә кешесе булып туа, сәхнә артында үсә.

1935 еллар. Ф. Камалова Оренбург колхоз-совхоз театрында эшли. Әтисез калган 12—13 яшьлек Гәүһәр дә аның белән бергә сәхнәгә чыга, концертларда катнаша (әтисе 1933 елда каты авырудан соң үлә). Менә еллар үтү белән сары иңә башлаган бер фоторәсем. Күбәләк булып киенгән Гәүһәр сәхнәдә Г. Тукайның «Бала белән Күбәләк» шигырен сөйли. Бу рәсемгә карагач, Орен-

бург далаларында чәчелеп утырган иске авылларның берсендә тузанга баткан иске мәчеттә барган концерт күз алдына килә, тамашачыларның алкышлары ишетелгәндәй була.

Шул елларда Оренбург театры репертуарында ныклы урын алган «Бердәнбер бала», «Булат бабай гаиләсе», «Зәңгәр шәл» спектакльләрендә Гәүһәр малайлар ролен башкарып, тамашачылар арасында «кечкенә артистка» дигән матур исем казана.

Еллар үтә. Гәүһәр Камалова да, юллар буйлап бара-бара, иң изге саналган газиз җирен таба. Ул изге урын — халык йөрәге. Ул бүген зур хөрмәт казанган кеше — Татарстанның халык артисткасы. Адашмас өчен төнлә йолдызларга карап очкан кошларны бүген ул юкка гына искә алмагандыр, күрәсең. Бик күп якты йолдызларга карап, адашмыйча юллар узды ул. Аның тормышта да, иҗатында да төп таянычы әнисе булды. Ә инде Бөек Ватан сугышының иң авыр көннәрендә Мәскәүдә А. Луначарский исемендәге Дәүләт театр сәнгате институтының (ГИТИС) драма студиясендә укыганда, ул турыдан-туры сәнгать йолдызлары арасында яши, алардан белем ала. Студиянең җитәкчесе К. Станиславскийның талантлы шәкерте О. Пыжова һәм башкалар ярдәмендә Гәүһәр бөтендөнья классик әсәрләрендә тамашачыны сокландыра алган образлар иҗат итә алырлык артистка булып җитешә. Моңа аның гел эзләнүчән тынгысыз характеры, табигать мул итеп биргән матур буй-сыны, беркемдә дә кабатланмаган үзенчәлекле тавышы нур өстенә нур булып ярдәмгә килә.

Менә Гәүһәр Казанда. Яшь артистка тамашачылар алдында иҗади имтихан тота. ГИТИСның драма студиясен тәмамлаучы яшьләр үзләренең диплом спектаклен — М. Горькийның «Васса Железнова» әсәрен Казан тамашачыларына күрсәтәләр. Васса ролендә Г. Камалова. Буржуаз сыйныфның череп таркалуын, һәлакәтен шушы образ аша онытылмаслык итеп күрсәтә ала яшь артистка. Театр белгече Х. Кумысников Г. Камалованың Вассасы турында: «Ул — гаҗәеп көчле, нык ихтыярлы, үз дигәнен эшләмичә, теләгенә ирешмичә калмый торган акыллы хатын. Аның байлыкка гына омтылмыйча, балалары, ире, үзе турында төпле уйлары, һичшиксез, тамашачының игътибарын үзенә җәлеп итә. Тамашачы аның фикер агышын эзлекле рәвештә, эчке каршылыклар аша үскәннән-үсә баруын күрә. Тыштан караганда, героиня һаман да әле үзенең ныклыгын саклый. Аның фаҗигасе — җаны-тәне белән алга этәргән эшнең чәлпәрәмә киләчәген сизүдә»,— дип яза.

Бу спектакльне күп кенә тамашачылар хәзер дә хәтерли. Иске дөнья белән җир өстенә мәңгелеккә киләчәк яңаның үзара көрәшендә Васса — юкка чыгачак сыйныф вәкиле. Җиңелергә теләмәү аны ерткычка әйләндергән. Менә ул, агу эчереп, ирен үтерә. Васса-Камалованың һәр хәрәкәте аерым тормыш детальләреннән тора, тамашачыны ышандыра. Артистка үз уены белән тамашачылар алдында Вассаны үлемгә хөкем итә.

Шунысы кызык: әлеге образны татар сәхнәсендә иң беренче булып Фатыйма Камалова иҗат итә. Ул гынамы әле, иҗат гомерендә Гәүһәр апага әнисе тудырган байтак образларны сәхнәдә уйнарга туры килә. Әнисе иҗатына олы хөрмәт белән караган артисткага бик күп иҗади газаплар кичерергә туры килә. Ул яңа образлар иҗат итә. Үзенекеләрне. Шундый образлардан бигрәк тә Н. Исәнбәтнең «Хуҗа Насретдин» комедиясендәге Гөлбану, «Зифа»сындагы Әйшүкне калку төстә билгеләп үтәргә мөмкин.

Бөтен илгә танылган атаклы Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә Г. Камалова сиксәннән артык образ иҗат итте. Бу бит театр сәнгатенә булган гомерлек мәхәббәтнең сиксән биеклеге, төрле төстәге сиксән балкышы. Артистка меңнәрчә тапкыр тамашачылар алдына чыккан, меңнәрчә тапкыр үз образлары белән елаган-көлгән, яшәгән-үлгән. Мәхәббәт һәм нәфрәт көче белән кешеләрне яшәргә, киләчәккә чакырган. Менә ул образларның кайберләре: А. Горькийның «Дошманнар»ында бөтен яшәеше гамьсезлектән торган икейөзле Полина, «Соңгылар» әсәрендә революционер егетне тәрбияләп үстергән курку белмәс, батыр рухлы Соколова, Т. Гыйззәтнең «Чаткылар» әсәрендәге изге күңелле Газизә, М. Брэндлиның «Килен кайтты» әсәрендәге шәфкатьсез Амелия Гамельтоны, Х. Вахитның «Күк капусы ачылса» водевилендәге тамашачыны бертуктаусыз көлдерүче Шәмсия, Т. Миңнуллинның «Ир-егетләре»ндәге та-

бигатьнең үзе кебек бай күңелле Гашия, Х. Вахитның «Мәхәббәтең чын булса» әсәрендәге ил анасы дип атарлык укытучы Хәят Газизовна, «Ике килен-килендәш»ендә Бибигайшә, С. Шәкүровның «Туган туфрак» әсәрендәге илкорткыч Маргаретбану, Г. Ибраһимовның «Татар хатыны ниләр күрми» әсәрендәге коточкыч явыз, кансыз Сабира, Ч. Айтматовның «Анам кыры»ндагы сәхнә поэмасы дәрәҗәсенә җиткән Тулганай һәм тагын уннарча образлар. Беркатлылар, явызлар, хәйләкәрләр, фидакярләр, алдаучы-алданучылар, илгә-көнгә тугры булып, якты киләчәк өчен һәлак булучылар... Артистка боларны барысын да бер максатка буйсындыра – дөнья матур булсын, дөнья пакьләнсен, кешеләрнең җаны иркенлектә-иректә булсын.

Сүзебез дөнья хәлләре турында барды. Үз иҗаты турында Гәүһәр ападан тәки сөйләтеп булмады. Чираттагы спектакльләрен әзерләүдә киңәшләре белән ярдәм итүен үтенеп Гәүһәр апага Чирмешән районыннан килгән кунак кызы да күңеленнән моңа риза түгел. Бәлки, артистка хаклыдыр, һәр иҗат үзе балкырга тиеш бит, нәкъ анык кебек. Иҗатың үзе синең турыда сөйләсен.

Халык артисткасының кошларны яратканын белә идем. Ә менә кошлар турында язылган шигырьләрне яттан сөйләвен ишеткәч, яңа бер спектакль күргән кебек булдым. Күптәннән таныш тавышы бу юлы язгы җил кебек йомшак иде:

Яшер, күгем, син кошлардан давылыңны.
Миңа калдыр җыры итеп гомеремнең.
Син юлдашы, дусты булсаң гомеремнең,
Бер йолдызың миннән булыр – мин бирермен...

# Сандугач җырлап җиңә

1944 елның көзе. Кайлардадыр канлы сугыш баруын, илне-җирне кайгы басуын, кешеләр күңелендә бетмәс-төкәнмәс әрнү барлыгын үз җаннарында тоя башлаган нәни балалар, җылы кояш белән саубуллашу өчен, салкын кыш кергәнче аның нурларында озаграк җылынып калыр өчен, көн дә болын-кырларга чыга башладылар. Кырларда башак җыйдылар, болыннарда — каз канаты. Җылы якка киткән кыр казларына кул болгап, үзләре дә «кыйгак-кыйгак» кычкырып саубуллашалар. Күз очып йомганчы күктә кыр казларының яңа төркеме пәйда була. Алар узу белән, балалар күңеленә тагын бер дулкын моң, сагыш килеп бәрелә. Алар артыннан салкын кышның күңел тәрәзәләренә төрле бизәкләр чигеп, таң атар-атмас өшетеп йокыдан уянуы искә төшә. Ләкин аны алтын көзнең искиткеч бизәкләре тиз оныттыра. Нәни Флёра да балалар арасында. Ул бер генә кешене онытмый — әнисен. Әнә күрше абыйны сугышта үлгән диделәр... Ә бит аларның авылларында сугыш юк. Ә әнисе үлде. Ире сугышта үлгән күрше апа гел бер җырны җырлый:

Җилләр тарый, җилләр тарый<br>
Сибелгән чәчләремне;<br>
Җил китереп болыт ясый<br>
Түгелгән яшьләремне.

Аның да әнисе үлде бит, димәк, ул да шул җырны җырларга тиеш. Якыннары үлгән бөтен кеше дә шул җырны җырлыйдыр. Флёра, иптәш кызларыннан аерылып, авылга таба юнәлә. «Апам тиз кайтырга кушты»,— ди ул «нигә болай ашыгасың?» дигән иптәшләренә. Авылга илткән сукмак аның җанына ниндидер бер иркенлек бирә, серен бүлешә сыман, һәм ул җырлый башлый. Күрше апаның җырын үз көе белән, күрше апа җырлаганча җырлый:

Җилләр тарый, җилләр тарый<br>
Сибелгән чәчләремне...

Бу авыл сукмагын Флёра гомере буена онытмый. Чөнки аның җыры биш яшендә әнә шунда башланды. Ике абыйсы, апасы, сеңлесе белән бергә ятим калды ул шушы сугыш елында. Әниләре сугышка хәтле үк үлгән иде. Бер уйлаганда, әниләре җир өстендәге бөтен нурны, җылыны алып китте кебек иде. Юк, алай булмаган икән. Ул дөнья ямен, дөнья җылысын балаларының тигез итеп күңелләренә салган, гомерләре буена җитәрлек итеп өләшкән икән. Ятим калган балалар бер-берсен җылытып, юатып, күз яшьләрен сөртешеп үстеләр, илгә-көнгә үпкә сакламадылар, кешеләрнең начарлыгын тиз оныттылар, яхшылыкларын гомерлеккә күңелләренә салып куйдылар, исраф итмәделәр, алдагы көннәренә сакладылар. Кыр казлары ничә китеп, туган якка ничә кайттылар. Анысын санап бара алмады Флёра.

— Без үскәндә, кыр казлары моңлырак, сузыбрак кычкыралар иде,— ди ул, балачагын искә алып.

Аның бу сүзләрен раслаган сыман, бер вакыйгага да тап булды ул. Кукмара районының бер авылындагы концерттан соң сәхнәгә бер апа менде. «Кыр казлары»н бигрәкләр дә бәгырькәйләремә уеп, мине елатыр өчен, миңа карап җырладың, кызым»,— дип кочаклап алды. Аптырап калган Флёраның күзләре яшь тамчыларына чыланды, апага сиздермичә генә сөртеп алды. Ул бу концертта Әнвәр Бакировның шагыйрь Рәшит Гәрәй шигыренә язган «Кыр казлары киткәндә»

дигән җырын башкарган иде. Һәрвакыт тамашачылар белән җылы мөгамәлә табып җырлаган җырчының карашы, чынлап та, бу мөлаем апаның күзләренә дә баккандыр. Ул инде аны хәтерләми. Ә менә апа аның янына сәхнәгә менгән, аңа башкачарак, олырак мәгънәдә аңлашылган җырчының карашы һәм бу вакыйга әлеге җырның дәвамы булуын җырчы үзе генә аңлый ала. Апа сүзен дәвам итте: «Кыр казлары, илдән киткәндә, бөтен моңнарын сиңа калдыргандыр, без кайтканчы, Мәгъруфә карчыкка да җырлыйдыр, читтәге балаларын онытмаган кебек, безне дә онытмасын, дигәннәрдер...»

Мондый очрашуларның үзенә күрә бер нәтиҗәсен чыгара Флёра. Бүген дә шулай булды. Озак уйланды ул. Моңлы җыр кеше күңелендәге яраны ачмаска, ә аны дәваларга тиеш. Ул дәваны кайдан аласы, күңел ярасына ничек ябасы? Ә бит бүгенге концертта ул унбишләп җыр җырлады. Унбиш җыр. Күбесе халык җырлары. Халык җырларын җырлыйсың икән, калганын да халыктан эзләргә, халыктан табарга кирәк. Дәва булырлык моң... Аны табу өчен халык кебек яна, шатлана, елый алырлык җаның булсын. Җырчы өчен дөньяда башка бәхет юк. Була икән — җырда түгел... Ничек соң әле бу җырда иртәрәк уйланмаган ул?! Югыйсә бит үз остазларыннан иң беренчесе Сара апа Садыйкова андый моң турында еш кабатлый иде. «Кешеләр җыр тыңламыйлар, моң тыңлыйлар»,— дия иде.

Флёра, авылдан Казанга килеп, киез итек фабрикасына эшче булып урнашты. Үз җыры аны «Спартак» клубы каршында эшләүче хорга алып килде. Ә анда мәңге арымас-талмас, изге күңелле, кырыс та, шатландыра да белүче композитор Сара Садыйкова хорга җитәкчелек итә. Талантлы һәр кешегә хөрмәт белән караучы, һәр талант иясен бөтен рухы белән яклаучы Сара ханым Флёраны чын-чынлап җырларга өйрәтә башлый, беренче музыкаль белемне бирә. Дүрт ел дәвам итә ул дуслык. Дүрт елдан соң Сара ханым үзенең укучысын олы сәхнәгә чыгарырга тырыша, аңардагы талантны, ихтыяр көчен исәпкә алып, билгеле.

1960 елның март ае. Казахстанның Актүбә һәм Алма-Ата дәүләт филармониясендә озак вакытлар эшләячәк татар артистлары бригадасына талантлы яшьләрне җыялар. Бригаданың җитәкчесе итеп халкыбызның атаклы гармунчысы Г. Вәлиев билгеләнә. Гомерен сәхнәдә уздырган талантлы музыкант башка республикада эшләргә тиешле артистларның беркем алдында да йөз кызартырлык булмаска тиешлекләрен, татар сәнгатенең йөз аклыгы булырлык талантлы кешеләр булуын беренче шарт итеп куя.

Сара апасы, Флёраның ай-ваена карамыйча, комиссия каршына кулыннан җитәкләп алып килә аны. Һәм монда Флёраның бәхете җиңә, аны профессиональ сәхнәдә җырчы-солистка булып эшли ала дип табалар. Юк, «бәхете җиңә» дип әйтү урынлы түгел сыман, аның табигатенең үз бизәкләре кебек матур тавышы җиңә. Шулай итеп, Кама Тамагы районының Иске Барыш авылында туып үскән ятимә кыз олы сәфәргә кузгала. Казахстан далаларының чиге юктыр сыман тоела аңа. Барасың-барасың — таш та кылган... Онытканда бер ун-унбиш өйле авыллар очрый. Кешеләр булмаганга гына бу далалар ятим дип уйлый ул күңеленнән, кешеләр булса, чәчәктә утырырлар иде. Һәм кинәт аның күз алдына үз язмышы килеп басты. Авылда, Казанда калган бик күп кешеләрне сагыну иде аның күңелендә, һәм менә ул дөньядагы иң «яшел шәһәр» Алма-Атада. Гаҗәеп киң күңелле, эчкерсез казах халкын үз итеп, яратып өлгерде. Инде Казанда ук әзерләнгән репертуарына берәм-берәм казах җырларын кертә башлады. Казах, рус, татар һәм башка милләт вәкилләрен берләштергән тамашачылар аның җырлавын яратып тыңлыйлар. Тамашачыдан бернине дә яшереп булмый. Үзеңнән талантлырак иптәшләрең артына качып яки сыенып булмый сәхнәдә. Флёра моны бик тиз аңлады һәм җырчы кешенең һәр көне иҗат утында яну булырга тиешлегенә ианды. Тамашачыга ошарга тырышу, бер көнлек уңыш артыннан кумады. Үз иҗатын булдыру өчен тырышты. Елыйсы урында көлмәде, көләсе урында еламады. Биредә аңа балачагыннан тәрбияләнгән сары алтыннан да кыйммәтрәк сабырлыгы ярдәм итте.

1962 елда эстрада артистларына бөтенсоюз аттестациясе уздырыла. Флёрага да «СССРның эстрада сәхнәләрендә чыгыш ясау хокукы бирә» дигән таныклык бирелә. Беренче тапкыр җырчы әнә шул көнне шатлана. Казахстан филармониясендә өч елга якын эшләгәннән соң, ул туган як-

ларга кайта. Татарстанның халык артисты, җыр сәнгатебезнең зур остасы Усман Әлмиев җитәкчелегендә күршебез Ульяновск өлкәсендә эшләүче татар артистлары бригадасында берничә ел эшли. Һәм менә Флёра Сөләйманова — Татар дәүләт филармониясе җырчысы. Биредә аны зур сынаулар көткәнен белми әле. Тырышып иҗат итә. Композиторлар һәм шагыйрьләр белән бергәләп яңа җырлар тудыруда катнаша, халык көйләреннән матур репертуар төзи, сәнгать дөньясында көннән-көн таныла бара. Һәм кинәт аның бик тә үзенчәлекле тавышы филармониянең шул чор җитәкчеләренең кайберләренә ошамый башлый. Флёра сәхнәдән китәргә мәҗбүр була. Инде халык җырчысына әйләнгән иҗатчының биографиясендәге бу мизгелне искә алмаганда да ярый иде. Гыйбрәт өчен булсын, дибез. Арабыздагы һәр талант иясенә хөрмәт белән карарга, аның талантының халыкныкы икәнлеген онытмаска тиешлегебезне искәртеп кенә кузгатуыбыз.

Флёра Казан радиосына эшкә килә. Монда да ул үзенә иҗади дуслар таба. «Сандугач җырлап җиңәр» диләр аңа дуслары. «Җырла, Флёра»,— дип, аның рухына көч өстиләр кешеләр. Радионың үз музыканты, Татарстанның атказанган артисткасы Екатерина Соколова белән иҗади дуслар булып китәләр. Иртә-кич репетицияләр ясала, яңадан-яңа җырлар өйрәнәләр.

Флёра Сөләйманова радиодан башкарган җырлар халык арасында таныла, тарала башлый.

Җ. Фәйзинең «Гөлшаһидә җыры», «Сагыш», М. Макаровның «Мәк чәчәге», Ә. Бәшировның «Әйткән идең», Р. Яхинның «Салагыш болыннары», Ф. Әхмәтовның «Тамчылар тамар чаклар», тагын уннарча халык җыры Ф. Сөләйманованы халык арасында киң танылган җырчы-иҗатчы итәләр. Татарстан радиосында аның нәкъ шул елларда башкарган илледән артык язмасы бар. Мәскәүдә ул башкарган җырларның пластинкалары чыга. Композиторлар, музыка белгечләре халык җырларын аның тавышы аша язып алалар.

Атаклы композитор Җ. Фәйзи халык җырларын зур концерт залларына күтәрүчеләр турында үзенең «Халык җәүһәрләре»[1] исемле китабында: «...Зифа Басыйрова, Әлфия Авзалова, Габдулла Рәхимкулов, Флёра Сөләйманова кебекләр исә, профессиональ җырчылык алымнарын үзлекләреннән өйрәнеп, халык көйләрен оста башкаручылар булып танылдылар»,— дип язган иде. Ф. Сөләйманова талантына зур хөрмәт, ышаныч белән караган Җ. Фәйзи әлеге китабына туплаган җырларның шактыен Ф. Сөләйманова башкаруында язып ала.

Моннан ун ел элек РСФСРның атказанган, Татарстанның халык артисты, халык көйләрен классик башкаручы Илһам Шакиров үзенең шәкерте Ф. Сөләйманова турында «Азат хатын» журналында: «...Ул хәзер халыкның иң яраткан җырчыларыннан берсе. Флёраның тавышы моңлы, йомшак. Холкы да тавышы кебек сабыр, тыйнак. Талант, саф чишмә кебек, барыбер үзенә юл таба икән»[2],— дип язып чыккан иде. Остазының бу сүзләрен чын мәгънәсендә аңлаган хәлдә, бүген «халык җырчысы» дигән исемгә лаек булып, киң колач белән иҗат итә. Халык җырларын башкаруның иң кирәк серләренә төшенеп (ә бу бәхет барлык җырчыларга да эләкми), үзе җырлаган җырны яңа интонацияләр белән баетып, яңа моңга төреп, сөйгән халкының үзенә кайтарып бирә. Гастрольләрдә йөргәндә, халык җырларын җыя, әгәр сүзләре булмаса, шагыйрьләрдән көйгә лаек булырлык сүзләр яздыра һәм әллә кайларда адашып калган көй яңадан туа, халыкка барып җитеп, кешеләр язмышына ачылып керә, яңа тормышта яши башлый. Ул башкарган халык җырларын санап күрсәтүнең биредә һич тә кирәге юк. Җырчының бөтен иҗаты халыкның үзендә диясе килә. Шуны исбат итеп, җырчы адресына тамашачылардан, җыр сөючеләрдән бик күп хатлар, рәхмәт сүзләре килә. Үзбәкстанның Маргелан шәһәреннән С. Муллагалиев үзенең рәхмәтен шигъри юлларга сала:

Канатыма куәт бирде җырың,
Җырлы минем яхшы көннәрем.
Рәхмәт сиңа — минем күңелемдә
Ак күгәрчен булып гөрләдең.

Синең җырсыз яши алмам җирдә,
Җырсыз ничек гомер үткәрим? —
Кил әле, кил, сайра, сандугачым,
Талың белән күккә күтәрим.

[1] *Фәйзи Җ.* Халык җәүһәрләре.— Казан: Татар. кит. нәшр., 1971.— 27 б.
[2] «Азат хатын» журналы.— 1973.— № 2.— 18 б.



**Сулдан уңга: Газиз Мөхәммәтшин, Саимә Ибраһимова, Гомәр Бәширов, Рәшит Әхмәтҗанов**

Ә менә Пермь өлкәсеннән Язилә Садыйкова, якты дөньяны күрә алмавына карамастан, күңелен төшермәвен, аның җырлары белән рухланып яшәвен яза.

Татарстанның халык артисткасы Вафирә Гыйззәтуллина узган ел «Социалистик Татарстан» газетасында кешелеге һәм иҗаты белән үрнәк булган Ф. Сөләйманова турында: «Мин Флёра Сөләйманова җырларын, чыннан да, сабый чактан ук ишетеп, аларга сокланып, шулар биеклегенә омтылып үстем. Ул үз тавышы белән оста идарә итә, чишмә суы челтерәп аккан кебек, тигез ләйсән төймә шикелле халык моңын күңелләргә китереп җиткерә. Халык аны бик ярата, ихтирам итә. Безнең якларга Флёра Сөләйманова тизрәк килсен иде»[1],— дип, сәламнәр җибәреп калалар,— дип язып чыккан иде.

Бик тә сабыр холыклы, җырлары кебек саф күңелле, кешелекле булган җырчыга карата әйтелгән бу сүзләрне бик күп иҗатчылардан ишетергә мөмкин.

«Үз-үземне белә башлаганнан бирле җырлыйм, кешеләргә дигән иң матур җырымны таба алганым юк сыман әле,— ди Флёра.— Һәр елны ике йөздән артык концертта җырларга туры килә. Репертуарны баетып, аңа яңа шигъри бизәкләр өстәп тормасаң, үзең өчен күңелсез була, яшәүдән тукталгандай хис итәм үземне».

Җырчының бу сүзләре безнең бөтен яшәешебезгә кагыла түгелме соң? «Җырчының һәр яңа җыры — яңа бизәк булырга тиеш». Татарстанның атказанган артисткасы Флёра Сөләйманова әнә шулай ди. Дөньяны ямьләүче яңа бизәк.

Болында каз канаты җыеп йөргән сабый көннәреннән үк күңелендә туган уйдыр бу.

*«Социалистик Татарстан» газетасы*

[1] «Социалистик Татарстан» газетасы.— 1982.— № 57.

# Җырга әверелгән гомер

Февраль ае — Муса Җәлил ае булды. Тууына 80 ел тулуга багышланган тантаналар — чорыбызның рухын чагылдыручы, кеше күңеленең уяулыгын арттыручы шигърият бәйрәмнәре булып узды. Мәктәпләрдә, авылларда, югары уку йортларында башланган әлеге бәйрәмнәр зур шәһәрләрнең сәхнәләренә күтәрелде, Җәлил көннәре әле дә дәвам итә. Аның солдат һәм шагыйрь буларак күрсәткән батырлыгы халкыбыз тормышында әнә шулай яңарып, кабатланып тора, Җәлил бөтен барлыгын тормышта үзе раслый, кешеләргә җиңүләр юлаша.

Җәлил турында һәркем үз фикерен тудырсын, үзенчә рухлансын. Җәлилнең батырлыгы моңа лаек.

Ә хәзер сүзебез шагыйрьнең Татар дәүләт опера һәм балет театрында узган юбилей кичәсендә күрсәтелгән «Җырларым» дигән шигъри-музыкаль спектакль турында. Аны карагач, шагыйрьнең «Хат ташучы» поэмасы, «Алтынчәч»е хәтердә яңарып, үлемсез «Моабит дәфтәрләре»н яңадан укырга чакыралар. Алдагы ике әсәрен язып бетергәч, ул әйтерсең лә «Моабит дәфтәрләре»н язарга җыенган. Җәлилне тик шулай күзаллап була. Моның шулай икәнен тормыш үзе дә раслады. Спектакль исә әнә шушы раслауның бер чагылышы булды, диясе килә. Күптөрле сәнгатьләр катнашкан мондый спектакльләрне бик сирәк күрәбез. Олы бәйрәмнәрнең сәнгать өлеше буларак кабул ителә алар.

...Менә залда ут сүнә. Җанны кузгатучы музыканың беренче аккордлары ук «Батырлык турындагы поэма»ның кульминацион ноктасына чакыра шикелле. Музыкага ярдәмгә прожекторның төрле нурлары килә. Алар кешеләр өчен кешеләрнең барысы да аңлап бетерә алмаслык батырлык эшләгән шәхесне — шагыйрьне эзлиләр. Тамашачы аны күрергә ашыга.

Артист Тәлгать Юсупов бөек җанлы көрәшче турында С. Вургунның безгә таныш сүзләрен кабатлый, һәм бу сүзләр спектакль башында ук Җәлилне Байрон, Петефи, Юлиус Фучиклар белән бер рәткә куя. Аңлы рәвештә эшләнгән бу олылык спектакльгә алдан ук зур миссия йөкли. Димәк, бөек шәхесләр югарылыгында барырга, шул биеклектән төшмәскә тиеш ул. Җәлилне тик шулай гына күрсәтергә мөмкин. Спектакльне әзерләүчеләр үзләренә шундый бурыч куйганнар.

Тын да алмый сәхнәне күзәтәбез. Музыка көчәя, бөтен залны биләп ала; узганны хәтерләтеп, күңелләрне киләчәккә чакыра. Пәрдә ачыла. Зәңгәр киңлекне хәтерләткән сәхнәнең югары өлешендә, тормыш һәм шигъриятнең югарылыгына менгән шикелле, халык тарафыннан Җәлилгә куелган һәйкәл һәм аны Мәңгелек утның кан төсле алсулыгы балкытып торуы безнең күңелләрдәге барлык хисләрне, уйларны, шигырьләрне, поэмаларны уята, терелтә шикелле. Спектакльнең сценарие беренче карашка гади генә төзелгән. Әмма андагы драматик вакыйгалар Җәлилнең бөтен көрәш һәм иҗат юлын үзенә сыйдыра алган. Автор ике кеше — шагыйрь (РСФСРның атказанган артисты Ю. Федотов) һәм аның хатыны (артистка А. Илһамова) образлары аша Ватанны фашизмнан азат итүче фидакярләргә һәйкәл куярга омтылган һәм теләгенә ирешкән, дия алабыз. Моның өчен ул, әлеге ике образны һәр күренештә үстерү, рухи олылык бирү өчен, бик күп символик образлар, сәнгатьнең башка күп төрләрен куллана: балет, опера, ялгыз җыр, нәфис сүз, музыкаль баллада, кинокадрлар һ.б. Драматик моментлар мәгънәле, максатлы рәвештә бер-берсенә ялгана, һәм сәхнәгә зур сәнгать күтәрелә. Шулай булганда, кечкенә бизәкләр дә ачыграк күренәләр. Спектакльнең төп өлеше әнә шундый югарылыкта барды.

Образларны тоташтырган халык музыкасы, халык җырлары, халык биюләре шагыйрь образын бер генә минутка да халыктан аермый, соңгы минутына хәтле аның рухы халык рухы белән бербөтен булып кала. Спектакльнең төп уңышларыннан берсе әнә шунда. Талантлы җырчыларыбыз З. Сөнгатуллина, Х. Бигичев, Ю. Борисенко. М. Якупов, Э. Җәләлетдинов, В. Ганиева һ.б. башкарган җырлар спектакльнең бер кисәге буларак кабул ителделәр, бүгенге җыр сәнгатебез йолдызлыгында бөтен төсләрдә балкыдылар. Спектакльдә йөзләгән кеше катнашты. Алар белән «дирижёрлык» итүче кеше – сценарий авторы һәм спектакльнең режиссёры РСФСРның һәм ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе И. Мәҗитов булды. Бу эштә тәҗрибә туплаган кеше. Бу юлы да уңышка ирешкән, диясе килә...

Ләкин спектакль соңындагы кайбер «кытыршылыклар» турында әйтми китү аларны үз күңелендә калдыру булыр иде. Мәсәлән, шагыйрь образын иҗат иткән артист Ю. Федотовка җитдилек, рухи олылык җитенкерәмәде шикелле. Җәлилнең шәхси трагедиясен, шагыйрьнең драматизм тулы язмышын ачып бетерә алмады, дигән тәэсир калды. Уңышлы тәмамланган финалда сәхнәгә, Җәлил җырлары булып, тормышның якты символлары булып, балалар йөгерешеп чыкты. Шул балаларны каплап ук диярлек биюләр башланды. Тантана хөкем сөргән минутларны кыскарткан ул биюләр кирәк иде микән?

А. Илһамова шагыйрь хатынын, Ватан-ана образы итеп, гаять шигъри итеп башкарды. Шагыйрьнең җырларын гәүдәләндерүче балериналар биюе һәм спектакльне спектакль итүче уңышлы кулланылган башка сәнгать чаралары Җәлил образын тулыландырып торганга, төп образ күңелләргә якын, кадерле булып калды.

*«Социалистик Татарстан» газетасы.– 1986. – 27 февраль*

# Ташламыйк балаларны![1]

Сөекле шагыйребез Сибгат Хәким моннан күп еллар элек үзенең көндәлек дәфтәренә Казан мәктәпләренең берсендә балалар белән очрашуы турында язып калдырган. «Тыңламыйлар,— дигән ул,— чөнки телнең эченә керә алмыйлар... Шуннан соң берничә ай яза алмадым. Яңадан андый мәктәпләргә бармаска сүз бирдем. Бу үз телең ни рәвештә бетүен карарга бару иде. Рәхмәт, яңадан карыйсым килми...»

Бу юлларны укыгач, шагыйрьнең ул чактагы хәлен аңларга була. Сулышы кысылган аның, бәхетен югалткан ул әнә шул минутларда. «Үз телеңнең ни рәвештә бетүен» күреп тору — әнкәңнең үлемен кичерү белән бердер ул. Юкка гынамыни туган телне Әнкә белән чагыштырабыз...

Шагыйрь бу хәлдән соң да мәктәпләргә йөрде, балалар хакын хаклап яшәде. Ләкин югарыда искә алынган кичерешләр белән... Бүген без андый мәктәпләргә барабызмы? Барсак, ниләр алып барабыз? Әллә үзара борчылып сөйләшүдән уза алмыйбызмы? Хәрәкәт, агым, эшләнгән эш күләме ни хәлдә?

Сүз уңаенда, халкыбызда яшәгән, буыннан-буынга тапшырылып барган бер гадәт турында искә алып үтәсе килә. Кеше сәфәр чыгамы, илне якларга яуга китәме, яки бөтенләй тормыш белән саубуллашамы — аның калганнарга, якыннарына бер генә васыяте бар: «Балаларны ташлама!» — ди ул. Бу васыятьнең безгә дә әйтелгәнен бер генә минутка да онытмыйк. Онытулар өчен шактый кыйммәт түләдек инде һәм түләргә туры килә әле...

Без, иҗат кешеләре, бүген мәктәпләргә, балалар янына барабызмы, ниләр алып барабыз? Әйдәгез, балаларга якынрак килик, сөйләшик әле.

Сүзгә җырчы Гөлзадә Сафиуллина белән композитор Риф Гатауллин да кушыла. Алар Казанның 3 нче урта мәктәбендә узган былтыргы бер очрашулары турында искә алалар. «Исәнмесез» белән «хушыгыз»дан башкага теше үтмәгән балалар янына баруларын алдан белә алар. Әзерлек белән баралар. Кунакларны ишек төбендә каршыларга куелган пионерлар белән үк саф татарча сөйләшү башлана. Балалар елмаюы узачак кичәнең сокландыргыч увертюрасына әйләнә:

— Исәнмесез, балалар!

— Исәнмесез! — диләр алар хор белән.

Җырчы шундагы бер малайдан ничәнче класста укуын сорый. Малай:

— Эдик,— дип җавап бирә.

Ә күп кенә сорауларга эчкерсез һәм оялчан елмаюлар яки бөтенләй дәшми калулар гына «җавап» була...

— Эдик белән без шул кичәдән соң дуслашып калдык,— ди Гөлзадә,— киләсе очрашуда бары тик татарча гына сөйләшергә сүз куештык. Быел ул мәктәптә тагын очрашу булды. Балалар белән җырлар җырладык, биедек, түгәрәк уеннары уйнадык, табышмаклар әйтештек, хәтта әкият сөйләүчеләр дә булды. Эдигыбыз чынлап та татарча сөйләшергә өйрәнгән.

— Андый мәктәпләрдә бер тапкыр очрашу уздырсаң, икенче тапкыр бармый кала алмыйсың,— дип, Риф Гатауллин Яшел Үзән шәһәренең 1 нче мәктәбе турында сөйләп китте.— Узган ел барган идек. Кичәбез балалар бәйрәменә әйләнде. Ә быел безне тагын чакырдылар. Бу очрашу үзгәрәк узды. 29 сентябрьдә шәһәрнең унбер мәктәбеннән дә укучылар М. Горький исемендәге культура сараена җыелганнар иде. Туган тел бәйрәменә әйләнеп китте бу кичә. Бәйрәмнәрнең

[1] Бу мәкалә шагыйрь Фәнис Яруллин (1938—2011) белән берлектә язылган.— *Төз.*

шул рәвешле кабатлануы безгә өр-яңа фикерләр бирде. Бу кичәләрдә балалар үзләре дә теләп катнашты. Ләкин һаман җанны бернәрсә борчый әле. Шигырьләрне, такмакларны, әкиятләрне татарча сөйләсәләр дә, җырлары – русча гына. Балалар белән бергәләп «Туган тел»не җырлаганчы, аларны рухи яктан бу мизгелгә әзерләргә, күңелләренә кереп, дөньяларына сибелергә, моң булып таралырга кирәк. Бу уңайдан шуны әйтәсе килә: әлеге очрашуларда без ата-аналарның да катнашуын телибез, аларны да чакырабыз. Андый очрашуларда гаилә конкурслары оештырабыз, ягъни кем үзенең әти-әнисе белән матуррак җырлый, кайсы гаилә матуррак бии. Җиңүчеләргә үзенә күрә бүләк тә әзерлибез. Очрашуларга барганда, һәрвакыт балалар китаплары, төрле сувенирлар алырга онытмыйбыз. Шәһәребезнең Совет районы мәктәпләрендә узган мондый кичәләрдә катнашкан ата-аналар балалар күңеленә нинди юллар белән милли хисләрне иңдерергә кирәк икәнен белеп китүләрен әйттеләр. Мондый кичәләргә барганда, репертуарыбызны өр-яңадан барлап, халыкның бетмәс-төкәнмәс рухи байлыгына – халык иҗатына таянабыз. Балалар өчен иҗат иткән җырларыбыз байтак инде. Җыр белән биюне бергә бәйли торган җырларыбызның берсе – «Без биибез». Аның сүзләрен халык язучысы Нәкый ага Исәнбәтнең «Балалар фольклоры» исемле китабыннан эзләп таптык. Китаптагы җырлар, такмаклар үзләре көй сорап торалар, һәм бу җырны башкарганда, бии белмәгән баланың да бии башлаганына күп мәртәбәләр шаһит булырга туры килде. Г. Тукайның «Кызыклы шәкерт» шигыренә язылган җыр, мәсәлән, халыкның элеккеге тормышына алып кереп китү өчен, Тукайлар, Гафурилар яшәгән көннәргә сәяхәт итү өчен кирәк иде. Шундый җырлардан соң балаларга Тукай иҗаты да якыная төшә.

Бу юлларны язучыларның берсенә, Г. Сафиуллина һәм Р. Гатауллин белән бергә, Казанның 87 нче мәктәбендәге сәнгать бәйрәмендә катнашырга туры килде. Бу сәнгать бәйрәме, килергә тиешле артистларның, язучыларның килмәүләре аркасында, бер тапкыр булмый калган икән инде. Алдагы көндә сөйләшкәндә, мәктәпнең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Асия Фәттах кызы Борһанова:

– Сез дә килми калып, бәйрәм булмый калса, балалар күзенә күренә алмам инде,– дип, бөтен барлыгы белән инәлгән иде.

Бәйрәмгә Гөлзадә белән Рифне дә чакырдык. Берсүзсез риза булып, алар балалар өчен тагын бер шефлык концерты бирделәр. Нинди генә концерт әле!

Әгәр бу кичәдә Гөлзадә белән Риф булмаса, балалар безне аңламый дип, күңелебездә балаларга нindидер рәнҗү дә калган булыр иде, мөгаен. Күреп тордык, балаларга без сөйләгәннәр барып җитмәде. Менә сәхнәгә Гөлзадә белән Риф чыкты. «Без биибез» җыры яңгырады. Үзенә күрә нәни бер спектакль сыман булды ул. Җырчыны хуплап, балалар җыр барышында ук кул чаба башладылар. Йөзләргә елмаю, шатлык бәреп чыкты. Әти-әниләрнең куанычы чиксез иде. Җырны сәхнәгә менгән балалар белән түгәрәкләнешеп, җырлап биеп кабатларга туры килде. Аннан композиторның Р. Миңнуллин сүзләренә язган шаян җырлары – «Өлкәннәр», «Энекәш кирәк миңа», халык җыры «Күгәрчен гөрлидер» һ.б. җырлар аша җырчы балалар белән бөтенләй дуслашып бетте, мәгънәви дуска, юлдашка әйләнде шикелле.

Аннан табышмаклар әйтешү, мәкаль-әйтемнәр аша узышу башланды. Җырчы, сәхнәдән торып, балаларга әдәбиятыбыз, сәнгатебез турында, халкыбыз турында уннарча сораулар бирде. Һәр бала җавап эзләде, аларга әти-әниләре булышты. Бергәләп җавап бирделәр. Җиңүчеләргә җырчы алып килгән матур китаплар, «Казан утлары», «Ялкын» журналларының яңа саннары бүләк ителде. Бу кичә өч сәгатьләп дәвам итте. Ата-аналарны гына түгел, көнаралаш кичәләрдә катнашкан әдәбият кешеләрен дә тирән уйга салды ул.

Шушы урында Гөлзадә Сафиуллина катнашында узган икенче бер кичәне искә алып китү уңышлы булыр. Бу кичәне күпләр карагандыр, мөгаен. Чөнки ул телевидение аша быел көзен генә күрсәтелде. Яңа Рәҗәп урта мәктәбенең «Кече артек» дип аталган пионер лагереннан үзенә күрә музыкаль бер репортаж кебек булды ул. Монда түгәрәк уеннар, табышмак әйтешүләр, төрле шаян такмаклар, тапкырлыкта сынашулар – барысы да бар иде. Җырчы үзенең фантазиясен,



**Әлфия Авзалова, Риф Гатауллин, Гөлзадә Сафиуллина һәм Мөдәррис Әгъләмов**

бөтен сәләтен биреп эшләде. Беренчедән, җырчының балалар белән шундый табигый рәвештә контактка керүенә, һәркемгә җайлы тел ачкычы табуына сокланып утырсаң, икенчедән, балаларыбызның халык авыз иҗатын, туган телне әйбәт белүе күңелдә канәгатьлек хисе калдырды. Менә шундый кичәләр төрлерәк, тагы да кызыклырак һәм күбрәк булса, балаларыбыз күңеленә җыр аша, моң аша халкыбызның бай фольклоры, туган телебезнең кадерле аһәңнәре тирәнрәк үтеп керер иде.

Менә ич, югалтканны табып була икән ләбаса. Моның өчен иҗади эзләнү, тырышлык һәм үз-үзеңне аямау гына кирәк. Тирән ышанып әйтергә мөмкин – бүген балалар күңеленә ачкыч таба алган җырчының киләчәктә тамашачысы бетмәячәк. Күңелгә салынган милли моң – телебезгә ачкыч ул.

Кемнәрдер, өметсезлеккә бирелеп, туган тел бетә, дип, аһ-ваһ килеп йөргәндә, Гөлзадә белән Риф тыйнак кына, бар дөньяга кычкырмыйча гына эш эшлиләр. Җырчы белән композитор балалар белән аралашудан үзләренә шатлык табалар, иҗатларын баеталар.

Кичәләр узгач, саубуллашканда, балалар һәрвакыт: «Хушыгыз! Кабат очрашканга кадәр!» – дип калалар. Бу аларның «Безне ташламагыз!» дигән иңрәү тавышлары булып ишетелә сыман. «Балаларны ташламагыз!» дигән ана тавышы булып, безгә туган телебез үзе дәшеп кала шикелле.

*«Социалистик Татарстан» газетасы. – 1988. – 25 октябрь*

# Иртәнге матурлык

Казан бик иртә уяна. Иртәнге сәгатьләр әле зәңгәр караңгылык кочагында була. Кешеләр инде, ак карны шыгырдата-шыгырдата, каядыр ашыгалар. Беренче күренгән трамвайларга, троллейбусларга утырып, шәһәрнең төрле якларына таралалар.

— Хәерле юл сезгә, хәерле көн! — дим мин аларга.— Физик һәм рухи көчебез тормышны ямьләсен, иминлекне сакласын. Хезмәтебез бетмәс-төкәнмәс тере чыганак булсын — бәхет табыйк, кешеләргә бәхет өләшик. Иртәнге матурлык — көн матурлыгы булып, көн матурлыгы — гомер матурлыгы булып сузылсын...

Бу матур иртәдә, әйдәгез, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының яшь артисткасы Алсу Гайнуллина белән танышыйк.

«Танышыйк» дип әйтү сәеррәк тә кебек. Чөнки Алсуны театрда һәм телевизион спектакльләрдә тудырган дистәгә якын образлары аша күпләр белә. Аның матур уенын күпләр яратып өлгерде.

Бик иртә килүем өчен уңайсызланыбрак ишек шакыйм. Артистларның кичке спектакльдән ярты төнне генә өйләренә таралышулары да истә.

Киң булып ишек ачыла. Алсуның кулында кәгазь битләре.

— Улымны уятырга, бакчага илтергә иртәрәк әле. Азрак йокласын дип торабыз,— ди ул, елмаеп.— Менә яңа пьесадан бирелгән ролемне өйрәнеп утыра идем. Шулай иртә тормасаң, көннең узганын сизми дә каласың.

— Ярар, иртә уянганнарның гомерләре озынрак була диләр,— дип шаярта аны тормыш иптәше.

— Матуррак була,— дип өстим.

Әйе, Алсуның матурлык турында күп уйланганы бар. Булганын энҗе бөртегедәй саклап, булмаганын бөртекләп җыйды ул күңеленә матурлыкны. Балачактан ук җырны, шигъриятне яратты. Тормышны да шигърият аша күрде, шуның белән яши башлады. Һәм матур итеп яши.

Һәр көнне диярлек йөзләрчә тамашачыларга үзе тудырган образлары аша матурлык турында үз сүзен әйтә ул.

Менә бүген дә таңнан торып эшкә утырган. Озакламый театрга репитициягә барырга кирәк. Телевидениедән бүген үзенә тапшырылган рольнең текстын кереп алуын үтенгәннәр. Кичен спектакльдә баш рольне уйныйсы бар.

...Таң белән ак карларны шыгырдатып ашыга-ашыга атлаган кешеләрне искә алам. Алар арасында яшь артистка Алсу да атлый. Аның хезмәте әнә шул кешеләр өчен кирәк. Алсу моңа шатланып туя алмый. Бөтен хыялы — замандашларының образларын, язмышларын сәхнәдә яктырту. Якты уйлар белән яшәгән артисткага язгы бәйрәм көнендә яңа иҗат шатлыклары телик.

*«Татарстан яшьләре» газетасы.— 1979. — 8 март*

# Сандугач

*(Иҗат портретына эскизлар)*

Сәхнәдә Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле концерты бара. Тамашачылар каршына озын зифа буйлы, ачык карашлы җырчы кыз чыгып баса. Үз-үзен тотышындагы гадилек, иркенлек, нәфислек аңа килешеп тора.

Тамашачы тынып кала – җаннарга дәва булырлык җырлар белән, моңнар белән очрашачагына шикләнми ул. Чөнки җырчыны беренче генә тыңлавы түгел. Ике арада сыналган дуслык бар.

Музыка телгә килә. Залга моң агыла. Миңлегөл Зәкиева башкорт халык җыры «Зөлхиҗҗә»не җырлый:

Яланда гына җирләрдән болан килә, Зөлхиҗҗә.
Уйсу гына җирләрдән ай үтәм, дип, Зөлхиҗҗә...

Борынгыдан сакланып калган бу җырны җырчы бүгенге кешеләргә кайтарып бирә, уйланырга, күңелдәге иң матур тойгыларны барларга мәҗбүр итә... Халык иҗаты җәүһәрләренең үлемсезлеге шушыдыр инде. Ә җырчыдан аңа талант һәм илһам кушыладыр. Миңлегөл моны тирән аңлап, күңеле белән тоеп җырлый. Җырның тылсымлы көченә бөтен күңеле белән ышана ул. Үзе дә бу моң белән тылсымланган... Җыр тәмамлангач, Миңлегөл үзенә бер төрле тирән дулкынлану хисе кичерә. Һәр җырдан соң шулай. Юкса бит инде артистка ансамбль белән бергә йөзләрчә концертларда җырлаган, туган илебезне аркылыга-буйга иңләп, илебездә яшәүче бик күп милләт тамашачылары каршында уңыш казанган. Шулай да тамашачы белән һәр очрашу, һәр җыр аны дулкынландыра. Һәр иҗат кешесе үзенчә янган шикелле, аның да үз иҗат сере, үз януыдыр бу...

Җыр! Беренче тапкыр кайчан очрашты соң әле Миңлегөл аның белән? Кайчан җырлый башлады?

Күңелендә балачактан калган бер якты истәлек саклана. Аларның гаиләсе ул чакта Украинада яши иде. Беренче класска укырга кергән елы. Класста беренче җыр дәресе бара.

– Кайсыгыз җырлап күрсәтә, кем нинди җыр белә? – ди укытучы апалары.

Миңлегөл кул күтәргәнен үзе дә сизми кала һәм бер мизгел эчендә кулын кире яшереп тә куя. Әмма һәр укучысын күз уңында тоткан укытучы апалары аны күреп өлгерә. Ул каушап, партага иңеп калган нәни «җырчы»ның янына килеп, башыннан сыйпый, дәртләндергеч сүзләр әйтә. Миңлегөлне күтәреп урындыкка бастыра. Менә шунда Миңлегөл гармунсыз-нисез «Шахта» көен җырлап җибәрә:

Китә казлар, китә казлар,
Китә казлар Донбасска;
Мин дә уйлап торам әле
Шул казлардан калмаска.

Татар халык җырын балалар да, укытучы да яратып тыңлый.

Алар гаиләсендә бөтен кеше җырлый. Ләкин Миңлегөлне сәхнә өчен җыр үзе сайлап ала. Гаиләләренең талантын аңа якларга, аңа үстерергә туры килә. Күңеленә сандугач кергән шикелле була аның.

Ул сәхнәгә юл ала. Көндезләрен эштә, ә кичләрен сәхнәдә үткәрә. Миңлегөл инде бу вакытта әтисенең туган җире – Азнакайда яши. Эштән арып кайткан нефтьчеләргә, төзүчеләргә җыр-

лый. Үзе дә алар арасында эшли. Һәм көннән-көн үзенең тормышының, киләчәгенең җыр белән тыгыз бәйләнүен тоя. Җыр күңел ачу өчен генә җырланмый икән. Җыр көчле икән ул, диңгез кебек тирән икән ул.

1962 елда уздырылган үзешчәннәрнең республика фестиваленә азнакайлылар, зур өмет баглап, үз вәкилләрен — Миңлегөлне җибәрәләр. Фестиваль көннәрендә Миңлегөл үзе дә зур дулкынлану кичерә. Ул бит йөзләрчә үзешчән сәнгать осталары арасында чыгыш ясарга тиеш. Һәм күңелдәге өмет-ышаныч алдамый — ул йөзләгән үзешчәннәр арасында «иң талантлыларның берсе» дигән бәяне ала — лауреат булып кайта.

1964 елда, үзешчәннәргә ярдәм итү өчен, Азнакайга Татарстанның халык артисты Гай Таһиров килә. Миңлегөл белән очрашкач, ул: «Бу кызның киләчәге сәнгатьтә булырга тиеш»,— дигән нәтиҗәгә килә.

Нәкъ шул көннәрдә нефть районнарында Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбленең гастрольләре бара. Миңлегөл, ансамбльгә кушылып, гастрольләргә чыгып китә. Юк, бер атнага, бер айга гына түгел, гомерлеккә кушыла ул бу коллективка. Аның иҗат юлы шулай башлана: Азнакай, Бөгелмә, Әлмәт, Казан һәм туган илебезнең йөзләрчә шәһәрләре, авыллары, чит илләр тамашачылары... Ләкин болар барысы да алда әле.

Яңа эшли башлаган көннәрнең берсендә ансамбльнең алыштыргысыз башлап җырлаучысы — халыкның сөекле җырчысы Галия апа Гафиятуллина авырып китә. Концертларны өзәргә ярамый. Һәркем борчуда. Күзләр Миңлегөлгә текәлә. Тәҗрибәсез, яшь булса да, ул «Бормалы су»ны бөтен моңы, матурлыгы белән тамашачы күңеленә җиткерә.

Талантлы яшь кызны республикабызның атаклы сәнгать осталары күреп ала. Заһид Хәбибуллин, Александр Ключарёв, Җәвит Котдусов, Әзһәр Абдуллинның авыр һәм шул ук вакытта шатлыклы иҗат юлында үзенә таяныч булуларын җырчы бүген олы рәхмәт хисләре белән искә ала: «Алар — иҗат гөлләремә су сибеп торучылар»,— ди.

Миңлегөл Зәкиева репертуарына күңеленә бик якын булган, хуш килгән җырларны гына сайлап ала. Аларны башкарыр алдыннан җырның тарихы белән кызыксына, музыка белгечләре белән сөйләшә. Икенче төрле итеп әйткәндә, иҗади эзләнә. «Әллүки», «Сибелә чәчәк», «Бөдрә тал», «Зөбәрҗәт», «Зөләйха», «Фазыл чишмәсе» һәм башка бик күп халык җырларын, композиторларыбызның халыкчан рухлы яңа әсәрләре аның башкаруында тамашачыларны узганнар аша әйләнеп кайтырга, бүгенге көн матурлыгын бөтен бизәкләре белән аңларга, тоярга мәҗбүр итә. Татарстанның атказанган артисты Шамил Әхмәтҗанов белән бергә башкарган «Маһинур белән Тимеркәй җыры»н (С. Сәйдәшев музыкасы), «Умартачы сөйгәнем» (И. Хисамов музыкасы) һәм башка җырларны Миңлегөл башкаруында тыңлаганнан соң, шундый бер фикергә киләсең: бу җырларны шундый нәфис итеп бары тик ул гына башкара ала. Бу инде җырчының бәхете, аның талантының чәчәк атуы.

Гастрольләрдә йөргәндә, Миңлегөлнең рус, украин халык җырларын бөтен нечкәлеге, тиешле колорит белән җырлавы башка милләт тамашачыларының олы рәхмәтенә лаек була.

1970 елның кышында ансамбль Себер ягында гастрольләрдә була. Чираттагы концерт Томскидан ерак түгел бер район үзәгендә булырга тиеш. Тышта 42 градус салкын. Артистларның күбесенә салкын тия. Тышта нинди салкын булса, клубта да шулай ук. Стакандагы су бозга әйләнгән. Клуб тамашачылар белән шыгрым тулы. Барысы да диярлек тун кигән. Ә артистларга күлмәкчән чыгып җырларга, биергә кирәк. Салкын тидерергә ярамый, гастрольләрне дәвам итәсе бар. Кире кайтып китәргә дә юл юк. Тамашачылар җыр көтә. Бер генә кеше дә кайтып китмәгән. Җыр халыкка әнә ничек кирәк. Артистларның һәрберсе моны күңеле белән тоя. Концерт аерым бер дәрт белән үтә.

Халык һәм җыр. Алар бергә очрашса, тормыш ямьләнә, дөнья яктыра. Моның өчен халык үзенең бөтен олылыгы белән җырчыны хөрмәтли, рәхмәтен әйтә.

Миңлегөл Зәкиевага да, күпмилләтле совет сәнгатен актив пропагандалаганы, хезмәт яратуы өчен, чын күңелдән әйтелгән рәхмәт сүзләрен еш ишетергә туры килә. Бу рәхмәт Совет Армиясе



**Сулдан уңга: Хәниф Хөснуллин, Равил Бикбаев, Рәшит Әхмәтҗанов, ?, ?, Хәсән Сарьян**

солдатларыннан да, илебезнең күпсанлы шәһәр һәм авылларында яшәүче хезмәт кешеләреннән дә,— кыскасы, халыкның үзеннән.

1978 елда җырчы тагын бер зур уңышка иреште. Ул җыр һәм бию ансамбльләренең бөтенсоюз смотры лауреаты булды. Җырчыга таланттан тыш батырлык һәм түземлек кирәк. Ә Миңлегөл Зәкиеваның таланты әнә шул сыйфатлар белән чәчәк атты.

Күптән түгел Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле Африка илләрендә гастрольләрдә йөреп кайтты. Конферансьеның «Башлап җырлый Миңлегөл Зәкиева!» дигән сүзләре Африка телләрендә дә яңгырады. Һәм ансамбль сандугачы, халык җырларын җырлап, еракта яшәгән дусларга шатлык өләште. Шул чакта аның күңеленә шагыйрь сүзләре килде:

Бер горурлык хисе яна миндә,
Эчтән бәреп яна битләрдә...

*«Татарстан яшьләре» газетасы.— 1979. — 15 март*

# Батыр башлап җибәрә

Сарман якларында икенче көн инде яңгыр ява. Көн буена үзләренә туктар урын табалмыйча агылып арыган болытлар, кич җиткәч, таулар артына иңәләр дә иртән тагын кешеләрдән дә алда «йокыдан» уяналар. Тагын эре-эре тамчыларны җил үзенең иләгендә или башлый. Ләкин шәһәрдәге кебек, монда беркем дә яңгырдан качмый, йөгерә-йөгерә ышыкланыр өчен урын эзләп чапмый. Һәркем үз юлында. Яңгыр яуса — җир бәхетле, дисәләр дә, игенчеләрнең йөзләре кырыс, сүзләре һаман бер тирәдә: чәчелгәнне урырга, урылганны урнаштырырга кирәк.

...Тигез асфальт юлдан машинабыз Сарайлы авылына борылды.

Муса Җәлил исемендәге колхоз — районда алдынгы хуҗалыкларның берсе, яшь игенчеләрнең матур эшләрен күрим дисәгез, анда барыгыз, дигәннәр иде ВЛКСМ райкомында. Колхозның бер бригадасы булган Сарайлы авылына шул максат белән килү иде. Районның алдынгы яшь механизаторы комсомолец Мөдәррис Шәфигуллиннар өенә юл тоттык.

Каршыларга Мөдәрриснең әнисе Маһимәүлидә апа чыкты. Терелеге, чаялыгы белән һәркемне бик тиз җәлеп итүче комсомол оешмасы секретаре Нәгыймә Хәбибуллина безне шул мизгелдә үк инде күптәнге танышлар итте дә куйды.

— Мөдәррис кырдан кайтты да машина-трактор паркына китте әле,— диде Маһимәүлидә апа.— Бик яугач кайткан иде, түзмәде, чыгып китте. Аның да эче пошып йөри бу галәмәткә.

Аяк асты пычрак булуга карамастан, апаның идәннәре сап-сары итеп юылган, өе җылы, өстәлдә самавыры кайнап утыра, мичтән яңа гына чыккан күзикмәкләрне өстәлгә китерде.

— Сезнең өйдә бүген бәйрәмме әллә? — дибез.

— Мондый көннәрдә балаларның күңеле төшенкелеккә бирелмәсен өчен,— диде ул.

Аның шул бер сүзеннән ана күңеленең барлык матурлыгы балкыды да куйды.

Сүз үзеннән-үзе тормыш хәлләренә күчте. Маһимәүлидә апа, тол калып, дүрт бала тәрбияләп үстергән — ике малай, ике кыз. Яшьлеге сугыш елларына туры килгән. Япь-яшь кыз колхозның бер бригадасын җитәкләгән.

— Бер трактор, дистәдән артык йончыган атлар янында корыч кебек нык, тырыш кешеләр булмаса, ай-һай, нишләп беткән булыр иде колхозыбыз?! Ул еллар безнең — яшь кызларның чәчләренә чал сипте. Әлеге заман — оҗмах ул. Ил-көн өчен, балаларым өчен куанып бетә алмыйм... — ди ул.

Без аңардан Мөдәррис турында сөйләвен үтендек.

— Мөдәррисем сабый чагыннан ук колхоз кырында. Шунда туып, өйгә шуннан йөгереп кайтты сыман. Хәзер дә ашарга гына кайтып йөри сыман. Яз-көз сөрә, чәчә, җәй өлгергән игеннәрне урып-җыя. 14 яшендә тракторчы ярдәмчесе булып, ныклап аякка басып эшли башлады. Үземнең энем өйрәтте аны һөнәргә. Укырга да аның киңәше белән китте: Лениногорск шәһәрендә тракторын да, комбайнын да йөгәнләп йөртергә өйрәнеп, документ алып кайтты. Эштән чыгып беткән тракторны берүзе ремонтлап, кырга чыгып китте. Шатлыгымның чиге булмады...

Өйгә Мөдәррис үзе кайтып керде. Чәчләрен сыйпап, мазутка буялган кулларына карап алды да, эчкерсез елмаеп, кул биреп күреште. Төз буйлы, сөйлисе сүзләрен елмаюга алмаштырып, сорауга бер сүз белән генә җавап кайтаручы оялчан кеше икән.

Мөдәрриснең авыл Советы депутаты, комплекслы механикалаштырылган иген җыю звеносы җитәкчесе, колхозда халык контроле члены, актив комсомолец булуын район үзәгендә үк белгән идек. Үзе турында берни дә сөйләтә алмагач, сүзне икенче яктанрак башларга туры килде:

— Син җитәкләгән звенода яшь механизаторлар бармы, ничек эшлиләр, остазлары кем? — дигән сорауга ул:

— Бергәләп эшлибез инде, яшьләрне эш үзе өйрәтә,— диде.

Яшьләр дигәнебез — 17—18 яшьлек егетләр — яңа гына 10 нчы классны тәмамлап, мәктәптән механизатор таныклыгы алып чыккан Сирин Әхмәтшин, авыл профессиональ-техник училищесында укучы, ә хәзер үз авылларына практикага кайткан Мирзанур Маннапов, Инсаф Шәйдуллин, Рәшит Фазлыев һәм башкалар икән. Бу тырыш егетләр дә, урып-җыюга төшкәнче, иске комбайннарны үзләре ремонтлаганнар. Һәм шул кыр корабларында кыен шартларда иген уралар. «Иртә чыксаң — алдыңнан көн чыгар, кич чыксаң — алдыңнан төн чыгар» дигән аксакаллар сүзенең чын мәгънәсенә төшенгән хәлдә эшләп йөриләр, чын игенчеләр булырга әзерләнәләр. Мөдәррис абыйлары (Мөдәррис алардан 6—7 яшькә генә олы) кебек таяныр кеше булганда, эш үзе шатлык алар өчен. Эшнең ярты авырлыгы югала сыман.

Мөдәррис быелгы урып-җыю чорында 2500 центнерга якын уңыш җыеп алган иде. Килограммнар, километрлар, центнерлар... Мөдәррис аларны санамый, башкалар санап баралар, хисаплыйлар. Аның өчен бөртекләр кадерле. Һәр көнне учына алып, бәхет тоткандай сихерләнеп карый. Сихерләнеп... Бөртекләргә җир җылысы, тормыш яме, таң нурлары иңгән. Мөдәррис өчен таңнарны кырда каршылаудан да, эшне беренче булып башлап җибәрүдән дә зуррак бәхет юк. Хәтерли әле: армиядә хезмәт иткән чакта, ул якты таңнар төшенә кереп интектерде. Армиядән кайту белән, сыналган да кеше булгач, аңа яңа техниканы ышанып тапшырдылар. Җирнең ул чын хуҗасы булып өлгерде. Яшь булса да, ил агалары белән бер хөрмәттә булды. Өйләнде, улы Марсель туды. Тагын куанычлар ишәйде, авылның яме, җирнең кадере артты аның өчен.

Депутатлык вазифасын да, халык контроле члены вазифасын да, үзенең кешелек вазифасын да Мөдәррис бер урында, бер вакытта башкара — иген кырларында, бер таңнан икенче таңга кадәр. Дөньяда ул иң олы эшне башкаручы, иң җаваплы урында эшләүче кеше. Ул — игенче!

Болытлар түгәрәк арышка инде. Юлда пычрак булса да, юл читендәге үләннәрдән яңгыр тамчылары берәм-берәм юкка чыга. Җил аларны «барыгыз, җир куенына иңегез инде, урыныгыз шунда» дигәндәй тәгәрәтеп төшерә. Мөдәррискә ияреп, басулар ягына киттек.

— Бәлки әле, төнгә хәтле ике-өч сәгать урып булыр, җилләтә бит,— диде ул.

Юлда аңа колхоз партия комитетының күчмә вымпелын һәм акчалата премия тапшырдылар. Алдагы көннәрдә дә, кичә дә иген уңышын җыюда колхозда ул беренче урынны яулады.

Менә әле тагын иген кырларына бара. Игеннәр җилләү белән, беренче булып аның комбайны кузгалыр. Батыр башлап җибәрә, артыннан мең кул ияре, ди халык. Халык улы дәрәҗәсенә күтәрелгән Мөдәррис Шәфигуллинның бөтен тормышына, эшенә, холкына бу мәкаль бик тә туры килә. Әйе, батыр башлап җибәрә. Хәерле сәгатьтә! Көннең һәр минуты игенчедән батырлык, чаялык, тырышлык таләп итә. Чөнки иген язмышы — ил язмышы.

*«Татарстан яшьләре» газетасы.— 1980*

# Киңәшчебез, дустыбыз

Танылган шагыйрь һәм прозаик, бик күп яшь каләм ияләренең әдәби остазы, җәмәгать эшлеклесе Әдип абый Маликов әдәбиятыбыз күгенә «Атаудагы хисләр» дигән поэмасы белән калыкты.

«Атаудагы хисләр»... Поэманы укыгач, бу Атау язмышына илнең сугыш чоры язмышы сыйганын күрәсең. Шул елларның бөтен ачысын татыган солдат егет Әдип Маликовның әлеге поэмага салынган тойгы-хисләре бүген дә, сүнмәгән-сүрелмәгән килеш, кешеләрнең җанын җылыта. Бу – Атауда туган җырларның дәвамы, шагыйрь гомеренең матурлыгы, гомернең бик тә мәгънәле узуы.

Әдип Маликовның бөтен байлыгы – кешеләр тормышын өйрәнү һәм җырлау, дияр идем. Поэмаларында, шигырьләрендә, повестьларында, очеркларында сурәтләнгән геройлар барысы да диярлек ил язмышын иңнәрендә күтәреп баручылар. Алар беркайчан да атылып-бәрелеп чыкмаслар, юкка-барга чаң какмаслар, тыныч кына, вакытны исраф итмичә, ил-җир гамен кайгыртып, иген үстереп, яңа калалар күтәреп, җир куеныннан «кара алтын» чыгарып йөриләр. «Ташчы» поэмасында – Касыйм, «Гайшә апа» поэмасында – Гайшә, «Салкын Алан» поэмасында – Нури белән Сорур. Әгәр аларны санап чыксаң, шактый мәйдан кирәк булыр иде.

Алда аталган әдәби каһарманнарның характер нигезе нәрсәдә? Үз-үземә шундый сорау куйгач, байтак уйланып утырдым. Ниһаять, алгы планга бер фикер калыкты: ул геройларда авторның үз холык-фигыле, дөньяга карашы, характер ныклыгы, тыйнаклыгы, күңел пакьлеге, шапырына белми күрсәткән гомерлек фидакярлеге чагыла лабаса! Үз күңелендә кояш балкымаган шәхес каләме таң балкышыдай табигатьле геройлар иҗат итә алыр идемени?! Ә инде фидакярлек дигәндә, Әдип абый Маликов – күпләр өчен өлге. Солдат фидакярлеге, шигырь, проза язу белән бер үк вакытта дистәләрчә елга сузылган журналист фидакярлеге (ул «Татарстан яшьләре»ндә үзхәбәрче булды). Әлмәттәге әдәби берләшмәдә озак еллар җитәкче булу фидакярлеге, җирле Совет депутаты буларак, халык белән эшләү фидакярлеге...

Заманында Әлмәт ташпулатларын салышкан ташчы, яшь каләм – мин үзем – Әдип Маликовның иҗади канаты астында сыену таптым, ярдәм, киңәш алдым, поэзия серләренә төшенә бардым. Ә минем кебекләр дистәләрчә бит.

Әдип Маликов, шигырьләрендә булсын, повесть яки очеркларында булсын, үзен чынбарлыкны җитди төстә тирәнтен өйрәнүче, художникларча тасвирлаучы итеп күрсәтте. Аның өчен әдәбиятта вак нәрсә юк. Ул – сюжет төзү остасы да. Шуңа күрә бу язучының әсәрләрен аерыла алмый мавыгып укыйсың. Гашыйк булып укуга тагын бер сәбәп бар: авторның тел осталыгы, халыкчан, тормышчан, шул ук вакытта әдәби чарланган, сәнгать югарылыгына күтәрелгән тел белән язуы.

1978 елда Әдип Маликов «Гашыйклар юлы» дигән бик үзенчәлекле китап чыгарды. Очерклар китабы. Анда чирек гасыр тарихлы Әлмәтнең художестволы елъязмасы тупланган иде. Фәкать шушы китап кына да авторны иҗат гвардиясе сафына бастырыр иде. «Гашыйклар юлы»ның авторы республикабыз данын бик еракларга җиткергән кала тарихын җентекләп өйрәнүен дәвам итә. Килер көннәрдә әдәбият сөючеләргә ул шуңа охшаган өр-яңа китап бирер әле, чөнки аның үз сүзләре белән әйткәндә:



**Сулдан уңга: Гариф Ахунов, Фазыл Мостафин, ?, Әдип Маликов, Мөхәммәт Садри(?)**

Тормыш безгә аек
хәтер биргән
Үткәннәргә кире
кайтырга,
Шул үткәннәр
чигенмәскә куша,
Шулар безне алга
чакыра.

Әнә шулай алга ыргылып-омтылып иҗат итүче остазыбызга бүген 60 яшь тулды. Бу инде 60 үр менү дигән сүз. Әмма алда үрләрнең яңалары, калкураклары. Аларга менү ансат булыр, дип, берәү дә раслый алмас. Иҗатта җиңел яулана торган үрләр булмый. Шулай да һич икеләнмичә әйтә алабыз: ул биеклекләргә менгәндә дә, Әдип абый Маликов таякка таянмас. Солдат чыныгуы, тормыш тәҗрибәсе, каләм куәте, гомер зирәклеге аңа көч-дәрт өстәп торыр. Без дә моны ихластан телибез.

*«Татарстан яшьләре» газетасы.— 1981*

# Уяулыкны югалтмыйк[1]

Татар халкы үзенең суверенлыгын игълан иткәч тә, шовинистик кара көчләр аңа каршы ачыктан-ачык дошманлык хәрәкәтләре күрсәтүдән туктамыйлар. Алар, җир йөзендәге соңгы колониаль империянең җимерелүен туктатырга теләп, төрле чараларгаябышалар. Без инде Мәскәүдә РСФСР Югары Советы җитәкчеләренең, депутатларының рус булмаган халыкларны кимсеткән сүзләрен күп ишеттек, матбугатта да укып торабыз. Казанда «демократлар» партиясе төзеп, татар халкының бугазына ябышкан Штанин, Михайлов, Халдеев, Шәкүров, Рокицкий кебек депутатларның, Беляев кебек «галимнәрнең» тәкъдимнәре, язмалары белән таныштык.

Һәм менә бүген бу кара көчләр татар халкының лидерларын таш базларга томалап куярга телиләр. Чаллы «демократы» Ю. Петрушинның яласы белән К. Сафиуллин һәм З. Әһлиуллин кардәшләребезне судка тартканнар. Бу – башбаштаклык! Бу турыда «Социалистик Татарстан» газетасында бик дөрес язылды. Ю. Петрушин татар халкының асыл ирләрен зindан белән куркыта. Мондый яман кешеләргә безнең арада урын булырга тиеш түгел. Без илсөяр ир-егетләребезне төрмәләрдә черетергә яңадан юл куймабыз.

К. Сафиуллин һәм З. Әһлиуллиннарга золым салучы Чаллы түрәсе Ю. Петрушин һәм аның иярченнәренә җәза бирелергә тиеш! Шушы гаделсезлеккә каршы барлык халыклар да бердәм күтәрелер дип ышанабыз.

*«Социалистик Татарстан» газетасы.– 1990. – 18 декабрь*

[1] Филология фәннәре кандидаты Марсель Әхмәтҗанов белән берлектә язылган.

## Бу дүрт шигырьне бүген бастырмый булдыра алмыйм...

Яңа гәҗитләр караштырып утыра идем, «Шәһри Казан»ның 27 ноябрь санында басылган ике материалга игътибар иттем. Беренче биттәге «Гаепләнүчеләр – милиция хезмәткәрләре» һәм икенче биттәге «Тимәгез Вафирәгә!» дигән язмалар иде ул. Икесе дә милициягә кагылышлы. Тамчы да гаҗәпләнмәдем. Болар – күптәннән башланган «эшләрнең» дәвамнары, өтер хәтлеләре генә, Россия милициясенең кылган «кызык» гамәлләренә хәзер Казанда беркем дә гаҗәпләнми инде. Алар «элеккечә» эшли бирәләр. Ә менә милли хәрәкәттә катнашучыларга яшәү көннән-көя авырая бара. Серле рәвештә үтерелүчеләр арта, ә үтерүчеләр табылмый. Кыйналучылар имгәнә – беркем дә җавапка тартылмый.

Шулай, җәмәгать, ил-көн, халык алдында милли хәрәкәттә катнашучыларны хур итү, шәхесләрен мыскыллауны Казанда бик нечкә итеп башкаралар. Бу – юк итүнең бер төре, иң газаплысы. Берничә генә мисал китерик: имеш, Фәүзия Бәйрәмова катнаш никахлардан туган балаларны юк итәргә чакыра икән. Пычрак яла үз эшен эшләде – милли хәрәкәткә күләмен үлчи алмаслык зыян килде. Тикшерү органнары гаепле кешене «тапмадылар». Татар маңкортлары «Суверенитет» гәҗитен бер-бер артлы судка бирәләр. Гәҗит акланса да, шау-шу үз эшен эшләп өлгерде – хәйрия акчасына чыгып килгән гәҗитнең материаль ягы начарланганнан-начарлана бара. «Мәрҗани» җәмгыяте президенты, милли мәгариф, мәдәниятебезне үстерү өчен көнетөне эшләүче Зәки Зәйнуллинны (әле яңа гына авыр операция уздырган чагы иде) биш-алты «кылычлы», кул-аягын каера-каера, эш урыныннан судка алып китәләр. Мәгълүм «Минзәлә вакыйгалары» да канлы көн булып татар тарихында сакланып калачак. Гаеплеләрне кайчан хөкемгә тартырлар? Һәм, гомумән, тартырлар микән әле?

Берәмләп, аерым-аерым пычраталар олы шәхесләрнең якты истәлекләрен. Бүген җасусларның зәһәрле угы халкыбызның ике җырчысына – Гөлзадә Сафиуллина белән Вафирә Гыйззәтуллинага табан төбәлгән. Шулай булмый ни, Россия милициясе, прокуратурасы каршында аларның «гаепләре» бигрәк тә зур шул. Бу ике җырчыбыз – соңгы 4–5 елда гына түгел, элегрәк тә халкыбыз азатлыгы өчен көрәшкән иҗатчылар. Болар инде сессияләр барган көннәрдә Ирек мәйданында 300–400 ләп милиция хезмәткәре сагы астында пикетта торучы бер дистә әби генә түгел. (Бу сүзем өчен Акъәбиләр гафу итсеннәр.) Болар – сынмас көрәшчеләр!

Менә шуңа күрә дә мин, мөхтәрәм җәмәгать, «Шәһри Казан»ның җомга санында басылган әлеге хәбәрләрне укыгач гаҗәпләнмәдем. Ләкин дөреслекнең бер генә мыскалын булса да халык белеп торсын дип, кулыма каләм алдым, һәм яңа гына тәмамланган шигырьләр китабымнан дүрт шигырьне аерып алып, матбугатта бастырып чыгарырга карар кылдым. Бу шигырьләр 1991 елның маенда – Ил-җиребезгә мөстәкыйльлек таләп итеп 18 милләттәшебез һәм бер Азәрбайҗан кешесенең Ирек мәйданында сәяси ачлык игълан иткән көннәрдә язылганнар иде. Җырчыларыбызны яклап, халык арасында минем дә тавышым ишетелер дим. Тагын бер сүз өстим: ни генә булмасын, киләчәк – безнеке!

### *Уян, вөҗдан!*

Империя! Илем булалмадың,
Син кол итеп тоттың татарны.
Өметләрен өздең! Хәзер алар
Берсен берсе эзләп табармы?

Әй, эшләдек! Ашыбызга каршы
Башыбызга һәрчак таш аттың.
Каткан икмәгеңне гомер буе
Күз яшемә манып ашаттың.

Шундый итеп таркаталдың: хәзер
Халыклардан калды төркемнәр.
Кеше ни ул?! –
Хәтта Кояшны да
Кол итәргә монда мөмкиннәр.

Кояш җиргә гел урысча дәшә,
Ай частушка сибә төн буе.
Чын вә ялган кочаклашып эчә,
Беркем белми – монда кем туе?

Вөҗдан йоклый монда ничә гасыр! –
Уятырга иде бер тапкыр.
Хәтта дастаннарда калган батыр
Бу зинданда башын югалтыр.

Уян, вөҗдан, уян! һәм минем дә
Йокылардан уят канымны.
Мин йоклатып аны – үз халкымны
Үтерүче булып калыйммы?!

Хәсрәт утларында каным яна –
Кил, җаныңны җылыт, и халкым!
Җиргә туып, сине эзләп таптым,
Үзең дә тап – ниләр югалттың.

...Аңсыз калып, кеше аптыраган,
Таңсыз калып, Кояш туктаган.
Саксаулга әверелә бара
Күз алдымда үскән бер чаган.

Син дә, халкым, шулай үзгәрәсең –
Кем җәзалый сине шулкадәр?!
Ирек даулар көчләләрең кайда –
Үтерелсәк,
Үлсәк без әгәр?

Ә әлегә Кояш – урысныкы,
Ай частушка сибә төн буе.
Разбойниклар кочаклашып эчә,
Беркем белми – илдә кем туе?



**Рәшит Әхмәтҗанов һәм Гөлзадә Сафиуллина Милли Мәҗлеснең III сессиясендә. 1992, 22 август**

## *Исәнем*

*Гөлзадә Сафиуллинага*

Караны каргый яктылык,
Яктыны – караңгылык...
Сиңа куркыныч янамый –
Тугансың Кояш булып.

Сиңа ни! – бәреп керәсең
Маңкортлар арасына:
Бүтән берсе дә кул сала
Алмасын анасына!

Оясыз оятсызларны
Сүз белән сихерлисең:
Юк, сезгә килешми, дисең,
«Разбойник» дигән исем.

Гел талауларда ачылган
Ник милли талантыгыз? –
Җирдә яшәгәч, иң элек
Кешене яратыгыз!

Сезгә яңадан тумыйча
Ярамый, «туганнарым»! –
Йә, ничек карап торыйм соң
Халкымны буганнарын?!

...Ә Ачлык, авызын ачып,
Гомерне ашап тора.
Минем санаулы көннәрем
Сине дә ашыктыра:

Гастрольләргә китәсең
Халыкны уятырга.
Ирек мәйданын татарның
Канына буятырга

Мөртәтләр әзер торалар –
Шуны белгәнгә күрә,
Казанга кире кайтасың
Үләргә аягүрә!

Сине күрәм дә шатланам:
Җыр исән! Халык исән!
Исәнем, онытма мине,
Иртәгә тагын китсәң.

Калдыр син, Кояш, калдыр син
Миңа да бирәр чаткы.
Бер чаткы... Сүндермәм аны
Соңгы сулышка чаклы.

## *«Ком бураны»*

*Вафирә Гыйззәтуллинага*

...бу көйне революциягә кадәр үк чыккан, диләр. Карт музыкантыбыз Исмәгыйль Һилалов бу көй турында болай ди: «Без бала чакта Уралда, Троицк шәһәрендә байларда хезмәт итүче Закирҗан исемле приказчикны үтерделәр. Шул уңай белән чыкты бу көй. Аны «Закирҗан бәете» дип атыйлар иде.

*Җәүдәт Фәйзи*

Бу җырны көн дә халкыңа
Җырладың быел җәен.
Яшен калдырган яшеллек
Икәнсең, сеңелкәем!

Бездәге һәр җыр – бер җегет
Үлмичә туалмаган.
Җырлыйсың... Куркам – мондый хәл
Татарда яши һаман.

Белеп җырлыйсың татарның
Мәңгегә уянасын, –
Сак бул, җырыңны замана
Каныңа буямасын.

Закирҗанның җаны булып
Уята «Ком бураны»:
– Сөйгән халкың кол булганда,
Өйдә ятып буламы!

Уята җырың, уята,
Уйлата барчабызны.
«Дошманга ут ачабызмы,
Урманга качабызмы?»

Батулла шаярта шулай,
Ә күзе яшьле аның.
Күрәсең, бүгенге кебек
Юк иде җырлаганың.



**Алгы планда — Вафирә Гыйззәтуллина, Рәшит Әхмәтҗанов**

**«Туган көнемнән үк бәхет биреп,**
**Азат балам диеп атадың.**
**Авыр чакларыңда Кол Гали күк**
**Колың булыйм, газиз Ватаным».**

Уятты күпме йөрәкне,
Терелтте синең көең.
Яшеллек чакырган яшен
Икәнсең, сеңелкәем!

Яшен ул, ут белән даулый,
Ут белән яулый күген.
Синең моң белән гимнга
Әйләнде бәет бүген.

Халыкның үзе кебек зур,
Үлемсез мондый көйләр:
Богаула — шартлатып өзәр,
Телен кис — барыбер сөйләр.

Яндыр — яңадан туачак.
Агула — терелачәк.
Бүгенен бетер — барыбер
Киләчәктән киләчәк!

Әллә яшеннәр калдырган —
Өстендә яшел кием...
Без фида китсәк китәрбез,
Син җырла, сеңелкәем!

## *Атарга түгел акларга!*

Сине күргәч, искә төште кинәт
«Үлем» белән бәйле бер өтер.
Бәлки, бүген сиңа ул өтерне
«Түгел»дән соң кую дөрестер.
«Өч сүзгә бер өтер төртер өчен
Артык Галим булу кирәкми» —
Бик еш ялгышасың — шул бер өтер
Әкеренләп безне сирәкли.

*«Мәдәни җомга» газетасы.— 1992. — 4 декабрь*

# Мөстәкыйль Татарстан: алда безне ни көтә?

Җанызны кем даулый?

Халкым! Синең бәхетсез йортында бүген тагын хәсрәт – гасырлар буена зарыгып көтеп алган мөстәкыйльлегең тар-мар ителү алдында тора. Үлгәннәр дә терелер чак. Син изге гамәлләрең белән җиргә иелгәнсең: уңыш җыясың, җир сөрәсең, җир куенына яңа орлыклар сибәсең, салымнарыңны каплар өчен, күпләп дуңгыз үрчетәсең. Хатын-кызларың, бала-чагаң кырда чөгендер, бәрәңге ала. Бер мизгелгә генә тураеп бас әле, башыңны күтәр!

Юк, мин сине эш ташларга чакырмыйм. Эшебездә – гомеребез озынлыгы, киләчәгебез. Тик азатлыктан башка кешенең киләчәге була алмый, үз язмышың моңа ачык мисал. Яулап алган мөстәкыйльлегебез безгә азатлык китердеме соң?! Аны яклап, мин дә быел май аенда Казанның Ирек мәйданында унике тәүлек сәяси ачлыкта утырган идем. Гомерем бәрабәренә аның яшәвен озайтырга теләдем. Ирек алдык, дип, шатлык кичердек. Тик Рәсәйдә татар бәхетенең кайчан озакка сузылганы бар соң?



**«Дәвам итә алмыйм шигыремне,**
**Мин кәгазьнең җәйдем ап-агын:**
**Акка кызыл ачык булып төшәр,**
**Яралы кош язар калганын».**

Бәйсезлегебез үзенең бер еллыгын канатлары сындырылган, ук тиеп күкрәге канаган бөркет хәлендә каршылады. Бәйсезлегең үзеңә охшаган. Бүген син үзең дә шундый хәлдә, халкым.

Канатларны кемнәр сындыра, кайсы түмгәк артыннан нинди мәргәннәр ук ата? Җаныбызны кем даулый? Әйе, елан йокласа да, дошман йокламаган! Татар шуны һәрчак онытып яшәде, авыр эштән соң аны һәрчак йокы басты. Бер генә мизгелгә тураеп бас, халкым. Без, синең аз санлы кызларың һәм улларың, кемнәрнедер кол итү өчен түгел, синең белән бер җирдә яшәгән бөтен милләтләр азатлыгы, сулар һавабыз булсын, бергә кабызган учаклар сүнмәсен өчен көрәшәбез.

Мәскәүнең азатлыгыбызны хупламаячагы алдан ук билгеле иде. Союз таркалды. [...] Урыс империясе калкып чыкты. Тамагың тыгылсын дигәндәй, былтыр гына да Мәскәүгә дүрт миллиард сум салым түләгән идек. Дөресрәге, түләттеләр.

Онытмагыз, былтыргы ел – азатлык алган елыбыз иде бит. Мал гына җитми, җан кирәк икән аларга. Азатлыгыбыз – безнең җаныбыз. Алар шуны даулый. Үз җаныңны сакларга әзерме син, халкым?! Сине гасырлар буена үлеп, югалып бетүдән коткарган улларыңның оныклары кайда?

Кай илләрдә, кай җирләрдә адашып йөриләр? Йөрәгеңә якынрак чакыр аларны бүген – якласыннар сине.

Дөрес, безне якласын өчен үзебез сайлап куйган Президентыбыз бар.

Без – халык уллары, дип, эш башлаган депутатларыбыз, Парламентыбыз бар. Тик аларга ышаныч бетеп бара. Әлегә хәтле Байрагыбыз, Гербыбыз, Гимныбыз, яңа Конституциябез юк. «Татарстанга тулы бәйсезлек алырга» дигән мөрәҗәгатькә нибары ике дистәдән артык депутатыбыз гына үз имзаларын салды. Үз халкына булган мондый хыянәтне, кыргыйлыкны дөнья парламентлары белми. Депутатларың да ике якка бүленгән. Берәүләр сине коллыкта калдыру өчен, икенчеләр азатлыгың өчен көрәшә. Киләчәктә һәркемнең хыянәте энәсеннән җебенә хәтле тикшерелер әле. Ә бүген куып тарат, халкым, үз куеныңда үзең асраган еланнарны! Тапшыр язмышыңны асыл улларыңа! Синең икмәгеңне ашап, сине кол итү өчен көрәшеп йөргән ДПР шикелле оешмалардагы төрле төстәге битлекләр кигән «демократлар», дөресрәге, шовинистлар һәм үз маңкортларың синең рухыңны хурлый, мыскыл итә. [...] Уяулыгыңны арттыр, халкым. Йокымсырау – үлемгә тиң бүген.

15 октябрьдә ТССР Югары Советының чираттагы сессиясе ачылачак. Үз халкын якларга теләгән, халыкка тугры калган депутатлар иң элек Татарстан Республикасының тулы бәйсезлеген игълан итәргә һәм сине халык буларак яшәтә алырлык Конституция кабул итәргә тиешләр. Азатлыгыбызны саклап калуда соңгы мөмкинлек бу. Әгәр Парламент шуларны башкара алмый икән, соңгы мөмкинлекне ычкындырмас өчен, синең кызларың һәм улларың барысын да эшләргә әзерләр, халкым. Аларның күңелендә курку юк. Алар куркудан узган инде. Нәселең юк ителгәндә, меңьеллык мәдәниятең юкка чыгарылганда, туган телең онытылып барганда – кеше булган кеше бу көрәштән читтә калмас. Бу көрәш – яшәү өчен көрәш, бу көрәш – иң изге көрәш!

Тагын бер сүз: игътибарыңны башка якка юнәлтү өчен, сине киләчәктә булачак ачлык белән куркыталар. Син болай да тук яшәмәдең. Үстергән икмәгеңне, тапкан малыңны Мәскәү ала барды. Ләкин бүген курыкма!

> Үз җиренә иелгән дә татар
> Иген чәчкән, урган... урачак!
> Илбасарлар белгән: ул турайса –
> Урагы бит кылыч булачак.

Син көне-төне эштә – беркайчан да ач булмассың. Бабайлар васыятен үтәп, җиреңне, туган туфрагыңны гына изге итеп сакла. Әмма сине коллыкка өстерәүчеләргә үз икмәгеңне ашатма, суыңны эчермә, йортыңны талатма. Әйткән сүзебезне кылган гамәлләребез расласын: йә горур килеш яшәргә, йә горур килеш үләргә! Сине яклаган өчен үтерелгәннәрнең бөек рухы безнең белән. Амин.

*«Шәһри Казан» газетасы.– 1990*

# Каләмдәшләремә уңышлар телим

*Күптән түгел Татарстан Язучылар берлеге идарәсе һәм «Туган як» җәмгыяте «язучы, галим Ибраһим Нуруллинга һәм танылган шагыйрь Рәшит Әхмәтҗанга Гаяз Исхакый исемендәге премия бирергә» дигән карар чыгарды. Без бүген аларны чын күңелдән котлыйбыз һәм шул җәһәттән Рәшит Әхмәтҗанның газета укучыларына әйтәсе сүзен тәкъдим итәбез.*

Гаяз Исхакый – халкыбызның бөек улы, бүген дә канап торган йөрәк ярасы. Мин шул бөек Көрәшче, бөек Бәхетсез исемендәге бүләккә, премиягә лаек булганмын. Көтмәгән идем. Каушап калдым.

Әдәбиятыбыз йортында бүген асыл талантлар да, көрәшчеләр дә, бәхетсезләр дә күп. Биш йөз елга якын таланып, кыйналып килгән халкыбызның бөтен байлыгы – аның исән калган балалары. Халыкның иң изге васыятьләре аларга тапшырылган. Бәхетсез халкыбыз белән бергә яшибез – без бәхетле. Ә бит бөек Бәхетсезебез гомере буе иленнән аерылып яшәргә мәҗбүр булган һәм соңгы сулышына кадәр халкыбыз азатлыгы өчен көрәшкән. Ул кичкән утлы сәхифәләрнең уннан бере генә безгә билгеле. Минемчә, дөнья буйлап таралган татарлар илгә җыелмыйча, аларны белеп тә, зурлыгын үлчәп тә булмастыр. Халкыбызның рухи мирасы бөтенләе белән әнә шундый хәлдә бүген. Безнең бәхетсезлек тә – таралганны җыйнап, югалганны юллап, талалганны тартып ала алмавыбызда.

Бүген халкыбыз авыр тарихи көннәр кичерә. Ләкин, ни булса да, безгә ярты-йорты мөстәкыйльлек кирәкми. Ярты-йортыдан, калдык-постыктан туйдык! Безгә үзебезнеке, үз өлешебез кирәк.

«Язучы сәясәттә катнашырга тиеш түгел, аның урыны – язу өстәле». Бәхетсез язучылар әнә шулай диләр һәм нигәдер үзләре бөек Көрәшче язган әсәрләр белән тиңләрлек бер китап та иҗат итә алмыйлар. Дөрес, язу өстәленнән аерылмыйча да, халыкны әйдәп баручы С. Баттал, Ә. Еники, Н. Фәттах, М. Мәһдиев, М. Әгъләмов һәм башка дистәләрчә язучылар турында сүз бармый. Иңнәрендә тау күтәрә алган А. Хәлим, Ф. Бәйрәмова, Р. Батулла, З. Зәйнуллин, Ә. Рәшитов, Р. Зәйдулла, Г. Морат кебек каләм ияләре кемне генә сокландырмый! Азатлыктан башка һичнигә дә баш ияргә җыенмыйбыз. Без язучылар күбәү бит, без ике йөздән артык. Бүген һәркем үзен барларга тиеш. Бу эшне иҗатчы үзе эшләмәсә – халык эшләр, халык барлар. Кемнең кем икәнен халык әйтеп бирер. Халкыбыз уянды. Аны беркем дә алдый, күзен буа алмый хәзер. Ул – артык та түгел, ким дә түгел – тигезлек өчен көрәшкә күтәрелде. Бөтен милләтләр дә бертигез хокукта булсын, ди ул. Аны көрәш юлыннан биздерермен дигән кеше – шыр җүләр булыр иде.


Тик менә Казанда һәр көн диярлек суд була. Милли хәрәкәттә катнашучыларны судка тарталар. Күпләр кыйналды. Телефоннан һәм хатлар аша янаулар дәвам итә. Боларга каршы эш кузгатылмый, бер генә чара да күрелми. Судка тартылучылардан чиратта – Зәки Зәйнуллин, Зиннур Әһлиуллин һәм башкалар.

Без шуны беләбез: Татарстанда яшәүче халыклар беркайчан да бер-берсенә кул күтәрмәячәк. Милли хәрәкәттә катнашучылар халкыбыз фатихасыннан башка бер адым да читкә атлаганнары юк. Халык өметенә күсәкләр белән сугучыларга үз башларын, үз иңнәрен куялар. Тавыш кына чыкмасын. Ә бит тарихыбыз, туган телебез, рухыбыз, мәгърифәтебез һаман типкедә йөри әле. Шулар өчен көрәшүчеләрне төрмә белән куркыту – кыргыйлык. Аннан соң, үз халкын яклаучы булудан ир-атны кем тыя ала? Беркем дә, берни дә! Бу турыда элек тә язылган, хәзер дә өр-яңа китаплар язылып ята. Каләмдәшләремә уңышлар телим.

*«Шәһри Казан» газетасы. – 1992. – 28 февраль*

# II БҮЛЕК.
# «ӘЙТКӘННӘРЕҢ БУЛСЫН ТУРЫ СҮЗ ГЕНӘ»


*Рәшит Әхмәтҗановның иҗаты, иҗтимагый эшчәнлеге турында замандашлары сөйли*





# Тынгысыз егет

З. Аитова



**Рәшит Әхмәтҗанов. 17 яшь**

«Кадерле редакция!

Минем шушы кечкенә хәбәремә газет битендә урын бирсәгез, мин бик шат булыр идем».

Моннан биш ел элек редакциягә шушындый үтенеч язылган бер хат килә. Яңа хәбәрченең хатын «төкле аягың белән» дип каршылау һәрбер редакциядә гадәткә кергән инде. Бу юлы да шулай була. Газетка язышырга зур теләге булган бу егетнең мәкаләсе җентекләп укыла һәм аның бу хәбәре басыла.

Шул көннән башлап редакция белән бу егет арасында язма элемтә урнаша. Ул йә мәкалә, йә шигырь язып җибәрә башлый. Тора-бара ахырда «Рәшит Әхмәтҗанов» дип язылган мәкаләләр газет битләрендә еш очрый. Шигырьләре дә әйбәт кенә чыга. Дөресен әйтергә кирәк, баштарак аның турында «ай-һай, бу малай үзе яза микән, әллә берәр җирдән чәлдерә микән?» дигән икеләнүләр дә туа иде.

Бервакыт редакциягә яшь кенә егет килеп керде. Аның кулында чемодан, аркасында рюкзак. Ул күрсәтелгән урынга кыяр-кыймас кына утырды да:

– Мин Рәшит Әхмәтҗанов булам,– диде.

Ул, төзүчеләр курсын тәмамлап, ташчы һөнәре алган. Күп кенә иптәшләре белән бергә чирәм җирләргә китәргә теләк белдергән дә, менә шунда китешли керүе икән.

Рәшит Әхмәтҗанов Кандыз совхозында ташчы булып эшләде. Сынатмады, тырышты.

Рәшит, кайда гына эшләсә дә, үз өстендә икеләтә җаваплылык сизә. Ул газетка актив языша. Уңышлыкларга сөенеп, кимчелекләргә көенеп, аларны бетерүне таләп итеп, төрле темаларга хәбәрләр, мәкаләләр, репортажлар, шигырьләр җибәрә. Быел Рәшит Әхмәтҗанов Акбуаның 2 нче урта мәктәбендә 9 нчы класска укырга керде. Һәм бик дөрес эшләде. Укы, эзлән, иҗат ит, егет! Бөтен кешелек дөньясының якты киләчәге булган коммунистик җәмгыятьне төзү өчен белемле һәм тынгысыз кешеләр кирәк.

*«Байрак» газетасы (Баулы).– 1959*

# Яшь авторның беренче китабы

Данис Хәбибуллин

Әдәбият белән кызыксынучы һәр иптәш, китап кибетенә кергәннән соң, беренче чиратта яшь һәм башлап язучылар җыентыгын сатып алырга тырыша. Чөнки теге яки бу иптәшнең әдәбиятта әле билгеле булмаган яңа бизәк табуы, телдән ни дәрәҗәдә оста файдалануы кызыксындыра.

Безнең кулда Рәшит Әхмәтҗановның Татарстан китап нәшрияты тарафыннан чыгарылган «Хыялларым үзем белән» җыентыгы. «Тирәкләрнең шаулавына кушылып җыр башлаган» Рәшитнең шигырьләре белән без 1959 елда танышкан идек. Ул вакытта ук Әлмәт шәһәрендә ташчы булып эшләүче 18 яшьлек бу егетнең беренче шигырьләренә сокланган идек. Иң әһәмиятлесе: Рәшитнең үз моңы, үз тавышы бар. Ул тормышны үзенчә күзәтә һәм, иң куанычлысы, күзәтүләрен үзенчә сөйләп бирә белә.

...Яз кояшын күргәч зәңгәр күктә,
«Алып бир» дип, кулым сузганмын.
*«Безнең тәрәзә»*

Сабыйлар өчен шуннан да табигый деталь бармы икән.

...Үзең җирдә җылыныр җылы барын
Мине уйлый-уйлый оныттың,—

дип дәвам итә автор аналарга булган тирән мәхәббәт хакында. Ышандырырлык һәм дулкынландырырлык юллар. Гади, ләкин укучыга нык тәэсир итә торган шундый строфалар «Ана сүзе», «Озатканда», «Диңгездә», «Таш күтәреп тала буыннарым» һәм башка шигырьләрендә дә бар.

Авторның мәхәббәт темасына язылган шигырьләре дә үзенчәлекле. Аның герое тыйнак, оялчан һәм кыюсыз. Ул сөйгәненә алтын таулары бүләк итү түгел, үзенең керсез сөюен дә әйтергә тартына. Ләкин бу сөю — чын сөю, көчле сөю.

...Күз йомарга әзер чәчәкләр,
Такыялар үрсәң бүтәнгә,—

ди лирик герой «Зәңгәр кыңгыраулар өзәргә» дигән шигырендә.

Шигырьләр арасында дүртьюллыклар да бар. Тик аларның кайберләре уңышсызрак чыккан. Мәсәлән, «Кышкы парчалар»да:

...Ә буран хәзер — мине калдырып
Еракка киткән гүзәл кыз туе,—

дигән юлларны ничек аңларга? Мәхәббәткә кул селтәп киткән кызлармы, алай булгач, нигә гүзәл ул?

Мин учак яктым. Әткәм яраткан
Кыр курайларын утта яндырдым.
Җыр кирәк миңа! Шуңа онытып,
Тик бер минутка җылынып калдым,—

строфасында да фикер ачык түгел.

Яшь авторларга хас булганча, кайбер чатаклыклар гына, әлбәттә, китапның бәһасен төшерә алмый, һәм шуңа күрә поэзия сөючеләр бу китапчыкны яратып кабул итәрләр дип уйлыйбыз.

*«Татарстан яшьләре» газетасы.— 1964. — 30 апрель*

# Ташлардан көч алам...

## Рәшит Саттаров[1]

Таш һәм ташчы турындагы сүземне мин шигырьдән башларга уйлыйм. Бу, беренче карашка, кайберәүләр өчен, бәлки, сәер дә тоелыр, әмма шигырь белән ташның уртак яклары бар, диясем килә.

Таш күтәреп тала буыннарым,
Ташлардан ук үзем көч алам.
Яшьлек, яшьлек,
Синең сафларында
Тау-ташларны ватып сыналам.



**Саҗидә һәм Хәниф Әхмәтҗановларның армия сафларында хезмәт иткән 8 улларыннан берсе – Рәшит. Самара хәрби часте. 1960**

Бу юлларның авторы – Рәшит Әхмәтҗанов. Ул әле бүген Совет Армиясе сафларында хезмәт итә. Гади ташчы иде, солдатка безнең төзелештән китте. Бирегә килгәнче аның поэзиягә мөнәсәбәте аз булган. Ул бездә кирпеч өйде, балта тотып, тәрәзә яңаклары, ишекләр ясады, пумала алып, бүлмәләрне буяды. Еш кына мин аның эшләгәнен күзәтә идем: стенаның тышкы ягына салыр өчен, бер өем кирпеч араларыннан үзенә ошаганын эзләп ала иде ул. Кайчакларда цементлап салган кирпечне ераккарак барып карый да, нидер килештермичә, кабат алыштырып куя. «Нигә алай итәсең?» – дип сорагач, ул: «Бусы матуррак,– ди.– Кешеләр, караганда, чыраен сытарлык булмасын».

Рәшит салган кирпечләр арасыннан бервакытта да цемент бүлтәеп тормый, аның кирпечләре бер-беренә шундый тигез яталар, аларның җөен дә күрмисең. Ул, эшен төгәлләгәч, озак кына йортның стенасына карап, хезмәтеннән ләззәтләнеп тора иде. Кайвакытларда мин аның эшләгәндә авыз эченнән генә нидер көйләгәнен дә ишетә идем. Ул җырлап эшли. Күңелдә җыр булдымы – кеше эшен ярата. Димәк, ул тормышта матурлыкны күрә белә.


Бераздан мин ташчыбызның шигырьләр язганын белдем. Җаен туры китереп, аның дәфтәрен укып карыйм: чынлап та шигырь юллары. Рәшит үзенең хезмәте – ташчы һөнәре турын-

[1] Әлмәт шәһәренең 8 нче төзү-монтаж тресты җитәкчесе, Социалистик Хезмәт Герое.

да язган. Шулвакыт аның үз эшен җаны-тәне белән сөйгәненә тагын бер кат ышандым.

Йортлар төзим...
Изге уйларымны
Җилме килеп бүлә, буранмы,—
Барын җиңеп, кайнар яшьлек хисем
Матурласын, әйдә, урамны.
Арып узыйм, талып узыйм әле,
Янып узыйм юллар арасын,
Һәр ташымны мин куанып салам,
Уйлыйм моннан дуслар барасын.

Шигырь миңа бик ошады. Ул һәр кешегә дә ошыйдыр. Ләкин минем шигырь турында түгел, бәлки аның авторы турында сөйлисем килә. Нишләп соң ул төзелешкә килгәч кенә шигырьләр яза башлады? Бу сорау мине әле дә уйландыра. Моның сәбәбен шуннан күрәм: Рәшит, безгә эшкә килү белән, матурлыкны үз кулы белән тудыра башлады һәм шул вакытта аңа чын мәгънәсендә игътибар итте. Хезмәт вакытында туган бу матурлык белән кызыксыну аның эчке дөньясын баетты, егетнең хисләре шигырьгә әйләнде, һәм ул поэзия юлына ныклы адым ясады, шуннан язмый булдыра алмады.



**Р. Әхмәтҗанов: «Буыннарым аша шулай таулар көчте: Таш ватылган тавышлар бар тавышымда».**

«Ул, бәлки, төзелешкә килмәсә дә шагыйрь булыр иде»,— диләр миңа. Бәлки, шигырьләр язар да иде. Әмма Рәшит төзелештә үз урынын тапты, шунда бөтен игътибарын биреп эшләде, хезмәт барышында матурлыкны тоярга өйрәнде.

Кеше сихри табигать куенында да яшәргә мөмкин, әмма матурлыкның аңа тәэсир итмәве бар. Чөнки хезмәтне ул үз йөрәгe аша тирән кичерми, һәм мин: «Рәшитне бары ташлар шагыйрь итте»,— дип уйлыйм.

Төзүченең матурлыкны тоя белүе турында сөйләгәндә, хәтергә сугыш еллары искә төшә. Үземдә ташчы булу теләге менә шул дәһшәтле көннәрдә, коточкыч бер вакыйгага дучар булган чакта туды. Блокадада калган Ленинград урамында йөри идем. Авыр бомба төште дә минем каршымда гына торган сигез катлы йортны урталай ярып ташлады, һәм йорт белән бергә минем йөрәгем дә ярылгандай булды. Тревога беткәннән соң, җимерек йортны карап йөрим. Нинди матур йорт хәрабә хәленә килгән. Кирпечләрне, архитектура бизәкләрен кулым белән тотып карыйм. Кеше кулы нәрсә генә эшләмәгән! Нинди нечкә һәм катлаулы икән ул төзелеш!

Солдаттан кайту белән, мин тешем-тырнагым белән төзү эшенә ябыштым.

Әле Рәшиткә хат яздым: «Уяу бул,— дидем,— без тудырган матурлыкны бомба җимерерлек булмасын! Алар кешеләрнең күңелләрен җылытсыннар, күзләрен иркәләсеннәр!»

Соңгы сүз итеп шуны әйтәсем килә: төзелеш — таш һәм кирпеч салу гына түгел, ул — сәнгать эше, кешеләрнең рухын өйрәнү эше, батырлык эше.

*«Татарстан яшьләре» газетасы.— 1964*

# «Хыялларым үзем белән»

Әдип Маликов

Берьюлы ике бәхет: үзең төзүче бул, таштан йортлар сал, кешеләргә сөенеч китер һәм шунда туган хисләреңне бергә тупла да, кешеләргә аларны тагын җыр итеп өләш. Сүз яшь шагыйрь Рәшит Әхмәтҗанов турында бара.

Моннан берничә еллар элек без аны Социалистик Хезмәт Герое Рәшит Саттаров бригадасында күрә идек. Ул Әлмәт шәһәрен төзүдә катнашты. Эштән соң кичке мәктәпкә ашыкты, шигырьләр язды.

Эш киемен салырга да өлгермәгән Рәшит, яңа шигырь парчаларын тотып, түгәрәк утырышына яки турыдан-туры өйгә килә. Без аңа: «Бу юлларың бик үк аңлашылмый бит»,– дигәч, ул кызарына, маңгаеннан тирләрен сөртә. «Әйе шул,– ди ул ахырдан, ризалашып,– үземә дә шулай тоела», һәм икенче көнне инде без шигырьнең гади, отышлы вариантын укыйбыз:

Таш күтәреп тала буыннарым,
Ташлардан ук үзем көч алам.
Яшьлек, яшьлек,
Синең сафларыңда
Тау-ташларны ватып сыналам.
Юллар салам...
Изге уйларымны
Җилме килеп бүлә, буранмы? –
Барын җиңеп, кайнар яшьлек хисем
Матурласын, әйдә, урамны.

Рәшит Әхмәтҗанов, Әлмәттән киткәч, икенче зур сынау үтте. Ул өч ел Совет Армиясе сафларында хезмәт итте һәм хәзер В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетында укый.

Укучы кулында бүген яшь авторның утыз шигырьдән торган беренче җыентыгы. Аны укый башлагач, үзеңне якты, зур дөньяга кергәндәй хис итәсең. Шигырьләрдә тышкы ялтырау да, купшы сүзләр дә юк. Алар тормышның үзе шикелле кырыс һәм табигый яңгырыйлар. Алар ничектер эчтән яктырып, нурланып торалар шикелле:

Хыялларым һаман үзем белән,
Кирәксенмим чакма чаткысын.
Күрәсезме, тауның күкрәгенә
Алып керәм кояш яктысын,–

ди шагыйрь. Лирик герой җирдәге сихри моңнарны бөтен кешеләргә тигез итеп бүләргә әзер. Аның сафташлары кояш белән бергә уяналар, кыяларны ватып, бәхет сарайлары салалар. Әмма автор дөньяның матурлыгы белән генә мавыкмый, ул кисәтеп куя:

Җир шарым, уяу бул үзең дә!
Куенында яшеренеп торалар...
Шартласа – сине дә, мине дә
Урыннан кузгатыр бомбалар.



**Төзүче яшьләр**

Җыентыкка кергән күп кенә шигырьләргә гомумиләштерү, философик фикер йөртү хас:

Алмаларны күреп куана,
Сабый әле, диләр, берәүләр.
Кулда алма – кояш шикелле,
Ә җанымда – тоташ күкрәүләр...

Бу юллар күп нәрсә турында сөйли. Аларга аңлатма бирүнең кирәге дә юк. «Тоташ күкрәүләр...» Яшь шагыйрьгә без киләчәктә дә шуны теләр идек.

Рәшит Әхмәтҗанов, мәхәббәт темасына кагылганда да, кайбер яшь авторлар шикелле, төчеләнү, яшь кою белән мавыкмый. «Зәңгәр кыңгыраулар өзәргә», «Гөлнәзирә», «Әлмәт кызы», «Ничек соң синең исем?» дигән шигырьләр, мәсәлән, тормыштан аерылмаган олы мәхәббәт хисе белән сугарылганнар:

Сагынганда, иркә сүзең килер,
Җылың килер, өши башласам.
Туган илем олы улы итмәс –
Олы юлда йөрми яшәсәм,–

ди шагыйрь.

«Хыялларым үзем белән» дигән шигырьләр китабын җәмәгать эше тәртибендә Зәки Нури редакцияләгән. Авторга карата ул таләпчән килгән, арадан иң әйбәт шигырьләрне генә сайлап алган. Рәшит Әхмәтҗанов үзе дә киләчәктә бу таләпчәнлекне киметмәс, тагын да матуррак шигырьләр бирер, дип ышанасы килә.

Хәерле юл сиңа, ташчы һәм шагыйрь дус!

*«Социалистик Татарстан» газетасы.– 1965*

# Яшь шагыйрьләрне укыгач...

*(Мәкаләдән өзек)*

Мөхәммәт Мәһдиев

Минем өстәлемдә – студент-шагыйрь Рәшит Әхмәтҗановның «Хыялларым үзем белән» дигән кечкенә генә китабы. Р. Әхмәтҗановны мин бу китап дөньяга чыкканчы ук белә идем. Без аның белән фәнни экспедициядә – Курган өлкәсендә, көмештәй күлләр, каен урманнары арасында йөрдек. Шунда Р. Әхмәтҗановның табигатькә гашыйк икәнен күрдем.

...Менә төн җитә. Күл өсте, офык белән тоташып, бакыр төскә керә. Күл уртасындагы камышлар арасында кыр үрдәге, кыр казы һ.б. кош-кортларның сихри тормышы башлана... Тормыш, тормыш... Җир шары әйләнә, көнне төн алмаштыра, тереклек дөньясы гөж килә. Шагыйрь күңеле әнә шуларны сизә, тормыш турында, җәмгыятьтә шәхеснең урыны турында уйлана... һәм шигырь туа:

Җир шарым,
Кайдадыр үзендә,
Куенында яшеренеп торалар.
Шартласа – сине дә, мине дә
Урыннан кузгатыр бомбалар!

Р. Әхмәтҗанов – университет студенты. Һәм, әйтергә кирәк, бик үк тырыш, мактаулы студентлардан түгел. Сессия вакытларында, теоретик курсны йомшак белгән өчен, мин аңа «өчле» билгесе куям. Фәннәрне үзләштерергә, утырып укырга анда ихтыяр көче җитми. Бу хәл аның поэзиядә бер җирдә таптану куркынычын тудыра. Югыйсә егеттә тормыш күренешләренең лирикасын аңлау сәләте көчле генә. Әнә шуны үстерергә, конкрет тормышка күчерергә өйрәнергә кирәк. Р. Әхмәтҗанов аяк астындагы җирне, аның чәчәкләрен, үләннәрен, җиләкләрен күңеле белән тоя. Ул җиргә, җирдәге тормышка гашыйк. Аның гыйшкы да – «кулына тал тубалын тоткан» Җир кызы:

Кулыңда тал тубалың бар,–
Тубалда җиләкмени?
Шатлыклар көтәсеңдер син,–
Сагышлар кирәкмени?

Р. Әхмәтҗановта да, Р. Фәйзуллинда һәм Г. Родионовта да абстрактлык бар. Әйтик, өлгергән, дөнья кичкән тәҗрибәле шагыйрьләр үзләренең бай тормыш тәҗрибәләрен, фәлсәфи фикерләрен шигырьгә салалар икән, бу – поэзиянең тирәнәюен күрсәтә, андый шигырьләр безнең күңелне җәлеп итә. Ләкин егерме яшьлек шагыйрьләр планета, галәм язмышы турында гына каләм тибрәтәләр икән, бу хәл миндә шикләнү уята. Нигә үзеңне чолгап алган гади кешеләрне җырламаска? Нигә конкрет сурәт бирмәскә? Сергей Есенин көчек балалары һәм карт сыер турында да әдәбиятның патриархы Горькийны тетрәтерлек итеп язган бит. Яшьләребездә әнә шундый гади тормыш күренешләренә югарыданрак карау сизелә.

*«Социалистик Татарстан» газетасы.– 1965*

# Канатлар ныгыганда

Равил Вәлиев

Университет турында сөйләгәндә, татар теле һәм әдәбияты бүлеге каршында инде күптәннән эшләп килүче әдәбият-иҗат түгәрәге турында дәшми калу мөмкин түгел. Алар нәкъ бертуганнар кебек, һәм бу аңлашыла да. Чөнки безнең тарих-филология факультетына күбесенчә матур итеп уйларга һәм хыялланырга яратучы яшьләр килә бит.



**Дусты Шәүкәт белән**

Татар совет әдәбияты үсешенә инде үз өлешләрен кертергә өлгергән әдипләребез Гариф Ахунов, Мәхмүт Хөсәен, Эдуард Касыймов, Самат Шакир, Әхмәт Юныс һәм башкалар да яшь каләмнәрен башлап шушында тибрәтә башлаганнар. Хискә бай талантлар әле дә ел саен түгәрәк әгъзалары сафына өстәлеп торалар.

Солдат гимнастёркасын салып, узган ел гына студентлар гаиләсенә килеп кергән яшь шагыйрь Рәшит Әхмәтҗанов, мәсәлән, шундыйларның берсе. Татарстан китап нәшриятында быел аның «Хыялларым үзем белән» дип исемләнгән беренче шигырьләр җыентыгы басылып чыкты. Кечкенәдән үк хезмәт давылы эченә кереп китеп, тормышның әчесен-төчесен аз-маз татырга өлгергән Рәшитнең каләменә тирән моң, үз кичерешләрен башкаларда да хис уятырлык итеп сурәтләп бирә белү хас. Чыннан да, авторның үз маңгай тирләре белән дә чыланган кирпечләрдән Әлмәт шәһәренең стеналары бертуктаусыз күккә ашып торганда туган менә мондый юлларны укыгач, ничек итеп салкын гына кала аласың?

Таш күтәреп тала буыннарым,
Ташлардан ук үзем көч алам.
Яшьлек, яшьлек, синең сафларыңда
Тау-ташларны ватып сыналам.

Түгәрәкнең һәр ел саен чыгып килүче «Безнең тавыш» исемле үз әдәби журналы бар. Буе унар метрга җитеп, бөтен стенаны тутырып торучы «Әдәби сүз»ләр дә бик еш чыгып тора. Моннан тыш, түгәрәк утырышларында уянган әдәби бәхәсләрне, танылган язучылар белән очрашып торуларны да искә алсак, яңа гына чыккан канатларны ныгытып, киң әдәбият күгенә омтылу өчен мөмкинлекләрнең бик күп булуы ачык күренә.

Теләк тә җитәрлек.

Кыскасы, уңыш телик без аларга иҗатларында!

*«Безнең Чирмешән» газетасы.— 1965*

# Күтәрелеш еллары

*(Мәкаләдән өзек)*

Рафаэль Мостафин

Рәшит Әхмәтҗановны дөньяны шигъри сурәтләүдә Р. Харисовның антиподы дияргә була. Ул — сүзнең тәмен белә торган ифрат халыкчан шагыйрь. Р. Харисовтан аермалы буларак, ул образның стихия көченә ышана, шул көч аны үз артыннан ияртеп алып китә. Ләкин кая! Моны еш кына шагыйрь үзе дә белми. Моннан берничә еллар элек «Казан утлары» журналы битләрендә яшь авторның бер төркем шигырьләре чыккан иде. Шуларның кайберләре беренче укудан ук хәтергә сеңеп калды:

Без мәңгегә, без мәңгегә монда,
Их, бу җирне күпме таптады
Безнең йөрәк бәйрәмнәренең
Кыңгыраулар таккан атлары!

Хәзер бу юллар шигырь яратучы һәркем телендә. Шигырьнең соңгы ике юлына игътибар итегез. Образ төзелеше ягыннан никадәр катлаулы алар. Берсе өстенә икенчесе өелгән метафоралар арасыннан иң үзәктәгесен, иң әһәмиятлесен табып алу — шактый кыен эш. Ләкин шигырьнең төп пафосы шулкадәр эчкерсез, авторның хисләр агышы шулкадәр көчле ки, үзебез дә сизмәстән без шигырь стихиясенә ияреп китәбез һәм әлеге юллардагы мәгънә тирәнлеген, акыл белән аңлаудан да бигрәк, күңел, йөрәк белән тоябыз.

Рәшит Әхмәтҗанов — зур мөмкинлекләре булган, шуларга да карамастан бик аз яза торган шагыйрь. «Казан утлары» журналының 1971 елда чыккан саннарының берсендә аның дүрт кенә шигыре бар иде. Әмма аларның һәрберсендә Рәшитнең үз йөзе, үз стиле ярылып ята. Әгәр Р. Фәйзуллин белән Р. Харисов моңарчы беркайда да очрамаган яңа образ уйлап табарга яки электән яшәп килгән образның яңа якларын ачарга тырышсалар, Р. Әхмәтҗанов, кагыйдә буларак, традицион образ-метафораларның халыкта киң таралган мәгънәләренә таяна. «Сугыштан кайталмаган егет сүзләре» исемле шигырендә ул, мәсәлән, халык иҗатында сафлык, пакьлек символы булып йөргән образны менә ничек файдалана:

Иелеп-иелеп ак каеннар сорый,
Ак розалар сорый шул хакта:
Нигә соң мин яшь шаһзадә булып
Килалмадым сиңа ак атта?

Ләкин шагыйрь халык иҗатындагы традицияләрне кабатлау белән генә чикләнми. Ул аларны үстерә, баета, аларга яңа ямь бирә.

*«Казан утлары» журналыннан*

# «Адымнар»

*(Мәкаләдән өзек)*

Нурмөхәммәт Хисамов




Өч яшь шагыйрь тарафыннан бергәләп чыгарылган «Адымнар» (Татарстан китап нәшрияты, 1969) җыентыгы укучы күңеленә күптән барып ирешге. Аның хакында матбугатта сүз әйтер вакыт җиткәндер.

Бер җыентыкта бер-берсеннән шактый аерылып торучы өч авторның шигырьләрен туплап бирү яшь замандашыбызның бүгенге гражданлык импульсларын тоярга һәм рухи йөзен шактый киң абайларга мөмкинлек бирә. Китап авторлары төрлесе төрле адым белән бер сызыктан атлый диярлек. Менә шактый йөгерек адымнар белән Тәуфикъ Камалиев килә. Уртадан – берәгәйле, озын адымнар белән Рәшит Әхмәтҗанов, икенче кырыйдан елмаеп, салмак кына Шамил Маннапов атлый...

Рәшит Әхмәтҗанов шигырьләре «Егет җыры» дигән баш астында тупланган.

Шагыйрьнең «егете» тормышның зур сынауларыннан качмаучы, бәлки алар белән үзе очрашу эзләп йөрүче, киеренке эчке тормыш белән яшәүче бер кеше булып күз алдына килеп баса. Егет зурдан фикер йөртергә ярата. Аның шигъри фикерләвендә башка ишләрендә булмаган үзенчәлек шуннан гыйбарәт. Ул – тормышның катлаулы хәрәкәтен табигатьнең җанлы стихиясенә күчереп карый һәм шунда бик гыйбрәтле хакыйкатьләрне ачып куя, зирәк-зирәк нәтиҗәләр ясый. Аның шигырьләре үзәгендә ил, халык, батырлык, тугрылык кебек олы кешелек кыйммәтләре ята. Егет һаман зур сынауларга, батырлыкка хәзерләнеп яши сыман. Шагыйрь аның шул сынауларга яраклылыгын кискен драматик кичерешләр аша үткәреп, тикшереп карый. Шушындый һәр тикшерүдән ул герой сафланып, кешелеклерәк булып, яктырып чыга.

Кичерешләрнең драматик үткенлеген бирү өчен, Р. Әхмәтҗанов антитезаны актив куллана. Ул, кагыйдә буларак, мәңгелек кыйммәтләрне вакытлы, узачак һәм бетәчәк күренешләр белән янәшә куя. Парадокс дәрәҗәсендәге контрастлар геройның олы кичерешләр балкышын бирә:

Йөрәккә кагыла салкын сүз,
Җылы кул, салкын таш, җылы җил.
Барысы да тарала, югала –
Кала тик туган ил, туган җир.

Көннәрнең асыл рухын автор бик дөрес сиземли. Халыкның үлемсез киләчәккә юл тотканда үзләренең үткәннәрдәге батыр сәхифәләрен барлап, автор алардан яңа яшәү куәте ала:



**Сулдан уңга: Габделхәй Сабитов, Рәшит Әхмәтҗанов, Шамил Маннапов. Казан. 1971, июль**

Чәчте, урды халкым,
Горур булды,
Үз язмышын ятка бирмәде.
Кешеләрнең бүген туган җирдән
Үлемсезлек алган көннәре. *«Бәйрәм»*

Халыкның мәңгелек яшәү хокукы нигезле хәтәр сынаулардагы намуслы җиңүләре белән ныгытылган.

Шул рәвешле, олы фикерләр аңарда чын мәгънәсендә шигъри гәүдәләнеш таба. Шагыйрь шигърияттнең булуын дөньяны яктыртудагы музасының шушы көченә ышана. Бу мәсьәләне һәр шагыйрь куя һәм чишәргә омтыла. Р. Әхмәтҗанов исә, беркемне дә кабатламыйча, үзенчә чишә алган:

Бу кышкы төннәр күңелдә
Кояшны эзләп килә.
Иртәгә кояш нәкъ минем
Күңелдән чыкмас димә. *«Алдан әйт»*

Р. Әхмәтҗанов үзенең лирик героен еш кына табигать стихиясенә куеп карый. Һәр сынаудан ул егетләрчә нәтиҗә ясый:

Йөрәккәем ташка уелса да,
Юк, куркыныч түгел бу дөнья!..

*«Татарстан яшьләре» газетасы.— 1970*

# Рәшит Әхмәтҗановны Язучылар берлегенә тәкъдим итү

*Хәсән ага!*

*Рәшитнең әйберләрен карап чыга алмассызмы икән? Һаман сузыла бит. Шушы айда тикшереп аласы иде инде аны.*

*Үзем Түбән Камага китәм. 20–25 ләрсез кайта алмам кебек. Мин кайтуга әзер булсагыз, җыелып алыр идек. Гәрәй Рәхим инде әзер.*

*Сәлам белән, М. Шабаев*
*7/IV. 1970*

## *Тәкъдим*

Рәшитнең беренче шигырьләренең берсе «Давылда» дип атала. Анда кыя ташка котырынган давыл бәрелгәндә, бөркет үз баласының очышын сынап карарга тели.

Каерыла бугай канатлары –
Бер югары оча, бер түбән...
Бөркет әйтә кебек:
Очалмасаң,
Синең өчен түгел тау түбәм!

Әйе, поэзия Парнасы түбәсендә яшәр өчен дә саескан булып кына түгел, бөркет булып, талант бөркете булып туарга һәм сыналырга кирәк. 1957 елда 16 яшьлек Рәшит Әлмәтнең нефтьчеләр газетасы редакциясенә беренче шигырен китерә. Редактор белән секретарь укып карыйлар да,


Сибгать Хәким һәм Хәсән Туфан



**Хәсән Туфан — сулдан өченче, Рәшит Әхмәтҗанов — дүртенче, Мәхмүт Хәсәнов — бишенче**

бераз гаҗәпләнеп үзара ымлашып алганнан соң: «Үзең яздыңмы соң бу шигырьне? — диләр. 16 яшьлек малайның мондый шигырьне яза алган булуына ышанып җитмиләр.— Безгә менә хәзерге көз көне турында бер шигырь кирәк иде, язып кара әле»,— дип, Рәшитне бер буш бүлмәгә кертеп, ишекне бикләп куялар.

Нигә язмасын, ачык һавада — яңгырлар астында да ташчы булып эшли башлаган бу егеткә Әлмәт көзе бик таныш ич, яза. Һәм бу сыналу шигыре газетада басылып та чыга.

Алтмышынчы еллар башында Сибгат Хәким белән Әлмәт ягына, халык арасына чыккан идек. Безнең номерга, кыяфәте һәм холкы белән Шәүкәт Галиевне хәтерләткән бер сөйкемле егет килеп керде. Рәшит исемле бу егет үзенең шигырьләрен укып карарга, киңәш алырга теләвен әйтте.

Укыдык. Шигырьләрен дә, үзен дә яраттык. Ләкин без дә, Әлмәт газетасы редакциясендәге вакыйганы белмәсәк тә, сынап карарга теләгәнбездер, күрәсең: шигырьләренең кайберләрен төзәтеп-үзгәртеп, яңадан язып китерергә киңәш бирдек. Икенче көнне үк үзе төзәткән вариантларны алып килде. Шактый таләпчәнлек белән тагын бер кат күздән кичердек һәм «әдәби табыш икән бит бу егет» дигән фикергә килдек.

Рәшит Әхмәтҗановның шигырьләрен безнең зур журналда һәм башкаларда дөньяга чыгара башладык. Рәшит безнең өметләрне тулы рәвештә күптән раслады инде.

Рәшитнең кайбер шигырьләрендә Гарсиа Лорка йогынтысы бардыр кебек тоела (мәсәлән, «Әллә инде кыр казлары кайта» шигырендә). Рәшит ләкин Испания чегәннәре фольклорына гына хас булган «табышмакны», катлаулы метафораларның йомшак якларын, татар шигыренә ят икәнлекләрен яхшы белә. Рәшитнең әйтми, ә сурәтли торган үз теле бар. Үз кичерешләрен генә түгел, халык йөрәгендәге кичерешләрне дә чын шигырь югарылыгына күтәреп, образлар аша әйтеп бирә ала ул.

Рәшит — гаҗәп әдәпле, тыйнак талант ул. Газеталарда, журналларда чыккан шигырьләре генә дә аның инде күптән член булырга тиеш икәнен раслаганнар иде. Алыйк без Рәшитне үз арабызга, татар Парнасына. Аның иҗади канатлары давылларда сыналган инде.

*Хәсән Туфан*
*1970, май*

## Рекомендация




Поэта Рашита Ахметзянова знаю с 1965 года, когда непосредственно участвовал в выпуске его первой книги стихов «Хыялларым үзем белән» («Всегда с мечтой»).

Стихи этой книги он написал в краю нефтяников – работал каменщиком на нефтяных стройках. Они были полны чувств любви к труду, к мечте и были полны призывом к подвигу, к любви окрылённым в труде людям. Затем, в 1969 году, он издал такого же характера и плана книгу «Егет җыры» совместно со сверстниками и собратьями по перу. Мне известна его последующая книга «Җиде кубыз», уже сданная в книжное издательство. Многие стихи Рашита Ахметзянова печатал и печатает журнал «Казан утлары», редактором которого являюсь я.

В творчестве поэта отчётливо видится время, современность, характеры людей – тружеников, новое в их взаимоотношениях, черты нового в жизни народа.

Считаю, что Р. Ахметзянов обязательно вырастит в поэта большого, масштабного, ибо знаем мы его всегда ищущего новое слово, работающего вдумчиво, требовательно к себе и своим товарищам, хорошо знающего детали жизни и жизненных людей. В члены Союза gисателей его нужно принять.

*Заки Нури*
*1970, 7 июля*

## Татарстан Язучылар берлегенең поэзия секциясе утырышы беркетмәсе[1]

*1970, 29 апрель*

*Шагыйрь Рәшит Әхмәтҗанов иҗатын тикшерү*

Катнашалар: Х. Туфан, И. Юзиев, М. Шабаев, Г. Рәхим, Р. Батуллин, Р. Гатауллин, Р. Мингалимов, Ә. Синегол, К. Латыйпов, Ә. Баянов, Р. Миңнуллин, Җ. Тәрҗеманов, Шамил Закиров, Р. Вәлиева, Рафис Әхмәтов, Г. Зәйнашева, Б. Сөләйманов, Зөлфәт һ.б.

Председатель – Марс Шабаев.

*Гәрәй Рәхим чыгышы.* Рәшит 1960–1961 елларда Әлмәттә яшәде.Әлмәт бүлегенең иң чәчәк аткан, үсеп килгән чагы. Лениногорск түгәрәге дә бик нык үскән иде. Шунда Ш. Бикчурин Рәшит шигырьләре белән таныштыра иде. Ул чакта әле мин шигырь сөюче бер фанатик идем. Шунда Рәшит Әхмәтҗановның шигырьләрен укып рәхәтләнә идем. Аның шигырьләре ул елларда «Совет әдәбияты» журналында еш чыктылар. Рәшит үзе Әлмәтнең төзү ветераны Рәшит Саттаров бригадасында ташчы булып эшли иде. Минем өчен Рәшит Әхмәтҗанов инде шул елларда ук шагыйрь иде. Дөресен әйтергә кирәк, ул елларда әле эшче образы, гомумән, әгәр шулай әйтергә яраса, производство темасы безнең поэзиядә күбесенчә гаять примитив, төссез, кеше образыннан башка гына, тимер-томыр, эш коралларын сурәтләү белән генә бирелә иде. Ә Рәшит шигырьләрендә эшче, конкрет алганда ташчы образы гаять тормышчан, табигый, шул ук вакытта зур хисле лирик герой булып сурәтләнде. Менә шул елларда язылган «Таш күтәреп тала буыннарым» дигән шигыреннән өзек:

[1] Беркетмә Р. Әхмәтҗановның шәхси архивыннан алынды.– *Төз.*

Таш күтәреп тала буыннарым,
Ташлардан ук үзем көч алам.
Яшьлек, яшьлек, синең сафларыңда
Тау-ташларны ватып сыналам.

...Арып узыйм, талып узыйм әле,
Янып узыйм юллар арасын.
Һәр ташымны мин куанып салам,
Уйлыйм моннан дуслар барасын.

Киләчәктән килгән шатлык итеп
Шуны әйтәм, аем-кояшым:
Җир ныклыгы булгач буыннарда,
Күтәрмәскә нигә җир ташын!

1965 елда Рәшитнең «Хыялларым үзем белән» исемле беренче җыентыгы чыкты. Бу җыентыкта производство темасы төп урыннарның берсен алып тора. Ташчы образы бу китапта шигырьдән шигырьгә күчеп килә, китапны бөтенләтә.

Гомумән, таш детале Рәшит иҗатында һаман саен күренгәләп килә. 1969 елда «Адымнар» исемле өч шагыйрь әсәрләре тупланган җыентыкта да күренә бу:

Ташлар белән үтә танышлык бар,
Мин аларга күптән бәрелдем.
Күп шакыдым ташка,
Ниндилеген әйтеп хәлемнең.
Ташлар ярып чыга агымсулар,
Ташны ярып үсә имәннәр.
Башны ташка бәреп,
Ташны күптән
Бабаларым вата белгәннәр.

Бая әйтеп киткән шигырь белән бу шигырь дөнья күрү арасында 4 ел вакыт бар. Ә язылуына 10 ел чамасы бардыр. Шунысы кызык: алдан укып үткән шигырьдә ташчы образында ниндидер романтик рух, горурлык һәм үз эшенә мәхәббәт хисләре яңгырый. Ул шигырь ничектер хис шигыре буларак көчле. Ә инде менә бу шигырьдә Рәшит таш турында бөтенләй башкача, фәлсәфи фикер йөртә. Дөрес, монда да горурлык бар, ләкин бу инде аңлы, фәлсәфи горурлык. Шигырьнең көче без күптән ишетеп белгән «башны ташка бәреп вату» дигән төшенчәгә каршы килеп, киресенчә башны ташка бәреп таш вату, ягъни хезмәттәге осталыкны тоеп, шуны фәлсәфәгә күтәрүдә.

Рәшит — лирик шагыйрь. Ул — баш-аягы белән шигырьнең матурлыгына, дөнья белән соклануга, нечкә лиризмга чумган егет. Дөресен әйтергә кирәк, Рәшитнең лирикасы беребезгә дә охшамаган, ул үзенчә яза белә. Артык зур сүзләр кулланмыйча, татар теленең иң зәвыклы, иң итагатьле тәгъбирләре белән шигырь төзи:

Күз йомарга әзер чәчәкләр,
Такыялар үрсәң бүтәнгә.

Яки:

Тормыш, тормыш, нинди күңелле син,
Әй, татлы да синдә моңаю.

Имән турындагы шигырендә:

Сынагандай итеп әле аңа,
Әле миңа кагыла җил-давыл.

Яки бер кызга эндәшә:

Мин — җирнең кече малае,
Ничек соң синең исем?

Яки:

Бала чагында җылыткан кояш
Җылыта икән гомер буена.

Әнисенә багышлаган шигырьдән:

Ә таш ярда әнкәй керләр чайкый,
Уе китә сулар төбенә.
Әй, ул гүя шулай диңгез айкый,
Телбизәкләр эзләп телемә.

Яки менә бу юллар:

Кемдер гүя мине
Алсу алма биреп алдаган.

Менә шушы кечкенә-кечкенә өзекләрдән дә Рәшит Әхмәтҗановның гаять нечкә лирик тоемын сизәргә мөмкин. Дөресен әйтергә кирәк, шушындый лирик, якты һәм өр-яңа детальләрне яшьләр арасында Рәшиттән дә оста тотып алучылар сирәк әле.

Рәшитнең иҗатында гражданлык лирикасы да шактый урын алып тора. Дөрес, Рәшит бу жанрда, кайберәүләр кебек, кирәгеннән артык төче пафоска бирелеп китми. Аның гражданлык шигырьләре ул кадәр кычкырып, кайберәүләр уйлаганча, гәзитләрнең беренче битенә чәпәп куярлык шаблон түгел. Рәшитнең гражданлык шигырьләре чын мәгънәсендә сәнгатьчәлекне күз алдында тотып, чын сәнгать әсәренә генә хас детальләр белән оеша.

Ерак юлга чыгасың, егет,
Сагышларга тырыш түзәргә, —

ди Рәшит тормышка беренче булып атлаучыларга.

Кылычлардан сакла үзеңне,
Саклан түбән иелми генә.
Куркып башын игәннәр кабат
Карый алмый зәңгәр күгенә...

...Мәхәббәтең белән юлларда
Бергә барсын мәңгелек үчең:
Яндырырлар, бәлки, учакта,
Үз илеңне яраткан өчен.

Кыю җаның, чая башкаең
Юлны лаек имин узарга.
Үлемсез дошман бул — дошманга,
Үлемсез дус бул син дусларга.

Менә бу шигырь, минемчә, чын мәгънәсендә җитди һәм тормыш күзлегеннән карап язылган. Монда патриотизм да, принципиальлек тә, һәм батырлык та бар. Яки менә Җәлилләр турында уйланып язылган шигырьдән ике юл:

Таш капчыкта яңгыраган телем —
Таш балчыкта гөлләр үстерде.

Минемчә, шушы ике юл гына да тулы бер халык характерын бик төгәл итеп ачып күрсәтә алган. Яки менә скептикларча, ил кайгысына читтән генә карап торучыларга бер сүз:

Ташлар белән үтә танышлык бар.
Берәүләрнең карап күзенә,
Сөлим әле ташлар ярып тапкан
Дөреслекне салып сүземә:

Туган туфрак яшәү көче миңа,
Һәр граммы — яшәү запасы.
«Таулар биек» диеп уфтанганның
Килми микән ташлар ватасы?!

...Иңнәремдә тоеп үзем беләм,
Көчле итә ирне туган җир.
Әй, җир, синнән үлем сорасалар,
Кешеләргә үлемсезлек бир!

Тагын шунысы бар: Рәшитнең гражданлык шигырьләре лирик мин исеменнән языла. Ул ил тормышына, ил язмышына читтән карап күзәтүче булып түгел, үзе шушында эшләүче бер хезмәт кешесе авызыннан әйтелә. Бу күренеш Рәшит шигырьләрен укучыга тагын да якынайта төшә.

Әйе, Рәшиттә тел мөмкинлекләрен тою, шигъри детальләрне оста куллана белү, шигырьдә дөрес идеяләрдә бару, кирәкле тематикага мөрәҗәгать итү осталыгы бар.

Ләкин әле бу шигырь өчен барысы да җитте дигән сүз түгел. Әле бит шигырьнең композициясе, детальләрнең бер-берсенә ялганып килә-килә шигырьне тулы бер организм хәленә китерүче логик бәйләнеше бар. Менә бу өлкәдә әле, минемчә, Рәшит бераз илтифатсызлык күрсәтә. Дөрес, элек язылган шигырьләрендә һәм «Хыялларым үзем белән» дигән китабына кергән шигырьләр гаять төгәл төзелгәннәр. Ләкин менә соңгы елларда язган шигырьләрендә

Рәшит ничектер чәчелә, шигырь эчендәге эзлеклелеккә игътибарын киметә төште. Бу, бәлки, соңгы шигырьләрдә фәлсәфилек артудан киләдер, ләкин шулай да моны Рәшиткә әйтеп китмичә ярамый. Мисалга Рәшитнең соңгы шигырьләреннән берсен генә китереп үтәм. Бу шигырьне укып барышлый, бер-берсенә янәшә торган шигъри детальләрнең ни дәрәҗәдә бер-берсенә бәйләнүләрен тотып алу шактый кыен:

Былбыл кунар әле диеп,
Гөл үстердем,
Ә син аны толымыңа
Кушып үрдең.

Әһә, ярый, берәү былбыл куну өчен гөл үстергән, һәм аны (сөйгәне булырга тиеш) бер кыз толымына кушып үргән. Бу былбыл шушы кыздыр, үзе теләгенә иреште, гөле былбыллы булды дип уйлыйк. Аннан, шушы фикерне үстереп:

Елга таптым – син аңардан
Сулар эчтең...

Ярый, егет газапланып елга тапкан һәм аннан сөйгәне су эчкән икән, бу әйбәт инде. Ләкин кинәт:

Күпер салдым – мине ташлап,
Ятка кичтең.

Ник? Нинди сәбәп бар әле кызга хыянәт итү өчен? Нигә ятка китте? Шигырь башында әйбәт кыз иде, егет тә гел яхшылык кына эшләде, ләкин кыз никтер китте. Аңлашылмый. Мантыйк болай бара алмый. Монда инде мантыйкка хыянәт күренә. Рәшитнең иҗатына карата булган бердәнбер тәнкыйть сүзем шушы. Шагыйрьнең гомуми иҗатына зур күзлектән караганда, бу җитешсезлек – кечкенә әйбер. Ләкин ул да булмаса, тагын да шәп булыр иде.

Рәшит Әхмәтҗановның шигырьләре матбугатта бик еш күренә дип әйтеп булмый. Рәшит үзе дә 1960–1962 еллардан соң бераз пассивлашты. Әлбәттә, моның сәбәпләре юк түгелдер. Ә менә соңгы 2–3 ел эчендә Рәшит тагын җиң сызганып эшләргә кереште. Беренче җыентыгы белән «Адымнар» җыентыгы арасында 4 ел буе китап чыгармыйча тору – шактый озын гомер. Ә менә «Адымнар»дан соң ук Рәшит «Җиде кубыз» исемле яңа җыентыгын әзерләде һәм нәшриятка тапшырды. Мин инде югарыда бу җыентыкка кергән шигырьләрдән дә мисаллар китердем, җыентыкка яңадан тукталып тормыйм.

Соңгы сүз итеп, мин бүген, әгәр шундый хокукым булса, секциядән Рәшитне Язучылар союзына әгъзалыкка тәкъдим итүне үтенәм. Минемчә, Рәшит инде моңа тулысынча лаек.

Марс Шабаев Рәшит Әхмәтҗановка сүз бирә. Шагыйрь яңа язылган шигырьләрен укый.

*Г. Зәйнашева.* Рәшитне соңгы вакытларда бигрәк тә аңлый, ярата башладым. Шигырьләрен укыгач, ниндидер әйбәт, ачык күңелле кеше белән сөйләшкән кебек буласың. Рәшит тормышның нюансларын тоя. Әйтик, таш. Ул аңарда шулкадәр нечкә тойгылар тудыра. Гражданлык хисе бик югары. Аналарга карата гаҗәеп зур мәхәббәт бөтен иҗаты буенча сузылып бара. Ана образын туган ил, туган тел белән бәйләп бирә белүдә искиткеч зур осталык күрсәтә. Беренче китабы бик шәп. Ә икенче китапта – «Адымнар»да – иң ошаганы Рәшит шигырьләре булды. Әзерләгән китабы – «Җиде кубыз» – шулай ук бик зур өметләр уята. Гәрәйнең чыгышы белән килешәм, тулысынча кушылам.

*Роберт Батуллин.* Мин Рәшитнең шигырьләрен музыкага охшатам. Мондый шигырь язу өчен бик тә нечкә тойгылы интеллектуаль йөрәк кирәк. Кайбер шигырьләренең кыйммәте конкретлыкта түгел, ә тойгы ассоциациясендә. Мин шагыйрьне Язучылар союзында тору өчен тулысынча өлгергән дип саныйм.

*Хәсән Туфан.* Бик дөрес, Батуллин, фикерең дөрес!

*Илдар Юзиев.* «Адымнар»дагы шигырьләрдә дә, элеккеләрендә дә Рәшитнең уңышы, чыннан да, бөтендөнья язмышы өчен гаҗәп тирән уйлануларда. Бу һич тә абстракция түгел, билгеле. Болай итеп язу өчен бик зур осталык кирәк. Рәшитнең җитлеккәнлеге шунда. Рәшитне чын шагыйрь дип саныйм. Тәнкыйть фикере дә әйтим. Логик бәйләнешсезлекләр очраштыргалый. Теле халыкчан. Тел тәгъбирләрен оста куллана. Ләкин монла артык куллану, мавыгу күбрәк бугай. Гомум фикере, фәлсәфәсе – аның уңай ягы, шул уңышлар кимчелек булып китмәсен иде. Ул үсәчәк. Аның шагыйрьлеген рәсмиләштерәсе генә кала.

*Әхсән Баянов.* Кызганычка каршы, мин күп әсәрләрен укымадым. Ләкин гомуми булса да фикер әйтергә тиешмен. Шагыйрьләрнең шигырьдә – бер кеше, тормышта икенче кеше булып яши торганнары бар. Бәлки, бу кешенең самими булмавындадыр. Ә Рәшитнең иҗатындагы сыйфаты белән тормыштагы сыйфаты аерылмый. Аның әсәрләре декларатив шигырьләр түгел, чын, талантлы әсәрләр. Ләкин кайбер образ, детальнең акыл һәм хис аша үткәрелмичә кулланылган очраклары бар. Рәшит өлгергән шагыйрь, һәм ул Язучылар союзы әгъзасы булып торырга бик тә лаеклы!

*Рөстәм Мингалимов.* Күренеп тора, Рәшит – шагыйрь, чын шагыйрь. Гомуми бер кимчелек бар бездә – яшь шагыйрьләрдә. Дөньяны белмибез, күрмибез, йөрмибез. Ләкин Рәшитнең шагыйрьлегендә шик юк. Ул союзда торырга лаек.

*Рәдиф Гатауллин.* Рәшиттә беркемне кабатламый торган моңлы шигърият. Тормыш белән нык бәйләнгән шигърият. Ни өчендер бу шагыйрь матбугатта сирәк күренә. Тыйнаклык кирәк нәрсә, ләкин болай ук түгел.

*Шәукәт Галиев.* Җитди шагыйрь. Таләпчән шагыйрь. Чын күңелдән аны Язучылар союзына тәкъдим итәм.

*Кави Латыйп.* Рәшитне инде иртәрәк кабул итәргә кирәк иде союзга. Рәшит күп эшли. Союзга алу бик тә дөрес эш. Хәерле юл, Рәшит!

*Хәсән Туфан.* Рәшит «Мин җаваплы!» дигән хис белән яши. Барыбызда да бер фикер. Рәшитне Сибгат Хәким дә, мин дә бер очрашуда ук яраттык. Үзенең теле, стиле, гүзәл стиле бар. Традицион шигырьнең серләрен үзләштерә бара. Рәшитнең һәр шигырендә шигърияттә генә була торган көч, куәт бар. *(Мисаллар китерә. Иң уңышлы әсәрләрен санап, анализлап чыга.)*

Рәшитне, чыннан да, союзга алу турында күптән кайгыртырга кирәк булган. Соңгы шигырьләрен «Казан утлары»на бирергә кирәк. Шул шигырьләре белән генә дә аны союзга алырга була.

*Марс Шабаев.* Рәшит бер дә үзен афишировать итеп йөрмәде. Тыйнак. Беренче китап белән икенче китап арасында ара шактый гына. Бәлки, бу тыйнаклыктан килә торгандыр.

Хәерле юл белән, документларны әзерләп тапшырырга кирәк. Сүз үзеңә бирелә, Рәшит!

*Рәшит Әхмәтҗанов.* Игътибарыгыз өчен зур рәхмәт!

*Председатель М. Шабаев*
*Секретарь З. Маликов*

# Шигырь канатлары

## Хәлим Җәләлов

Мин әдәбият белгече дә, шигырь язучы да түгел. Шулай да шагыйрь Рәшит Әхмәтҗановның яңа җыентыгын[1] укып чыккач алган кайбер тәэсирләрем белән уртаклашмакчы булам.

Шагыйрьнең бу китабын көтеп алдым һәм ялгышмаганмын. Җыентык беренче битеннән үк күңелне биләп ала, үзең дә сизмәстән, син шагыйрьнең фикердәшенә әвереләсең. Шигырьләрдән мул лирик тойгылар, халкыбызга хас моңнар бөркелеп тора.




**Р. Әхмәтҗановның 75 еллыгына багышланган кичәдә Хәлим Җәләлов чыгышы. Казан. Тукай клубы, 2016**

Кешенең җәмгыятьтә тоткан урынын, шигъриятнең тормыш иминлеге өчен көрәштә җаваплылыгын тоеп яза шагыйрь:

Кагылулар, сугылулар булса —
Дошманнарга каршы чыгарбыз.
Без туган тел булып
                    җырларбыз да
Без туган җир булып сугарбыз!

Яшьлек, мәхәббәт, тугрылык турындагы шигырьләрдә шагыйрь күңелендәге олы хисләрнең сафлыгы, паклеге күренә.

Кайсы гына шагыйрь изге затка — әниләргә багышлап шигырь язмады икән! «Ятим» дигән шигырьгә күз салыйк.

Ятим бала...
Әгәр үги ана
Чакырмаса пешкән ашына,
Гомер буе сабый яланаяк
Әнкәсенең йөгерә каршына.

Шушы нәни генә шигырьдә дә сурәтләү көченең куәтен күрергә була. Аз сүз белән күп мәгънә аңлатуның, кыска һәм оста язуның үрнәге инде бу, минемчә. Гомумән, мондый юллар Рәшит Әхмәтҗановның үз шигырьләренә карата таләпчәнлеген, шигырьдәге сүзләр белән бик сак эш итүен күрсәтә.

Шагыйрьнең шигъри теленә игътибар иткәндә, иң әүвәле бер күренеш күзгә ташлана: шагыйрь үзе уйлап тапкан сүз конструкцияләре, бик тә урынлы неологизмнар («Чәчтәңкә», «Талбасма», «Телбизәк» һ.б.) шигырьне тагын да нәфисләндерә, тәэсир итү көченә куәт өсти. «Сугыштан кайталмаган егет сүзләре», «Замана таный безне», «Бәйрәм» кебек шигырьләрендә шагыйрь ил улларының азатлык өчен көрәштә битараф калырга хаклары юклыгын, гомерләрен илгә багышлаганнарның үз халкы күңелендә мәңге сакланачагын әйтә.

[1] Сүз Р. Әхмәтҗановның «Ак канатлар» җыентыгы турында бара (Казан: Татар. кит. нәшр., 1972).

Гуманизм хакында сүз чыкканда, яшь шагыйрьнең «Бәйрәм» дигән шигырен мисал итеп китерәсе килә:

...Рәхмәт, илем!
Гомер биргәнсең дә,
Янган йөрәк сүнми, югалмый.
Туган җирдә дошман каберләре...
Каберләрдән ирләр үч алмый.

Китапка кергән шигырьләр арасында «Алдан әйт...» исемле шигырьдә мондый юллар бар:


Бу кышкы төннәр күңелдән
Кояшны эзләп килә...
Иртәгә кояш нәкъ минем
Күңелдән чыкмас димә.

Әгәр шагыйрь күңеленнән кояш чыга икән, туган халкының көнен, яшәешен җылытыр, яктыртыр өчен чыга.

Рәшит Әхмәтҗанов җыентыгы шигырь сөючеләр өчен матур бүләк, минемчә.

«Ак канатлар» турында тәнкыйтьчеләр һәм әдәбият белгечләре үз фикерләрен әйтерләр әле. Хәзергә, сүзне тәмамлап, шагыйрьнең шигъри канатлары һичкайчан талмасын, үзенең шигырь сөюче дусларын яңадан-яңа шигырьләре белән шатландырсын, дип, теләк телисем килә.

*«Социалистик Татарстан» газетасы.– 1972. – 12 ноябрь*





**Дусты Саимә Габдрахманова. Татар Кандызы**

# Беренче очрашу

Мөдәррис Вәлиев

Шагыйрь белән аның укучысы ике тапкыр очрашып таныша: шигырьләре аша һәм үзен күреп. Икенче танышу беренчесен тулыландыра, шагыйрь шәхесен күбрәк ачарга ярдәм итә.

Рәшит Әхмәтҗановның үзе белән очрашуым язучыларның Г. Тукай исемендәге клубында булды. Озын, чандыр буйлы, мөлаем чырайлы егет шигырьләрен укый башлагач, залда аеруча бер тынлык урнашты.

Сорыйсың: – Йә, туган, исәнме,
Хәлләрең ничек соң, бер сөйлә?

Залда утыручылар белән шагыйрь арасында гүяки күзгә күренмәс нечкә җепләр сузылды. Күптән таныш шигырьләр авторның үз авызыннан бөтенләй яңа төсмерләр белән бизәлеп яңгырагандай булды.

Шушы очрашудан соң мин Р. Әхмәтҗановның «Ак канатлар» җыентыгын кабат укып чыкмыйча булдыра алмадым. Һәм күрдем: югарыдагы шигырьне шагыйрь юкка гына үз репертуарының «аккорды» итеп алмаган икән. Әлеге әсәр – аның иҗатындагы иң уңышлы шигырьләреннән берсе. Нәкъ менә шушы шигырьләре белән әдәбият мәйданына чыкты да ул.

Рәшит Әхмәтҗанов шигырьләренә лирик җылылык һәм эчке драматизм хас. Анда авторның ике «канатка» – бер яктан халкыбызның авыз иҗатына, икенче яктан классик поэзиягә таянуын абайлау читен түгел.

Шагыйрь халыкның үзеннән килгән сурәт-бизәкләрне, шигъри детальләрне ала да, шуларны яңа фикерләр әйтү, хисләрен белдерүдә үзенчә файдалана. Сандугач, кыя, давыл, дөнья кебек образлар безгә, тузаны сөртелгән асылташлар сыман, яңа төсмерләр, яңа бизәкләр белән ачылып китәләр. Бу авторның аеруча матур поэтик теле, төгәл композиция – сурәт чаралары куандыра.

Шагыйрьнең лирик герое «мәңгелеккә елмаю биргән» тормышны сөя, «канатлар көярлек» булса да, үз җирендә калуны, аңа тугрылыклы булуны яклый. Чөнки туган туфрак кына кешегә бетмәс-төкәнмәс көч бирә, бары тик аның гына «һәр граммы яшәү запасы» була ала. Җыентыкта илгә, чорга лаек булып яшәү, кешеләргә бары тик шатлык һәм бәхет кенә китерергә омтылу хисләре киң чагылыш тапкан. Шундый хис-фикерләрне укучыга җиткерүдә шагыйрьнең алымы уңышлы, отышлы. Алда әйткәнемчә, лирик җылылык һәр строфада драматизм белән үрелеп бара. Аның моңы да тормышсөяр, оптимистик моң, чөнки шагыйрьнең җирдә яхшылыкның – яманлыкны, яктылыкның караңгылыкны җиңәсенә ышанычы зур һәм моңа ул үзенең укучыларын да ышандыра:

Без мәңгегә, без мәңгегә монда!
Эх, бу җирне күпме таптады
Безнең йөрәк бәйрәмнәренең
Кыңгыраулар таккан атлары,–

ди ул.

«Ак канатлар» – шагыйрьнең өченче мөстәкыйль җыентыгы. Димәк, поэзия сөючеләр аның китабы аша өченче тапкыр очраштылар, һәм бу очрашу Рәшит Әхмәтҗановны шагыйрь буларак бик күп яңа, матур яклары белән ачачак.

*«Татарстан яшьләре» газетасы.– 1972*

# Аргамаклар юлда арымасын

Рәшит Гәрәй

Шагыйрь Рәшит Әхмәтҗанов поэзиягә «кыңгыраулар таккан атлар» белән җилдереп килеп кермәде. Туган ягының яшел тугайларында көтү көткән, нефть каласы Әлмәттә яңа йортлар төзешкәндә ташлар күтәреп беләкләре талган бу егет үзенең хис һәм тойгыларын кәгазь битләренә башкаларга сиздермичә генә күчерде, язганнарын газета һәм журнал редакцияләренә кыяр-кыймас кына юллады. Кулына корал тотып Совет Армиясе сафларында хезмәт иткәндә, ил һәм халык алдында үзен тагын да җаваплырак итеп тою, авыр походларда һәм хезмәттә җырның иң тугрылыклы юлдаш икәнлеген аңлау, Казан дәүләт университетында укып, югары белемгә ия булу аның күзләрен ачып, иҗат офыкларын киңәйтеп җибәрде. Шуннан соң аның шигырьләре вакытлы матбугат битләрендә, коллектив җыентыкларда торган саен ешрак күренә башлады. Беренче җыентыгының поэзия сөючеләр тарафыннан җылы кабул ителүе яшь шагыйрьнең күңеленә яңа канатлар өстәде, аны элеккегә караганда да тырышыбрак, дәртләнебрәк иҗат итәргә рухландырды.

Күптән түгел Татарстан китап нәшрияты Рәшит Әхмәтҗановның «Ак канатлар» исемле яңа җыентыгын бастырып чыгарды. Җыентык авторның лирик хисләр белән сугарылган сиксәнгә якын шигырен үз эченә ала. Шагыйрь озын язарга, кайбер яшь әдипләребез шикелле, кирәксәкирәкмәсә дә, образлар һәм детальләрне катлауландырырга, җөмләләр матур булсын өчен генә



**Яшь солдат Казанда язучылар семинарында. Сулдан уңга: Хисам Камалов, Кыям Миңлебаев, Равил Фәйзуллин, Кави Латыйпов, Рәшит Әхмәтҗанов, Рафаэль Төхфәтуллин. 1960 еллар уртасы**

сүз уйнатырга яратмый. Шигырьдә әйтергә теләгән фикерен ул үзенә генә хас булган сурәтләү чаралары ярдәмендә нагрузкалы, тыгыз юлларга сыйдырырга тырыша. Бу хакта шагыйрь җыентыкны ачып җибәргән «Керләр чайкый әнкәй» дигән шигырендә үзе дә бик дөрес искәртеп үтә:

Керләр чайкый әнкәй, керләр чайкый,
Уе китә сулар төбенә.
Әйтерсең ул шулай диңгез айкый,
Телбизәкләр эзләп телемә.

...Тел югалтса егет – ил югалткан,
Сүз югалтса – иле оялган...
Ә чын сүзләр безнең иреннәрдә
Ничә кабат канга буялган.

Шагыйрьнең әнә шундый чын сүзләрдән тукылган шигырьләре укучыны битараф калдыра алмый, аны уйланырга, үзенең үткәненә, бүгенге һәм иртәгәсе көненә аек акыл белән карарга мәҗбүр итә. «Юк, озатмыйм», «Уем тирән», «Сугыштан кайталмаган егет сүзләре», «Кошлар очып уза», «Тайгадагы учак», «Мәңгелекне дәвам итәбез», «Әй, сеңлем» кебек шигырьләрендә Рәшит Әхмәтҗанов тормыштагы төрле хәлләрне кешеләр йөрәге аша уздырып тасвирлый. Менә шуңа күрә дә ул шигырьләр күңелгә үзләреннән-үзләре агып керәләр, хәтергә тирән уелып калалар. Шагыйрь күп кенә очракларда үзе белгән, үзе күргән һәм беренче карашка кечкенә булып тоелган бер вакыйганы тотып ала да, шуңа таянып, зур гомумиләштерү көченә ия булган олы фикер әйтә. Менә бер мисал. Сазлыклар ерып килә-килә арган юлчылар, ял итәргә туктагач, агач төбенә учак ягалар. Учак, ялкыннарын өскә үрләтеп, шактый озак яна. Ләкин кинәт, һәркемнең йөрәген әрнеттереп, өстә нindидер кошчыкның үз-үзен кая куярга белмичә, шашынып-ярсынып агач ботакларына бәргәләнә башлавы лирик геройның бәгырен телгәли, һич көтмәгәндә күз алдына килеп баскан бу фаҗигале күренешнең сәбәбен автор җанны тетрәндерерлек итеп ике-өч строфада әйтеп бирә:

И Сандугач, хәсрәтеңне
Әйтә күрмә дусларыма.
Үзем генә йөрәгемне
Кысыйм салып учларыма.

Кайгыларың коелмасмы,
Ела, кошчык, кагын, очын!
Бу агачта ояң булган.
Балаң янган, сандугачым.

Шигырьне шушы урында тәмамларга да бик мөмкин булган булыр иде. Әмма шагыйрьнең әле әйтеп бетерәсе, башкаларның да колагына ишеттерәсе тагын берничә гыйбрәтле сүзе – киңәше бар. Ул сүзләрен автор, шигырьдәге фикерне тагын да көчәйтү, тәэсирлерәк итү өчен, ахыргы строфага калдыра:

...Соңгы күмер, утлы күзләр
Булып миңа гел карыйсың...
Сандугачлар янган утта
Җылынырга ярыймы соң?!

Уйлана, фикер йөртә белгән кешегә бу юллар бик күп нәрсә турында сөйли. Афоризм булып яңгырарлык мондый канатлы сүзләрне Рәшит Әхмәтҗанов шигырьләрендә шактый күп очратырга мөмкин. Аның бу җыентыкка кергән шигырьләрендәге «туган җирдә дошман каберләре... каберләрдән ирләр үч алмый», «сезнең җанда кояш бар шикелле, күңелегездә сезнең таң алды», «үзебезгә безнең сиздермичә, безне дә бит утка ягалар», «кыюлар ятып еламый кешеләр йөрәгенә», «туган илгә кайтыр аккошларга тамчылап күл җыя сагышым», «туган илдә кызлар җырламаса, егетләргә гомер нәрсәгә», «ак канат биргән идең дә, каралтты аны кайгым», «далаларны узгач, диңгез табыла безнең кебек йөргән юлчыга» шикелле тирән мәгънәле җөмләләрне истә калдыру өчен, аларны кат-кат укып торасы юк. Бер тапкыр уку белән, алар үзләре үк тел очына эленеп калалар. Әйе, Рәшит Әхмәтҗанов сүзнең кадерен белә, аның зур көчкә ия булуын яхшы аңлый һәм тел белән бик сак эш итә.

Шагыйрьнең кайбер каләмдәшләре арасында: «Ник соң ул зуррак күләмле әсәрләр тудыру өстендә эшләми икән?» – дигән сорауны ишетергә туры килә. Бер караганда, бу сорау урынлы да кебек. Әмма, төптәнрәк уйласаң, Рәшит Әхмәтҗановның озын язарга үз-үзен көчләп мәҗбүр итмәве һич тә гаҗәп түгел. Кайберәүләр гомуми сүзләр тезмәсеннән торган шигырь юлларын дилбегә буе сузып та әйтеп бирә алмаган теге яки бу фикерне ул өч-дүрт строфада ачып бирергә




тырыша. Хәзергә аңа барыннан да элек шигырьнең төп үзенчәлеген аңлап эш итү — үзенең яисә лирик геройның хис һәм кичерешләрен оста тотып алынган поэтик детальләр аша укучы күңеленә җиткерә белү кыйммәт. Шигъри осталыкка өйрәнгән һәм җитәрлек тәҗрибә туплаган әдипнең киләчәктә зуррак күләмле әйбәт әсәрләр тудырырга да көченнән килер. Җыентыкта урын алган «Уем тирән», «Балаларын эзли аналар», «Вожатыйлар», «Бәйрәм» шигырьләре аның инде әнә шул юнәлештә кыю гына адымнар ясавы турында сөйли, һәм бу юлда шагыйрьнең уңышка ирешәчәгенә шикләнмәскә мөмкин. Моңа аның көче дә, тырышлыгы да җитәрлек. Үз исеменнән сөйләп, бер шигырендә ул менә болай ди:

Ташлар белән үтә танышлык бар.
Берәүләрнең карап күзенә,
Сөйлим әле ташлар ярып тапкан
Дөреслекне салып сүземә:

Туган туфрак яшәү көче миңа,
Һәр граммы — яшәү запасы.
«Таулар биек» диеп уфтанганның
Килми микән ташлар ватасы?!

Туган туфрагыннан яшәү көче һәм илһам алып, үзе әйтмешли, сүзенә тормыш дөреслеген салып иҗат иткән шагыйрьнең «Ак канатлар» җыентыгын зур канәгатьләнү белән укыйсың. Ләкин андагы шигырьләрнең бөтенесе дә бер үк дәрәҗәдә әйбәт эшләнгән, аларның берсенә дә тел-теш тидерерлек түгел дисәк, бу һич тә дөреслеккә туры килмәс иде. Китапта әле тиешле кондициягә килеп җитмәгән, кәгазь битенә күчкәнчегә кадәр күңел җылысы белән җитәрлек сугарылмаган шигырьләр дә юк түгел. Андый шигырьләрне җыентыктан берәм-берәм чүпләп алып, авторның үзенә кире кайтарып бирәсе килә. Шома гына язылган булсалар да, «Инде без дә китәбез бит», «Карлар ява», «Кагылулар, сугылулар булса», «Нишләдең син, нишләттең син илем күгең», «Оял, дөнья, кодрәтеңне күргән күздән», «Бу далада эзләр, эзләр», «Яр сөйгәннәр моңлы була», «Гомер шулай инде, энем», «Аккош йоклаган су кебек тыныч идем», «Җәй. Кызу. Гөлләр күзендә...» дип башланып киткән шигырьләр Рәшит Әхмәтҗанов тарафыннан түгел, әйтерсең лә бөтенләй башка кеше кулы белән язылганнар. Поэзиядә моңарчы инде бик күп тапкырлар әйтелгән фикерләр кабатланганлыктан, ул шигырьләрдә шагыйрьнең үз тавышы кечерәеп, тоныкланып кала. Фикер ярлылыгы, фикер сайлыгы исә «илдә батыр булу әйбәт... кая барсаң, шунда, егет, батыр бул», «онытсаң да, энем, мине, онытма син туган илне» дип, башкаларга үгет-нәсыйхәт бирү белән чикләнүгә китерә. Билгеле булганча, маңгайга әллә каян бәрелеп торган коры сүзләр белән акыл бирүгә корылган андый шигырьләрнең хискә дә, акылга да тәэсире бик бәләкәй. Җыентыктагы әнә шундый уңышсыз шигырьләрне укыганда, безне бары тик бернәрсә юата: киләчәктә моның ише йомшак шигырьләрдән арыну өчен Рәшит Әхмәтҗановның тулы мөмкинлекләре бар.

Бүгенге көндә аның иҗаты күтәрелеш, үсеш чорында. Алда аңа ләззәтле һәм газаплы кичерешләрдән соң туа торган берсеннән-берсе уңышлырак шигырьләр юлдаш булсын. Шагыйрьне поэзия дип аталган чиксез зур дөньяга алып чыккан «йөрәк бәйрәмнәренең кыңгыраулар таккан» аргамаклары ярты юлда арып калмасыннар.

*«Казан утлары» журналы.— 1973*

# Хисләр канатында

Әхмәт Рәшитов

Соңгы елларда шигъриятебезгә гаять үзенчәлекле берничә шагыйрь өстәлде — бай тарихлы әдәбиятыбызга яңа варислар килде, һәркайсының үз моңы, үз көе — тулы бер шигъри ансамбль. Тагын шунысы сөенечле: бүген авазлар торган саен төсмерлерәк, ачыграк, куәтлерәк яңгырый. Яшәешнең кырыс картиналарын саран һәм төгәл штрихлар белән сурәтләүче Равил Фәйзуллин һәм тормышка, матурлыкка мәҗнүннәрчә гашыйк, романтик рухлы Рәдиф Гатауллин, һәр вакыйгадан, һәр күренештән, һәр әйбердән мәгънәви асыл эзләүче Ренат Харис һәм публицистик ялкынлы, дөньяда бер нәрсәгә дә битараф кала алмаучы Гәрәй Рәхим... Әлбәттә, шигъри диапазоннарны болай чикләп кую шактый шартлыдыр, чөнки әлеге сыйфатлар күпмедер дәрәҗәдә теге яки бу шагыйрьгә дә хас, һәм аның шулай булуы табигый дә.

Рәшит Әхмәтҗанов исеме матбугат битләрендә телгә алынган бу чордашларыннан алдарак күренгән иде. Шулай да аның шагыйрь буларак җитлегүе алар белән бер тирәгәрәк туры килде.

Күп кенә тәнкыйтьчеләр «Рәшит Әхмәтҗанов иҗатына халыкчанлык һәм тормышчанлык хас» дигән фикер әйтәләр. Бу нидән гыйбарәт соң? Мөгаен, аның шигырьләренең халык авыз иҗаты белән тыгыз үрелүендә, шигырь төзелешенең, образларының, фикерләвенең классик шигырь белән нисбәтендәдер. Шагыйрьнең хисләре тирәннән, халыкның күңел түрендә яшеренеп яткан сөенеч-борчулардан, иң якын кеше белән генә уртаклашырдай эчке серләрдән, матурлыкка, яктылыкка, аклыкка омтылудан килә. Шагыйрь тышкы үзенчәлек артыннан кумый; чынбарлыктан, яшәештән аерылган, ниндидер уйлап чыгарылган фикерләр ышыгына качмый, һәрвакыт үз-үзе булып кала. Ул оста ювелирны хәтерләтә:

Бөртекләп, мыскаллап җыйдым
Дөньяның аклыкларын.
Шул ук дөньяга очырдым
Аклыкның аккошларын,—

ди шагыйрь.

Бу юллар аның соңгы — «Гомер чишмәсе» дип исемләнгән яңа китабыннан. Шигъри җыентыклары белән укучылар күңелен яулап алган Рәшит Әхмәтҗановны бүген нәрсәләр дулкынландыра соң? Ул үзенең шигъри антына тугры калганмы? Автор, бу сорауның биреләчәген алдан ук сизенгәндәй, беренче шигыре белән үк «мин һаман шундый» дип җавап бирә. Балачак еллары дәһшәтле сугыш чорына туры килгән буынның бер вәкиле шагыйрь. Шуңа күрә булса кирәк, тынычлык һәм сугыш, кешелеклелек һәм кыргыйлык, мәхәббәт һәм нәфрәт аның иҗатына төп мотивларның берсе буларак килеп керәләр:

Утлар шулай иртә уяттылар,
Илдән кузгаттылар гомерне.
Кызарганчы кыздырдылар...
Аннан
Кулга тоттырдылар тимерне.

Бөктек аны,
Тимерчеләр булдык,—
Язмыш түгел, тормыш кушканга.
Без дә шулай богау кигерештек
Безне үтерәсе дошманга.

Теге яки бу вакыйга, гәрчә ул бик әһәмиятле булса да, аның шигырьләренең төп асылын, нигезен тәшкил итми — шагыйрь аның заман өчен мөһим якларын гына тикшерә һәм шуның нә-

тиҗәсен фәлсәфи яктан аңларга омтыла, кыю гомумиләштерүләр ясый. Бу аңлашыла да, чөнки шигырьнең хасияте шундый. Күргәнне-белгәнне коры санап чыгу гына чын сәнгатьне тудыра алмый әле. Дөньяны шагыйрьләрчә күзаллау ул — кешенең, Һади Такташ сүзләре белән әйтсәк, «туып та әле исем бирелмәгән хисләренә исем бирү». Шагыйрь моңа марксистик-ленинчыл караш, гомуми фикер әзерлеге, тел-сурәтләү чараларының бай арсеналы ярдәмендә ирешә. Ул сүзгә үтә сак — ялган пафостан, артык ялтыравык бизәкләрдән һәрвакыт качарга омтыла. Шигъри сөйләме гади, тыйнак, саллы, мәгънәле һәм моңлы. Моңлы шигырьләр яза шагыйрь һәм бу аның иҗатының иң күркәм сыйфатларыннандыр, мөгаен. Сүзләре, халык җырларындагыча, җайлы, килешле, юллар җырлап тора. Шигырьнең композициясе, образлары бүгенге шигърият ирешкән казанышлар югарылыгында.

Ә хыяллар Себер киңлегендә
Киек Казлар Юлы шикелле.
Заманамы монда, үз янына,
Безнең кайнар яшьлек китерде,—

ди автор үзенең «Тайгада» дигән шигырендә. Шагыйрь җир йөзендә барган гигант үзгәрешләргә үз мөнәсәбәтен белдерергә тырыша, шигъри хөкемен чыгара. Туган илнең умырзая төсе сеңгән кырлары буйлап үткәндә дә, яңа тарих сәхифәләрен язышкан ил картының гыйбрәтле сүзләрен тыңлаганда да, карлыган җыйган ананың сагышларын уртаклашканда да, сөйгән ярын сагынганда да, халыкның үлемсезлеге, мәңгелек рухи хәзинәсе хакында уйланганда да, Рәшит Әхмәтҗанов шигырьнең бөтен җегәрен төп максатка — теманы тулы һәм сәнгатьчә итеп ачуга юнәлтә. Аның «Миләшләргә киләм», «Бер дулкын — көн кебек», «Яңгырлы көндә», «Бәләкәй генә малай», «Сандугач керде күңелгә», «Умырзая төсе кырларда», «Безнекеләр», «Сине күрергә барам», «Йөгермә йомгак артыннан», «Туйда бер сүз», «Авырганда» кебек шигырьләре сәнгатьчә эшләнешләре белән дә, якты идеаллары, ак теләкләрне раслаулары белән дә игътибарны җәлеп итәләр.

Бу җыентык шагыйрь талантының тагын бер матур ягын ачуы белән үзенчәлекле. Анда байтак кына икеюллыклар һәм дүртьюллыклар урын алган. Киная, мәгънә, читләтеп әйтүгә корылган бу шигъри юллар үзенчә нәфис һәм гыйбрәтле. Хикмәтле сүз әйтү бүгенге шигърият өчен әллә ни яңалык түгел түгелен — урта һәм яшь буын шагыйрьләрдә аның шактый кызыклы үрнәкләрен табарга мөмкин. Аерма шунда: Рәшит Әхмәтҗанов, Көнбатышның шәрәләндерелгән рационализмын бер читкә куеп, шигъриятнең су башына — Көнчыгыш робагыйларына, аларның романтик рухына, шигъри төзелешенә мөрәҗәгать итә:

Ишегемнән кермәсәң дә — төшемә кер,
Килеп кит, мин сагынуга түзмәгәндә.
Тик «сөям» дип әйтер идем, үзең юк шул...
Син — диңгездә, мин чүлләрдән эзләгәндә.

Җыентыкта тагын шигъри үлчәмнәрнең төрлелеге күзгә ташлана. Бу да авторның туктаусыз эзләнүе, һәр шигырьгә тәңгәл яңгыраш табарга тырышуы нәтиҗәсе.

Шагыйрь иҗатын игътибар белән күзәтеп барган һәркемне китап үзенең якты хисләре белән сөендерә һәм шул ук вакытта күңелгә беркадәр борчу да сала. Әйе-әйе, анысын да ачыктан-ачык әйтергә кирәк, күпмедер дәрәҗәдә борчый да. Рәшит Әхмәтҗанов моннан алда дөнья күргән «Ак канатлар» китабы белән үзенең иҗат мөмкинлекләрен тулырак күрсәткән иде. Биредә исә, кайбер матур казанышлар булуга карамастан, әүвәлгедән үзгәреш сизелми сыман. Иң элек тематик офыкны киңәйтү сорала кебек. Сокланып укырдай шигырьләр янәшәсендә үк «Мин таныдым сине», «Юлдашларга», «Диңгездән кайттым мин бүген», «Кылыч», «Мөмкиндер ич...» кебек әллә ни зур табыш булмаган әсәрләр дә урын алган. Шагыйрь укучыларын яңадан-яңа иҗат уңышлары белән сөендерер әле.

*«Социалистик Татарстан» газетасы.— 1976. — 23 декабрь*

# Кеше күңеленә якынаю

Госман Садә

Тешләрне камаштырырлык саф сулы чишмә. Тибеше — йөрәк тибешедәй. Таштан ташка сикереп, челтер-челтер, үз көен көйли-көйли, чишмә ага. Иртәнме яки кичenme — кайчан килмә, ул үзгә. Иртәнге җыры кичкесенә охшамаган була. Шундый кабатланмас моңы белән ул сине әсир итә.

Рәшит Әхмәтҗановның яңа шигырьләр җыентыгын укып чыккач, шундый хис кичердем. Шагыйрь китабын тикмәгә генә «Гомер чишмәсе» дип атамагандыр. Чөнки шигырь — үзе рухи чишмә бит ул. Шагыйрьнең һәр әсәре җанлы. Автор нәрсә хакында иҗат итсә, шуның тере картинасы күз алдына килә. «Җир уллары, җир кызлары» шигырендә шагыйрь, игенченең җырын офыкларга алып менгән тургайга карап, болай ди:

Ул җырлардан гүзәлрәк җырлар
Җирдә ишеткәнем юк әле.

Китапта лирик хисле, эчке тирән мәгънәле, тургай җыры тамган туган җиргә чиксез мәхәббәт белән сугарылган мондый юлларны шактый күп очратырга мөмкин. Шагыйрь «эчкерлелек белми яшәгән» әнисенең сүзенә колак сала. «Җир белән бергә картайган» ил картының васыять булырдай хикәятен тыңлый.

Гашыйклар беркайчан
Ил ташлап китмиләр,—


ди шагыйрь иленә гашыйк карт исеменнән. Шигырь «Сөйләде ил карты» дип атала. Бу әсәрнең герое, туган җирен, туган туфрагын үзенең каны һәм тире белән сугарган Ил карты, «иң соңгы сулышы — иң соңгы зур сынау кешегә» дип, бик дөрес әйтә. Ә үзе соңгы сынау алдыннан курыкмый. Чөнки ил алдында, кешеләр каршында аның йөзе ак, күңеле пакь, аның сүзләрендә никадәрле кешелеклелек, туган җирне олылау.

Җиремә үземнең
Төсемне калдырып,
Ятармын бер көнне
Җиремне ябынып.

Илгә, җиргә тугрылык. Шагыйрьнең күп кенә башка шигырьләрендә бу фикер кызыл җеп булып сузыла. Шактый тормыш тәҗрибәсе туплаган, күп нәрсәгә карата карашы инде ныгып урнашкан шагыйрь үзе дә улына («Улыма») мондый киңәш бирә:

Боз булса да, илне
кочакла.

Шагыйрь әнә шундый тирән фәлсәфи юллар белән укучыга үз дөньясын ачып сала. Шагыйрь дөньясы шау чәчәктән генә тормый. Тормышның үзе кебек катлаулы. Матурлык белән явызлык янәшәдә генә, бер юлдан йөриләр. Гүзәллекне сөюче шагыйрь таш өстендә үсеп утырган гөлләргә соңгы йотым суын сибә. Ә шул таш астында — елан оясы. Тормыш та нәкъ менә шулай. Ак янында кара бар. Шагыйрь үзенең әлеге фәлсәфи фикерен дүрт юллык шигырьгә сыйдырган.




Кыскалыкта – осталык. Рәшит Әхмәтҗановның «Бүген кинәт күк күкрәде...», «Күзге яңгыр коя», «Һәр тамырда бер карурман» кебек башка кыска шигырьләре дә шунда ук күңелдә калалар.

Стенада болан мөгезе.
Ә үзе?

Һәркемне уйландырырлык юллар бу. Күпме мәгънә. Табигатьтән ни кала, аның өчен җаваплымы без? Ирексездән күңелдә шундый сорау туа. Бер сүз белән әйткәндә, бу шигырьне гуманлы шагыйрь иҗат иткән. Р. Әхмәтҗановның төп үзенчәлеге дә, башкалардан аерылып торган ягы да әнә шунда. Ул әйтергә теләгәнен самими, шул ук вакытта кинаяле юллар белән укучыга җиткерә:

Учаклар яктым,
Әткәм яраткан
Кыр курайларын...
Ялкынга салдым,
Җыр кирәк җанга!

Рәшит Әхмәтҗановның шактый күп шигырьләре халык иҗатына тартым. Автор эчтәлек белән форма камиллегенә, авазлар яңгырашына, ритмик төгәллеккә, мәгънә бөтенлегенә ирешкән. «Карлыган җыя ана», «Сау булыгыз, кыр казлары», «Сандугач керде күңелгә», «Әллә ни әйтсеннәр» дигән шигырьләре шундыйлар рәтенә керә.

Шагыйрь һәр шигыре белән күңелне үзенә тарта. Автор үзе дә бер шигырендә бик төгәл итеп болай ди:

Якынайдым кеше йөрәгенә.

Үз чиратында укучы да аңарга карата шундый ук сүзне әйтә ала. Йөрәктән чыккан хис кенә йөрәккә үтеп керә. Бу фикерне Рәшит Әхмәтҗанов иҗатының башка якларына да кагылып раслап булыр иде.

Гомумән, җыентыкка эчтәлекле әсәрләр тупланган. Алар шагыйрьнең үсеш юлында югарырак бер баскычка күтәрелүен күрсәтәләр.

Бакча чүп үләнсез булмый, диләр. Рәшит Әхмәтҗановның да кайбер кимчелекле, ашыгыбрак язылган шигырьләрен күрсәтеп булыр иде. Ләкин максат ул түгел. Иң мөһиме – алдымда яңа җыентык, әйбәт шигырьләр җыентыгы. Сүземне чишмә белән башлап җибәргән идем һәм чишмә белән тәмамлыйм. Шигырь сөючеләр шагыйрь Рәшит Әхмәтҗановның илһам чишмәсеннән (конкретрак әйтсәк, китабыннан) яратып авыз итәрләр. Бу чишмә саекмасын, зурайсын, мул сулы елгага әйләнсен.

*«Татарстан яшьләре» газетасы.– 1977. – 17 май*

# Офыклар артында ачышлар

Рафис Гыйззәтуллин

Шагыйрь Рәшит Әхмәтҗановның «Ак канатлар» исемле беренче китабына язган рецензиясен Р. Гәрәй түбәндәге сүзләр белән тәмамлаган иде: «Бүгенге көндә аның (Рәшит Әхмәтҗановның.– *Р. Г.*) иҗаты күтәрелеш, үсеш чорында. Алда аңа ләззәтле һәм газаплы кичерешләрдән соң туа торган берсеннән-берсе уңышлырак шигырьләр юлдаш булсын. Шагыйрьне поэзия дип аталган чиксез зур дөньяга алып чыккан «йөрәк бәйрәмнәренең кыңгыраулар таккан» аргамаклары ярты юлда арып калмасыннар» («Казан утлары» журналы.– 1973.– № 4).

Күптән түгел китап кибетләренә Рәшит Әхмәтҗановның «Гомер чишмәсе» исемле яңа китабы чыкты. Ике җыентык арасында дүрт ел гомер. Уйласаң, иҗат кешесе өчен шактый вакыт бу. Күңелдә сораулар туа: аргамаклар юлда арымаганнармы? Ак канатлар нинди биеклекләргә күтәрелгән, нинди офыкларга җиткәннәр? Ярты юлда туктап калмаганнармы?..

Дулкынланып «Гомер чишмәсе»н укый башлыйм. Шигырь арты шигырь килә...

Кемдер шигырьләрне энҗе муенсага охшаткан. Кабатлау булса да, Рәшит Әхмәтҗанов шигырьләрен мин дә шундый муенсага тиңләр идем.

Җыентыктагы һәр шигъри энҗе үзенчә ялтырый, һәрберсе үзенә хас төс бирә. Шул энҗеләр, бергә җыелып, үзенчәлекле яктылык хасил итәләр. Ә бу яктылыкны алар яшәүдән, мәхәббәттән, кыскасы, тормышның үзеннән алалар. Әйе, әйе, тормышның үзеннән. «Ак канатлар»да башланган матур адым «Гомер чишмәсе»ндә дә дәвам итә, үзенчә яңгыраш таба. Авторның кайсы гына шигырен алып карасак та, без анда тормыш турында тирәннән фикер йөртү, яшәүнең мәгънәсе турында уйлану күрәбез, тынгысыз җанлы лирик герой белән очрашабыз. Шагыйрь үзе дә, аның лирик герое да үз интим хисләрен җырлау белән чикләнмиләр. Алар ил, халык язмышына бәйле зур мәсьәләләр белән янып яшиләр.

Дошманнар атты илемә –
Уклары миңа тиде,–

ди шагыйрь «Мин һаман шундый» исемле шигырендә.

Авторның ватанны, халкын яратуы ифрат көчле, һәм бу турыда Рәшит Әхмәтҗанов гади, самими итеп яза. Аның әсәрләрендә ясалмалылык юк:

Без кешелек яклы кешеләрбез,
Җиңүләргә барган нәселдән.
Ә туган җир, мәңге бәхет биреп,
Кайгыларны безнең яшергән.

*«Алма белән кояш арасында»*

Туган ил, туган җир турында язылган шигырьләр бик табигый рәвештә шагыйрьнең әнисенә, сөйгән ярына багышланган әсәрләренә килеп тоташа. Авторның «Әнкәң уйлана», «Карлыган җыя ана» дигән шигырьләрендәге ана образы үзенең эчкерсез, изге булуы белән аерылып тора.

Рәшит Әхмәтҗанов кеше күңеленең нечкә һәм катлаулы кичерешләрен поэтик чаралар белән күрсәтергә омтыла. Бу – аның яхшы ягы. Автор бу максатына кеше һәм табигать, кеше һәм тормыш арасындагы мөнәсәбәтләрне тасвирлау аркылы ирешә. Менә тагын дүрт кенә юллык бер шигырь:

Бүген кинәт күк күкрәде...
Ниләр яуды, кая акты?
...Яшь имәнне яшен сукты,
Карт алмагач чәчәк атты.

Аның шигырьләренең төп геройлары барысы да җир кешеләре, безнең әтиләребез, әниләребез, безнең туганнарыбыз, алар — «җир кызлары, җир уллары».

«Гомер чишмәсе»нең икенче бүлегендә шагыйрьнең мәхәббәт турындагы шигырьләре тупланган. Мәхәббәт турында язу хәзер авыр, әйтәсе сүзләр әйтелгән, диләр. Кемнәр өчендер бу шулайдыр да. Ә менә Рәшит Әхмәтҗановның бу өлкәдә дә табышлары байтак кына. Мисалга «Умырзая төсе кырларда» дигән шигырьне китерү дә җитә. Сөю, сөелү, сагыну, сагыш турында шагыйрь образлы итеп болай ди:

Офыкларда йөри...
Кемдер йөри аны урларга.
Аны мөмкин җырда җырларга тик...
Умырзая төсе кырларда.

«Гомер чишмәсе»ндә табигатькә, кошлар, җәнлекләргә багышланган тирән мәгънәле шигырьләр бар. «Язлар быел соңга калды...» дигән шигырендә, мәсәлән, шагыйрь, торналарга карап, кешеләр турында уйлана. Тормышта булган тирән драматизмны ул шушы ике юл эченә сыйдыра:

Йолдызлардан азрактыр без кешеләр.
Без азрак — чөнки бит без
                    ныграк яндык...

Мондый мәгънәле шигырьләр Рәшит Әхмәтҗановның кыска шигырьләрендә еш очрый. «Таш өстендә гөлләр», «Җыр кирәк җанга», «Ут эченнән...», «Сине уйлыймын да» кебек шигырьләре — әнә шундыйлардан.

Таш өстендә гөлләр...
Гөл өстенә
Соңгы йотым суны коясың.
Һәм актарып ташны,
          таш астыннан
Тапканым бар елан оясын.
*«Таш өстендә гөлләр»*

Шагыйрь, әнә шулай кыска язып, тирән мәгънә бирә, көтелмәгән нәтиҗә ясый.

Җыентыкта халык инде үз итеп, яратып өлгергән «Сау булыгыз, кыр казлары», «Акчарлаклар» дигән җырлар белән бергә «Умырзая төсе кырларда», «Миләшләргә киләм...» кебек җыр булып китәрдәй матур шигырьләр күп.

«Гомер чишмәсе»н бер талпыну белән укып чыктым да уйга калдым. Шагыйрьнең «Гомер чишмәсе» тирән, саф икән. Ул гел-гел шулай булсын, шагыйрь аны гел күңеленнән чыгармасын, иҗатын тагын да активлаштырсын, укучыларны күләмлерәк, тагын да тирәнрәк эчтәлекле әсәрләр белән куандырсын иде. «Язлар быел соңга калды...» дигән шигырен укыгач, аның моңа да көче җитәрлегенә ышаныч туа.

Аргамаклар юлда арымаганнар, ак канатлар югарырак күтәрелгәннәр икән.

Җыентыктагы «Белмисеңдер...», «Сөймәсәң», «Әллә ни әйтсеннәр» кебек матур гына фикерләре булып та, сәнгатьчә эшләнеп җитмәгән шигырьләр шигъри офыкларны тарайта алмауларына чиксез сөенеп куйдым.

Юлчы һаман да юлда. Алда әле барып җителмәгән ак шәфәкъ бар. Табылмаган, ачылмаган табышлар алда әле!

*«Казан утлары» журналы.— 1977*

# Күңелдәниләр калды?

Роберт Әхмәтҗанов

Һәр яңа җыентык шагыйрьнең рухи үсешенең бер этабы — яңага күчеш этабы итеп каралырга тиеш. Һәр яңа шигырь шагыйрь рухының трансформациясе ул. Үсеш-үзгәреш шигырьдән шигырьгә, җыентыктан җыентыкка күчә бара. Җыентык исә, әгәр дә бик җентекләп, композицион яктан бик тәфсилләп төзелә икән, үзенә бер организм кебек ул. Биредә һәр әсәрне кайсы әсәр белән янәшә кую әһәмияткә ия. Бу исә күңел хронологиясен, эчке дөнья үсешенең эзлеклелеген күрсәтү өчен генә түгел, ә бәлки поэтиканың бөтенлеген, стильнең никадәр төзеклеген һәм, ниһаять, шагыйрь сайлаган иҗат платформасының ни дәрәҗәдә тотрыклы икәнен раслау өчен дә бик кирәкле нәрсә.

Җыентыктагы аерым шигырьләр отышлы яки отышсыз булырга да мөмкин. Әмма болар гына авторның иҗади йөзен билгели алмый әле. Шунлыктан әдипнең иҗатын бөтен тулылыгы белән күз алдына китерергә теләсәң, аның шигырьләр китабын тулысынча кайта-кайта укып чыгу, алай гына да түгел, күзаллау өчен, беркадәр «тын алырлык» интервал калдырырга да кирәк. Ниләр истә калды соң? Шагыйрьнең күңел камертоны нинди, фикер музыкасы ничек, рух сурәте ниндирәк? Ниһаять, алар иҗат шәхесе белән никадәр тәңгәл киләләр?

Шагыйрь Рәшит Әхмәтҗановның шигырьләрен мин һәрвакыт укып-күзәтеп киләм (адаш булганы өчен генә түгел, билгеле). Аның моннан элегрәк чыккан «Гомер чишмәсе» исемле җыентыгы, мәгълүм булганча, поэзия дусларында җылы тәэсир калдырган иде. Менә, ниһаять, аның «Җан яктысы»н укып чыктык.

Китапны ачып кердек, шигърият дөньясында йөрдек һәм ябып чыктык — ниләр калды соң күңелдә? Нинди моң? Шагыйрьнең җан яктысы ни дәрәҗәдә яктыртты безнең күңелләрне?

Дөресен әйтик: яктырып, сафланып чыктык.

Иң беренче моның сәбәбен эзлибез — нилектән?

Кыска гына бер җавап күңелгә килә: самимилектән!

Әйе, шигъри хисләрнең эчкерсезлегеннән, эмоциональ җегәреннән, ихласлыгыннан...

> Сибелеп үт илкәемә,
> Әй, ак болыт, пакь болыт!
> Калсын әле бүгенге көн,
> Калсын алтын чак булып.

Халыкка, дөньяга әйтер өчен тәмам өлгереп җиткән сүз генә әнә шулай табигый булып туа, үз юлын таба.

Авторның күңел камертоны ниндирәк соң?!

Аның моңы халыкның җанлы сөйләменнән, туган телебезнең чиксез мөмкинлекләреннән борнап чыга. Шунлыктандыр хис-тойгыларның график сурәте халык нәкышендәгедәй сыгылмалы, чәчәкле, орнаментлы. Бу уңайдан аның «Онытмыйм» исемле шигыре күңелгә килә. «Адашкан сарык бәрәнен эзләргә киткән бала»ның күңел монологы социаль фәлсәфәгә күтәрелә:

> Онытмыйм,
> Һаман исемдә
> Сине эзләгән төнем.

Мине, адашкан чакларда,
Саклады, яклады шулай
Кояшлы туган телем.

Үсеш дәвам итә:

Караңгыдагы караклар
Якмаслар инде учак.
Яклаучы булмаса әгәр –
Беләмен, алар минем дә
Тунымны салдырачак.

Катгый, ачык позиция!

Туган телгә әнә шундый зур ставка ясый шагыйрь.

Сүз дә юк, дөрес эшли ул. Чөнки мондый җылы мөгамәлә һәр ике як өчен дә игелекле. Аның каравы «Кояшлы туган тел»дә шагыйрьне шигъриятнең олы юлына алып чыга. Ә шагыйрь исә үз нәүбәтендә аның сафлыгының, пакьлегенең тугрылыклы сакчысы булып кала.

Китапта кыска күләмле лирик-фәлсәфи шигырьләр шактый урын ала. Зәңгәр диңгездән уч белән су алганда суның зәңгәрлеге югалгандай, ул кыска шигырьләр дә шулай ук бер-берсе янәшәсендә генә җетерәкләр кебек. Алар ничектер, бер-берсен көчәйтеп, бербөтенне тәшкил итәләр сыман (шунлыктан мин дә биредә аларга аерым-аерым тукталырга җыенмыйм). Билгеле, алар арасында «ата» торганнары да, фикер нагрузкасы сыек булганнары да бар. Әмма мәсьәләнең асылы анда түгел. Аларның уртак тоны күңелдә уңай тәэсир калдыра.

Аларның һәркайсы мәгънәле бер шигъри орлыкка корылган. Укый торгач, азакта мондыйрак көтелмәгән резюме килеп чыкканнары да бар:

...Дөнья дип атала, дустым,
Син басып торган урын.

Шагыйрьнең «Кыска шигырьләре» дә тормышның үзеннән килгән кызыклы күзәтүләргә корылган күңел нәтиҗәләре буларак кабул ителә. Шулар арасында «Сугыш елы» дип исемләнгән, һәр бүлеге берәр строфадан торган шигырь аеруча истә калырлык. Анда сугыш елларының балалар күңелендәге ачы юшкыны яңара сыман. Олы фаҗига...

Тышта буран. Инсаф бабай үлә...
Мин тын гына аны озатам.
Соңгы сүзе: – Мин ипигә барам,
Сез көтегез, балам, тиз кайтам...

«Исәннәр моңы» поэмасы шулай ук сугыш фаҗигасен, туган илгә, Ватанга тугрылык хисләрен, кеше күңеленең төрле параметрларын – бөеклеген һәм түбәнлеген чагылдыруга нигезләнгән:

Йолдызларга үрелеп кул тидергән
Ирләр буен дарлар үлчәрме?! –
Дошман баскан җирдә нәфрәт шартлый –
Мина иттек сезнең үчләрне.

Сугыш темасына язылган поэтик әсәрләр бездә инде күп язылды һәм әле дә чыгып тора. Билгеле, бу инде яңа тема түгел. Әмма туган илгә, Ватанга, халкыңа тугрылыгың, вөҗдан сафлыгың сынала торган олы дау мәйданы буларак, бу тема искерүне белми, ул гел яңа. Рәшит Әхмәтҗанов бу теманы үзенчә чишү алымнарын тапкан, аны әхлакый принциплар югарылыгына күтәргән, социаль яңгырашлы итә алган.

Җыентыкның исеме булган «Җан яктысы» бу җәһәттән дә үзен аклый: ул илгә кыен чакта утларга кергән фидакярләрнең җан яктысы белән кушыла, ахыр чиктә исә тулаем китапның якты лейтмотивына әйләнә.

*«Татарстан яшьләре» газетасы.– 1982*

# Тургай

Ркаил Зәйдуллин

Рәшит Әхмәтҗанов иҗаты хакында сүз чыкса, капылт кына шагыйрьнең мәгълүм шигыреннән бер өзек хәтергә килә:

Сандугачлар янган утта
Җылынырга ярыймы соң?!

Һәм гаҗәп тә түгел: әлеге ике юлда олы мәгънә ята. Әйе, тормыш – катлаулы. Әгәр сиңа килгән бәхет башка бер җан иясенә хилафлык китерү бәрабәренә икән, бу әле бәхет түгел. Син гаепсез булган очракта да...

Шагыйрь төрле төсләрдә балкучы җәйгор ул, шагыйрь җәйге болын ул. Яңа әсәр – яңа төсләр балкышы. Шул балкышка орыну – шатлык. Р. Әхмәтҗановның «Казан утлары»нда (№ 9) басылган шигырьләре миңа шул шатлыкны бүләк итте.

Тагын таң нурлары тамды
Ямь-яшел яфракларга.
...Таң белән мин дә сәфәр чыгам.
Юлым арышлар арасыннан үтә...
Ерак-еракка...
Иксез-чиксез киңлек.
Баш очымда тургай бөтерелә.

Мин аңа игътибар да итмим төсле – шундый нәни ул, шундый гадәти ул. Ара-тирә машиналар уза, аларның гөрелтесе тургай сайравын күмеп китә, тик бу берничә минутка гына... Дөнья тагын элеккеге хәленә кайта һәм мин шунда тургайның үзем өчен никадәр кадерле булуын аңлыйм.

Тургай сайрый. Ул инде күктә бер кара нокта булып кына калган. Күтәрелә тургай, чөнки «иле – зәңгәр күге шундый аяз аның, шундый биек!»

Безнең поэзия – бәхетле поэзия. Зур һәм бер-берсенә охшамаган шагыйрьләребез, саный китсәң, байтакка җыйнала. Мисалга 1960 елларда әдәбиятка килгән шагыйрьләрне генә алыйк. Хәер, үз вакытында әлеге шагыйрьләр иҗаты хакында сүз байтак булды. Зур бәхәсләр купты. Хакыйкать бәхәстә туа дигәндәй, бу шагыйрьләр иҗаты тиз арада әдәбиятта үзенә лаеклы урын алды.

1960 еллар буыны... Рәшит Әхмәтҗанов та, һичшиксез, шушы буын вәкиле. Ләкин сөйләшүләр, бәхәсләр вакытында аның иҗаты, миңа калса, нигәдер гел күләгәдәрәк кала килде шикелле.

Бүгенге көндә, минемчә, Рәшит Әхмәтҗанов – халыкка, аның күңеленә иң якын торган шагыйрьләребезнең берсе.

«Илгә – ирек!» дип,
　　　　карурман кичтек,
Җил булып истек, ут
　　　　булып яудык.
Тау булып бастык
　　　　дошман каршына,
Дошман өстенә тау булып
　　　　аудык.



**«Татарстан яшьләре» газетасы редакциясендә.**
**Ринә Зарипова, Хәмзә Зарипов, Барлас Камалов, Илгиз Миңһаҗев, Илдус Сафин, Рифкать Бикчуров, Рәшит Әхмәтҗанов. 1980 еллар**

Гамьсез тыңлаучыга тургай бертөрле генә сайрый булып ишетелергә мөмкин. Бер минутка туктап, өскә кара, юлчы! Тургайның канатларыннан сагыну тама, тургайның канатларыннан әрнү тама, тургайның канатларыннан ярату тама!

Шагыйрьнең әнкәсенә багышлап язган шигыре тетрәтте мине. Ул әнкәсен үзе белән күк арасындагы (димәк, дөнья белән!) элемтәгә охшата. Шигъри элемтәгә. Һәм бер көнне тавыш килми. Әнкәй белән, үткәннәр белән элемтә... Шагыйрь эзли, аны югалта-югалта эзли...

Сахраларда шактый
йөрелгән –
Бармактагы балдак
эрегән...
Кайткан идем ярым
янына –
Килмә, килмә, диеп
ялына...

...Тургай моңын тыңлап барам. Машиналар узып китә, гөрелтеләре офыкка эленеп кала. Тургай канаты орынган арышлар тын гына пышылдашалар...


*«Татарстан яшьләре» газетасы.– 1983*

# Чәчәк җылысы

Мөдәррис Әгъләмов

Алтмышынчы елларда татар шагыйрьләре хорында бер үзенчәлекле шигъри аваз яңгырады.

Таш күтәреп тала буыннарым,  
Ташлардан ук үзем көч алам.  
Яшьлек, яшьлек,  
Синең сафларында  
Тау-ташларны ватып сыналам...



Бу унсигез яшьлек шагыйрь Рәшит Әхмәтҗанов иде. «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналында басылып чыккан беренче шигъри бәйләмендә үк ул дөньяны төзекләндерергә, матурларга, яңартырга омтылучы шәхескә карата җитлеккән шагыйрьләргә хас осталык белән дан җырлады. Үткәннәр белән бүгенгенең, бүгенге белән киләчәкнең яңалыкны иҗат итүче кешедә бер төенгә төенләнүен нечкә күңеле белән тоемлаган әлеге яшь шагыйрь Хәсән Туфан, Сибгат Хәким кебек өлкән әдипләрнең дә игътибарын үзенә бик тиз тартты. Аның үз укучылары даирәсе барлыкка килде.

Инде талантлы шагыйрь булып танылган Рәшит Әхмәтҗановның күптән түгел генә Татарстан китап нәшриятында дөнья күргән «Җан яктысы» исемле яңа җыентыгы да әнә шушы беренче шигырьләрдән үсеп чыккан. Без бу китапта да гомеренең юл башында ташчы булып эшләгән, Әлмәт каласының нигезен салышкан шагыйрь егетне һәм менә шушы тормыш җирлегеннән үсеп чыккан төзүче — җиребезне яңартучы образын бик ачык күрәбез. Аның әнкәсе җибәргән бияләйләр турында уйланулары да менә шушы рух белән сугарылган:

Тетелделәр бияләйләр, сүтелделәр —  
Зыкы суык... Таш өшеми, куллар өши.  
Күтәрдек без сине, Әлмәт, биекләргә,  
Бураннарда, суыкларда күктән төшми.

Хезмәт безгә иң матур җыр булды җирдә,  
Чәчәкле җәй итте безнең күңелләрне.  
Гомерләрнең иң биек бер ноктасына  
Байрак итеп эләр идем ул көннәрне...

Яңа китапка кертелгән әсәрләр шагыйрьнең үзе тоткан юлдан эзлекле рәвештә алга баруын күрсәтеп тора. Бу җыентыгы аша автор кыска, төгәл һәм тирән мәгънәле итеп яза белүен тагын бер мәртәбә раслый.

Моңарчы без Рәшит Әхмәтҗановны шигырь жанрында гына эшләүче шагыйрь итеп белә идек. Ә бу җыентыкта исә аның «Исәннәр моңы» исемле поэмасы да тәкъдим ителгән. Алдан

ук шуны әйтеп куйыйк: әлеге поэма үзенең язылышы белән шактый үзенчәлекле. Мәсәлән, бу үзенчәлек аның формасында да чагылыш таба. Беренче карашка, поэманың һәр бүлеген аерым мөстәкыйль шигырь итеп тә укырга мөмкин. Бу — әсәрнең яхшы сыйфатымы? Әллә... Бу уңайдан Һади Такташның «Киләчәккә хатлар», «Мәхәббәт тәүбәсе» кебек әсәрләрен искә төшереп үтәсе килә. Әлеге поэмаларның аерым өзекләре кешеләр күңелендә аерым бер мөстәкыйль әсәрләр шикелле яшәмиләрмени?!

Шунысы әһәмиятле: Р. Әхмәтҗановның «Исәннәр моңы» поэмасындагы һәр бүлек бер фикер агышына, бер «арка сөяге»нә, яшәешнең бер тулы картинасын тудыруга буйсындырылган. Менә шуңа күрә ул шигъри цикл түгел, бербөтен әсәр буларак кабул ителә.

Рәхимҗан, Басыйр, Ләйсәнә, ана... Әлеге геройлар поэмада ил язмышы белән яшәүче олы җанлы кешеләр буларак гәүдәләндерелгән. Аларның дөньясы бик киң. Бәлки, менә шуңа күрәдер дә автор поэманың билгеле бер кысалар белән чикләнмәгән «ирекле» формасыннан файдаланган. Шагыйрьнең уй-фикерләре ярларыннан ташып чыгуы, минемчә, бик табигый, чөнки аны аерым кысаларга гына сыймаучы тормыш материалы шуңа этәргән.

Поэмада шагыйрь белән лирик герой икесе бер булып китәләр, бер дәрәҗәдә уй-фикер йөртәләр, бергә яшиләр. Шагыйрь үзенең укучысы белән дә үз тиңе итеп сөйләшә, фикер алыша, бәхәсләшә. Укучы, лирик герой, шагыйрь арасында үзара ышаныч, бер максат өчен яну барлыкка килә. Үз вакытында Әхмәт Фәйзинең мәшһүр «Флейталар»ы да әнә шундый сыйфаты белән халык мәхәббәтен яулап алган иде.

«Җан яктысы» дип исемләнгән китапның төп юнәлеше — шагыйрьнең ярып барган төп бразнасы: шәхес һәм тирәлек, шәхес һәм мохит, шәхес һәм җәмгыять. Кешеләрнең кичерешләре аның сулаган һавасында, кешеләрнең — аңа, аның кешеләргә карата мөнәсәбәтләрендә.

Кемнәрдер еракта,
Кемнәрдер йөрәктә...

Мәхәббәттә булсын («Ят җирдә сине сагынам», «Мин кабат туармын», «Мин бүген дә гашыйк», «Әйттеләр сиңа кешеләр») яки үз замандашларына карата мөнәсәбәттә булсын («Йөрәктә», «Кайбер дусларга җавап», «Җилсез, давылсыз кара төн» һ.б.), шагыйрь сөенә, газаплана, бәхәскә керә. Әйткәнебезчә, лирик герой — шагыйрь, шагыйрь — лирик герой.

Сер түгел, кайбер шигырь китапларында «лирик мин», шомба балыгы кебек, кулдан шуып чыга. Аны «тота» алмыйсың. Кем ул? Бу юлларны язган кешеме? Юк, ул түгел. Илебез киңлекләрендә бөек гигантлар күтәрешкән чордашмы? Ул да түгел. Кай җирендәдер кызыклы фәлсәфә бар, җирне — күккә, үсеп утырган агачны кирегә әйләндереп кую бар, ә шагыйрь юк. Ә бит Тукай шигърияте ндә Тукай бар, Такташта — Такташ, Җәлилдә — Җәлил, Туфанда — Туфан, Хәкимдә Хәким бар!

Бу яктан караганда, «Җан яктысы» китабына кертелгән әсәрләрдә җиргә нык басып торучы актив герой бар, шагыйрьнең үзе — Рәшит Әхмәтҗанов бар. Алар өчен халыкка, Ватанга хезмәт итүдән дә зуррак вазифа юк.

Туган көнемнән үк бәхет биреп,
Азат балам, диеп атадың.
Авыр чакларыңда Кол Гали күк
Колың булыйм, газиз Ватаным.

«Җан яктысы»... Чыннан да, бу китапны укыганда, күңелгә ниндидер якты нур иңә, җанны туган җирдәге чәчәк җылысыдай назлы хисләр җылыта. Шигърият сөючеләрнең дә аны шулай кабул итәчәгенә ышанам.

*«Социалистик Татарстан» газетасы.— 1983. — 29 апрель*

# «Кавышыр көн»

*(Рецензия)*

Фәиз Зөлкарнәев

Беренче тапкыр укыганда, Рәшит Әхмәтҗановның шигырьләре күңелдә каршылыклы тойгылар уята. Еш кына шигырьләрендә нинди дә булса берәр төгәлсезлек димме, нәрсәнеңдер җитеп бетмәвеме үзен сиздерә. Ләкин шуңа да карамастан, ә, бәлки, нәкъ менә шуның аркасындадыр, алар тәэсирлеләр, алардагы хис-халәтнең сафлыгы, ихласлыгы күңелне әсир итә. Чөнки аның хәтта бик үк уңышлы килеп чыкмаган әсәрләрендә дә шигъриятнең сулышы, җаны була.




Рухи олылык, зыялылык юк аңарда, әмма шагыйрьлеге, сизгер күңеле, үткер күзе бар. Ул — җир кешесе, аның дөньяны аңлау, кабул итү рәвеше авылча, халыкча.

Алтмышынчы елларда әдәбиятка килгән шагыйрьләр иҗатында, күпмедер дәрәҗәдә куәт алып, поэзиябездә бер тенденция яши башлады. Сүзнең тәмен, моң-аһәңен тоеп язу кимеде. Укыйсың — шигырьләр коры-сары чәйнәгәндәй тәэсир калдыралар. Әллә туган телебезнең тәмен шулай акрынлап җуя барабыз инде? Бәхеткә каршы, чынлап торып сүз остасы, стилист була алган шагыйрьләребез күбрәк. Аларның шигырьләре төгәл яңгырашы, музыкальлеге белән әлеге ямьсез шауны җиңеп, колакны гына түгел, җанны да иркәли. Моң — үзе шигъри көч бит, һич тә шигърият арсеналында онытылып ятарга тиеш түгел ул. Р. Әхмәтҗанов күңелен нәкъ менә моң иркенә куеп иҗат итәргә ярата. Аның иң тәэсирле шигырьләре матур яңгырашлы, аһәңле. Бу сыйфаты белән ул кайчакта хәтта Х. Туфан, С. Хәким кебек олы шагыйрьләребезгә якынлаша.

Яңа җыентыгын укыгач, тагы бер кат уйладым: Рәшит Әхмәтҗановка шагыйрь буларак эчке дисциплина җитенкерәми шикелле. Шигырьләрендә бераз таркаулык бар. Дөрес, менә дигән шигырьләр дә яза: «Бәйрәм», «Ничек соң синең исем?», «Учак», «Сугыш елы», «Әллә инде кыр казлары кайта...», «Яңгыр теләү»... Ләкин болардагы сыман төгәллек, шигырьнең форма-композиция ягыннан камиллеге аның иҗатында канунлашкан гадәти күренеш дип әйтеп булмый. Рәшит Әхмәтҗанов шигырьләрен нindидер бер эчке стихиягә, күңел-хис стихиясенә бирелеп, хисләрен артык җилбәгәйгә җибәреп яза шикелле. Менә шушы стихиялелек шигырьнең эчке тәртибен өзеп, күмеп киткән чакларда, бик үк камил булмаган әсәр килеп чыга. Бу җыентыкта

да бар алар: «Гашыйк булгач, тормыш мине кеше итте...», «Сулар ага...», «Корыч булалмыйсың, сиздем инде...», «Көннәр генә түгел, алда...»

Югыйсә уй-хисләрен гаять төгәл, пөхтә аңлата ала торган шагыйрь үзе. Кайбер юллары афоризм булып яңгырый:

...Сандугачлар янган утта
Җылынырга ярыймы соң!

...Яшәү – бәхет!
Тик ирнемдә кипте
«Китмә, яшьлек!» дигән бер догам.
Җирдә җылы артык булмас әле,–
Мин дә җанны ягып калдырам.

...Әйтәләр дә бит гомерне
Яңгыр тамчысы диеп,
Суларның тәме үзгәрде,
Тормыш ачысы тиеп.

Китап төзү – үзе бер сәнгать. Китап шигырьләр тупламасы гына түгел, ә китап булсын өчен, шактый тырышырга һәм моның өчен аерым сәләт кирәктер. Рәшит Әхмәтҗанов җыентыгын әйбәт төзегән димәс идем мин.

Җыентыкта – биш бүлек. Шигырьләр төркемләп, бүлекләргә аерып бирелгән икән,– димәк, аларны нәрсәдер үзара бәйләргә, башкаларыннан нидер аерып торырга тиештер бит инде. Күпме генә эзләсәм дә, мин аны таба алмадым. Нинди принцип нигезендә бүлгәләгән аларны шагыйрь? Хронологик яктанмы? Юк. Тематик яктанмы? Шулай ук – юк. Дөрес, лирик герой үсешен, аның күңел хәрәкәтләрен чагылдырырга тырышу бераз сизелә. Әмма ул теләк дәрәҗәсеннән узмаган. Бүлекләр бер-берсеннән аз аерылалар, үзара охшашлар. Чөнки аларда бер үк темага караган бер характердагы шигырьләр урын алган. Мәхәббәт шигырьләрен башка темага караган шигырьләр арасына куеп була – монысын аңлыйм мин. Ләкин шагыйрьнең «Без – халык», «Бәйрәм» кебек күтәренке пафослы, менә дигән публицистик шигырьләре янына «Бала» дигән наив әсәрен нигә урнаштыруын аңлый алмадым. Алар үзара һич яраша алмыйлар ич. Ә берничә бит узып, «Безнең тәрәзә» шигыреннән соң, ул, киресенчә, бик урынлы булыр иде.

Кыскасы, шагыйрь җыентыгын ныклап уйлап төземәгән дигән тәэсир калды. Гомумән алганда, шигырьләр әйбәт, ләкин китап төзү культурасы булмаганга күрә, алар җыентыкта бер-берсен тулыландырасы, бер-берсен үстерәсе, күтәрәсе урынга бер-берсенә комачаулыйлар гына. Шагыйрь өзми дә куймый бер үк сүз сөйли, бер үк катыкны туглый сыман тойгы кала. Күңел хәрәкәте күренми.

Йомгаклап нәрсә әйтә алам? Әлбәттә, «Кавышыр көн» җыентыгы дөнья күрергә тиеш. Ул күпмедер дәрәҗәдә Рәшит Әхмәтҗанов иҗатының яңа сүзе булыр. Ләкин ул яңа гына түгел, матур сүз дә булсын иде. Җыентыкта унбишләп зәгыйфь шигырь бар. Автор аларны йә кабат карап чыксын иде, йә бөтенләй алып ташласын. Бүлекләрне, андагы шигырьләрнең урнашу тәртибен дә кабат карап чыгу зыян итмәстер.

*1985*

# Рәшит Әхмәтҗановның «Йөрәк бәйрәме» исемле кулъязмасы турында[1]

Тәлгат Галиуллин

«Йөрәк бәйрәме» кулъязмасына (460 бит) Р.Әхмәтҗановның утыз елга якын вакыт аралыгында иҗат ителгән әсәрләре тупланган. Шуңа күрә ул шагыйрьнең иҗат манерасы турында сүз йөртергә, билгеле бер нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә.

Тормышны үтә лирик чаралар белән иңләргә омтылуы, табигый салмак интонациясе, халык җырларының аһәңенә якынлыгы белән Рәшит Әхмәтҗанов иҗаты җитмешенче еллар уртасында ук тәнкыйтьнең игътибарына һәм уңай бәясенә лаеклы булды. Яшь шагыйрьнең Туфан иҗатыннан үрнәк алуы, олы дөнья мәшәкатьләрен шигъри деталь аша тасвир итүе, халык җырларының бизәк-өлгеләренә таянып, тыныч кына үз юлын эзләве турында да фикер әйтелде.

Р. Әхмәтҗанов чынбарлык белән шәхес, табигый матурлык белән сәнгать арасында эчке якынлыкка, гармониягә омтыла. Кышкы төннәрдә дә, буранда да ул күңеле белән «кояш эзләп» юлга чыгучы шагыйрь. Туктаусыз хәрәкәт һәм үзгәреш-яңарыш, фән-техниканың әкиятчеләр хыялына да кермәслек ачышлар ясаган чорында информация дәрьясы заманында тынычлык һәм иплелек эзләү беркадәр сәеррәк тә тоелырга мөмкин. Ләкин тынычлык эзләү белән тынычлануны һәм гамьсезлекне бутарга ярамый. Шагыйрь табигатьнең дә, кешенең дә төрле халәтләрен үзәккә ала.

«Алдан әйт...» шигырендә табигатьнең бер күренеше тасвирлана:

Йә кырда җилләр ыжгыра:
Әйтерсең бүген менә
Бәхетсез ятып елый күк
Кешеләр йөрәгенә...

Янәшәлек алымы тормышында йолдызын югалткан, кылган эшләренең очын җуйган бәхетсез кеше образын тудыруга оеткы бирә. Алдагы юлларда параллелизмны антитеза «кысрыклый», шагыйрь әлеге фикеренә үзе үк каршы чыга, метафораны икенче мәгънә ягы белән әйләндереп куя:

Бәхетсез кеше елый, дип
Сөйләдем юри генә.
Кыюлар ятып еламый
Кешеләр йөрәгенә.

Бу шигырьдә психологик анализның тирәнәюе, тормышны күпьяклы чагылышлары аша күрергә омтылу, «тынгысызлык аша тынычлыкка» юл алу ачык сизелә.

Р. Әхмәтҗановның уңышлы лирик шигырьләренә тыйнаклык, эчке җыйнаклык, табигый аһәң, моң, фикерне каударланмыйча үстерү хас. Аның өчен халык иҗаты гәүһәрләре, Туфан, Хәким кебек шагыйрьләрнең ачышлары Галәветдин лампасы ролен уйный. Ул, бай культурабыз мирасына хөрмәт белән карап, аны үзенең ышанычлы ярдәмчесе, таянычы дәрәҗәсенә күтәрә белә.

[1] Р. Әхмәтҗановның шәхси архивыннан алынды (авторның култамгасы белән; үзгәртелмичә бирелә).— *Төз.*




Эссе көндә син, сандугач,
Мине эчтең;
Мин дөньяга моңлы җырың
Булып күчтем.

*«Тамчы монологы»*

Күгемне ятим калдырып,
Коега төшкән дә ай.
Янып, балкып ята суда
Бер кызның алкасыдай.

*«Ай төшкән кое төбенә»*

Беренче мисалда шагыйрь метафорик, шартлы образ ярдәмендә поэзиянең моңы, хасияте турында уйланса, икенчесендә һәркемгә якын, таныш төшенчә аша табигать белән кеше арасындагы уртаклык идеясен раслый. Ике мисалда да шагыйрь дөньяны образлы, шигъри кабул итә.

Ул табигатьнең ай, кояш, кыш, буран, җил кебек сурәтләренә киң таяна, аларны җанландыру аша яңа образ-сыннар тудыра, сурәтле фикерләү байлыгына яңа буяулар өсти.

Шагыйрь гасырлар түрендә туган халык җырларының дәртен, моңын, рухын аңларга, алар ярдәмендә заман проблемаларын ачарга омтыла. Халык җыры стихиясе тышкы бизәк, милли орнамент булып кына калмый, аның фикерләү рәвешенә килеп керә. Мәсәлән, «Җәй» шигырендә Р. Әхмәтҗанов «Сандугачым, су тап, су тап, йөрмә суларга сусап» дигән халык җырын эпиграфка чыгара да кичерешне ачу юлында аның икенче, тирәнрәк мәгънәсен өскә калкыта:

Кайчан моң беткәне бар соң
Үз илен сөйгән ирдә?

Еш кабатлануы белән укучыда инде ризасызлык тудырган сурәтләрне дә шагыйрь яңача яңгырата белә. Мәсәлән, ул поэзия тарихына Такташ исеме белән кереп калган, әмма аның эпигоннары тарафыннан абруе төшерелгән «зәңгәр» төснең яңа бер нюансын таба алган:

Зәңгәр күзләрендә зәңгәр һава.
Кыр казлары очып узарга.

*«Әллә инде кыр казлары кайта»*

Рәшит Әхмәтҗановның халык иҗаты алымнарына рухи якынлыгы турында тәнкыйтьтә фикер әйтелеп тора. Мәсәлән, ул еш кына лирик парчаларына, йөрәк серләрен, интим кичерешләрне үзәккә алган шигырьләренә эпиграф итеп халык җырларын ала һәм аның мәгънәсен, рухын шигыренең идея-эстетик максатына буйсындырып үстерә, киңәйтә, җәя:

Сары яфрак...
Су өстендә ята ялтырап.

«Яфраклар җыры» шигырен ачып җибәргән бу күзәтү табигатьнең бер картинасын сурәтләү аша («Беребез талда, беребез имәндә? Өзеләбез җилләр килгәндә») төгәлләнгән нәтиҗәгә килергә мөмкинлек бирә:

Өзгәләмә безне җил белән,
Бик яшисе килә ил белән.

«Җәй. Кызу. Гөлләр күзендә...» шигыренә башлам итеп «Сандугачым, су тап, су тап, йөрмә суларга сусап» җыры алына һәм аның үзәгендә яткан күренеш иң элек туры мәгънәсендә («Җәй. Кызу. Гөлләр күзендә чык тамчылары кибә...») ачыла да укучыны бөтенләй икенче мәгънәле нәтиҗәне кабул итүгә әзерли («Чык тамчылары сумыни, Сандугач моңы алар»). Язмыш урманнарында сандугач моңнары кибә, әмма шагыйрь үзенә башка язмышны да теләми:

Без калыйк әле, Сандугач,
Канатлар көйгән җирдә...
Кайчан моң беткәне бар соң
Үз илен сөйгән ирдә?

Халык җыры күңелдә менә шундый олы уйлар уята, лирик герой рухында яңа хисләр тудыра. Чөнки мондый фикерләргә сандугач символының киң мәгънәсе, аның туры һәм күчерелмә семантикаларын ачу алып чыга.

Шагыйрь кабатланмас образлар, метафоралар иҗат итү юлында да халык сызган юлдан бара. «Хуш инде, җәй» шигыренең күпертү алымы нәкъ менә халык җырларына хас юл белән иҗат ителгән:

Яфракларны кисә көзнең
Алтынсу кайчылары.
Сиксән сигез керфегемдә –
Сагыну тамчылары.

Алдарак әйтелгәнчә, халык иҗаты мотивлары, сурәтлелек чаралары иң тирән шигъри күзәнәкләргә үтә, анда яңача трансформацияләнеп, үзе мөстәкыйльлек ала:

Аккош гомерләре кайда үтә?..
Монда бүген буран дулады.
Илкәемә искән җылы җилләр,
Сөйгәненә баралмаган кыздай,
Шигыремә кереп елады.

Шул табигый фонда лирик геройның үз кичерешләре алгы нәүбәткә чыга. Тормыш катлаулыгын образлы чагылдыру нияте шигырьгә янәдән аккош образын алып керә:

Елады җил...
Чал дөньяда кинәт
Ишеттем дә аккош тавышын –
Болыннарның үзәгенә үтеп,
Туган илгә кайтыр аккошларга
Тамчылап күл җыя сагышым.

Халык җырына мәхәббәте хакында шагыйрь үзе туктаусыз искә төшереп тора. Нәкъ халыктагыча, «яр сөйгәннәр моңлы була, Җырлы була», «Кеше китә, җыры кала, диләр, Кайгысы да җир өстендә кала» дип яза да икенче шигырен җырдан өзек белән башлап китә («Җырласам әгәр, таң ата, диеп, Таң кайгыларны тарата, диеп») һәм үзенең максатлы нәтиҗәсен ясап куя:

Уйла син, җирем, кайгысы белән
Бу балам мине ярата, диеп.

*«Җырласам әгәр...»*

Алдагы куплетта да шул ук композицион өлге – халык җыры хисси тезисын кире кагу аша аныклау, үз идеясен раслау үстерелә (түгелә яшем – мин еламыйм). Өченче строфада шагыйрь эпиграфка әйләнеп кайтып, халык җырының рухи прогресста биләгән олы тарихи әһәмиятен раслауга килеп чыга:

Халкымның җаны тудырган җырны
Онытсам әгәр – таң атмас иде.
Шул җыр булмаса – җирдә беркайчан
Таһир Зөһрәне яратмас иде.

Алты меңгә якын җыр туплаган «Кыска җырлар» китабы басылып чыгу уңае белән язылган «Бу үзе» шигырендә дә җыр «халык җаны» дип атала, аның сәнгатьчә гүзәллеге ачыла («Җидегән йолдыз җиде балкый Җиде төн уртасында»):

Исе китмәгән халкымның
Җирнең алтыннарына,—
Җыр төяп йөргән икән ул
Атына, корабына.

«Сагыш булгач...» шигыре «сагынуым сары алтын» дигән халык фразеологиясен ялтыратып «уяту», бәхәсләшү алымы белән башланып китә һәм икенче мәгънә чыгару өчен оеткы була:

Сагыш булгач,
сары алтын
Нигә кирәк? Сагындым да
Саргайдым мин, саргайдым
Һәм сап-сары нур булдым.

«Исәннәр моңы» поэмасында «Агымсудай ага, диләр, гомер, Шулайдыр ул, улым, шулайдыр» гыйбарәсе яңа, тормышчан, хәтта прагматик нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә:

Агымнарда агып барганнарга
Җиңелдер бу дөнья, уңайдыр.
Авыр булды яшәү,
Хәзер инде
Кирәк түгел миңа җиңеле...

Р. Әхмәтҗанов бик борынгы заманнарда туып, безнең көннәрдә дә нәфислеген җуймаган халык җырларына чордашының шәхси кичерешләрен ялгап алып китә белә:

«Шам Шәриф лә дигән ай шәһәрнең
Тәрәзәсе саен якты шәм...» —
Шулай җырлап мин гөлләргә түгел,
Йөрәгеңә синең эндәшәм.
*«Борынгы көйгә»*

Халык җыры иң интим кичерешләрне хәрәкәттә, динамикада ачу мөмкинлеген бирә. «Ак әремнәр кемне әрләсен?» шигырендә халык җыры энҗеләре белән халык мифологиясе бергә кушылып китә:

«Болгар җирләренә барыйм дисәң —
Җитмеш чакрым юлда карурман.
Сак белән Сок сиңа кычкыралар:
«Без генәме әллә аерылган,
Без генәме әллә аерылган...»

«Җитмеш чакрым», «карурман», Сак белән Сок образлары лирик геройның кичерешләре, фикере ачылсын, актарылсын өчен җирлек әзерлиләр, аның хисләрен гомумиләштерү чарасы булып хезмәт итәләр. Алдагы юлларда янәдән беренчел мотив алга чыга: «Болгар җирләренә үтим дисәң, Кара урманнарны узасың...» Бу — гади кабатлау түгел. Кайчандыр кала, ныгытмалар утырган җирләрдә таш хәрабәләр калган, анда ерак заманнар елап ята. Менә шундый элегик, моңсу уйланулар, «үткәнне кайтарып булмый» дигән хакыйкать уяткан әрнүле фикер ахыр чиктә оптимистик бетемгә алып килә:

Тарихымның утлы сүзләреннән,
Замананың нурлы күзләреннән
Эзлик әйдә яшәү мәгънәсен.

«Идел барында» шигырендә дә тарихны иңләү аша халыкның теле һәм җире мәңгелек дигән фикер үткәрелә.

Шагыйрь халык мифологиясендә батырлык, фидакярлек үрнәкләре таба («Авызы белән дәрьялардан»), казлар канатына мәхәббәт сагышының сарылуын сиземли («Казлар канатында очып киткән сөю елата»). Аның лирик герое әхлакый сафлыгы, характерының бөтенлеге белән күңелдә кала.

Шагыйрь фольклордан үрнәк-өлге алуында үзен билгеле бер жанр белән генә чикләми. Лирик җыр ачышларына өстенлек бирсә дә (табигый сәләте шуны таләп итә), ул мәкаль-әйтемгә дә, бәет кебек үзенчәлекле жанр ачышларына да таяна. Әйтик, абыйсы Камил истәлегенә багышланган «Җир өстендә ап-ак ат» шигыре — рухы белән бәеттән үсеп чыккан әсәр. Герой ап-ак атка атланып авылына кайта һәм аянычлы хәбәргә юлыга:

Икебез дә еладык,
Авыр хәбәр алуга.
Абый үлгән сугышта...
Әйди безне нәфрәтләр.
Ашаган-эчкәнебез —
Күз яше дә хәсрәтләр.

Бәет поэтикасы — шагыйрьгә кара җир кебек кара кайгының авырлыгын укучыга тулырак җиткерүдә ышанычлы юлдаш.

Халыкта кайгының олылыгын, чиктән ашуын әйтү хаҗәте булганда, аның күләмен дәрья суына тиңләү алымы яши. Бу алым бигрәк тә озын җырлар һәм бәетләр өчен хас. Яшь артист Дамир Нәбиуллин истәлегенә багышланган шигырендә Р. Әхмәтҗанов шул күпертү алымына таяна:

Нәни чокыр уям кабер ташыңа...
Дәрья кадәр кайгы килде башыма.

Бәетнең тормыш фаҗигасен чагылдыруга мөмкинлек биргән гомумиләштерү алымнарына еш мөрәҗәгать итә Р. Әхмәтҗанов. Мәсәлән, «Исәннәр моңы» поэмасында Бөек Ватан сугышында батырларча көрәшеп, күзен югалткан егетнең монологы «Басыйр бәете» дип атала. Жанрның үзенчәлекле алымнары физик һәм рухи югалтуларны калку итеп күз алдына бастырырга мөмкинлек бирә:

Батырлык ни? — Белмиләр монда ирләр,
Хатын-кызлар елыйлар, иңриләр.
Арыды ул,— башны кая куясы?
Күккә карый,— юк күгендә кояшы.

Әлбәттә, егерменче гасырның 1970–1980 еллары шагыйре үзен халык иҗаты традицияләре белән генә чикли алмый. Ул хәзерге совет поэзиясе казанышларына таяна, татар әдәбиятының иң яхшы традицияләрен маяк итеп ала. «Исәннәр моңы» поэмасына М. Җәлилнең «Моабит дәфтәрләре»нең героик аккордлары килеп керүе дә табигый яңгырый:

Үлем аша, беләм, үз җиремә,
Үз иркемә тизрәк кайтырмын.

Яисә:

Батырларга — бары яшәү генә,
Үлеме юк җирдә батырның...

Ихтыяҗ булганда, Р. Әхмәтҗанов Дәрдемәнд традицияләренә дә килеп чыга. Диңгез сурәтенә еш мөрәҗәгать итүендә, аның ярсулы, давыллы холкына мәхәббәт тотуында һәм аларны шәхес рухы катлаулылыкларын ачуга буйсындыра белүендә Дәрдемәнднең шифалы йогынтысы сизелеп-сизелеп үтә:

Исәннәр генә торалар
Яр булып диңгеземә.
Давыллый...

Офык аша җан
Гүя нидер сизенә...

*«Диңгезне күптән күргән юк...»*

«Аккош йоклаган су кебек тыныч идем...» шигырендә С. Рәмиевне хәтерләткән ярсу, бунтарь мотивлар алга чыга:

Кораб янар, диңгез янар, сөю янар...
Ике күзем елан булып сине чагар.

1976 елда иҗат ителгән «Исәннәр моңы» поэмасының эчтәлеген сугыш һәм кешелеклелек, сугыш һәм батырлык чыганагы дип атап булыр иде. Тема яңа түгел, тема тапталган. Сентиментальлек тә үзен сиздереп-сиздереп үтә (моңлы аваз, янә моңлы аваз монологлары). Әмма шагыйрь лирик гомумиләштерү чаралары, күпертү алымнары ярдәмендә Ләйсән, Басыйр, Рәхимҗан, аларның әниләренең ышандырырлык образларын тудыра алган. Поэмада «Куанычын Самавырга салып кайнатты», «...Кызыл күмерләрдән кабынган күк,— сизмәдем дә, — алсу таң атты» (бу чагыштыру Туфанның 1920 еллар поэтикасын искә төшерә), «Ут кешегә үзе гомер бирә... Һәм үтерә үзе яндырып...», «Сары төс иңә җилләргә Сибелгәндә яфраклар. Җилпенә сыман күгемдә Яраланган канатлар», «— Ай нурыннан шәлләр бәйлә, Дөньяда ай яктысы», «— Исеңдәме искән җилләр Туздырды чәчләремне?» кебек чагыштыру-метафоралар поэмага самими рух, лирик колорит бөркиләр һәм сугыш калдырган катлаулы коллизияләрне табигый фонда ачуга хезмәт итәләр.

Рәшит Әхмәтҗанов табигатьтә илаһи матурлык үрнәкләре таба, аның һәр чагылышында әчке мәгънә, яшәү өмете, үзара килешү һәм көрәшү күрә белә:

Күлләрдән озак эзләдем —
Юк алар. Күккә менәм,
Кайтып килмиләр микән соң
Ап-ак болытлар белән?
«Алып кайт инде» дигәндәй,
Иртәнге томан аша
Аккош күзенә охшаган
Чәчәкләр саубуллаша.

*«Аккошларны эзлим»*

«Кошлар бәйрәменә чакыру» шигырен сагыштан исән калган, гөл бөртеге кадәр йөрәгендә илгә үлемсезлек алып кайткан сандугач образы бизи.

Тормыш диалектикасын, яшәү белән үлем кебек катлаулы күренешләрне табигать сурәтләре аша сынландыру юлында да шагыйрь уңышлы тәҗрибәләр ясый:

Безнең дә бит төсләр үзгәрә —
Ял кирәктер, бәлки, безгә дә.
Мин кояшка карыйм. Әйтте ул:
— Ял итәсең килсә — яфрак бул.

*«Алмалы булды җәй, алмалы»*

Шагыйрьнең метафоралары бер яктан гади, халыкчан яңгырашлы, әмма һәрвакыттагыча үзенчә, кӧтелмәгәнчә. «Сау булыгыз, кыр казлары» шигырен, мәсәлән, ике төрле метафора бизи, авторның кичерешләрен калкытып куя: «Ә аста кызыл миләшләр — йөрәк ярасы кебек»; «Кайларга гына китсәм дә, Йөрәгем илдә кала».

Туган илгә мәхәббәт хисе белән сугарылган, аның олылыгын раслаган («Барысы да тарала, югала — кала тик туган ил, туган җир») «Сорыйсың...» шигырендә «Җиремдә каеннар — ак бишек» метафорасы олы патриотик фикерле сюжетка лиризм бөрки.

Шагыйрь мәхәббәт хисенең олылыгын, илаһилыгын, кешене савыктыргыч көчен ачуга да зур көч куя. «Мин кабат туармын дөньяга», «Мин бүген дә гашыйк», «Уй диңгезенең яры юк», «Тамчы турында соңгы шигырь», «Аерылу» шигырьләре, «Мәхәббәт дисбесе» циклы жанр таләплә-

ренә җавап бирәләр, хәзерге татар поэзиясенең мәхәббәтнең төрле чагылышларын тасвирлаган уңышлы шигырьләре белән бер сафта торалар. Шагыйрь кичереш динамикасын тормышчан фонда ачып бирә белә:

Әйттеләр сиңа кешеләр:
Канаттың, дип, канатын...
Рәхмәт инде... шатлыклардан
Мине шактый елаттың.

*«Әйттеләр сиңа кешеләр...»*

Р. Әхмәтҗановтан тагын да кыюрак шигъри адымнар көтәргә мөмкинлек бар. Тематик һәм жанрлар диапозоны киңәеп, сурәтле фикерләү алымнары төрлеләнә, гражданлык пафосы тирәнәя төшсә, поэзиябез отар гына иде. Аның иҗатында заманның тиз агышлы проблемаларына «баш бирмәскә» омтылу «кирәклеге» сизелә, вакыты белән «көн кадагына» сугу, актуальлек, заманчалык җитми.

Рәшит Әхмәтҗановның бериш шигырьләре белән бәхәсләшәсе, башкарак борылыш, үзгәрәк акцент яисә йомгак күрәсе килә. «Күз яше тама» шигыренең чагыштыруы һәм нәтиҗәсе чама хисен югалту буларак кабул ителә. «Яр сөйгәннәр моңлы була...» парчасының лирик аһәңен шапырынкы дидактик нәтиҗә боза:

Илдә батыр булу әйбәт,
Матур ул.
Кая барсаң, шунда, егет,
Батыр бул.

«Яңгырлы көндә» шигырендә бер үк куплетны кабатлау күләмне арттырудан башка нәрсә бирми. «Су өсте тып-тыныч...» шигыренең мәгънәсе ачык түгел, «Юлдан бара идем...»дә декларативлык алга чыга, «Кем буярга тели мине», «Миңа кил» шигырьләрендә үз шәхесе турындагы фикерне куерту өстенлек ала. Олы гына идеяле «Сау калган» шигырендә тиешле нәтиҗә ясалмый. «Диңгездән кайттым мин бүген» әсәренең исеме җисемен ачмый (әйтергә кирәк, шигырьгә исем бирү Р. Әхмәтҗанов өчен шактый авыр проблема, шуңа күрә ул җәя эчендә ачыкламыш итеп бирелә торган сүзне дә исемгә чыгара). Иҗатында вариантлылык көчле. Бериш шигырьне укыганда, аны каядыр ишеткәндәй буласың. Ул — Р. Әхмәтҗановның элегрәк язылган шигырьләреннән алган хис булып чыга. Бу төр шигырьләр бар. Әмма алар кулъязманың гомуми дәрәҗәсенә күләгә төшерә алмыйлар. Кулъязма дөнья күрергә лаеклы дип саныйм.

*Тәлгат Галиуллин (култамгасы)*
*1985, 5 ноябрь*

# Эзләнүләр, табышлар...

Фәүзия Бәйрәмова

Кайвакыт бик үзәк өзелгән, нәрсәгәдер ышанычың җимерелә башлаган, кемнедер сагынган-моңсуланган вакытлар була. Кем белән сөйләшергә, борчуларыңны кем белән уртаклашырга белмисең. Шул чакта, Тукай язганча, «мин кулыма китап алам, аның изге сәхифәләрен актарам».

Шагыйрь Рәшит Әхмәтҗановның Татарстан китап нәшриятында быел басылып чыккан «Кавышыр көн» исемле шигырьләр җыентыгы да минем җаныма күптән көтелгән шифалы яңгыр шикелле тәэсир итте.

Рәшит Әхмәтҗанов әдәбият мәйданында йә бөтенләй күренми тора, йә шаулап-гөрләп килеп чыга. Үзенә реклама ясап йөрми ул, ләкин шагыйрьнең яшәве турында янып язган һәр шигыре сөйләп тора. Аларда хис, ихласлылык, мәгънә.

Төннәр, ай-һай, озын...
Йокламыйбыз.
Гомерлеккә, ахры, уяндык.
Шаулый урман: «Сезнең
йөрәкне,— ди,—
Күккә кояш итеп куярлык».
Төннәр — тоташ төтен.
Ә без — учак.
Җанга төрле уйлар уела.
Дөм караңгы булмасын дип
дөнья,
Йокламадык гомер буена.

Бу шигырьләрне укыгач, шәхси борчуларың кечерәеп кала, дөнья зураеп, тарихы, табигате, кешеләре белән синең каршыңнан үтә, күңелне кузгата. Кешегә шулай тәэсир итәрлек көчне шагыйрь кайдан ала соң? Аның үзенең җаны ни күреп, ни кичереп шулай тетрәнә? Бәлки, Сәгыйть Рәмиевләрдән килгән моң-уйланулардыр — кеше күңеле, аның үз-үзе белән, мохит белән мәңгелек көрәше...

Ела, кошчык,
кагын,
очын!..
Бу агачта ояң булган,
Балаң янган, сандугачым.

...Соңгы күмер!
Утлы күзләр
Булып миңа гел карыйсың...
Сандугачлар янган утта
Җылынырга ярыймы соң,
Ярыймы соң?!

Рәшит Әхмәтҗановның табигать, бигрәк тә кошлар турында әйбәт шигырьләре бар. Әкияттәге кошлар телен белгән егет кебек, ул аларның җанын аңлый, алар белән бергә сызлана, рәнҗи, хөкем итә шикелле. Ләкин мин үзем аның кошлар, табигать турындагы шигырьләрендә дә кеше язмышы күрәм. Әйтик, менә аның дүрт кенә юллык «Былбыл моңы» дигән шигыре:



**Җыелышта. Сулдан уңга: Фәүзия Бәйрәмова, Зиннур Мансуров, Әхмәт Рәшитов, Рәшит Әхмәтҗанов**

Патша булгач, читлегеңә яшер,
Тәхетеңдә тыңла! Соңыннан...
Ирек турындагы җырым
белән
Сөрәчәкмен сине мин
моннан.
Мәңгелек хыял! Мәңгелек көрәш...

Шагыйрьнең мәхәббәт турындагы шигырьләре дә төче юатулардан, акыл өйрәтүдән ерак тора. Аларда да шул ук көрәш, эзләнү, табу, югалту, туктаусыз хәрәкәт.

Дөрес, бу шигырьләр шаккатырып, чәчрәп тормыйлар, ә күпме моң, өмет һәм мәхәббәт аларда! «Төшләремә кердең каен булып», «Эзләдем», «Йөрәкләр янар, сызлар!», «Мин саргаеп сагынгач», «Уй диңгезенең яры юк», «Аерылу», «Сорашма син кара таштан», «Унөченче аем»... Шулай да бу лирик шигырьләрдә кабатланып торган чарасызлык, арыганлык мотивлары, боегу-саргаюлар бераз артыбрак китмәдеме икән? Миңа шулайрак тоелды. Ләкин һәр укучының үз зәвыгы, һәркем шигырьдән үз күңеленә тәңгәл килерлек кичерешләр эзли.

Рәшит Әхмәтҗанов шигырьләрен беренче кат укыячак кешеләрдән көнләшәм. «Күбрәк менә шундый яхшы, уйлы-гамьле шигырьләр укысагыз, дөньяда яшәве тагын да мәгънәлерәк булыр иде»,– дип әйтәсем килә.

*«Социалистик Татарстан» газетасы.– 1985. – 28 декабрь*

# Шагыйрь йөрәге — киң дөнья

Мансур Вәлиев

Кырлар буйлап куды
безне ачлык...
Качып-посып шунда
арыш удык.
Тамак туйгач,
офыкларга кадәр
Аллы-гөлле күбәләкләр кудык.

Балачагы авыр сугыш елларына туры килгән шагыйрь Рәшит Әхмәтҗанов үзенең әле яңа гына басылып чыккан «Кавышыр көн» исемле китабында әнә шулай яза. Бер караганда гап-гади дүрт юл, тыйнак кына, шулай ук гади генә сүзләр. Әмма алар истә кала, йөрәккә уела. Ни өчен шулай? Мөгаен, шуңадыр: бу шигырьдәге беренче юлдан, тәүге сүздән үк күңелгә ятышлы һәм моңлы аһәң алына, кешеләр башына килә торган олы кайгы — ачлык турында шигъри әңгәмә кузгала. Укучы күңелендә халык җырларына тартым, салмак агышлы, ләкин тирән, уйчан көй пәйда була. Шигырь әнә шул моңлы көй булып йөрәк түренә үтә.

Чоры авыр булса да, бала барыбер бала инде — әз генә тамагы туюга, ул күбәләк куарга тотына. Менә шушында инде шагыйрьнең лирик герое да үз язмышының хәлиткеч баскычын атлый, аның дөньясына искиткеч мул булып төрле-төрле табигать образлары, җан ияләре, күренешләре килеп керә. Хәзер инде, соңгы елларда, Рәшит Әхмәтҗанов шигъриятенең бөтен барлыгын диярлек табигать дөньясы тәшкил итә. Гүя шагыйрь табигать булып телгә килә алучы шундый серле бер җан — ул һәркайда бар һәм ул һәркайчан сизгер. Менә бер урында лирик герой: «Мин, тормыш, синең бер дулкының! Җыр — минем диңгездә җилкәнем!» — дип, дулкын хасиятенә керә. Ә икенче шигырендә исә, киресенчә, ул дулкыннарга болай эндәшә: «Уттан туып, уттан үлгәнегез юк шул әле сезнең». Өченче мизгелдә инде ул кыр казларын үз туганы дип белдерә: «Мин дә бит сезнең арада канат үстергән бала». Күрәбез, лирик герой дулкынга да әверелә, ут улына да әйләнә, кыр казы рәвешенә дә керә. Нәрсә бу, нинди күренеш бу? Укучы, шигырь сөюче моны ничек аңларга, ни дип кабул итәргә тиеш?

Әйе, өстән уйлаганда кискен генә алышыну кебек. Чөнки дулкынның утка, утның исә һавадагы кыр казына һичбер төрле бәйләнеше юк. Әмма аларның һәркайсын үз йөрәгенә сыйдырып, берләштереп яшәүче шагыйрь җаны үзен дулкын итеп тә, ут төсле дә, кыр казы сурәтендә дә бик иркен, табигый тоя. Ул берьюлы аларның барысы да булып яши төсле һәм төрле чакта төрле җан иясе булып, яисә табигать күренеше булып телгә генә килә сыман. Ягъни биредә без шагыйрь җанының биниһая киңлеге белән очрашабыз.

Шагыйрь үзенең эчке дөньясы белән табигать арасында бернинди аерымлык, кискен бүленеш күрми. Гүя барча табигать аның йөрәгенә сыйган да, шунда ду килеп яшәп ята. Барча күренешләр шагыйрьнең йөрәк хәлләре генә... Әнә шуңа күрә лирик герой үзенең йөрәк хәлләрен сөйләргә теләп авызын ача, ә теленә исә яңадан менә мондый сүзләр килә:

Тамчы тамар —
Ут эченнән
Барыбер ул яфрак табар.

Шигъри илһам шагыйрьнең малай чагында ук әнә шундый юллар тудырган! Кыска, ләкин чын шигърият үрнәге булган юллар! Тыгызланган никадәр хис, мәгънә, нәтиҗә анда! Шигырьдә өч кенә әйбер катыша: тамчы, ут, яфрак. Аларның өчесе дә безгә таныш, билгеле. Болай санап кына узгач, шундый шик тә туа: бу сүзләр белән инде тагын нинди яңа фикер, яңа мәгънә әйтеп булсын икән? Бигрәк тә күп кулланылган сүзләр бит. Ләкин шигъриятнең, талант көченең бөтен хикмәте дә әнә шунда шул. Ул карап торырга гап-гади тоелган туфракта безнең һушыбыз китәрдәй гүзәл гөлләр үстерә. Биредә дә шундый очрак. Иң беренче юлны «Тамчы тамар» дип укыйбыз – халкыбыз телендә борын-борыннан сөйләнеп йөргән күренешләр күз алдына килә. Тамчы бит ул – яшәү, өмет, киләчәк дигән сүз. Икенче юл – «Ут эченнән» – шулай ук якын һәм таныш сурәт. Ут ул – көрәш, газап, яну дигән сүз. Шагыйрь әнә шул ике стихияне – тамчыны һәм утны янәшә китереп куя да алардан өр-яңа поэтик мәгънә чыгара. Димәк, нинди генә авыр газаплар, көрәшләр булса да, барыбер яшәү өстен чыгачак, өмет исән калачак! Яфрак булачак!

Турыдан-туры тормыш хакында, көндәлек яшәеш турында шагыйрь чагыштырмача азрак яза, әмма берәгәйле яза. Сүзләрнең иң саллыларын, иң тәэсирлеләрен сайлап яза. Гүя Рәшит Әхмәтҗанов бу вакытта да безнең телебезнең, сүзләребезнең көчен, куәтен табигать хасиятләре янына куеп, шулар белән чагыштырып карый һәм теге яки бу сүзләрне шулай тикшергәннән соң гына ала. Сүзләрнең иң ышанычлы тоелганнарын гына, бәгырьгә, үзәккә үтәрдәйләрен генә ала. Менә мисалга берсе:

Ятим бала...
Әгәр үги ана
Чакырмаса пешкән
 ашына –
Гомер буе сабый яланаяк
Әнкәсенең йөгерә
 каршына.

Мондый юллардан соң инде бернинди дә аңлату кирәкми! Биредә безнең йөрәк берьюлы йөзгә, меңгә телгәләнә дә, түзеп, чыдап булмастай әрнү белән тилмерә, газаплана башлый. Күңелдә шул сорау гына тирбәлә – ник соң болай? Ник соң мондый шәфкатьсезлек? Кешеләр белән табигатьне янәшә куеп, чагыштырып карау, гүя укучыга дөньяның бүгенге реаль үлчәмнәрен искә төшерү өчен кирәк...

Кошлардагы матурлыкны
 кайчак
Канатсызлар күреп
 яратмыйлар.
Ә бит кошлар
 кешеләрнең кылган
Батырлыгын күктә
 кабатлыйлар.

Күрәсезме, шагыйрь биредә дә һаман үзе булып кала. Ул, тереклек ияләрен бүлгәндә, кешеләр һәм башкалар дип карамый, ә үзенчә атый – канатлылар һәм канатсызлар, дип! Аныңча, менә шушы нәрсә – канатлы булу мөһимрәк, кадерлерәк. Әйе, без, укучылар, шагыйрьне бик яхшы аңлыйбыз. Халкыбыз да канатлыларны үз тарихыннан белә һәм хәтерендә кадерләп саклый. Батырлар алар – канатлылар!

Шагыйрь иң олы, иң фәлсәфи мәгънәләрне дә туган авылда яуган яңгыр кебек итеп, яисә иртән томан таралган сыман итеп – гади һәм ягымлы, аңлаешлы һәм тәэсирле чаралар аша бирә ала, сурәтли ала.

Иле янды Гөлбикәнең,
Ире янды Гөлбикәнең...

Көл булганын онытса да,
Онытмады гөл икәнен.



**Киңәшле эш таркалмас. Казан утлары журналы редакциясе. Сулдан уңга: Рәшит Әхмәтҗанов, Мансур Вәлиев, Мәхмүт Хөсәен, Мәхмүт Хәсәнов, Рашат Низами, Флүс Латыйфи, Тәүфикъ Әйди, Җәүдәт Миңнуллин, Рәдиф Гаташ, Кояш Тимбикова, Нажар Нәҗми, Ренат Харис**

Бер үк сүзләр генә кабатланып тора шикелле. Ә сүз арасындагы фикер һавага хәтле моң белән, тәэсир белән тулган. Чөнки шигырь төбендә, нигезендә шагыйрь йөрәге ята. Алдарак без танышып үткән киң колачлы һәм сизгер йөрәк ята анда.

Рәшит Әхмәтҗанов шигырендәге һәр юл, һәр сүз халкыбызның күңеленә меңнәрчә еллар буена туплана килгән, җыйнала килгән моң диңгезенә тоташкан, ялганган була. Шагыйрьнең һәр сүзе, шигырендәге һәр ымы кеше күңелендә яшәүче әнә шул диңгезне хәрәкәткә китерә. Һәр сүз әнә шул диңгез хәтле хисне, моңны, тәэсирне кузгата. Тәэсир көченең төп сере, сәбәбе менә нидә! Тамырыңның китүендә!

Табигатьтән, аның мәңгелек гүзәллегеннән, ныклыгыннан, яшәүчәнлегеннән килгән әнә шундый асыл сыйфатлар шагыйрь иҗатын бүген олы мәртәбәгә – халыкчанлыкка алып килгәннәр. Аның җыры рухы белән дә, рәвеше, яңгырашы белән дә халык күңеленнән ургылып чыккан моң булып ишетелә. Шигырьләрдәге лирик герой – без тансыклаган шәхес, үзен табигать баласы дип санаучы сизгер җан. Укучы каршында ул заманыбызның гүзәл кешесе булып гәүдәләнә. Шагыйрь үзе дә, аңа карап:

Дөнья дип атала, дустым,  
Син басып торган урын! –

ди.

Әйе, дөрес. Дөньяның үзәге әнә шул. Сизгер җанлы, киң күңелле кешеләр бүген дөньяның үзәген тәшкил итәләр.

Яңа китапны укып чыккач, авторга кайбер теләкләр дә туа. Мәсәлән, вакыт-вакыт әсәрләрдә фикер йөртү артык гомуми планга күчә, нәрсә хакында сүз баруы ачыкланып җитми. Шигырьләрдә еш кына очрый торган «дошманнар» сүзе дә әнә шундыйрак тәэсир калдыра. Кыскасы, үзенең мәхәббәте һәм нәфрәте адресын әле тагын да ачыклыйсы бар төсле шагыйрьгә. Ул чагында сәнгатьчәлек тә, тормышчанлык та яңа бер биеклек яулаячак. Иҗатта өр-яңа уңышлар киләчәк.

*«Социалистик Татарстан» газетасы.– 1985*

# Рәшит Әхмәтҗановның «Бишташ» поэмасы турында[1]

Марсель Галиев

Рәшит Әхмәтҗанов поэма жанрына озаклап, ашыкмыйча, бик нык әзерлек белән килде. Моңа кадәр язып караганнары — бу яңа поэма «Бишташ» каршында әнә шул газаплы эзләнүнең бер чагылышы булгандыр.

Әсәрнең исеме үк уңышлы. «Бишташ» — халыкның борынгыдан килгән хикмәтле уены. Һәм шул биш ташны шагыйрь бер йодрыкка сыйдыра алган. Арадан бер ташы гына бармак арасыннан күренеп тора — анысы алтынчы таш, кемдер тәрәзәгә аткан мәкерле таш...

Ташка табыну күп халыкларга хас. Японнардагы ташлар бакчасын гына искә төшерик. Бездә дә «нигез ташы» дигән хикмәтле сүз бар. Гомумән, табигатьтә, ташлар каршында адәм баласы, үзе дә сизмичә, сүзсез кала. Әйтерсең ташларның җаны бар. Син аны өнсез калып тыңлыйсың. Галәмнең яралышына шаһит булган ташларга җирнең дә, кешелекнең дә бөтен тарихы сыйган. Аны ишетә, тоя, сизә белү һәркемгә бирелмәгәндер.

Рәшит Әхмәтҗанов бу поэмасында ташлар белән җан телендә сөйләшә. Гадәти хикәяләү, проза элементларына төшәргә бөтен мөмкинлекләр бар югыйсә: әсәрнең үзәгендә — Әлмәттә йортлар салучы ташчы егет. Яңа шәһәр салынуга багышлап, сокланулы, купайтулы, вакытлы шаукымга ияреп, күпме әсәрләр язылмагандыр, Рәшит Әхмәтҗановның бу поэмасы — бөтенләй башка. Ул ташчы — төзүче чагында кайнаган хисләренең шагыйрь дәрәҗәсенә җитеп олыгаюын көтә белгән. Һәм шушы сабырлык, вакытлы хисләрне җиңү аны, лирикасына хилафлык китермәгән хәлдә, фәлсәфи фикерле тыгыз әсәр язуга китергән.

Үзәк герой — ташчы — кешеләргә оя кора, аның кулында кешене җылытучы таш. Ә шагыйрь күңелендә — тарих. Ул, җылы таш рухын аңлап, дәверләр буйлап сәяхәт итә. Таш — дуска, дошманга ыргытыласы корал да, кабергә куеласы истәлек тә, бизәнү әйбере дә. Кеше кулында таш көчле дә, көчсез дә икән әле.

Лирик геройның хезмәте, фикерләве, рухы, мөнәсәбәте поэманың буеннан-буена үзен сиздереп бара. Сюжет һәм композиция камиллеге — тышкы форма белән әсәрнең эчке хасияте төгәл гармониядә булудан килә. Аерым бүлекләрдә ритмиканың үзгәрүе хисләрне яңарта, күңелне талчыктырмый.

Кыскасы, Рәшит Әхмәтҗанов (үз иҗаты мөмкинлегеннән генә карамыйк) — бу әсәре белән татар шигъриятенең поэма арсеналына яңа бер бизәк өсти. Әйбәт әсәргә киң күңеллелек, хуплау кирәк.

Бу поэма югары шигъри куәт белән язылган. Телнең тәмен белеп, игътибарлы укуны сорый. Сәләтле укучы аны аңлап яратыр дип уйлыйм.

*Марсель Галиев (култамгасы)*
*1986, 2 октябрь*

[1] Кулъязма Р. Әхмәтҗановның шәхси архивыннан алынды.— *Төз.*

# Йөрәк бәйрәме

*(Шагыйрь Рәшит Әхмәтҗанов турында этюдлар)*

Зиннур Мансуров

Туган көнемнән үк бәхет биреп,
Азат балам диеп атадың.
Авыр чакларында Кол Гали күк
Колың булыйм, газиз Ватаным.

Алма сортлау җайланмасына карап торам. Тегермән ташыдай әйләнмәле әрҗәгә эрелеваклы бакча җимешләре коела. Энә төртер урын юк. «Спортлото» шарлары кайнаша шикелле. Җиде юл чатындагы алмаларны алда нинди рәк язмыш көтә? Хәер... Бире дә һәркайсы үз бәһасен үзе билгели. Югары сыйфатлы алма әнә беренче юлдан китеп бара. Җиз иләктән үтмәгәннәрен икенче юл бөтереп ала. «Өчле» билгесенә лаек булганнары да шактый...



**Беренче рәттә: Рәшит Әхмәтҗанов, Зиннур Мансуров**

Алмалар этешә-төртешә юл сайлаганда, ничектер шагыйрьләр язмышы турында уйлана башладым. Югыйсә шигырь белән алма арасында уртаклык та күренми шикелле. Күзәтәм һәм уйланам. Үзенә күрә ОТК вазифасын да үтәүче житез хәрәкәтле апа әледән-әле беренчеләр рәтенә ялгышып керүче «әрсез» алмаларны өченче конвейерга күчерә. Чынлыкта «Ньютон алмасы» була торып, үз бәһасен белмәүче «тыйнагы» да очраштыра. Гадел хөкемдар аныcын да үз урынына куя. Уртачалар юлындагы тыгылуны да җайга салырга ашыга...

Барыннан да бигрәк мине «стандарт булмаган» алмалар төркеме уйландырды. Бөтенләй аерым урында торган шушы алмалар белән чын шагыйрьләр арасында ниндидер уртаклык күренә. Стандартсыз, димәк, үзенчәлекле. Талантларның үзьяшәешлелеген калыплашуга бирелмәү билгеләмиме? Мәгълүм хакыйкатьне кабатлап әйтик: сәнгать – шәхси тормыш тәҗрибәсе, дөньяны тулысынча индивидуаль рәвештә танып-белү нәтиҗәсе. Производствоны, әйтик, стандартлаштырып була, ә иҗатны...

Алмадан башланып киткән әлеге этюдларда мин, күпләрнең билгеләвенчә, стандартлыкка сыймаганлыгы күзгә бәрелеп торган шагыйрь Рәшит Әхмәтҗанов турындагы күзәтү-уйлануларым белән уртаклашырга телим. Мондый аерым төркемгә аны нинди сыйфатлар керткән? Шагыйрьнең сирәк очрый торган үзенчәлекләре нидән гыйбарәт? Бергәләп ачыклыйк.

***

Бишкә кадәр һәрбер бала падиша булыр... Борынгылар сүзен җөпләмичә булмый, әмма падиша булу һәркемгә дә тәтемәгән. Бигрәк тә кырык беренче елгыларга... «Без барлык газапның

тәмен имдек ана сөтендә...» Газизанә баштан кичереп язылган әлеге сүзләр астына шагыйрьнең барлык яшьтәшләре кул куярга ризадыр.

Карт дөньяның иң яшь кисәге
Безнең маңгай үзе иде бит.
Сугышларга чапкан атларның
Тояклары аңа тиде бит.

Адәм баласы, гадәттә, өч яшьтә генә үзен үзе ача башлый, ә аңарчы хәтта көзгедәге сурәтен дә юньләп танымый икән. Мәхшәр көнне сабыйларның чәче агарыр дигәндәй, сугыш өрәге белән күзгә-күз очрашу еларга өлгермәгән малайларны да ирсетә. Кешелек җәмгыяте үсешендәге мәгълүм бер баскычны сикереп үткән шикелле, кырык беренче елгыларның шактыена сабый чакны «әйләнебрәк» узарга туры килгәндер. Көтүгә беренче мәртәбә әндри әбәте илткәндә, Рәшит әле үзе дә төенчек чаклы гына булган. Борыныннан шаулап аккан канга (алабута күмәче гаепле) сәерсенүле күзләре белән исе-акылы китеп караганда, тәүге тапкыр әнә шулай «канын койган» чакта да ул әле кечек падиша яшеннән узмаган. «Гел хәтердә... Беркөн Ачытауның яшеннәрдә янды кылганы...» Авылга таба йөгерүче утлы кылганнар өстенә бөтен чандыр гәүдәсе белән егылуы һаман истә, чөнки балачак илендәге шушы «утлы амбразура»га барысын да аңлаптөшенеп ташланган. Гарасатлы сугыш кырыннан кайткан әлеге кылганнар шагыйрь тәнен хәзер дә өтеп-өтеп ала шикелле.

Ә җанымда — тоташ күкрәүләр...

Хәтер чаңы уяу. Күңелдәге балачак хатирәләре һәрдаим яңарып торалар, чөнки алар сөт белән генә түгел, кан-яшь белән дә язылган. «Сугыш елы» хроникасы күз алдыннан үтә. Гадәти бер төш вакыты. Үзен үзе бик иртә белештерә башлаган сабый хәтеренә бүгенге тормыш рәхәтлекләре дә юып ала алмаслык тирәнлектә уелган.

Әнкәй кайта кояш баткач кына,
Төнлә генә туктый кырда эш.
Кояш гүя, ач энемне җәлләп,
Төш вакытында баерга тиеш.

Сугыш елы баласы икмәккә, шагыйрь булып танылгач, дөньяда беркемне дә кабатламыйча, үзенчә билгеләмә бирә. Бугазда яшен ташы булып торучы хатирә:

Тышта буран. Инсаф бабай үлә...
Мин тын гына аны озатам.
Соңгы сүзе:
— Мин ипигә барам,
Сез көтегез, балам, тиз кайтам...

«Өлкәннәрнең барысы да башта бала булганнар. (Әмма моны һәркем дә хәтердә тотмый)». Гомер буе үзен балачак илчесе итеп санаган Антуан де Сент-Экзюпери хаклыдыр, әмма сугыш чорына туры килгән балачак беркайчан да онытылмый. «Мин балачагымнан килгән көтүче егет булам...» Әгәр үзенең авыр балачагына кайтырга теләмәсә, Рәшит Әхмәтҗанов шагыйрь була алыр идеме? Шигырьләрнең барысын да безгә, гомумән, балачак әйтеп яздыра шикелле. Иҗатыбыз гомер башында яралган күңел катламнарын актарудан гыйбарәт түгелме? «Сабыйлар күк елмаерга көчем булырга тиеш»,— дип, дөньяга һаман да балаларча беркатлылык белән карыйбыз, балачакта барлыкка килгән рухи плацдармга таянып торабыз.

Балачагында җылыткан кояш
Җылыта икән гомер буена.
..................................
Барлык картайганнар
Үз яшьлеген
Сагынудан үлә, күрәсең...

Әдип үзенең әсәрен «биография» атлы каләм белән яза. Аксиомага әверелгән әлеге хакыйкатьне без теләсә кайчан кабатларга яратабыз. Халыкныкын кушып, биографиябезне зурайтабыз. Барысы да дөрес. Инкяр итеп булмый. Әмма... Тәрҗемәи хәлнең балигъ булганнан соңгы чоры турында күбрәк сөйлибез. Кайчандыр бала булганлыгыбыз онытыла. Биография балачактан башлана. Талант үзәгендәге субъектив натура да... «Мин үземнең балачагымны «яралы балачак» дип әйтер идем...» Әгәренки үсмер чоры сугыш елларына туры килгән прозаик Вакыйф Нуруллин гомум әдәби геройлар галереясына керүче гыйбрәтле язмышлар тудыра алган икән, ул «ниләр күргәнне, ниләр кичергәнне сөйләп кенә бетерә алмаслык» гомер башлангычына, йөрәген сызланулы итеп калдырган «яралы балачак»ка шактый дәрәҗәдә бурычлы. Әдипнең сүзне гомер юлына керүдән башлавы урынлы. Шулай да соңыннан «Балачакның яраланмавын телим» дип әйтеп куюы белән килешәсе килми. Балачак гыйбрәтле булсын, берүк, идиллик булмасын. Күпме «какканны вә сукканны» күтәргән бөек Ятим дә үзенең сабый вакытын күз яше белән сагынып искә төшергән, зуп-зур Тукайның кечкенә Апуш чагын «ачы-тәмле хыял» итеп күргән.

Җәмгыятькә файдалылык һәм шулай ук җитештерүчәнлек ягыннан караганда, әйе, кул арасына керергә өлгермәгән балачак тау-тау матди байлыклар тудырмый. Әмма балачак илендә тупланган рухи хәзинә бөтен гомергә җитә!

Бишкә кадәр һәрбер бала падиша булыр, дигән борынгылар, ә ир уртасы Рәшит Әхмәтҗанов үзенең балачагын «шикәр биреп» сөендерергә тели. Иркәләнү һәм назга коену, тамак туклыгы һәм өс бөтенлеге җәһәтеннән падиша булмаса да, сугыш елларында чыныккан гыйбрәтле балачак киләчәктә шагыйрь иҗатын баетырлык кыйммәтле рухи байлыкларны күпләп җитештерергә өлгергән.

Күзендә яшь, күнелендә моңнар —
Балачагың синнән карап тора...

***

Кандыз елгасы. Җиденчеме тапкыр коенып чыккан Рәшит зәңгәрсу какча гәүдәсен кояшта кыздыра. Рәхәт! Кинәт комлыкны сары кырмыска күче сырып алды. Эреләр! Кармакны җимләп, балык каптырырлык. Күченүләреме?! Комлыкта кара болыт күләгәсе шуыша шикелле... Көтү башы аларны кая алып бара?

Иртәгесен, көтүгә әбәт илтер алдыннан, Рәшит таллыкта үзе генә белгән кош оясын карап килергә ниятләде. Борынлап кына чыккан бәгырькәйләре үзләрен ничек хис итәләр? Үрелеп караса! Йөрәге жу итте — оя тулы кырмыска. Кошчыкларны ашап бетерә язганнар!

Көтелмәгән шушы вакыйга аны тәмам әсәрләндерде. Гомерендә беренче тапкыр ул үзен битарафлыкта гаепләде, чөнки яманлык кылучыларның юлына аркылы чыга алмады. Шушы тойгы күңел катламнары астыннан әле хәзер дә саркып чыга. Төзәлмәс яра каны шикелле...

Этиканың төп категорияләреннән саналучы яхшылык һәм яманлыкның шагыйрь иҗатындагы яшәеше гыйбрәтле әкияти вакыйга буларак күңелдә уелып калган шушы фаҗигадән башланмыймы? Яхшылык һәм яманлык... Әлеге төшенчәләрнең диалектик концепциясе Рәшит Әхмәтҗанов әсәрләрендә шактый ачык төсмерләнә, һәм, гомумән, шәхестәге көрәшчәнлек сыйфатлары нәкъ менә шушы җирлектән баш төртә:

Бәхетләрдән
Дөньягызны онытмагыз.
Изгелекнең
Дошманы бар — бигрәк явыз!

«Йөрәк авырулы» шагыйрь, гомумән, битараф була алмый. Шигърият беркайчан да нейтраль дәүләт шикелле яшәмәгән, һәм ул борынгы заманнарда ук Данте авызыннан әйттереп искәрткән: җәһәннәмдә дә иң кызу урыннар, имеш, бөек мораль сынаулар вакытында битарафлык күрсәткәннәргә билгеләнгән. Шигърият каршылыклы, фаҗигале һәм бөек гасырда яшәүче Рә-



**Татарстан язучылары съездыннан соң. Сулдан уңга: Җәүдәт Миңнуллин, Рәшит Әхмәтҗанов, Зиннур Мансуров, Равил Фәйзуллин**

шит Әхмәтҗановтан да гамьсезлекнең көрәшчене үтерүен халык алдында инде ничәнче тапкыр кабатлата. Эчтәлек сораучы таләпчән укытучы төсле, шагыйрьне «үз сүзләре» белән сөйләттерә.

Изгелекнең дошманы белән көрәшү мотивы, шагыйрьнең поэтик предметы буларак, бөтен иҗаты аша калку рәвештә үткәрелә. Көрәш мәйданын ул үзенчә сайлый. Гыйсъянчыдай чәчрәп чыкмый – шагыйрьләрнең «эчке янулы»сы. Көрәш булмаган җирдә әдәбиятның кирәге юклыгын тирәнтен аңлаган хәлдә кешелекнең алга барышына ярдәм итүче кешелеклелек өчен рухи алышны үзәккәрәк чыгара.

Дөньяның караңгы ягына
Барыбер төшкәндер бер нурым.
Хәтта мин агулы еланга
Эндәштем: саумы, дип, матурым...

Әлеге юлларда шагыйрьнең яшәү-көрәшү принцибы ачыла. Шагыйранә гражданлык кодексы борынгылар этикасы таләпләрен сызып ташламый – яхшылыкка яхшылык һәр кешенең эшедер, яманлыкка яхшылык ир кешенең эшедер. Яманлыкка – яхшылык... Мондый мөнәсәбәт яманлыкка карата килешмәүчән булырга чакырган этика таләпләренә туры киләме? Яманлыкка яхшылык белән суктыру көрәш тактикасы гына түгелме? Таш атканга аш ату... Барысы да халык этикасыннан. Агулы еланга да «матурым» дип эндәшүче шагыйрь менә шундый көрәш алымын сайлый. Шунысы гаять әһәмиятле: әлеге сыйфат аңа ана сөте белән кергән, ягъни тумыштан

килгән һәм, әлбәттә, балачакта ныгып зураюга ирешкән. Синнән гомер буе балачагың карап тора икән, димәк, ул үзенең эчкерсезлеген югалтмыйча уяу саклый. Яхшылык нәкъ менә шушы нигез сыйфаттан ярала. Әсәрләрдәге көрәш мотивының үзенчәлеге дә шәхес күңелендә тамырланган яхшылык башлангычыннан киләдер. Казаныңа нәрсә салсаң, чүмечеңә шул эләгә...

Үз җиремә иңсен минем игелегем,–
Изгелеге кадерләде бу башымны.
Шул изгелек тотып калды, дөнья, синең
Минем башка бәргән чакта ташларыңны.

Дөньяда яхшы кешеләр бетмәгән... Шагыйрь борынгылар этикасы кануннарына таяна, үзе дә рәхимҗаннар сафында атларга омтыла. Күңеленә игелеклелек оялаган, һәрбер гамәлендә Хозыр Ильяслык сизелеп тора, өр-яңа чалбарын дустына биреп киткән Такташны хәтерләтүче адымнары да шактый. Стиль – кеше. Язу рәвешен ничек кенә аңлатма, асылы барыбер шәхескә кайтып кала. «Үзең яшәгәнчә яз»... Шигърият фәненең беренче кагыйдәсен Рәшит Әхмәтҗанов йөрәк канына сеңдереп үзләштергән. Шагыйрьнең тормышы белән иҗаты арасында каршылык сизелми. Шулай булуы кыйммәт. Лирик «мин»енең прототибы була алмаучылар әдәбият дөньясында болай да шактый.

Стиль – кеше... Язарга өйрәнгәндә үк калыплашкан почеркта да кешенең холык-фигыле ачык чагыла. Кардиограмма йөрәкнең ничек эшләгәнен күрсәтә. Шушы уңайдан Социалистик Хезмәт Герое Рәшит Саттаровның тормыштагы шәхес белән иҗаттагы шәхес игезәклеген аңларга ярдәм итүче кызыклы күзәтүләренә мөрәҗәгать итик. «Еш кына мин аның эшләгәнен күзәтә идем,– дип яза атаклы төзүче.– Стенаның тышкы ягына салыр өчен бер өем кирпеч арасыннан үзенә ошаганын эзләп ала иде ул. Кайчакларда цементлап салган кирпечне ераккарак барып карый да, нидер килештермичә, кабат алыштырып куя. «Нигә алай итәсең?» – дип сорагач, ул: «Бусы матуррак,– ди.– Кешеләр, караганда, чыраен сытарлык булмасын».

Рәшит салган кирпечләр арасыннан бервакытта да цемент бүлтәеп тормый, аның кирпечләре бер-беренә шундый тигез яталар, аларның җөен дә күрмисең. Ул, эшен төгәлләгәч, йортның стенасына озак кына карап, хезмәттән ләззәтләнеп тора иде. Кайчакларда мин аның эшләгән вакытында авыз эченнән генә нидер көйләгәнен дә ишетә идем. Ул җырлап эшли...»

Ташчы егетнең хезмәткә карашын ачып күрсәтүче әлеге күзәтүләрдә кешеләргә игелеклелек кылу омтылышы гына түгел, шагыйрьнең иҗатка мөнәсәбәте һәм бигрәк тә сүз белән эш итү рәвеше күзалланырлык булып чагыла. Индивидуаль шигъри морфология үзенчәлекләренә соңрак тукталырбыз, ә хәзер сүзебезне иҗатның тирәндәге агымын ачу юнәлешендәрәк дәвам иттерик.

Үзлегеннән аталану... Биологиядә шундый төшенчә барын беләсездер. «Үзенең тәпиен суыручы аю»ны хәтерләткән шагыйрьләр булгаласа да, тулаем поэтик кыйммәтләр үзеннән-үзе генә яралмый. Шагыйрьнең күңел тамырлары – милли тарих тирәнлегендә. Халкыбыз культурасы шәхеснең яшәешенә, поэтик язмышның эчке нигезенә әверелгән, һаман саен үсә баручы иҗат өскормасының ныклы нигезе булмаса, әйтик, Хәсән Туфан яшь каләмдәшенә биреп калдырган фатихасында мондый нәтиҗәләр ясар идеме: «Үз кичерешләрен генә түгел, халык йөрәгендәге кичерешләрне дә чын шигырь югарылыгына күтәреп... бирә ала...»

Әсәрләрнең идея-эстетик асылын билгеләүче рухи культура, әйе, шәхеснең яшәү рәвешенә аерылгысыз төстә бәйләнгән. Мондый бәйләнеш Рәшит Әхмәтҗанов язмышында ачыграк сизелә. «Барысын да кешеләргә бирим, нәрсә бар бу җанда – һәммәсен». Шагыйрь ап-ак кәгазьгә күңелдәгесен генә түгә, кешеләрне гаҗәпләндерергә тырышкан күз буучы шамакайдай, авызыннан көтмәгәндә йомырка чыгарып азапланмый. Күңеленең «культуралы катлам»ында һәркемне дә сокландырырлык табышлар болай да җитәрлек, һәм шунысы кыйммәт: шагыйрьнең философик культурасы китап укуга гына нигезләнмәгән, ә гомер тәҗрибәсенең катлам-катлам утырымнарыннан күтәрелгән.

Мин яшенне юкка гына
Җанга яшердеммени!

Җанга яшерү... Шагыйрь барысын да яшереп бетерә алмый. Табигате шундыйдыр: эчендәге — тышында... Дөньяга сабыйларча беркатлылык белән карау кайчак үзенә дә өстәмә кыенлыклар китерә. Балалар самимилеге белән яшәр өчен, әйе, әлегә дөньясы көйләнеп бетмәгән.

Таш өстендә гөлләр...
Гөл өстенә
Соңгы йотым суны коясың,
Һәм актарып ташны,
таш астыннан
Тапканым бар елан оясын.

Шагыйрь иҗатының үзәгенә куелган проблемалардан берсе — яхшылык һәм яманлык концепциясе чагылышына гына тукталыйк. Гомуми күзәтүләрдән чыгып караганда, яманлык категориясе тулаем иҗат җирлегендә тарихи тәрәккыяткә мөнәсәбәттә бирелә. Кешелекнең алга баруына комачаулык итүче көчләр, аерым алганда социалистик җәмгыятькә каршы күренешләр, яманлык итеп бәяләнә. Көрәш кырының әсәрләрдән аңлашылган гомуми манзарасы шундый. Яхшылык һәм яманлык концепциясенең шагыйрь иҗатында чагылышын тагын да төгәлрәк күрсәтеп буламы? Өстәмә шәрехләүләр, әлбәттә, кертергә мөмкиндер. Шулай да сурәт томанлырак килеп чыга. Сәбәбе? Барысы да һөҗүм юнәлешен билгеләүдә аныклык җитмәүдән киләдер. Шагыйрьнең кемгә каршы көрәшүе кайчак тоныграк күзаллана. Ачыклагычта тиешенчә тотылмаган фоторәсем шикелле.

Кагылулар, сугылулар булса,
Дошманнарга каршы чыгарбыз...

Аныксызлыктан килеп чыга торган гомумилек, әйе, әсәрләрдәге вакыт тибешен төгәл тоярга комачаулый. Шагыйрь кайчак замана елъязмачысы булудан тайпыла. Яшәгән еллары да билгеле булмаган борынгы әдипнең иҗат үрнәкләрен өйрәнгәндәгечә, кайвакыт китап бите читенә шундый сорау язу теләге уяна: әсәр кайсы чорга карый? Киләчәк «заман мөһере» булган канатлы сүзләрне генә кабул итәдер.

«Изгелекнең дошманы бар — бигрәк явыз!» Шагыйрьнең әлеге искәртүе, җырның кабатланулы кушымтасы төсле, төрле авазларда яңгырый. Яхшылык онытыла, яманлык онытылмый. Каршылыклы дөньясында әледән-әле кабатланып торучы яманлык күренешләре канат җилпергә дә өлгермичә корбан булган балачак кошчыкларын һәрдаим хәтердә җанландыра. Алай гына да түгел... Астыртын көлүче кырыс язмыш шундый ук хәлне, берничә дистә еллар үткәч, яңадан залимнарча кабатлый. Искитмәле кабатлану!

...Әле уянып та җитмәгән дача тәрәзәсенә кемдер берничә тапкыр чиертеп үтте... Болдырга чыккач, барысы да аңлашылды — тәрәзәгә ужым чыпчыгы шакыган! Томшыгы белән тукылдаткан... Чү! Очышында гасабилану сизелә. Якындагы җиләк түтәле өстендә бөтерелә башлавы исә сагаеп калган күңелне тәмам тәшвишләндерде. Оясына куркыныч яныйдыр! Җиләк яфракларын аралап карарга иелүе булды һәм кинәт утка пешкән төсле читкә тайпылып куйды. Ояны ниндидер елан урап алган! Тагын соңга калды. Кошчыкларны явызлык авызыннан тартып алырга янәдән соңгарды. Уяулык җитмәде. Инде ничәнче тапкыр!

Кошчыклар фаҗигасенең кабатлануы ниндидер табигый очраклылыкмы? Зиһен төшенеп җитми. Кабатлану... Яра өстенә яра. Балачакның битарафлыкта гаепләп җәзалавымы? Яхшылык эшләргә соңаруның җинаять булуын искәртәме? Кошкайлар үлеме шуны аңлатамы? Ап-ачы хакыйкатьне бәгырьгә уеп төшендерер өчен нигә әле кошлар җаны кирәк булды?

Кошлардагы матурлыкны кайчак
Канатсызлар күреп яратмыйлар.
Ә бит кошлар кешеләрнең кылган
Батырлыгын күктә кабатлыйлар.

Хаклык, яхшылык, матурлык... Теләсә кайсы сәнгать әсәре, гадәттә, шундый категорияләрдән чыгып бәяләнә. Шагыйрь иҗатының кайбер үзенчәлекләрен «яхшылык рентгены» инде азмы-

күпме ачып күрсәтте. Игътибарны хаклык һәм матурлык гәүдәләнешенә юнәлтик, шигъри морфология табигатен ачыкларга тырышыйк. Күзәтүне нидән башларга? Мәсьәләгә урау юлларсыз гына якын килү өчен Ибраһим Нуруллинның мондый сүзләрдән башланган мәкаләсен искә төшерик: «Поэзиябездә үзен сиздерә башлаган бер тенденция — үтә катлауландырып язу, ассоциативлык белән кирәгеннән артык мавыгу, форма оригинальлегe артыннан куу күңелне күптән кытыклап килә иде. Рәшит Әхмәтҗановның «Ак канатлар» исемле җыентыгы чыккач... кулга каләм алырга булдым». «Аңлаешлы» һәм «аңлаешсыз» шигырьләр турындагы күзәтүендә тәнкыйтьче, шагыйребезнең «табышмакчылыкка шактый өлеш кертүен билгеләп, күп кенә шигъри мисалларга карата мондыйрак фикерен белдерә: «Йә, укучым, берәр нәрсә аңладыңмы? Ни әйтергә теләде шагыйрь? Мин, оятыма каршы, берни аңлый алмадым».

Сүзегезне ефәк белән бүләм, Ибраһим ага, әмма фикерегезне тулаем инкяр итәргә җыенмыйм. Шулай да кешедәге кешелеклелекне яклаучы адвокат шикелле, шагыйрьдәге шагыйрьлекне булдыра алганча яклап чыгарга уйлыйм. Кискенрәк яңгыраучы әлеге чыгышыгызда «тагылган гаеп», минемчә, объективлык ягыннан бик үк ышандырырлык нигезгә таянмаган. Бәяләмәләрдә тәнкыйтьнең кайчак яхшыны да, начарны да чамасыз зурайтып күрсәтүе, барыннан да бигрәк, аерым дулкыннарны гына кабул итүче радиоалгыч төсле, рецензентның ничектер шәхси зәвыкка ныграк ышануы, хөкемдар карашларына туры килмәү аркасында гына теге яки бу әсәрнең «аңлаешсыз»лар төркеменә кертелүе сиздертә шикелле. «Аңлаешсыз»лыкта гаепләүче дәлилләргә тукталыйк.

...Тайгада учак яккан юлчылар, үзләре дә сизмәстән, шундый җинаять эшләп ташлыйлар: яндырылган агач ябалдашында сандугач оясы булган... «Учак» шигырен автор болай төгәлли:

Сандугачлар янган утта
Җылынырга ярыймы соң?!

Тәнкыйтьче әлеге юлларга карата үзенең мондый дәгъвасын белдерә: «Сандугач дигәндә, бөек шагыйрьләр күздә тотыла дип уйлыйк. Пушкин, Лермонтов, Байрон, Петефи, Тукай h.б. янып үлмәделәрмени? Без алар янган утта җылынмыйбызмыни? Шагыйрь югарыдагы ике юлның мәгънәсе белән кызыксынып тормаган...»

Әсәрнең идея чишелешен күп кенә очракта апофеоз-бетемдә белдерүче шагыйрь бу юлы «шартлатып әйтелгән» соңгы сүзнең мәгънәсе белән кызыксынып тормаган. Шулаймы? Шигырьдә үткәрелгән фикер, минемчә, шактый уңышлы төйнәлгән. Шулай да соңгы ике юлга нинди мәгънә салынган икән? Ачыклап карыйк. Барыннан да элек шуны әйтик: әсәрдәге үзәк фикер ачыктан-ачык көрәш мотивларына түгел, ә кешелеклелекне билгеләүче әхлакый башлангычка нигезләнгән. Шагыйрь сандугач һәм юлчы йөзендә үзара килешә алмаслык дошманнарны күрсәтергә омтылмый. Учак ягып җылынырга теләгән юлчылар, юк, Мөҗәйләрне крематорийда яндырган тираннар түгел. Зөлфәткә кушылып әйткәндә, «сугыша белми былбыл»... Юлчыларның гамьсезлеге аркасында очраклы төстә һәлак булган сандугач балалары «сугыша белгән былбыл һәм җырлый белгән бөркет»кә яки Данкога охшаш Мусалар сурәтендә түгел, ә көндәлек тормышта кылган гамәлләребезнең яхшысын-яманын билгеләп торучы матурлык фәрештәсе, әхлакый яхшылык символы рәвешендә күзаллана. Шунысына игътибар итегез: тайгада учак ягучылар сандугач балаларын вәхшиләрчә күрә торып яндырмыйлар һәм, бәхеткә каршы, саксызлыклары аркасында килеп чыккан күңелсезлек өчен һәммәсе дә вөҗдан газабы кичерәләр.

Ачынулы уйлар белән янучы мондый кешеләр (ирексездән браконьерлар) Галилейларны утка аткан инквизиторларга берничек тә бәйләнми. Күңелдә янәшәлек ассоциациясе дә тумый. Барысы да аңлаешлы. Без атаклы «Гали белән Кәҗә» шигыреннән ниндидер сыйнфый каршылыклар эзләп азапланмыйбыз ич. Шагыйрь тарафыннан шактый аник ният белән язылган «Учак» әсәренең дә тематик чишелешен башкача интерпретацияләп маташмаска кирәктер. Универсаль подтекстлар бирелмәгән. Ике төрле уйларга нигез юк. Шигырь уяу булырга чакыра. Сандугачлар янган утта гамьсез рәхәтлеккә бирелеп җылынсак, җылы яратучы елан төсле, сөякләребезгә җылы эзләп кенә йөри башласак... Гамьсезлек утында җылынырга ярамый! Кемнеңдер михнәте

бәрабәренә табылган рәхәтлектә җаныбыз йокымсыраса, сандугач балалары янудан да зуррак фаҗига булуы ихтимал. Шагыйрь әнә шул хакта искәртә.

Яшерен сөйсәң дә, сөюне
Ай күрә, кояш ала.
Ала да давылга бирә,
Давыл дәрьяга сала.

Шагыйрьнең күп кенә әсәрләрен табышмакка чыгарган тәнкыйтьче, аңлаешсызлыкка янәдән мисал китереп, тулаем шигырьгә карата тагын катгый хөкемен чыгара: «...мәгънә – ноль». Әлеге шигъри юлларда мәгънә чынлап та юкмы? Моңа ышанасы килми. Яшерен сөюнең дә тора-бара бөтен миргә «фаш булу»ын халыкчан яңгыраштa әйтеп бирә алган шагыйрьнең әлеге әсәргә салган уй-ниятен барлык нечкәлекләре, мәгънәви төсмерләре белән аңлатып бирергә теләмим. Шигырь фәнни хезмәт түгел – ахырда резюме язып булмый. Анысын һәрбер укучы үзенчә чыгара.

Нәрсә әйтергә теләде шагыйрь? Күпчелек очракта шигъри юллардан шундый сорауга җавап эзләнә. Югыйсә үзебезгә дә еш ишетергә туры килә: фикер әйтер өчен генә шигырь язмыйлар. Нәрсә әйтергә теләде? Мондый сораулар белән генә әсәрнең идея-эмоциональ тирәнлеген ачып булмый. Табигате буенча үзендә серлелек элементын яшергән нәзберек поэзияне маңгайга бәреп әйтелгән куркытулы сораулар ничектер чикли шикелле. Сораулар серлелекне үтерәләр. Маяковскийча әйткәндә, «Поэзия ул – баштанаяк! – беленмәгән якка юл алу». «Җырлады кыз чиркәү хорында...» исемле шигырендә Александр Блок нинди уй-ниятен ирештерергә теләгән? Күпме аңларга тырышма – ахырынача төшенеп булмый. Серлелеген тирән яшергән әлеге шигырьне дә мәгънәви яктан нольгә чыгарыйкмы? «Оятыма каршы, берни аңлый алмадым» дисәк, дөресрәк буладыр.

Үзебез шагыйрьләрнең «яхшы һәм төрле» булуларын телибез һәм үзебез шундый иҗатчыларны ничектер өнәмичәрәк кабул итәбез. Моны чал поэзия тарихы да раслый. Яхшы шагыйрь, гадәттә, авыррак танылa. Талантның төрлелек чиген киңәйтергә омтылуы гадәтилеккә күнеккән хөкемдарларда ризасызлык тудыра. Күзгә бәрелеп торган төрлелек, әйе, беренче чиратта сәерсенү уята. Тормышыбыз шулай корылганмы? – Ахрысы. Тукайча туры итеп әйткәндә, «Безнең татарларда... һәрбер нәрсәгә каршы тору ата-бабадан калган бер гадәттер». Шундыйрак каршы торулар поэзиядә дә күзәтелгәли. Алтмышынчы еллар уртасын гына искә төшерегез. Поэзияне төрлеләндерергә омтылган яшьләргә сәерсенеп карауچылар булмадымы? Традицион шигырь белән иркле шигырьне үзара каршы куярга тырышучылар да табылды. Вакыт әлеге бәхәсне үзенчә хәл итте. Гадәти тоелмаган «стандартсыз» яшьләрнең күбесе хәзер инде яхшы шагыйрьләр булып танылды. Яңарышка, авырлык белән булса да, күнегелде.

Алтмышынчы еллар уртасында күтәрелгән «гаугалы» буын шагыйрьләренең берсе Рәшит Әхмәтҗановның озаграк танылуын һәм кайберәүләр тарафыннан кыенрак кабул ителүен дә аның талантларга гына бирелә торган авыр юлдан барырга, ягъни башкаларныкына охшамаган иҗат дөньясы белән мең авазлы поэзияне үзенчә төрләндерергә омтылуыннан чыгып аңларга кирәктер. Шагыйрь поэзиядәге серлелек башлангычына чагыштырмача ныграк таяна, серлелек җирлегенә тирәнрәк үтеп керергә омтыла. Төрлеләр рәтендәге урынны, мөгаен, шушы сыйфат билгелидер. Кайбер әсәрләренең авыр аңлашылуы да серлелеккә өстенлек бирүдән киләдер.

«Серлелек»не кайчак «табышмак» белән бутыйбыз. Шагыйрьләр иҗатын тикшергәндә, «табышмак өстенә табышмак», «шигъри ребус», «фикерне яшерү», «җеп очын югалту», «башваткыч» кебек гыйбарәләр мулдан сибелә, ә поэзиянең тумыштан килгән серлелеге, иҗатчының образлы фикерләү үзенчәлекләре, талантның эчке үсеш тенденцияләре, җиңел генә үтеп керә алмаслык катлаулы лирик дөньяның асылы һ.б. шундый мәсьәләләр тиешенчә күтәрелми. Шагыйрьнең бөтен нечкәлекләрен ачып салган эчке портретны профиль күләгәсен ашык-пошык буяштырып бирүче моменталистларча эшләп булмыйдыр. Кешене дәвалар өчен организмның эчке төзелешен белү зарур. Монысын яхшы беләбез. Гомумән, мәгълүм фикерне кабатлап әйткәндә, авторны

тәнкыйтьләү җиңел, мәгәр бәяләү кыендыр, һәм шушы уңайдан Гёте сүзләрен искә төшерү дә урынлы булыр: «Язучыны аңлаешсызлыкта гаепләр алдыннан үзеңнең шәхси акылыңны анализларга һәм аңламауның сәбәбе шунда түгелме икәнен ачыкларга кирәк. Әңгер-меңгердә хәтта эре хәрефләр дә авырлык белән укыла».

Шагыйрь Рәшит Әхмәтҗанов әсәрләрендәге серлелекнең асылын ничек аңлатыйк? Иң элек Хәсән Туфанны тыңлап үтик: «Рәшитнең кайбер шигырьләрендә Гарсиа Лорка йогынтысы бардыр кебек тоела. (Мәсәлән, «Әллә инде кыр казлары кайта» шигырендә.) Ләкин Рәшит Испания чегәннәре фольклорына гына хас булган «табышмаклы», катлаулы метафораларның йомшак якларын, татар шигыренә ят икәнлекләрен яхшы белә. Рәшитнең сурәтли торган үз теле бар...» «Өметләрне аклады» дип башланган фатихасында аксакал үзенең «энекәше» турында шундый сүзләр әйтеп калдыра. Өметләрне аклаган шагыйрьнең «Егет җыры» исемле җыентыгындагы атаклы каләм – яшел каралы каләм эзләрен күздән кичерик. «Туй көне җитә» шигыре урнашкан биткә Хәсән ага мондый сүзләр язып куйган: «Халык ритмы һәм Тукайлар ритмы ничек яңарып яңгырый!» Арырак китәбез. «Җан тетрәткеч шигырь бу!» Монысы – «Сөрелгән җир кап-кара...» дип башланучы шигырьгә бирелгән бәяләмә. «Тамчы монологы»н да ул үзенчә кабул иткән: «Юк, Лорка тәэсире түгел, бу үзе татар «Лорка»сы».

Лорка... Очраклыдырмы-юктырмы: Рәшит Әхмәтҗанов иҗатына кагылган аз санлы тәнкыйть мәкаләләрендә әлеге дә баягы Лорка исеме очраштыргалый. Атаклы испан шагыйренә тиңдәшлек үткәрмичә әйткәндә, алар арасында ниндидер охшашлык күренә шикелле. Күләм-дәрәҗәсен төгәл билгеләп булмый торган мондый охшашлык шагыйрьләрнең фикерләү рәвешендә, бигрәк тә метафоралар куллануда сизелә. Кайберәүләр өчен «аңлашылып җитмәүче» шагыйрьләр рәтендә торучы Гарсиа Лорканың ихлас ачылып әйткән мондый сүзләрен Рәшит Әхмәтҗанов әсәрләрендәге уй-хис яшәеше табигатенә карата да кулланып буладыр: «Теманың бөтен катлаулылыгын бик яхшы аңлаган хәлдә, мин төгәлләнгәнлеккә дәгъва итмим; мин сызыкламалар гына эшләргә – сөйләп бирмәскә, ә фикергә юнәлтергә телим».

«Татар Лоркасы» Рәшит Әхмәтҗанов әсәрләренең кайберәүләргә аңлашылып җитмәве, «фикер агышының логик эзлеклелеккә буйсынмаган» булып күренүе, кыскасы, шагыйрьнең бөтен серлелеге маңгайга бәреп тора торган төгәлләнгәнлеккә дәгъва итмәүдән, гомумән алганда, югарыда әйтелгән иҗат принцибына охшаш инануга нигезләнүле фикерләү рәвеше табигатеннән килмиме? «Үзен кабат-кабат укытырга мәҗбүр итмәүче китапны мин яхшы китаплар рәтенә куя алмыйм...» – Рәшит Әхмәтҗановның әнә шундый нәзберек зәвыгы да шагыйрьнең иҗат холкын шактый сизелерлек дәрәҗәдә чагылдыра төсле. Укылган китапны яңадан кулыңа алу, димәк, андагы тирәнрәк мәгънәви катламнарны колачларга теләү, димәк, ачылып бетмәгән серләр ләззәтен татырга ымсыну, димәк, иҗатчы буларак, үзең дә тышлык белән чикләнмәгән «очсыз-кырыйсыз» китаплар тудырырга омтылу. Шагыйрь шуңа омтыла. «Уйлар катлау-катлау, хисләр катлау-катлау» (Сибгат Хәким).

Шагыйрьнең каралама-кулъязмаларын актарам. Матур язу дәфтәрендәгечә түгел – үзе генә таныйрлык урыннар шактый. Төзәтмәләр дә җитәрлек. Укыйсың – тәртеләсең. Кайчак төшенеп булмый. Ашыгып язылган рецепт шикелле. Рецепт... Шагыйрь әнә шулай дәва өләшә, һәрбер күңел дәвадан үзенчә шифа таба...

Караламалар ашыгып язылмаган. Җөмләләр кат-кат эшләнгән. Сөйләүгә авышкан урыннар, фикер агышын өзмәслек итеп, акыллы рәвештә сызылган. Шагыйрь чын шигъри тел – кыска, тыгыз, сурәтле һәм музыкаль тел белән язарга омтыла. Болай да уйланулар резюмесын кристаллаштыручы метафоралар арасыннан мөмкин кадәр җыйнагын һәм зуррак сыешлысын сайлый. Метафоралар катлаулана, эчтәлек тыгызлана. Янә Хәсән ага сүзләре хәтердә яңара: «Рәшит Испания чегәннәре фольклорына гына хас булган... катлаулы метафораларның йомшак якларын, татар шигыренә ят икәнлекләрен яхшы белә...» Йомшак якларын беләдер. Шулай да метафоралары шактый катлаулы чыга. Кайбер әсәрләрнең аңлашылып җитмәве, мөгаен, шушы «мазок» катлаулылыгыннан да киләдер. «Асылынып, тау тирбәлә талымның иңнәрендә», «Дөнья, дөнья...

Хәзер ике күзем — чүлләрендә ике күл була», «Сандугач килеп кунар чак җитте җир астындагы һәрбер тамырга»... Катлаулы булсалар да, минемчә, аңлаешлы метафоралар. Нишлисең, барысы да фикерләү рәвешенә бәйледер, һәркемнең үз почеркы. Төрле шагыйрьләрне бердәй кабул итәр өчен төрле нечкәлектәге тоемга ия булу кирәк. Йөрәкләр тибешенең график сурәтләнеше, күпмедер охшашлык булса да, берсен берсе стереотип төгәллегендә кабатламый, һәрбер йөрәкнең биотогы үзенчә. Поэзиядәге төрлелекне әнә шундый кабатланмаулар билгели. Шагыйрьләр төрле булган кебек, шигырь сөючеләр дә төрле: алар өчен «авыр аңлаешлы» Дәрдемәнд тә, «җиңел аңлаешлы» Такташ та кадерледер.

Һәр сүз миннән бер матурлык сорый,
Мин фәкыйрьмен — алыйм кайлардан?
Ярый, килдең син: кояштан тамдың,
Шигыремә төштең айлардан...

«Һәр сүз миннән бер матурлык сорый...» Шагыйрьнең кемгәдер аңлашылып җитмәве, бәлки, сүз белән эш итә белмәүдән генә киләдер?! Тирәннән эзләнгән сәбәп, әнә шулай, өстә генә ятмыймы? Тикмәгә генә шулай әйтелми: поэзия — иң яхшы тәртиптәге иң яхшы сүзләр. Әдәбиятта «сүз рәтен» белмәүчеләр бихисап. Буталчыклык шуннан килмиме?

Рәшит Гәрәй: «Шагыйрь озын язарга, кайбер яшь әдипләребез шикелле, кирәксә-кирәкмәсә дә... җөмләләр матур булсын өчен генә сүз уйнатырга яратмый».

Роберт Батуллин: «Мин Рәшитнең шигырьләрен музыкага охшатам. Мондый шигырь язу өчен бик тә нечкә тойгылы интеллектуаль йөрәк кирәк».

Равил Фәйзуллин: «Безнең... чичән телле Рәшитләребез... бар».

Сибгат Хәким: «Аның шигырьләрендә сүзләр шулкадәр үз урыннарында, ул сүзләр йорт стеналарына ипләп салынган ташлар, кирпечләр кебек, аларны икенче төшкә күчерүе читен, икенче төшкә алып куясы да килми».

Төрле вакытта (сүз берләшмичә) әйтелгән әлеге фикерләрдән катгый дөрес нәтиҗә чыгарырга җөрьәт итмәстән, Рәшит Әхмәтҗанов иҗатындагы кайбер тел буталчыкларын күздә тоткан хәлдә (алар кемдә булмый?!) һәм озын-озын шигъри мисаллар китермичә генә шуны белдерәсе килә: югарыдагы күзәтүләр шагыйрь файдасына сөйлиләр төсле.

Шулай да... Шагыйрьнең катлаулы фикерләү рәвешенә турыдан-туры бәйле булмаган, төгәлрәк әйткәндә, камилләшеп җитмәгән сыйфатларга — осталыкка кагылышлы (авыр аңлауга китерүче) җитешсезлекләргә дә күз йоммаска кирәктер. Шагыйрьдәге шагыйрьлекне аяк терәп яклыйм, әмма «гаепләр»ен тулаем инкяр итәргә җыенмыйм. Иҗат кимчелексез булмый. Аңлаешсыз юллар да очрыйдыр. Алар тәүге иҗат адымнарыннан ук килә бугай. Мондый юллар «матур егерме ике яшьтә» әзерләнгән беренче китабында да бардыр. Шагыйрь иҗатына хәерхаһлы булган Әдип Маликов Әлмәт каласын төзешкән ташчы егетнең беренче шигъри тәҗрибәләрен түбәндәгечә искә төшерә: «Без аңа: «Бу юлларың бик үк аңлашылмый бит»,— дигәч, ул кызарына, маңгаеннан тирләрен сөртә. «Әйе шул,— ди ул, ахырдан ризалашып,— үземә дә шулай тоела», һәм икенче көнне инде без шигырьнең гади, отышлы вариантын укыйбыз».

Серле дөнья күкрәгәндә
Кал син, энем, үз хәлеңдә.

Шагыйрь үзенең энесенә шундый киңәш биргән. «Үз язуы»н тудырган иҗатчыга, алай язма, болай яз, дип, акыл өйрәтүнең кирәге бармы? Өйрәтүчеләр, әлбәттә, очраштыра. Нәрсәдер көчләп тагарга тырышабыз. Художникның эчке дөньясын, рентген шикелле, тиешенчә яктырта алмыйбыз. Дөрес диагноз куелмый. «Коеп куйган» шагыйрь, һичшиксез, үзе булып калсын. Әмма киңәшләргә саңгырау булмаска кирәк. Күпләр тарафыннан күрсәтелгән кимчелекләрне кире кагып булмый.

«...Шигырь эчендәге логик эзлеклелеккә игътибарын киметә төште». Шагыйрь иҗатына кагылышлы мәкалә һәм чыгышларның «кимчелекләр өлешендә» Рәшит Әхмәтҗановка еш кына

шундый дәгъва белдерәләр һәм кайбер «аңлаешсыз» әсәрләрнең уңышсызлыгын нәкъ менә логик эзлеклелек булмаудан күрәләр. Тормыштан сәнгатькә төгәл анализсыз күчеп булмыйдыр. Бүгенге аналитик заманда бигрәк тә. Иҗатның шундый кагыйдәсен дә онытмаска кирәк: стиль аныклыгы фикер аныклыгына һәм, соңгы исәптә, максат аныклыгына китерә.

Фикер аныклыгы... Фикер поэзиясе, гадәттә, аңлаешлы була. Абстрактлылыкка авышкан романтик образлылык исә үзеннән-үзе буталчыклы катлаулылыкка этәрә. Мондый үрнәкләр дә очрый. Ярым тоннарның азлыгы, кирәкле очракларда график төгәллеккә ирешмәү, абстракт төшенчәләрнең анык күзалламалар белән нигытылмавы, фикернең калкурак итеп күрсәтелмәве дә әсәр үзәгендәге логика умырткасының тотрыксызлыгына һәм йөрәкләргә аңлаешлы серлелек белән бернинди уртаклыгы булмаган буталчыклыкка китерә. «Аңладыгызмы?» дип, маңгайга бәреп сорауга караганда «Аңлата алдыммы?» дип әйтүне тормышта дөресрәк саныйлар. Мондый кагыйдә иҗатка да ярашлы.

Ә чын сүзләр безнең иреннәрдә
Ничә кабат канга буялган...

Фикерне калкытыбрак күрсәтү, әйе, әсәрне аңлаешлы иттерә. Аллы-гөлле гыйбарәләр, бормалы-сырмалы сүзләр, күзгә төтен җибәрү төсле, әсәрдәге теләсә нинди бушлыкны яшереп торалар. Кайвакыт купшылыкны нәфислектән аермыйбыз. Поэзия тасма теллелекне, бушбугазлылыкны яратмый. Шушы уңайдан бер хикәят хәтергә килә.

Бер шагыйрь бер бай адәмнең ханәсенә барды. Байны мәдехләп шигырь әйтте. Ул бай адәм моңар бик хушнуд булды (рәхәтләнде.– *З.М.*). Әйтте: «Хәзердә минем кулымда акчам юк, ләкин ашлыгым бик күп, иртәгә кил, сиңа ашлыктан бер нәрсә биреп җибәрермен»,– диде. Шагыйрь иртәгесен янә байның ханәсенә килде. Бай әйтте: «Нихәл, ник килдең?» – диде. Шагыйрь әйтте: «Кичә ашлык бирермен дип вәгъдә кылган идең, аның өчен килдем»,– диде. Бай әйтте: «Гаҗәпсең, син мине сүзең белән хушнуд кылдың, мин һәм сине сүзем белән хушнуд кылдым»,– диде.

Җанга берни дә бирмичә, укалы сүзе белән хушнуд итәргә тырышып, күзгә кибәк сибүчеләр азмы? Сүз боткасын күпме җылытсаң да, сүз боткасы булып кала. Фаразлау көче белән логика көче тигезлеген сакламыйча, хиссият стихиясенә баштанаяк бирелүчеләрне аксөяк кызлар төсле купшы киенгән бушсүзлелек ныграк эзәрлекли. Моны онытмау зарур. Көрәш поэзиясенең һәрбер сүзен солдатка тиңлиләр, һәм ул һәрвакыт солдат булып калырга тиеш:

Җинелмә сүздә, җинелсәң –
Җиреңне дә дауларлар.
Юкка гынамыни җирдә
Чичән булган бабаңнар.

Шагыйрь иҗатын янә күздән кичерәм. Китап исемнәрен бер-берсенә бәйлим: «Хыялларым үзем белән», «Егет җыры», «Ак канатлар», «Гомер чишмәсе», «Алмалы җәй», «Җан яктысы», «Кавышыр көн»... Егерме еллык иҗат гомерен колачлаган әлеге китапларны уртада торучы үзәк исем астында берләштереп карыйм. «Гомер чишмәсе»... Тоташ бер китап күз алдына килә. Китапларның берсендә дә авторның фотосурәте бирелмәгән. Бирелмәсен. «Яшәгәнчә язарга» омтылучы шагыйрь Рәшит Әхмәтҗанов портреты тоташ бер китап тәшкил иткән әсәрләрдә болай да ачык күренә. Мартирос Сарьянның төрле яшьтәге сурәтләрен берләштергән автопортрет шикелле. Әнә китаптан унсигез яшьлек ташчы егет карап тора. Йөзеннән эчкерсезлек һәм садәлек сирпелә. Моңсу күзләрендә «сугыш еллары авырлыгын чәчләренә бәйләп сөйрәгән» Ләйсән, әбиләр, «бүреләрне җиңә алган колыннар», гомер буе әнкәсенең каршысына яланаяк йөгерүче ятим балалар, «Үстегезме, әллә үлдегезме?» дигәндәй, каңгылдашып кайтучы торналар чагыла төсле. Яшь – кече, уй – олы.

И бала, алтын яшьлегең
Бу җиргә нәрсә чәчәр?
Нәрсәләр чәчәр? Урмасмы
Бары тик көмеш чәчләр?




Әсәрләрнең уртак җыелмасында әнә икенче сурәт төсмерләнә. Таныш күзләр ничә яшьтә? Чама белән генә әйткәндә, ахры, Тукай яшен узып бара. Карашы элеккечә эчкерсез. Унсигездәге чалымнары кискен үзгәреш кичермәгән. Хисләр утыра төшкән. Элекке моңсу күзләр тирәнрәк булып күренә. Үзләре һаман очкынлы. Гамьлелеге арта төшкән шикелле.

Кырыгын узган шагыйрь... Бөтен рухи хәзинәләр ачкычы булган ихласлылыгын зирәклек белән тагын да ныгыта төшкән. Акыллылык сирпеп торган күзләре, балачактагыча, дөньяга самимилек белән карыйлардыр. Йөзендә чәүчәләклеккә охшаш бәргәләнү сизелми (тирән елга тавышсыз ага). Элеккечә. Шөһрәткә ымсыну чалымнары күренми. Тыйнак («Булсын бар биеклегем арыш биленнән генә...»). Үзенең хакыйкатен раслау юлында ул тормышның ачысын-төчесен татырга өлгергән. Картларныкы төсле капчыклык булмаса да, яшәеш хикмәтләрен шактый туплаган. «Яшь чагында авыр ташлар — тау астында, җиңел ташлар гына тора тау башында». Җандагы ялкын күзләрдә чагыла: «Күрмисез, минем күңелдә фидаи яшәгәнен...» Маңгае киңәеп киткәндәй тоела. Чигә чәчләре уңган. Тынгысызлык күз төпләренә аз гына талчыкканлык иннеге сылаштырган.

Алма белән кояш арасында
Дөрләргә дә безгә дөрләргә!
Гомер озын.
Ямьсезләндек бары
Матурлыкны күбрәк күргәнгә.

Матурлыкны күбрәк күргәнгә... Шагыйрь җиңел юлдан бармый. Матурлык өчен көрәшкәндә, әйе, ямьсезләнергә дә мөмкиндер. Ихлас җанның кылган кайбер яхшылыклары кайвакыт үзенә начарлык булып кайта. «Сүземә карагыз — юллар ачармын, үземә бакмагыз — үзем начармын...» Тукаебызның әлеге сүзләре матур яңгырашлы рифма өчен генә әйтелмәгән. «Эшләр шома гына бара...» Мондый канәгатьлекне «шома миле» генә белдерә аладыр. Хәер... Дөньяда бит шома яшәп, шома язганнар да җитәрлек. Күрәләтә авыр юлдан барырга омтылучы Рәшит Әхмәтҗановны без андыйлар рәтенә һич кенә дә кертә алмыйбыз. Вакытында аңа тәнкыйть тә эләкте, әмма ул үзенең юлыннан тайпылмады. Талантның шома була алмавын шагыйрь үзе дә бик яхшы төшенә. Күңеленә Чернышевскийча караш-инану язылган: «Үзеңнең әсәрләрең белән беркемдә дә ризасызлык уятмау, үзеңә карата беркемдә дә каршылык кузгатмау... Мондый кызыксыз бәхет бары тик баналь сүзләрне риторик рәвештә тарату белән шөгыльләнүче буш кешеләргә генә эләгә».

Мин, ахры, еракка —
Йөрәккә китәрмен...

Шушы авыр юлда өзлексез камилләшә баручы (шомармаучы!) Рәшит Әхмәтҗановка җиңеллек юрамыйк.

*«Казан утлары» журналы.— 1986*

# Ташларны җыяр вакыт

Ркаил Зәйдуллин

«Ташларны чәчәр вакыт, ташларны җыяр вакыт»,– ди китап.

Рәшит Әхмәтҗановның исеме соңгы елларда, әдәби тәнкыйтьтә булсын, чыгышларда булсын, еш кабатлана башлады. Бу юкка түгел, әлбәттә. Минемчә, аның иҗаты яңа яклары белән ачылып, әдәби җәмәгатьчелекнең игътибарын үзенә тартты.

Билгеле, мин аның иҗатын икегә бүләргә дә һәм бер-берсенә каршы куярга да җыенмыйм. Элек тә Рәшит Әхмәтҗановның әйбәт шигырьләре, халык теленә күчкән гүзәл юллары бар иде. Әмма ни сәбәптәндер әдәби тәнкыйть аңа ул чакта игътибар итеп җиткермәде.

Моңарчы без аны ярсулы, ә кайчакта моңсу лирик шигырьләр остасы дип белә идек. Поэма жанрында ул үзен сынап карамады шикелле. Менә «Казан утлары» журналының быелгы 4 нче санында аның «Бишташ» дигән поэмасы дөнья күрде. Дөресен әйтергә кирәк, башта бераз сагаеп кулга алдым журналны. Зур шигъри әсәр тудыру кыен эш. Шул эшне ерып чыга алганмы шагыйрь?

Аңлашылса кирәк, минем максатым поэманы төрле яктан анализлап һәм бүтән әсәрләр белән чагыштырып саллы мәкалә язу түгел, анысы исем алган хөрмәтле тәнкыйтьчеләребезгә калсын.

Поэма нинди булырга тиеш? Моңа хәзер ачык кына беркем дә җавап бирә алмыйдыр... Бу жанр хәзер әдәбият теориясендәге кысаларга гына сыймый. Үзебездә һәм үзәк матбугатта чыккан поэмалар – шуңа дәлил.

«Бишташ»ны мин бер тында укып чыктым. Гомумән, Рәшит Әхмәтҗановның шигъри әсәрләрен укыганда сөрлекмисең. Ул табигый. Бу сыйфат чын шагыйрьләргә генә хастыр, мөгаен. Хикмәт монда традицион язу стилендә генә түгелдер. Әсәрнең иң зур уңышы –470бербөтенлектә. Югыйсә матбугат битләрендә әсәрнең күләменә карап кына «поэма» дип кую очраклары да булды. «Бишташ»та сюжет сызыгы өстә күренеп ятмый, әмма ул һәрдаим сизелеп тора.

Тәнкыйтьтә Рәшит Әхмәтҗановны мантыйксызлыкта гаепләүчеләр дә булгалады. Әйе, стандарт фикер йөртүче кешеләргә аның бу әсәрендә дә җим җитәрлек. Тик шагыйрь кем соң ул? Ул – гадәти логиканы җимереп, үз логикасын тудыра алган кеше! Шагыйрьлек шунда, иҗат итүнең мәгънәсе шунда. Сүзне калыпка салырга да, рифма табарга да, хәтта символлар иҗат итәргә дә өйрәнеп була, тик шигъри логика серенә генә өйрәнеп булмый. Бу тумыштан бирелә. Перу шагыйре Сесар Вальехо болай ди: «Символ иҗат итүчеләр, сез башта халыкка ялангач килеш күренегез, ә аннары мин сезнең ыштаныгызга карармын. Гүзәллеккә генә мөкиббәннәр, күренә ки, сезгә үлеп карарга туры килмәгән әле».

Учта ташлар сикерешә. Юк, уен түгел бу. Ташлар мине дөнья турында, яшәеш турында уйларга этәрде. Янә бер тапкыр үз күңелемә төбәлдем...

Шагыйрь сугыш еллары балаларының сурәтен искиткеч осталык белән күз алдына китерә:

...Утырам ташлар өстендә.
Күздә яшь яңа кипкән.
Көлмәкне,
Ашар икмәкне
Сугышлар талап киткән.



**Студентларның төзү отрядында. Р. Әхмәтҗанов – сулдан беренче**

Шаккатмалы образлар да, метафора да юк монда, ә укыгач, җан сулкылдап куя. Бу – язмыш. Ә шигърият – иң беренче нәүбәттә язмыш ул...

Әдәбиятта ташка борынгыдан мөрәҗәгать итәләр. Сизифны һәм аның мифик ташын гына искә төшерик! Мәңгелек көрәш. Кешенең бернинди авырлыклар каршында да сыгылмавын, өметсезлеккә бирелмәвен искәртә сыман ул.

Баксаң, шагыйрь дә Сизифка охшаган икән бит! Поэмада бу риваятькә ишарә булмаса да, мин алар арасында параллель үткәрергә җөрьәт иттем.

Шагыйрь тарихка күз сала. Минемчә, Кол Гали язмышы турындагы бүлек – иң уңышлысы... Бу бөек Болгар шагыйре турында без байтак версияләр, күзаллаулар ишеттек, әмма поэмадагы Кол Гали минем күңелемә нигәдер якынрак – шагыйрь һәм шәхес ныграк ачыла.

Тарих – янган кульъязмалар, каберләрдән кубып диварларга күчкән ташлар... Тарих – сабак. Шагыйрь кисәтә. Аның авазында әрнү, әрнүле ачыш:

...Тик шагыйрьләр яклаганга гына
Җирдә исән калдык, күрәсең.

Һәм тагын да зур әрнү, дөресрәге, инрәү:

Барыбыз да Галәм бәгыреннән
Мордар китәчәкбез ләбаса!

Шагыйрьләр каләменә сөрмә бул, таш!

Автор поэмада төссез, абстракт сөйләүче түгел, монда аның үз биографиясе.

Минем үз тарихым: Туфан өч көн
Ташчы булып бездә эшләде.

Шагыйрь халык язмышына төрле ракурслардан якын килә. Язмышлары аерылгысыз:

Бездә яши шундый бер өстенлек:
Уттан алда мөмкин балкырга.
Бөек халкым – давыл кочагында,
Минем җаным шунда – Халкымда.

Давыл шундый: безнең алга Гамлетның мәшһүр соравын куя ул...

Рәшит Әхмәтҗановның поэмасы – шагыйрьнең үз иҗатында гына түгел, шигъриятебез өчен дә куанычлы вакыйга. Минем бу язмам шул куанычны уртаклашу рәвешендәрәк килеп чыкты. Каләмдәшләр поэма турында үз фикерләрен әйтерләр, чөнки... ташларны җыяр вакыт җитте.

*«Татарстан яшьләре» газетасы.– 1987. – 26 май*

# Ташлар симфониясе

Марс Шабаев

Алдымда – «Казан утлары» журналының быелгы апрель саны. Шагыйрь Рәшит Әхмәтҗановның шул санда басылган «Бишташ» исемле поэмасын бер тын белән укып чыктым да хисләремнән айный алмый утырам.

Рәшит Әхмәтҗанов – лирик шагыйрь. Аның иҗади уңышлары да лирикада калку һәм үзенчәлекле булып аерылып тора. Ә поэма жанры, нигездә, эпик жанр. Бу эпиклыкны шагыйрьнең лириклыгы ничек трансформацияли алды икән? «Бишташ» поэмасын укый башлаганчы, күңелдә әнә шундый сагаюлы сорау да кузгалып куйган иде.

Татар шигърияте лирик-романтик рухтагы поэмаларны Һ. Такташ, Ф. Бурнаш, Ә. Фәйзи, Х. Туфан кебек зур шагыйрьләребез иҗатыннан башлап белә. Ул безнең көннәрдә Ә. Баян, И. Юзиев, Р. Харис, Роберт Әхмәтҗанов кебек шагыйрьләребез иҗатында үсеш таба. Димәк, укучының лирик поэмаларны кабул итәргә әзерлеге бар.

Ташлар образы да – шигырьдә традицион тотрыклы образларның берсе. Әллә кая еракларга китеп тормыйча гына, Әхмәт Фәйзинең «Кара таш ник дәшми?» һәм Роберт Әхмәтҗановның «Таш елады» балладаларын хәтергә төшерик. Шагыйрь Рәшит Әхмәтҗанов исә үзе ташчы булып эшләгән кеше. Әлмәт шәһәрен төзегәндә кулларыннан үткән Чупай ташлары, еллар аша килеп, шагыйрьнең күңелен яңадан кузгаткан.

«Таш, батмыйча, су өстендә йөзеп йөрде». «Бишташ» поэмасына Кол Галидән китерелгән бу шигъри эпиграф укучыны алдан ук җитди сөйләшүгә әзерли. Юк, һич тә бишташ уены уйнарга гына чакырмый булса кирәк безне шагыйрь. «Поэмага чакыру» дигән кереш бүлектә Рәшит Әхмәтҗанов укучыны ипле генә, җай гына итеп үз күңеленә алып керә. Үз күңеле белән укучы күңелен бер моң дулкынына көйли.

«Әле гөл бөртеге сыман гына» булган лирик геройга, «кояш кочагына кереп», озын-озаклап иркәләнеп торырга туры килми: «авырлыгын дөнья салды канатларга».

Каршылады Әлмәт мине,
Ташларына ташлар бәреп...–

ди шагыйрь. Бу юлларны укуга, сискәнеп китеп: «Плакатлардагыча җансыз ташчы турында язганмы әллә?» – дияргә ашыкмыйк. Булды, шагыйрьләребез андый әсәрләрне дә байтак яздылар. Рәшит Әхмәтҗанов исә «җанына – җыр кәрванына» төялгән ташларын барлый. «Менә монысы – моңсыз башка бәрәсе таш, ә монысы – оятсызның алларына «аш» итеп куясы таш... Әмма «таш – авырлык, икмәк түгел...» Шул ташлардан йортлар саласы бар. Илне аякка бастырасы бар. Чөнки «һәр терегә кирәк оя». Иңнәренә дөнья авырлыгын иртә күтәргән «кырык беренче ел балалары», әнә шулай итеп, Илгә терәк булалар.

Шундый бер ассоциация туа: концерт башланыр алдыннан оркестрантлар музыка коралларын тикшереп-уйнап карыйлар. Әле скрипка, әле флейта, әле фагот авазлары... Өзек-төтек си-бемоль... ре-мажор... Арада берничә такт таныш музыка... «Кайчан уйный башларлар икән инде?» – дип, түземсез бер ашкыну белән көтәсең... Утлар сүнә... һәм, ниһаять... Менә ул без көткән симфония!

«Бишташ» поэмасының керешеннән соң «Беренче таш» бүлеге әнә шул без көткән симфониянең беренче бүлеге булып яңгырый:

Бу таш... болгар бабам
туган йортның
Нигезеннән купкан, күрәсең.
Мин абындым аңа...

Шагыйрь безне тарихыбызның ерак үткәненә алып кереп китә. Болгар ташы телгә килә, абынучыга сорау: «Нигә тибәсең?!» Менә шушы кыска гына сорау күңелләрне айкап ташлый. Туган нигезенә, үзенең үткәненә «тибеп узучылар» әллә азмы бездә?

Аннары безнең күз алдына аягын ташка бәреп кистергән, шуның белән «зур ачыш» ясаган борынгы кеше килеп баса.

Әмма шагыйрь безне бүгенге җирлектән аермый, онытылырга бирми. Күктә яңадан «Әлмәт ае». Күңелдә — борынгы таш. Әнә кеше инде тораташлардан сурәт-сыннар уя.

Поэмада бик табигый рәвештә Хәсән Туфанның мәгълүм шигъри юлы яңгырап китә: «Талантлы син, Кеше туганым!», «һәм талантлы менә шул кешедән... корбан чалдылар»,— ди шагыйрь. (Төгәлсезлек: кешедән түгелдер, кешене корбан чалалардыр). (Диалекталь алым. Китапны төзүче искәрмәсе). Суешлар, сугышлар башлана. «Ташны көйдерерлек каргышлар» иңрәп чыга:

Тарих анналларын актара Ай:
Халык каны тамган битләрне
Кат-кат укый... кайсы
баскынчының
Кай җирләрдә башы
беткәнне...

Шагыйрьнең ассоциатив фикерләве безне яңадан бүгенге көнгә кайтара. «Кыйтгаларда яңа мәҗүсиләр корбан чалып, биеп йөриләр». «Муенга таш бәйләп, су төбенә ташлаучылар» инде бүген:

Ут ыргытып утырмакчы алар
Безнең өскә Җидегән
йолдыздан...

Бүгенге көннең хәвефле чынбарлыгы — Америка президенты Рейганның «йолдыз сугышлары» дигән саташулы доктринасы калкып чыга.

Ә кулдагы ташың телсез
Калган
Иң борынгы матдә.—
Син — телле! Син — йөрәкле!
Үлемнәрне үтер,
Алып бабаларың шикелле.

Бу өндәү-чакыру безгә, укучым!

«Икенче таш» — поэма-симфониянең икенче бүлеге. Бу таш «кешеләрне аскан залимнең кара кабер ташы». «Күзе бар күк явыз Кисекбашның — Кол Галине эзли...»

Бөек Кол Галинең «су өстендә йөзгән ташы» яңа трансформация кичерә. Шул ук вакытта җирлек бүгенге: «Әлмәттә яз. Тереләрне күккә тарта ил Кояшы!» — ди шагыйрь. Рәшит Әхмәтҗанов Кол Галинең ачыкланмаган фаҗигале язмышыннан яңа бер легенда-версия тәкъдим итә. «Кешеләрне аскан залим» яшь чагында аның иң сөекле кәнизәге үлеп китә. Залим: «Үлде бердәнберем, ник башкалар тере?!» — дип, һәр күзгә чалынганны үтертә башлый. Шунда Кол Гали әйтә: «...мине тотып утта яндыр, койма халык канын!» Бөек шагыйрь халкын яклап һәлак була. Автор мондый нәтиҗә ясый:

Тик шагыйрьләр яклаганга гына
Җирдә исән калдык, күрәсең...



**Рәшит Әхмәтҗанов, ?, Җәүдәт Миңнуллин**

Бу юллар артында Кол Гали генә түгел, халкы өчен яшьли «янып беткән» Тукай да, «үлеме җыр булып яңгыраган» Муса Җәлил дә, «вөҗданы да, намусы да бары халык юлында» булган Хәсән Туфан да басып торалардыр шикелле.

«Өченче таш» — шагыйрьнең «җаны җәйли торган җәйләүдән иелеп алган илем ташы». Ул кайчандыр «тау булгандыр, бәлки... нәни генә бер тылсымлы затка әйләнгән». (Төгәлсезлек бар: зат — җанлы шәхес. Ә сүз җисем, матдә турында бара.) Бу таш вак кисәкләргә ватылып, һәркемгә автор тарафыннан үз өлеше бирелә. Аның бер кисәге «үз иленнән хәер сораучы кулына» «менә шушы таштан бәхетеңне тап син» дип әйтеп салына. Әйе, эшлексез җилкуарлар, кеше тапканны гына ашап ятучы әрәмтамаклар байтак әле. Икенче кисәк таш — «үзен үзе җәлләп елаучыга». Мондый «сытыклар» да җитәрлек. Алар белсеннәр: «киләчәккә барып була икән, ташлар яуса да...»

Шушы урында Рәшит Әхмәтҗанов янә бер кызыклы экскурс ясап ала. Безне «адаш абый»-сы — атаклы төзүче, Социалистик Хезмәт Герое Рәшит Саттаров белән таныштыра. Шагыйрь Әлмәттә аның кул астында ташчы булып эшләгән. Төзүченең кулында «таш та җылы», «хәйләкәр ул абый — ташлар аша ятим җанны иркәли». Ике-өч строфага сыйган бу эпизод әлеге «үз иленнән хәер сораучыларга», шыңшучы-елаучыларга гыйбрәт булсын: әнә кемнән үрнәк алыгыз, бәхетсез җаннар!

«Дүртенче таш» — яшен ташы. Бүлек шагыйрь Хәсән Туфанның якты истәлегенә багышланган. Аның «Талантлы син, Кеше туганым!» дигән юллары юкка гына яңгырап китмәгән икән поэмада. Шәхес культы хөкем сөргән елларда нахак ялалардан газап чиккән, озак вакытлар теленнән-халкыннан аерылып торган Хәсән ага Туфан искиткеч мөлаем, ягымлы, тере булып күз алдына килә дә баса. Менә ул Әлмәт каласында йөри. Тирә-якта «намустай ак Чупай ташыннан» салынган йортлар. Туфан «урамнардан узды, робагыйлар язган сыман ап-ак ташларга». Яшен ташы телгә килә: «Сөрмә буласы таш идем Туфанның каләменә».

«Бишенче таш» — шагыйрьнең тәрәзәсенә атылган таш. «Бу таш та бик кадерле»,— ди шагыйрь. Бала бәргән таш булса, «аңлатыр аңа дөнья: ташлар бәрү ни була? Ашка бәрү ни була? Башка бәрү ни була?» «һәм, таш бәреп, бу Җирне җимереп тә булганын...».

Тирән хисле, шигъри образларга бай, күп төсле буяулар белән бизәлгән матур әсәр иҗат иткән Рәшит Әхмәтҗанов. Поэманың полифоник яңгырашы гаять көчле. Шагыйрьнең бишташ уенындагы ташларны шигъри образ итеп күтәрүе һәм шул биш таш аша илебез-халкыбыз язмышына, аның тарихына поэтик экскурс ясавы бик табигый, көчәнмичә генә эшләнгән. Кайбер урыннарда композицион төзеклектә хилафлык төсмерләре сизелсә дә, әсәр бербөтен булып кабул ителә.

«Бишташ» әсәре — Рәшит Әхмәтҗановның шигърияттә яңа үр яулавы. Бу поэма 1980 еллар татар поэзиясендә билгеле бер казаныш булып бәяләнер, дип уйларга кирәк.

*«Социалистик Татарстан» газетасы.— 1987. — 30 май*

# «Аучылар кибетендә»

Марсель Әхмәтҗанов

Татар поэзиясе тарихында бик ерак гасырлардан бирле килә торган фәлсәфи-публицистик жанр бар. Аның безнең көннәргә хәтле килгән иң әүвәлге өлгесе итеп XIV йөз шагыйре Хисам Кятибнең «Җөмҗөмә солтан» дастанын күрсәтергә мөмкин. XVIII–XIX гасырларда бу өлкәдә Габдерәхим Болгари, Колмөхәммәт Болгари, Яхъя Болгари һәм башка шагыйрьләр каләм чарлаганнар. Бүгенге татар поэзиясе мәйданында бу жанрны үстерүчеләрнең берсе — шагыйрь Рәшит Әхмәтҗанов.

Шагыйрьнең заман, халык язмышы, әхлак проблемаларына багышланган «Аучылар кибетендә» исемле яңа фәлсәфи-публицистик поэмасы шушы көннәрдә матбугатка чыкты («Татарстан яшьләре». — 1988. — 10 июль).

Поэманы укый башлагач, күз алдына сугышның соңгы еллары, сугыштан соңгы еллардагы халкыбыз башыннан үткән тарихи вакыйгалар конкрет килеп баса. Шагыйрь бүгенге буын яшьләренең әхлагын сугыштан соңгы буын кешеләре әхлагы белән чагыштыра һәм борчылып, янып чаң суга... Югалтуларыбызның зурлыгына, аларның арта баруына бөтен йөрәге белән борчыла шагыйрь.

Поэмадагы вакыйгалар аучылар кибетендә генә барса да, бер-берсе белән гаҗәп тыгыз бәйләнгән фәлсәфи проблемалар әсәрдә калку чагылдырылганнар. Һәр проблема конкрет мисаллар аркылы ачыла. Әхлак сыйфатларының төшүен автор аучылар образлары аркылы ача. Моннан кырык еллар элек аучылар, халык милкен һәм куркынычсызлыгын саклап, изге эш башкарганнар. Аучылар яшәгән тамак ачлыгы дәверенә рухи ачлык дәвере килгәч, аучылык һөнәре кешелеккә каршы эшләрнең бөтен комбинацияләрен эченә алган, социаль үзгәреш кичергән һөнәргә әйләнә. Аучылар элек үзләре аулаган ерткыч бүреләр психологиясе белән эш итүче бәндәләргә әйләнделәр, саф җаннарны «аулый» башладылар. Дөньяга туа алмый калган балалар, намуслы хезмәт кешеләре, чәчәк кебек яшьләр аларның корбаннары сафларын тутыралар. Шагыйрь «аучылар» дигән термин астында бюрократларны һәм карьеристларны, спекулянтларны, эшлексезләрне һәм җинаятьчеләрне күз алдында тота.

Шагыйрь Рәшит Әхмәтҗанов кечкенә күләмле, ләкин уран төше кебек тыгыз фикерле бу поэмасын уңышлы эшләп чыккан. Аның әйтергә теләгән фикере ачык: кешеләр, акылыгызны җуймагыз, гуманизм дигән, аң-белем, хезмәт, намус, Ватан, туган җир, туган тел, ата-ана дигән изге мәгънәгә ия булган төшенчәләрне онытмагыз!

«Аучылар кибетендә» поэмасы бүгенге тормыш таләпләреннән чыгып, үзгәртеп кору рухында язылган.

*«Социалистик Татарстан» газетасы.— 1988. — 13 август*

# Көче – гомумиләштерүдә

Мөдәррис Әгъләмов

Узган ел шагыйрь Рәшит Әхмәтҗанов укучыларга «Бишташ» поэмасын бүләк иткән иде. Матбугатта ул уңай бәя алды. Без моңа кадәр Рәшитнең лирикасына күнеккән идек. Алар арасында йомарлам-йомарлам кар кебек сусыллары да, яңгыр тамчыларыдай ялтырап торганнары да күп иде. Без аларны үз иткән идек инде. Рәшит Әхмәтҗанов дигән беркемгә дә охшамаган шагыйребез барына инану килгән иде. Әмма «поэма» дигәч, ничектер Рәшитнең иҗаты күз алдына килмәгән иде.

Соңгы ике елда шагыйрь безнең өчен өр-яңа яктан ачылып китте. Быел тагын бер поэмасы басылды. Исеме дә бөтенләй аңа хас булмаган, прозаик исем – «Аучылар кибетендә».

Шагыйрь әнә шул кечкенә генә кибет аша олы дөньяга карый. Ул караш – җитди караш. Үткәнгә, бүгенге көнебезгә, киләчәккә төбәлгән бу борчулы караш та иҗтимагый җирлеге булган яңгыраш бар. Поэманың геройлары да безнең тирәлектәге кешеләр. Менә аның яшь дусты – аучы малае. Кибеткә керү белән, аның күзләре ялтырый башлый. Нәрсә генә юк биредә! Хәтта чибәр сатучы кызга кадәр бар. Әмма лирик чигенешләрендә шагыйрь безне үткәннәргә алып китә:

Халыкларның асыл улларына
Ядрә үтми торган күлмәкләр
Ник сатылмый?

Поэманы аучылар кибетеннән алып чыккан төп тема да әнә шунда инде.

Әллә каян – арттан – ач бүреләр өзгәләгән сугыштан соңгы чорлар хатыны Фатыйма калкып чыга.

Яшь дустының әтисе күтәрелә. Ул төпчек улына мирас итеп бернәрсә дә калдыра алмаган, әмма «телнең һәм хәтернең иксез-чиксез көчен калдырган».

Хәтта кибет эчендәге пыяла аквариум да поэма эчендәге нәни шедеврга әверелгән:

Аквариумнарын океан дип
Йөзә монда кәрлә балыклар.
Шулай яшәрләрме, үз телләрен,
Хәтерләрен җуйса халыклар.

Мондый тыгыз мускуллы шигъри гадилеккә һәм ихласлыкка корылган поэмалар сагындырган иде инде. Фатих Кәримнең «Идел егете», Сибгат Хәкимнең «Сары капкалы йорт», «Гөбнә буенда», Роберт Әхмәтҗановның «Таш аргамагы»ннан соң бик тә сагындырган иде.

Аучы кибетендә чират. Халык затлы итеп эшләнгән бизәкле коралларга чират тора. Ләкин «Алтын булсын корал, көмеш булсын, авырттыра алар бертигез». Никадәр генә кыска әйтергә теләсәм дә (гафу итегез!) бер өзек китерми китә алмыйм:

Халык чират тора.
...Илнең нурын урлап саткан карак
Амнистия көтә.
Чират җитә.
Дәүләт малын урламаган өчен,



**Әдәби очрашудан соң**

Берәү орден көтә.
Чират җитә.
Үз баласын җиргә тудырмаска
Кызлар врач көтә.
Чират җитә...

Шигырьдәге гомумиләштерү иң югары накалга күтәрелә.

Шушы кечкенә генә поэма турында әле бик озак сөйләп булыр иде. Биредә һәр юл уйландыра.

Рәшит Әхмәтҗановның үз укучылары бар. Һәм ул укучылар минем кебек үк бәхетле дип әйтәсем килә.

*«Социалистик Татарстан» газетасы. — 1988. — 13 август*

# Озын юлга җитәрлек

Рәшит Гәрәй, Фәнзаман Баттал

Казанга кайтып барабыз... Юл ерак, бу автобуста әле биш-алты сәгать селкенәсе бар. Икәүләп юл йөрүебез беренче тапкыр гына түгел. Шуңа күрә алдан ук шәйләп утырдык: башка чаклардагы кебек, кырыкмаса кырык темага кереп чыгачакбыз. Туган-тумачалар, уртак таныш-белешләр, яңача яши башлаган илнең сөендергән-көендергән яклары... Беткәнмени сөйләшер сүз!

Әмма бу юлы бер тема бөтен юлга җитте. Сәбәпчесе — алдарак утырган бер кыз, дөресрәге, аның кулындагы «Татарстан яшьләре» газетасы булды.

Җайлап кына сүз каттык, газетаның ул укып чыккан битләренә күз салдык.

— Менә бу поэманы укыгыз әле,— диде кыз моңсу гына.

— Кызыкмы, кызганычмы?

— Шомлы,— дип куйды кыз, аннары тагын бер сүз өстәүне кирәк тапты: — Сискәндергеч...

«Аучылар кибетендә». Поэма. Куш битнең яртысын алып тора. Авторы — Рәшит Әхмәтҗанов...

Рәшитнең беренче карашка бернинди әһәмияте юк кебек әйберләрдән, вакыйга-күренешләрдән тирән мәгънә таба белүче шагыйрь икәнлеге безнең өчен яңалык түгел. Ләкин «дилбегә буе» поэма язу өчен аучылар кибетеннән нәрсә генә тапты икән? Хуш, мылтык күрсен, дары, ядрә... Кем күрмәгән аларны?

Укый башламас борын ук тагын бер нәрсәгә игътибар иттек: поэманың буеннан-буена «чират» сүзе сибелгән. Суга да чират торып зык күргән заманда кем өчен яңалык ул?

Укый башлау белән, фаразлар чигенде. Баксаң, бу кибетнең тәрәзәләре дөньяга, үткән һәм киләчәк заманнарга, җан тетрәткеч язмышларга карый икән. Дөресен генә әйткәндә, кибет биредә биниһая зур йомгакның җеп очы гына.

...Ачлык. Ач бүреләр ач халыктан ризык даулый. Авыл читендәге бүре улавы, авыл эчендә кешеләр елавы. Алты баласы белән калган Фатыйма исемле хатын каяндыр бер төенчек бәрәңге юнәтә, авылына — ач балалары янына ашыга. Кайтып җитү насыйп булмый, бүреләр корбан итә...

Шомлы, фаҗигале хәлләрне ничек кенә оста тасвирламасын, вакыйгалар, күренешләр генә Рәшит Әхмәтҗанов өчен максат түгел әле. Аучыларча әйтсәк, мылтыкны коруы гына бу. Атканы — фикер, фәлсәфә. Аларны укучының зиһененә төзи шагыйрь. Юлдаш кызыбызча әйтсәк, сискәндереп җибәрә, уй дәрьясына ташлый.

Кулдан ычкындырмый үлгән мескен
Төенчеген... бәрәңгесе тулы...
Биш баласы елый.
Шатлана тик
Туң бәрәңге тоткан төпчек улы.

Дүрт-биш юлга нәрсә генә сыймаган! Вакыйга да, җан өшеткеч күренеш тә, яшь аралаш елмайтып, кинәт кенә айнытырлык трагедиясе дә бар.

Укучы моннан соң алга таба тиз генә укып китә алмаячак әле, теге сабый урынына үзен куеп, читтән карап торачак, яшәлгән гомерен барлаячак. Урынлы-урынсыз көлгән чакларыннан да гыйбрәт алачактыр, бәлки.

Корал кибете икән, димәк, әҗәлләрнең туй башы да шушында. Куяннар, бүреләр, төлкеләр кырылачак. Әмма бу дөньяда олырак затларны аулаудан мәгънә һәм ләззәт табучы «сунарчылар» да бар.

Халыкларның асыл улларына
Пуля үтми торган күлмәкләр
Ник сатылмый?

Кем белә, икенче бер шагыйрь җәлладлар кулыннан үткән асыл улларны санап китүне дә мәгъкуль күргән булыр иде, бәлки. Азмы бездә җаны кыелган акыл ияләре? Сталин тираниясе белән Гитлер фашизмы гына да халык өчен җан атып яшәүче күпме әдипләрне, мәгърифәтчеләрне кырган бит! Шик тә юк, Галимҗан Ибраһимов, Шамил Усманов, Кәрим Тинчурин, Муса Җәлил, Абдулла Алиш, Фатих Кәрим кебек дистәләрчә халык улларын күздә тота автор. Мәгәр берсенең дә исем-фамилиясен атамый — үзең уйла, кеше, үзең барла, гыйбрәт ал, башкаларга сөйлә!

Хәер, сөйләвен дә сөйләрсең, әмма һәр тыңлаган аңлармы соң? Нәкъ шушы урында күңелгә шик сала шагыйрь:

Бер почмакта — олы аквариум,
Йөзеп йөри кәрлә балыклар.
Күз алдына килә үз телләрен,
Хәтерләрен җуйган халыклар.

Сагайта, энә белән төрткәндәй сискәндерә Рәшит Әхмәтҗанов.

Йа Хода, берзаман безнең халык та шушы көнгә калмасмы? Диңгезне — аквариумга, илне модалы чүпрәккә, бай тарихыбызны ялтыравыклы өстәл-шкафларга алыштырмабызмы? Игелек урынына кансызлык, каты бәгырьлелек көчәймәсме? Бихисап сораулар тудыра поэма, як-ягыңа игътибар белән карарга, җавап эзләргә мәҗбүр итә. Маңкортлардай гамьсез яшәсәк, безнең алгы буыннарга андый куркыныч янап, кисәтеп тора. Әнә бит, намуслылар, иле, халкы өчен җан атып торучылар сафы белән янәшә рәхимсезләр, оятсызлар чираты да үсә.

Илнең нурын урлап саткан карак
Амнистия көтә.
Чират җитә...
Дәүләт малын урламаган өчен,
Берәү орден көтә.
Чират җитә...
Үз баласын җиргә тудырмаска
Кызлар врач көтә.
Чират җитә.

Шундук тагын бер тәгъбир йөрәккә утлы күмер булып төшә: «Кем тудырмый, шулар үтерә»... Димәк, җиргә туасы кешене тудырмаучылар — кеше үтерүчеләр, акыл җыя белмәүчеләр — акылы-ние белән бергә халыкны үтерүчеләр. Аларның да тормышта максатлары бар, шул максатка бару өчен, чиратлары бар. Алар да адәм сурәтендә, әмма ике аяклы, ике куллы кортлар гына.

Бу фикерне аңлау ачы, бик ачы. Маңкортлар чиратына ашкынучылар бетәргә, аларның күзе ачылырга, яктылык эзләргә тиеш, дип өметләнә күңел. Кайда ул яктылык, тәмам адашмас-саташмас борын табарга мөмкинме аны? Шулчак поэманың лирик герое безгә аваз бирә:



**Бер төркем язучылар Мәскәүгә съездга килгәч. Сулдан уңга: Әхсән Баянов, Роберт Миңнуллин, Илдар Юзеев, Мансур Вәлиев, Гариф Ахунов, Ринат Мөхәммәдиев, Равил Фәйзуллин, Әдип Маликов, Рәшит Әхмәтҗанов, Гарәф Шәрәфетдинов, Рөстәм Кутуй, Шәүкәт Галиев. 1980**

Төнне көнгә әйләндерә торган
Матдә ич мин,—
Әйдә яндыр мине.
Яктыралсаң — яндыр,
Яхшыралсаң —
Җәлләрмени кеше җанда барын.
Бу яну барыбызга да уртак булырга тиеш.

Рәшит Әхмәтҗанов моңа кадәр дә тирән фикергә, аксакалларга хас зирәк фәлсәфәгә мохтаҗ булмады. (Сүз арасында әйтеп үтик, ак сакал йөртергә иртә булса да, шигърият мәйданыбыз аксакалларының берсе итеп таныйлар аны.) Кыюлыкка да кытлык кичермәде — күп әдипләр күк, күкрәүләр, шомлы җилләр үткәч кенә юлны дәвам итәргә ниятләп йөргән бер заманда яшенле гарасат уртасыннан йодрык төйнәп, ярсып, чәчрәп алга барды. Хакыйкать өчен, халкы өчен янарга, яктырту «матдәсе» булырга һәрвакыт әзер иде.

Шулай да сизелә, әле Рәшит тә хөррият, хәбәрдарлык чорын өмет иткән елларда кайбер төенчекләрен чишмичәрәк саклаган икән. Бу поэмасы да шуларның берсеннән борын төрткән, дөньяга чыккан, дигән фаразыбыз бар. Шигъриятгәге юлының табигый киңәюе булса да ни гаҗәп. Һәрхәлдә, чорыбызның шушындый әсәрләргә, шушындый шагыйрьләргә сусаган чагы.

...Сүзне сәфәрдән, шушы поэманың озын юлга җитәрлек фикер азыгы бирүдән башлаган идек. Акылы бар укучыга гомер юлына җитәрлек фәлсәфәне бирүе дә бик ихтимал аның.

*«Татарстан яшьләре» газетасы.— 1988. — 14 август*

# «Карачкы» поэмасына карата бер фикер[1]

Марсель Галиев

Ярый әле... бу дөньяда акыл һәм хис тәңгәллегенә тере сулыш биргән шигърият бар. Мин кеше! дигән затның бер кулы белән гаҗәеп сәнгать җәүһәрләре тудыра алуына сокланып карыйм да... икенче кулы белән меңнәрчә еллар дәвамында үз кавемен изәр, юк итәр өчен акыл җитмәс явызлыклар кылуына шаккатып, чарасыз калам. Кем син, кеше? Каян килдең син бу Җир-анага? Явызлык һәм миһербанлыкны үлчәр бизмән каршында аптырап калган мизгелдә кешенең җан авазын, илаһи хисен исәпли алмый торган рухи урталык — тел куәсенең галәми тәэсире — шигърият ярдәмгә килә, шигърият сүрүенә кергән моң, сагыш, әрнү, җирдәге кырыс кануннарга сыеша алмыйча, кеше дигән затның асылын, яшәешен, рухи халәтен табигый чынбарлыктан өстен яссылыкка менгерә ала. Менә шул чакта инде син, чистарынып, көнкүрештәге болгавыр ваклыклардан арынып, яңадан туа аласың. Поэзиянең көче — гомереңне яңарта алуда. Тел дигән хикмәтле диңгезнең кабатланмас дулкыннарында коену ләззәтен кичерә алу өчен, шул дулкыннарга тупланган йөгерек тамчыларның аерым-аерым бердәм пышылдавын, җырын, назын тоя белү кирәктер.

Мин әле һаман «Идегәй» дастанының шифалы кайтавазында яшим, нәүмиз яшәгән күңел чикләрен соңлап булса да мең авазлы оркестр киңәйтеп җибәргән халәттә, яңа әсәрләргә дә мин шул тәэсирдән чыгып карыйм.

«Карачкы» поэмасына мин әнә шундый фикерләр белән янып килдем һәм алданмадым. Әсәр, чынлап та, телнең югары катыннан торып язылган, Олы мәхәббәт турында; заманның фаҗигаләре аша җирдә кабатланмый торган тормышны, кешене яратуга, иманны сакларга чакырган шагыйрьнең әрнүле тавышы җанның акыл сыялмый торган тарлавыкларына хис яктылыгы алып керә. Югарыда телгә алган дастанның йогынтысын, тәэсирен мин бу поэманың аерым бүлекләрендәге борынгы шәрыктан килгән әйләнмәләрдә, фикерне бер йодрыкка туплап, мәкаль югарылыгына җиткереп, хикмәтле әйтә белүдә, көй агышында тойдым. Поэманың эчтәлеген сөйләргә тырышу, аерып таркатып карау гөнаһ дип саныйм. Аны ялгызың гына укырга, шул дөньяда яшәп алырга һәм иң гадел шаһит — күңелең белән кичерергә кирәк.

Кеше хисләре җир белән күк арасында тирбәлә. Ул җәяүле дә, канатлы да... Таяну ноктаң җирдә чакта, күкне онытмыйча, кунар ноктаң күк дәрьясында чакта, җирне онытмыйча, асыл урталыкны табып, телнең нечкә җан тибрәнешләрен тоеп яза белү — шагыйрь Рәшит Әхмәтҗановның бөтен шигъриятенә хас сыйфат. Бу поэмасы белән ул тагын үзе генә тапкан моң чишмәсен кешеләр хөкеменә юллады.

*1989, 13 апрель*

[1] Кулъязма Р. Әхмәтҗановның шәхси архивыннан алынды.— *Төз.*

# И ләззәтле йөрәк бәйрәме...

Әзһәр Габиди




1950 еллар ахыры — 1960 еллар башында иҗат итә башлаган татар шагыйрьләре арасында үзенчәлекле үзавазын актив яңгыратып торган Рәшит Әхмәтҗановның шигырь китапларының берсе «Адымнар» дип атала иде. Аккан судай, искән җилдәй еллар бер-бер артлы үтә торды. Шагыйрьнең дә адымнары һаман ныгый, тирән хисле, якты моңлы тавышы һаман көрәя, ягымлылана барды. Ул поэзия сөючеләрне «Хыялларым үзем белән» (1965), «Ак канатлар» (1972), «Гомер чишмәсе» (1976), «Алмалы җәй» (1979), «Җан яктысы» (1980), «Кавышыр көн» (1985) кебек китаплары белән сөендерә килде. Инде менә шагыйрьнең 30 еллык иҗатыннан үрнәкләр сайлап алынган, соңгы елларда язылган яңа шигырьләре дә кертелгән иң күләмле «Йөрәк бәйрәме» исемле сигезенче китабы дөнья күрде. Бу инде шагыйрь шәхесе, аның иҗаты һәм язмышы хакында иркенләп сөйләшергә, киңрәк һәм төплерәк фикер йөртергә тулы мөмкинлек бирә.

Шагыйрьнең китап исемнәрен болай җиңел генә санап чыксак та, ул поэзиягә җиңел генә килеп кермәде. Рәшитнең бала һәм үсмер чагы сугыш һәм аннан соңгы авыр чорга туры килгән, ул — «кырлар буйлап ачлык куган, качып-посып шунда арыш уган, тамак туйгач, офыкларга кадәр аллы-гөлле күбәләкләр куган» буын вәкиле. Юк, ул шигърияткә әдәбияттан түгел, тормышның үзеннән, аның шактый зур тәҗрибәсен туплап, бай биографиягә ия булып, Баулы ягының яшел хәтфәдәй тугайларында маллар көтә-көтә, Әлмәттә кирпеч өеп, буыннары тала-тала, шул ташлардан үзенә көчләр ала-ала, аларны ватып, сынала-сынала, походларда авыр булса да, йөз сытмыйча атлый-атлый, илем диеп яна-көя, яшьлеге кешеләр иминлеген саклый-саклый, таң нурлары тамган кырлардан серләр эзли-эзли, дөньяның шигъри матурлыгын шул яктылык аша күзли-күзли, тыныч һәм тыйнак кына килеп керде.

Без күп вакытта менә шулай: шагыйрь әдәбиятка зур тормыш тәҗрибәсе туплап, бай биографиягә ия булып килде, дип сөйләргә яратабыз. Ләкин бу зур тәҗрибә һәм бай тормыш биографиясе үзе генә әдәбиятка һәм сәнгатькә бернәрсә бирми әле. Әнә шул тормыш материалын шагыйрь күзе белән карап, шагыйрь йөрәге аша үткәреп, әдәбият чынлыгына күтәрә, бай био-

графияле язмыш дәрәҗәсенә җиткерә белергә һәм аны халыкчан тел белән динамикалы итеп күрсәтеп бирергә кирәк. Рәшит башлангыч шигырьләреннән үк шуны яхшы тоеп, аңлап эш итте. Халык иҗатына хас сурәтләүгә, образлылыкка, халыкчан фикер йөртергә омтылды. Гомумән, аның шигърияте өчен оригиналь шагыйрь булып кылану, укучы аңламаслык катлаулы метафоралар, купшы эпитетлар, төче чагыштырулар белән мавыгу, декларативлылыкка, тышкы эффектка омтылу – чит нәрсә. Аның иҗаты өчен халыкчан гадилек, ихласлылык, гадәти сурәтләү чараларыннан оста файдалану, сүзнең кадерен белү һәм аның белән сак эш итү хас. Ул моны «Керләр чайкый әнкәй» дигән шигырендә үзе дә:

Керләр чайкый әнкәй, керләр чайкый,
Уе китә сулар төбенә.
Әйтерсең ул шулай диңгез айкый,
Телбизәкләр эзләп телемә.

Бар дәверләр аша хәтерләгез:
Ничек өйрәндек без сөйләргә?!
Сүзләр өчен бирдек күзләрне без,
Каныбызны бүлдек сүзләргә.

Тел югалтса егет – ил югалткан,
Сүз югалтса – иле оялган.
Ә чын сүзләр безнең иреннәрдә
Ничә кабат канга буялган...–

дип икърар итте.

Рәшит Әхмәтҗанов – романтик рухлы, фәлсәфи карашлы, лирик җанлы, хис, моң, фикерне тыгыз итеп органик үрүче, поэтик юнәлеше, кызыксыну даирәсе, тематик эзләнүе ягыннан туган җир, туган тел, табигать, яшьлек һәм мәхәббәтне данлаучы һәм аны яратып җырлаучы шагыйрь.

Туган көнемнән үк бәхет биреп,
Азат балам диеп атадың.
Авыр чакларыңда Кол Гали күк
Колың булыйм, газиз Ватаным.

Юк, бу шигъри юллар шагыйрьнең үзен күрсәтергә теләп күкрәк кага-кага, тамак яра-яра ватандар булып сөрән салуы да, үзен җир улы итеп танытырга маташуы да, купшы сүзләрне бербер артлы тезеп, бизәкче булып кылануы да түгел. Ә чын ихластан, чын күңелдән әйтелгән чын йөрәк авазлары.

Монда шуны да басым ясап әйтергә кирәк: бу шигъри юллар шагыйрьгә ярарга тырышып, аның иҗади үзенчәлеген бар булмышыннан калку итеп күрсәтергә уйлап, исәп тотып сайлап алынмады. Аның туган җиргә, туган телгә, туган табигатькә һәм шуның иң югары чагылышы булган Ватанга кайнар мәхәббәте, чиксез бирелгәнлеге, тиңсез тугрылыгы шагыйрьнең «Табам әле» исемле иң тәүге шигыреннән алып бөтен иҗаты буенча кызыл җеп булып сузылып килә һәм аның шигъриятенә кайнар сулыш бөркеп тора. Моның шулай икәнен авторның китабындагы төрле елларда язылган «Сау булыгыз, кыр казлары», «Әллә ләйсән, әллә кар инде», «Бәйрәм», «Тайгада», «Ямьсезләнеп беттек», «Сагына ил», «Яфраклар җыры», «Учак», «Сынмас җәя», «Калам җиремдә генә», «Мин һаман шундый», «Бик яшь идек», «Миңа кил», «Бу үзе», «Кояш батканда», «Әнкәм теле» кебек шигырьләр үзләре үк раслап торалар. Билгеле, мондый чор сулышын, заман рухын сынландырган шигырьләр бер укучыны да битараф калдырмыйлар. Шигырьләрдәге «Туган җирдә дошман каберләре, каберләрдән ирләр үч алмый», «Баш игәннәр кабат карый алмый зәңгәр күгенә», «Сынган беләк җиң эчендә булса – җиңнән чыккан иде йодрык», «Зәңгәр күзләрендә зәңгәр һава – кыр казлары очып узарга», «Кылычлар бит безнең башыбызга иелмәгән өчен тигәннәр», «Сандугачлар янган утта җылынырга ярыймы соң?», «Илен сөйгән ирнең иманы бер, сатылганның – тиен бәясе», «Туган илдә кызлар җырламаса, егетләргә гомер нәрсәгә» кебек халык әйтеме, халык мәкале булып китәрдәй юллар үзләре генә ни торалар! Шуңа алар хисне кузгаталар, аны туктаусыз хәрәкәткә китерәләр, акылны уяталар һәм онытылмаслык булып күңелгә уелып калалар.

Хыялның мәңге кипмәс, мәңге корымас чишмәсе булган табигатькә мөрәҗәгать итмәгән шагыйрь юктыр. Булса да сирәктер, һәм ул буш бизәкләрдән торган рифмаларны үреп баручы бер тезмәче генә. Рәшит Әхмәтҗановның бар үзенчәлеге – шагыйрьнең табигать белән дуслыгында, аның белән бер җан, бер тән, аерылгысыз бербөтен булуында. Ул, шуңа булса кирәк, Туган җиргә, үзен үстергән Ватанга мәхәббәт белдерәсе, гомер һәм аның кадере, яшәү һәм аның мәгънәсе, тормыштагы урыны һәм бурычы турында сүз алып барамы, мәхәббәтнең яшерен утларында газапланамы, табигатькә, җанны иркәләүче ямь-бизәкләренә мөрәҗәгать итә. Шулар аша үзенең уй-тойгыларын, хис-кичерешләрен, теләк-омтылышларын белдерә. Менә дигән хисси шигырьләр коеп куя. Алар акылдан бигрәк хискә тәэсир итәләр, аны хәрәкәткә китерәләр, аннан акылны уяталар. Шагыйрьнең «Исемдә, әнкәй, исемдә», «Ничек соң синең исем?», «Тамчы тавышы», «Очрашулар», «Кошларга», «Агачлар яфрак коя», «Кояшның кире үзенә», «Елмаеп торам икән мин», «Сандугач керде күңелгә», «Онытмыйм», «Сау бул, болыт», «Аккошларны эзлим» кебек шигырьләрен укыгач, кайсы гына укучы тирән хисләргә бирелми, тирән кичерешләргә күмелми, уйларга чуммый, дулкынланмый, тетрәнми һәм борчылмый калыр икән?! Ышанмыйм, андый битараф кеше табылмастыр!

Шагыйрьнең яшьлек һәм мәхәббәт лирикасы да нәфис, ягымлы, үзенчә. Аның бу төр шигырьләре нечкә тойгы, якты сагыш, юксыну хисе, татлы газап белән мөлдерәмә. Ә бит чын сөю, чын ярату татлы да, бер үк вакытта газаплы да була. Ул сине аклыкка, пакьлеккә, матурлыкка, батырлыкка илтә. Ул сине яшәртә, үстерә һәм иҗатка этәрә. Шагыйрьнең лирик героеның мәхәббәте дә шундый олы. Ләкин икесе ике җирдә яшәгән, әмма кавышуларына өмет өзмәгән оптимистик мәхәббәт.

Күктән таш яуса да, хәбәреңне  
Шул ташларның җибәр берсендә.  
Тау хәтле таш булсын,  
Ул таштан мин  
Йөзек кашы ясар идем дә,  
Туй бүләге итеп саклар идем,  
Күрешкәндә сиңа бирергә...  
Көн дә чыгам кояш чыгышына,  
Кавышасы көннәр тизме әле,  
Сагынасы көннәр күбрәкме?  
Син еракта.  
Монда, син юк якта,  
Сагынам мин синең йөрәкне.

Рәшит Әхмәтҗанов шигырь жанрында гына түгел, поэма жанрында да эшләүче автор. Аның укучыларның киң даирәсен тапкан «Исәннәр моңы», «Бишташ», «Аучылар кибетендә» исемле поэмалары да бар. Әллә шагыйрь үзе, әллә китап нәшрияты саранлык күрсәткән. Бу поэмаларның берсе дә китапта урын алмаган. Инде китап нәшрияты күрсәткән икән, һич югында, шигърияттә моңарчы бик күп тапкырлар әйтелгән, фикерләрдә кабатланган, шагыйрь мөмкинлегеннән бик күп түбән булган «Карлар ява», «Армиягә киттек», «Яр сөйгәннәр моңлы була», «Сулар ага», «Бер дулкын – көн кебек» шикелле шигырьләрне китаптан мәхрүм итеп булса да, поэмаларның берәрсенә урын бирергә иде. Ул чагында китап тулырак та һәм отышлырак та булыр иде. Ни әйтсәң дә, язучының сайланма әсәрләре ел саен чыгып тормый бит. Чыгарылганы аның әдипнең иҗатын тулырак күзалларлык булсын иде.

Менә шагыйрьнең күңелгә ләззәтле рухи минутлар бүләк итүче «Йөрәк бәйрәме»ндә кунакта булдык. Инде бу ак рухлы китапка – озын ак юл, шагыйрьгә, яңа иҗади ачышлар ясау, яңа табышлар яулау өчен, тел ачкычлары теләргә кала.

*«Хезмәткә дан» газетасы (Баулы).– 1989*

# Башың таш булмаса

Айрат Ибраһимов

Рәшит Әхмәтҗановның «Бишташ» поэмасын укыган идем. Ләкин ул игътибарымны тирәнтен җәлеп итмәде. Композициясе таркау, таш образы ачык бирелмәгән кебек тоелды. Минем өчен язылмаган бу, дидем. Әнә Игорь Стравинский яки Рихард Вагнер музыкасын яратмыйм, ә аларны мактаучылар азмыни? Белла Әхмәдуллинаны да аңламыйм. Ул шигърият белгечләре өчен яза, минемчә, безнең өчен түгел. Теге «эстетство» шаукымы, бәлки, Рәшиткә дә кагылгандыр...

Ә быелтыр очраклы рәвештә «Татарстан яшьләре»нең «Аучылар кибетендә» дигән поэма басылган саны кулыма килеп керде. Әсәрне укыгач, безгә тиң укучы нинди нәтиҗә ясый? Ошады — ошамады, яхшы — начар, кызыклы — кызыксыз... Әмма бу поэма турында алай гына әйтеп үтеп булмый. Ул уйлый белә торган һәр укучыны уйландырырлык. Ул торгынлык сазлыгына чик куйган апрель җилләре белән сугарылган.

Бу поэма заман таләбенә җавап итеп язылган, һәм менә нәкъ шуңа күрә «Казан утлары»нда барган «Заман һәм шигырь» дигән сөйләшүдә аның турында зур сүз кирәк. Белгечләр сүзе.

Чөнки кыска гына поэмада «озын-озак» романнар әйтә алмаслык тирән фикерләр әйтелгән.

Чөнки аның метафораларын аңлау укучыда үзе бер ләззәт тудыра.

Чөнки летаргик йокыдан уяна башлаган халкыбызга әҗәл даруы кебек хаҗәт бу әсәр.

Уйландыра ул. Уйландыра гына түгел, кайбер нәрсәләрне ачып та сала. Алыйк әхлакый категорияләрне. Беренчедән, кешегә бәя бирер өчен, аңа нинди корал ошаганына автор башта ук игътибарны юнәлтә. Икенчедән, поэмадан шуны аңларга була: пычрак җанлылык, мөртәтлек — тамырларыннан ваз кичү йә аларны югалту нәтиҗәсе. Дөрес, бу яңа фикер түгел, әмма шул фикерне шундый шигъри көч белән әйтә белү...

Уйландыра.

Хәтерне, телне үтерә торган корал нидән гыйбарәт?

Нигә соң «...һәркем җанга

Гамь кермәслек кием киенгән?»

Нинди шартлар этнең этенә дә намордникларга мохтаҗлыкны бетергән. Аучыларның төрлесе була, әмма һәркайсында көч зур — коралы кулында. Ә аучыга мылтыгын саграк кулланырга нинди хәлләр комачаулый соң? Мондый сорауларны тезеп куярга мөмкин.

Ләкин кирәкмидер. Икенчесе мөһимрәк: шагыйрь хәрәкәткә чакыра.

> Эңгер-меңгер җиткән, ут кабыз! —

Икенче җирдә:

> Акылыңны коткар, соңлама! —

дип укыйсың. Һәм:

> Хәтер сиңа туры юл күрсәтер
> Халкың җанын эзләп китәргә.
> Тапмый калма аны,
> Әгәр җирдә
> Исәпләсәң гомер итәргә,—

дип өнди шагыйрь.



**Татарстан язучыларының XI съездында. 1989**

Рәшитнең бу поэмасы оптимизм белән сугарылган булуы белән дә кадерле.

Илдән илгә күчеп, теге елан
Ут кабызып йөри берәм-берәм.

Яки:

Акчарлаклар килеп очар әле,
Боз астында гына Иделем,—

кебек юллар өмет чаткылары уятты, тик шунысы бар: кем соң ул елан, акчарлаклар? Кемне күтәбез? «Менә дәү абый кайтыр да...»

Әйтәсе килә, кычкырасы килә, көтмим кемне дә. Эш үзебездә. Бик кыен шартларда да тамырларыңны саклап була, тик битарафлык кулына гына эләкмә.

Поэма шәп, дидем. Әмма аның икенче ягы да бар әле. Аны укыгач, мин Рәшитнең «Бишташ»ын кире кайтып укырга мәҗбүр булдым. Дөресен әйтим: шагыйрьнең бу ике поэмасын чагыштырсаң, әлбәттә, «Аучылар кибетендә» бар яктан да килгәнрәк, уңганрак. Ул «Бишташ»ка да икенче күз белән, йөрәк җылысы белән, кызыксыну белән карарга мәҗбүр итте. Һәм юкка булмаган. Бу ике поэмада да сүз бер үк нәрсә — тамырлар, әхлак, хәтер турында бара ич! Бу мәсьәләләр, минем кебек үк, Рәшитнең дә авырткан җире икән! Тик кем ничек әйтә ала, кемнең нәрсәне аңларга сәләте бар. Орлык нинди туфракка төшә бит...

Бу җәһәттән шуны да ассызыклап үтәсе килә: Рәшит Әхмәтҗанов поэмалары шигъри тәрбия ягыннан да файдалы. Урта укучы дәрәҗәсенә төшмичә, аны, укучыны үз дәрәҗәсенә күтәрергә тырышу, әлбәттә, күркәм сыйфат. Ә инде бишташ турында уйланулар башың таш булып катмасын өчен ярдәм итүе мөмкин.

Озын сүзнең кыскасы шул: «Аучылар кибетендә» — шигъриятебездә күренекле вакыйга. «Туфаннарның варислары бар әле»,— дип куанырлык.

*«Татарстан яшьләре» газетасы.— 1989. — 11 май*

# Шагыйрь өчен сөенәм

Мөдәррис Әгъләмов

Халыкта гаҗәп зур мәгънәле бер сүз бар: ТУКАЙЛЫК. Бу төшенчә халыкка бирелгәнлекне дә, әйткән сүзен йөрәккә үткәрә торган кеше мәгънәсен дә бирә. Әлеге сүз беркайчан да үзенең саллылыгын югалтмас, дәрәҗәсен төшермәс дип уйлыйм. Татар халкының уяну чоры белән бергә туган исем ул.




1950 еллар ахыры – 1960 еллар башында әнә шундый яңа бер сүз барлыкка килде. Ул да булса – ТУФАНИЛЫК. Монысы да очраклы түгел иде. Тукайның шәкерте – совет чоры Тукаена әверелгән Хәсән Туфан хөрмәтенә әйтелгән бу тирән мәгънәле сүз аның шәкертләренә бик тә ябышып тора.

Әнә шул шәкертләренең иң талантлыларыннан, иң самимиләреннән берсе – шагыйрь Рәшит Әхмәтҗанов. ТАССРның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә тәкъдим ителгән «Йөрәк бәйрәме» китабында шундый юллар бар:

Кайсы өскә чыгар –
көрәшәләр
Туфанилык белән фанилык.

Шагыйрь әнә шул көрәшнең уртасында утыз биш ел яши, иҗат итә. Үз сүзләре белән әйтсәк:

Шигърияттә – бары туфанилык,
Фанилыкка гомер юк анда.

Шагыйрь моңа инанган. Аның әлегә кадәр чыккан китапларында, китап булып чыкмаган поэмаларында бу ышаныч үзәк юл булып ята. Иртәме-соңмы моны халык аңларга тиеш иде. Соңгы елларда мин шушы үзгәрешне күреп сөенәм. Шагыйрь өчен сөенәм. Укучылары өчен сөенәм.

*«Яшь ленинчы» газетасы.– 1990. – 28 март*

# Алабуга дәүләт педагогия институты галимнәре һәм студентлары хаты[1]

Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаеклы әсәрләр быел да җитәрлек булыр, чөнки соңгы елларда китап сөючеләргә җитешкәннәр арасында шактый камилләре бар. Алар арасында шулай ук үзенең тематик материалы, кичерешләренең үзенчәлекле булуы белән Рәшит Әхмәтҗановның да «Ачлык мәйданы» җыентыгы аерылып тора.

Татарстанның атказанган мәдәният эшлеклесе Рәшит Әхмәтҗановның «Ачлык мәйданы» дип аталган бу шигырьләр җыентыгы үз-үзен татар милләтенең бер вәкиле итеп тойган кеше өчен бер тын алуда укып чыгарлык китап, чөнки бу җыентык «йокыга талган гүзәлләрне, батырларны» уятырга, бүленгәннәрне, аерылганнарны бердәмлеккә өнди.

Бу җыентыкны Г. Тукай премиясенә тәкъдим иткәндә, без түбәндәгедән чыгып фикер йөртәбез:

1. «Татарстанның социаль-сәяси тормышы тамырдан үзгәргән чорда суверенитет идеясен халык үз итеп кабул итте. Шуңа бәйле рәвештә әдәбиятның эстетик идеаллары, эчтәлеге тирән кичерешләр белән бәйле. Әдәбият стереотиптан котыла бара. Билгеле булганча, әдәбият өчен тыелган темалар юк. Шул җәһәттән чыгып карaганда, Р. Әхмәтҗановның «Ачлык мәйданы» җыентыгы зур игътибарга лаек. Андый тематиканың әле башка әдәбиятларда күтәрелгәне юк. Җыентык Татарстанның бәйсезлеге өчен көрәшкә, иң драматик, гадәттән тыш вакыйгаларга багышланган. 1991 елның май аенда Ирек мәйданында булган ачлык хатирәләре барыбызның да хәтерендәдер, чөнки бу вакыйгалар йоклаган татар халкын йокысыннан уятты – бу җыентыкның иң кыйммәтле якларының берсе. Дөрес, ачлык игълан итү сәяси көрәш чараларының иң соң дәрәҗәсе дип карала ала, тик тормышка, туган иленә һәм җиренә, авылына һәм шәһәренә, теленә мәхәббәт хисләре тәрбияләү төрле юллар аша башкарыла. Шуның иң изгесе ана сөте, тәмле һәм ягымлы теле белән, тирә-юнь табигатенә һәм аның тирәсендә яшәүче, эшләүче, матур итеп сөйләшә белүче халкына таянып язылган юллар белән тәрбияләнә.

2. Шигъри җыентыкның күңелгә ятышлы, ягымлы сүзләре, тирән уй һәм тойгылары, халкыбызның кайгы һәм шатлыклары, көенеч-сөенечләре аша язылган сүзләре рухи байлык бирерлек. Чыннан да, яраткан халкыңның сулышын тоймасаң, аны ишетә алмасаң, аңлап та, җырлап та, матур шигырьләр дә, әсәрләр дә язып булмый, Рәшит Әхмәтҗанов – әнә шундый рухлы егетләребезнең берсе. Аның һәрбер шигыре йөрәгенең нечкә кылларыннан туган хис-тойгылар белән сугарылган. Милләт аңы уянган вакытта, онытылган, сихри булган тарихны искә төшергәндә, бу җыентыктагы шигырьләр безгә тарихның яңа битләрен ачарга ярдәм итә. Бу җыентыктагы әсәрләргә охшаган шигырьләр бәйләмә мондый авыр, ыгы-зыгылы тормышта безгә бик тә кирәк. Бу шигырьләр җыентыгы яшьләребезгә мирас булып калырлык, чөнки шагыйрь бу акциядә турыдан-туры катнашучы буларак, үзе белән иңгә-иң торган егерме фидаиның уй-тойгыларын чагылдыра, алар янына килгән төрле караштагы кешеләрнең үзләренә мөнәсәбәтен тасвирлый. Шул җыентыктагы шигырьләр искиткеч экспрессив язылганнар. Күрәсең, ихлас күңелдән язылган шигырьләр хисләрне, карашларны, бер төенгә туплап, халкыбызның бәйсезлеккә булган карашын чагылдыралар. Автор ачыктан-ачык акны – ак, караны кара дип атый.

Әдәби процесска моңарчы күренмәгән тема килеп керде. Аның игътибарга лаек бүтән әсәрләр белән беррәттән тәнкыйтьләнергә дә, бүләкләнергә дә хокукы бар. Җыентык Г. Тукай премиясенә тәкъдим ителә. Шагыйрь, билгеле булганча, үзенең тормыш максаты итеп милләт азатлыгы өчен көрәшне сайлаган. Җыентык Мәскәү сәясәтчесенең «суверенитет бары урындагы номенклатура өчен генә кирәк» дигән фикерен юкка чыгара. Китап гади укучы өчен дә, республика башында торучыларга да рухи азык бирә ала.

Язылганнарны раслап имзаларын куючылар бер төркем татар теле укытучылары һәм татар бүлегендә укучы студентлар: (25 имза)

[1] Хат Р. Әхмәтҗановның шәхси архивыннан алынды.– *Төз.*

# Ташлар шагыйрь итте

*Лена Шакирҗанова*

Рәшит Әхмәтҗановның «Бишташ» поэмасы басылып чыккач, бер нәрсә ачыкланды: китапханәләрнең, гомуми мәгълүматларына караганда, аны укучыларның иң популяр әсәрләрнең берсе итеп танулары күренде. Кайбер иҗатчыларның, әдәбият сөючеләрнең үз фикерләрен матбугат аша белдерүләре дә, бәлки, шуның чагылышыдыр.

***

...Шагыйрьнең бишташ уенындагы ташларны шигъри образ итеп күтәрүе һәм шул биш таш аша илебез-халкыбыз язмышына, аның тарихына, Кол Галиләрдән алып Хәсән Туфаннарга кадәр поэтик экскурс ясавы шулкадәр табигый, көчәнмичә эшләнгән ки, сокланмый һич мөмкин түгел. Поэма жанр законнарына тулысынча буйсындырылган. Композицион төзеклек, бер генә төртеп торган артыклыклары булмау әсәрне бик камил, бербөтен итә.

Шагыйрь «җанына — җыр кәрванына» гомер буе җыя килгән ташларыннан «биш шигъри йөзегенә җем-җем кашлар куя» да укучыларына тәкъдим итә. Беренче таш — «болгар бабам торган йортның нигезеннән», «ил хәсрәте иңгән таш»... Икенче таш — «кешеләрне аскан залимнең кара кабер ташы»... Өченче таш — шагыйрь «вак-вак ватып, һәркемгә өләшенгән ил ташы»... Дүртен-




**«Казан утлары» журналы укучылар белән очрашуда. Чыгыш ясаучы — Рәшит Әхмәтҗанов**

че таш — яшен ташы... Бишенче таш — тәрәзәдән кергән таш...


**Рафаэль Төхфәтуллин һәм Рәшит Әхмәтҗанов**

*Галия Минская*

Рәшит!

«Бишташ»ыңны укып чыктым. Үзем шатланам, үзем сине күз алдыма китерәм. Укып туймаслык, гаҗәп матур әсәр язгансың. Бу фикерне әйтергә үземнең хаклы икәнемә инану өчен, әсәрне кат-кат кулыма алам... Йөрәккә үтеп керерлек, тирән мәгънәле, тарихка калырлык әсәр язгансың. Халкым көткән бу поэмаң өчен мең-мең рәхмәт үзеңә!

*Рәшит Саттаров*

...Рәшит, бездә эшли башлагач, матурлыкны үз кулы белән ясый башлады һәм шул вакытта аңа чын мәгънәсендә игътибар итте. Хезмәт вакытында туган бу матурлык белән кызыксыну аның эчке дөньясын баетты, егетнең хисләре шигырьгә әйләнде, һәм ул поэзия юлына ныклы адым ясады, шуннан язмый булдыра алмады.

«Ул, бәлки, төзелешкә килмәсә дә шагыйрь булыр иде»,— диләр миңа.

Бәлки, шигырьләр язар да иде. Әмма Рәшит төзелештә үз урынын тапты, шунда бөтен игътибарын биреп эшләде, хезмәт барышында матурлыкны тоярга өйрәнде. Һәм мин Рәшитне бары ташлар шагыйрь итте дип уйлыйм.

*Рәшит Бәшәр*

Адаш!

«Бишташ»ыңны укыдым. Намуска хыянәт итмәвең өчен әйтеп бетергесез рәхмәт сиңа! Туфан өчен рәхмәт! Туфан турында беркайчан да мондый якты шигъри юллар языла алмас шикелле.

Бүгенге татар шигъриятендә бик күпләр дан өчен, дәрәҗә өчен үзләрен корбан итәргә әзер торганда (исемнәрен атамыйм, үзең чамаларсың), син үзеңнең зур һәм талантлы шагыйрь-шәхес икәнеңне, искиткеч якты, саф күңелле, зур идеаллы шагыйрь икәнеңне исбатлый алдың. Рәхмәт сиңа!

*Лена Шакирҗанова*

Рәшит дустым!

Синең «Бишташ»ыңны тагын бер тапкыр укып чыктым. Тагын да тирәнрәк мәгънәләргә төшендем әле. Афәрин!

*«Татарстан яшьләре» газетасы.— 1990. — 24 март*

# Шагыйрь иҗатына бер караш[1]

Сафуан Муллагалиев

Рәшит Әхмәтҗанов беренче карашка сәер кеше инде ул. Әмма син аңа якынлашсаң — беркайчан да аерыла алмыйсың, чөнки ул искитмәле кешелекле, эчкерсез — дус кеше.



Кулыннан килгән кадәр һәм үзенең белгәннәрен барысын да кешегә бирергә әзер тора һәм бирә дә... Ихтирамлы, игътибарлы һәм хөрмәтле кеше ул.

Шундый кешеләр күбрәк булса иде, дим мин.

Рәшит Әхмәтҗанов — бик авыр чорга туры килгән буын вәкиле. Ул — поэзиягә тормышның төпкеленнән күтәрелгән әдип. Аның тирән хисле шигырьләре дә шуны раслыйлар...

Рәшит Әхмәтҗанов заманыбызның үзенчәлекле зур таланты — зур шагыйре ул... Китапларын укый башладыңмы, ул сине шигъри тылсымы белән бөтереп ала да, китапны укып бетергәнче туктый алмыйсың... Укып бетергәч тә, китап белән бергә сулыйсың, уйлыйсың.

Рәшит Әхмәтҗановның иҗаты кешелекле — халыкчан үсештәге иҗат.

Гомере озын булсын — ул әле бик күп һәм бик шәп шигырьләр, поэмалар иҗат итәчәк халыкка...

Татарстанның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә тәкъдим ителүе дә шуның мисалы...

Рәшит Әхмәтҗановның «Йөрәк бәйрәме» дигән шигырь китабы һәм «Бишташ» дигән поэмасын бөек Тукай исемен йөрткән премиягә тулысы белән лаек һәм дөрес дип саныйм.

*1990, 9 апрель*

[1] Кулъязма Р. Әхмәтҗановның шәхси архивыннан алынды.— *Төз.*

# Пар канатлар талмасын...[1]

Шамил Маннапов

Шагыйрь Рәшит Әхмәтҗанов, дип әйтүгә, минем күз алдыма бер күренеш килеп баса. 1960 еллар иде. Без, бер төркем яшь шагыйрьләр, язучыларның Тукай исемендәге клубында чыгыш ясар өчен җыелдык. Ул вакытта биредә әдәби җомгалар гөрләп бара торган иде. Менә без сәхнә артыннан сузылып карыйбыз: зал шыгрым тулы. Алгы рәттә олуг шагыйрьләребездән Хәсән Туфан, Сибгат Хәким, Нәби Дәүли, Нури Арслановлар утыра.

«Кайсыгыз башлап чыга?» дип сорады кичәне алып баручы. Без беркавым тынып калдык, шундый могтәбәр аксакаллар алдына башлап чыгарга кыюлыгыбыз җитенкерәмәүдән иде бугай бу.

Шулвакыт какча озын гәүдәле бер егет, җиңелчә тамак кыргалап, сәхнәгә атлады. Һәм беренче шигыре белән үк залны авызына каратып өлгерде. Туган җирнең газизлеге, туган җирең, туган халкың язмышы өчен үзеңне җаваплы итеп тою, аның киңлекләреннән «йөрәк бәйрәмнәренең кыңгыраулар таккан атлары» белән узу турында иде бу шигырь. Ә «Сез китмәгез, акчарлаклар, акчарлаклар, Чит җирләрдә каерыла пар канатлар...» дигән юлларның киләчәктә һәркем отып алачак җыр булып әвереләсен ул вакытта без башыбызга да китермәдек... Яшь шагыйрь дигәнебез үзе — төзелештә ташчы булып эшләгән, аннары солдатта булып, әле күптән түгел генә Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый башлаган Рәшит Әхмәтҗанов иде.

Әлеге кичә азагында сәхнәгә күтәрелгән Хәсән Туфан башлап аның кулын кысты.

Ул бәхетле яшьлек кичәләреннән соң шактый сулар акты инде. Без Рәшит белән шагыйрь буларак бергәләшеп үстек, кем әйтмешли, бер казанда кайнадык һәм иҗатыбызның рухы буенча якын булып калдык. Мин каләмдәшемнең сәхнәгә шигырь сөйләргә чыкканда гына түгел, шигъриятендә дә кискен проблемалы темаларга кыю алынуын, үзенә генә хас язу рәвешен, образлар тәртибен табудагы осталыгын күрә киләм, хәзер инде ул — дистәгә якын китап авторы, үзе яшь шагыйрьләрнең остазы.

Соңгы елларда Рәшит Әхмәтҗанов зур әсәрләр язуга һаман ныграк тартыла. Шигырьләр һәм җырлардан тыш, аның талантлы каләме белән бер-бер артлы «Бишташ», «Аучылар кибетендә», «Карачкы» поэмалары иҗат ителде һәм татар шигъриятендә яңа сүз әйтү буларак кабул кылынды. Без, аның каләмдәшләре, Рәшитнең әсәрдән әсәргә һаман үсә, камилләшә баруын күреп сөенәбез. Шуңа күрә аның «Йөрәк бәйрәме» һәм «Бишташ» поэмасы Тукай бүләгенә тәкъдим ителүен нәкъ шулай булырга тиешле табигый хәл буларак кабул кылдык. Киләчәктә дә шагыйрьгә иҗади уңышлар юлдаш булсын, шигъри Тулпарының пар канатлары талмасын!

*1990, апрель*

[1] Кульъязма Р. Әхмәтҗановның шәхси архивыннан алынды.— *Төз.*

# Шагыйрьнең уңышлары

Нури Арсланов

«Карачкы»! Хикмәт бу кушаматның кайчан һәм кайдан килеп чыгуында түгел, ә аның поэмада символик сурәт булып күз алдына килеп басуында. Һәм образның җирнең алтыдан бер өлешен биләп торган мәмләкәттәге миллионлаган халыкларның уртак сурәте булып күтәрелүендә.

Илебез ярты гасырдан артык дәвер буе торгынлыкта иңрәп, фаҗигале халәттә яшәде. Күп корбаннар бирде. Күп югалтуларга очрады. Мәдәният һәм икътисад бөлгенлеккә килде. Шәхес үзенең аңын, иманын, нәселен җуяр хәлгә җитте. Ә кайберәүләр, әлеге поэмадагы шикелле, «Карачкы»га әйләнде. Кешеләр бер-берсеннән шикләнеп, куркып, сакланып яши башладылар... Максатыбыз изге булса да, аңа бару юлы явызлыкка таба юнәлеш алды. Миллионлаган халык диктаторлар тарафыннан «халык дошманы»на әйләндерелде. Кешеләр хакыйкать белән хаксызлык арасында юлларыннан, уйларыннан язды. Өметләр ялган булып чыкты!

Хәзер инде, шөкер, илебездә башка җилләр исә, кеше хакын яклаучы яңа мөмкинлекләр туа. Шуннан файдаланып, элекке уе, фикере йозаклы әдәбият та илгә үз авазын ишеттерерлек итеп өндәү юлына басты. Бу темага язылган әсәрләрдә бигрәк тә шагыйрьләр зур активлык күрсәтә башладылар. Арада һәлакәтләрне ачып сала торган, шәхеснең горурлыгын аңлата торган, гади генә итеп әйтсәк, халыкның күзен ачкан, күңелен яңа үзгәртеп корулар мәйданына өндәгән әсәрләр дә, бәхеткә каршы, барлыкка килә.

Менә шундыйлардан — «Карачкы» поэмасы. «Казан утлары»ның 1989 елгы 12 нче санында чыккан бу әсәр башта миндә беркадәр сәер хисләр уятты. Поэма кадәр поэмага ник мондый исем бирелгән? Әллә сатирик әсәр микән, дип уйладым. Әмма мин ашыкканмын: эчкә кергән саен, шагыйрьнең теләге ачыла бара икән. Ул йөрәгеннән сыкрап чыккан сагышларын, мәхәббәт һәм нәфрәтләрен бик гади сурәт итеп чагылдырырга теләгән, торгынлык шартларында карачкыга әйләндерелгән шәхесне бөтен илгә хас булган сурәт итеп — бербөтен сурәт итеп гәүдәләндерүгә ихлас күңелен куйган һәм шуңа ирешкән!

Шагыйрь Рәшит Әхмәтҗановның каһарманнары ниләр генә күрми?! Төрек Садыйк белән Әменнең бәхетсез мәхәббәте дә, ирнең сөргенгә китеп, аерылышулары да, Идел буендагы ачлык еллары да, Әменнең, ач улына кырдан бер уч арыш алып кайтып, авылдан сөрелүе дә, Карачкының «төрек шпионы» дип Себер китүе дә, бала елавын ишетүе дә, Карачкының «палач» янына килүе дә... Ниһаять, аның «оран салуы» да... болар барысы да нәкъ безнең ил халкы язмышы, барысы да еракларда ятып калганнар һәм тере калганнар кичереше, аларның кыйналуы, газаплануы, мәңгелек сагышы. Шушы илләр һәм халыклар фаҗигасе шагыйрь Рәшит Әхмәтҗановның «Карачкы» поэмасында бик оста сөйләп бирелгән. Шул темага моңа кадәр язылган әсәрләрнең киң колачлысы, иң зур планда сурәтләнгән үзәк өзгеч картинасы дип атар идем мин бу поэманы.

Әсәрнең язылу планы да игътибарга бик лаек: анда җыйнак һәм тирән фикерле, аерым исемле бүлекләр дә төгәл бер әсәрнең баскычлары булып, үзенчәлекле алым белән язылганнар. Мәсәлән, поэмадагы: «Әменнең туган илен сагынуы», «Карачкының анты», «Карачкының таң атканда ишеткәннәре» кебекләр. Гәрчә алар барысы да диярлек мөстәкыйль шигырь вазифасын үти алсалар да, бер-берсе белән сюжет тезмәсенә тәсбих төймәләре кебек тезелгәннәр.



**Сулдан уңга: Рәшит Әхмәтҗанов, Нури Арсланов, Барлас Камалов. 1990**

Кыскасы, шагыйрь Рәшит Әхмәтҗанов яңа, яхшы поэма язган. Мин аның иҗатын күзәтеп барам: аның һәрбер яңа китабы яңалыклар, үсеш адымнары белән алга атлый. Әдәбият-сәнгать кешесе өчен үсү – яңара бару – яшькә карамый, андый кеше актык сулышына кадәр эзләнүдән, үсүдән туктамый. Безнең Рәшит Әхмәтҗанов та шундый шагыйрьләрнең берсе. Шуңа күрә дә аның 30 еллык иҗади хезмәт дәверендә чыккан китаплары – эзләнүләрдән, үзенә карата таләпчәнлектән читтә калмаган, хезмәт борчулары, уңыш шатлыклары белән бергә үрелеп үскән җимешләр.

Бу яктан шагыйрьнең иң соңгы китабы – «Йөрәк бәйрәме» һәм «Бишташ» поэмасы да дикъкатьне үзенә аеруча җәлеп итә. Анда шагыйрьнең ихлас лирикасы да, көләч юморы да һәм, ниһаять, заманга аваздаш сәяси шигырьләр дә үз ноталарында хаклык, азатлык моңнарын җырлап торалар.

Лауреатлар билгеләгәндә, гадәттә, авторның китап булып формалашкан соңгы әсәрләрен алалар. Ә, минемчә, бу мәсьәләдә авторның бөтен булган кадәр иҗаты күздән кичерелергә тиештер кебек. Шуңа күрә дә мин, бу мәкаләмне язганда, сүзне шагыйрьнең әле китап булып чыгарга өлгермәгән әсәреннән башладым. Минем стандарттан беркадәр читкә чыгуым Рәшит Әхмәтҗановның 1990 елда Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты булуына, әлбәттә, зыян китермәстер дип уйлыйм.

Шагыйрь бу зур бүләккә лаек. Әле күп әсәрләре белән киләчәктә дә безне шатландырачагына иманым камил, өметем зур!

*«Социалистик Татарстан» газетасы.– 1990. – 1 апрель*

# Яратыгыз аны!

Кояш Тимбикова

Рәшит Әхмәтҗан шигырьләрен укыганда, күңелемдә халкыбызның моңлы җырлары яңара. Ул шигырьләр үзләре үк — безнең халык, туган җир, Ватан турындагы җырларга тиң. Шагыйрьнең кайсы әсәрен генә укысаң да, кыска дүртьюллыкларынмы, озын поэмаларынмы — һәрберсендә туган ил, халык язмышына кагылышлы тирән тарих авазын ишетергә мөмкин.

...Җырласам әгәр, таң ата, диеп,
Таң кайгыларны тарата, диеп,
Уйла син, җирем, кайгысы белән
Бу балам мине ярата, диеп.

Бу иҗат бакчасы милли шигъриятебезнең киң колачлы, күп төсмерле бер тармагын тәшкил итә. Шуңа өстәп аның тагын бер үзенчәлеген күрсәтергә кирәк: әлеге сихри бакчада барысы да табигый, үз, җанга якын.

Рәшит Әхмәтҗан үзенең шигъри образлары өчен ифрат ачык төсләр таба белә, әйтерсең лә ул аларны табигатьнең үзеннән — урман-кырлардан, елга-диңгезләрдән, күк киңлекләреннән күчереп кенә ала. Образларның гадилеге, аңлаешлы булуы исә шагыйрьнең халыкчанлыгында, бөтен омтылышларының халыкныкы белән тәңгәл килүендә.

Иҗаты алдына куелган бурычларны чишкәндә, шагыйрь көтелмәгән нәтиҗәләр дә ясый:

Сагышларымнан — сары нур булдым,
Кайгыларымнан — кара нур булдым.
Нурсыз дөньяга нур булып тулдым,—
Кемнәрдер уйлый, имеш, хур булдым.

Шагыйрь Рәшит Әхмәтҗан шактый катлаулы тормыш юлы узган. Күп балалы гаиләдә туып үскән авыл малае ул. Җидееллык мәктәпне тәмамлагач, аңа төзелештә ташчы булып эшләргә туры килә. Шигырьләрендә ташчылар образына, ташларга еш мөрәҗәгать итүе дә, хәтта ташчы горурлыгы да, мөгаен, шуннан киләдер.

Аңа шулай ук ир-егетне сыный торган тагын бер юлдан — Совет Армиясе сафларында гаскәри хезмәт юлыннан да узарга туры килә. Бу изге бурычны да шагыйрь исән-имин һәм җанына тагын да кыйммәтлерәк «байлык» туплап үтәп чыга. Армия газетасында аңа багышланган зур мәкалә басыла, туган ягына, илгә тугрылыклы ул үстергән газиз әнисе исеменә командирларының рәхмәт хатлары ява. Сабый чагында сугыш елларының кырыслыгын, кимсетелүле чикләүләрен кичергән шагыйрь җанлы егет армия сафларында башкача хезмәт итә аламыни соң?!

Армиядән соң Рәшит Әхмәтҗан, Казан дәүләт университетында укып, югары белемле әдәбиятчы була, редакцияләрдә эшли башлый, «Яшь ленинчы», «Татарстан яшьләре» газеталарында аның ялкынлы публицистикасын әле дә яхшы хәтерлиләр. Хәзер исә ул «Казан утлары» редакциясендә бүлек редакторы булып эшли.

Редакцияләр — тормыш хәлләренең өзлексез кайнап торган ноктасы. Бәлки, шуңа күрәдер Рәшит Әхмәтҗанга безнең кешеләрнең көнкүреше дә, уй-тойгылары да, өмет-максатлары да яхшы таныш. Бу якынлык аңа әсәрләрендә гадиләрнең эчке халәтен, омтылышларын, борчуларын



**Җанлы әңгәмә. Сулдан уңга: Рәдиф Гаташ, Рәшит Әхмәтҗанов, Диләрә Зөбәерова, Кояш Тимбикова**

яктыртырга мөмкинлек бирә. Аның шигырь һәм поэмаларында хезмәт кешесенең тормышка мөнәсәбәте, дөньяда үз урынын яулау өчен алып барган көрәше тасвирлана.

Шагыйрь әсәрләрендә генә түгел, чынбарлыкта да — ялкынлы көрәшче. Беләсездер: бездә 1988 елны «Татар иҗтимагый үзәге» дигән бер хәрәкәт башланып китте. Мондагы көрәшчеләрнең төп максаты — Татарстанны мөстәкыйль дәүләт итеп үзгәртү. Бу юлда күп нәрсә эшләнде дә инде: 1990 елның 30 августында Татарстан Югары Советы сессиясе республиканы суверен дип танучы Декларация кабул итте. Матди мөстәкыйльлек өчен көрәш дәвам итә.

Шагыйрь Рәшит Әхмәтҗан — Татар иҗтимагый үзәгенең иң актив әгъзаларыннан берсе. Ул әлеге хәрәкәттә үз җанында күптән яшәп килгән омтылышларны тормышка ашыру өчен җирлек таба кебек. Халыкта аның телен, тарихын, мәдәниятен саклап калу һәм тагын да үстерү өчен әлеге көрәшчеләр юлында атлауны ул үзенең беренче ихтыяҗыннан саный. Бу исә аның иҗатына да саф сулыш алып килде:

...Уяныгыз! — Инде күптән
Узды күз йомар чаклар.
Күзеңне йомсаң, шул йокы
Илеңне дә кочаклар...

Кадерле балалар! Шагыйрь Рәшит Әхмәтҗан сезне бик якын күрә, ул сезгә йөрәк түреннән, җанын ярып чыккан хисләрен бүләк итә. Сез дә аны яратыгыз, кадерләгез!

*«Яшь ленинчы» газетасы.— 1991. — апрель*

# Шагыйрь белән сөйләшү

*(Рәшит Әхмәтҗанов белән әңгәмә)*

Рабит Батулла

Тынлыктан соң давыл, давылдан соң тынлык – гел шулай дәвам итәчәк. Әдәбият диңгезендә дә нәкъ шулай: тынлык давылны әзерли, давылдан соң тынлык урнаша. Давыл булып Тукай калыккан. Яшен булып Такташ яшьнәгән. Өермә булып Туфан әдәбият мәйданын иңләгән. Шуннан соң – тынлык. Озакка сузылган шомлы тынлык. Әмма әдәбияттагы бу шомлы тынлык поэзия давылын әзерли алмады. Бу чор татар әдипләрен, сәнгать эшлеклеләрен күпләп кулга алу вакытына туры килә. Дөрес, әдәбият юкка чыкмады. Әйбәт кенә шагыйрьләр берәмләп-берәмләп мәйданга килгәләде, ләкин давыллы каләмнәр булмады. Сугыш чоры, сугыштан соңгы афәт, сугыш романтикасы, индустриаль корылыш шагыйрьләре Кәрим, Җәлил, Кутуй, Хәким, Давыдов, Афзал, Юзи, Шәүкәтләр буыныннан соң ярый әле Әхмәтҗан (Роберт) берүзе калыкты. Аннан соң тагын тынлык, вә бер-бер артлы дистәләп шагыйрь пәйда булды! Равил, Рәдиф, Рөстәм, Гәрәй Рәхим, Харис, Мөдәррис, Зөлфәт, алардан чак кына алдарак Әхмәтҗан (Рәшит)...

Ни сәбәптәндер, бу елларда мәйданга чыккан шагыйрьләрне санаганда, Рәшит Әхмәтҗан исеме гел азактарак әйтелә килде яки бөтенләй әйтелми иде. Үзара әйтмешли, аның исеме «обойма»га керми иде. Ул вакыттагы тәнкыйть гел бер үк исемнәрне тәгәрәтә торды. Тәнкыйтьчеләр алар шундый халык, үсәрдәйрәк бер язучыны сайлап ала да гел шуның тирәсендә бөтерелә башлый, кырда, янда, түрдә калган шәп шагыйрьләр игътибардан төшеп кала килде. Мәсәлән, Зиннур Насыйбуллин, Эдуард Мостафинның гаҗәеп моңлы фикерле иҗатларын тәнкыйтьчеләр күрмәде, күрергә теләмәделәрме? Рәшит Әхмәтҗан белән дә шул ук хәл. Әлбәттә, шәхеснең үзеннән дә тора, еламаган балага имезлек каптырмыйлар. Үзегез беләсез, әшнәлек оештыра алмаучы шагыйрьләр шулай тыйнаклык эчендә яши. Әмма иҗатның саф, олы икәнен («обойма»га кермәсәң дә, әшнәлек кора белмәсәң дә), сине танырга мәҗбүр булачаклар. Күкләргә чөймәсәләр дә, Рәшит Әхмәтҗанның зур шагыйрь икәнен бүген берәү дә инкяр итә алмый.

1970 еллар башында аулак бер чарлакта көн саен диярлек бер төркем яшь шагыйрьләр, сәнгатьчеләр мәҗлесе була иде. Бу чарлак Рәшит Әхмәтҗан бүлмәсе иде. Давыл шагыйрьләре кичләрен, төннәрен Рәшит янына җыела иде, бу үзенә күрә татарның «поэзия салоны» ролен үти торган иде. Шул мәҗлесләрнең берсендә шигырь турында сүз чыккач, мондый сүз әйтелде:

– Килер вакыт, Рәшит шигырьләрендәге моң сезнең фәлсәфи фикерләрегездән өстен чыгачак!

Бу әүлиялык рас килдеме икән, юкмы икән, анысын моңа кадәр Рәшит иҗатын күрергә теләмәгән тәнкыйтьчеләргә калдырыйк, әмма Рәшит Әхмәтҗан шигырьләре, поэмалары күңелләрнең иң нәзек кылларына кагылмый калмый – ул шигырьләрдә халык язмышы, халык аһ-зары, халык моңнары, халык өметләре.

*– Рәшит дус, синең иҗатың шаулы вә шәрәфле исемнәр белән уралмаган. Әмма син барыбер үз мәсләгеңә тугры калдың. Шулай да әйт әле, ул исем-бүләкләрне башкаларга тапшырганда, син нинди халәттә була идең?*



**Әдәбият һәм сәнгать һәрвакыт янәшә! Сулдан уңга: Рәшит Әхмәтҗанов, Әдип Маликов, Роберт Миңнуллин, Галина Казанцева, Хәйдәр Бигичев, Рөстәм Кутуй, Равил Фәйзуллин, Рафаэль Сәхәбиев, Зилә Сөнгатуллина**

— Лаек кешегә бирелсә, ихлас сөенәм, «урлап» алганнарга карата мин бер генә сүз әйтәм: булдыралар, чукынганнар!

— *Без — торгынлык корбаннары...*

— Торгынлык-торгынлык, дибез, сүгәбез, дөрес сүгәбез. Тик шушы торгынлыкта татар әдәбияты, сәнгатенә өерелеп, өермә булып, үзең әйткәнчә, давыл булып олы талантлар килде. Һәрберсе — бер дөнья. Кабатланмас шәхесләр: шагыйрьләр, драматурглар, артистлар, музыкантлар, рәссамнар. Шул чорда иҗат юлы алдылар, шул чорда өлгерделәр, бүген бөтен әдәбият-сәнгатьне алар тартып бара.

— *Чыннан да, рәхимсез цензура чорында сез, шагыйрьләр, иҗат башладыгыз, шагыйрь булып өлгердегез. Өстәге цензура гына түгел, шагыйрьнең үзенең миендә дә цензура утыра иде, шагыйрь ни уйлаганын үзе язмый иде. Гарип шигырь язганың булдымы?*

— Юк! Шигырь йә бар, яисә ул юк. Син гарип санаган тезмәләр алар шигырь түгел. Шуннан килеп чыга ки «начар шигырь», «яхшы шигырь» атамалары. Шигырь бар икән — инде ул яхшы дигән сүз. Начар шигырь була алмый, начар икән инде, ул шигырь түгел. Миңа калса, торгынлык чоры акыллы фикерле шагыйрьләрне «тел төбе, киная, ишарә вә юл араларына» яшеренергә мәҗбүр итте. Шул фикерләр, астыртын уй моңга төрелсә, чын поэзиягә әйләнә. Шуңа күрә татар әдәбиятында шигырь гел алда булды. Димәк ки, чын поэзия булсын өчен, шагыйрь өстендә кылыч-цензура торырга тиеш?

— *Җәлил балта астында үзенең шигъри һәйкәлен салды. Туфан күкрәгенә мылтык терәгәндә иҗат итте... Безнең өстә дә цензура — КГБ тукмагы гел эленеп тора иде, әле дә булса ул күсәк алынмаган кебек... Син үткәнеңә борылып караштыргалыйсыңмы?*

— Бөтен язганнарымны баштанаяк тикшереп чыктым. Мин шигыремдә ялганламаганмын, шөкер. Бер китабымны да коммунизм, партия дип башламаганмын. КамАЗ, нефть, атом электр



**Рәшит Әхмәтҗановның остазы Хәсән Туфан Матбугат йортындагы Тукай клубында**

станциясе дип әсәрләр язып, кешеләр олы исемнәр алды. Татарны суырып сытарга куелган бу аждаһаларны мактап бер юл да шигырь язмаганмын икән, мең шөкер. Мин партияне дә, халыкны да, үземне дә алдамаганмын.

— *Чыннан да, поэзия гел алда булды. Талантлар берьюлы килде. Шунысына сөенә идем, шагыйрьләр бер-берсенең иҗатын нык белә, һәр шигырь өчен, һәр яңа талант өчен куана иде. Тагын шундый бер күтәрелеш-яңарыш поэзиядә булыр дип уйлыйсыңмы?*

— Хатын-кызлар күпләп килер шигырьгә. Әмма дистәләгән ир-ат шагыйрь бергә килү көтелми. Гомумән, шигырь язучыларның хәле өметле түгел. Читтәге чишмәләр корыды. Хатын-кыз күңелендә аналардан күчкән моң сакланган әле. Моның үз сере бардыр.

— *Синең остазың кем?*

— Хәсән Туфан! Мин илаһи сын итеп башка бер генә шагыйрь алдында да баш имәдем. Кемдер: Такташ, Җәлил, Есенин, ди. Мин: Туфан, дим. Харис әйтә: Есенин дөньяның бөек шагыйре, ди. Мин әйтәм, Туфан кай җире белән аннан ким? Туфан хәтта бөегрәк тә, дим. Мин дә бик күп яхшы шагыйрьләрне укыдым, өйрәндем һәм хөрмәт итәм, билгеле.

— *Бүгенге шигырьгә ни җитми?*

— Моң! Моң җитми шигырьгә. Шигырь ул — җыр. Бөек фикерләр язып була торгандыр, моң булмаса, ул фикер шигырьгә әйләнә алмый, ул бары тик политикага гына әверелә.

— *Ышанычың кемнәргә?*

— Эдуард Мостафин гел читтә. Әрсез түгел. Иҗаты олы, әле тагын да ачылачак, аның потенциаль шигъри куәте әле поэзиябезгә гүзәл әсәрләр тапшырачак. Нияз Акмал — шәхес, шагыйрь. Ул да үз сүзен әйтә килә. Тик шигырьдән читләшмәсен иде... Тагын да яшьрәк шагыйрьләр бар: Ләис, Ркаил, Газинур, Сүлти, Илсөяр Иксанова. Болар да олпат шагыйрь булып бара. Яшьләрдән иҗат батырлыгы көтәм.

— *Син конкрет, практик эш дип нәрсәне күз алдында тотасың?*



**Рәшит Әхмәтҗанов – сулда**

– Язучының, артистның эше – иҗат итү. Ләкин бүген язып кына утыра торган вакыт түгел. Азатлыгыбыз кыл өстендә. Урамга чыгарга кирәк! Балта күтәреп түгел. 30 августта Ирек мәйданында халык «азатлык» дип кычкырмаган булса, безгә кәгазьдәге суверенитет та тәтеми иде. Кирәге чыккан саен, татар халкы мәйданга күпләп тупланырга тиеш, менә шул булыр бүгенге конкрет эшләрнең берсе. Ә без башкарасы санап бетергесез эшләр безнең егетләрне көтеп тора.

– *Иҗади өметләрең?*

– Җиреннән, нәселеннән, теленнән аерылган татар баласының язмышы – «Кайгы йомгагы» дигән поэма язам. «Шигырь китапханәсе» рәтендә минем дә кулга тотып карарлык китабым чыгып килә.

– *Сайланма әсәрләрме?*

– Әйе. Анда шигырьләрем, җырларым, балалар өчен шигырьләрем, дүрт поэмам кергән. Бу минем бөтен иҗатыма йомгак ясау. Гомеремнең икенче яртысында тагын шундый бер китап иҗат итә алсам, җаным тыныч булыр иде.

*«Әллүки». – 1991. – 12 апрель*

# Агым – яшәү, шигърият – яшьнәү

*(Рәшит Әхмәтҗанов белән әңгәмә)*

Нәҗибә Сафина

*– Сәбәп итмәсәң, насыйп булмый, диләр. Сөйләшергә форсат чыгуга – Сезгә 50 яшь тулуга – мин бик шатланып куйдым әле. Ярты гасыр шагыйрь гомере кичкән Кешегә сорауларым бар. Җавапларны шигъриятегезне сөючеләр, хәтта сөймәүчеләр дә – дусларыгыз, дошманнарыгыз укысын иде дип, аеруча яшьләр укысын дип, яшьләр газетасына бирәм.*

*Рәшит әфәнде, сез кырык беренче ел балалары бит инде. 1940–1950 еллар сезнең җаннарга гомерлеккә кереп калган. Ул еллар сезнең аша да үткән. Аларны ничек кичердегез?*



**Ике туган балалары: Рәшит һәм Роза. 1963, февраль**

– Нәкъ шул еллардагы кичерешләрне саклау мине шагыйрь иткәндер дә, бәлки: шактый авыр чорны сабый җаны аша уздыру уен эш булмады. Шулай да без – ул чор сабыйлары – бәхетле җаннар булганбыз әле. Сабыйлык белән бик күп фаҗигаләрне җиңелрәк кабул иткәнбез. Ачлык, ачтан үлү, черегән башак бөртекләреннән, бәрәңгедән агуланып үлү... Болары өчен әниләребез кайгырган, без сизмәгәнбез. Ә шулай да кеше гомеренең һәр минуты кыйммәтле, сагышлы, шатлыклы, җырлы. Фаҗига дәвам итә: авыр бала чакны никтер җан сагына. Моның ни өчен шулай булуын үзем дә аңлап бетерә алмыйм.

Мин үземнең «Бишташ» исемле поэмамда шундый халәтемне сурәтләргә тырышып караган идем каравын... Бу сорау бик зур – газета битләре генә җитми аны сөйләү өчен. Бәлки, кеше гомере дә җитмәс.

*– Сез шигъриятькә XX съездан соңгы «язгы җилләр исә башлау» чорында килдегез. Университетта да шул чор яшьләре белән бергә укыдыгыз, иҗат иттегез. Ул чор яшьләре белән ул чактагы мөнәсәбәтләрегезне яхшы хәтерлим. Сез аларның халык уллары булып формалашуына үзегезнең ихлас иҗатыгыз белән зур йогынты ясадыгыз. Хәзер алар белән мөнәсәбәтегез ничек?*

– Әйбәт кебек. Тик бу сорауга җавап бирмәү гаделрәк булыр иде: минем белән аралашучы яшьләр үз сүзләрен үзләре бирәр вакыт әйтерләр әле миңа карата.

*– Халыкның кайсы буынына аеруча инәлеп дәшәсез бүген, кемнәрнең сезне ныграк ишетүен телисез?*

– Һәрбер әти кеше кебек, кызым Ләйлә (ул медицина институтында укый), улым Айдарның (10 нчы сыйныф шәкерте) минем җанымны ишетүләрен телим, әлбәттә. Болай дип әйтүемне яшьләргә, балаларга өметемне баглау дип аңласыннар иде. Яшьләр – алар минем бүгенгем һәм киләчәгем. Иҗатым алар кулына калачак. Аларга өметем зур – халкыбызның меңәр ел буена кан коеп, башларын салып саклап калган рухи байлыгын ишәйтерләр әле.

Яшьләргә тагын әйтәсе килгән сүзем шул: яши торган дөньябыз бик катлаулы. Үсеп җитеп, кайда гына булсагыз да, беркем, берни алдында кимсенмәгез – бөек халкыгыз бар. Беркемне дә

кимсетмәгез — халык намусына тап төшмәсен. Безнең халкыбыз беркайчан да беркемне дә таламаган.

*— Таламаган дигәннән, узган ел «шагыйрь Рәшит Әхмәтҗановны урамда чишендергәннәр» дигән сүзләр йөргән иде. Гайбәтме бу, әллә гыйбрәтме?*

— Кызганычка каршы, гыйбрәт шул. Өем янында гына затлы бүрегемне, җылы пирчәткәләремне салдырып алдылар.




**Рәшит Әхмәтҗановның әнисенә бүләкләре. 1965**

Әле тагын бер әкәмәт булды. «Кешене эт талаган» дигәнне ишеткәнем бар иде, тик бу юлы минем этемне кешеләр талаган булып чыкты. Йөреп керсен дип, этләр йөри торган мәйданга чыгарган идем, менә дигән муенчагын салдырып алып калганнар. Совет кешеләренең бөтен нәрсәсе уртак булырга тиеш, дип юаттым үземне.

*— Күп шагыйрьләр хәзер «яфрак астына» качып кына иҗат итәләр. Аларның күбесе митинглардан, халык җыеннарыннан читтәрәк йөргән бер заманда сез вакыйгаларның үзәгендә булдыгыз, ялкынлы чыгышлар ясадыгыз. Нинди максат, нинди ышаныч алып чыкты сезне мәйданнарга?*

— Бер генә мизгелгә дә күзебезне йомарга ярамый хәзер. Чөнки «елан йокласа да, дошман йокламаган». Уяулыкны тагын да арттыру өчен, алдан әйткәнемчә, йөрәкләрне канаткан хәбәрләр турында бүген сөйләшергә-киңәшләшергә тиешбез.

*— Аларның үзәгенә ниләр яшеренгән соң?*

— Татарлар үзара талаша башладылар. Судлашучылар да бар. Шул хәлләрне көтеп кенә торган шовинистлар, өлкә, край, республикаларның иң зур рус газеталарында озын-озын мәкаләләр басып чыгарып, болай дип әйтәләр: менә күрегез, янәсе, татарның иң зыялы кешеләрен! Күрегез аларның рухи дөньясын! Шулай дип, рус телендә бөтен дөньяга кычкыралар.

Без, татарлар, бу нәрсәләрне үзебез алданрак күрергә һәм бер йодрыкка йомарланып, мөстәкыйльлегебезне якларга тиешбез. Юкса безне бөтен тарих буенча шулай тарката килделәр. Аерылдык — аю ашады, бүлендек — бүре ашады.

Әнә шуларны уйлаганда, бүген һәр минутыбыз исәптә булырга тиеш. Һәр кеше һәр көнне ирегебезне яклауда бер гамәл башкарсын. Ә тавыш-гауга чыгарып, тәгәрмәчләргә тимер таяк тыгучылар хәттин ашкан.

Бүгенге кайбер акыл ияләребез үзләренең язган мәкаләләрендә халкыбызны наданлыкта, гамьсезлектә гаеплиләр. Юк, ышанмыйм мин аларга. Һәм сез дә ышанмагыз аларның сүзләренә! Күкрәгебездән йөрәгебезне тартып алсалар да, азатлыгыбызны яңадан тартып ала алмаслар. Халык зур ул, халык көчле ул. Халык — без ул. Халык җиңәчәк. Шундый уй-максат, ышаныч мәйданнарга чыгарга мәҗбүр итте мине.

*— «Шигырь китапханәсе» сериясендә «Моңлану» дигән китабыгыз дөнья күргән икән. Ник моңланасыз?*

— Халкыбыз язмышы — кара урман. Мин бүген шул кара урманда йөрим. Кеше үтеп керә алмаслык җирләренә җитәсе бар әле. Мин шул урманда үземчә моңланып җырлыйм. «Карурман» көен чыгарган бөек композиторны, шагыйрьне сагынам, аңа баш иям, рухына дога кылам.

*«Татарстан яшьләре» газетасы.— 1991*

# Күңел һәм җан сәфәре[1]

Равил Фәйзуллин

Бу китапка замана давылларын җанына яшергән ир-егет әдипнең дөньяга биргән күңел байлыгы, кешеләргә әйткән фикер-хикмәтләре, хис-моңнары тупланган.



**Р. Әхмәтҗановның тууына 75 ел тулу уңаеннан үткәрелгән кичәдә. Чыгыш ясаучы – Равил Фәйзуллин. Казан, Тукай клубы, 2016**

Укыйсың да ирексездән бу моңнарның чишмә башын эзли башлыйсың. Шагыйрь үз җиребездә – Баулы районы Татар Кандызы авылында туып үсә, күңеленә матурлыкны гомер буена җитәрлек итеп шунда ала. Аның сөйләгәне бар: имеш, борын-борын заманнарда, әле аларның авылларына яңа гына нигез салына башлаган чакларда, бу якларны кап-кара урманнар каплап торган. Кандыз елгасы, көмеш билбау шикелле, кара урманны икегә бүлеп аккан да аккан. Елганың бер ягыннан – Сакның, икенче ягыннан Сокның моңлы тавышлары ишетелеп торган... Җитте, шунда тукталып алыйк. Димәк, шагыйрьнең күңел һәм җан сәфәре әнә шуннан башланган. Канлы сугыш еллары хәсрәтен эчкән сабый – шул еллардан калган моңнар әсирлегендә яшәгән бала – үсә төшкәч – ташчы, аннан солдат, студент, журналист, шагыйрь, җәмәгать эшлеклесе – шагыйрьнең яшәү юлын әнә шул баскычларга бүлеп булыр иде.

Рәшит Әхмәтҗановның шагыйрь, һәм дә зур шагыйрь икәнен кешеләргә раслыйсы юк. Әмма аның шигъриятенең үзенчәлеген, нечкәлекләрен үзебезгә аңлыйсы, күпләребезгә төшендерәсе бар әле. Өч дистә елга якын ул шактый ук актив эшләп килсә дә, иҗаты турында әдәби җәмәгатьчелекнең төпле фикерен соңгы биш-алты ел эчендә генә ишетә башлады шикелле. Бу хәлнең сәбәпләре нидә? Бәлки, тәнкыйтьчеләрнең исемлек кысасына керә алмый калуындадыр? Бәлки, иҗатының артык үзенчәлекле булуындадыр? Яшермим, Рәшит Әхмәтҗанов дигән шагыйрь минем үзем өчен дә шактый ук «каты чикләвек» булып чыкты. Налим балыгы шикелле шома (яхшы мәгънәдә), тиз генә тоттырмый... аның шигъриятен «саңагыннан» эләктереп булмый... Шигырьләре техник яктан, Хәсән Сарьян «юнган агач» шикелле, бик нечкә зәвык белән эшләнгән; өстәвенә образ, чагыштырулар, эпитетлар һ.б. калфак чигешендәге энҗеләр шикелле бик мул сибелгән. Шагыйрьлекне аерым юл-строфалардан да тоеп була:

Муеныма аскан ташың – тау иде,
Мине тирән су төбенә салды ул.

[1] Рәшит Әхмәтҗановның 1958–1989 елларда иҗат иткән әсәрләре сайлап тупланган «Моңлану» (1991) исемле шигырьләр, поэмалар җыентыгына кереш сүз.



**Чыгыш ясаучы – Рәшит Әхмәтҗанов. Президиумда утыручылар арасында Роберт Әхмәтҗан, Марк Зарецкий, Роза Кожевникова, Мөхәммәт Садри, Рәдиф Гаташ, Шамил Маннапов, Ренат Харис, Мәгъсум Насыйбуллин, Фәннур Сафин, Рашат Низами, Шәмсия Җиһангирова бар**

Бүләк алып чыктым әле мин сиңа:
Сине сөйгәч – энҗе булып калды ул.

Рәшит Әхмәтҗанов – чын мәгънәсендәге татар милли шигъриятенең төп, дөрес юлында торучы шагыйребез. Ул – Р. Харис та түгел, Г. Рәхим яки Р. Мингалимов та түгел. Ихтимал, аны күпмедер дәрәҗәдә М. Әгъләмов белән параллель куеп буладыр. Аларның төп эчкән чишмәләре – халык иҗаты, татар халкының эстетик традицияләре. Биредә сүз иҗатчының юнәлеше, кыйбласы турында бара. «Һәр сүз миннән бер матурлык сорый, мин фәкыйрьмен – алыйм кайлардан?» дисә дә, шагыйрь, әйткәнемчә, сүзне, илһамны, җимне халык иҗатыннан, халык күңеленнән ала. Шуңа күрә дә аның шигырьләрендә безнең фольклорга хас бик күп традицион атрибутлар, образлар, тәгъбирләр тулып ята. Беренче карашка гади күренгән шигъри сүз-берәмлекләр, шагыйрь күңелендә үзгәртелеп, яңа төсмерләр ала, образ-фикергә әйләнә:

Урман эчләрендә урман шаулый,
Урын тапмый болан үзенә.
И болан...
Йә сугарлар балам күзенә дип,
Яфрак сибеп йөри эзенә.

Ачык аланнарда төлке уйный,
Урманнарга кача яшь болан.
Кил, болан...
Урманнардан берни урламаган
Соңгы җан иясе – мин булам.

Кызганыч, безнең бүгенге яшьләребезнең күбесе халык иҗаты белән җимләнеп үсмәгәнгә, шагыйрь күңеле тудырган гаҗәеп бай һәм тылсымлы дөньяны тиешенчә танып, эстетик ләззәт ала алмый. Шәхес культы һәм торгынлык елларында бер-ике буын милли укучыларыбызны югалттык. Шулай да, үзебезне юатып, үзгәртеп коруларның нәтиҗәсе яңарышларга китерер дип өметләник.

Рәшит, үзенең шигърият өчен яратылганын сизеп микән, бүтән жанрларга сибелмичә, фәкать поэзиядә генә эшләп килә. Ул бу яктан күпмедер дәрәҗәдә Х. Туфан, С. Хәким, Н. Арслановлар юлы белән китте. Бөтен җегәрен бер ноктага – бу очракта поэзиягә юнәлтү, табигый, аны бу өлкәнең чын остасы итә. Шуңа күрә дә Р. Әхмәтҗанов, Фәйзулла Туишев, Фәйзи Биккениннар гармуннарның теләсә нинди төрендә уйнаган шикелле, шигырь жанрының теләсә кайсы биләмәләрендә виртуозларча иркен эш итә: шигырьләрнең, озынын яки кыскасын булсын, менә дигән итеп коеп куя, поэмаларны да оста үреп чыга, моңлы яки дәртле җыр текстларын да үзенчәлекле итеп яза. Әйтик, шагыйрьнең «Акчарлаклар»ы классик җырлардан саналырга



**Ипи-тоз һәм ачык йөз. Сулдан беренче Нәби Дәүли, аның янәшәсендә Рафаэль Мостафин һәм Рәшит Әхмәтҗановлар**

хаклы дип уйлыйм. Балалар өчен дә җыйнак һәм тәрбияви әһәмиятле итеп яза белә. Бу китапта шагыйрь поэтик иҗатының бөтен кырлары шактый тулы чагылыш таба.

Чын иҗатчының асыл табышларын үз бизмәнеңә салып үлчәп бәяләү кыен. Кемдер әйтмешли – шагыйрьлек булса була, булмаса булмый инде ул. Биредә Рәшит талантының олылыгын дәлилләгән йөзләрчә, хәтта меңнәрчә уңышлы мисаллар китерергә мөмкин булыр иде. Әмма бу очракта андый детальләштерүләргә мохтаҗлык юк шикелле. Шигырьләрнең күпчелеге теләсә нинди нечкә зәвыклы укучыны канәгатьләндерерлек.

Поэмалар дигәннән, алар дүртәү: «Язлар быел соңга калды», «Исәннәр моңы», «Бишташ», «Аучылар кибетендә». Соңгы икесе авторның гына түгел, гомумән, поэзиябезнең табышы саналырлык поэмалар. Бер караганда, бу поэмаларның сюжет җепләре өзелеп-өзелеп киткәндәй тоела. Алай түгел икән шул. Ул җепләр үзәк өзгеч моң белән тоташтырылганнар. Моң сихеренә ия булган шагыйрьнең үзенчәлеге, иҗади табышы итеп кабул итәргә кирәк моны.

Р. Әхмәтҗанов – үзендә шагыйрьлек куәсе булган өчен генә иҗат итә торган кеше түгел. Ул – ил тарихы, халык язмышы, аның бүгенгесе һәм киләчәге турында борчылып, әрнеп иҗат итүче шагыйрь. Шигырьләрендә әчке моң саркып тора. Күңелдә бар булганны ачыктан-ачык әйтергә мөмкинлекләр җитмәгән очракта (торгынлык елларында язылган шигырьләрен күздә тотып әйтәм), иҗатчы бүтән юлны сайлый – кинаяләр, катлауландырылган образлар аша тасвир итә. Тик шунысы хак: Рәшит Әхмәтҗанов нәрсә турында гына язмасын – авыр тойгылы уйлармы алар, якты-дәртле хисләрме – Шигъриятнең Матурлыкка һәм Гаделлеккә хезмәт иткәнен бер генә минутка да онытмый.

Шагыйрь күңеле үз халкының бөтен тарихын хәтердә тотып иҗат итә. Хәтерсезләрне уятыр өчен нәкъ менә шундый шагыйрь кирәк булгандыр да әдәбиятыбызга.

Шагыйрьнең күңеле тарихны тыңлый, җаны киләчәкне сагына. Ул шулай, Сак белән Сокны кавыштырырлык итеп, яңа шигырьләр язу турында хыяллана.

# Бердәнбер юл түгел[1]

Фәнзаман Баттал

Адәм баласын үзе теләп дөньядан китүгә, үз-үзен корбан итүгә мәҗбүр итәрдәй көчләр икәү генә: Мәхәббәт һәм Нәфрәт. Әгәр кешенең биниһая мәхәббәтенә, якты хисләренә, изге теләкләренә бертуктаусыз киртә куеп киләләр икән, ул яшәүдән мәгънә тапмый башлый, дошманын җиңү хакына гомерен бирә...

Без 1991 елның язында, ямьле май аенда, шундый вакыйганың шаһитлары булдык: Милләтебезнең ике дистәгә якын улы һәм кызы газиз Ватан — Татарстан хакына Үлем мәйданына чыктылар. Дөрес, алар берниндн икеләнүсез үлем кабул итәргә чыккан мәйдан «Ачлык мәйданы» дип йөртелде ул көннәрдә. Ләкин, әгәр татар халкы үз максатына ирешә алмаган булса, бу фидаи җаннар Газраилне шунда каршылаячак иде!

Һәркайсыбызның хәтерендә: кара көчләр, сәясәт кыясына үрмәләүче куркак җаннар, Татарстанны киләчәк гасырларда да Рәсәй империясенең койрыгына тагылган дегет чиләге итеп күрергә теләүче шовинистлар мөстәкыйльлек игълан иткән Ватаныбызда Империя Президентын сайлату карары чыгардылар. Милләтне уятырга, айнытырга, Ил өстенә янаучы куркыныч һәм җирәнгеч афәттән саклануга туплау кирәк иде. Әлеге фидакярләр үз иңнәренә шундый олуг йөкне салдылар.



**Милли Мәҗлеснең 2 нче чакырылыш сессиясендә. 1994, 26 май**

Ул көннәрдә кояшның да берөзлексез шушы мәйдандагы хәлләрне күзәтәсе килде сыман: күк йөзе чалт аяз, түзеп тормаслык эссе, дөнья яшеллеккә төренә, түтәлләрдә чәчәкләр баш калкыткан. Әмма татар халкының коллык елларында да Ирек мәйданы дип йөртелгән бу мәйданда табигать яме белән хозурлану юк. Чөнки ачлык кабул иткән унтугыз җанның өзелү куркынычы бар.

Коллык йокысыннан көннән-көн айный, вакыйганың асылын аңлый башлаган халык мәйданга җыела. Ике-өч мең кеше... Ун мең... Егерме биш мең... Утыз мең... Илле мең! Халык курыкмаска, курыкмыйча яшәргә өйрәнә. Казанның үзеннән дә, республиканың барлык төбәклә-

[1] «Ачлык мәйданы» (1993) китабына кереш сүз.

реннән дә милләттәшләр шушы изге дә, каһәрле дә үзәккә агыла: «Фидаиларның хәлләре ничек, барысы да исәннәрме әле?» Һәр караш Ватанпәрвәрләрдә. Әнә алар:

Фәүзия Әүһади кызы Бәйрәмова – язучы, Татарстанның халык депутаты, «Иттифак» фиркасе рәисе, Казаннан.

Рифкать Гайнетдин улы Шәмсетдин – Алексеевск районы Әшнәк авылы егете, механизатор.

Зиннур Гайнетдин улы Шәмсетдин – Рифкатьнең абыйсы, шул ук районнан, шул ук авылдан, һөнәре дә шул ук – механизатор.

Зәки Лотфулла улы Зәйнуллин – язучы, техник фәннәр докторы, отставкадагы полковник, «Мәрҗани» җәмгыяте президенты. Казанда яши.

Заһид Борис улы Мәхмүди – язучы, журналист. Казанда яши.

Рәшит Хәниф улы Әхмәтҗан – шагыйрь, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Казаннан.

Илдус Хәниф улы Әхмәтҗан – Рәшитнең энесе, Татарстанның атказанган артисты, Муса Җәлил бүләге лауреаты. Казанда яши.

Зөфәр Кашшаф улы Сәлиев – сугыш ветераны, мөгаллим, җәмәгать эшлеклесе. Казанда яши.

Нәкыя Зиннурова – мөгаллимә. Алма-Ата каласыннан.

Сәлим Габдрахман улы Әбү-Бәкер – сугыш ветераны. Алма-Атадан.

Әнисә Мәгъсүмҗан кызы Нурисламова – мөгаллимә. Чаллыда яши.

Гөлсирә Нуриҗан кызы Лотфуллина – хисапчы. Чаллыда яши.

Гөлнур Миңнегали кызы Хәйруллина – тәрбияче. Чаллыдан.

Абдул Алмаз углы – дин әһеле, Азәрбайҗанның халык депутаты. Баку шәһәреннән.

Фазыл Абдулла улы Вәлиәхмәт – мөгаллим, журналист. Карабаштан.

Әхәт Хәй улы Мушинский – язучы. Казаннан.

Газинур Васыйк улы Морат – шагыйрь. Казанда яши.

Марат Мирзазаһит улы Арсланов – «Тәүбә» җәмгыяте рәисе. Чаллыда яши.

Шәкүр Шәйдулла улы Вафин – КамАЗ эшчесе. Чаллыда яши.

Бу исемлекне тулаем язуыма сәбәп шул: минем ышануымча, алдагы гасырларда нәкъ шушы мәйданда, ошбу улларына һәм кызларына багышлап, халык һәйкәл салачак, аларның исемнәрен алтын хәрефләр белән шул һәйкәл мәрмәренә уячак. Шунсыз булмый! Чөнки үз көрәшчеләрен оныткан халыкның бәйсезлеккә, азат яшәүгә хакы юк!

Инде кулыгыздагы китапны ачар, укыр вакыт җитә. Бу китапның күп юллары әнә шул Ачлык мәйданында туды дип уйлау хата булмас. Язылуы, кәгазьгә төшүе, бәлкем, соңрактыр. Әмма шытулары, кайнар хисләргә төрелеп туулары шунда!

Шөкер әле, халык безнең якта –
Үләчәкбез җылы кочакта.

Халык кочагында, милләт кочагында! Ләкин, кызганыч, аларны кочакларына кертмәскә, якын итмәскә тырышучы татарлар да (маңкортлар дию дөресрәк) булды. Хәтердә, көяз байбәтчәләр елмаешып йөри:


– Үзләре ашарга теләмәгәч, азык талоннарын безгә бирсеннәр иде...

Бер мәхлук кычкыра:

– Урыска каршы барган өчен атарга кирәк аларны!

Ләкин бу трагедия түгел: һәр ашлыкның кибәге булган кебек, һәр халыкның да җан көекләре була. Ә халкыбыз батыр, үз азатлыгын яуларга әзер. Мәйданда утыручы Рәшит барысын да – фидакярләрне дә, икеләнүчеләрне дә, үз көрәштәшләрен кызганучыларны да күрә:

Ә син, дус, кызганма мине,
Без үлми торган халык!
Булмагач булмый икән ул
Халыкның җанын алып!




**Азатлык юлында туган шигырьләр җыентыгы. 1993**

Шигъри йөрәк нәрсә белән кайный? Әлбәттә, шигырь белән. Яндыра да, ярсыта да ул шигырь!

Мәңге алданган халыкта
Икеләнү бар тагын:
Куймас микән авызын ачкан
Бүрәнәгә бармагын?!

Ягъни киләчәктә дә безнең халык әкияттәге юләр Шүрәле булып яшәмәсме, үз юлын таба белерме, ата-баба васыять иткән Азатлыкны кайтаруда куркып-өркеп калмасмы?

Инде, мөгаен, шуны гына әйтәсе кала: рәсәйчеләр сәясәте үтмәде, милләтебез үз хакимиятенә чит патшаны сайламады, аннан баш тартты! Һәм бу соңгы 440 ел дәвамына беренче мәртәбә! Димәк, артка юл калмады – чигенү бетте.

Бүген сөенеп искә алабыз: ике атна буе ачыккан кыю милләттәшләребез дә, нindидер могҗиза беләнме, Аллаһы Тәгалә ярдәме беләнме, исән калдылар.

Көрәшнең шул чорын үткән халкыбызга, иншалла, уй керде. Ул хәзер яхшы белә: ачлык кабул итү, үз-үзеңне тыныч үлемгә дучар итү Азатлык өчен көрәшнең бердәнбер юлы түгел. Соңгы гасырларда дистәләрчә дәүләтләргә, халыкларга бәйсезлек китергән көрәш ысуллары да бар. Без, татарлар, тыныч, сабыр халык. Әгәр дошманнар кискен көрәшкә, канлы сугышка мәҗбүр итәләр икән, без анысын да кабул итәргә әзер. Чөнки коллыкта яшәүгә караганда ирек өчен сугышта үлү кыйммәтрәк.

Хәзер, китапның битләрен бер-бер артлы ачып, шагыйрьне тыңлыйк...

*1993, 27 май*

# Өмет йолдызыбыз әле сүнмәгән

Борис Антонов

*Кичә редакция телефоны көн буена тынып тормады. Кукмарадан, Бөгелмә, Чаллы, Арча, хәтта Башкортстаннан, хәвефләнеп, бары бер сорауны бирәләр: «Фәүзия Бәйрәмованың хәле ничек? Безнең монда «бик авыр» дип сөйлиләр... Хәбәрчебез Б. Антонов сәяси ачлык игълан итүчеләрнең хәлен белеп кайтты.*

**Заһид Мәхмүди** («Шәһри Казан» журналисты. Мәйданда 10 нчы көне): «Хәзергә барыбыз да исән-саулар. Менә әле, Ф. Бәйрәмовадан башкаларыбыз, мунча кереп кайттык. Башта кертми азапладылар. Министрлар Советындагы җаваплы хезмәткәр Зиннур Бәдретдинов мунча директорына шалтыратып сөйләшкәч кенә рөхсәт иттеләр. Укучыларыбызга минем сүземне төгәл җиткер: үз җирендә ят кеше икәнлегеңне тою – иң аянычы менә шул. [...] Милләттәшләрем, әгәр сайлауга баралар икән, Рәсәй президентлыгына теркәлгән бөтен кандидатларны да сызып кайтсыннар».

**Рәшит Әхмәтҗанов** (шагыйрь, «Казан утлары» журналының әдәби хезмәткәре, 50 яшь. Мәйданда 10 нчы көне): «Син үзең матурлап яз инде. Хәзер баш та эшләми. Моңарчы әле безгә каршы көрәш барды. Табибәләребез дә соңгы ике көндә генә әйбәт карый башлады. Бәдрәфкә барулары әҗәл иде. [...] Хәзер инде Министрлар Советыныкына йөрергә рөхсәт алдык. «Азатлык» егетләренә (алар чиратлашып көне-төне безнең янда кизү тора), гомумән, бөтенләй таныш булмаган милләттәшләребезгә рәхмәт. Кыенлыклар белән булса да шифалы су табып китерәләр. Ул беткәндә, колонканыкын эчәбез.

Минем сәяси ачлык игълан итүем кинәт кенә ясалган адым түгел. Милләтемнең кара бәхете гомерем буена йөрәгемне җәрәхәтләп торды. Бу соңгы чарага барырга язмыш үзе акрын-акрын әзерләп килгәндер. Сөендергәне: дистәләрчә мең кеше хәл белергә килә. Милләт уяна, уйлана. Көендергәне: теләсә ни кычкырып, мыскыллап китүчеләр бар. Безгә кушылырга теләүчеләр бик күп. Аларны кирегә үгетлибез – корбаннар саны артуны теләмибез. Фәүзия ханымны яхшы беләм мин: ахыргача торачак... Татарстан Президенты итеп Шәймиевне күрәсем киләме? Белмим әле, сессиядә үзен ничек тотар бит».

Ике егет күңелләрне тетрәндерерлек моңлы итеп курай уйнап утыра. Берсе – Камал театры артисты Камил Камалов икән. Бирегә көн дә килеп хәл белә, фидаиләрнең авыр хәсрәтен җиңеләйтергә тырыша. «Алай итми болай булмый шул»,– дип куйды ул көрсенеп.

**Марат Арсланов** (Бөтендөнья мөселманнары «Тәүбә» җәмгыятенең Чаллы филиалы рәисе. 2 нче көне); «Фәүзия ханым – Азатлыкка булган өмет йолдызыбыз. Ул сүнсә, азатлыгыбыз да сүнәчәк. Бу хәсрәтле көннәрдә җанында намусы булган һәр татар берләшергә тиеш».



**Бертуган Әхмәтҗановлар Кандыз Сабан туенда. Утырганнар (сулдан уңга): Мияссәр, Бәхтияр, Мәгъния, Рәис, Камияр; басканнар: Сания, Камиярнең улы Әхтәм. 1997**

Газетабызның 21 май (№ 100) санында сәяси ачлык игълан иткән 16 кеше хакында хәбәр биргән идек. Ул гали затларга 20 майда – шагыйрь Газинур Морат, язучы Әхәт Мушинский, 22 майда Чаллыдан Марат Арсланов кушылды.

Кичә бер төркем табиблар, профессорлар Фәүзия Бәйрәмовага консилиум үткәрделәр. Нәтиҗәсен алдагы саннарда хәбәр итәрбез.

***

Кичә университетның, педагогия, ветеринария, мәдәният, медицина, химия-технология институтларының 30–40 студенты Ирек мәйданында «утырып торулы» забастовка башлап җибәрде. Аларга теләктәш Чаллы студентлары да юлга җыенды. «Без әлегә күп түгел. Иртәгә исә саныбыз йөзәрләп булачак. Чехословакия, Кытай һәм башка җирләрдә студентлар хәрәкәтенең нәрсәгә китереп җиткерүен җитәкчеләребез аңларга тиеш!» – диләр алар.

***

Үткән дүшәмбедә көн буена Министрлар Советы бинасының баскычларына утырып забастовка игълан иткән 50–80 яшьлек карчыклар сүзләрендә нык тора. Әле дә дога кылып утыралар иде: «Без Аллаһы Тәгаләдән халкыбызга – азатлык, Фәүзиягә сәламәтлек һәм озын гомер бирүен сорыйбыз»,– диделәр.

*Шәһри Казан газетасы.– 1991. – 25 май*

# Ачлык мәйданы – җиңү мәйданы ул

Мәхмүт Әхмәтҗанов

Шагыйрьләрнең төп көче, җегәрлеге – иҗатларында, әсәрләрендә. Шуңа күрә халык борын-борыннан тапкыр сүз ияләрен яраткан. Дөньяда иң көчле корал – идеология, дигән тәкъбир бар. Минемчә, идеологларның беренче сафларында шагыйрьләр, әдипләр дә бара. Әлбәттә, шул мәгънәгә җавап бирерлек булсалар...



**Ирек мәйданында. 1991**

Рәшит Әхмәтҗанның әле яңа гына дөнья күргән «Ачлык мәйданы» исемле шигырьләр җыентыгы – әнә шуның бер шатлыклы үрнәге. Киң җәмәгатьчелеккә әлеге китап авторының кем икәнлеген аңлатып торасы юк. Шигырьләре халык арасында киң таралган, мәхәббәт казанган. Шагыйрьнең Гаяз Исхакый бүләгенә ия булуы да шул хакта сөйли дип карарга кирәк. Рәшит Әхмәтҗан шигырьләренә җылы лиризм, үзенчәлекле илаһи аһәң, йөрәккә үтеп, күңелләрне биләп ала торган олы хисләр хас. Әмма бу очракта башка нәрсә хакында – шагыйрьнең сүздән генә гыйбарәт булмаган зур көрәш юлына басуын әйтәсебез килә... Әлбәттә, бу очракта параллельләр китерергә, үз шагыйребезне Петефилар белән чагыштырырга да мөмкин булыр иде.

Берәүләр митингларга йөрүне дә әхлаксызлык билгесе дип санаган бер чакта (гадәттә, моны куян йөрәклеләр сөйли), Рәшит Әхмәтҗан газиз Ватанының гүзәл киләчәге хакына үзен корбан итү юлына басты. Бу 1991 елның чәчәкле мае кошлар сайравына хозурланып утырасы заман иде. Әмма туган илең аһ-зар елаганда, кош тавышы колакларга бик керми шул. Бигрәк тә йөрәгең яралы булса. Күпләр беләдер: соңгы һәм иң көчле тыныч көрәш чарасы булып ачлык игълан итү тора. Аның алдында тираннар да югалып калалар. Рәшит Әхмәтҗан әнә шул алымны сайлады. Әлбәттә, моның өчен көчле рухлы, тимердәй ихтыярлы, идея ягыннан нык чыныккан булырга кирәк. Чөнки беркем дә бу көрәшнең ахыры ни белән бетәсен белми. Монда адым саен кешене үлем шәүләсе эзәрлекли. Шагыйрь Әхмәтҗан моны яхшы белә:

Коллыкны яндырып каныбыз дөрләсен,
Дөрләсен, сүнмәсен – ант итик, Ватанчы:
Йә бозлы йортыма азатлык яуларбыз,
Йә янып бетәрбез – кол булып калганчы!

Азатлыкны, ирекне кешеләр генә түгел, һәр җан иясе дә тели. Кайбер кошларны читлеккә ябу белән, алар шундук һәлак булалар. Табигатьләре коллыкны күтәрми. Алай гынамы, асфальт кадәр асфальтны күтәреп, тишеп, үләннәр кояшка үреләләр! Әмма бу ничек кенә гаҗәп тоелмасын, кайбер кешеләрнең психологиясенә коллык сөреме кереп тула да, аны бетерү искиткеч

кыенлаша, кайчакта бөтенләй мөмкин булмый. Шуңадыр инде Муса пәйгамбәр, үзенең яһүд халкын Мисыр коллыгыннан алып чыгып киткәч, туп-туры туган иленә кайтмаган; шул халыкны 40 ел буена чүлләр буйлап йөрткән. Коллыкта яшәгәннәр үлеп беткәч кенә, коллыкны күрмәгән яшьләрне туган җиренә китереп җиткергән.

Тирән мәгънәле риваять бу. Һәм, нигездә, бик тә ышандырырлык. Юкмы әле дә бер тәлинкә умач өчен кол булырга әзер торучылар? Алар, үзләрен аклау өчен, йөз төрле сәбәп эзлиләр. Ә аларны табып торасы юк, исеме — коллык психологиясе. Һәм шушы стереотипны җимерү искиткеч авыр. Татарның бүген төп оппоненты Мәскәү түгел, ә үзебезнең посып утыруга корылган коллык психологиябез, мескен хисләребез... Бүген иң төп бурычларның берсе — коллык психологиясен тәнебездән, каныбыздан, аңыбыздан бәреп чыгару. Икенче төрле әйткәндә, милли аңны уяту. Әлегә без миңгерәү хәлендә. Рәшит Әхмәтҗанның «Азатлык» шигыре, минемчә, әнә шул мәсьәләгә багышланган:

Ташчы егет! Күтәр башкаеңны,
Авыр ташларыңны куеп тор.
Исән рухыңны — кылычлардан
Үткенрәк итеп чыныктыр.

***

Кыйнадылар, илдән куа-тибә,
Тик башыңны имә — Ил исән!
Ил яши ул — әгәр иманыңны
Каның аша аңа иңдерсәң,—

ди шагыйрь йөрәге белән. Шуны ачык итеп һәм кистереп әйтергә кирәк: халыкның йөрәгенә барып җитми, милли аңын, хисләрен уятмый торып, дәүләтчелегебезне тергезү, аякка бастыру мөмкин түгел. Рәшит Әхмәтҗан моңа — халыкның әлегә кадәр уянып җитә алмавына пошына, борчыла:

Ялган булып су төбенә батасы бар,
Әгәр хаклык өскә калкып чыкмаса.
Дошман таптар каберләрдә ятасы бар —
Халкым болай бер-ике ел йокласа.

«Ачлык мәйданы» җыентыгына кергән әсәрләр арасында 14 монолог бар. Шагыйрь ачлык мәйданында булган батырларның күпләренә шулай итеп сүз биргән, алар әйткәнне шигырь калыбына салган. (Ике атна ач торуның, мәсхәрәле нахак сүзләр ишетүнең нәрсә икәнен аңлау өчен ике генә көн ач торып карарга кирәк!) Чаллыда яшәүче кыю татар кызы Гөлсирә Лотфуллина үзенең ни өчен ачлык игълан иткәнен яхшы белә һәм болай ди:

Үз илемдә үз иркем,
Күз агартып карама!
Саклыйм аны җанымда
Җиде буын балама.

Марат Арсланов (Чаллыда «Тәүбә» җәмгыяте рәисе) киләчәкне яшь буын кулында күрә. Аның кимендә ике сәбәбе бар: беренчедән, бүгенге яшьләр тоталитар системаны, ГУЛАГны күрми, йөрәкләре алынмый үстеләр, икенче яктан, аларга яшисе дә яшисе әле... Шуңа шатланып, Марат Арсланов (шагыйрь язмасында) болай ди:

Юк, болардан инде кабат коллар тумас,
Юк, болардан беркайчан да тумас коллар,—
Татар җанын, татар канын, татар илен
Соңга кадәр саклаячак токым болар.

Бу юлларга: «Бирсен Ходай! Амин!» — дип кенә өстисе кала.

Ачлык мәйданына агылучылар арасында илнең иң гүзәл, батыр кешеләре дә күп иде. Шуларның берсе – курку белми торган гүзәл җырчыбыз Вафирә Гыйззәтуллина. Ул үзенең җырлары белән Мәйдан батырларын рухландырды, аларга көч бирде. Аның «Ком бураны» Мәйданда набат-чакыру булып яңгырады. Булса иде тагын берничә Вафирәбез! Ул чакта кайберәүләрнең: «Кем кем җырын урлаган?» – дип бәхәс корырга вакытлары булмас иде. Вафирәнең җырларын беркем дә урламый, ул үзе – халкыбыз җыры! Рәшит Әхмәтҗан аңа рәхмәт йөзеннән түбәндәгеләрне әйтә:

Уятты күпме йөрәкне,
Терелтте синең көең –
Яшеллек чакырган яшен
Икәнсең, сеңелкәем!

Шагыйрьне шагыйрь итә торган сыйфатларның (фәнчә әйтсәк, алшартларның) берсе – гади генә күренештән дә фәлсәфи тирәнлектәге нәтиҗә ясый белү. Бу халәт Рәшиттә бар. Менә аларның бер-ике үрнәге:

Халкым бүген ирек алалырмы,
Богавында әллә калырмы?
Көчкә сулыш алып яткан бөркет
Көтә шулай соңгы давылны...

Әйтерсең лә бу юллар әле генә игълан ителгән Рәсәй империясе Конституциясе проекты уңае белән язылган инде. Әмма шуңа иманым камил: тарихка бөек исеме белән кергән горур татар халкы өзгән богауларын бервакытта да яңадан кимәс!

Менә икенче мисал – шагыйрь Газинур Моратка мөрәҗәгать:

Азатлыкны, бәлки, гомерләргә
Алмаштырып ала алырбыз.
Исәннәрнең әйтүләре мөмкин:
– Безнең белән сез дә калыгыз!
– Калырбыз.

Аллага шөкер, шулай булды да.

Мин яшьләребезгә якты өметләр баглыйм. Моңа урын бар. Чаллы егетләре, кызлары үзләре генә ни тора! Әмма битарафлар да җитәрлек. Бу хәлгә без, өлкәннәр, гаепле. Без аларны чамадан тыш иркәләдек, җил-яңгыр тидертмәдек. Ләкин чынбарлык мескеннәрне, йомшакларны изә, сыта. Шулай да бөтенләй соң дип әйтеп булмый. Безне тәрбияләүче әбиләребез бар бит әле! Шагыйрь Р. Әхмәтҗан әйтмешли:

Болар элгән бишектә бер тирбәлсә дә,
Калмас коллык кочагында балалар.
Юккамыни, аларны бер күрү белән,
Омончылар таштай катып калалар.

Татарның дөньяда абруе зур. Бигрәк тә төрки кардәшләр арасында. Бакудан килгән Азәрбайҗан халык депутаты Абдул Алмаз углы, безгә теләктәшлек күрсәтеп, шулай ук ачлык игълан итте. Ирек мәйданыннан китмәде. Рәшит Әхмәтҗан язмасында бу депутатның монологыннан өзек китерү урынлы булыр кебек:

Җирдән җиде нәселеңне җый, татар! –
Тик берләшеп бәхет йортын ачарсың.
Ялган белән тапма да, өләшмә дә –
Давыл алып китәчәк ич барчасын.

Фәүзия Бәйрәмова хакында нindидер белешмә бирү – вакытны бушка үткәрү ул; аны татарлар гына түгел, күршеләр дә, чит илләрдә дә яхшы беләләр. Аңа карашлар төрле. Әмма моңа карап төп сыйфаты үзгәрми: Фәүзия – үз халкы өчен җанын фида кылырга әзер торучы кыюдан да кыю күркәм татар кызы. Мин аңа карап сокланам да, аның белән горурланам да: ул бик күп




**Ирек мәйданында Татарстан Премьер-министры Мөхәммәт Сабиров чыгыш ясый**

ирләр эшли алмаганны эшли, күтәрә. Рәшит Әхмәтҗан китабында Фәүзия монологы да бирелгән. Менә шуның бер өзеге:

Беркем дә белмәсен бүгенгә —
Үземне әзерлим үлемгә.
Җанымны әзерлим. Әзер мин!
Бернидән курыкмыйм хәзер мин.
Төн буе әле мин балкырмын,
Кояшы чыкканчы халкымның.

Бик тә төгәл сүзләр!

Югарыда әйтелгән җыентыктагы һәрбер шигырьгә тукталырга мөмкин булыр иде. Чөнки аларның иҗтимагый резонансы көчле. Ләкин язманың күләме андый мөмкинчелек бирми.

Шулай да берсенә тукталыйк әле:

И таралган татарлар,
Илегез эзли сезне,
Кошка әйләндегезме,
Ташка әйләндегезме?

Җыеп кына шуны әйтәсе килә: шагыйрьләр күпләр, төрлеләр, үзенчәлеклеләр. Рәшит Әхмәтҗанның алар арасында үзенең хөрмәтле урыны бар. Ул үзенең иҗатындагы һәм көрәштәге кыюлыгы, максатчанлыгы белән татар халкы һәм аның поэзиясе өчен яши. Соңгы китабы шуны тулысынча раслый.

*«Шәһри Казан» газетасы.— 1993. — 27 ноябрь*

# Коллыктан көрәшсез арынылмый

Гурий Тавлин

Канатлары киселгән бөркет оча алмый, ләкин ул тавыкка әверелми, барыбер бөркет булып кала – ирекккә, күккә, үз мохитенә омтыла. 1552 елда руслар типкесенә эләккән татар халкы да, 440 ел буена мәсхәрәләнеп, каһәрләнеп яшәсә дә, күккә күтәрелә алу сәләтеннән мәхрүм ителгән бөркет кебек, горурлыгын югалтмады, коллык зынҗырларыннан арыну, хөррият яулау турында хыялланды. Ниһаять, ул теләгенә ирешкән кебек булды – 1990 елның 30 августында дәүләт суверенитеты турында Декларация кабул итте. Ләкин империячел рус дәүләте әле бүгенгә кадәр Татарстанга, электәгечә үк, савым сыеры итеп карап, аның бәйсезлеген танырга теләми.

1991 елның беренче яртысында Рәсәй хәкимдарлары Россия Президентын сайлау турында карар чыгардылар. Ул сайлауларда мөстәкыйль Татарстан да катнашырга тиеш дип табылды. Май аенда шуңа протест йөзеннән халкыбызның азатлык өчен тормышларын аямаган биш чая кызы һәм ундүрт гайрәтле улы – барысы унтугыз фидакяр – башкалабызның Азатлык мәйданында парламентыбыз бинасы алдында ачлык игълан иттеләр. Үз ихтыярлары белән халкыбызның бәйсезлеге, намусы, пакь вөҗданы хакына үзләрен үлемгә хөкем итүчеләр арасында әдипләр, шагыйрьләр, укытучылар, механизаторлар, дин әһеле, артист, җәмәгать эшлеклеләре бар иде. Алар максатларына ирештеләр: республикабызда Россия Президенты сайланмады, халкыбыз көчләп тагылган ул чарадан баш тартты. Ике атна буена авызларына ярма бөртеге дә капмый милләтебезнең йөз аклыгы, мөстәкыйльлеге, якты бәхете, коллык богауларыннан арынуы хакына ач торган ватанпәрвар кызларыбыз һәм улларыбыз исән калдылар.

Ул унтугыз фидакяр арасында Гаяз Исхакый бүләге лауреаты, күренекле публицист шагыйрь Рәшит Әхмәтҗан да бар иде. Күптән түгел аның шул борчулы көннәргә багышланган «Ачлык мәйданы» исемле шигырьләр мәҗмугасы басылып чыкты. Тирән эчтәлекле, гыйбрәтле китап ул. Аңа «Мирас» кече предприятиесе һәм аның җитәкчесе – танылган җырчы һәм җәмәгать эшлеклесе Гөлзадә Сафиуллинаның матди ярдәме дөньяга юл ярырга булышкан.

«Ачлык мәйданы»ның тышлыгын символик сурәт бизи. Анда татарларның ае урыс җәтмәсенә эләккән итеп ясалган. Ләкин күренеп тора: ул җәтмә инде нык түгел, черегән, тырышса да, айны тоткарлый алмаячак, таралачак.

Мәҗмугасының кереш шигырендә шагыйрь:

> Коллыкны яндырып каныбыз дөрләсен,
> Дөрләсен, сүнмәсен – ант итик, Ватанчы:
> Йә бозлы йортыма азатлык яуларбыз,
> Йә янып бетәрбез – кол булып калганчы! –

ди.

Ул юлларны бары халык язмышын үз язмышы итеп кичерүче кеше генә тудыра алуына ихластан ышаныла. Тынычланырга ярамый, көрәш әле туктамаган, дәвам итә, дип искәртә безне Рәшит.

*«Татарстан хәбәрләре» газетасы.– 1994. – 22 гыйнвар*

# Кояш чыгып килә

Айдар Хәлим

Мин беренче тапкыр күргәндә, алар унбер иде. Күз алдыгызга китерегез: күктә шашкан кояштан ниндидер кисәк-кисәк ялкын коела, ул асфальтка төшеп ләпәшә һәм Ирек мәйданының мәңләгән машина көпчәкләре астында таш булып каткан асфальт түземен жуеп эри башлый... Бу аяусыз эсседә сагыш булып саргайган палаткалар. Флангларда, әллә ни күзгә ташланмый гына посып, оеган омоннар. Пеләш маңгаенда нур кылычлары уйнаган Ленин да, күктән һәм арттан бәргән температурага чыдый алмый, һәйкәленнән төшәр дә, Казаннан мәңгегә чыгып сызар сыман.

Ә монда, палаткалар алдында һәм парламент бинасына якынрак тәңгәлдә корыштырылган япма астында, эчкә баткан күзләр, аларда карын ачлыгы түгел, ирек һәм азатлык ачлыгы ялкынлана; туктаусыз теләктәшлек күрсәтә һәм туктаусыз талаш-каргыштан балта йөзе кебек чарланган йөзләр, аларда Мөхәммәд пәйгамбәр сәхәбәләренә хас илаһи инанганлык. Монда минем күптәнге дусларым — көрәштәшләрем — Явыз Иван Казанны алганнан, ягъни 1552 елдан соң татар тарихында беренче тапкыр татар иреген даулап һәм Ельцин хакимиятен Татарстанга кертмәс өчен күмәк рәвештә сәяси ачлык тота... Юк, «тотып» кына калмый, мәйдан кадәр мәйданны сәхнәгә, трибунага, җыелган халыкны «тамашачыга» әйләндереп, бердәнбер коралы — микрофон аша, коллардан кеше, шәхес ясау өчен, шушы ук коллар еллар аша гына аңлаячак көрәш алып бара... Иреннәре кара көйгән Фәүзия Бәйрәмова. «Хәлеңне белергә килдем, сеңлем... Уфалардан теләктәшлек алып килдем...» Туктаусыз чыгыш ясаудан иреннәре күбекләнгән Зәки Зәйнуллин... Минем борынгы дустым, болай да какча гәүдәсе тилергән кояш нурларында тагын да кипкән, үтә күренмәлегә әйләнеп, бөтен бәдәне тоташы белән бер йөрәкне хәтерләткән сөекле шагыйрем Рәшит Әхмәтҗан... Мин аны кочаклыйм, ә ул колагыма карлыккан тавыш белән шигырь укый:




**ГКЧП көннәре. Рәшит Әхмәтҗанов һәм Айдар Хәлим. Казан. 1991, август**

Күрә алмас идек
Бүгенгене —
Җиңалмаган булсак үлемне.
Офыклардан Кояш чыгып килә —
Безнекеләр каны түгелме ул,
Безнекеләр җаны түгелме?!

Дөрес, Рәшит. Күк безнекеләр җаны, безнекеләр рухы белән шыплап тулган. Ә җирдәгеләр җаны безнекеме? Шуларны безнеке итү өчен азатлык вахтасына баскансың бит син. Ә мәйдан — гүли. Ул бер арта, бер кими, чәчкә китерә, теләктәшлек белдерә, хуплый, хурлый, каргый, хәтта,



**Мәйдан тотучыларның берсе — Фазыл Вәлиәхмәт**

«милләтләрнең тынычлыгын бозган өчен», биткә төкерә... Әйе, үз милләттәшең ул, башка беркем дә түгел. Шушы шартларда мин алар белән бер тәүлек бергә булырмын. Казан татары «тыйнак» бит ул: үзгәртеп кору чорында бердәнбер урамын «татарлаштырган», ягъни бер яһүди Жданов исемен икенче бер яһүди исем — Эсперантога әйләндергән урамында мине «КамАЗ» көтә — басылып яткан «Сагыш китабы»н алып кайту өчен, мин Вильнюска китәчәкмен. Бер ханымнан Рәшиткә чәчкә илтүен һәм миннән алда үлми торуын үтенеп, мин ерак юлга чыгам...

Китапны төяп, нәкъ бер атнадан әйләнеп кайтканда, алар инде унтугыз иде. Кайчандыр киләчәктә татар милли-азатлык хәрәкәтенең махсус архивы һәм музее булдырылыр. Татарстан мөстәкыйльлеге юлында хәлиткеч акцияләрнең берсе булып, татарны уятуда искиткеч зур тарихи роль уйнаган егетләребез һәм кызларыбызның исемнәре мәрмәр ташка алтын хәрефләр белән уелырга һәм бервакытта да онытылмаска тиеш. Фәүзия Бәйрәмова — «Иттифак» фиркасе рәисе, язучы, Казаннан; Зәки Зәйнуллин — полковник, фән докторы, язучы, Казаннан; Рәшит Әхмәтҗан — шагыйрь, Казаннан; аның бертуган энесе Илдус Әхмәтҗан — Г. Камал театрының күренекле актеры, Казаннан; Рифкать Шәмсетдин — механизатор, Алексеевск районының Әшнәк авылыннан; Рифкатьнең абыйсы Зиннур Шәмсетдин — механизатор, шул ук авылдан; Заһид Мәхмүди — язучы, Казаннан; Зөфәр Сәлиев — сугыш һәм хезмәт ветераны, Казаннан; Нәкыя Зиннурова — мөгаллимә, Алма-Ата каласыннан; Сәлим Әбү-Бәкер — сугыш һәм хезмәт ветераны, Алма-Атадан; Әнисә Нурисламия — мөгаллимә, Чаллыдан; Гөлсирә Лотфуллия — хисапчы, Чаллыдан; Гөлнур Хәйруллия — тәрбияче, Чаллыдан; Абдул Алмаз углы — дин әһеле, Азәрбайҗан халык депутаты, Бакудан; Фазыл Вәлиәхмәт — журналист, Карабаштан; Әхәт Мушинский — язучы, Казаннан; Газинур Морат — шагыйрь, Казаннан; Марат Арслан — «Тәүбә» җәмгыяте рәисе, Чаллыдан; Шәкүр Вафа — КамАЗ эшчесе, Чаллыдан... Азатлыкның бу волонтерлары Ирек мәйданында ятканда, Казан күге урталай ярылды: кайдадыр офыкта, Кояш күтәрелгән җирдә, кечкенә шәфәкъ ашъяулыгы, ә күкнең галәмәт дәү гөмбәзендә кара болытлар. Ниндидер чүп тастымаллары асылынып тора иде: әйе, Казанның өч йөз-дүрт йөз меңләп татары арасыннан утыз-кырык меңе, теләктәшлек күрсәтергә дип, мәйданга митингка килде, ике йөз меңе балконнан һәм трамвай тәрәзәсеннән үзенең «беркайда да, бернинди акциядә дә катнашмавы белән бәхетле күзләре» белән дөньяга карап, авыз ерды, катнаш никахка, маңкортлыкка баткан йөз меңе: «Ничек инде, Татарстанда патша итеп Ельцинны сайламыйсың?!» — дип, Рәсәй империясе хакына астыртын һәм коллаборацион үгет-нәсыйхәт алып барды... Их, без! Ә хәзер батырлар күбәя. Күбәйсеннәр. Без шуны телибез дә инде. Болай гына, шаяртып кына әйтүем, җәмәгать...

Шигъриятнең Тукай, Такташ һәм Туфан ачыткысыннан яралган чын шигъри баласы шагыйрь Рәшит Әхмәтҗан ул җаваплы көннәрдә милләт азатлыгы хакына бер гражданлык батырлыгы кылган булса, бүген ул азат милләте хакына беркем дә эшли алмаган икенче бер шагыйранә-иҗтимагый батырлык ясады: күптән түгел өстәлләребезгә аның «Ачлык мәйданы» дип исемләнгән гүзәл шигырьләр китабы ятты. Башта ук олы бер кечелеклелек һәм итагатьлелек белән әйтеп куясым килә: җыентык башыннан азагына кадәр хатын-кызга, Җир-анага, аналык рухына бөек сөю белән өртелгән. Әгәр аның төп каһарманнары булып Азатлык көрәшчеләре — Фәүзия Бәйрәмова, Нәкыя Зиннурова, Вафирә Гыйззәтуллина, Гөлзадә Сафиуллиналар булса, бу китапны Азатлык азыгы итеп дөньяга күрсәтүдә хәйриячелек иткән «Мирас» кече предприятиесе җитәкчесе, җырчы, шул ук Гөлзадә Сафиуллина тора. Рәхмәт сиңа, Гөлзадә кардәшем, билдән бөгелеп рәхмәт!

Гомере буе тауга менгән, әмма бер генә тапкыр да таудан төшү халәтен белмәгән кешенең тауга менүнең никадәр газаплы икәнен аңлата алмаганы кебек, бу китап турында язу да авыр.

Чөнки мондагы яшь тамчысы – кеше ышандыру өчен елаудан азат булгач,– саллы, саф һәм авыр. Шигъри мәҗмуга ике мең ярым чамасы шигырь юлыннан тора. Фикереңне раслау, мисал китерү өчен дистәләгән шигырь укып, цитата эзләп торасы юк, монда һәр юл туплардан ата һәм мотлак шартлата. Монда шагыйрь җан Газинур Гафиятуллиндай амбразурага ташлана һәм күкрәк читлегенә дөбердәтеп кургашын тутыра. Бөтен китап – халык, милләт турында туктаусыз уйлану һәм ут йоту. Нервлары йомшак милләттәшләребез бу кадәр фикер һәм хис ташкынын күтәрә алмаячак. Һич арттырмыйча әйтәм, татар шигъриятендә үзем белгәннән алып бүгенге заман шигъриятенә кадәр дүрт тапкыр тетрәнү кичердем. Беренчесе – Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәре» циклы. Ялгышмасам, 1958 ел. Икенче тапкыр Сибгат Хәкимнең Тукайга багышланган «Кырыгынчы бүлмә»се. Ялгышмасам, алтмышынчы еллар азагы. Өченче тапкыр шагыйрь Рифгать Закировның 1993 елның башында «Казан утлары»нда чыккан «Гамьле моң» поэмасы. Һәм менә дүртенче тапкыр – Рәшит дус Әхмәтҗанның «Ачлык мәйданы». Ә шигъриятнең лирик гражданлыкка (сәер атама!) катнашы бар икән, минем фикеремчә, соңгы дистә еллардагы без күтәрелә алган биеклекләр шундый таулардан гыйбарәт. Әлбәттә, алар арасында, бәлки, мин күрмәгән һәм күрә алмаган, кемдер алардан да биек итеп күргән таулар бардыр. Бәхәсләшмим.

Китапның тышлыгында Рәсәйнең иң Баш балыкчысы Ельцин, айны җәтмәгә эләктереп алып, офыкка кереп бара. Әлбәттә, Ельцин кадр артында. Рәссам А. Үтәгән моны бик гүзәл рәвештә үтәгән, гәрчә китап тышлыгы тозлы балык төрә торган кәгазьдән эшләнсә дә. Кәгазь сортындамыни эш, ягъни, минем картинәй әйтмешли, эш бит фурмыда түгел, курмыда, курмыда!

Уян, вөҗдан, уян! Калакун кагырга шагыйрь әрхәрәй түгел. Ул биотоклы, шаукымлы куллары белән йөрәкләрне капшап, шундый ук шаукым эзли...

Шундый итеп таркаталдың:
　　　　хәзер
Халыклардан калды
　　　　төркемнәр.
Кеше ни ул?! –
Хәтта Кояшны да
Кол итәргә монда
　　　　мөмкиннәр...
Ә әлегә Кояш – урысныкы,
Ай частушка сибә төн буе.
Разбойниклар кочаклашып
　　　　　　эчә,
Беркем белми – илдә кем
　　　　　　туе?

Беләләр, шагыйрь шаярта гына. Белмәгәнгәме:

Яшәр генә чагым иде,
Сандугач кебек сайрап.
Булмады. Бабамнар кебек
Утырам кылыч кайрап...

И сандугач, сандугач,
Анда түгел, монда кач...
Синең – илең, минем – өем
Иелми торган Агач!

Сандугачны түгел, шагыйрь алтын-байлыкны да качарга чакыра. [...] Явыз Иван һәм Пётр патша яулары һәм «Васыятьнамәләре» аша талап җыелган байлыкның да кадере юк. Байлыклар да җылап чеңри һәм чери.

Сандык-сандык алтын эзләп
　　　　йөргән
Комсызларның җаны
　　　　әрнесен:
Ул алтыннар күптән
　　　　балкыта бит
Меңәрләгән чиркәү тәресен.

Төптә кылычлар бар.
Хәзинәгә
Алар белән булмый юл
　　　　　　ачып.
Кешеләргә Акыл кирәк чакта
Кала алсаң, алтын, кал
　　　　　　качып!

Шушы ук шигырендә буш мичкәнең таркау тактасына утырып, егерменче гасырның туксанынчы елларында Кабан күленнән алтын эзләргә чыккан мөхтәрәм публицистларыбыз Мостафиннардан автор ачы итеп көлә:

Кабан күле – көзге.
Һәркем үзен
Бер карасын иде көзгедән.
Сезгә алтын кирәк.
Ә милләтнең
Тәсбих төймәләре өзелгән...

«Фазыл Вәлиәхмәт монологы» – җыентыкта иң көчле әсәрләрнең берсе, минемчә. Хәер, онтыгыз Каһарманның шигъри оранннары рәвешендә язылган бу китаптан һәр оранны мисалга китереп булыр иде, әмма мин чын шигърияткә комментарий бирүне түбәнлек дип саныйм. Укучы үзе укысын, мин бары тик аның игътибарын гына юнәлтергә телим:

Акыллары белән көчлеләрне
Акылсызлар тотып көчлиләр.
Бер катламда яшәп, бу кадәрле
Бер-берсенә нигә үчлеләр?..

Талаучылар – иске. Куркыталар:
Кулларында һаман ук-җәя.
Тудыручы сирәгәйгән саен,
Һәлак итүчеләр күбәя.

Империя капкасында йозак –
Аннан чыгар өчен юк ишек.
Ишекләре ачылмаслык булгач,
Чын ирекккә, татар, чык ишеп!

Юк. Ишеп чыкмый татар. Аһ, татар! Аңардагы коллык тойгысы үз мөстәкыйльлеген, үз ирекен кайтару, азатлык яулау турында уйлаудан азат булу микъдарына җиткерелгән. Шуңа күрә ул, коткыларга бирелеп, үзенең батыр һәм акыллы кызы Фәүзиясен талата, Зиннурын төрмәгә яптыра, кияүгә чыкмаган көрәшче нарасые – Алсу Ганиеваны үтертә; аңа бер-берсенә теләктәшлек күрсәтү түгел, бер-беренә пычрак ату ләззәт китерә. [...] Боларын мин әрнегәннән, өндәге аю шикелле киерелеп, озак уянуыбыздан гарьләнеп кенә әйтәм. «Матросская тишина», Бутырка белән рәттән үзебезнең Пләтән төрмәләре барлыгын кисәтеп, шагыйрь яңа язылган шигыренең күчермәсен сорап, Татарстан Дәүләт музееннан килгән кызкайга менә нәрсә ди:

Таш төрмәне
Кабер ташларына
Бүлгәләсәң – җитми калыр
                    күк.
Иң соңгысын кулдан,
«Минеке!» дип,
Палач үзе тартып алыр күк.
Бирмик. Элек ташка уеп
                    язган
Һәрбер сүзне кеше укысын.
Эзлик. Монда әле табылмаган
«Моабит дәфтәрләре» юкмы
                    соң?
Бар, сеңелем, яңа музейлар
                    ач –
Шигырьләрне аер сөяктән.
Әнә күктә урыс ятьмәсенә
Татарларның ае эленгән...

Минем йөрәгемә утлы күз төшкәндәй була. Кайчандыр җитмешенче еллар башында матбугатта дөнья күргән бер шигыремдә мин:

Кәркәле күгендә аунап,
Яңа ай әвәләнә.
Ул да конвой ятьмәсеннән
Чыгалмый чәбәләнә... –

дип язган идем. Каләмдәшем һәм көрәштәшем белән булган бу кадәр җаный якынлык мине бер температурада яшәгәнлегебезне искәртеп, тагын бер тапкыр куандыра... Чөнки:

Кан бирә дә кан тапшыра
                    татар –
Шунын өчен генә туганмы?
Шартламыйлар гына –
                    хәшәрәтләр
Күбенгәнче эчте ул канны.
Татар бирә – болар йота
                    бара,
Кан буйсына мәллә әмергә!
Шуңа күрә азканлылык чире
Интектерә... татар әлегә
Уяналмый күп кан
                    югалтудан...

Менә шундый «физиологик диагнозлар» да куя шагыйрь милләткә. Мондый әмер чын иҗатчыга бары тик күктән төшә. Бу әмер талон исәбенә яши алмый, шуңа күрә ул үлемсез.

Авырсынмый миңа да таш куегыз.
Таш өстенә әмеремне уегыз.
Үләнме каплар, имәнме — барыбер.
Очраштырыр әле безне ул әмер.
Сукыр түгел кеше аны күрмәскә:
Сезгә дигән әмерем бер — Үлмәскә!

Болай булгач, үлмибез инде, Рәшит дускай. Татар хәзер, Аллага шөкер, йокламаслык булып уянып килә. Әмма без башлаган көрәш вахтасы — ул әле көрәшнең башы гына. Милләтне озайлы көрәшкә юнәлтергә, «адреслы яклау» исәбенә генә түгел, адрессыз яклау, итек түгел — чабатага калган хәлдә дә, тук карынга түгел, ач карынга да мөстәкыйльлек өчен көрәшне дәвам итү зарурлыгына тупларга кирәк.

Ә «Ачлык мәйданы» китабына килгәндә, аны һәр мәктәп, һәр аудиториядә кычкырып укытыр, радио-телевидениедән аерым тапшырулар гөләндәме оештырыр идем... Кулымнан килсә, бүген үк Тукай премиясен бирдертер идем. Аны бу бүләккә автор үзе эшләгән «Казан утлары» журналы тәкъдим итә алган булыр иде. Дөрес, ачлык вахтасы көннәрендә Казан буйлап, имеш, журнал идарәсе ачлык вахтасына баскан каләмдәшенә «түләүсез отпуск алу өчен гариза яздыру, аннан соң гына ач утыру хокукына ия булуы» турында имзалы гариза яздырып алу өчен махсус хезмәткәр җибәрүе турында азау тешле имеш-мимешләр йөргән иде. Монысы аның шаяру гына булмагандыр. Хәзер инде — эш беткән. Эш беткәч, Тукай бабабыз әйтмешли, җитди итеп «уйнап-уйлап» карарга ярый. Кыскасы, мондый шигърият үрнәге Тукай бүләгенә насыйп булса, ул Тукай вөҗданы алдында сафлыгыбызны гына раслар иде.



**Ирек мәйданында. 1991, май**

Китапка ярыйсы гына сүз башы язган Фәнзаман Баттал да моны куәтләр кебек.

*«Ватаным Татарстан». газетасы.— 1994. — 28 гыйнвар*



**Рәшит абыйның хәле ничек?**




**Ирек мәйданында игълан ителгән сәяси ачлык тотуда катнашучылар. 1991, май**




**Аксакал язучы Гариф Ахунов хәл белергә килгән**




**Җитди сөйләшү. Уңнан беренче — Татарстан Премьер-министры Мөхәммәт Сабиров**



*Р. Әхмәтҗанов:* **«Ирек булса, җитәр иде безгә**
**Яшел үлән белән ак күлмәк…»**



**Ирек мәйданында игълан ителгән сәяси ачлык тотуда катнашучылар. 1991, май**




**Татарстан суверенитеты өчен көрәш мәйданында ачлык игълан итүчеләр төркеме. Сулдан уңга: Илдус Әхмәтҗанов, ?, Фәүзия Бәйрәмова, Рәшит Әхмәтҗанов, Зәки Зәйнуллин, Зөфәр Сәлиев. 1991, май**



**Дөньяда халыклар – күршеләр һәм кардәшләр күп, без шуларның берсе һәм башкалар белән тигез хокуклысы**

# III БҮЛЕК.
# «БЕЗ АЗРАК – ЧӨНКИ БЕЗ БИТ НЫГРАК ЯНДЫК»

*Рәшит Әхмәтҗановның вафатыннан соң республика матбугатында дөнья күргән кайгынамәләр, мәкаләләр, шигырьләр*



***

Безгә байтак борчулар һәм югалтулар китергән иске елны әле генә кичеп, инде бер иркен сулап, һәммәбезгә яхшылык-исәнлекләр теләп, яңа елда яши башлаган идек. Ә тормыш без дигәнчә генә бармый. Татар әдәбиятына тагын югалту килде: 5 гыйнвар көнне илле дүртенче яшендә шагыйрь Рәшит Әхмәтҗановның йөрәге тибүдән кинәт туктады.

Рәшит Хәниф улы Әхмәтҗанов 1941 елның 14 апрелендә Татарстанның Баулы районы Татар Кандызы авылында туган. Авыл мәктәбендә җидееллык белем алганнан соң, Бөгелмәдә төзүчеләр училищесын тәмамлый, Әлмәт шәһәрендә ташчы булып эшли. 1961—1964 елларда армиядә хезмәт итә, аннары Казан дәүләт университетын тәмамлый. Башта Татарстан Мәдәният министрлыгында, соңрак «Татарстан яшьләре», «Яшь ленинчы» газеталары редакцияләрендә эшли. 1980 елдан — «Казан утлары» журналы хезмәткәре.

Рәшит Әхмәтҗанов газета һәм журналларда басылып чыккан беренче шигырьләре белән үк Х. Туфан, С. Хәким, Г. Хуҗи, З. Мансур кебек мөхтәрәм каләм ияләренең игътибарын үзенә җәлеп итте. Тәҗрибәле әдипләр аның үзенчәлекле иҗатын, табигый сәләтен югары бәяләделәр, шагыйрьне канатландырып, яңа иҗат үрләренә әйдәделәр. Шул вакыттан бирле ул олы иҗат юлыннан тайпылмады, шигърияттә яңа ачышлар ясап, яңа биеклекләргә күтәрелде. Дистәдән артык китап бастырып чыгарды. «Хыялларым үзем белән» исемле беренче җыентыгыннан соң «Җан яктысы», «Ак канатлар», «Гомер чишмәсе», «Кавышыр көн», «Йөрәк бәйрәме» һәм башка китаплары аша үзенең зур шагыйрь, моңлы шагыйрь булуын раслады. Милләтебез тарихының тирәнлеген аңлап, татар теленең бөтен нечкәлеген тоеп, халык җырларына хас җыйнаклык белән моң-сагыш тулы шигырьләр, җырлар язды. «Акчарлаклар» җыры аша гына да ул һәр татар кешесенә таныш.

«Язлар быел соңга калды», «Исәннәр моңы», «Бишташ», «Аучылар кибетендә» исемле әсәрләре белән Р. Әхмәтҗанов поэмалар остасы булуын да исбат итте. «Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исемгә иреште, Язучылар берлегенең Г. Исхакый исемендәге бүләгенә лаек булды. Кабатланмас олы иҗаты, Татарстан мөстәкыйльлеге өчен көрәштәге фидакяр гамәлләре, тынгысыз җан авазы белән ясаган чыгышлары, балаларча ихласлыгы, җорлыгы, ярдәмчеллеге бу шагыйрьнең милләттәшләребез күңеленнән китмәс шәхес булуын дәлилли.

Без аны һәрчак юксынырбыз.

З. Вәлиева, И. Хәйруллин, М. Хәсәнов, М. Таишев, И. Әхмәтҗанов, Н. Зарипов, Р. Мөхәммәдиев, Г. Бәширов, Г. Ахунов, И. Юзиев, Ш. Галиев. Г. Зәйнашева, Р. Фәйзуллин, Р. Харис, Т. Галиуллин, Р. Мингалим, Р. Гаташ, К. Булатова, Р. Батулла, З. Мансуров.

*«Ватаным Татарстан» газетасы.— 1995. — 6 гыйнвар;*
*«Шәһри Казан» газетасы.— 1995. — 6 гыйнвар*

# Хушлашу сүзе

Татар халкы үзенең тагын бер кадерле улын – чын талант иясен, ихлас шагыйрен югалтты. Рәшит Әхмәтҗанов көтмәгәндә генә вафат булды.

Соңгы өч ел безнең халыкның талантлы балаларын чалгы белән чапкандай кыра торды. Инде... Рәшит дустыбыз...

Кабатланмас иҗаты, күңел кайнарлыгы белән ул халкыбызның дәрәҗәсе, горурлыгы, намусы өчен көрәште.

Аның шигырьләре чын мәгънәсендә салкын көндә янып торган бер якты, җылы учак булды. Без аның яңадан-яңа учаклар кабызуын көтеп яши идек.

Ил өстенә киләчәк кара болытларны игенче сыман алдан ук сизгәндәй, яшь чагында ул болай дип язган иде:

Төне буе кара карлыгачлар
Йөрәгемә кайгы ташыды...

Беләбез, сандугачларның гомере озын булмый. Сайрап бетермичә китеп бара алар.

Синең күңелдәге сайрар моң халык күңеленнән китмәс, Рәшит дустыбыз.

«Татарстан яшьләре» гәзите үзенең элекке хезмәткәренең, даими авторының, яраткан шагыйребезнең якты хатирәсе каршында баш иеп саубуллаша. Авыр туфрагың җиңел булсын, дустыбыз!

*«Татарстан яшьләре» газетасы. – 1995. – 6 гыйнвар*

***

Бу шигырьләрнең журналда басылып чыгуын, кызганычка каршы, шагыйрь үзе күреп өлгермәде. Талантлы каләмдәшебез, редакция буенча хезмәттәшебез Рәшит Хәниф улы Әхмәтҗанов гыйнварның бишесендә кинәт вафат булды. Ул әле илле дүртенче яше белән генә бара иде. Шигърияттә күптән үз урынын тапкан, фәлсәфи-халыкчан лириканың кабатланмас җәүһәрләрен тудырган шагыйрьнең соңгы шигырьләре дә безнең йөрәкләргә һәм мәңгелеккә матурлык үрнәге буларак юл алалар. Әйе, мәңгелеккә – бу турыда хәзер инде бөтен татар гавамына кычкырып әйтеп була. «Хуш, дустыбыз! Саумы, олуг шагыйрь!» дибез.

*«Казан утлары» журналының 1995 елгы*
*1 нче санында басылган шигырьләр бәйләме уңаеннан*

# Безнең мемориал

Татар әдәбияты соңгы чорда үзенең күренекле вәкил һәм вәкиләләрен яшьли һәм еш югалта башлады. «Аргамак» журналы, ничек кенә авыр булмасын, туктаусыз матәм текстлары язарга мәҗбүр.

Менә Идел йортыбызга, чал Урал һәм ерак Бараба далаларына, татар милләтенең укучысы булган һәр төбәккә көтелмәгән һәм бик тә зур кайгы килде: 1995 елның 5 гыйнварында, илле дүртенче яшь белән генә барганда, татар шигъриятенең җәүһәрләрен калдырган иҗатчысы, татар милли-азатлык хәрәкәтенең сөекле һәм батыр көрәшчесе, Гаяз Исхакый исемендәге әдәби бүләк лауреаты шагыйрь Рәшит Хәниф улы Әхмәтҗановның йөрәге тибүдән туктады.

Ватан сугышы елларында ачлыкта-ялангачлыкта үскән сабый, Совет Армиясендә хезмәт иткән чын солдат, ятимлек аша Казан дәүләт университетында тырышып укыган студент, үзенең беренче шигырьләре белән үк Тукай, Такташ, Туфаннар йолдызлыгына күтәрелгән шагыйрь, хәстәрлекле ата һәм ир, ялганның нәрсә икәнен белмәгән Гадел Кеше һәм намуслы дус — Рәшит Әхмәтҗанов менә шундый дус иде.

Хуш, дип әйтүе әҗәлнең үзе кебек авыр. Ул «Аргамак» журналының авторы, яраткан укучысы һәм киңәшчесе иде. Караңгы төннәрдә йолдызларны сагынган кебек сагыначакбыз без сине, Рәшит дустыбыз. Синең исемең татар әдәбиятының корифейлары — үлемсезләр исемлегендә. Шигърияттәге урының Тукай исемлегендә булгач, синең каберең дә Тукай рәтендә. Җаның оҗмахта булсын, йа Раббым. Амин.

Рәшит Әхмәтҗанов туган иле, туган җире, туган милләтенең Бөек Патриоты иде. Хәтәр заманнарда ул афәтне үз күкрәгенә алды. Милли моңның курае сыман какча гәүдәле бу олуг кеше дошманнарын үткен сүзе белән генә җиңә иде. Җөмһүриятебезнең мөстәкыйльлеге куркыныч астында калгач, атап әйткәндә, 1991 елның маенда, кояш эссесенә түзә алмый эрегән асфальтта ул тарихыбызда беренче тапкыр милли азатлыгыбыз хакына ундүрт көнлек сәяси ачлык тотты һәм җиңеп чыкты.

Шундый итеп таркаталдың: хәзер
Халыклардан калды төркемнәр.
Кеше ни ул?! —
Хәтта Кояшны да
Кол итәргә монда мөмкиннәр,—

дип язды ул үзенең атаклы «Ачлык мәйданы»нда Рәсәй империясе турында. Рәшит Әхмәтҗановның барлык гомере бишектән үк фашизмга каршы көрәшкә багышланды. Без сине, Рәшит, йолдызларны сагынган кебек сагыначакбыз. Хуш. Хуш. Хуш.

*«Аргамак» журналы идарәсе, авторлар коллективы һәм күп меңләгән укучылары*

*«Аргамак» журналы.— 1995.— № 2*

# Синең гомер – көн яктысы...[1]

Сания Фәйзерахманова



**Рәшит Әхмәтҗановның сеңлесе Сания. Казан дәүләт университетының 2 нче курс студенты. 1973**

1803 елда Пенза губернасыннан күчеп, Татарстанның Баулы районы Сөләйман авылына (Кандызның бер өлеше) нигез салган Сәетгәрәй бабабызның оныгы – безнең әтиебез Мөхәммәтхәниф (1890–1958) белән төрек кызы Әминә апаның Бәхтияр, Әмрия, Мәгъния исемле балалары дөньяга килгән. Әминә апа яшьли вафат булгач, әниебез Бибисаҗидә (1910–1978) – Оренбург өлкәсе Северный районы Кряжле авылы кызы – ятим калган сабыйларны үз канаты астына ала. Һәм үзләренең тагын Камил, Мияссәр, Кәмияр, Мәгавия, Рәис, Рәшит, Ильяс, Илдус исемле уллары; Назмия, Рәйсә, ..., Сания исемле кызлары туа. Әни миңа, син – уникенче балабыз, дия иде. Димәк, алар 15 бала бакканнар. Урыннары оҗмах түрләрендә булса иде...

Миңа өч яшьләр чамасы булгандыр. Бөтен тирә-як кар көртләренә чумган. Бездә юрган сыру өмәсе. Ап-ак мамык өеменнән зуррак кисәкләр алып, Рәшит абыем миңа кечкенә «шәл» һәм «бишмәт» ясап киендерде. Беркетелгән мамыкка кагылыр-кагылмас кына мине кочагына алып, күрегез, минем сеңлем нинди матур булды, дип, горур кыяфәт һәм зур җитезлек белән бөтерелеп, өйдәгеләргә күрсәтеп чыкты.

Бүгенгедәй хәтеремдә, Рәшит абыйның туган йортка кунакка кайтуы, беренчедән, күңелләребезне, урамнарыбызны, авылыбызны ямьләсә, икенчедән, көтү куу вакыты җиткәнче, әни янында бергәләп кич утырулар минем өчен олы бәйрәмгә тиң иде.

Ул алып кайткан күчтәнәчләрдән авыз итәргә дип, чәй өстәленә иң беренче чиратта авылның көтүчесе һәм Бөек Ватан сугышында ирләре һәлак булган тол хатыннар – күрше апалар чакырыла иде. Шаян-мәзәк хәлләр сөйләшү, боекканнарның күңелен күтәрү, хатирәләр яңарту мәҗлесе кебегрәк уза иде ул. «Их, моңлы итеп Коръән укучы, үзе ясаган курайда уйнап биетүче Хәниф абзый да исән булса...»– диючеләргә игътибарымны арттырдым. Әтиебезнең (фотосы юк) бик тә күркәм кеше булуын шушы кабатланмас очрашуларда ишеттем.

Сагынулары ташкынга тиң иде. Кандызны, 15 бала баккан газиз ананы, туганнарны, авылдашларны, аның дәрәҗәсендә үк сагынып яшәүче, сагынып кайтучы кеше, мөгаен, тумагандыр әле.

Аккош гомерләре кайда үтә?
Монда бүген буран дулады.
Илкәемә искән җылы җилләр,
Сөйгәненә баралмаган кыздай,
Шигыремә кереп елады.
Елады җил...

Чал дөньяда кинәт
Ишеттем дә аккош тавышын –
Болыннарның үзәгенә үтеп,
Туган илгә кайтыр аккошларга
Тамчылап күл җыя сагышым,–

дип язган иде ул...

[1] С. Фәйзерахманованың шәхси архивыннан алынды.– *Төз.*



**Әнисе Саҗидә белән. Казан, 1978**



**Әнисе Саҗидә, энесе Илдус һәм сеңлесе Сания**


Рәшит Әхмәтҗановның әнисе Сәҗидә

Ә әниебезнең йөрәк хисләрен тирәнтен чагылдырган дистәләгән шигырьләрен гомер буе күңелдән кабатлап йөрерлек, иксез-чиксез мәхәббәт белән сугарылган алар.


Миңа 17 яшь. Университетка керү имтиханнарына аның белән бергә әзерләндек диярлек. Ул махсус минем өчен еллык ялын алган иде. Һәммәбезне якын күргән Луиза апа-җиңгәчәй тәмле ризыкларны пешереп кенә торды. Рәшит абый шактый шигырьләр иҗат итте. Яңаларын миңа укытканнан соң, фикерләремне тыңлап, аларны ни дәрәҗәдә аңлавымны төшенгәч, сөенеченнән С. Сәйдәшев көенә язылган җырны: «Җир җиләге ачы була, үз вак(ы)тында пешмәсә...»– дип көйли, йә булмаса, «Кәвал авылы көе»н яратып башкарыр иде. Шуны да искәртеп китим: аның үзенең дә дүрт дистәдән артык шигыренә композиторларыбыз тарафыннан халык күңеленә үтеп керерлек җырлар иҗат ителде. Татар халкының күренекле улы Рабит Батулла әйткәнчә, чынлап та, тел сәнгатендәге композитор булды ул.

Рәшит абыйның Бауман урамындагы Халык иҗаты йортында эшләгән вакыты, минем – студент чак. Төшке ял вакытына туры китереп, мине очрашуга чакыра һәм, кесәсендәге бар акчасын учыма салып, ашханәгә озата. Ә үзе керми. Тагын акчасы булса, үзе ашамыйча, ул еллардагы бик күп студент кардәшләргә, һичшиксез, өләшкән булыр иде ул...

Төрле төбәкләрдә яшәвебез сәбәпле, бик сирәк күрештек шул, бик кызганыч, әлбәттә. Ә телефон аша сөйләшкәндә, җир йөзендә аңардан һәм миннән бәхетле кеше булмагандыр кебек. Иң шатлыклы минутыдай яңгыравыклы, сөенечле тавышы белән «Сания, синме бу?» дип башлар иде сүзен. Күрешсәк, икебез дә күз яшьләре түгә идек... һәм саубуллашканда да... «Мин исән чагында, бернигә борчылма, кайгырма, акыллым» дия иде.


Туган йорт сүтелер алдыннан

Һәркайсыбызга зур кайгыртучанлык һәм ярдәм күрсәткән газизләрдән дә газиз абыебыз, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Гаяз Исхакый бүләге иясе Рәшит Хәниф углы Әхмәтҗанов вафат. Ул бай әдәби мирас калдырды. Мәңгелеккә киткәндә, киная һәм шаярту белән: «Мин сыпыртам шигъри тәмугыма «фәрештәләр» тулган дөньядан»,– дип пышылдагандыр кебек. Аны озатканда, халык бик күп иде. Кабергә индергәндә, энҗе кар бөртекләре ява башлады. Ул аклык, ул сафлык мине сабый чагымда абыем бизәп киендергән йомшак, җы-



**Рәшит Әхмәтҗанов һәм аның хатыны Луиза, кызы Ләйлә, бертуганнары Сания һәм Илдус әниләре Саҗидә белән. 1972**

лы ак мамыкны хәтерләтте. Бакыйлыкка киттең, хуш! Гүрең нурлы, рухың шат булса иде, газиз абыем!

Әгәр дә шагыйрь, үлемсезләр исемлегендә булып, бездән бик-бик еракларда яшәсә, тормышы башкача узар, башкача иҗат итәр һәм сагышлы шигырьләре дә бик аз булыр иде.

«Бер нарасый кебек, кырлар буйлап көлеп йөрим ап-ак күлмәктән» дигәндәгечә, төшләремә керсә, мин аңа: «Исемеңне синең телгә алгач, күз яшьләрен күрәм гөлләрнең» һәм шул гөлләр арасында мин дә булырмын, гомерем буе сине юксынырмын,— дияр идем.

Матурлык һәм Батырлык үрнәге булып калган бөек Шагыйрь! Якыннарыңның, туганнарыңның, бердәнбер сеңлеңнең, дусларыңның күңелләрендә мәңгегә сагышлы сөенеч булып калдың инде.

...Бер акчарлак ярда ятып калды,
Башкаена дулкын таш бәргән.
Җырларыңны,
Җырчы улларыңны
Сакла, Казан, шундый хәлләрдән.

*1995, 7 гыйнвар*

# Нәни инеш, тамчы һәм зурлык[1]

Мәгъсүм Хуҗин

*Бу уйланулар Рәшит Әхмәтҗановның иҗади эшчәнлегенә егерме биш ел тулу уңаеннан 1984 елның декабрь азагында язып куелган. Аны мин матбугатка бирмәдем. Рәшитнең шигърияте соңгы елларда колачлана баруын истә тотып, мәкаләне зурайтырга, әдәби портрет төсе бирергә иде исәбем. Тагын бер сәбәбе бар — анда шигырьләрдән мисаллар ишле, ә мондый хәл миңа беркайчан да ошамады. Әйе, мәкаләне үзгәртеп язарга өлгерермен әле, холкымча — ашыкмыйм әле, дип уйланылды, Рәшитнең соңгы китаплары, күләмле поэмалары мәкаләдә һичшиксез искә алынырга тиеш кебек иде.*

*...Рәшит вафат...*

*Хәзер исә мәкаләне үзгәртүне кирәк тапмадым. Аны эчтәлеген Рәшит белгәнчә бастыру дөрес. Ә белүенә дәлил — аның миңа бүләк иткән «Йөрәк бәйрәме» исемле китабына язган сүзләре:*

*«Мәгъсүм абый!*

*Теге... нитеп кенә йөргән иде бу... дип, башкалар кебек минем турыда уйламавыгызны беләм. Шул уегызны раслап чыккан китап бу.*

*Рәшит. 30.05.88».*

*Шагыйрь иде Рәшит. Аның шагыйрьлеген баштагы иҗаты да, соңгы әсәрләре дә раслый. Шагыйрь булып башлады, шагыйрь булып яшәде, шагыйрь булып китеп барды Рәшит... Халкы күңеленә-хәтеренә.*

*Автор*

Инеш ага. Нәни инеш. Гомере буена яктыга атлыгып ага ул. Аның шавында шатлыклар да, сагышлар да ишетелә. Шул шатлык һәм сагыш моңнары инешкә агарга көч бирә дә инеш үзе дә әнә шул шатлыкларга һәм сагышларга, тормыш агымына кушыла. «Нәни инеш» исемле шигырьнең эчтәлеге шундый.

Гадәттә, программ шигырь кычкырып тора кебек. Ә бу шигырь (ул шагыйрьнең «Хыялларым үзем белән» исемле беренче китабын башлап җибәрә) тыйнак агышлы. Шулай да ул, минемчә, шагыйрьнең, әле булачак шагыйрьнең, киләчәк юлын төртеп күрсәтә. Тормышта битараф булмаячак шагыйрь, тормышның куәтле, шарлавыклы агымына нәни инеш булып кушылыр ул.

Кушылдымы соң?

Әйдәгез, шагыйрь Рәшитнең тагын бер шигырен укыйк әле. Ул «Үзем сөйли белмәм кебек...» дип атала.

Шагыйрь, тормыш мине гашыйк итүен, кеше итүен үзем сөйли белмәм кебек, сөйли белмәм, ди. Мин кичергәннәрне сезгә көн яктысы сөйләр, ди. Уйлана каласың: ни өчен соң әле көн яктысы сөйләргә тиеш; шигърият мәйданына чыккан Рәшитнең моңа үз көче җитмиме? Ни өчен көче җитми? Ул бит, тормыш мине кеше итте, дигән иде. Ашыкмыйк. Шагыйрьнең фикере, тасвиры безне кая алып барыр, кай урынга китереп чыгарыр икән.

Рәшит чәчкән арышлар көн яктысына үреләләр, шул яктыда аның хыяллары күренә. Әйе, алдавыч утлар да бардыр, әмма алар кояш нур чәчкәч үк сүреләләр. Хәзер инде, шигырь агышында, Туган илгә мөрәҗәгать таләп итела:

[1] Мәкалә 1984 елның 23 декабрендә язылган.

Туган илем, көн дә минем күңелемә
Синең кояш изгелекләр булып инде,
Эштә түккән тирләремнең һәр тамчысы
Туфрагыңа мәхәббәтем булып сеңде.

Горурланам мин дә, дуслар, эшем белән:
Мин дә шаулы заманымның бер тамчысы.
Үзем сөйли белмәм кебек, сөйли белмәм,
Уйларымны сөйләр сезгә көн яктысы...

Сөйли Рәшит – уен-фикерен, Туган ил кояшы күңеленә иңдергән изгелекләрен, үзенең кылган гамәлен көннең яктысыннан сөйләтә. Чөнки көннең якты булуында Рәшитнең үз өлеше, эш кешесе өлеше, ниһаять, шагыйрь өлеше бар. Табышмак түгел, аңлаешлы фикер бу.

Кычкырып әйтүне без кайчакта гражданлык позициясе итеп кабул итәбез. Бу шигырьдә исә кычкыру юк, нәкъ менә шуңа күрә дә ул – шагыйрьнең гражданлык позициясенең ныклыгына саллы мисал. Рәшит үзе бүтән бер шигырендә әйткәнчә, «дәртле дә һәм моңлы да җыр» булып яңгырый бу шигырь, һәм аны шундый җыр итеп тыңлый да белергә кирәктер.

Югарыда телгә алынган «Нәни инеш» һәм «Үзем сөйли белмәм кебек...» исемле шигырьләрен Рәшит моннан егерме биш ел чамасы элек язган иде. Сүз уңаеннан, аның беренче китабы чыгуга да унтугыз ел икән.

Чирек гасыр узган Рәшитнең иҗатка килүенә. Хаклы сорау: үсеш, күтәрелеш бармы соң?

Бу сорауга Рәшитнең иҗаты белән таныш кеше һичшиксез уңай җавап бирәчәк, һәм аның иҗаты соңгы елларда колачын киңрәк җәя, шигърият мәйданында мондый көчле колач белән шикләнмичә бил алышырга мөмкин, әлбәттә. Шагыйрьнең соңгы еллардагы шигырьләре – моңа мисал. Мин бу фикерне, Рәшитнең «Казан утлары» журналында ел саен басылып килгән тук башаклы шигъри көлтәләрен һәм «Җан яктысы» исемле китабын укыгач, кульязма хәлендә яңа җыентыгы белән танышкач, ышану белән әйтәм. Шулай да мисаллар китерү кирәктер.

Рәшитнең «Казан утлары» журналында быел басылган «Кошлар бәйрәменә чакыру» циклындагы бер шигырендә мөрәҗәгать итеп әйтелгән мондый юллар бар:

Яшел болыннарда – яшьлектә кал,
Дулкыннарда яшә... Шауласыннар.
Ә мин китәм –
Ут күзенә кереп,
Кешеләргә бер җыр аласым бар.
Көт. Кайтырмын.
Дөрләп янсам да мин,
Күзләремдә калыр яфрак төсе.
Шул төс булыр сине сөюемнең
Мәңгелеге белән бүгенгесе.

Танымасаң, тагын бер кат кара –
Күзләремдә булыр яфрак төсе.
Күргәч... җәлләп берүк елый
күрмә,–
Каршы чык та кайткан юлларыма,
Сулыш кебек кирәк, син тизрәк
Туган туфракны сал кулларыма.
Бер уч туфрак...

Күрәсез, кешеләргә җыр алып чыгу өчен, шагыйрь ут күзенә керә. Соң, бу көрәш ләбаса инде! Һәм бу көрәштә җиңүче булгач та, шагыйрьгә туган туфрагы кирәк. Туган җирне яратуны Рәшит дүртьюллыгында болай дип белдерә:

Һәркем белә торган дүрт гамәлнең
Тик берсенә җаным буйсына –
Туган җирем,
Мең кат тапкырланган
Мәхәббәтем, нурым тик сиңа!

Шагыйрьнең үз сүзләре белән әйткәндә, аның «илне сөюе гомерлеккә».

Яшьлегемне үзең белән
Алып китмә, алсу таң!
Узмаган гомерне бирәм,
Әгәр миңа туктасаң.

Туган якның алсу таңы белән очрашу шулай ук Туган илне яратуның чагылышы булып аңлашыла.

Һәркемнең яраткан шигыре, хәтта ялгыз шигырь юлы буладыр. Андый юллар беренче укудан ук күңелгә сеңә. Мин дә кайчак шундый юлларны күңелемнән кабатлыйм. Тукайны искә төшерик:

Бар иде, ялгыз калып, җырлап юанган чакларым...

Рәшитнең дә күңелне кузгатырлык шигырьләре күп. Шуларның берничәсен мисал итик:

Бөртек идек. Илдә үстек!
Җилдә шаулыйбыз менә...
Әгәр җилдә искән булсак,
Читтә урып-сукмас иде
Безне, йә, кемнәр генә?!

Яки:

Җиңелмә сүздә, җиңелсәң –
Җиреңне дә дауларлар.
Юкка гынамыни җирдә
Чичән булган бабаңнар.

Яки:

Кабереңбулу мөмкин дошман
җирендә –
Тик дошманнар йөрмәсеннәр илеңдә.

Әйе, шагыйрь Рәшитнең егерме биш еллык иҗаты олыдан кубып сөйләшерлек. Иҗатының башлангыч елларында ул үзен «Мин дә шаулы заманымның бер тамчысы» дип белдергән иде. Соңрак Рәшит «Тамчы монологы» исемле шигырь язды. Анда ул, кайберәүләрнең «бер тамчының нәрсәсе бар...» дип әйтүләренә карамастан, бер тамчының нинди көчкә ия булуын күрсәтә. Чүлләр кебек кипкән иреннәргә җан биреп тамган тамчы исеменнән мондый сүзләр әйтелә анда:

Эссе көндә син, сандугач,
Мине эчтең;
Мин дөньяга моңлы җырың
Булып күчтем.

Хәзер, шуңа бәйле рәвештә, шагыйрьнең «Җан яктысы» исемле китабыннан дүртьюллыкны укып карыйк:

Сандугачлар диңгезләрдән түгел,
Чишмәләргә килеп су эчә.
Тагын сайрап үзәк өзәр өчен,
Моң эчәләр алар, минемчә.

Дөрес әйтә Рәшит – җырның дәртле дә, моңлы да булуы өчен, шагыйрь Туган җире чишмәсенә сукмакны онытмаска тиеш.

Нәни инеш... Тамчы...

Мин дә, Рәшиткә ияреп, шушы кечкенә нәрсәләр турында фикер йөрттем. Югыйсә чирек гасырлык иҗат турында зуррак итеп әйтергә тиеш идем, Рәшитнең шигырьләренә битараф калмаучы кеше буларак ягъни. Әмма Рәшитнең бер кечкенә шигыре белән сүземне тәмамласам, аның иҗаты турындагы фикерем кечкенә үк түгелдер. Кечкенәлек һәм зурлык турында шагыйрьнең фикере менә мондый:

Нәни исемнәр,
Нәни җисемнәр!
Нәни, димәдем
Сезне беркайчан.

Сез бит – дусларым!
Гомерем буе
Сездәге гүзәл
Зурлыкны ачам...

*«Татарстан» журналы.– 1995. – № 3–4*

# Шагыйрь истәлегенә

Фәнис Шәйдуллин

Якташыбыз, кабатланмас шигъри аһәңле ватанпәрвәр шагыйрь Рәшит Әхмәтҗанов, кызганычка каршы, бу дөньядан бик иртә китте. Әмма аның җан авазы белән иҗат ителгән әсәрләре, Татарстанның мөстәкыйльлеге өчен көрәштә ясалган фидакяр адымнары халык күңелендә саклана.

27 ноябрьдән алып 29 ноябрьгә кадәр безнең районда шагыйрьнең каләмдәшләре, дуслары, туганнары, бер төркем әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләре булды. Алар Баулы төбәгенә шагыйрьнең исемен мәңгеләштерү юнәлешендә эшлекле тәкъдимнәр алып килгәннәр.

Бу изге адымны башлап йөрүче төркемнең җитәкчесе – Сара Садыйкова исемендәге Мәдәни-хәйрия фонды рәисе Әзһәр Хөсәенов. Шагыйрьнең истәлеген олылап килгән әдипләр һәм сәнгать кешеләре арасында Татарстанда гына түгел, аннан читтә дә танылган шәхесләр бар. Танылган җырчы Габдулла ага Рәхимкулов, композитор Сафьян Ибраһимов, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире урынбасары Рашат Низамиев, милли эстрада йолдызы, җырчы Фердинанд Сәлахов, ялкынлы публицист һәм язучы, «Аргамак» журналының баш мөхәррире Айдар Хәлим, оста баянчы Ринат Габдрахманов бар. Бу очрашуга шагыйрьнең тормыш иптәше Луиза ханымның һәм бертуган энесе – Татарстанның атказанган артисты Илдус Әхмәтҗановның килүе дә нур өстенә нур булды.

Кунакларны Баулы һәм Бөгелмә районнары чигендә хакимият һәм җәмәгатьчелек вәкилләре ипи-тоз белән каршыладылар. Кышкы озак юлда ару-талчыгуларына карамастан, алар шул ук көнне Рәшит Әхмәтҗановның туган авылы Кандызда шагыйрьнең авылдашлары, туганнары белән очрашу кичәсе уздырдылар, ул укыган мәктәптә булдылар.

Кичәдә хезмәттәшләре, дуслары, туганнары шагыйрь турында истәлекләр сөйләделәр. Рәшит Әхмәтҗанов шигырьләре, аның сүзләренә язылган җырлар башкарылды.

Икенче көнне иҗат группасы район хакимияте башлыгы Н. Ш. Зарипов, аның урынбасарлары һәм хакимият хезмәткәрләре белән очрашты. Чәй табыны артында барган эчкерсез әңгәмәдә шагыйрьнең истәлеген мәңгеләштерү юнәлешендә конкрет чаралар билгеләнде. Анда Рәшит Әхмәтҗановның каберенә һәйкәл кую, районда аның музеен булдыру һәм башкалар күздә тотыла.

Шул ук көнне кунаклар татар гимназиясендә, 5 нче урта мәктәптә, сәнгать мәктәбендә булдылар. Шагыйрь турында истәлекләре белән уртаклаштылар.

Кичен Муса Җәлил исемендәге Мәдәният йорты шыгрым тулы иде. Шагыйрьнең иҗатын яратучылар һәм белүчеләрнең күплеге әнә шунда да чагылды. Рәшит Әхмәтҗанов истәлегенә багышланган очрашуны район хакимияте башлыгының беренче урынбасары М. М. Абдуллин ачты.

Сара Садыйкова исемендәге Мәдәни-хәйрия фонды җитәкчесе Әзһәр Хөсәенов иҗат группасының Баулыга килүенең максаты – шагыйрьнең иҗатын пропагандалау, аның истәлеген мәңгеләштерү юнәлешендә эшкә керешү икәнен әйтте. Рәшит Әхмәтҗанов киләчәктә әдәбиятта үзенең бөеклегенә лаек урын алачак әле, диде ул.

Шагыйрьнең студент еллары дусты, публицист һәм язучы Айдар Хәлимнең чыгышы һәркемнең күңеленә үтеп керерлек булды. Ул шагыйрьнең олы йөрәкле, керсез күңелле, милләтебез, те-



**Рәшит Әхмәтҗанов туган йорт. Татар Кандызы**

лебез, Татарстаныбызның бүгенгесе һәм киләчәге өчен җан атып йөргән олы шәхес булуын калку чагылдырды. Рәшит Әхмәтҗанов татар шигъриятен Тукай туктаган урыннан алып китте, диде ул.

Язучы Рашат Низамиев Баулы төбәгенең Фәнис Яруллин, Рәшит Әхмәтҗанов кебек каһарман уллары белән горурлана алуына басым ясады, аның Татарстанның бәйсезлеге өчен көрәштәге фидакяр адымнары турында әйтеп узды.

Татар эстрадасы йолдызы Фердинанд Сәлахов Рәшит Әхмәтҗановның риясыз, асыл зат булуын сөйләгәндә, дулкынланмый калырга мөмкин түгел иде. Ул шагыйрь сүзләренә язылган җырларны башкарганда, зал алкышлардан тынып тормады.

Шагыйрьнең бертуган энесе – Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артисты Илдус Әхмәтҗанов – бөтен залны тетрәтердәй итеп, абыйсының шигырьләрен укыды. Ә район газетасының хәбәрләр бүлеге мөдире Сәгыйть Әхмәтҗанов тирән хис белән аның җырларын башкарды.

Рәшит Әхмәтҗановның хатыны Луиза ханымның истәлекләре дә һәркемнең йөрәгенә үтеп керерлек булды.

Халкыбызның яраткан җырчысы Габдулла Рәхимкуловның һәм композитор Сафьян Ибраһимовның чыгышлары кичәгә үзенчәлекле төсмер һәм ямь бирде.


Кичәнең буеннан-буена Рәшит Әхмәтҗановның рухы сизелеп, гомумхаләттә чагылып торды.

Кунаклар шагыйрьнең якташларына ачык йөзләре, әдипнең якты истәлеген йөрәкләрендә саклаулары өчен рәхмәт әйтеп, киләчәктә тагын да очрашырга насыйп булсын, дип саубуллаштылар.

*«Хезмәткә дан» газетасы.– 1995. – № 103*




**Шагыйрь туган нигездә яшәүче Ильяс Әхмәтҗанов-ның кызы – Татарстанның атказанган укытучысы Нәфисә Мифтахова Васил Шәйхразиев белән**



**Илдус Әхмәтҗанов Р. Әхмәтҗановның 60 еллыгына багышланган кичәдә шагыйрьнең шигырьләрен укый**



**Фердинанд Сәлахов Р. Әхмәтҗановның 60 еллыгына багышланган кичәдә чыгыш ясый**



**Мәктәп укытучылары Р. Әхмәтҗановның 75 еллыгына багышланган кичәдә шагыйрь сүзләренә язылган «Акчарлаклар» җырын башкаралар**



**Баулы районы Татар Кандызы мәктәбенең укытучылар коллективы**

# Акчарлагы иде Иделнең

## Равил Вәлиев

Үрмәкчедән күрмәкче дигәндәй, заман шаукымына ияреп, көннәрдән бер көнне без дә ут күршем белән тышкы коридорга тимер ишек куйдырттык. Җан рәхәте хәзер: ял көннәрендә авылга яки дачага китеп баргач та, төнлә йокларга яткач та, ишекне кайчан каерып керерләр икән, дип, бер дә куркып вәсвәсәләнәсе юк!

Тик менә ике гаиләгә уртак йозак булгач, ачкычлары җитми кала икән, каһәр төшкере. Мондый чакта инде, билгеле, мастерскойга барып, тизрәк яңа ачкыч ясаттыру ягын карыйсың.

Киттем шулай чыгып мин дә тиешле кярханәгә. Ачкыч ясаучы агай каядыр киткән иде, күрәсең:

— Хәзер килер, рәхим итеп, азрак йөреп керегез,— диделәр.

Безгә нәрсә: бар дисәләр — барасың, кайт дисәләр — кайтасың! Ачкыч-өлгене заказлар кабул итә торган ханымга биреп калдырдым да киттем чыгып Свердлов урамына.

Бер көйгә генә атлап барган җиремнән, каршымда пәйда булган ике катлы агач бинага күзем төшеп, кинәт мин имәнеп киткәндәй булдым. Тукта, чү, «Таң» дип аталган балалар бакчасы түгелме соң әле бу? Шулай икән бит!

Еллар, еллар...


Ә бит чирек гасырлап элек Казан дәүләт университетында бергә укыган группадаш дустыбыз, татарның иң күренекле шагыйрьләреннән берсе булып җитешкәч кенә, быел кышын бөек Тукаебыз кабере янәшәсенә иңдерелгән Рәшит Әхмәтҗанов алтмышынчы еллар азагында нәкъ менә шушы балалар бакчасында төнге каравылчы булып эшләп йөргән иде. Иртән һәм кичләрен кулында — себерке-көрәк. Ә көн саен чистартылып торылырга тиешле бакча юлларыдай озынозак кышкы төннәрдә — бер-бер артлы ургылган шигырь, шигырь, шигырь! Иртәгесен иртүк исә, төнге шигъри хисләр дулкынында йөзә-йөзә кызарышып беткән күз-керфекләрне тырнап ачып, тиешле лекцияләрне тыңлар өчен, тагын университет аудиторияләренә чыгып чабасы бар.

Әлбәттә, «эшләп укыгач», инде күптән шагыйрьлек юлын сайлаган Рәшитебезнең көндезге лекцияләргә еш кына килми калган чаклары да булмады түгел. Мондый вакытларда без, гомергә тамаклары туймаган ач корсаклы бер төркем студентлар, сабакташыбызның хәлен белеп кайту сылтавы белән, Свердлов урамындагы балалар бакчасының «өченче» каттагы чарлагына җыйнала торган идек.

Инде кич җиткән. Бер минут тик тормый торган кыбырсык балалар өйләренә кайтып китеп, бакча бинасы да көндезге шау-шудан тынып калган. Рәшитебезнең шигырь яза торган карандаш кебек нечкә-ябык, ләкин кайчандыр Әлмәт каласында үзе тезгән кирпечләрдәй каты һәм үтә тырыш куллары бакча ишегалдында инде күптән көрисен көрәп, себерәсен себереп куйган.

Ә аскы каттагы кухнядан, безнең гаҗәеп сизгер борыннарны кытыклый-кытыклый, ифрат тансык итле ботка исе күтәрелә. Төнге каравылчыга дип махсус калдырылган әлеге ботканы бераздан чарлакка алып менә дә Рәшит, үзенең сабакташларын әүвәл телләрне йотарлык тәмле ризык, аннары шундый ук тәмле шигырьләре белән сыйлый.

Хәтердә әле: 1967 елның җәендә бугай, безнең тарих-филология факультеты студентларын «чирәм җир»гә — Алексеевск районындагы Ялкын авылы фермаларын төзергә җибәрделәр. Уни-



**Солдат хезмәтеннән кайтып, Казан дәүләт университетына кабул ителгәч. Сулдан уңга: Равил Вәлиев, Рәшит Әхмәтҗанов, Айдар Хәлим. 1964**

верситетка кергәнче ташчы булып эшләгән Рәшитебез биредә үзен күлдәге балыктай хис итте. Көндезләрен, ике-өч кешелек норманы үти-үти, булачак ферма стеналарына кирпеч тезде. Иртәкичләрен исә, иске такталы агач сәкегә йөзтүбән ятып, кайнар хисле шигырьләрен язды.

Бер караңгыдан икенчесенә хәтле дәвам иткән ярсу хезмәт, ашкынулы яшьлек хыяллары белән тулы әнә шундый көннәрнең берсендә, кунак булып, безгә Казаннан ике кыз килде. Икесе дә чибәрләр, икесе дә Луиза исемле.

Авырткан җирдән кул китми, яраткан җирдән күз китми дигәндәй, җылы карашы ук әйтеп тора: аларның берсе – каратут йөзле һәм кечерәк буйлысы, әлбәттә, Рәшитебезнең булачак кәләше иде. (Һәм бу, берничә ел үткәч, нәкъ шулай килеп чыкты да). Казан медицина институтында теш табибы булырга укый, ди.

Билгеле, ике Луизаны без хәлдән килгәнчә кунак итәргә тырыштык. Ә инде Рәшитебезне әйткән дә юк – ул ерак араларны якын итеп килгән «тәнәкәй» кызын өрмәгән җиргә дә утыртмады!

Казан кызлары, тәмле әйбер күп булмас дигәндәй, икенче көнне үк китеп бардылар. Тик алар калдырып киткән моңсулык пәрдәсе «чирәм җир»дә байтак көннәр эленеп торды әле.

Ерактагы сөйгән ярын сагыну-саргаюдан Рәшитебез аеруча интекте. Аз гына каршы җил исеп куйса да бик тиз яралана торган нечкә күңеленә урын тапмаган әнә шундый моңсу-юксынулы кичләрнең берсендә, гадәтенчә, агач сәкесенә йөзтүбән ятып, ул үзенең хәзер күпләргә мәгълүм булган «Акчарлаклар» исемле шигырен язды:

...Сөйгән ярым китеп барды
Кулын болгап.
Җаным көчле – мин кайтырмын
Юллар урап.

Акчарлаклар, акчарлаклар,
Акчарлаклар!
Мәхәббәттә кирәк икән
Пар канатлар.



Равил Вәлиев һәм Рәшит Әхмәтҗанов кунакка килүче ике Луиза белән

Үзе гаҗәеп моңлы, үзе искиткеч музыкаль яңгыраган, бер строфада «акчарлаклар» сүзенең өч мәртәбә кабатлануы диңгез-елга күгендә ачыргаланып елаучы акчарлаклар тавышын хәтерләткән бу шигырь миңа шулкадәр көчле тәэсир итте ки, янымда ярым ватык баян булудан һәм азмы-күпме нота белүемнән (Арча педучилищесында укыган елларда өйрәткәннәр иде) файдаланып, мин әлеге юлларны тиз генә көйгә салдым. Без «чирәм җир»дән кайтып, яңа уку елы башланган көннәрдә, нотасы белән бергә «Акчарлаклар» җыры «Татарстан яшьләре» газетасында басылып та чыкты һәм студентлар арасында таралып та өлгерде кебек.

Минем ише һәвәскәр тарафыннан чыгарылган көйнең, әлбәттә, шуннан артыгына куәте җитмәде. Ә Рәшитнең көчле каләменнән төшкән көчле сүзләр үзләренә шундый ук көчле музыканың язылуын таләп итте.

Һәм менә ул көн килде. Шәриф Камалның «Акчарлаклар» повесте буенча куелырга тиешле спектакльгә (сценарий авторы – Г. Ахунов) гаҗәеп аваздаш яңгыраган әлеге шигырьгә композитор Хөснул Вәлиуллин менә дигән көй иҗат итте. Ә йомшак-бәрхет тавышлы Зәйтүнә Әхтәмова тарафыннан радио аша башкарылгач, ул көй халык арасында бик тиз популярлашып китте.

Ә инде «чирәм җир» мәсьәләсенә килгәндә, без ул елны Кама буеннан кесәләрне шактый калынайтып кайттык. Һәм, көн күрмәгән көн күрсә – көндез чыра яндырыр дигәндәй, Казан кибетләренә ябырылдык. Кечкенәдән этисезлек камчысын татып, аннары сугыш арты кыенлыкларын кичереп үсүе аркасында моңарчы юньле кием күрмәгән Рәшитнең күптәнге хыялы – кеше арасына чыгарлык һәм затлы бер кәчтүм-чалбар юнәтү иде. Әнә шул хыялны, ниһаять, тормышка ашыру йөзеннән киттек беркөнне икәү кибеткә.

Кесә тулы акчалы мондый бәхетле көннәр безнең ише ярлы-ябагай студент халкына бик сирәк тәтегәнлектән, күр-шат минутларыбызны мөмкин чаклы озаккарак сузу өчен, әлбәттә, без Казан кибетләрен әүвәл бер кат әйләнеп чыктык. Аннары гына иң ошаган кәчтүм-чалбарлы кибеткә әйләнеп кайттык.

Инде тиешле акча кассага түләнде, буй-буй сызыклар төшерелгән соргылт-көрән кәчтүм-чалбар да чытырдавык кәгазьгә бик пөхтәләп төрелде. Шулчак, Кызыл Позиция урамындагы тулай торагыбызга кайтып китәргә торганда, Рәшитнең каршыда эленеп торган озын итәкле, кыек якалы, калын путалы бер халатка күзе төшмәсенме! Әллә ни искитәрлек җире дә юк кебек болай үзенең, нәкъ халык мәзәкләрендә сөйләнгән Хуҗа Насретдин халаты инде менә!

Нишләтәсең, күз төшкәч – киеп карамыйча булмый. Рәшитнең ачлы-туклы килеш кар көрәп, урам себереп, төннәрен исә бертуктаусыз шигырьләр яза-яза карга чукырлык ите дә калмаган арык гәүдәсенә, кем әйтмешли, болай да йөгән элеп куярлык! Үзенә ошаган теге киң-озын халатны киеп җибәргәч, ул бөтенләй бакча карачкысына охшап калды.

— Ишәк муенына эленәчәк бу мәрҗәннең нигә кирәге бар инде, Рәшит дус? — дияргә мәҗбүр булдым мин, аптырагач.

Башка вакытларда, аз гына ярамаган сүз әйтеп җибәрсәң, ул бик тиз үпкәли торган иде. Бу юлы исә сүзнең аңгыралык һәм ялкаулык символы булган ишәк турында түгел, ә җәй буе хәләл тиребезне түгеп алган күпме акчабызны суырачак купшы халат хакында баруын аңлап, Рәшит сырт йоннарын кабартып маташмады.

Тик аның үз туксаны туксан иде. Җаны теләгән — елан ите ашаган дигәндәй, тәки сатып алырга туры килде бит әлеге «буржуй» халатын. Алуын алдык... Әмма душка кереп чыккан көннәрендә бер-ике мәртәбә кигән булды да, әлеге халаты турында Рәшитебез бөтенләй онытты. Әллә берәрсенә бүләк итте ул аны, әллә инде озын куллы ябагайлар чәлдереп тә өлгерделәр үзен.

Халаты халат... Безнең ише ни фатиры, ни кереп юынырлык ваннасы булмаган ярлы студент халкына анысы, кем әйтмешли, шәрә билдәге каеш бау кебек инде.

Ә менә затлы кәчтүмнән колак кагу мәсьәләсенә килгәндә, эш болай була. Энәдән генә төшкән яңа киемен киеп беркөнне Бауман урамыннан барганда, Рәшитебез Баулы районыннан килгән бер якташын очрата. Үзенә «чыбык очы — ботак» кадәрле генә туганлыгы да булган әлеге агайның көтмәгәндә өе янып киткән икән. Шуңа түләнергә тиешле акчаны юллап, Казан тикле Казанга килеп чыккан. Өстендә — киеләсе киелеп, инде тузып беткән алама кием.

Шулчак олы җанлы Рәшитебез нишли дисезме? Өстендәге яңа кәчтүмен сала да, ике дә уйламыйча, бәлагә тарыган якташына суза:

— Мә, туган! Әле синең Казан түрәләре янына керәсең бар...

Һәм, кешегә яхшылык эшли алуына кош тоткандай сөенеп, үз юлыннан китеп бара.

Их, Рәшит, Рәшит!

Әле ничек ул чакта теге якташыңа соңгы чалбарыңны салып бирмәгәнсең! Иманым камил: Бауман урамы хәтле Бауман урамында әгәр ялангач калырга туры килмәсә, син, билгеле, монысын да эшли алган булыр идең! Чөнки син шундый Кеше идең!

Сүз уңаеннан әйтеп үтәсем килә: мин үзем, шәхсән, шигърияттә дә, кырыс тормышта да гомер-яшәеш ваклыкларына бирешмичә чын шагыйрь булып кала алган, бернинди риясыз һәм нарасый күңелле бары өч татар шагыйрен генә беләм. Аларның беренчесе һәм иң күренеклесе, әлбәттә, Хәсән ага Туфан. Икенчесе — арабыздан шулай ук иртә китеп барган Чаллы шагыйре Хәниф Хөснуллин. Өченчесе — сабакташ дустыбыз Рәшит Әхмәтҗанов...

Ә тимер ишек ачкычын бу юлы тәки ясаттырып булмады: кярханә остасы авырып киткән икән — тагын берничә көннән килеп чыгарга куштылар.

Ләкин мин һич үкенмәдем. Чөнки, шактый ерак калган моңсу еллар истәлеген яңартып, тимер ишегем түгел, кайнар яшьлегем ачкычын тапкандай булдым.

Хуш, «Таң» бакчасы!

Хушыгыз, ашкынулы студент еллары!

Хуш, Рәшит дус! Сине сагынып җаннар бәргәләнгән минутларда мин әле монда тагын, тагын килермен.

Ә көзге урамда, кыштыр-кыштыр килеп, агачлардан сары яфраклар коела. Ул сары яфраклар, әрнүле сагыш-моң уятып, аякларга гына түгел, йөрәк хисләренә дә килеп урала:

Быел көз дә бигрәк сәер килде:
Тышта эссе — яфрак коела,
Рәшит дустым!
Синең гомерең дә
Иртә килгән көздәй тоела.

Көзең — иртә, көлтәләрең — мулдан,
Өем-өем шигъри көшелләр...
Ул көшелдән, җан азыгы табып,
Авыз итә бүген кешеләр.

*«Шәһри Казан» газетасы.— 1995. — 22 сентябрь*

# Шагыйрьгә туган җире ихтирамы

Гариф Ахунов

Без, бер төркем язучылар, артистлар һәм шагыйрьнең хатыны Луиза ханым, күренекле шагыйребез Рәшит Әхмәтҗанның туган жиренә — Баулыга барган идек. Бу эш шагыйрьнең вафатына бер ел тулу уңаеннан эшләнде. Баулы хакимияте башлыгы Наил Шамил улы Зарипов кунакларны гаять зур ихтирам белән каршы алды, безгә данлы Баулы каласының һәм шул районның ирешкәннәре, ирешәчәкләре хакында сөйләп, үзләрендә туып үскән әдәбият-сәнгать әһелләре белән горурлануын белдерде. Иртә вафат булган мәшһүр шагыйрь Рәшит Әхмәтҗан турында ул аеруча дулкынланып сөйләде. Баулыда аның исемендәге



Гариф Ахунов хатыны Шәһидә белән

Әлмәт шәһәрен төзүчеләр






**Илдус Әхмәтҗанов абыйсының кабере янында**

урам булачагын, шушы көннәрдә Баулыда шагыйрьгә музей ачылачагын һәм хакимиятнең Рәшит Әхмәтҗан каберенә һәйкәл куярга унбиш миллион сум акча бирүен хәбәр итте.

Мин бу хәбәрләргә аеруча шатландым. Чөнки Рәшитне егет чагында Әлмәткә китереп, Социалистик Хезмәт Герое ташчы Рәшит Саттаров бригадасына мин урнаштырган идем, аның беренче шигырьләрен, үзе солдатта чакта, «Хыялларым үзем белән» дигән исем кушып, аерым китап итеп чыгарган идем.

Баулы хакимияте башлыгы, әдәбият һәм сәнгатьне биш бармагы кебек белүче Наил Зарипов сүзен җилгә очыручылардан булып чыкмады. Әдәби кичәләр бик зур зәвык белән, акыллы итеп оештырылган, Татарстанның атказанган артисты, Рәшитнең энесе Илдус абыйсының шигырьләрен язылганча кайнарлыгы белән, үзәкләргә үтәрлек итеп укый. Баулы төбәге кешеләре якташларының поэзиясен ихтирам белән бирелеп тыңлыйлар иде.

Иртәгесен без Рәшит Әхмәтҗанның Баулыдагы музеен карадык. Бик зур һәм якты бер залда шагыйрьнең тормышы, иҗаты тулы чагылган, монысына инде, хакимият белән бергә, шагыйрьнең гомер юлдашы Луиза ханым да күп көч куйган: Рәшитнең китаплары, кулъязмалары, язу әсбаплары, киемнәре, зур бүләкләре алдан ук әзерләп бирелгән, шагыйрь Әхмәтҗанның бер метр зурлыктагы портреты рәссам тарафыннан ясалган. Шушы ук залда яшь рәссамнарның лирик пейзажлары куелу да шагыйрь лирикасына ямь өсти иде.

Инде менә Баулы хакимияте башлаган изге эшнең гүзәл нәтиҗәләреннән тагын берничәсе билгеле булды. Мәшһүр шагыйребез Рәшит Әхмәтҗан каберенә һәйкәл-таш куелды. Баулы хакимияте биргән акчага шагыйрьнең хатыны Луиза Әхмәтҗанова, бертуган энесе Илдус Әхмәтҗановның да өлешләре өстәлгәч, кабер өстендә кара граниттан таш, таш өстендә Шагыйрьнең портрет-барельефы, шагыйрьнең үз шигыреннән шундый юллар пәйда булды:

Бөек халкым – давыл кочагында,
Минем җаным шунда – Халкымда!

Баулы каласында Рәшит Әхмәтҗан урамы да барлыкка килде. Элек, торгынлык елларында, кабер өстендәге таш-һәйкәлләрне Язучылар берлеге куя иде. Хәзер, үзгәртеп кору заманында, язучыларга андый акча бирелми. Шуңа күрә без, Татарстан әдипләре, Баулы хакимият башлыгына, шагыйрьнең гомер юлдашы Луиза ханымга, бертуган энесе Илдуска, таш-һәйкәлне ясаган рәссам Александр Кузьмич Кисловка кайнар рәхмәтебезне белдерәбез. Арча хакимияте башлаган зур эш – әдәбият-сәнгать әһелләренә булган ихтирам башта Зәй районы хакимиятенә күчте, аннары Әтнәгә, Балтач, Апаска, Азнакай, Теләче, Кукмара, Биектауга, ниһаять, зур булып, Баулыга да барып җитте. Чаллы, Әлмәт, Лениногорск, Мамадыш калаларында ул күптән бар иде инде, бу изге эшкә башка төбәкләр дә кушылыр дигән өметтә калабыз, чөнки мәдәнияттән башка халык язмышын күз алдына китереп булмый.

*«Ватаным Татарстан» газетасы.– 1996. – 27 ноябрь*

# Вөжданны уятучы иде

## Зөфәр Сәлиев

Шөкер әле, халык безнең якта –
Үләчәкбез җылы кочакта.
*Р. Әхмәтҗанов*

Әйе, ул үлде. Былтырның гыйнвар аенда, 55 яшен тутырырга бер ел кала, йөрәге шартлап үлде. Җылы кочакта дип әйтә алмыйм, ул күзаллаган азат, мөстәкыйль татар дәүләтен Рәшит Әхмәтҗанов язмышы көтмәсә ярар иде, дип, бер Тәңремә ялварам.

Инде нишләргә дә кемнән илаһи ярдәм көтәргә? Рәшит бәгърем дә үзенең соңгы, «Ачлык мәйданы» китабындагы бер шигырендә татар милләтенең төпсез кара коедан тиз генә чыга алмаслыгын кисәтеп куя кебек:

Кемдер монда ирек даулый,
Кулында – милләт байрагы.
Кемдер безгә коллык яулый –
Аның да бар үз байрагы...
Ә иртәгә,
кемнәр килеп
Нинди байрак эләр тагы?

...Без аның белән 1991 елның коры, эссе маенда «Ачлык мәйданы»нда танышып, гомерлек дуслар булырга сүз куешкан идек. Дуслыгыбыз озын гомерле булмады. Мәрхәмәтсез үлем ни өчендер аны тизрәк җир куенына кертеп яшерергә ашыкты. Әмма ул минем күз алдымда хәзергәчә теп-тере килеш тора. Халык хәтере исә аны үз гомере буенча саклар. Шуңа ышанасы килә. Чөнки анда милләтебезнең гасырлардан килгән аһ-зарын туплаган бөек Тукай рухы бар, азат татар милләте өчен көрәштә шушы какча гына гәүдәле, мөлаем йөзле асыл затта арысландай көч бар иде. Олуг шагыйрьнең түбәндәге сүзләре әле дә колагымда чыңлый, һәм аны татар җанлы барлык кешеләр ирек даулау көрәшебездә шигарь итеп алырлар дип уйлыйм:

Империя! Илем булалмадың,
Син кол итеп тоттың татарны.
Өметләрен өздең! Хәзер алар
Берсен берсе эзләп табармы?

Әй эшләдек! Ашыбызга каршы
Башыбызга һәрчак таш аттың.
Каткан икмәгеңне гомер буе
Күз яшемә манып ашаттың.

Шундый итеп таркатлдың: хәзер
Халыклардан калды төркемнәр,
Кеше ни ул?! –
Хәтта кояшны да
Кол итәргә монда мөмкиннәр.

Кояш җиргә гел урысча дәшә,
Ай частушка сибә төн буе.
Чын вә ялган кочаклашып эчә,
Беркем белми – монда кем туе?

Рәшит Әхмәтҗановның шигырьләрен укыйм да, күземнән яшь тамчылары тәгәри. Нәкъ мин уйлаганны шигъри сүзләр белән ярган да салган! Аның «Ачлык мәйданы» исемле әлеге соңгы китабы (1993 ел), әгәр Гөлзадә Сафиуллина кебек танылган җырчыбыз, Илгиз Бариев кебек милли җанлы эшкуарыбыз булмаса, кем белә, хәзергә кадәр Татарстан китап нәшриятында чират көтеп,



**Азатлык юлында. Сулдан уңга: Фазыл Вәлиәхмәт, Рәшит Әхмәтҗанов, Зөфәр Сәлиев. Казан, 1991**

тузан җыеп ятар иде. Йа Хода, димен, мәрхәмәтең киң, кылыр игелегең чиксез! Татар күзен ачар өчен бөек затларыңны сирәк кенә булса да дөньяга китерә торасың...

Рәшит турында сүзне мин иң әүвәл бөек шагыйребез Хәсән Туфан авызыннан ишеткән идем. Мәктәп директоры булып эшләгән чагым. 1968 елда бугай, Хәсән ага белән озаклап гәпләшү бәхетенә ирештем. «Инде Сез олыгайдыгыз, татар поэзиясендә Сезнең урынга лаек алмаш бармы?» — дип сорыйм. Иң элек Рәшит Әхмәтҗанов исемен атады. «Бөгелмә ягыннан бер егет килде, коеп куйган талант»,— ди. Ул ни өчендер Бөгелмә ягы, диде. Р. Әхмәтҗановның Баулы районы Татар Кандызы авылында туып үскәнен мин соңрак белдем.

Шуннан бирле аның иҗаты белән кызыксынып, аны күзәтеп тордым, һәм, ниһаять, 1990—1991 еллар. Татар милләтенең кабаттан йокыдан уяну чоры. Рәшит Әхмәтҗанов кебек ир-егетләр йөрәгендәге тышаулы атлар тыпырчынып, атылып-бәрелеп богаудан ычкынды:

Коллыкны яндырып каныбыз дөрләсен,
Дөрләсен, сүнмәсен — ант итик, Ватанчы:
Йә бозлы йортыма азатлык яуларбыз,
Йә янып бетәрбез — кол булып калганчы!

Инде тарихта калган кебек көннәр. Шулай да мин ул чорны юксынам — татлы вә газаплы көннәрне. 1990 ел: мөстәкыйль дәүләт төзеячәгебез турында Декларация кабул иттек. 1991 ел.

Тиздән Татарстан һәм Россия президентларын сайлау көтелә. [...] Күңелем белән тагын Аллаһы Тәгаләгә инәләм: «Син бар икән, бер икән һәм чиксез мәрхәмәтле икән!» Суеш булмый калды...

Әмма ул чактагы Татарстан халык депутаты, «Иттифак» милли-азатлык фиркасе рәисе, милләт анасы Фәүзия Бәйрәмова, «Мәрҗани» җәмгыяте президенты Зәки Зәйнуллиннар җитәкчелегендә бер төркем милләтпәрвәрләр Россия Президентын бездә сайлатуга протест йөзеннән Ирек мәйданында (Рәшит Әхмәтҗанов соңрак аны «Ачлык мәйданы» дип тарихка кертеп калдырды) ачлык игълан иткәннәр.

1991 елның эссе мае. Мәйданда көне-төне халык диңгезе чайкала. Ачлык игълан итүчеләргә башка татарлар кушыла: Алма-Ата каласыннан Нәкыя Зиннурова һәм Сәлим Әбү-Бәкер, Чаллыдан Әнисә Нурисламова, Гөлсирә Лотфуллина, Гөлнур Хәйруллина, Марат Арслановлар... Бакудан Азәрбайҗан халык депутаты, дин әһеле Абдул Алмаз углы, Алексеевск районының Әшнәк авылыннан бертуган Рифкать һәм Зиннур Шәмсетдиннәр, Казан шагыйре Газинур Морат, язучы Әхәт Мушинский, журналист Заһид Мәхмүди... бертуган шагыйрь Рәшит һәм Г. Камал театры артисты Илдус Әхмәтҗановлар — барысы 18 кеше.

Рәсми рәвештә рөхсәт алып, кирәкле кәгазьләрне тутырып, мин дә 19 нчы кеше булып ачлык игълан иттем.

Бәхетсезлек буенча, дөресрәге, Татарстан азатлыгы хакына көрәшкә күтәрелгән «коллегаларым» 14 көн буена ачлыкның бөтен җәфасын күрсә, миңа аның 12 көне эләкте. Кирәк идеме бу соңгы чара? Без бит, таләпләребез үтәлмәсә, милләтебез хакына ачлыктан үләргә әзер идек.

Хәзер әйтә алам: бу соңгы чарага барырга без мәҗбүр булдык. Таләбебез өлешчә генә үтәлсә дә — Россия Президентын Татарстан халкы сайламады, димәк, аның указ-муказларын үтәү безгә мәҗбүри түгел — без милләтебезгә күпме дәрәҗәдәдер игелекле эш кылдык диеп әйтергә мөмкин.

Ә иң мөһиме — халыкны уята, җәмәгатьчелек фикерен үз ягыбызга авыштыра алдык. Баштагы көннәрдә митингларда 2–3 мең кеше тирәсе иде. Ә дөнья, Россия һәм газиз Татарстаныбыз газеталары яза башлагач, без геройларга әйләндек. Хәтерлим әле: «Шәһри Казан»ның ул вакыттагы Борис Антонов дигән, хәзер язмаларына Барис Айтуганов дип кул куючы хәбәрчесе, көн саен килеп, хәл-әхвәлләребезне, уй-теләкләребезне белешеп йөрде һәм газетасында язып чыкты. Нәтиҗәдә 2–3 мең кешедән башланган митинглар 5, 10, 25 һәм тора-бара 50 мең кешене җыя башлады!

Азатлыкны яклаган керәшене, урысы, татары, чувашы — һәммәсе дә безнең белән булды. Хәтта Камил Камалов кебек артистлар, күңелебезне юатырга теләп, курайларда уйнап, җырлар җырлап утырдылар.

Моны ни өчен язам? Тукай мәгълүм истәлегендә «аягымда шул үги апам чапкан кәрәктән тирән җәрәхәт җөе әле дә саклана, шуңа күрә язам» ди. Ә минем күңелемә татар милләтенең хәзерге хәле каны саркып тора. Тукай:

Җырлый-җырлый үләрмен мин үлгәндә дә,
Дәшми калмам Газраилне күргәндә дә.
«Без китәбез, сез каласыз!» дип җырлармын,
Җәсадемне туфрак берлән күмгәндә дә,—

дип җырлап үлсә, Рәшит Әхмәтҗанов безнең арадан болайрак җырлап китеп барды:

Яши башлыйк дисәк — баш кыелды,
Ә яшәсәк — күздән яшь тамды...
Сөякләрдән торган тауны ишеп,
Тарихыбыз бүген уянды!

Үлгәнчегә кадәр дус булырга вәгъдә бирешкән Рәшитем хәзер юк инде. Аның 55 яшь тулган көнен билгеләп тә үткән булыр идек. Нишләмәк кирәк?!

Җанны әрнеткән шигырьләре калды, якты, зур юлга күрсәтүче иманы калды. Алты яшәр юлдан кайтса, алтмыш яшьлек хәл белә килер дигән сүз бар татарда. Инде мин җитмештә, улымдай

якын күргән, илбашы булырдай акыл-фигыльгә ия ул углан төшләремә кереп төрткәли. Җанымны өтәли:

Күрә алмас идек бүгенгене,
Җиңалмаган булсак үлемне.
Офыклардан Кояш чыгып килә –
Безнекеләр каны түгелме ул,
Безнекеләр җаны түгелме?!

Фидаилар белән бу дөньяны
Пычрагыннан күпме тазарттык.
Шушы җаннаргамы тиеш түгел
Дөньядагы Бөек Азатлык?!
Азатлык!
Азатлык!!
Азатлык!!!

Рәшит Әхмәтҗановны күз алдыма китерәм дә, күземнән яшь ага. «Әй, җаным, шагыйрь булсам, син ут салган әләмне ялкынлы шигъри сүздә милләттәшләремә җиткерер идем!» Ә ул сәләт миңа бирелмәгән... Рәшит, татар халкы җанын янар таудан чыккан ташкынга тиңләгәнсең икән, әле ул янар ташкын ут дәрьясына әйләнер!

*Редакциядән*: Соңгы көннәрдә мәрхүм Рәшит Әхмәтҗановның 55 яшьлеге уңаеннан Казан китапханәләрендә дистәләрчә конференцияләр үтте. Гомерләрен татарның милли бәйсезлеге көрәшенә багышлаган йөзләрчә кеше Рәшит Әхмәтҗанов рухы алдында ант эчте. ТИҮ шулай ук Рәшит Әхмәтҗанов исемендәге фонд оештырып, һәр елның апрелендә аңа багышланган конференцияләр үткәрүне, Татарстанның мөстәкыйльлеге өчен җан атып йөрүче милләттәшләрне Рәшит Әхмәтҗанов исемендәге истәлекле бүләкләргә тәкъдим итү мәсьәләләрен карады. Татар милли-азатлык хәрәкәте җитәкчелеге Рәшит Әхмәтҗановның исемен мәңгеләштерү максатында Татарстан шәһәрләренең урамнары-мәйданнарына шагыйрь исемен бирү кирәклеге турында тәкъдим белән чыкты. Әлеге мәсьәлә Татарстан Республикасы һәм Казан шәһәр хакимиятендә каралачак.

*«Шәһри Казан» газетасы.– 1996. – 19 апрель*

# Шагыйрь дәвам итә

Рашат Низамиев

Империя капкасында – йозак,
Аннан чыгар өчен юк ишек.
Ишекләре ачылмаслык булгач,
Чык иреккә, татар, тау ишеп!
*Рәшит Әхмәтҗанов*

Шагыйрьне ныграк аңлар өчен, аның туган ягын барып күр, диләр. Бу, чынлап та, шулайдыр. Шушы ният белән без, татар мәдәниятенең бер төркем вәкилләре, Баулы районына чыгып киттек. Көн җылымса, автобусыбыз Казан урамнарыннан җилдерә генә. Әмма Компрессорлар заводына илтүче дамбага җиткәч, эшләребез комга терәлде! Комга терәлсә, яхшырак буласы икән дә бит. Казан тикле Казанда ком тавының булмавы харап итте дә инде безне. Юллар тайгак, бераз гына үр менәсе бар. Әмма ике-өч чиләк ком сибелмәү аркасында троллейбуслар һәм «КамАЗ»дан алып «Запорожец»ка тикле машиналар терсәккә-терсәк туктальп-бөялеп калган... Кыскасы, шушы бер чакрым араны ике сәгать чамасы уздык без.

Боларны ни өчен сөйлим? Юл уңаенда без Себер тракты урамыннан Сафьян Ибраһимовны да алып китәргә тиеш икәнбез. Шулкадәр вакыт урамда басып торуга түзде микән ул, кулын селтәп кайтып китмәдеме икән? Күпләребез шуңа борчыла. Ә бит безнең төркемдә гамьле, татар рухы өчен борчылып яши торган танылган кешеләр бара. Болар – Сара Садыйкова исемендәге Мәдәни-хәйрия фонды рәисе Әзһәр Хөсәенов, җырчылардан Габдулла Рәхимкулов һәм Ферди-



**«Казан утлары» журналы хезмәткәрләре. Сулдан уңга: Флүс Латыйфи, Җәүдәт Миңнуллин, Рәшит Әхмәтҗанов, Мөдәррис Вәлиев, Ринат Мөхәммәдиев, Ренат Харис, ?, Кояш Тимбикова, Мәхмүт Хәсәнов; басканнар: Рашат Низамиев, Тәүфикъ Әйди, Рәдиф Гаташ, Мансур Вәлиев**



**Рәшит Әхмәтҗанов истәлегенә багышланган кичәдә шагыйрьнең «Сандугач керде күңелгә» җырын Габдулла Рәхимкулов башкара. Баянда — Сафьян Ибраһимов. Баулы, 1996**

нанд Сәлахов, баянчы Ринат Габдрахманов, артист Илдус Әхмәтҗанов, Луиза Әхмәтҗанова һәм шушы юллар авторы.

Ни гаҗәп: бер як җилкәсенә баянын асып, бер як кулына сумкасын тотып, Сафьян агай сөйләшенгән урында басып тора лабаса. Сәхнә һәм сәнгать ветераннарыбызның мондый фидакярлегенә сокланмый мөмкин түгел. Туңган, әлбәттә, автобус эчендә бераз җылынып алгач кына һәркайсыбызның хәл-әхвәлен белешергә вакыт тапты.

Инде хәзер алгарак узып булса да әйтик, 27—29 ноябрьдә Баулыда шушы якларда туып үскән талантлы шагыйребез — Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Г. Исхакый исемендәге премия лауреаты Рәшит Әхмәтҗановны искә алу, хөрмәтләү көннәре булып узды. Сүз уңаеннан: бу игелекле эшне оештыру гамәлләрен С. Садыйкова исемендәге Мәдәни-хәйрия фонды һәм Баулы районы хакимияте үз өстенә алган иде. Моның өчен рәхмәт аларга!

Яшерен-батырын түгел, Себерне, Украина һәм Белоруссия якларын байтак урап кайтканым булса да, Татарстан дигәндә, Азнакай якларыннан ерак киткәнем юк иде. Баулы һәм аның кешеләре белән беренче тапкыр очрашуым. Шуңа да биредәге күп нәрсә игътибарымны җәлеп итте, район тарихы белән дә кызыксындым. Бер яктан Оренбург өлкәсе, икенче яктан Башкортстан Республикасы белән «чиктәш» булып яшәүче бу районның язмышы да, яшәеше дә үзенчә кызыклы икән.

Туктале, сүземнең башы шүрәле иде бит дигәндәй, без бит шагыйрьнең туган авылына юл тоткан идек. Сәфәр — бер хәл, ә уйлар үзенчә юл яра. Без инде күнегеп беттек шикелле: Казан арты, Арча төбәге фәнгә, әдәбият һәм сәнгатькә күренекле кешеләрне көлтәсе-көлтәсе белән генә биргән, дибез. Бу бик дөрес, бәхәсләшеп тормыйк. Ләкин, күрегез әнә, Баулы якларыннан да менә дигән әдипләр, талант ияләре, күренекле шәхесләр чыккан икән ич. Шагыйрьләрдән



Р. Әхмәтҗановның иҗатын барлап, якты истәлеген халыкка җиткереп торучы Татар Кандызы урта мәктәбе укытучылары. 1974

Сирин, Рәшит Әхмәтҗанов, батыр рухлы Фәнис Яруллин, тарихи романнар авторы Мөсәгыйть Хәбибуллин, әдәби тәнкыйтьче Рафаэль Мостафин, үзенчәлекле әдип Миргазиян Юныс, композитор Ганс Сәйфуллин, күренекле артист Илдус Әхмәтҗанов.

Шагыйрь Рәшит Әхмәтҗановны искә алу кичәләренең беренчесе, әлбәттә, аның туган авылы Татар Кандызы мәдәният йортында башланды. Залда бүрек ташларлык та урын юк. Авыл халкы, совхоз җитәкчеләре, шагыйрьнең туганнары җыйналган. Кичәне Әзһәр Хөсәенов ачып җибәрә, Казаннан килгән кунаклар белән таныштыра. Башкала кунаклары исә кул кушырып утырырга гына килмәгәннәр. Әле шушы бәйрәмгә Чаллыдан Рәшитнең сабакташ дусты, шигъри аркадашы Айдар Хәлим дә килеп җиткән. Сөйли белә, сүз остасы, аңа алкышлар яуды. Аннары сүзне мин алдым. Бер генә өлешен мәкаләдә әйтеп китәсем килә. Болай дидем:

– Казанда, Ирек мәйданында Татарстанның мөстәкыйльлеген яклап каты көрәш барды. Хәлләрнең иң кискен вакытында унтугыз кеше сәяси ачлык игълан итүгә хәтле барып җитте. Шунысы игътибарга лаек: бу ачлык көрәшендә бер сезнең авылдан гына да ике кеше катнашты. Болар – абыйлы-энеле Рәшит һәм Илдус Әхмәтҗановлар. Сез, авылдашлары, алар белән хаклы рәвештә горурлана аласыз. Шундый егетләрне үстергәнегез өчен рәхмәт сезгә!

Әйе, моннан биш ел элек Ирек мәйданында да, Г. Камал театры каршында да митинглар ялкын булып, татар рухы булып кайнады. Рәшит Әхмәтҗанов көрәшче дәрәҗәсенә күтәрелгән җырчылардан Вафирә һәм Гөлзадә ханымнар белән аеруча дус иде. Аларны тыңлый белде һәм үзе дә кайнарланып микрофон каршына баса иде. Тавышы көчле, нык, ачык, халык йөрәгенә барып җитә торган борчылу, бәргәләнү, чакыру авазлары тулып ята... Мин бу авазны хәзер дә ишетәм сыман, алар колак төбендә яңгырый:

Коллыкны яндырып, каныбыз дөрләсен,
Дөрләсен, сүнмәсен – ант итик, Ватанчы...
Йә бозлы йортыма азатлык яуларбыз,
Йә янып бетәрбез, кол булып калганчы!

Мондый юлларны язар өчен бер генә нәрсә – Ватан өчен әрнү хисе кирәк. Рәшиттә ул җитәрлек иде. Шагыйрь юкка гына ачлык игълан итмәде. Шуның нәтиҗәсе буларак, «Ачлык мәйданы» дигән китабы дөньяга чыкты. Бу – шагыйрьнең яшәве, рухи батырлыгы да иде. Әрнүле иҗатын әле бәяләп бетергәнебез генә юк. Үзенең милләтен ярата белмәгән маңкортларны хурлык диварына әнә ничек оста «кадаклап» куя ул:

Бер күзендә – шовинисттан курку.
Бер күзендә – дөрләп китәр дары!
Таныйсыздыр... дәррәү җыелганнар
Мие каткан татар маңкортлары.



**Бер төркем язучылар һәм артистлар Рәшит Әхмәтҗановның туган ягы Баулыда**

Бик күпләрнең сөйләгәне бар: Рәшит бертуган энесе Илдусны бик ярата иде, диләр. Берсе – шагыйрь, берсе – артист, икесе дә бер анадан туган татар балалары. Менә Г. Камал исемендәге Академия театрының танылган артисты Илдус Әхмәтҗанов авылдашлары каршына чыгып баса. Күңел түреннән чыккан сүзләр белән авылдашларына мөрәҗәгать итә. Аннары үзенең саф, чиста, матур тавышы белән шагыйрь абыйсының шигырьләрен укый. Зал тетрәнеп тыңлый. Күренеп тора, алар җырга, моңга, яхшы сүзгә сусаган.

Җыр димәктән, җырчыларга да мәйдан җитәрлек иде. Габдулла Рәхимкулов һәм Фердинанд Сәлахов, шагыйрь турында кайбер истәлекләрен уртаклашканнан соң, Баулы ягы эшчәннәренә җырдан үрелгән сәламнәрен тапшырдылар.

Соңыннан Казан кунаклары авылның мәктәбе белән таныштылар. Мондый затлы, чиста, заманча мәктәпне, гадәттә, район үзәкләрендә генә күргән бар иде безнең. Алай гынамы, бернинди башкала стандартларыннан калышмый торган музейларына хәтле бар! «Икмәк музее» дип атала ул. Бу хакта тәфсилләп махсус язарга кирәк.

Хуш, рәхмәт сиңа, Кандыз! Син безне татар халкына хас булган кунакчыллык белән каршы алдың һәм озаттың.

Икенче көнне иртән безне Баулыда район хакимияте башлыгы Наил Шамил улы Зарипов кабул итте. Район тормышы, үзенең ярдәмчеләре белән таныштырды.

Көн бик тыгызга көйләнгән иде. Районның оста куллары төзегән музей белән таныштык, 14 нче татар гимназиясендә һәм сәнгать мәктәбендә укучылар, укытучылар белән очраштык.

Безнең очрашулар районның М. Җәлил исемендәге Мәдәният сараендагы әдәби-музыкаль кичә белән төгәлләнде. Халык өч сәгать буена сүз хикмәтен һәм җыр яктысын күңеленә сеңдереп, ял итеп утырды. Кичә башланганчы Рәшит Әхмәтҗановның «Ачлык мәйданы» дигән китабы якташларының һәркайсына таратылган иде. Бу уңайдан шагыйрьнең хатыны Луиза ханым Әхмәтҗанованың сүзләре истә калган:




**Баулы шәһәренең әдәбият һәм сәнгать сөючеләре, мәдәният хезмәткәрләре, кунаклар**

— Татар халкының язмышы, киләчәге өчен борчылып язылган китап бу. Шуңа күрә аны, зинһар, читкә ташлый күрмәгез. Бүген укымасагыз, иртәгә, иртәгә булмаса, башка көннәрне укырсыз. Мин сезгә ышанам.

Зал — кунаклар белән, кунаклар зал белән рәхәтләнеп аңлашты бу кичәдә. Яшьрәк чакта «Айли, баулылар, һәр эштә мактаулылар»,— дип тыңлап-ишетеп кенә белгән Баулы якларын, аның кешеләрен инде үз күзләрем белән күргәннән соң, мин бер хакыйкатькә ышандым. Баулының иң зур байлыгы — «кара алтын» түгел, аның ачык йөзле хезмәт сөючән кешеләре икән!

Шагыйрьнең туган ягына гына түгел, аның иҗатына, күңел дөньясына да сәфәр булды бу.

Рәшит Әхмәтҗанов — кулына кирпеч-таш тотып йортлар салган кеше, хезмәт биографиясен шуңардан башлаган. Әмма ул күңел биографиясен шагыйрь буларак тәмамлады. Миңа калса, сүзен әйтеп өлгерде шикелле. Ул элегрәк шигырьләрендә «дошман» сүзен шактый еш куллана иде. Кайберәүләр, нинди дошман, дип, мыек астыннан көлде. Төптән уйлап карасак, тоемласак, ул инде империя белән шовинизмның татар халкы өчен иң зур дошман икәнен әллә кайчан чамалаган, кинаяләр белән сөйләшкән икән. «Ачлык мәйданы»н яңадан укып карагыз. Ул инде «коллык» сүзен ачыктан-ачык һәм үз мәгънәсендә куллана. Тел яшереп торырга вакыт юк, гомер бара.

Менә шулай. Каләмдәшебез әйтмешли, шагыйрь дәвам итә. Без Баулы якларында әнә шуңа ышандык.

*«Ватаным Татарстан» газетасы.— 1996. — 5 гыйнвар*

# Якташлары Рәшит Әхмәтҗанов турында

## *Изге күңелле кеше иде*

*Мөсәпбиха Сәлимова, укытучы*

Сүз башы итеп шуны әйтәсем килә: Әхмәтҗановлар нәселендә сәнгатькә хирыс, олы җанлы кешеләр күп. Мин Рәис, Рәшит, Ильяс, Илдус, Санияне татар теле һәм әдәбиятыннан укыттым. Бүгенгедәй хәтеремдә, дәрестә Рәшит тышлыгы чия төсендәге калын гына китапны парта астына бер куя, бер ала.

– Нишлисең, Рәшит? – дим.

– Берни дә эшләмим.



**Әхмәтҗановларның татар теле һәм әдәбияты укытучысы Мөсәпбиха Сәлимова (сулда), математика укытучысы Рәйсә Сафиуллина**

Мин берничә тапкыр сорасам да, ул шулай бер үк төрле җавап бирде. Китабын алсам – Сибгат Хәкимнең шигырьләр җыентыгы. Әйтер сүзе бардыр дип, башка эндәшмәдем. Тәнәфестә мине туктатты да:

– Апа, мин сезгә шушы китапны бүләк итәм,– дип, аны миңа сузды.

Аптырап калдым.

– Нинди бүләк?

– Туган көнем белән,– ди бу.– Минем бүген туган көнем, апа.

Мин телсез калгандай булдым. Аннан гына аңыма барып җитте. Мин аның туган көнен белергә тиеш булганмын лабаса. Миңа шуны аңлатасы килгән сабыйның. Көлеп җибәрдем. Туган көне белән тәбрикләп, колагын тарттым. Үзем буш сәгатемдә кибеткә йөгердем, күчтәнәч алдым, дәресләр беткәч, алар классына кереп, туган көне белән тәбрикләдем. Рәшит бик канәгать булып елмаеп утырды. Шагыйрь булып җитешкәч, үз китапларын истәлеккә бирә торган булды. «Апа, укытучыга багышлап язылган шигырьне үзегезгә багышланган дип уйлагыз»,– ди иде.

Рәшит хәтеремә эчкерсез, изге күңелле кеше булып мәңгегә кереп калды.

## *Авылыбыз горурлыгы*

*Нәсимә Хәйретдинова, укытучы*

Рәшит Әхмәтҗанов тыйнак, тәртипле, иптәшләренә карата игътибарлы укучы булып күңелемә кереп калган. Миңа аны Татар Кандызы урта мәктәбендә татар теленнән укытырга туры килде. Хисчәнлеге, йомшак күңеллелеге белән дә аерылып тора иде ул. Әнә шул сыйфатлары аны шагыйрь иткәндер дә. Кайсы ел икәнен хәтерләмим, район үзешчән сәнгать смотрында Рәшит шигыренә язылган матур бер җырны мәктәп коллективы хор белән башкарып, беренче урынны алып кайтты. Урын билгеләгәндә, җырның сүзләрен нәкъ менә үз укучыбызның язган булуы зур роль уйнаган иде. Бәлки әле, ул җырны хәтерләүчеләр дә бардыр.

1987 елның 25 октябрендә Кандыз авылы Мәдәният йортында үткәрелгән бер очрашу вакытында ул миңа 1985 елда нәшер ителгән «Кавышыр чак» дигән китабын бүләк итте. Китапны ачуга: «Хөрмәтлебез Нәсимә апа! Шигъри дулкыннар аша килгән тирән хөрмәтемне һәрчак сизеп, аңлап торсагыз иде» дигән язу бүген дә Рәшитне күз алдыма китереп бастыра.

## *Югалтуыбыз үкенечле*

*Җәмилә Гаделшина*

Рәшит мин мәктәп директоры булып эшләгән елларда Татар Кандызы сигезьеллык мәктәбендә белем алды. Ул сыйныфташларыннан сәнгатьне үтә яратучы укучы буларак аерылып тора иде. Түбән сыйныфларда укыганда ук, кыска-кыска шигырьләр язып, сыйныфташларын да, укытучыларны да гаҗәпләндерә иде. Ул шигырьләр мәктәп газеталарында басылып чыга иде. Без аларны җыя гына бармаганбыз шул. Мәктәп укучылары ул чакта ук аны «шагыйрь» дип йөртәләр иде. 7–8 сыйныфта укыганда, аның шигырьләре инде «Пионер» газетасында басыла башлады.

Рәшитнең шигырьләре башка беркемнекенә дә охшамаган булулары белән аерылып тора. Бу – чын шагыйрьлектер. Шуңа күрә мин аның белән чын күңелемнән горурланам. Үз автографын язып бүләк иткән китабын һаман да кадерләп саклыйм.

Бу талантлы, олы шагыйребезне югалту гаять үкенечле.

## *«Сандугач керде күңелгә»*

*Сәгадәт Әхмәтшин*

Шагыйрь Рәшит Әхмәтҗанов минем күңелемә «Сандугач керде күңелгә» җыры белән керде. Аның белән танышуым да кызыклы гына килеп чыкты. Казанга «Яшь талантлар» семинарына баргач, Яшьләр үзәгендә лифтта очраштык. Мин аннан: «Сез шагыйрь Рәшит Әхмәтҗанов түгелме?» – дип сорадым. Ул миңа: «Әллә охшаганмынмы?» – ди. «Рәсемегезне күргәнем бар, шигырьләрегезне дә яратып укыйм. Мин дә бит, сезнең кебек, Баулы районыннан, аз-маз каләм тибрәткәлим – шигырьләр язам»,– дим.

Кунакханәдәге номерда мин Рәшит абыйга берничә шигыремне күрсәттем.

«Үзең укып күрсәт»,– ди бу. Мин берничә шигыремне укыдым. Ә ул: «Шигырьне ялкынланып, дәрт белән укырга кирәк, ә син авыз эченнән ботка пешерәсең»,– диде.

Минем иҗат җимешләрем «кесә шигырьләре» булып чыккан икән. Рәшит абый шундыйрак бәя бирде. «Яз, энекәш, ләкин шигырь ул күңел түреннән чыгарга тиеш»,– диде.

Шулай таныштык.

## *Һәрчак халык күңелендә*

*Фатыйх Сәлимгәрәев*

Тәүге тапкыр моннан 38 ел элек очраштык без аның белән, мин, сигезенче класста укырга дип, Баулыдагы 2 нче урта мәктәпкә документларымны илтсәм дә, сентябрь башында укырга барма-



**Рәшит Әхмәтҗанов, Сирин Батыршин, Мәгъсүм Латыйфуллин мәктәп укучылары белән очрашуда**

дым – авылда хат ташучы булып эшләп йөргән чак иде. Октябрь урталарында инде, китергән язу-документларны алырга дип, янә бирегә килдем һәм укырга калдым. Безгә, тирә-як авыллардан килгән татар балаларына, мәктәп яны тулай торагыннан урын да бирделәр. Класста 31 бала булып, алар арасында Татар Кандызы авылыннан чандыр озын гәүдәле, үткен карашлы Рәшит Әхмәтҗанов та бар иде. Соңрак аның шагыйрь җанлы, туры сүзле егет икәнлеге дә мәгълүм булды. Без, бер парта артында утырып, мөгаллим-мөгаллимәләребездән сабак алдык. Кичләребезне шул торакта үткәрә идек. Юньле ашау-эчү, кием-салым да тәтемәде безгә – сугыш елларында туган балаларга. Шулай да зарланмадык, сыкранмадык – белемгә омтылыш көчле булгандыр инде. Ә шимбә-якшәмбе җиттеме, төрлебез төрле якка – авылларыбызга, туган йортларыбызга таралыша идек. Кышкы зәһәр салкыннарда, язгы-көзге пычракларда күпме чакрым юлларны җәяүләп узмаганбыздыр.

Ничек кенә булмасын, күңелле иде ул малай-үсмер чаклар. Класстан тыш күпме кызыклы чаралар уздырыла. Мәктәптә әдәби түгәрәк эшли. Аңа Мәгъсүм Латыйфуллин җитәкчелек итә иде. Еш кына ул түгәрәккә Баулыда гомер итүче, 1920 елларның ялкынлы трибун шагыйре Сирин Батыршин да килә. Аның бөтен күңелен биреп, үзенең шигырьләрен укуы әле бүгенгедәй хәтеремдә. Түгәрәкнең иң актив әгъзаларыннан берсе, әлбәттә, Рәшит иде. Ул күп яза, күп укый. Тулай торакта кышларын бозлы тәрәзә каршында озак итеп шигырь язып утыручы да Рәшит булды, һәр язганын безгә укып күрсәтүе гадәткә әверелде. Ә без, авызларыбызны ачып, аны сәгатьләр буе тыңларга да әзер идек. Гаҗәеп яхшы хәтерлим, шигырьләрен үзенә генә хас бер осталык белән укуы күңелгә сеңеп калган. Без дә шунда вак-төяк нәрсәләр язгалап, түгәрәк утырышларына тәкъдим иткәли идек анысы. Әмма Рәшит белән бил алышырга безгә бик ерак иде. Шулай да ул безнең каләм аша үткән язмаларны җентекләп укый, киңәшләрен бирә. Әле дә хәтеремдә, Муса Җәлилгә багышланган бер шигырь язган идем. Аның ярдәме белән ул ярыйсы гына килеп



**Шагыйрь Сирин Батыршиннан киңәшләр. Сулдан уңга: Рәшит Әхмәтҗанов, Мәгъсүм Латыйфуллин, Сирин Батыршин, ?**

чыкты һәм «Яшь ленинчы» газетасында дөнья күрде. Газетага язган мәкаләләргә дә кул «тыгарга» иренми иде. «Бәрәңге басуында» дигән кечкенә репортажым да район газетасында урын алды.

– Репортаж – җанлы язма ул, анда барысы да тормышның үзеннән туа,– ди торган иде Рәшит.

Әгәр мин журналист булып җитешкәнмен икән, монда Рәшитнең дә, татар теле һәм әдәбияты укытучылары Мәдинә Вәлкәева, Әлфия Аппакаева кебекләрнең дә, һичшиксез, зур йогынтысы булгандыр дип саныйм. Мин гомерем буе аларга рәхмәтлемен!

Кыңгыраулы мәктәп еллары һәркем өчен дә бертигез узмады. Рәшиткә дә, уку елы тәмамланганчы ук, мәктәпне ташлап, Әлмәткә – төзелешкә, үз ипекәен үзе эшләп ашарга китәргә туры килде. Әйе, мохтаҗлык-җитмәүчелек кемне генә барасы юлыннан, максатыннан аермады. Тырыш, һәрчак тугры сүзле егет кайда гына эшләсә дә, укыса да, гомеренең азагына кадәр иҗат белән янып яшәде.

Мин, Казанга барган чакларда, ул «Татарстан яшьләре» газетасында, «Казан утлары» журналында эшләгән елларда, аның янына кергәли идем. Ул, һичшиксез, Баулы яклары хакында сорашыр, таныш-белешләренә сәламен тапшырыр иде.

Татар Кандызы авылында туып үскән классташымның безнең арабыздан китүенә елдан артык вакыт үтсә дә, моңа һич тә ышанасы килми. Әйе, үлемсез шигырь-поэмалары белән халык күңеленә юл тапкан шагыйрьне без бүген дә үз арабызда дип хис итәбез. Әдип үлсә дә, аның әсәрләре һәрчак халык күңелендә.

Язмамның ахырында минем бер үтенеч-теләгемне дә белдерәсем килә: Рәшит Әхмәтҗановның исемен мәңгеләштерү максатыннан Татар Кандызы авылында шагыйрь туып үскән урамга аның исемен бирү, ул яшәгән йортка мемориаль такта кую бик мәслихәт эш булыр иде. Монда җирле үзидарә органнарының, җәмәгатьчелекнең инициативасы гына кирәк, минемчә. Аның өчен әллә ни чыгымнар да таләп ителми югыйсә.

*«Хезмәткә дан» газетасы.– 1996. – 12 апрель*

# Ярсыган йөрәге дөньяны тарсынды


Фәния Хуҗахмәт

Милләтне, халыкны ничек уятырга, ничек үз дәүләтебезне корырга, дип янган көрәшчеләребез дә, йөрәк каны белән шигырь язган шагыйрьләребез дә бар. Ләкин берсе дә Рәшит абый түгел. Ул башка иде.

1991 елның май ае беркайчан да хәтердән чыкмас. Ул чакта татар халкының 19 газиз баласы, Татарстанда Россия Президентын сайламас өчен бердәнбер булып калган көрәш юлы дип, ачлык игълан итте. Бу гарасат 14 көн дәвам итте. Еллар үтәр, кайбер вакыйгалар тонып калыр, онытылыр. Ләкин кызу кояш астында үтә күренмәлегә әйләнгән Рәшит Әхмәтҗанов онытылмас. Йөрәгенең хәлсез икәнен дә белә идек. Нәкъ 12 көн, 12 төн язды Рәшит абый, бертуктамый шигырь язды. Соңгы китап – «Ачлык мәйданы» – «Ирек мәйданы». Монда коллык ачысы да, азатлык көрәше дә, исәннәргә әмер дә, соңгы сүз дә.

Нәкъ бер ел элек, азатлык өчен көрәшкән Чечня халкын бомбага тотканда, Рәшит абыйның йөрәге чыдамады, тибүдән туктады. Ул үзе лаек булган татар зиратына, Габдулла Тукай белән янәшә кабергә кереп ятты.

*Татар календаре. 1996 елның 25 гыйнвар бите*



**?, Рәшит Әхмәтҗанов, Ирек Мөхәммәтов, Барлас Камалов**

# Язмышында – ил гаме

Вәгыйзь Хәнипов

Мин аның белән беренче тапкыр Казан дәүләт университетының Кызыл Позиция урамындагы тулай торагында таныштым. 1964–1969 елларда әлеге уку йортының татар теле бүлегендә Ринат Мөхәммәдиев, Гәрәй Рәхим, Рөстәм Мингалимов, Нур Әхмәдиев, Әхәт Гаффар һәм башкалар белем алды. Аларның барысы да хәзер инде күренекле язучылар һәм шагыйрьләр.

Ә какча гәүдәле Рәшит Әхмәтҗанов ул чакта ук олыга тартым, түбә чәче сирәгәйгән, тиз аралашучан, шат күңелле, җор телле кеше буларак истә калган.

Ул үзенең курсташларыннан 5–6 яшькә өлкәнрәк иде. Мөхтәрәм әдибебез Хәсән Туфан әйтмешли, аның киләчәге өметле иде.

Рәшит концерт-театрларга йөрергә бик ярата, язучыларның, артистларның юбилей кичәләренең берсен дә калдырмый, кайткач, үзенең тәэсирләре белән уртаклаша иде. Безнең тулай торакта рәссам-сынчы Бакый Урманче, композитор Җәүдәт Фәйзи һәм татарның башка күренекле сәнгать әһелләре белән очрашулар еш үткәрелде. Рәшит алар белән якыннан аралаша иде.

Авылда туып үскән кеше буларак, Рәшит эчкерсез, саф күңеллелеге белән аерылып тора иде. Ниндидер яшертен эш йөртүләр яисә кемгә булса да явызлык эшләү аңа ят нәрсә иде.

Берничә ел бергә тулай торакта яшәү дәверендә, башка факультетта укысам да, мин алар бүлмәсенә бик еш кереп йөрдем. Рәшит Әхмәтҗанов бик күп яза, ә язганнарын илһамланып, кычкырып укый иде. Шул мәлдә ул икенче Рәшиткә әверелә дә куя. Ялкынланып шигырь укулары әле дә күз алдымда тора.

Укуны тәмамлап, төрле якларга таралышкач та, безнең аралар өзелмәде. Ул Казанда яшәде. Шул чорда без аның белән берничә мәртәбә очраштык. Рәшит Әхмәтҗанов иҗатының башлангыч чорында лирикага өстенлек бирсә, соңгы елларда ул милләт язмышын алгы планга куйды, ирек-азатлык өчен көрәште, яшәү мәгънәсен шунда тапты.

Рәшит Әхмәтҗанов, кемгәдер ярарга тырышып, карьерага омтылучы кеше түгел иде. Ул бөтен җаны-тәне белән милләт язмышы, аның мөстәкыйльлеге өчен көрәште, ярты гасырдан аз гына артыграк гомерендә безнең өчен бай рухи мирас калдырды.

*«Хезмәткә дан» газетасы.– 1997. – 12 апрель*

# Тәңренең тамгасы белән[1]

Марсель Галиев

Кая китте соң әле дога урынына шигырьне өстен күргән еллар?

Тукай клубында бер-бер артлы сәхнәгә чыккан шагыйрьләрнең фикер ярлылыгына бай булуыннан арып, янәшәдәге кызлар белән сүз уйнатып утыра идем, кинәт... залның арткы диварын да уятырлык итеп тәгәрәп килгән көчле, яңгыравык тавыштан сискәнеп, башны күтәреп карадым. Сәхнәгә кара мыеклы, ялтырап торган пеләш башлы, озынча йөзле шагыйрь чыгып баскан. Тар иңсәле ыспай гәүдәсендә костюмы да чат килешле утыра. Дөнья кайгысын иңенә салган шикелле җитди кыяфәт... Якты баш, дим, кызларның игътибарын җәлеп итәргә тырышып (яшьли пеләшләнгән кешедән көлү безнең милли сыйфатыбыздыр, мөгаен). Ә эчемнән уйлыйм: бу кыяфәт белән ул кемне дә битараф калдырмас. Эллада скульпторлары да бу башны өлге итеп алырга кызыгырлар иде.



> Без мәңгегә, без мәңгегә монда,
> Эх, бу җирне күпме таптады
> Безнең йөрәк бәйрәмнәребезнең
> Кыңгыраулар таккан атлары!

Әллә ничек, моңлы көй сүрүенә төреп укый, мондый шигырьне кабул итәр өчен җирдә — яфрак белән яфрак сөйләшкән, күктә исә йолдыз белән йолдыз серләшкән шартлы мизгелдә, табигать кочагында самими халәткә керү кирәктер. Ә минем, яшь кан типкән тәнемне андый талгынлыкка дучар итеп, замана шау-шуыннан читтә калырга исәбем юк. Нинди кыңгырау, нинди атлар — архаизм! Чабаталы чордан китә алмаган шагыйрьләр кавеменнәндер бу, дип, эчтән вәкарь белән хөкем чыгарам. Маңгайны Җир шарына тиңләп, «планетар» фикергә «ирешкән» ак шигырьләр язып йөргән беренче курс студенты әнә шундыйрак «фәһемле» иде ул чакларда.

Чынбарлыкта исә Шагыйрь үзе йөгәнләгән аргамакларда алдагы чорларга томырылып чапкан икән. Үз вакытында аңламавыбызга үпкәләми генә, юлга маяклар тезеп, безнең килеп җиткәнне көтеп торган...

Җитмешенче елларда кат-кат тыңланган бу шигырьне менә хәзер, гасыр бетәргә аз гына калган бер дәвердә, кулыма алып, яңадан укыйм. Колагымда — шагыйрь тавышы, һәр сүз артыннан эзәрлекләп озата бара. Укыйм да... гамьле сокланам. Курку һәм өмет арасында яшәргә мәҗбүр

[1] Рәшит Әхмәтҗановның «Сайланма әсәрләр» китабына кереш сүз («Рухият» нәшрияты, 1998.— 5–34 б.)



**Татарстан язучылары съездында**

ителгән бу тормышта, ятим калган хәтереңне уятып, дәүләтле халыкның варисы икәнеңне аңларлык горурлыкка ирешкәч кенә, бу шигырьне үз олылыгында кабул итәргә мөмкиндер. Әгәр кыңгыраулы атлар күңел капкаларыннан сыеп керә алмый икән, син – коллык бөкресе чыккан гәүдәң әсирлегендә тезләнгән рухыңны аягүрә бастыра алмыйсың инде... Тәкъдиреңә язылган җан асрау халәте белән килешергә мәҗбүрсең.

Әйе, халкыбыз язмышына караган бүгенге мәгълүмат аша шагыйрьнең әсәрләре яңа бер тирәнлектә ачылып китә. Аның, шигъри ноталарга хилафлык китермичә, кыю-тәвәккәл фикерләве үткен күңел күзе төшәрлек хисси ярага кагыла. Ул искәрткән чәчәкне күтәреп карасаң... таҗлары астында – канлы хәсрәт...

Болан күзе сыман моңлы итеп
Карый ласа монда һәр тамчы!

Җитмешенче елларда Рәшит Әхмәтҗан шигырьләрен укыганда, мине ризасызлык биләп ала иде: нинди мифик дошман? Нинди көрәш? Нигә бәргәләнә бу җан? Галибанә матурлыкка сокланып илһамланыр өчен яратылган үз аһәңе бар югыйсә, нигә канәгатьләнеп, тыныч хасияткә күчә алмый! Әрнү... Сагыш... Бетмәс хәсрәт... Юк, болар мине ардыра, гаҗиз итә, һәм мин, сыктаулы шигырьләрне читкә куеп, бүтәннәрнекен, канәгатьлек хисе өстенлек иткән әсәрләрне кулга алам. Мондыйларны уку рәхәт, җанны талкытмый, ваемсыз тойгылар аша вакытны рифмаларда тирбәтеп йоклатырга була.

Зирәк шагыйрь исә шул елларда ук халыкның күз яшьле тарихы сакланган җиде йозаклы мәгарәләренә белем аша түгел, ә шигъри тойгылар дулкынында үтеп керә алган һәм андагы коточкыч фаҗига-афәтләрнең гарасатлы шәүләсен сиземләп, шуны якты дөньяга чыгарып фаш итүне максат итеп куйган икән.

Иске бу дөньяга күп хәлләрне
Сөйләмәгән әле яшь йөрәк.
Ә сөйләсәм... канга буялыр күк
Өстемдәге шушы ак күлмәк.

Илленче еллар ахырында татар поэзиясендә «шинельле шигырьләр» өстенлек итә, Европагача җитеп, яу кырларыннан исән кайткан фронтовиклар әдәбият мәйданын тота иде. Әмма яшь шагыйрь Рәшит Әхмәтҗан, бу агымга ияреп китмичә, яралы җаннарга шифа бирерлек чәчәк җылысын, кимсенгән күңелләрне юатырлык сүз тәгъбирен, «туфанлы хис», «туфанлы моң»га төреп, йөрәк биеклегенә күтәрергә алынды. Әгәр ул истәлек-хатирәләр язса, иҗатына Хәсән Туфанның никадәр бәрәкәтле йогынтысы булуын тәфсилләп сурәтләр иде. Хәер, олуг остазына рәхмәте аның күп кенә шигырьләрендә чагыла, ак кәгазь каршында ул аның чал яктысын һәрчак тоеп яза иде.

Әлмәттә ташчы булып эшләгән яшь егет — Рәшит белән танышуын Хәсән ага болай дип теркәп калдырган: «...1957 елда 16 яшьлек Рәшит Әхмәтҗан нефтьчеләр газетасы редакциясенә беренче шигырен китерә. Редактор белән секретарь укып карыйлар да, бераз гаҗәпләнеп, үзара ымлашып алганнан соң:



**Рәшит Әхмәтҗановның укытучысы — Оренбург өлкәсе Северный районы Керәҗле авылыннан Мәгубә Мифтахова**

— Үзең яздыңмы бу шигырьне? — диләр. 16 яшьлек малайның шундый шигырь язуына ышанып бетмиләр...

— Безгә менә хәзерге көз көне турында бер шигырь кирәк иде, язып кара әле,— дип, Рәшитне бер буш бүлмәгә кертеп, ишекне бикләп куялар. Нигә язмасын, ачык һавада — яңгырлар астында да ташчы булып эшли башлаган бу егеткә Әлмәт көзе бик таныш ич,— яза, һәм бу — сыналу шигыре газетада басылып чыга.

Алтмышынчы еллар башында Сибгат Хәким белән Әлмәт ягына, халык арасына чыккан идек. Безнең номерга кыяфәте һәм холкы белән Шәүкәт Галиевне хәтерләткән сөйкемле егет килеп керде. Рәшит исемле бу егет үзенең шигырьләрен укып карарга, киңәш алырга теләвен әйтте.

Укыдык. Шигырьләрен дә, үзен дә яраттык. Ләкин без дә, Әлмәт газетасы редакциясендәге вакыйганы белмәсәк тә, сынап карарга теләгәнбездер, күрәсең: шигырьләрнең кайберләрен төзәтеп-үзгәртеп, яңадан язып китерергә киңәш бирдек. Икенче көнне үк үзе төзәткән вариантларны алып килде. Шактый таләпчәнлек белән тагын бер кат күздән кичердек һәм «әдәби табыш икән бит бу егет» дигән фикергә килдек».

Казан дәүләт университетында укыганда ук, Рәшит Әхмәтҗанның беренче китабы дөнья күрде. Шул уңайдан бер вакыйганы, алардан соң без укырга кергәч тә, көлеп сөйлиләр иде әле. Имеш, Рәшит атна буе университетка барып күренмәгән, укырга йөрми икән. Кафедрадан, моның хәлен белергә дип, старостаны җибәргәннәр. Яңа китабы белән хозурлану көннәре кичергән Рәшит Әхмәтҗан аңа болай дигән:

— Нигә барып йөрим, укытучылар үзләре әнә минем китапны укысыннар...

Шаянлык аңа тумыштан бирелгән иде. Нинди дә булса хикмәтле сүз әйтә дә үзе үк, түбәдән кар ишелгән кебек итеп, гөмбердәтеп көлә башлый. Мондый да сәхнәви көлүгә иярми кара! Ул — җәмгыятьнең ясалма кануннарына ярашып, сәләте чамалы килеш тә йолдыз тотарга үрелүчеләрдән ачы итеп көлә белә, әгәр күзәтүләрен проза итеп язса, чордаш шәхесләрнең сурәтен нечкә юмор белән елмаю диварына кадаклаган булыр иде. Кызганыч, юморның цензура тарафыннан кысылган көлү дәрәҗәсе ул дәвердә кәрлә биеклектә генә иде шул. Бәлки, шуңадыр, сәнгатьле көлә белү сәләтен кәгазьгә гарипләндереп төшерәсе килмичә, редакция коридорларында тәмәке көйрәткән арада чордашларының күзенә төтен җибәрү белән канәгатьләнә иде ул.

Ә бәлки... гаҗәеп нечкә зәвыклы лирик өчен югары шигърият серләрен, телбизәкләргә төреп бирә белгән каләмен юмор карасына ману килешеп тә бетмәгәндер. Чөнки ул үз бәясен үзе белә иде!

***

Дуслар җыелган җирдә ул бер шигырен бигрәк тә яратып сөйли иде. Әле генә шаярышып-көлешеп утырган була, әмма шул хикмәтле шигырен сөйләргә дип баскач, бөтенләй үзгәреп китә, гүя җаны тәннән аерылып, хәвефле ерак дөньялар белән тоташа, күз карашында шомлы моң оеп кала...

Туган илдә чәчәк җылысыдыр.
Эх, шул җиргә ятып җылыйсы бер!
Кайтма, диеп озатмадылар.

Йөзләр генә сары, баш исән.
Аккошлардан корбан чалыр идем,
Туган илгә кайтып җиталсам.

Корбан буласы кош һавада,
Илгә җитсен... Минем юлны бүлеп,
Каф таулары ята арада.

Бу шигырьдән соң бер мәлгә уңайсыз тынлык урнаша, сүз җебе ялгана алмый, кырлы стаканнарда кыҗраган утлы хәмер генә утырдашларның тел куәсен әкренләп әүвәлге хәлгә кайтара иде. Шигырьне күпләр кабул итә алмый, «...корбан чалыр идем» дигән юлына төртеләләр дә, шагыйрьне каты бәгырьлелектә гаепләп, кан чыгару фәлсәфәсен куерталар иде. Андый чакта шагыйрь: «Наданнар сез!» – дип усалланып куя, әмма шигыренең бөтенлеген таркатып, үзенең хаклы икәнен исбатлаудан ерак тора иде. Шәхсән үземә бу шигырь сәерлеге белән ошый, «корбан чалыр идем»е эффект өчен кертелгән, шагыйрьнең кылануыдыр дип карыйм, эчтәлеге хакында ныклап уйланганым юк иде.

Еллар үткәч, вакыт-вакыт хәтергә төшеп, аңымны сызып үтә торган бу шигырь, кинәт күк капусы ачылган кебек, зиһен офыкларымны яктыртып җибәрде.

Йа Хода!

Кеше җанының Иблис кодрәте җиталмаслык упкынына, акыл һушсыз калып убыла торган тирән упкынына каләм иясенең күз салуы бит бу! Нигә соң әле мин аккошны сузып салып корбан чалу мизгелен күз алдыма китереп гөнаһланам?! Нигә мин чит илдә калып, туган иленә мәңге кайталмыйча яшәргә мәҗбүр ителгән Исхакый кебек мөһаҗирләрнең каһәрле, хәсрәтле, өметсез язмышын йөрәгемнән кичереп карый алмыйм?! Шигырьнең исеме «Сагыш» дип атала ич. Өмете өзелгән ирнең гасабиланып кычкыруы – «Аккошлардан корбан чалыр идем...» – никадәр ачы хәсрәтнең актарылып чыккан сыктау-сулкылдавы... Әрнүле газап авазы, сагышның тере сурәте!

Юк, бу шигырь ак кәгазь битенә төшмәгәндер, аны адәм баласыннан өстен күк һәм җир сагышы, иелеп, дәһшәтле тылсымын пышылдагандыр сыман...

Бу шигырь – аң-зиһен галәменә буйсынмый торган хисси бөеклек, реквием, көтелмәгән ачыш түгелмени!

***

Бәләкәйдән, буразнага күмелерлек чактан ук ачлык-ялангачлык кичергән, сугыш барган яклардан качып килгән явыз бүреләрне, ак өмет вәгъдә иткән ләкләкләрне күреп, Кандыз суында коенып үскән, балигъ булгач инде шәһәрләшсә дә, авыл-табигать ләүкәсендә һәрчак пакьләнеп алып, рух сафлыгын кайгыртып яшәгән шагыйрьнең тышкы кыяфәтен дә, холык-фигылен дә берничә сызык белән ашыгыч кына сурәтләү мөмкин түгелдер. Вакыты белән ул беркатлы, вакыты белән меңкатлы күренә. Үзен бәяли белмәгән заманга усалланып та алгалый, аннары, тиз арада тынычланып, мөлдерәп караган сабый хәлендә кала. Көндәлек тормышта юмарт, кунакчыл булса да, күңел дөньясы ишекләрен һәркемгә ачып куярга ашыкмый; керләнгән уйлы, хөсетле затлар өчен аның бусагасы биек иде.

Аның кебек тә килештереп, тәмле итеп зарлана белүче бүтән булыр микән? Менә шундый чакларда аның артистлык сәләте ачылып китә иде.

Бервакыт мин аны кызык итәргә булдым. Гадәттәгечә күрештек. Сайрар алдыннан кош канатларын төзәткән кебек, сизәм, Рәшитем иркенләп зарланырга әзерләнә. Шуны сизенеп, мин башлап үзем «һөҗүмгә» күчтем:

– И-и, Рәшит, карап торам да... бигрәкләр дә бәхетсез кеше инде син, ә! – дип башлап җибәрдем дә тезәм генә.

Рәшитемнең күзләре зур булып ачылды, гәүдәсен житез генә калкытып:

– Син нәрсә, багърем (Р. Әхмәтҗанов «бәгърем» сүзен шул рәвешчә әйтә иде.– *Төз.*), мине мыскыл итәсең?! Минем андый көнгә калганым юк, Аллага шөкер! Мин әле!

Әһә, ачтыңмы асылыңны, дигәндәй эч тотып көлүемне күреп, ул туктап калды, аңлап алып, үзе дә кушылып көләргә кереште, ике колагы берьюлы кызарып чыкты. Шуннан соң ул, мине күргәч, «хәтерлим» дигән шикелле елмаеп куя да берәр мәзәк хәл искә төшереп сөйләргә тотына иде. Зарлануы исә калкан гына, миңа да тормыш җиңел бирелми, берүк, көнләшеп, күз тидерә күрмәгез, дигән кебек, кешеләрдән саклану чарасы иде бугай. Шулай итеп Шагыйрь кешеләр арасында әвәрә килә: шаяра-көлә, кемгәдер ялгыш бәрелә, рәнҗи, сөенә-көенә, таба-югалта – тормыш кайный, әмма күңеле һәрвакыт уяу, кагылгысыз биеклектә сүз дәрьясыннан телбизәкләр эзли... Ходайның һәр бирмеш көне аңа, бал корты кебек, сүз таҗларыннан микъдарлап нектар җыю өчен багышланган. Тамчылап җыелган илһам касәсен чайпалдырмыйча үз түбән астына алып кайтырга да, вакыт белән бергә-бер калып, шигъри бураэналарга тәһарәтле уйларың белән кереп китәргә... Бусы инде – газаплы сәгадәт. Киләчәк гомер өлешеңә кереп, йөрәгеңне рәхимсез талау... Башкача булмый. Тәңренең тамгасы белән тугансың икән, сиңа бу җирдә олы миссия йөкләнгән. Ашыгырга кирәк...

***

Сүз сәнгате чарлана башлаган бакый заманнардан бирле дастаннар, поэмалар Шәрык шигъриятенең мең еллык тарихын билгели. Поэма язалмаган шагыйрь, бөркет булалмаган кош кебек, әдәби мирас тәхетеннән читкәрәк этелеп карала. Безнең гасырда үзе хакында легендалар тудыруга сусаган тоталитар җәмгыять эпик поэмаларга бигрәк тә мохтаҗ иде. Күп кенә өлгер шагыйрьләр, әлеге хакими теләкнең кендегенә басып, дан-дәрәҗәләр яулап, кинәнеп яшәп калдылар. Әмма җитмешенче еллар азагында инде йөрәк кушканны язарлык мөмкинлекләр дә яуланган иде.

Поэма язу – мамонтны терелтергә тырышу кебек заяга сарыф ителгән көч түгү, дип карасам да, бу авыр жанрны иярли алучыларга барыбер аерым хөрмәт белән карый идем. Рәшит Әхмәтҗанның исә поэма язарга алынуы ничектер көтелмәгәнрәк булды. (Бәлки, ул моңа гомере буе әзерләнгәндер.)

Беренче поэмасын укырга дип, ул Эльс Гадел белән мине өенә чакырды. «Килегез, багырьләрем. Луиза апагыз өйдә юк. Аулагый. Соңыннан бераз утырып та алырбыз...» – диде.

Бүгенгедәй күз алдымда: кояшлы матур көн иде. Иркен кухняның җылы идәненә җәелешеп утырдык. Рәшит бераз каушый да, бераз уңайсызлана да шикелле. Әле кәгазьләрен рәтли, әле борынынннан тып-тып тамган су кранын борып куя, тамак кырып ала – шулай итеп корыла бу, корыла... Менә ул, безгә яны беләнрәк утырып, поэмасының беренче битен ачты. Без тынып калдык. Ул борынгы көйгә салып укый башлагач, еракта калган балачак искә төшкәндәй булды. Гүя мин буранлы, шомлы төндә, бүре улаулары ишетелеп торган кышкы төндә, сукыр лампа яктысында «Сак белән Сок» бәетен тыңлыйм. Юк, миңа боларны күз алдыма китерергә якты тәрәзә, кафельле диварлар комачаулый. Рәшит һаман укый, ә без, вакыт исәбен югалтып, тыңлыйбыз да тыңлыйбыз. Моның азагы булмас шикелле иде, кинәт коткаручы табылды бит! Зал ягыннан көтмәгәндә бер бала җылаган тавыш ишетелде. Тыны да чыкмагач, искәрмәгән дә идек, анда Рәшитнең дүрт-биш яшьлек малае тыңлап утыра икән ләбаса.

— Нәрсә булды икән блондин улыма? – дип, Рәшит җәлт кенә сикереп торды.

Аксыл-сары чәчле улын «блондин» дип йөртә иде ул. Аның, олы бүлмә ягына чыгып: «Нәрсә булды, улым Айдар?» – дигәненә каршы сабыйның: «Кызганыч бит, әти...» – дигән җавабы ишетелде.

Бу сүзне ишетеп, без, Эльс белән бөкләнеп көлә-көлә, идәнгә тәгәрәштек. Шулай итеп, буа ерылды.

— Малаең иң көчле тәнкыйтьче булып чыкты! – диде Эльс.

— Сезне чакырган мин җүләр... Көләргә генә булсын сезгә! – дип, Рәшит үпкәләвен белдереп турсайган иде.

Эльс, бәрхет-баритон тавыш белән, дикторларча һәр сүзне табигый йомрылыгына җиткереп, поэманың барып чыкмаганлыгы хакында сендереп сөйли башлады. Тора-бара сүз табынга күчеп, хәмер ялкыны да кушылгач, баштарак мәлне нык үҗәтләнеп каршы торган Рәшитебез әкрен-әкрен генә бирешә башлады. Кичкә таба инде өчебез берьюлы сөйләр дәрәҗәгә җитеп кызышканда, ул поэмасын бөгәрләп чүп савытына ыргытырлык булып өлгергән иде.



**Рәшит Әхмәтҗанов улы Айдар белән**

Аннан соңгы дистә ел буена Рәшит Әхмәтҗан берничә поэма язды. Борынгы Шәрык акыннары кебек, олпат яшькә җиткәч тә саекмаслык шигъри куәте бар иде аның. Халыкның данлы һәм шанлы язмышын тарих анналларыннан казып алып, искиткеч бай һәм гыйбрәтле татар эпохасын поэмаларга сыйдыру осталыгы аңарда җитеп ашкан иде.

Хәтеремдә: «Бишташ» поэмасын ул, серле кош тоткан кебек, сак кына кулыма тоттырып, редколлегия әгъзасы буларак, журнал өчен фикер язып килүемне үтенгән иде. Язганмын. Төп нөсхә Рәшит Әхмәтҗан әсәрләрен сайлап, җыентык төзеп утырган көннәрдә кәгазьләр арасыннан килеп чыкты. Андагы кайбер юлларга яңабаштан күз салу хилафлык булмас дип уйлыйм:

«...Ташка табыну күп халыкларга хас. Японнардагы ташлар бакчаларын гына искә төшерик. Бездә дә «нигез ташы» дигән хикмәтле сүз бар. Гомумән, табигатьтә, ташлар каршында адәм баласы, үзе дә сизмичә, сүзсез кала. Әйтерсең лә ташларның җаны бар. Син аны өнсез калып тыңлыйсың. Галәмнең яралышына шаһит булган ташларга җирнең дә, кешелекнең дә бөтен тарихы сыйган. Аны ишетә, тоя, сизә белү һәркемгә бирелмәгәндер.

Рәшит Әхмәтҗан бу поэмасында ташлар белән җан телендә сөйләшә. Гадәти хикәяләү, проза чалымнарына төшәргә бөтен мөмкинлекләр бар югыйсә: әсәрнең үзәгендә – Әлмәттә йортлар салучы ташчы егет. Яңа шәһәр салынуга багышлап сокланулы, купайтулы күпме әсәрләр вакытлы шаукымга ияреп язылмагандыр. Рәшит Әхмәтҗанның бу поэмасы – бөтенләй башка... Ул ташчы-төзүче чагында кайнаган хисләренең шагыйрь дәрәҗәсенә җитеп олыгаюын көтә белгән, һәм шушы сабырлык, хисләрнең кайнарлыгын җиңү аны, лирикасына хилафлык китермәгән хәлдә, фәлсәфи, тыгыз мәгънәле әсәр язуга китергән.

Үзәктәге каһарман – ташчы – кешеләргә оя кора, аның кулында кешене җылытучы таш. Ә шагыйрь күңелендә – тарих. Ул, җылы таш рухын аңлап, дәверләр буйлап сәяхәт итә. Таш – дошманга ыргытыласы корал да, дус каберенә куеласы истәлек тә, бизәнү әйбере дә. Кеше кулында таш көчле дә, көчсез дә икән әле.

...Югары кимәлдә, шигъри куәт белән язылган бу поэма телнең тәмен белеп, игътибарлы укуны сорый. Сәләтле укучы аны аңлап, яратыр, дип уйлыйм» (1986, 2 октябрь).

Ул елларда яңа поэма төгәлләгән шагыйрьдән каләмдәшләре арасында көнләшү хисе туу да гаҗәп түгел иде. Ярый ла ул көнләшү маңгайга сырлар уйдырырлык каршылыклар китереп чыгармаса...

Хәтеремдә, Рәшит Әхмәтҗан «Карачкы» дигән поэмасын бастыру хафасы белән йөри. Борчыла, шикләнә, әллә нинди фаразлар уйлап чыгара. Шундый мәрәкә килеп чыгуга үзе эчтән канәгать тә шикелле... Поэмасын шулай кулдан-кулга йөртә торгач, эчке рецензия язарга дип, миңа бирделәр. Тиз генә укып чыгып, фикерләремне яздым да, хәзер килеп җитәм, дип, үзенә телефоннан шылтыраттым.

Нәшриятның унынчы катына менеп җитеп лифт ачылуга, каршымда басып тора бу:

— Багърем, сине дүрт күз белән көткән арада газиз акчама алган бер пачка сигаретны тартып бетердем,— дип, язган кәгаземне кулдан алды да, авыл агайлары сыман чүгәләп, аркасын стенага терәп, тәмәке тарта-тарта укып та чыкты. Аннары, сикереп торып, кулымны кысты: — Рәхмәт, багърем. Бу яхшылыгыңны ил онытмас... Артыграк та чөйгәнсең бугай, дусларны көнләштереп...

Аның кыяфәтенә, йөрешенә, бөтен гәүдәсенә таралган сөенүен, чын-чынлап куануын күреп, мин гаҗәпкә калдым. Минем язу булмаса да, поэмасы басыла бит инде югыйсә... Бәлки, хикмәт анда түгелдер, бу халәтнең асылы тирәндәрәктер... Күпме айлар, күпме йокысыз төннәр буе илһамланып, үз-үзен аямыйча, шушы әсәр вакыйгалары хәятында яшәп, ул тәмам арып, таланып, йончып, бүгенге көнгә җиңүче булып кайтып төшкән бит. Яңадан туган кебек, бу тормышка сабыйларча күнегеп кенә барган мәлләредер. Поэмадан бушанган Шагыйрьнең, фәрештә кебек, бер гөнаһсыз калган таркау-нәүмиз халәте...

Шул чакта ул җәһәт кенә машинкада бастырып алмаган булса, үзем өчен югаласы язмамда мондый юллар булган икән:

«Ярый әле... бу дөньяда акыл һәм хис тәңгәллегенә тере сулыш биргән шигърият бар. «Мин — кеше!» дигән затның гаҗәеп сәнгать җәүһәрләре тудыра алуына сокланып карыйм да... икенче кулы белән меңнәрчә еллар дәвамында үз кавемен изәр, юк итәр өчен акыл ирешмәслек явызлыклар кылуына шаккатып, чарасыз калам. Кем син, Кеше? Каян килдең син бу Җир-Анага? Явызлык һәм миһербанлыкны үлчәр бизмән каршында аптырап калган мизгелдә адәми затның җан авазын, илаһи хисләрен исәпли алмый торган рухи урталык — тел куәсенең галәми тәэсире — шигърият ярдәмгә килә. Шигърият сүрүенә кергән моң агышы, әрнү, җирдәге кырыс кануннарга сыеша алмыйча, адәмнең асылын, яшәешен, рухи халәтен табигый чынбарлыктан өстен яссылыкка менгерә ала. Менә шул чакта инде син чистарынып, көнкүрештәге болгавыр ваклыклардан арынып, яңадан туа аласың.

Поэзиянең көче — гомерне яңарта алуда.

Мин әле һаман «Идегәй» дастанының шифалы кайтавазында яшим. Күңел чикләрен соңлап булса да мең авазлы оркестр киңәйтеп җибәргән халәттә, яңа әсәрләргә дә шул тәэсирләрдән чыгып карыйм.

«Карачкы» поэмасына мин әнә шундый фикерләр белән янып килдем һәм алданмадым. Әсәр, чынлап та, телебезнең югары кимәленнән торып язылган. Олы мәхәббәт турында: заманның фаҗигаләре аша җирдәге тормышны, илне яратуга, иманны сакларга чакырган шагыйрьнең бәгырь авазы җанның акылга сыялмый торган тарлавыкларына хис яктылыгы алып керә. Югарыда телгә алынган дастанның йогынтысын, тәэсирен мин бу поэманың аерым бүлекләрендәге борынгыдан килгән әйләнмәләрдә, фикерне мәкаль тыгызлыгына җиткереп, саллы әйтә белүдә, көй агышында тойдым.

Поэманың эчтәлеген сөйләргә тырышу, аерып, таркатып карау — оста каршында гөнаһ дип саныйм. Аны ялгызың гына укырга, шул дөнья белән яшәп алырга һәм иң гадел шаһит — күңелең белән кичерергә кирәк.

Кеше хисләре җәяүле дә, канатлы да. Таяну ноктаң җирдә чакта – күкне онытмыйча, кунаклар ноктаң күк катларында чакта – җирдәге тамырың тибешен онытмыйча, асыл урталыкны табып, телнең нечкә җан тибрәнешләрен тоеп яза белү – шагыйрь Рәшит Әхмәтҗанның бөтен иҗатына хас сыйфат. Бу поэмасы белән тагын ул үзе генә тапкан моң чишмәсен кешеләр хөкеменә юллады» (1989, 13 апрель).

***

Исәннәрне исәпләгән чакта,
Сөю мине таба алмаган.

Мәхәббәттә Шагыйрь – назга сусаган кадерле ятим. Үз холкына хас булганча, хис-тойгыларның моңлы баласы. Бәхетен җилдереп алып киткән аргамаклар артыннан, күз яшенә чыланып, эчтән ялварып йөгерә, тәмам өметен өзеп туктап калган мәлләрендә иң садә хисләрен дога итеп пышылдап хәл ала да тояк, тәгәрмәч эзләре калган юл тузанын учына кыса.

Хушлашмыйча, еракларга күз төбәп киткән олуг мәхәббәтенә үпкәләгән чакларында ул гади җир кызын искәрә ала, сагыш томаннарын ерып, аңа эндәшә:

Гомерне саклый бу җирдә
Кавышыр мизгел генә.
Йөрәгем ярылып үләрмен,
Шушы мизгелнең үткәнен
Тик миңа сиздер генә.

Мәхәббәттә Шагыйрь – үзе уйлап тапкан матурлык иленең иркә бер колы; гөлгә – туфрак, җилкәнгә – җил, керфеккә – яшь, дулкынга яр була белә.

Ничек соң мин яшь шаһзадә булып
Килалмадым сиңа ак атта...

Мәхәббәттә Шагыйрь – үзе белгән дүрт фасыллы дөньяның шаһы; тәхет биеклегеннән әмер генә бирсен, сандугачлар сулавыннан – яз, яшел ялкыннардан – җәй, күзләрдәге яфрак төсеннән – көз, аккошлар аклыгыннан кыш туа. Шушы фасыллар арасында ул гүзәл юклыкны эзли, чакыра, алгысына, тагын моңга бирелеп, ләззәтле газаптан бер мәлгә чарасыз кала.

Кулыма алтын богаулар
Кил әле, кидер, иркәм.
Югыйсә сазым кылларын
Өзәрлек итеп чиртәм.

Юк, бәхетен җилдереп чапкан аргамакларны куып җитәсе килми аның. Эзләгәнеңне табу – югалту мизгеле дә икәнен аңлаган йөрәк, ярга якынаюга кире борылып, үз-үзен сындырып сынаган дулкыннар кочагына кабаттан ыргытыла.

Дулкыннан – дулкынга, йолдыздан – йолдызга, шигырьдән шигырьгә күчәр өчен, аңа туктаусыз сагыш нуры белән өртелгән үкенечле хис, татлы әрнү, җилләр телендә ялвару түбәнчелеге кирәк.

Ләйләле-Мәҗнүнле төрки-татар шигъриятендә Рәшит Әхмәтҗан лирикасы – әлегә ачылмаган энҗеләр ганимәте, таш диварлар арасында кысылып сула барган күңелләрне коткару-терелтү дәвасы.

Сөю-сәгадәт хәятында үзеңне бәхетсез тойганда гына бәхетле язмышлы шигырь туадыр, мөгаен.

Ә аргамаклар, шигърият алиһәсен җилдереп алып киткән аргамаклар, чакрымнарны, елларны тәгәрмәчләренә урап, һаман алга томырылалар. Каләмле хыялга аларны куып җитәргәме-юкмы? Тояк эзе саен шигырь...

Менә Шагыйрь офыкка бәрелеп туктап кала. Күзләрендә – яфрак төсе. Йөрәге күкрәк читлегенә сыеша алмыйча тибә. Олы юл тузанын ияртқән Сөю аргамагы отыры ерагая, ерагая бара... Дала читенә таянган кояшның моңсу шәфәгына кереп югала.

Шагыйрьнең соңгы аккорды, бәхилләшү авазы, кош булып күккә күтәрелә дә, иңрәп, дала күкрәгенә егылып төшә...

Дәшәрмен теге дөньядан:
«Без һаман дамы бергә? –
Бергәме?! Үлмә, бәгырем,
Мин кердем синең гүргә.

***

Казан күге аязлыктан гаҗиз.
Күктә кояш кайный, мәйданда – халык.

Бер төркем язучылар, сәясәтчеләр, ачлык игълан итеп, Ирек мәйданында урын биләп алдылар (1991 елның май ае). Җөмһүриятебездә Россия Президентын сайлауда катнашмау турында сәяси шау кузгатып, бу тарихи сәгатьнең укларын борып җибәрүче Жанна д Арк – «Газиз халкым!» дип, бәгырьгә үтәрлек чыгышлар ясап, меңнәр күңелен бер итүче Фәүзия Бәйрәмова иде.

Казан күге коргаксыган көннәр.

Аяз күктә кояш зеңләп тора. Эсселеккә чыдар әмәл юк. Аяк астында асфальт эри. Афәтле эсселеккә чыдар да идең – иңнән кагып, «Мәрхабә, егетләр!» дип китүчеләр артыннан ук тупас йодрыклы маңкортлар, калкынып, төнлә һөҗүм оештырабыз, дип янап китәләр. Үзен бәхетле санап йөрүче коллар чиркандыра. Ярый әле, үз сәламәтлеген яндыру хисабына көрәшүчеләр арасында Зәки Зәйнуллин бар. Балтыйк буеның тозлы җилләрендә чыныгып, империянең асылын башка халыклар язмышында да күреп кайткан полковникның гаярьлеге кайнар башларны, таш диварга килеп бәрелгәндәге кебек, кире чигенергә мәҗбүр итә.

Болай да ябык Рәшит Әхмәтҗан, ничә көннәр буена зәһәр кояш астында ач торып, тәмам какланып, каралып беткән. Күзләре генә утырып калган. Ат күзләре кебек – әле ярсу, әле моңсу. Эчендә гүя бер гөнаһ калмаган, шигъри кисәүләр генә көйри...

– Улым, арагызда иң ябыгы син. Менә, каймакка гына туглап, төче коймак пешереп килдем, бисмилла әйтеп, авыз ит әле, бәбкәм...

– Рәшит улым, минем өчпочмакларымның тәмлелеген Яңа бистәдә белмәгән кеше юк. Бер төенчек алып килдем, алып кал...

Болар – нурлы йөзле, эчкерсез апалар. Чын-чынлап, Шагыйрьнең хәленә керергә тырышып мәш киләләр. Ач торган чакта ашарга ярамаганлыгын Рәшит Әхмәтҗан аларга һич кенә дә төшендерә алмый. Елмаеп шаярта-шаярта, елмаеп битәрли-битәрли, аларны озата.

Бераздан халык төркеме өстендә аның микрофоннан көчәйтелгән тавышы яңгырый:

Яшәргә! Яшәргә! Азатлык алмыйча
Кузгалып китү юк быелгы җәемнән.

Шул җәйдә, Декларация кабул ителәсе көндә дә, Шагыйрь халык белән бергә иде (1991, 30 август). Ирек мәйданының беркайчан да болай кеше диңгезеннән тыгызланганы булмагандыр. Халык ташкынын тыяр өчен, катлы-катлы милиция чылбыры тезелгән, һәр адымын үлчәп яшәргә өйрәнгән йончу ирләрне уздырып, алгы сызыкка хатын-кызлар, әбиләр чыккан. Ак яулыклы әбекәйләр, кирәк чакта, гавамны үсендереп җибәрәләр, кирәк чакта, ак намазлык өсләрендә Ходайдан ярлыкау-сабырлык сорыйлар.

Мәйданда – догалы читекләр.
Мәйданда – дагалы итекләр.

Әнә ул, яшел байрак асларында Шагыйрь халыкка сүз кодрәте чәчә. Шигырьләре – тышауларын өзеп, күкрәге белән тарих араннарын бәреп чыккан юргалар кебек. Сулышсыз калып

тыңлаган мәйдан йөрәгендә дәүләтле, ханлы һәм канлы гасырлар кайтавазы уяна, коллык йокымсыравына күнеккән тәннәрдә татар каны уянып кычкыра башлый:

Халкым бүген ирек алалырмы,
Богавында әллә калырмы?
Көчкә сулыш алып яткан бөркет
Көтә шулай соңгы давылны...

Кинәт мәйдан, тылсымлы кул ишарәсенә ияргән кебек, дәррәү каерылып өскә карый. Югары Совет бинасының алтынчы кат тәрәзәсендә булачак Президент басып тора икән. Артында бер төркем яраннары да шәйләнә. Хәлиткеч декларация кабул ителер алдыннан озын тәнәфес вакыты бу.

Ялгыш сызылган бер шырпыдан кабынырга торган халык бер мәлгә тын кала. Тыкрык саен ябык машиналарда корыч мускуллы омончылар, бронежилетлы, резина таяклы, нурсыз күзле бу егетләргә кеше тәнен һәм рухын таптау фәне өйрәтелгән — бу мизгелдә алар да тып-тыныч.

Булачак Президент биектән, тәрәзә аша мәйданга төбәлгән. Гүя сүзсез дуэль бара. Корридадагы кебек хәвефле секундлар. Тореадор ике үлем арасында... Каршында — шашкан үгез үткен мөгезләрен төбәгән. Үгездән — канлы үлем. Халыктан — рухи үлем. Әгәр тореадор үгезне, сәнгатьле итеп, нәкъ вакытында аудара алмый икән, халык аны сызгырып, мыскыллап аренадан озатачак. Әгәр инде оста итеп, нәкъ вакытында сыртына яткырса, халык тореадорны милли каһарман итеп пьедесталга менгерәчәк. Тореадор — хәтәр ике көч арасында...

Булачак Президент тәрәзә каршында тораташ калып басып тора. Менә хәзер аның бер бармак селкүе җитә, куәтле ташкын халыкны тапап чыгачак. Кайсы хакимнең тарихта мондый ләззәттән ваз кичкәне бар?! Кайсы хакими затның, меңнәр җанын кыеп, кан чыгарып, даһи титулын аласы килмәс икән?!

Тарих явызлыкка табына, яхшылыкның хәтере кыска...

«Камыр булма, Минтимер!» дигән плакатлар арасыннан халык аңа төбәлгән. Бу мизгелдә аның күңелендә ниләр кайный, бер үзе генә беләдер... Мин үземчә фикер чыгарам: дүрт гасырдан соң, ниһаять, чын татар моңыннан яратылган татар хакиме... Әнкәсенең бишек җыры, чалгы тавышлары, сандугачлы Агыйдел әрәмәлекләре... аның тән күзәнәкләренә таралып, сезме мәрхәмәт сорап пышылдадыгыз? Югыйсә әмер генә көтеп, тәкатьсез торган шундый көч, тимер ташкын кул астында була торып! Юк, мондый мизгелдә кан чыгарып дан алудан шәһәр ташында туып үскән, ят тәрбия алган салкын җанлы шәхес чирканмас иде, тәхет биеклегеннән бурзайларга явыз әмерен ташлар иде.

Ә ул, «иде»гә таянмыйча, халыкка карап тора. Чыгышы белән ханнар нәселенең турыдан-туры дәвамы булмаса да, язмыш-әнкә аңа солтанатлы исем куштырган (күп кенә олуг ханнарның исемендә «тимер» булу юкка түгелдер: Төп Тимер, Туган Тимер, Мәңге Тимер, Тимер Котлык, Тимер Мәлик, Тимер Хуҗа, Тукай Тимер, Баш Тимер, Шаһтимер һ.б.).

Шулай итеп... Мәйдан көтә. Тореадор — аренада...
Буйсынма! Буйсынма! Нәкъ сиңа
Җир-күкнең әмере бирелгән:
Илеңне азат ит иң элек,
Җан азат бары тик Ил белән.

Декларация кабул ителгән ул көн һәм төн Рәшит Әхмәтҗан өчен утлы шигырьләрдән генә тукылган иде. Аның «Ачлык мәйданы» дип исемләнгән шигырьләр бәйләме — кылыч йөзеннән йөргән хәвефле көннәр, төннәр биргән аһ-зарлы, газаватлы илһам кодрәте, гомеренең истә кала торган шомлы тантанасы иде.

Ә көне... нинди кояшлы иде.
Мәйданда — дагалы итекләр... таптарга әзерләр.
Мәйданда — догалы читекләр... тапталырга әзерләр иде.

***

Бер гаилә булып түгәрәкләнгәнбез. «Казан утлары» редакциясенең гадәти генә бүлмәсе — бәйрәмчә. Иске елның соңгы көне (1994). Табын мул. Иң уртада — һәртөрле салатлар, шәраб шешәләре арасында — кыздырылган кыр куяны. Хуш исле яшеллек, лимон кисәкләре арасыннан күз карашын тартып тора. Кама ярының ак карлы тугайларыннан атып алынган. Баш редактор Равил Фәйзуллинның Яңа ел күчтәнәче.

Табын сандугачы — Рәшит Әхмәтҗан. Кәефе шәп. Һәрвакыттагыча, пөхтә киенгән. Эчтән балкып, гәүдәне төз тотып, очынып кына йөри.

Телләр язылып килгәндә, иң өлкән кунагыбыз — ашау-эчүнең тәмен, рәтен, кадерен белгән Аяз ага Гыйләҗевкә куян түшкәсен бүлүне тапшыргач, Рәшит Әхмәтҗан, тост әйтергә дип басып, табынны йөгәнләп кенә алды. Һәр сүзенең кытыгын китереп, шау көлдереп, үзе уйлап чыгарган мәкальләр белән сипләп, шаян тост әйтте дә, җитдиләнеп: «Моны истә калдырыгыз, багерьләрем, бүтән ишетмәссез»,— дип, беребез дә моңарчы ишетмәгән сәер бер җыр җырлады.

Үзе дә белмичә, шулай җиңел, рәхәт итеп, безнең белән бәхилләшүе булган икән...

Яшьләр коридорга бүселеп чыгып биегәндә, ул, бармак арасына кыстырган тәмәкесе белән киңәшеп, көч биреп торды:

— Бик кызмагыз, багерьләр. Рудольф Нуриев кебек бию осталарына да көнгә өч тапкыр гына чүгәргә рөхсәт ителгән. Яңа елга керәсе бар.

Шулай диде дә... үзе... Яңа ел бусагасында...

Шунысы гаҗәп: ул әйткән тостны да, җырының сүзләрен дә, никадәр бәргәләнсәк тә, кабат искә төшерә алмадык. Әйтерсең лә соңгы көнен Иске ел хәтерләрдән юып алган, гүя серле төш күреп, без аның өнсез рухы белән генә аралашканбыз.

Бер уй тынычландыра: аның иҗаты үзеннән башка да ятим була алмый икән. Актык сулышынача гомерен шигърияткә багышлаган шәхесләр сирәк була. Рәшит Әхмәтҗан шундый могтәбәр сирәкләрнең берсе иде.

Ул — матбугатта һәрбер тәнкыйтьче саный торган түтәл-түтәл исемлеккә сыя алмыйча, үзе бер дөнья булып иҗат итте.

Әгәр аңа Күк иясе:

— Шигъриятнең пәйгамбәре итәм, калган гомереңнән ваз кичәсеңме? — дисә, ул сүзсез риза булыр, халык бәгыренә тәңгәл килгән чын шигърият хакына җирдә бүтән мәңге кабатланмаячак гомерен корбан итәр иде.

Иртәрәк китте... дибез.

Күкрәк читлеген аерып чыгып, галәми чиксезлеккә очарга дип талпынган җан кайчан өлгереп җитә? Моның белән кем идарә итә? Бәлки... иҗат гөмбәзең билгеле бер кимәлгә җиткәч, үз зурлыгында күрсәтү өчен аны шәхестән аерып алуны Тәңре үзе хәл итәдер.

Казанның Татар зиратында, гасырның мәртәбәле затлары куелган урында, бөек Тукай янында күмелү бәхете... очраклылыкмы? Ике шагыйрьнең янәшә килүе — алдан билгеләнгән тәкъдирме?

«Минем гасыр таңындагы шигъриятемне гасыр азагына менә кем ялгар!» — дип, Тукай рухы дәшеп китергәндер, бәлки...

Җавап эзләп, мин аның китабына иеләм. Тормыш агачына сәҗдә кылган Шагыйрьнең юату сүзе шәмаилгә күчә:

Мин җылытам әле, дөньям, сине,
Җаным суынганчы җылытам.

# Дулкын баласы[1]

Кояш Тимбикова

...Рәшит Әхмәтҗанов белән соңгы сөйләшүем искә төшсә, җаным тетрәнә, үз-үземне өзгәләп ташлардай булам. Аның белән аеруча дуслар идек. Вафатына инде күпме вакыт үтте, мин әле аны һаман исән дип беләм, аның белән сөйләшкәннәрне-киңәшкәннәрне, бәхәсләшкәннәрне аз гына да истән чыгара алмыйм.

Соңгы унбиш еллап дәвердә без аның белән гел бергә «Казан утлары»нда эшләдек. Башта икәү генә бер бүлмәдә утыра идек, аннары аердылар. Тик бүлмәдәмени хикмәт? Эшкә мин алданрак бара идем. Ул да иртән килә. Мин коридорда, аның аяк тавышын ишетүгә, каршы чыгам, ә кайчакта ул мине коридорда ук каршы ала. Беренче сорауларыбыз: «Берәр нәрсә яза алдыңмы?» Бу – бездәй эшләп иҗат итүче язучыларның төнге эш турындагы сүзләре. Мин үземнең ниләр эшләвемне, ул үзенең ни язганын әйтә. Миңа «мактану» бик эләкми, чөнки төнге язудан башка аш пешерү, идән-кер юулар да бар бит әле. Рәшит исә һәр төндә диярлек, дүрт кенә юллык булса да, шигырь чыгара.

– Йә, укып күрсәт әле, зинһар! – дим.

– Чынмы? Тыңларсыңмы? – ди.

– Аның нәрсәсенә гаҗәпләнәсең? Кем инде синең шигырьне тыңлаудан баш тартсын?!

– И-и, Кояш, белмисең син, артларыннан инәлеп йөреп тә укыта алмыйм кайберәүләргә, ишетергә дә теләмиләр.

– Әйдә, ярар, зарланып торма әле! Укы, хәзер ятлап алам, бөтен коридор буйлап, кем очраса, шуңа сөйләп күрсәтермен үзем! – дим.

– Җүләрләнмә инде, миңа шул гына җитмәгән! – дип көлә һәм укый башлый.

Шагыйрь буларак кына түгел, кешеләрчә ярдәмчеллеге белән дә миңа нык илтифатлы булды ул. Берсендә бик тә авыр хәлдә калдым: өебезнең бер бүлмәсендә 93 яшьлек әнием хәрәкәтсез авырып ята, икенчесендә – ирем, мин уртадагы залда, читлектәге коштай, кая барып бәрелергә белми интегәм. Ике бик җитди авыруны карарга да, эшкә йөрергә дә, җитмәсә, бакчаны барлап торырга да – барына да бер ялгызым. Бакчабыз еракта, электричка белән барып, аннан тагын җәяүләп йөри торган урында. Шулай ут йотып яшәгән көннәремнең берсендә Рәшит эш бүлмәсенә керде дә:

– Карале, бакчагыз һаман казылып бетмәгән, мин дустың Марсель Галиев белән дә килешеп куйдым, бер көн билгелик тә, әйдә, бергәләп казып куйыйк! – ди бу.– Җир кызганыч бит, бәрәңге генә үстерсәң дә...

Әй ачуым чыкты, әй гарьләндем!

– Шул безнең уч төбе кадәр бакчадан башка кайгың юкмы, Рәшит?! Булмаса, бар, эчемне пошырып торма әле!

– И-и, нишлисең соң син? Ярар, ярар, миңа димәгәе...

– Синә шул сазлык җир кадерлеме, әллә кешеләрне савыктырумы? Өемдә ике авыру ятканын беләсең ич!

---

[1] Истәлек К. Тимбикованың «Дулкын баласы» (Казан: Татар. кит. нәшр., 1997.– 114–119 б.) исемле китабыннан алынды.



**«Казан утлары» журналы хезмәткәрләре Мостай Кәрим белән. Басканнар (сулдан уңга): Рафаэль Төхфәтуллин, Тәслимә Сибгатуллина, Гөлзадә Бәйрәмова, Флүс Латыйфи, Җәүдәт Миңнуллин, Мансур Вәлиев, Рәдиф Гаташ, Мөдәррис Вәлиев, Сәйдә Зыятдинова, Рашат Низами, Роза Сөләйманова, Нияз Акмал; утырганнар: Рәзифә Вафина, Роза Туфитуллова, Кояш Тимбикова, Мостай Кәрим, Рәшит Әхмәтҗанов**

Җүләр димә инде мине: рәхмәт әйтеп, егетләрнең ярдәменә таянасы урынга Рәшитне эт итеп сүгеп, туздырып ташладым. Алай да шом кереп калды. Ял көнне әни янына апамны чакырып китердем дә бакчаның эшен бетереп кайттым. Рәшит тә күргән моны. «Молодец, гөл иткәнсең бакчагызны!» — дигән була.

Бакча турында тагын бер фәлсәфә куертып алыйм әле. Безгә ул җирне: «Язучыларга гына!» — дип, 1975 елда биргәннәр иде. Әй мыскыл да иткәннәр икән. Бу җир кирпеч заводы өчен ике метр тирәнлегендәге сары балчыгы каерып алынган карьер төбе булып чыкты. Әле булса азапланабыз, аны ел саен су баса, анда алмагачларның тамыры чери, юньле берни үсми. Язучылар — җир белгечләре түгел бит: бергәләп эшкә тотындык, йортлар сала башладык. Безнең өй, миңа калса, иң матуры. Ул Ленин бабайның Петербург янында патшадан качып яткан шалашы рәвешендә салынды. Ике як дивары гел түбәдән генә тора, җирдән үк түбә шиферы күтәрелә башлый. Шул сәер кыяфәтен тагын да матурайтыр өчен, бинаһая биек бу шалаш очына без берәр нәрсә сурәте дә ясап кадакларга булдык. Рәссам Илдар Әхмәдиев белән киңәшләштем. «Мин үзебезнекенә, көнбагышка охшатып, кояш рәсеме кадаклап куйдым,— диде ул.— Кайберәүләр әтәч элә...» Илдарның сүзләре турында уйландым да әтәчне кире кактым, кечкенә чагымда бер кызыл әтәч талаган иде, гайрәтем чигеп калды әтәч халкыннан. Инде көнбагыш төслерәк кояш сурәте хакында ни дияргә? Бездә, мишәрләрдә, көнбагышны «айбагар» дип тә йөртәләр. Башыма шул сүз кереп оялады. «Айбагар, айбагар, ай...» Таптым: әтәч тә түгел, кояш та түгел, көнбагыш та түгел, без өй кыегының очына яңа туган ай сурәте кадаклап куярга булдык. Шалаш-өебез биек, аңардан да өстәрәк, колга очында, күккә тиярдәй булып, ай кадакланган. Аебызны беренче булып Сәет абый Шәкүрев котлады, иремә әйтә:

— Кара, кызык иткәнсең син, ә! «Хатыным — Кояш, өем — Ай!» диярлек бит бу, — ди.

Бераздан дустыбыз Марсель Галиев килде. Ул башка яктанрак яхшы җирле бакча алган иде.

— Безнең бакчадан сезнең «Ай» күренә! — ди, шатланган кебек.— Аны мин сезгә буяп бирим әле. Бик шәп буяуларым да бар...

Бу егет, Рәшит кебек, «ярдәм итим!» димәде. Монысы хәйләкәррәк. Аннары аның рәсем сәнгатенә осталыгын да беләбез.

— Әйдә соң, буя! — дидек.

Менеп китте ул сигез-тугыз метр биеклектәге түбә очына. Баскыч-мазар юк, эләгеп кенә тора инде. Җитмәсә, ул көнне бакчабызга Фәния Хуҗахмәт тә килгән иде. Ул астан, Марсельне тиргәп, әллә нинди күрсәтмәләр биреп тора. Марсель бер кат буяп чыккан иде, Фәния бот чабып көләргә тотынды.

— Ник көләсең, затсыз? — дип сорый Марсель.

— Мин сиңа яңа кушамат тагам: «Сары ай» дип калдырам мин сине, ник айны сарыга буядың? — ди.

— Әй, Фәния, ярар инде,— дибез без.— Сары чагы да буладыр айның, Марсельне каушата күрмә, егылса-нитсә, нишли алабыз?

— Егылмыйм! — ди Марсель.— Алай да бу затсызның сүзендә хаклык бар, ак белән тагын бер кат буяп алам әле!

Өй кыегына эленгән айның тарихы моның белән генә бетмәде. Берәр атна үттеме-юкмы — мине Язучылар берлегенең ул чактагы җаваплы секретаре Фәрвазыбыз чакыртып алды. Йөзебите кара көйгән, иреннәре дерелди:

— Син, кызый, бер дә тик кенә яши белмәдең,— дип башлады.— Инде тыныч кына эшләп, шуннан пенсиягә чыгарсың дип ышанып, синең өчен шатланып тора идем...

Фәрваз — группадашым, дустым, миңа зыянга бер эш тә эшләмәде. Мин аның белән тел яшереп тормый идем. Әле дә:

— Нәрсә булган, вәгазьләреңне калдырып торып, турысын гына әйт әле! — дим.

— Ни пычагыма әллә нинди айлар куйдырдың бакчаңа? Обкомга китәбез хәзер. Мусинга. Үзе парторг, үзе мәчет ачып куйган, дип, шикаять язганнар.

Киттек. Обкомда Мөдәррис Мусиновичның мине ничекләр мәсхәрәләгәнен язып тормыйм. Ул да гүр иясе бит. Үлгәннәр турында йә яхшыны гына сөйләргә, йә берни дә әйтмәскә өйрәттеләр мине. Үзем гаепле: мин КПССның татар язучылары белән җитәкчелек итүче Мөдәррис Мусиновичка безнең дача өе кыегындагы ай сурәтенең КПССка да, ислам диненә дә һичнинди мөнәсәбәте булмавын аңлатып бирә белмәдем, еладым да еладым...

Рәшит Әхмәтҗанов белән бакчаларыбызның бер җирдә булуы гаиләләребез даирәсендә дә тәмам дуслаштырып җиткергән иде инде. Менә быелгы җәйнең чәчәкләре дә, җиләк-җимешләре дә Рәшитне юксынып боегып утыралар. Кем уйлаган? Аңардан мәңгелеккә аерылышуны белсәм, мин соңгы очрашу-сөйләшүләрдә бөтенләй башкача тоткан булыр идем үземне. Әй, бу дөнья!

Рәшит Әхмәтҗановны мин соңгы тапкыр 1994 елның 27 декабрендә күрдем. Эшкә барган идем. Нәкъ элеккечә: «Ниләр язасың, Рәшит?» — дип сорадым.

— Әй! Кояш дус килгән! Язам гынамы соң — шигырьләрем журналда басылып ята, инде корректурасы килде, тыңла! — диде дә мең кеше йөреп торган корректорларыбыз бүлмәсенең ишек төбендәге урындыгына чүмәшеп укый башлады:

Дәшәрмен теге дөньядан:
«Без һаман дамы бергә? —
Бергәме?! Үлмә, бәгырем!
Мин кердем синең гүргә»...

Рәшит соңгы чакта үлем, гүр кебек кирәкмәгән нәрсәләр турында ешрак сөйләнә башлаган иде. Тагын шул. Ачуым чыкты:

– Тапкансың язар нәрсә! Матурлык хакындарак уйлап яз әле, шомлысы синең шигырьләрдән башка да буа буарлык! – дидем дә башкасын тыңламас булдым.

Яңа 1995 ел туды. Беренче көннең таңында ук телефоныбыз шалтырады.

– Котлыйм, дуслар! – ди Рәшит.– Йокыгыздан бүлдемме?

– Нинди йокы инде, Рәшит, төшке ашка әзерләнеп йөрибез. Котлавың өчен рәхмәт! Яңа елны ничек каршы алдың? – дим.

– Безгә артистка Асия Галиева килергә тиеш иде. Шуны каршыларга чыгып, аймылыш булдык. Ике сәгать урамда басып тордым, туңдым, мин гел туңам бит...

– Килдеме соң Асия ханым?

– Ул, адашып, кире кайтып киткән. Хатын такси белән барып алды,– ди.

Көлештек. Бу сөйләшүебез әле кешечәрәк булды. Ә соңгысын искә төшерүе дә авыр. Гыйнвар башында кешеләр атна буе ял итте бит. Яңа ел бәйрәменә урысларның Раштуасы ялганды, эшләмичә ыгы-зыгы килеп, халык гел өендә ятты. 4 нче гыйнварның кичке ягында Рәшит кабат шалтырата.

– Кояш, мин үләм бит,– ди.

– Әй, Рәшит, синең бүтән эшең юк шул! – дим. Кем белә бит?! Кем белә аның шул сүзе хак сүз булып чыгасын?! – Минем монда өй тулы кунак, кухняда ашым ташый, үлми тор әле?! – дим.

Рәшит шаркылдап көлде:

– Әле генә үлмиммени? – ди.

– Соң, Рәшит, шулай дими ни диим, үлмичә калган кеше юк. Барыбыз да үләбез.

Мондый буш фәлсәфә сатып утырганчы, бөтен кухнясын, бөтен кунакларны ташлап чыгып йөгергән булыр идем дә бит... Кем белә?! Икенче көнне, 5 гыйнварда, Рәшитнең үлгәнлеген хәбәр иттеләр. Бәгырьне көйдереп янгыраучы шигырьләре генә калды. Аның миңа багышланган «Җылы сүз» шигыре болай тәмамлана:

...Ул үзе дә анда өрфиядәй,
Нәзек кенә шәлен ябынган:
Күзләребез сүнсә, сүз эзләгез
Без кабызган сихри янгыннан...

# Акчарлакның сагышы...

*(Үлеменә бер ел тулу уңаеннан мәрсия)*

Рабит Батулла

> Сез китмәгез, акчарлаклар,
> Акчарлаклар...
> *Рәшит Әхмәтҗан*

Күпме шагыйрь һәм әдип – олуг исемнәр, зур бүләкләр алалмыйча китте бу фани дөньядан! Лаек килеш – алмыйча киттеләр. Үпкәләгән сыман, хәтта рәнҗегәндәй дөньядан күчте алар! Күпме лаек исәннәр хәзер дә шул халәттә, үпкәләгән шикелле, кемгәдер рәнҗегәндәй – бүләксез, орденсыз иҗат итә. Ләкин шунысы бар: лаек мәрхүмнәр дә, лаек исәннәр дә чынлыкта үпкәләмидер, рәнҗемидер – андыйларның максаты бүләк-медаль түгел. Әмма алар өчен җан атучылар, шигырь сөючеләр үпкәдә, рәнҗештә. Әлеге шагыйрьләр исә гасырларда укып ятларлык әсәрләр калдыра да җылауга тиң сагышлы елмаеп вафат була.

Риваятьләр каһарманы кеби батыр ир, олуг әдип Салих ага Батталның кытыршы гомере, фаҗигале әҗәле тетрәндермиме йөрәкләрне! Назга-сөюгә саран булды аңа язмыш, бик тә саран булды: тәкъдир аңа яхшылыкны мыскыллап-мыскаллап, җәзасын исә олылап-олаулап, мул бирде...

Нишләп шулай була икән ул дөнья: талантлы булса, тормыш җаен белми, бүләкләр артыннан чапмый, «җәмгыятебезнең каймагы» булганнар йортыннан фатир дауламый; эше аз, акчасы күп булган җылы эзләми – ул иҗат итә, нәфис сәнгать ярата, гүзәл шигърият бинасын кора һәм, шул бинаны корганда, торыр өчен үзенә дә иркен бина төзүне онытып җибәрә.

Бар коеп куйган шагыйрьләр. Алар химаягә, игътибарга мохтаҗ. Андыйларның тормышкөнкүреш эшләрен кемдер кайгыртырга тиеш. Кемдер... Бай химаячеме, хөкүмәтме, халыкмы? Нишләрсең, әгәр бай кеше сәнгатьтән хәбәрсез булса, хөкүмәттә сәнгать аңламаган кешеләр утырса, халкың үзе ярдәмгә мохтаҗ булса?!

Без әнә шул, үз мәнфәгатьләрен алга сөрә алмаган чын талантларга өстәнрәк багабыз; вакытвакыт, ихтыяри-ихтыярсыз рәнҗеткәлибез дә. Без өс-башы өф-өф ителгән, шома битле, сакалмыек үстермәгән, гел ак якага муенчак тагып, кеше алдында хәмер эчмәгән, төзйөрешле һәм тәти сөйләшүчеләрне күбрәк үстерәбез. Дөрес, тәтиләрне үстерергә кирәк, ләкин ярдәмгә-химаягә мохтаҗ талантларны да читкә какмаска иде... Олы исемнәрне, рәсми игътибарны киемгә карап кына түгел, иҗатка, бары тик иҗатка карап кына өләшер вакытлар дә җитәр, иншаллаһ! Бирелде бит Тукай бүләге Семён Липкинга, Шәрәфигә, Әлфия ханымга, Мөдәррискә, Фәнискә – соңрак булса да, бирелде! Ун елга гына соңара шул татар! Ун-егерме еллар моннан элек алар моңа лаек түгел идемени?!

Өс-башы өф-өф ителгән кешенең таланты да булса, бу бер камиллек булыр иде дә... Талантлы кешенең өс-башы өф-өф ителгән булса, шәп булыр иде дә... Кайчак табигать икесенең берсен генә бирә шул.

Бәс, талант микъдарын дөрес үлчәп, рәсми бүләк бирер өчен бер генә бизмән кала: әдәбиятсәнгать кануннары. Моның өчен әдәбият-сәнгать тәнкыйтенең нык үскән булуы һәм исем-бүләк



**Каләмдәшләр. Сулдан уңга: Рәшит Әхмәтҗанов, Фәннур Сафин, Рабит Батулла**

өләшүчеләрнең югары дәрәҗәдә мәгълүматлы булуы шарт. Әмма... Шартлар көтә-көтә гомер үтә. Иҗат кешесе шартына-мартына бакмастан, иҗат итә.

Иҗат, сәнгать, әдәбият – ул могҗизалар иле, серләр яшерелгән сандык, маҗаралар аланы. Сәнгатьченең иҗат остаханәсе сихрилек, серлелек белән тулган була.

Анна Ахматовадан сораганнар:

– Твардовский иҗатына мөнәсәбәтегез ничек? – дигәннәр.

Шагыйрә әйткән:

– Твардовский, әлбәттә, яхшы шагыйрь, ләкин анда сер юк! – дигән.

Анна Ахматованың бу сүзе әдәбият-сәнгать өлкәсендә эшләүчеләргә шәмаил урынына язып, диварга эләрдәй тирән мәгънәгә ия.

Без дә бит әдәбияттан, сәнгатьтән могҗиза, сер көтәбез түгелме? Көткән нәрсәбезне китапта тапсак, без бәхетле. Тапмасак – әсәрнең кыйммәте бетә.

Татар шигъриятендә ачылмаган серләр бик күп. Ул серләрне ачып, бер куаначак, шул могҗизаны халыкка җиткереп, ике кат бәхетле буласы тәнкыйтьчеләрне көтә «Шигърият» дигән серләр сандыгы.

Серлелек, тел төбе, киная, ишарә, төрттереп, читләтеп әйтү, могҗизалы маҗаралар татар әдәбиятында күп исемнәрне мәңгеләштерде: Кол Гали, Мөхәммәдьяр, Мәүла Колый, Кандалый, Имәни, Акмулла, Дәрдемәнд, Рәми, Тукай, Такташ, Туфан.

Алардан соң әдәбиятта сугыш темасы «тәхет» яулады. Шигырьгә яңа буын вәкилләре килеп керде: Илдар Юзи, Шәүкәт Гали, Рәшит Гәрәй, Хисам Камал, Әхсән Баяннар... Ике буын арасында күпер булып Әнвәр Давыд, Зәки Нури, Гали Хуҗи килде... Бу күпернең субай баганалары булып Фатих Кәрим, Гадел Кутуй, Сибгат Хәкимнәр аягүрә басты...

Хәрби лирикадан соң шигърият дигән дәрьяда тынлык, салмаклык, җилсезлек чоры башланды. Шигырь көймәсенең җилкәне шәлперәйде. Көймә, уңай җил көтеп, чарасыз гына сәясәт дулкыннары каккан якка әкрен генә тирбәлә калды. Әнә шундый чарасыз тынлыкта Роберт Әхмәтҗан, җилләп-давыллап, җилкәннәрне өреп кабартты, берүзе галәм бушлыгын тутырды. Роберттан соң тагын тынлык, һәм татар шигыренә күпләп яшь шагыйрьләр ургып, бәреп керде: Рәшит, Равил, Рәдиф, Рөстәм, Гәргәри, Харис, Зөлфәт, Мөдәррис, Разил, Зиннур, Фәннурлар – бар да серле шагыйрьләр...

Коммунистик хакимият чорында, ачык фикер әйтергә мөмкин булмаган чакта, бу шагыйрьләр серле кинаяләр, ишарәләр артына олуг фикер яшерәләр иде. Зиһниятле укучыга ул – ачыш, хәбәрсезгә ул гап-гади сүз тезмәләре иде. Астарлы сүз, яшерен фикер төрелгән шигырьләр бөек бер шигърият хасил итте.

Символлар, кинаяләр белән артык мавыгу хәтта табышмак кеби шигырьләр язарга этәрде һәм кинаяләр-ишарәләр шагыйрьнең бары тик үзенә генә аңлашыла торган табышмакка да әверелгән очраклары булды. Әмма, ни генә булмасын, бу эзләнүләр матур нәтиҗә дә бирде. Шигырь күпкүзәнәклегә әверелде, «ура, ватанпәрвәрлек»тән ераклашты.

Менә шушы бөек калкыныш чорында аталган шагыйрьләр исемлегенең иң башында Рәшит Әхмәтҗан тора. Ул – боларның барыннан да алда беренче шигырь китабын бастырып чыгарган шагыйрь.

Фикер шигыре белән хис шигыре арасында беренче күперне дә ул – Рәшит Әхмәтҗан салды.

Рәшитнең хиссият, моң, сагыш, рәнҗү, җирсү белән тулган бәгырендә яралган шигъри җәүһәрләр иң башта йөрәккә, хискә, соңра зиһенгә, фикергә бәрә иде. Аның шигыре – музыка. Музыка зиһен, акыл падишасы түгел, музыка – хиссият падишасы!

Рәшит Әхмәтҗан – серле шагыйрь. Ошбу серне бәгъре тибрәнүгә сәләтле кеше генә тоя ала, ача ала. Фикер аша ачылмый Рәшит шигыре эчендәге сер; хис, күңел күзе белән генә ачыла ул сер. Шул түгелме нәфисәи сәнгать! Аның шигыре нечкә кылларга тияр-тимәс кагыла, кагыла да – җылата, җылата да – уйлата. Шулай итеп, Рәшит хис аша укучы күңеленә олы фикер сала. Чөнки Рәшитнең бәгырендә яралган хис (ватан, милләт, йола, әче тәкъдир) укучы күңелендәге аваздаш хисне уята. Рәшитнең күңеле сихри хис нурланышы бирә башлый, бу нурланышны кабул итәрдәй икенче бер калеб – бәгырь булырга тиеш, ул бәгырь, ул калеб укучыныкы, шигырь сөюченеке. Мөкәммәл бер аңлашу, ике яклы элемтә-бәйләнеш барлыкка килә. Син күңелең белән шагыйрьнең ни әйтергә җыенганын сизә башлыйсың, аны аңлый башлыйсың. Бу хисләр ватанпәрвәрлек, милли каһарманлык хисләре икән. Күңелеңнең иң нәзек кылларын тибрәтерлек итеп язган кешедә илаһият тарафыннан бирелгән куәт барын аңлыйсың, Рәшитнең каһарман йөрәкле адәм икәнен тоясың. Кече күңелле, олы йөрәкле «Рәшит Әхмәтҗан шигыре» дигән серле дөнья ачыла.

Бу шигырьләр шагыйрь вафатыннан соң аеруча хисле, моңлы вә мәгънәле яңгырый.

«...көләргәме, еларгамы, әллә күзне мәңгелеккә йомаргамы?» дип язды шагыйрь үләр алдыннан.

«...ишәяләр шундый бичаралар, ничә үлдем... һаман үч алалар».

Үткән эш үткән, кире кайтмас Рәшит Әхмәтҗан. Үкен син, хет үл, җыла. Ләкин аның шигырьләре – үлемсез. Бүгенге җыламсырап лаф ору соңга калган үкенү түгел, исән калган Рәшитләр, Әхмәтҗаннар, Рөстәмнәр, Зөлфәтләрнең кадерен белик, диеп әйтүем иде.

Эх, бу җирне күпме таптады  
Безнең йөрәк бәйрәмнәребезнең  
Кыңгыраулар таккан атлары!

Рәшит гомере буе олуг бәйрәм көтеп яшәде, менә шушы иң беренче язган шигыреннән алып вафатына кадәр бәйрәм көтте. Кыңгыраулы атларда бәйрәмне айкап йөрде ул шигырьләрендә.

Ул күңеле, көрәше, хыялы белән халкына ничәмә-ничә тапкыр бәйрәмнәр яулады, ирек алып килде.

Рәшитнең иҗаты акчарлак кеби парлак, аның акчарлагы болытларга, күкләргә, биеклеккә хуҗа булды.

Аның иҗат җәүһәрләре гаҗәеп бер ундырышлы мохиттә шомарды, ялтырады. Үзе кебек талант ияләре белән бер Казанда кайнау да, башлангыч иҗатында аңа эләккән дусларча тәнкыйть тә, киңәшләр дә, соңгы елларда гына килгән шөһрәт тә аның каләмен чарлады, чыныктырды; яшәгән саен, Рәшитнең күңеле нечкәрә-йомшый барды, күңел йомшара барган саен, аның шигырьләре югарырак үрле иде.

Рәсми даирәләр алдынгы тәти исемлеккә кергән шагыйрьләр-әдипләр турында гына мәдхия, тәнкыйть мәкаләләре язып, «курсовойлар, дипломныйлар» һәм диссертацияләр якларга алынган тәнкыйтьчеләр, әдәбият-сәнгать белгечләре, а-ау, сез кайларда йөрисез! Кайда сез ачкан яңа талантлар, кайда сез үстергән шәхесләр, сез яңача шәрехләгән әсәрләр? Нигә Рәшит Әхмәтҗан кебек сирәк туа торган талантларны алданрак сиземләмибез, күрмибез, үз вакытында аларны тәкъдир итмибез?

Утызынчы еллардагы тәнкыйтьнең төп максаты талантларны ачу түгел, ябу, бетерү иде. Аннан соңгы еллардагы тәнкыйть рәсми «обойма»га кергәннәрне мактау илә мәшгуль булды кебек. Соңгы вакытта тәнкыйть ни эшли? Классиклар белән әвәрә килә. Классика да кирәк шәйдер, әмма әдәби мохит өчен яңа исемнәр дә, яңа шәрехләр дә бик әһәмиятле нәрсә.

Күңел әдәбият белеме өлкәсендә яңа ачышлар көтә. Яңа исемнәр тирәсендәге эзләнүләрне тели күңел. Иске исемнәр янында моңарчы күренмәгән яңалык, ачыш; мәшһүр турында яңа фикер, яңа шәрех сагына күңел.

Горур җаннар үлми — һәлак була!
Бөркет мине күзли — мин китәм:
«Бу да, балам кебек, горурлыктан
Һәлак булыр, ахры» ди микән?..

Рәшит Әхмәтҗан иҗатындагы серләрне ачу киләчәк буын тәнкыйтьчеләренең җилкәсенә төшә. Бер аның иҗаты гына түгел: Равил Фәйзулла, Рөстәм Мингалим, Рәдиф Гаташ, Ренат Харис, Разил Вәли, Зиннур Насыйбулла, Зиннур Мансур, Мөдәррис Әгъләм, Зөлфәт, Лена Шагыйрьҗан, Ркаил Зәйдулла, Газинур Морат, Ләбиб Лерон, Рөстәм Сүлти һәм башка бик күпләрнең иҗатын баштанаяк өйрәнеп, тел төбен, киная-ишарәләрен, астарлы сүзләренең серенә төшенергә, хиссият аша килгән серле фикерне, фикер аша туган хиссиятне шәрехләп бирү яңа тәнкыйтьченең иҗат мәйданы булыр.

Бар шагыйрьләр — олуг талант ияләре. Ләкин алар үзләре исән чакта үз иҗатларына үзләре комачау итә, андыйлар үз иҗатына авыр йөк-балласт кеби. Алар, гадәттә, тәти кием кими, алар — төртмә холыклы, кызмача йөри, шуның аркасында аның иҗаты да рәсми даирәләр каршында пар канат белән очып, югары күтәрелә алмый. Кинәт шәхес вафат була: олуг иҗат артык йөктән, үзен бар итүче кешедән арына һәм биеккә күтәрелә. Рәсми тәнкыйть тә аңа карата фикерен үзгәртә: шагыйрь даһилар рәтенә куела.

Бар шагыйрьләр — алар үз талантларыннан өстәрәк тора, андыйлар өрлеккә ятып, яхшы-чыдам бау белән үз иҗатларын күтәреп-тотып тора. Шәхес вафат итүгә яки өрлектән төшүгә үк, бау кулдан ычкына, иҗат йөге аска төшеп китә.

Бар сәләт ияләре — алар шулкадәр нәтиҗәле иҗат итә ки, ул шагыйрьнең җилкәсенә авыр иҗат йөге җыела, шөһрәт, иҗат бәхете артканнан-арта бара. Шушы талант иясенә шушы талант йөген күтәреп йөрер өчен ныклы тез буыны, рухи үҗәтлек бирелмәгән була. Чәндер аяклар, зәгыйфь буыннар, нечкә муен чыдый алмый, шәхесне үз таланты үзен сытып үтерә: күпме сәләт ияләре сәрхуш булды, янды, үлмичә һәлак булды.

Уйна, көл туган җиремдә.
Гашыйк ит бөтенесен.

Каләмдәшләре арасында иң шаяны, җор сүзлесе ул иде – Рәшит Әхмәтҗан.

Берзаман Рәшитнең чәче агара башлады. Буятмады ул ак чәчләрен. Чәч буятып яшәргә тырышучылардан ул көлә иде. Чәч агару ул – картаю галәмәте түгел, агарган чәчне кынага буяп йөрү – картаю билгесе.

Чәче коела башлауга, кайбер җегетләр ян-яктагы чәчен озын итеп үстереп, шәрәләнгән баш түбәсен каплап, аркылы яткызып, сулап-майлап йөртәләр. Рәшит пеләшен капламады. Башлык астына яшерергә дә азапланмады. Ясалма чәч тә кимәде. «Алла биргән, Алла алган» дип, калган чәчен да ялт итеп кырдырып йөрде. Шаяртучылар, үртәүчеләргә дә исе китмәде.

– Мөдәррис белән Равилгә теләктәшлек йөзеннән чәчемне юри кырдырдым,– дип көлә иде үзе.

Бу да үзенә күрә бер батырлык.

Чәч коелу ул картлык галәмәте түгел, пеләшеңне яшерергә тырышу картлык килгәнне аңлата.

Рәхәт көлә иде ул Рәшит, һәрнәрсәдән кызык табар иде, мәрхүм, шаярырга оста булды.

Ул ризыкның кадерен белә иде; ул тәмләп ашый, ашамлыкны һәрвакыт бәрәкәтле итеп тота, янга калдыра, соңгысын ашап бетерми, башкалар өчен, мохтаҗраклар өчен саклый һәм соңгысын мохтаҗ кешегә чыгарып бирә. Ул тәмәкене дә тәмләп, бәрәкәтле итеп тарта иде.

Кысанлык аны төнге каравылда торырга мәҗбүр итте; ул балалар бакчасын саклый иде. Торыр урыны булмагач, үзе дә шул бакчаның чарлагында яшәде. Бу чарлак «Дум калхуз» гына түгел, килгән-киткән Казан кешеләре дә шунда җылы куыш таба, бу чарлак шагыйрьләр, сәнгатьчеләрнең иҗат йорты да иде. Түбәсе булмаганнар, вокзалда кунып йөрүче шагыйрь-шогарә, хатыны куып чыгарган бичара ирләр дә, юлы төшкән «командированныйлар» да Рәшиткә килеп сыена, чарлагы тар булса да, күңеле киң – барыбыз да сыя идек.

– Рәшит кебек олы җанлы, киң күңелле дуслар сирәк була,– дип сөйли Әзһәр Хөсәен.– Казанга килгәч тә, минем торыр урыным юк иде. Рәшит мине үз чарлагына сыендырды. Мин, шунда торып, театрда администратор булып эшли башладым. Аннан курчак театры һәм Камал театры директоры булып киттем. Рәшиткә чиксез хөрмәтем, рәхмәтем...

Әзһәр кебекләр хет Рәшит эшләгән яхшылыкларга рәхмәт укый. Рәшит урын, тәгам биргән кайбер бәндәләр соңра, Рәшиттән көлеп, аны кимсетергә тырышып, иҗатын да күрмәмешкә салышып йөрде. Андыйларга Рәшит эчтән генә бик рәнҗи кебек иде. Ләкин яңадан шул кеше килсә, барыбер аңа урын, ризык бирә иде. Нечкә күңелле иде, мәрхүм, кечкенә генә игътибарга да шатлана; рәнҗетсәләр, күз яше белән җылый иде.

Ул – шагыйрь, бары тик шагыйрь! Жанрларда ул чәчелмәде. Саф шагыйрь килеш иҗат итте.

Әмма без аны аңламадык. Зарланса – көлдек. Кызык сөйләсә дә – көлдек. Без хәтта аның искиткеч нәфис каләмле, гаять олы талант иясе икәнен дә аңлап бетермәдек шикелле. Юкса ул әдәбиятка күбебездән алдан килде, олы иҗат калдырып, күбебездән алда бәхилләште.

Шагыйрьләр арасында иң сагышлысы, иң моңлысы, иң күп җирсегәне ул иде – Рәшит Әхмәтҗан.

Вафатына атна кала гажур (газета-журнал нәшрияты) коридорында очраштык. Мин каядыр ашыга идем. Аның күзе дымлы, йөзе бик тә борчулы иде. Ул, мине читкәрәк алып:

– Ашыксаң да, әз генә янымда тор! – диде.

– Ни булды? – дип сораганымны да көтмичә:

– Үләм бит, Батулла,– диде дә җылый башлады.– Гомерем әз калды.

Салганнан шулай хисләнгәнме дисәм, юк, Рәшит ап-аек иде. Еш шаяруы белән бергә ул еш зарлана торган кеше иде. Шуңа күрә без, дуслары, аның аһ-зарына иялэнгән, игътибар итми идек.

– Үтәр әле,– дидем.

– Үтми, үтәрлек түгел,– дип, Рәшит сабый баладай үкси.

– Ни булды соң? – дим.

– Дөньягыз суык, җанга җылы юк! – диде шагыйрь.

Мин эшем белән китеп бардым, Рәшит, күз яшьләрен бүтәннәргә күрсәтмәскә тырышып, лифт белән тәрәзә арасында калды. «Син дә мине аңламадың!» дигәне һаман колакта яңгырый. Аның тавышы диңгезсез калган акчарлак авазына охшаш иде. Бер атнадан соң Равил Фәйзулланың «Шагыйрь Рәшит Әхмәтҗан вафат!» дигәне дөньяны тетрәтте.

Ни булды? Шигырьдән шигырьгә үсә килә иде, поэма арты поэма яза иде. Шөһрәт тә килеп җитте үзенә: Исхакый бүләген бертавыштан аңа, иҗатына бирделәр. Осталык биеклегенә җиткән, тәҗрибәсе, иҗат бәрәкәте мул: яз да яз! Шул чакта гына аның эчендә ниндидер кылы өзелде. Кем өзде аның бу кылын? Йөрәк ни өчен тибүдән ваз кичте? Юрый-юрый, үзенә үзе әҗәл чакыруы идеме бу? Тукай әйтмешли, тәдриҗи үзен үзе үтерергә уйлаган идеме ул? Әллә олы талантының рухи буналышы (кризисы) идеме бу мизгелләр? Каян сизгән, ничек сизгән ул тиздән үләсен?

...Энесе Илдусны чакыртып, бераз сөйләшеп утыргач, шагыйрь ятарга тели, ята да – җан да бирә.

Сер. Иҗаты тулы сихри сер аның. Әҗәле дә сер булып калыр. Гадәти булмаган талантның гадәти булмаган вафатыдыр бу үлем. Үзенең олы талантка ия икәнен белеп тә, аның шул талантын күрмәмешкә салышканнары аны еллар буе борчыды, рәнҗетте сыман... Бәлки, әнә шул еллар буе җыелган сагыш-рәнҗеш аның гомерен кыскарткандыр? Төрле гоманнар кормыйча, кире чыкмас фаразлар урманына кермичә генә, бөтен җавапларны Рәшит Әхмәтҗанның олы иҗатыннан, сихри-серле шигырьләреннән эзләргә кирәктер.

...Татар шигърияте көрәшче, каһарман шагыйрьләр иҗатыннан тәшкил.

Рәшит Әхмәтҗан исә – шигырьләре белән дә, азатлык өчен ачык көрәштә дә шәхси үрнәк күрсәткән милли каһарманыбыздыр!

Олуг куәгә ия булып та, дөньяда тиешлесен үз вакытында алалмыйча вафат иткән шагыйрьләрне, сәнгатьчеләрне Илаһ изге көрәштә – Җиһад сугышта – Газаватта һәлак булган шәһитләр кеби, турыдан-туры үз хозурына кабул итә торгандыр, мотлак. Алар, бу шәхесләр, көнем өчен дип түгел, денем өчен дип яши, иҗат итә һәм фани дөньядан дарелбәкага – мәңгелек йортка күчә.

Гүрең нур булсын, урыныңны Җәннәттән әйләсен, Рәшит кардәш!

Бу мәкалә-мәрсия Корбан бәйрәменә каршы таңда язылды. Акчарлаклар тәрәз каршыннан очып-очып уза... Шулар мәҗбүр итте мине кинәт каләмгә тотынырга.

...Акчарлаклар Рәшит Әхмәтҗан тавышы илә кычкырдылар...

*«Казан утлары» журналы.– 1996. – № 1*

# Күрик әле әйбәт китапларны!

Мансур Вәли-Барҗылы

Барыбыз да күреп-белеп тора: бүгенге әдәбиятыбызның хәле кызыклы да, кызганыч та, чөнки, бер яктан, хәзер әдәбиятта сурәтләнгән тормыш бик тә киңәйде, төрлеләнде. Безнең татар укучысы да хәзер, бүтән иректе ил кешеләре кебек, үз күңеле теләгән, төрле темаларга язылган әдәби әсәрләрне табып укый ала. Әмма, икенче яктан, хәзер эчтәлек бик тә саекты, сыйфат ягы үтә аксый башлады... Монысын демократия чоры билгесе дип санаучылар да бар. Кайчак алар белән дә килешергә туры килә, чөнки соңгы елларда күренгән бер төр авторлар тел матурлыгы һәм сурәтләү чаралары ягыннан әллә ни мактана алмасалар да, үз әсәрләре белән әдәбиятка кызыклы гына геройлар алып килде, яңа актуаль проблемалар күтәрде. Аларның үз укучылары булуы билгеле, яклаучылары да күренеп тора.

Әлбәттә, төрле зәвыктагы укучының үзе теләгән китапны укырга, һичшиксез, хакы бар. Без аңа андый мөмкинлекне, шундый шартны тудырырга, рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерергә тиеш. Ләкин әйбәтлеге беркемдә дә шик-шөбһә тудырмаган китаплар да басыла тора бит әле, егетләр!

Менә күптән түгел генә кулыма шундый китапларның берсе килеп керде. Исеме генә дә ни тора — «Ак вә кара»!

Без мәңгегә, без мәңгегә монда.
Эх, бу җирне күпме таптады
Безнең йөрәк бәйрәмнәребезнең
Кыңгыраулар таккан атлары!

Гаять тә зур талантка ия булып та, мактаулы исемнәр һәм дан-дәрәҗә артыннан чапмаган, бик иртә үлеп киткән олы шагыйребез Рәшит Әхмәтҗанның «Бәйрәм» исемле шигыреннән бу.

Шигырьдәге рухи көч, эчке азатлык, эчке горурлык ташкынына игътибар итегез. Әсәрнең иң тәүге, иң беренче юлына ук кайнар вулкан сыман, ялкын шикелле бәреп чыга ул көчле пафос, ул титаник хис-кичереш! Ә инде татар күңеле турында ничек төгәл һәм матур итеп әйтелгән: «Безнең йөрәк бәйрәмнәребезнең...» Бер яктан, монда коллык хәлендәге халыкның бәйрәме күздә тотыла, эчтән генә, тышка чыгармыйча, чит-ятка белдермичә генә уздырыла торган бәйрәм... Ә инде икенче мәгънәсе: бу — чын бәйрәм, бөтен җаның-тәнең, бөтен йөрәгең белән тантана итеп, ихластан шатланып, горурланып үткәрелә торган бәйрәм! Көчле талант иясенең бер әсәрендә әнә шундый мәгънә катламнары — һәр икесе дә дөрес һәм гадел булган фикерләр — бергә үрелеп, бер шигъри тән, бер җан булып яши.

Мондый шигърият үрнәкләре безнең татар халкының күңел түренә шундук үтә. Андый чын әсәрләр язмыш юлларын аның белән бергә уза...

*«Ватаным Татарстан» газетасы.— 2000. — 28 гыйнвар*

# Шагыйрь артист

Гөлзадә Бәйрәмова

Йөрәгеңне жуя күрмә,
Әллә кая куя күрмә.
Сыйдырсын ул Туган илне,
Җырлап йөр син «Әллүки»не,
Онытсаң да, энем, мине,
Онытма син Туган илне!
*Рәшит Әхмәтҗанов. «Энем Илдуска»*

Шигърият һәм сәхнә. Шагыйрь һәм артист. Бу төшенчәләр бер-берсе белән янәшә торсалар да, һәрбер артист нәфис сүз остасы була алмаган кебек, һәрбер нәфис сүз остасы да артист була алмый. Шушы ике биеклеккә чын сәнгати дәрәҗәдә бердәй ирешә алучы зур талант ияләре — элгәррәкләрдән Хәким ага Сәлимҗанов, Габдулла ага Шамуковлар булса, бүгенгеләрдән, мөгаен, Илдус Әхмәтҗановтыр...

Артист, сәхнәдә уйнау дәверендә йөзләгән рольләр башкарса да, гадәттә, халык күңелендә бер-ике роле белән кала. Әйтик, Шәүкәт Биктимеров — Әлмәндәр карт, Ринат Таҗетдинов — Мәхдүм, Равил Шәрәфиев исә Әҗәл буларактыр... Ш. Хөсәеновның «Әни килде» әсәрендәге Ана образы безгә Галимә Ибраһимова уйнавы белән кадерле. Исламия Мәхмүтова И. Юзеевның «Кыр казлары артыннан» спектаклендәге Ясминә булып...

Юк, бу аларның башка рольләрне начар уйнап, монысын гына яхшы уйнадылар, дип әйтү түгел, хикмәт — күңелгә якын булган, күздән яшь китерерлек, аның уй-кичерешләрен үзеңнеке итеп кабул итеп, син әйтәсе килгән сүзләрне аның аша ишетеп, мәңге истә калырлык образ тудыра алуларындадыр. Илдус Әхмәтҗанов, дисәк, безнең күз алдына иң беренче Тукай образы килә.

Тарихи шәхесләрне уйнау — күп артистларның хыялы. Әмма теләк бер нәрсә, мөмкинлек — икенче. Йөз-кыяфәтнең дә азмы-күпме охшаган булуы, образны тулырак гәүдәләндерү өчен эчке дөньяның да, күңелеңнең дә әлеге зат белән күпмедер дәрәҗәдә тәңгәл килүе кирәк.

Тукай ролен ул беренче тапкыр 1976 елда режиссёр Әхтәм Зарипов куелышындагы «Яз сулышы» исемле телевизион спектакльдә башкара. Күренекле режиссёр Ә. Зарипов Илдус Әхмәтҗановны талантлы артист булуы белән бергә кеше буларак та югары бәһали:

«Илдус тудырган образларның характерлары, холкы бар. Ул, образны ачканда, эшне персонажның үзенчәлеген табудан, холык-фигылен ачыклаудан башлый. Бу — бары тик чын профессиональ артистларга гына хас сыйфат. Иң күркәм сыйфатларының тагын берсе — аның тумыштан интеллигент булуыдыр. Чын зыялы, затлы кеше ул! Эш белән онытылып киткән чакларда да ул үз дәрәҗәсен һәм үз урынын онытмый, һәркемгә шәхес итеп карый. Аңа вельможа да, бомж да — кеше. Хаксызга рәнҗетсәләр — авыр кичерә, озак терелә. Вәгъдәле, иманлы кеше».

Икенче тапкыр ул Тукай булып 1986 елда Туфан Миңнуллинның «Без китәбез, сез каласыз» спектаклендә уйный. Тукаебыз аның башкаруында горур, мәһабәт, эчке җегәре ташып торган зыялы зат булып гәүдәләнә. Бу спектакльдән соң хәтта аның үзенә дә Тукай дип эндәшә башлаучылар була. Ходай Тәгалә, әйтерсең лә Тукайны иртә алганына үкенеп, аның урынына, аның эшен, фикерләрен халыкка җиткерергә Илдус Әхмәтҗановны җибәргән. Тукайның 100 еллык

бәйрәменә килгән Мостай Кәрим, спектакльне карагач: «Тукай ролен башкаручы Илдус Әхмәтҗанов яхшы уйный, Тукай – тормышчан, ышандыра. Артист шагыйрь образын әдәпле итеп, югары культура күрсәтеп башкарды. Мин тере Тукайны күрдем»,– ди.


**Илдус Әхмәтҗанов. 1970**

Татар әдәбиятында, сәнгатендә бер нәселдән чыккан аталы-уллы яки абыйлы-энеле талантлы шәхесләр бик күп. Бертуган Садри һәм Әхмәтһади Максудилар, Галимҗан Нигъмәти, Нәкый Исәнбәт, Фатих Әмирханнар нәселе, Нил һәм Илдар Юзеевлар, Гали һәм Яхъя Халитлар, Фәрит һәм Мирсәет Яруллиннар, Хөснул һәм Аллаһияр Вәлиуллиннар, Рәшит һәм Илдус Әхмәтҗановлар...

Үзе турында артык ачылып сөйләргә яратмый артист. «Соң мин бит болай да бөтенләем белән сезнең каршыда, сәхнәдә бөтен җаным белән ачылам бит инде»,– дип әйтүеме, зыялы кешеләргә хас булган тыйнаклыкмы, үзем өчен серле булган бу шәхес турында тагын да күбрәк беләсе килү мине берничә ел бергә эшләгән олуг шагыйрь Рәшит Әхмәтҗановның хатыны – заманында Илдус Әхмәтҗановның укытучысы булган Луиза ханымга илтте.

– Ул нәселгә хас иң төп сыйфат нинди? – дип соравыма Луиза ханым:

– Горурлык! – дип җавап бирде.– Һәм барысы да гаҗәеп сабыр, сүзгә осталар. Аларның фикерле итеп сөйли белүләренә шакката идем. Рәшит, әтисенә охшап, уенчак, җор күңелле булса, Илдус, киресенчә, әнисенә охшап сабыр, басынкы. Аның кечкенәдән үк үз эчке дөньясы бар иде. Кемнәрдер өчен, бәлки, ул сәер, үз эченә бикләнгән малай булып күренә торган булгандыр. Искиткеч кешелекле, ярдәмчелләр алар.

...Хатирәләр, хатирәләр... Бергә эшләгән елларда профкомга кәгазьләр тутырырга туры килгәндә: «Ничә яшьтән эшли башладың, Рәшит абый?» – дип сорагач: «Биш яшьтән, багырьләрем, миңа тормыш нужасын биш яшьтән тарта башларга туры килде»,– дигәч, без аны, уенчак күңелле кеше буларак, шаяртадыр, дип уйлый идек, ләкин, әтиләре иртә үлү сәбәпле, ишле бала белән тол калган әниләренә балалар үзләре ярдәм итмичә, кем итсен соң?!

...И ул үсмер чакның татлы йокылары! Саҗидә апа, акрын гына басып, нарасый Илдусны көтүгә уятырга дип янына килә... Илдус әнисе эндәшкәнче үк инде вакыт җиткәнен тоеп ята, тиз-тиз генә капкалап ала да, чандыр иңенә чыбыркысын салып, авыл башына юнәлә, һәр җәй саен шулай, һәр көн саен шулай... Берничә елдан соң башкалабызның иң зур театрларының берсендә – Галиәсгар Камал театры сәхнәсендә – М. Фәйзинең «Ак калфак» спектаклендә көтүче Бакый ролен уйныйсы егеттән тормыш үзе шулай репетиция ясаттыргандыр, мөгаен.

Юк, ул малкайларны, ачы итеп сүгенеп, чыбыркылап кумый, инде йокы да ачылган, җәйге көн үзенекен итә – тәннәр дә язылган, аларны үз көйләренә җибәрә дә хыял диңгезләренә чума, күңелдә кичә яза башлаган шигыренең дәвамы туа башлый. «Әллә шагыйрь булырга инде?» – дип сөйләнә ул үзалдына. Әнә бит Рәшит абыйсын ничек яраталар, ул кайткач, аның белән очрашулар оештыралар, кызлар аның шигырьләрен яттан сөйли, күбесе аңа гашыйк та... Тик Рәшит абыйсы ошатырмы? Килешерме аның белән ярышу? Туганнары арада иң сабыр, тагын

да кешелеклерәк булган энекәшләрен авылда калдыру ягында, Рәшит абыйсы исә аны сәнгать дөньясына тарта, театр училищесына укырга кирәргә өнди. Нечкә күңелле шагыйрь абыйсы сизә: аның урыны — сәхнәдә.

1968 елны ул Казанга театр училищесына укырга килә. Татар әдәбиятыннан язылган иншасын укыганнан соң, комиссия членнары Хәй Вахит, Рәшидә Җиһаншиналар, сокланып: «Язучы булырга тиешле бала бит бу, әллә университетның татар теле һәм әдәбияты бүлегенә җибәрикме икән?» — дип тә уйлап куялар, тик этюдларны да оста башкарып, тиз эләктереп ала, сүзне тоя белә, артистка кирәк иң төп сыйфатлар — төз гәүдә, ачык, матур тавышлы бу егетне университетка җибәреп «әрәм» итәселәре дә килми. Әлеге курс студентлары Ленинград театр, музыка һәм кинематография институтына укырга җибәрелә. Илдус Әхмәтҗановның табигатьтән, тумыштан килгән талантына Ленинград — Петербург кебек борынгы, зыялы шәһәр, аның тарихи шәхесләре белән аралашу, мәһабәт театр залларында үзеңне шәхес итеп тоеп, башны горур тотып йөрүләр дә тәэсир итмәгәндер дип кем әйтә ала? Әле авылдан чыгып, ерак болын басуыннан, авыл клубыннан башка җир күрмәгән малай-егеткә чагыштырып карап гыйбрәт алыр, акыл туплар өчен бу зур мәктәп түгелмени? Ятим балага олы сәнгать дөньясына чыгарга мәрхәмәтле язмыш үзе юл ачып торгандыр, күрәсең...

Биш елдан драма һәм кино артисты дипломы алып кайтканнан соң, 1973 елдан Г. Камал театрында эшли башлый Илдус. Төрле дәрәҗәдәге рольләрне уйный ул. Беренче зур роле — Р. Батулланың «Өчәү юлга чыктык» спектаклендә Мирзахан. Илдус Әхмәтҗановның характерына капма-каршы роль. Ләкин аның яшенә, бүгенге халәтенә туры килә. Ул да бит, Мирзахан кебек, институт тәмамлап яңа гына эшкә кайтты. Димәк, аның уй-кичерешләре, хыяллары синеке дә... Тик ул «тискәре» герой. Әдәбиятта «уңай һәм тискәре» геройлар, «социалистик реализм» методы чәчәк аткан чорлар. Тамашачы, гадәттә, «уңай» герой яклы. Һәм менә шул «тискәре» образ аша тамашачы мәхәббәтен, аның ышанычын яулыйсы бар. Спектакль тәмамланып, зал алкышларга күмелгәч, үзенә әйтелгән котлау сүзләрен ишеткәч кенә җиңел сулап куя яшь артист.

Икенче роль — Г. Боровикның «Канлы күләгәләр»ендә Педро роле. Бу рольне уңышлы башкарганы өчен, аңа республика иҗат яшьләре конкурсының лауреаты исеме бирелә.

Театр тормышына чын-чынлап кереп, инде ныклап уйный башлыйм дигәндә генә, ир-атлар узарга тиешле тагын бер мәктәп — армия хезмәте аны да читләтеп үтми. Бу рольне аңа ерак Герман илләрендә «уйнарга» туры килә.

Илдус Әхмәтҗанов 27 еллык иҗат дәверендә кырыклап роль башкарган. Бер-берсен кабатламый торган, күпчелеге капма-каршы булган, артисттан зур осталык таләп итә торган рольләр.

Рус классикларыннан М. Горькийның «Һаваларда йолдыз»ында Алексей Пешков, А. Островскийның «Җимерелгән бәхет»ендә Дерюгин, В. Распутинның «Авылдашлар, акча кирәк» пьесасында ревизор, Ч. Айтматовның «Ахырзаман»ында Бастон (1989 елда бу роль өчен Илдус Әхмәтҗановка Муса Җәлил премиясе бирелә), татар драматургларыннан М. Фәйзинең «Асылъяр»ында Искәндәр, «Галиябану»да Бәдри, Г. Исхакыйның «Алдым-бирдем»ендә Әхмәди, Ю. Сафиуллинның «Идегәе»ндә Субра карт, Т. Миңнуллинның «Гөргөри кияүләре»ндә Гөргөри, З. Хәкимнең «Су төбендә сөйгәнем» спектаклендә Гаделша... Кызык бит: бөек Тукай һәм исерек Гаделша...

«Гөргөри кияүләре»ндә исә Илдус Әхмәтҗанов бөтенләй башка яктан, көлкеле образлар тудыра алучы артист буларак ачыла.

Гөргөри исемле керәшен карты, ата-бабалардан калган гореф-гадәтләрнең югала баруына нык борчылуын белдереп, кечкенә кызын керәшен йолалары буенча кияүгә бирергә тели. Яшь гаиләләрнең таркалуын да нәкъ менә шушы йолаларның сакланмавыннан күрә ул.

Драматик рольләрдә уйнап күнегелгән артистның комедия жанрында да югары биеклектә кала алуын күреп сөенәсең, аның талантына сокланасың. Төп герой Гөргөри тудырган шушы рух спектакльнең башыннан-ахырына кадәр сәхнәне бербөтен итеп тота ала.

Әйе, капма-каршы персонажлар... Чын профессиональ артистның көче дә, сәләте дә нәкъ менә шунда: кирәк чакта, ролең зуррак булса — зурая, кечерәк булса, кечерәя белүдә икән.




**Көрәшчеләр сафындагы Илдус Әхмәтҗанов һәм Фазыл Вәлиәхмәт. Ирек мәйданы, 1991**

– Бүгенге драматургия, театр тормышына килсәк, ул үз сүзен әйтте, үзен күрсәтте инде. Кайчандыр дәүләтчелеге булган, олуг тарихы булган халык өчен театр сәнгате белән генә чикләнеп калу бик аз. Безгә чын-чынлап кино сәнгате, татар киносы турында уйлый башларга вакыт җитте. Читтән артистлар чакырып китереп түгел! Үзебезнекеләрне дә күрә белергә генә кирәк. Бу уйлар 1997 елда Мисырда «Исә Болгар җилләре» фильмын төшергәндә дә һич башымнан чыкмады,– ди Илдус Әхмәтҗанов, чын мәгънәсендә борчылып.

Бер кешедәге шуның кадәр көчкә-җегәргә, хәтергә, итагатьлелеккә, зыялылыкка, әле тәрҗемә эше белән шөгыльләнүен дә искә алсак, белемгә хәйран каласың! Лопе де Веганың «Мәхәббәт маҗаралары»н ул шигырь белән тәрҗемә иткән. А. Островскийның «Капкан саен калҗа булмый», В. Шекспирның «Король Лир», «Антоний һәм Клеопатра», «Ромео һәм Джульетта» әсәрләре аның тәрҗемәсе аша татарча яңгыраш алган, һәм күңелендә йөргән шигъри сурәтләүләре, шигырь белән әйтәсе килгән фикерләре шушы тәрҗемәләрдә чагылыш тапкан. Әйе, Шекспирны тәрҗемә итү өчен, аны сәхнәдә татарча яңгырата алыр өчен, зур шагыйрь талантына ия булу да кирәк шул!

Илдус Әхмәтҗанов, драма артисты буларак, Тукай образын уйнап танылу алса, нәфис сүз остасы буларак та Тукай аның иҗат мирасының төп өлешен тәшкил итә. Быел Г. Тукай премиясенең аңа бирелүе дә аның Тукайлыгының рәсми төстә танылуы булып тора. Әлеге премия аңа Тукай шигырьләреннән төзелгән «Сөй гомерне, сөй халыкны» дигән театральләштерелгән программасы (1992–1996 еллар) һәм «Өзелгән өмет» (1997–2000) циклы өчен бирелде.

– Барыбыз да китап укырга яратканлыктан, өйдә китап күп иде. Инде 10–11 яшьләремдә Тукайның дүрттомлыгын укып чыккан идем. Кайсы биттә нинди шигырь, нинди аңлатмалар белән бирелгән, аларны яттан белү – инде ул вакытта ук минем яшәү рәвешемә әйләнгән иде,– ди Илдус.– Сүз дә юк, ике өлкәдә дә – драмада да, нәфис сүздә дә Тукайны иҗат итү зур белем, әйтер идем, тарихи белем, осталык, саклык таләп итә. Ялгыш кына да үзеңнең «мишәр сөйләмеңне» әйтеп җибәрергә ярамый, бүгенге чордан булган сүзләр дә керергә тиеш түгел. Гомумән, Тукай шигырьләре, татар шигърияте иҗатымның ахырына кадәр минем төп иҗат эшчәнлегем булып калыр, ахры,– ди артист.



**Илдус Әхмәтҗанов Карло Гоцциның «Болан патша» әсәрендә Тарталья ролендә**

Әйе, Илдус Әхмәтҗанов шигырьне сөйләп кенә чыкмый, хис һәм фикер берлегән бергә кушып, йөрәк һәм акыл аша уздырып, аннан образ тудыра. Тукай шигырьләрен, С. Хәкимнең «Кырыгынчы бүлмә», Р. Фәйзуллинның «Сәйдәш» поэмасын һәм башка татар шагыйрьләренең шигырьләрен тетрәнеп, бер мәлгә тын да алмыйча, онытылып тыңлыйсың. Хәзерге дөньяңнан китеп, шагыйрь тудырган, бу очракта артист тудырган дөньяда яшәп аласың.

Тукай премиясенең кырык елдан артык тарихы бар. Моннан утыз бер ел элек бу премия нәфис сүз сәнгатендә бердәнбер Айрат Арслановка бирелгән.

— Нәфис сүз остасы дигән исем — халык артисты дигән исем белән бер дәрәҗәдә булырга тиеш. Һәм Илдус Әхмәтҗанов — менә егерме җиде еллап шушы өлкәдә әйдәп баручы артист. Аның кебек чын мәгънәсендәге Нәфис сүз остасы булу өчен туган телне бөтен нечкәлекләре белән тоярга, халкыңның үткәненә һәм киләчәгенә хөрмәт белән карый белүче милләтпәрвәр булырга кирәк,— ди Айрат Арсланов.

Милләтпәрвәрлек... 1991 елның май ае. Республикабызның язмышы хәл ителгән көннәр. Шәһәр уртасындагы мәйданда түгел, су буендагы таллар күләгәсендә дә эсселеккә чыдап булмый. Бер төркем язучылар, сәясәтчеләр игълан иткән ачлыкта Илдус Әхмәтҗанов та бар. Сәясәт уенының ахыры ни белән бетәсен, нинди юнәлеш аласын кайвакыт аның башында торучы дәүләт сәясәтчеләре үзләре дә белеп бетермиләр. Ул-бу була калса, бер нәселдән ике корбан буласы... Әнә абыйсының мәйданны ярып шигырь укуы ишетелә:

Яшәргә! Яшәргә! Азатлык алмыйча
Кузгалып китү юк быелгы җәемнән.

Ике туган монда да янәшә. Һәм соңгы минутларында да...

1995 ел. 5 гыйнвар. «Архивны Илдуска бирерсең»,— ди Рәшит абый Луиза ханымга, шул арада шаян сүзләр дә әйткәләп куя, ни уйларга да белмәссең... Яңа ел вакыты бит, чыршы бәйрәмендә көне буе аю булып «уйнап» йөреп арыган булса да, иртәгә авырулар кабул итәсе табибә җиңгәсен ял иттерәсе килеп, абыйсы янында үзе генә утырып кала. Сәгать төнге ике. Тыныч кына яткан абыйсы кулларын алга сузып талпынып ала, һәм шул минутта ике туганның күзләре очраша. «Утны сүндер!» — ди абыйсы кинәт кенә. Ут ничек тиз сүнсә, шулай ук тиз генә кабына да. Абыйсы мәңгелек йокыга талган... Нинди генә югары дәрәҗәләргә ирешсәк тә, туганнар өчен барыбер «абый-апа», «эне-сеңел» булып калабыз шул. Мөгаен, Рәшит абыйсы да шигъри күңелле энесен куркытасы килмәгәндер, бәлки...

Табигать бушлыкны яратмый. Бүгенге буынга Тукайлар рухын Илдус Әхмәтҗанов кебек талантлы улларыбыз җиткерсә, киләчәккә, бәлки, «Каргышлы балачак» телефильмында инде Тукайның Уральскига китүгә хәтле чорын сурәтләп күрсәткән улы Рөстәм илтер? Һәрхәлдә, моңа җирлек бар. Тукай белән янәшә күмелгән шагыйрь Рәшит абыйсы да, Татарстанның халык артисты, Муса Җәлил һәм Тукай премияләре лауреаты — әтисе Илдус Әхмәтҗанов та, Тукай үзе дә, талантлы уллар тудыра белүче татар халкы да моңа шат булыр иде. Иншалла, шулай булсын! Буыннар чылбыры өзелмәсен иде!

*«Казан утлары» журналы.— 2000. — № 6*

# «Сагындырып искә төшәләр дә...»[1]

Җәүдәт Дәрзаман

...Без яшь иҗат көчләренең шигырьләрен туплаган «Җырчы чишмә» китапчыгында бергәләп чыккан идек. Бүген татар шигъриятендә ат уйнаткан күп кенә каләмдәшләребез белән бергә инде, әлбәттә.

Рәшит абый имтиханнарны, армиядән кайтуга, солдат киемнәреннән биреп йөрде. Аралашырга җайлы, ипле кеше иде. Кайчакларда тулай торагыбыз янынннан гына узучы тимер юл буена чыгып китәбез. Ул шунда ипләп кенә, тыныч кына үзенең шигырьләрен сөйли башлый. Мин, аны тыңлаган саен, гаҗәпләнгәннән-гаҗәпләнә генә барам. Камиллекләре белән таң калдырырлык, моңнары мәңгегә хәтереңдә уелып калырлык шигырьләр иде алар.

Аннан соң әле без бөтен группабыз белән Мостафа ага Ногман җитәкчелегендә Ютазы районына бәрәңге алышырга бардык. Анда да Рәшит абый һәрвакытта группабызның җаны булды.

[1] «Сагындырып искә төшәләр дә...» циклыннан күренекле шагыйрь Рәшит Әхмәтҗановның якты истәлегенә багышланган радиотапшырудан өзек. Язманы кәгазьгә Сания Фәйзерахманова күчерде.



**Кандыз буенда. Сулдан уңга: Рәшит Әхмәтҗанов, ?, Мәгъсүм Латыйфуллин**

Аның янында уен-көлке һичкайчан да тынып тормый иде. Колхоздан кайтсак, армиягә повестка көтеп тора. Шулай итеп, мине шампан шәраблары белән озатканда да әле хәрби киемнәрен салырга өлгермәгән Рәшит абыйлар урынына без өч егетне, 45 елгыларны, армия хезмәтенә алып киттеләр. Кыскасы, гыйлем кыяларын Рәшит абыйлар белән кимерү насыйп булмады.

Бөтен иҗаты моң белән тулы булса да, миңа аның тормыштан зарланганын ишетергә туры килмәде. Югыйсә җиңел булмаган бит аның тормышы ...Баулы районы Татар Кандызы авылында колхозчы гаиләсендә туган малай, авыл мәктәбендә 7 нче классны тәмамлаганнан соң ук, Бөгелмәдә төзүчеләр хәзерләү училищесында укый. Аны тәмамлагач, нефть районнарында һәм Әлмәт шәһәрендә ташчы булып эшли. Шул чорларда ук якташ каләмдәше Шамил Бикчурин белән тыгыз элемтәдә яши башлый. Аннан соң армия хезмәте, университетта студент еллары... Укуны тәмамлагач, 1980 елларга кадәр Татарстан Мәдәният министрлыгында инспектор. Соңрак – «Яшь ленинчы», «Татарстан яшьләре» газеталары. 1980 елдан гомеренең соңгы көннәренә кадәр «Казан утлары»ның хатлар бүлеге хезмәткәре.

Рәшит абый Әхмәтҗанов шигърияттә ниндидер яңа формалар эзләп мөгез чыгарырга азапланмады. Замандашы Равил Фәйзуллин кебек, яшьлегендә ручкаларга яфрак ярдырмады, күзләрне идән ярыгына тәгәрәтеп төшермәде.

Борынгыдан килгән классик шигърият үрнәкләрендә әкрен генә, җай гына, әмма үзенә генә хас бер үҗәтлек белән иҗат энҗеләрен барлавын белде. Нәтиҗәдә әдәбиятыбызның Х. Туфан, С. Хәким, Г. Хуҗиев кебек олпат шәхесләре аның иҗатына бик тиз игътибар итте, зур бәя бирде. Рәшит абый, чыннан да, тормыш-көнкүрешнең гади генә бер күренешеннән, сайрар кошның гади генә бер канат талпынуыннан да олы бер фәлсәфи мәгънә чыгара белә иде.

Бүген кинәт күк күкрәде,
Ниләр яуды, кая акты?
Яшь имәнне яшен сукты –
Карт алмагач чәчәк атты.

Уйлап карасаң, әйтик шушы дүртьюллыкка өстәп, тормышның хикмәтләре турында ниләр әйтеп була? Хәер алай дип тә кистереп куярга ярамый икән әле. Рәшит абый әйткән «Ут инде сүнде дисәм...» шигырендә:

Аста – ут.
Утлар өстенә
Яңгырлар бәреп яуды.
Җирдәге ут – җандагы ут, –
Янды да һаман янды.

Яңгырлар яуды да яуды,
Ут инде сүнде дисәм...
Дөньяның күле дә ташмый,
Һәм чүлләре дә исән.

Күлләрдә балалы казлар –
Бөтенесе дә аклар.
Каңгылдап йөри чүлләрдә
Моңаеп дуадаклар.

Чыланган килеш торам мин,
Кузгалып китә алмыйм.
Дөнья, бер җебең өзек ич,
Кайда ул, ничек ялгыйм?

...Яңгырлар ява да ява.
Ут инде сүнде дисәм, –
Дөньяның күле дә ташмый,
Һәм чүлләре дә исән.

Алыйк аның «Бу агымнар» дигән тагын бер шигырен:

Бу агымнар
Җирдә таралырга,
Юл табарга безне өйрәтте.
Бездән алда ага кайларгадыр
Кешеләрнең кайгы-хәсрәте.

Рәхмәт әйтик шушы агымнарга,—
Җиңеләя кеше хәлләре.
Ләкин нәфрәтемнең тик беразын
Кире миңа бирсеннәр әле.

Җирдә җиңелмәгән шул нәфрәтем
Мәхәббәтем белән кушылсын.
Кушылсыннар... Һәм йөрәгем бүген
Алар кебек бер җыр тудырсын.

Кешеләргә сәфәр җыры булсын,
Бишек җыры булсын балага,
Шифа булсын илен сөйгәннәрнең
Тәнендәге яңа ярага.

...Нәфрәт, сөю, шатлыкларның бүген
Җанда күкрәп торган мәлләре.
Дөнья, кеше сине сөеп үлә,—
Йә, җиңелме кеше хәлләре?!

Әйе, җиңел түгелдер бу дөньяда үзе дөрләп янган кешегә. Әмма яну белән януның да аермасы бар икән бит әле. «Күбәләк кенә булсак» дигән шигырь:


Учак ягу — бу дөньяны
Җылыту түгел әле.
Кул җылына,
Ут күзендә
Яна төн күбәләге.

Һәлак була да күбәләк —
Ялкынсыз кала учак...
Юк,
Кояш кирәк тә түгел,
Күбәләк кенә булсак.

*P. S.* Алга таба Рәшит Әхмәтҗановның үзе укуында язмалар тыңлана. Яшь, матур, бәрхет кебек йомшак тавышы белән «Миңа кил», «Бар иде, бүген кайда соң?» шигырьләрен сөйли. Халкыбызның яраткан җырчысы Р. Ибраһимова Р. Әхмәтҗанов шигыренә «Бергәләп җырлыйк (Әнкәм теле)» исемле җырны башкара.— *Төз.*

Ә хәзер мин, хөрмәтле радиотыңлаучылар, сүзне Рәшит абыйның байтак еллар бергә иңгә-иң торып эшләгән, иҗат иткән, димәк, аны шактый якыннан белгән каләмдәше, иҗатының беренче адымнарыннан ук шигърияткә заманча ачкыч эзләгән, бүген инде Татарстанның халык шагыйре, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире Равил Фәйзуллинга бирмәкче булам.

— Равил әфәнде, әгәр кулыгызга киндер белән рәссам пумаласы бирелсә, Рәшит Әхмәтҗановны сез нindirәк буяулар белән тасвирлар идегез икән?




*— Минем кулымда буяулар юк, киндер дә юк каршыда, мин — сүз белән эш итә торган кеше, аның образын, шәхесен шуңа күрә сүз белән тасвирлап карыйм. Бу очракта инде, әлбәттә, хатирәләргә бирелми булмастыр...*

*1989 ел иде. Рәшит Әхмәтҗановның исеме шактый яңгыраса да, аның кулында калын китабы юк иде әле ул вакытта. Ә китап чыгарасы бик килә, сүз дә юк. Өстәвенә — 50 яшь. Шул хыял белән йөрде ул вакытта. Менә сез «Шигырь китапханәсе» сериясен беләсез. Андый китап чыгару шагыйрьләр өчен зур дәрәҗә иде. Әлбәттә, Рәшитнең дә андый теләге, хыялы бар иде. Һәм ул аны нәшриятка кульязма рәвешендә китереп тә биргән иде. Китап чыгу мәсьәләсе нәшриятта тәгаенләнгәч, ул миңа шушы томлыкка кереш сүз язуымны үтенде. Хәзер уйлап куям менә. Озак көтелгән кадерле китабына баш сүз язуны нигә миннән сораган икән? Юкса холык-фигыль белән дә, язу стиле ягыннан да шактый аерылабыз. Аннан соң мин ул вакытта ирекле иҗат кешесе, профессиональлыкта, түрә-мазар да түгел кебек,*

*дәрәҗәле пост та биләмим. Дөрес, элек тә бәяләмәләр язганым бар иде. Бәлки, шуларны истә тотып та үзенең төп китабына баш сүз язуны үтенеп, миңа мөрәҗәгать иткәндер. Ризалык бирелде. Вәгъдә — иман дигәндәй, дүрт-биш битлек мәкалә язылды. Һәм ул бер ел үткәч, аның 50 еллыгына, 1991 елда «Моңлану» исемле сайланма әсәрләр китабында «Күңел һәм җан сәфәре» исеме белән кереш сүз булып басылып та чыкты. Ошаткандыр дип уйлыйм инде. Бүләк иткән китабына «Равил, безнең гомерләр шулай узды инде... Безнең бергә яшәүгә мин бер генә караңгылык та төшермәдем. Рәхмәт сиңа! Рәшит Әхмәтҗанов. 6 май, 1991 ел» дип язып биргән иде. Бу хәлләрдән соң 10 ел гомер үткән. Менә хәзер шул китаптан кайбер җөмләләрне укып китәм:*

*«Рәшит Әхмәтҗановның шагыйрь һәм дә зур шагыйрь икәнен кешеләргә раслыйсы юк. Әмма аның шигъриятенең үзенчәлеген, нечкәлекләрен үзебезгә аңлыйсы, күпләребезгә төшендерәсе бар әле. Өч дистә елга якын ул шактый ук актив эшләп килсә дә, иҗаты турында әдәби җәмәгатьчелекнең төпле фикерен соңгы биш-алты ел эчендә генә ишетә башлады шикелле. Бу хәлнең сәбәпләре нидә? Бәлки, тәнкыйтьчеләрнең исемлек кысасына керә алмый калуындадыр? Бәлки, иҗатчының артык үзенчәлекле булуындадыр? Яшермим, Рәшит Әхмәтҗанов дигән шагыйрь минем үзем өчен дә шактый ук «каты чикләвек» булып чыкты. Налим балыгы шикелле шома (яхшы мәгънәдә), тиз генә тоттырмый... аның шигъриятен «саңагыннан» әләктереп булмый... Шигырьләре техник яктан, Хәсән Сарьян «юнган агач» шикелле, бик нечкә зәвык белән эшләнгән; өстәвенә образ, чагыштырулар, эпитетлар һ.б. калфак чигешендәге энҗеләр шикелле бик мул сибелгән. Шагыйрьлекне аерым юл — строфалардан да тоеп була.*

*Муеныма аскан ташың — тау иде,*
*Мине тирән су төбенә салды ул.*
*Бүләк алып чыктым әле мин сиңа:*
*Сине сөйгәч — энҗе булып калды ул.*

*Рәшит Әхмәтҗанов — чын мәгънәсендә татар милли шигъриятенең төп, дөрес юлында торучы шагыйребез. Ул — Р. Харис та түгел, Г. Рәхим яки Р. Мингалимов та түгел. Ихтимал, аны күпмедер дәрәҗәдә М. Әгъләмов белән параллель куеп буладыр. Аларның төп эчкән чишмәләре — халык иҗаты, татар халкының эстетик традицияләре... Беренче карашка гади күренгән шигъри сүз — берәмлекләр — шагыйрь күңелендә үзгәртелеп, яңа төсмерләр ала, образ-фикергә әйләнә:*

*Урман эчләрендә урман шаулый.*
*Урын тапмый болан үзенә.*
*И болан...*
*Йә сугарлар балам күзенә, дип,*
*Яфрак сибеп йөри эзенә,*

*Ачык аланнарда төлке уйный,*
*Урманнарга кача яшь болан.*
*Кил, болан...*
*Урманнардан берни урламаган*
*Соңгы җан иясе — мин булам.*

— Равил әфәнде, бик матур мисаллар... Шигъриятебезгә менә бүгенге көннәрдә Рәшит Әхмәтҗанов кебек яшь шагыйрьләребез, аның традицияләрен дәвам итүче шагыйрьләребез килер микән?

— Монда әгәр дә, ягъни мәсәлән, Рәшит Әхмәтҗанов кебек кенә түгел, әле Рәшит Әхмәтҗановка охшамаган яисә бүтән шагыйрьләргә охшамаган яшь, талантлы шагыйрьләр килсә дә риза булыр идек инде. Кызганыч, безнең бүгенге яшьләребезнең күбесе халык иҗаты белән җенләнеп үсмәгәнгә, шагыйрь күңеле тудырган гаҗәеп бай һәм тылсымлы дөньяны тиешенчә тоеп, эстетик ләззәт ала алмый.

— Равил әфәнде, сез Рәшит Әхмәтҗанов белән шактый еллар бергә янәшә эшләдегез. Без аны сүз башыбызда да әйттек. Кеше буларак, гади иптәш буларак, ул сезнең хәтердә ничек саклана.

— *Рәшитнең фанилыктан бакый дөньяга күчүенә дә җиде ел вакыт үтеп китте. Хәтер офыгыннан китеп, онытылу рәшәсендә эреп югалыр өчен дә ярыйсы гына вакыт. Юк, бу шәхес, Рәшит Әхмәтҗанов, онытыла торганнардан түгел. Еш искә төшә, юксындыра. Бездә кайчак киткән затлар турында, тәүбәгә килгәндәй булып, ярым рия, ярым риясыз сөйләүчеләр табыла. Янәсе, вакытында кадерен белмәдек, бәяләмәдек. Дөресрәге, алар кадерен белмәделәр, бәяләмәделәр, диләр. Вакытында исем бирелмәде, премия алынмады. Монда гадел булырга кирәк. Гадәттә, андый соңарып гаделлек*

*урнаштыручылар бу очракта «хокуклы» булмый. Һәр очракта фактның үз вакыты, үз сәбәбе, үз чишелеше. Тормыш логик юрауларга караганда күпкә катлаулырак. Әйе, чыннан да, соңарулар булгалый. Әлбәттә, Рәшит Әхмәтҗанов Тукай премиясе ала алган булыр иде. Шулай да премияләрдән, мактаулы исемнәрдән фитиш ясарга ярамый. Тарихта вакытта кристаллашкан исем генә кала. Тукай премиясез, Такташ, Җәлил... бернинди исемсез Рәшит Әхмәтҗановның иҗаты да кайбер исемле лауреатларныкыннан бер дә ким түгел, хәтта өстенрәк тә әле.*

*Рәшит белән унбиш еллап бергә эшләдек, мәрхүменә хәтле ул, бөтен кешеләргә хас булганча, оригинал холыклы иде. Фәрештә генә иде дип әйтә алмыйм аның турында, кирәк чакта ул бик уйчан, кайчакта юаш та күренергә мөмкин иде. Кайчакта карыйсың, бик кыю һәм усал, кирәк чакта сабыйларча хәйләкәр, беркатлы, дивана булып та уйнарга мөмкин иде. Күрәсең, ул нәселдә артистлык сәләте дә бар. Илдус Әхмәтҗанов. Ул бер нәселдә, туганнар арасында... һәм ул оеткы Рәшит Әхмәтҗановта да бар иде. Һәм ул төрле образларга керә ала иде. Ләкин башкалардан аермасы нәрсәдә иде, дисәләр, нечкәлек иде. Һәрнәрсәдә нечкә кала иде. Шигърияттә дә, тормышта да һәм мәхәббәттә дә дип уйлыйм. Җор, мәзәк сүзле дә, урыс әйтә бит «тонкий» дип. Аннары, бер карасаң, шундый кешенең... 1991 елларны Ачлык мәйданында әллә нинди олпат баһадир кебек ир-атлар аның урынында була алмадылар бит. Юкка гына бит безнең Рәшит абзый, шунда чыгып, халыкның азатлыгы өчен, халыкның идеаллары өчен көрәшчеләр сафына басмады! Шуңа күрә ул бик төрле гаммаларга: хис ягыннан да һәм холкы, характеры ягыннан да шактый катлаулы һәм зур, бай шәхес иде.*

– Рәхмәт, Равил әфәнде!

Сезнең сүзгә куәт булсын. Хәзер без радиотыңлаучыларыбыз игътибарына Рәшит Әхмәтҗановның «Ачлык мәйданы» китабыннан берничә шигырь тәкъдим итик. Аларны шагыйрьнең бертуган энесе – Татарстанның халык артисты, Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Илдус Әхмәтҗанов укый:

Дүрт йөз елга чигенәм дә йөрим һаман да
Күккә хәтле күтәрелеп янган Казанда.
Кабан күле – казан. Инде казан кайнаган,
Халык канга баткан, әле хәлдән таймаган.
Кыргый Урда белән әле Казан көрәшә –
Ата-ана, улы-кызы баскан янәшә,
Казанның күге җирдәге каннан кызара,
Әүлиялар сөйләшәләр күктә үзара:
Күр, Казанны каплап алган кяфер башлары,–
Тауларыннан нигә яумый икән ташлары?
Күгеннән ник каргыш яумый – нәҗес, яманга,
Карлыгачлар һәм тургайлар каргамаганга!
Имән урманы «авам» дип шауламаганга,
Таудагы кылганнар дөрләп яналмаганга,
Дошман басуга, таулары ярылмаганга...
Һәрбер түмгәгенә дошман абынмаганга...
Чокырларың дошманнарны нигә йотмады,
Яна дөрләп, яна көйрәп Казан йортлары.
Җайдагыннан инде күпме атлар ычкынган.
Янган утта кешни-кешни алар кычкырган.
Идел, нигә сыңар тамчы каның тамуга
Әйләнмәде дошман өчен кара агуга?!
Каеннарың ник дошманга каралмадылар,
Карагайлар сөңге булып кадалмадылар?
Аең нигә аермады берсеннән берсен.
Ник кояшың баемады – адашып үлсен!
Кайттым, кайттым канга батып бүгенге көнгә,
Мең кабат артып нәфрәтем җирдә үлемгә.
Кемнәрдә гаеп әле соң, кемнәрдә гаеп? –
Соңгы агачың утыра кочагын җәеп.
Кочагында исән калган соңгы умарта.
Кортлары бер очып китә, әйләнеп кайта.
Татарның иле шул инде – дошманнан калган,
Могҗизалар белән аны Алла коткарган.
Кагыла күрмә син аңа, үрчеп яңарсын,
Кагыла күрмә син аңа – үлем табарсың.
Балы гына түгел, аның агуы да бар,
Гасырлар буе җыелган... Кагылма! Чагар!

– Хөрмәтле радиотыңлаучылар! Сез «Сагындырып искә төшәләр дә...» циклыннан күренекле шагыйрь Рәшит Әхмәтҗановның якты истәлегенә багышланган тапшыру тыңладыгыз. Аны шагыйрьнең каләмдәше Җәүдәт Дәрзаман әзерләде һәм алып барды. Тапшыруда Татарстанның халык шагыйре, Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Равил Фәйзуллин катнашты. Шигырьләрне Татарстанның халык артисты, Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Илдус Әхмәтҗанов укыды...

*2001, апрель*

# Сагыну (хатирә)

Әдип Маликов

Архивымда Рәшит Әхмәтҗановның егермедән артык хаты саклана. Өчпочмаклы штамп сугылган йолдызлы хатлар. Шуларны кузгата башлауга, йөрәгем әллә нишләп куйды. Бар иде бит минем дә маркасыз хатлар юллаган солдат чакларым. Менә Рәшитнең беренче хаты:

*«Әдип абый, Саҗидә апа, балалар!*

*Барыгызга да сагынып күп сәлам. Мин 3 ноябрьдә Куйбышев шәһәрендә хезмәт итә башладым. Хәрби киемнәр киеп көзгедән караган идем, шактый олыгаеп киткәнлегем күренде, мыек кына җитми. Язучыларга, Әлмәт әдәбият берләшмәсенә сәламнәремне юллыйм. Барысы өчен дә кат-кат рәхмәт! Хат көтәм. Кабат сәлам белән, Рәшит.*

*1961, 4 ноябрь. Куйбышев шәһәре»*.



**Саҗидә Сөләйманова**



**Әдип Маликов**

Ноябрь ахырында язган җавап хатында шундый юллар:

*«Хатыгызны, «Совет әдәбияты» журналын алып бик шатландым, рәхмәт... «Тальян моңы»-ның җиңеп чыгуы бик тә күңелле вакыйга (сүз Ш. Бикчуринның музыкаль комедиясе турында), күрә генә алмадым үзен. Саҗидә апаның яңа шигырьләрен укыйсы килә. Алдагылары күңелгә бик ошагач, яңа көйнең дәвамын тыңларга кем генә теләмәс икән...»*

Рәшит Әлмәттәге яңалыклар, бигрәк тә мондагы әдәби хәрәкәт белән нык кызыксына иде.

Шигырьләр җыентыгын төзергә киңәш итеп язган хатыма каршы Рәшит «иртәрәк булмас микән?» дигән шик белдерде башта. Аннары бу изге эш белән үзе үк мавыгып китте.

Рәшит Әхмәтҗанов белән беренче танышлык ничек башланды соң? «Тамчы» поэмасын язар алдыннан мин Рәшит Саттаров җитәкләгән төзүчеләр бригадасына киләп сала башладым. Коллективлары белән дуслаштым. Бер баруымда күрәм — яшь егет пәйда булган бригадада. Саттаров мине бер читкәрәк дәшеп алды да әйтә куйды: «Уйчан, аз сүзле сабый. Адашлар булып чыктык...»

Кайбер серләрен дә белеп алган Рәшит абый. Шигырь белән мавыга икән бит адашы. Бер шигырен аңа сөйләп тә күрсәткән. Оста ике юлын отып та калган:

Таш күтәреп тала буыннарым,
Ташлардан ук үзем көч алам...

— Карале, нәкъ минемчә бит бу! — дип шатланып куйган ул вакытта Саттаров.— Гомер буе шулай уйлап йөрдем.

Мин читтән генә күз салдым егеткә: кыйгачрак кашлар, моңсу күзләр, киң маңгай. Ә чәчләре ике яклап бераз эчкә кергән. Янына барып, кул бирдем яшь Рәшиткә. Ул кинәт кызарынып әйтә куйды:



**Кандыз авылы**

— Мин Сезне беләм ич, Әдип абый, журналдан укып барам...

— Бик әйбәт, рәхмәт,— дидем,— адаш абыең кебек якын булыйк.

Егет, бераз аска карап торганнан соң, кыюсыз гына әйтә куйды:

— Мин әле бик бәләкәй кеше бит...

Саттаров, шундук аның сүзләрен элдереп:

— Син бит төзүче! — диде. Үзе, миңа күз кысып: — Менә Әдип абыегыз булдыралмый андыйны,— дип өстәде.

Югалып калмадым:

— Без дә бит заманында казармалар, землянкалар төзедек,— дигән булдым,— әле ничек кенә: юан-юан тайга агачларын җилкәләребезгә салып чыгара идек.

...Рәшит Әхмәтҗановның үз планнары бар икән: кичке мәктәпкә укырга керү һәм әдәби берләшмә утырышларына йөрү. Соңгысы турында ул Бөгелмәдә төзүчеләр курсында укыган чагында ишетеп белгән.

Мин, адресыбызны әйтеп, Рәшитне өебезгә чакырдым. Еш килеп йөрде ул безгә. Яңа шигырьләрен укый иде. «Матур, матур»,— дисәк, кызарып куя, төзәтмәләр кертсәң — уйга кала. Саҗидә аңа «улым» дип кенә дәшә иде.

Рәшит ял көннәрендә әдәбият берләшмәсе утырышларына да килгәләде. Бәхәсләргә катнашмады, бер читтән генә күзәтеп утыра иде. Әлмәттә төзүчеләр бригадасында дүрт ел эшләгәннән соң, Рәшит Әхмәтҗановны 1961 елның көзендә армиягә озаттык. Ул кичке урта мәктәп аттестаты белән китте Әлмәттән.

***

Солдат хатлары... Күңелем тагын шуларга әйләнеп кайта. Кайбер өзекләрен генә китерәм:

*«...Мин өйдән шигырьләремне сораттым. Сезгә тизрәк җибәрергә тырышырмын. Яңаларын да...*

*Планга кертеп, яңа шигырьләр өсти барырга мөмкиндер, бәлки. Алай булса, үзем дә ныграк тырышыр идем. Әле булганнарын да ныклы кул белән, Сезнең ярдәмегез белән төзәтергә кирәк. Әдип абый! Сезнең игътибарыгыз шатландыра һәм яңа шигырьләр язарга рухландыра...*

*Сагынып, Рәшит. 31.1.62.»*

Озак та үтмәде, Рәшиттән күп кенә шигырьләр килеп җитте. Хатында болай диген:

*«Бу әле өйдән килгән нәрсәләр түгел, төрле елларда язылып, күңелдә калган парчалар. Яраклы табылмасалар да инде болар, ну Сезгә барсыннар әле, карап карарсыз үзләрен. Күчермәләре миндә калмый, Сездә саклансыннар. «Хезмәт байрагы»на (шәһәр газетасы) тәкъдим итәрсез, ошамасалар...*

*Рәшит. 2/11–62»*.

Шигырьләренең бер өлешен Әлмәт газетасында бастырып, авторның үзенә җибәрдем. Алар арасында «Истәлек» (1958) дигән шигыре дә бар иде:

Эх, үзләренә чакырган таулар...
Хәтереңдәме, дустым Биктимер?
Истәлеккә диеп таш кыяга
Исемебезне язган идек бер.

Беләм, хәзер безнең бу истәлек
Тарих түрләренә юл алмас.
Кыяларны ватып, йортлар салсак,
Хезмәтебез мәңге югалмас.

Аның соравы буенча Тукай томнарын һәм Сәҗидәнең «Кыр казлары» дигән беренче китабын салсам да, «Хезмәт байрагы»нда Рәшитнең үз шигырьләре басылган әдәби сәхифәләрне юлласам да – рәхмәт сүзләре явып кына торды. Рәшит кебек яшь талантлардан рәхмәт сүзләре ишетү – үзе бер бәхет.

Хатлары эчендә яңа шигырьләре килә торды Рәшитнең.

Без, Әлмәт язучылары, бергәләп сөенә-сөенә укый идек аларны. Яшь талант килә бит әдәбиятыбызга!

*«Мин инде, үзебез сөйләшкәнчә, машинкада басылган шигырьләремне көтеп ятам»,*– дип язды Рәшит, кыюланып китеп.

***

Кыскасы, Рәшит Әхмәтҗановның «Хыялларым үзем белән» дигән беренче шигырьләр җыентыгы, туган ягы Баулыда, Әлмәт төзүчеләре арасында һәм Самара казармаларында язылып, 1965 елда Татарстан китап нәшриятында дөнья күрде. Аны җәмәгать эше тәртибендә Зәки Нури редакцияләде. Ул чагында инде Рәшит Казан дәүләт университеты студенты иде.

***

«Хыялларым үзем белән» җыентыгын укый башлагач, үзеңне якты, зур дөньяга кергәндәй хис итәсең. Шигырьләрдә тышкы ялтырау да, купшы сүзләр дә юк. Алар тормышның үзе шикелле кырыс һәм табигый яңгырыйлар. Алар ничектер эчтән яктырып, нурланып торалар шикелле:

Хыялларым һаман үзем белән,
Кирәксенмим чакма чаткысын.
Күрәсезме, тауның күкрәгенә
Алып керәм кояш яктысын.

Лирик герой җирдәге сихри моңнарны бөтен кешеләргә тигез итеп бүләргә әзер. Аның сафташлары кояш белән бергә уяналар, кыяларны ватып, бәхет сарайлары салалар. Әмма автор дөньяның матурлыгы белән генә мавыкмый, ул кисәтеп куя:



**Сулдан уңга: Рафаэль Төхфәтуллин, Әдип Маликов, Гариф Ахунов. Азнакай, 1960**

Җир шарым, уяу бул үзең дә!
Куенында яшеренеп торалар...
Шартласа – сине дә, мине дә
Урыннан кузгатыр бомбалар.

Җыентыкка кергән күп кенә шигырьләргә гомумиләштерү, философик фикер йөртү хас:

Алмаларны күреп куана,
Сабый әле, диләр берәүләр.
Кулда алма – кояш шикелле,
Ә җанымда тоташ күкрәүләр.

Рәшит Әхмәтҗанов, мәхәббәт темасына кагылганда да, кайбер яшь авторлар шикелле төчеләнү, яшь кою белән мавыкмый. «Зәңгәр кыңгыраулар өзәргә», «Гөлнәзирә», «Әлмәт кызы» кебек шигырьләр, мәсәлән, тормыштан аерылмаган олы мәхәббәт хисе белән сугарылган:

Сагынганда, иркә сүзең килер,
Җылың килер, өши башласам.
Туган илем олы улы итмәс –
Олы юлда йөрми яшәсәм...
*«Озатканда»*

Рәшит дустыбызның «Хыялларым үзем белән» дигән беренче җыентыгы дөнья күргә инде 35 ел вакыт үтте. Әйе, аның шигърияте Әлмәт якларында бөреләнде. Без моның белән горурланабыз. Поэзиянең олы мәйданына юл ярып чыккан ялкынлы шагыйрь «җанында тоташ күкрәүләр» белән яшәп, гаҗәеп кешелекле, тирән хисле шигырь һәм поэма җыентыкларын калдырып китте халкына. Укучылары мең рәхмәтле аңа!

*«Ватаным Татарстан» газетасы.– 2001. – 14 июнь*

# Рәшит абый гел искә төшә

Хәсән Ильяс

Рәшит абый яхшы күңелле, хисле кеше иде. Тик аны аңлый алганнар гына аңлады. Миңа Тәүфикъ Әйди һәм аның белән «шабаш» та эшләргә туры килде. Бу аның, җиде-сигез ел рәттән төзелештә ташчы булып эшләгәннән соң, «Татарстан яшьләре»нә урнашам дип, эштән киткән чагы иде. Көн саен — җәйге эсселәрдә, көзге яңгырлы көннәрдә, кышкы салкыннарда, бураннарда — сигез-тугыз сәгать эшләп кайтканнан соң иҗат белән шөгыльләнүнең ифрат та авыр икәнен Рәшит ага үзе генә белгәндер. Язмас иде, кул гына селтәр иде язучы-шагыйрь. Язмыйча булдыра алмый. Аның йөрәге, күкрәге тулы фикер. Булган хисләрен, фикерләрен әйтеп калырга тырыша.

Ул чакта, без 1978 елны Дөбъяз ягында эшләгәндә, Рәшит ага алты китабын чыгарган иде инде. Көрәк тотып җир казыган, авыр-авыр ташларны күтәреп ташыган чагында да бу шагыйрь, тирләп-пешеп, су эчәргә, тәмәке тартырга туктаганда да, шигырьләр укый иде.

Бервакытны, ялга кайткач, аның фатирында ике кичне кунган идем. Балалары кечкенә иде әле. Хатыны — Луиза апа. Кече күңелле гүзәл ханым. Бер-берләрен күз карашларыннан ук аңлыйлар. Мин хәтта «бу Луиза ханым — теш табибы — ничек итеп кешеләрнең тешләрен суырып ала икән?» дип гаҗәпләнеп тә куйдым. Кешеләрне сәламәтләндерү хакына, кирәк булгач, суырыплар ала торгандыр инде.

Шимбәдә көне буена эшләп, кич кенә Казанга ял итәргә дип кайткан Рәшит ага, якшәмбе көнне иртән иртүк миңа фатир ачкычларын калдырганнан соң, Васильеводагы дачасына китеп барды. Йокылы-уяулы килеш, мин һични аңышмыйча калдым. Кичен телевизор карап утырган вакытымда соң гына кайтып керделәр. Бер балалары Луиза апа күкрәгендә йоклый, Рәшит аганың кулында авыр әрҗәләр, аркасында — биштәр.

— Нишләп бик озак тордыгыз? — дидем мин.

— Төзим бит. Бер кадак каксаң, икенчесен, өченчесен кагасы килә,— диде Рәшит абый.— Ә Луиза апаң помидор, кыяр җыйды, ярыла, саргая башлаганнар.

— Рәшит абый, сезнең дачагыз төзелеп бетмәгәнмени әле? — дип сорадым мин.

— Һи, дустым, аның мәңге төзелеп бетәсе юк,— диде ул.

Рәшит абыйның миңа бүләк иткән үз китабында мондый юллар язылган: «Рәшит абыең белән Луиза апаңнан. Үзеңә дә тиздән бәхетле гаилә коруыңны һәм акыллы балалар үстерүеңне теләп». Бу сүзләрендә Рәшит ага күрәзәче булган дисәм, һич кенә дә ялгышмамдыр. Фәния белән өйләнешкәнебезгә берничә ай гына үткән иде әле, Рәшит абыйны Ибраһимов проспектындагы озын «Хуҗалык товарлары» кибетендә очраттык.

— Хатыным,— дип таныштырдым.

Бераз сөйләшеп торганнан соң, Фәниядән гафу үтенеп, мине читкәрәк алып китте дә:

— Чынлап та хатыныңмыни? — диде ул.— Котлыйм! Ялгышмагансың. Дөрес сайлагансың. Луиза апаң белән безнең шикелле бәхетле булыгыз! — дип китеп барды.

Декабристлар урамындагы Матбугат йортында очрашкан чакларыбызда да: «Башкорт» икәнеңне кешегә әйтәм»,— дип янаган булды тагын. Башын артка ташлап, рәхәтләнеп көлә инде үзе. Көлә белеп. Көлдерә белеп. Ә ул минем, үзе әйтмешли, «чеп-чи» татар икәнне дә, Башкорт-



**Районда очрашу. Рәшит Әхмәтҗанов — уңнан алтынчы**

станнан килгән татар егетләренә «башкортсытып карау» кебек мөнәсәбәтләрне дә бик яхшы сизә һәм белә иде.

Берзаманны, яңгыратып көлеп торган чакта, йөгерә-сикерә Эльс Гадел Матбугат йортының ничәнчедер катыннан җиденчесенә төшеп бара иде.

— Көлүең белән Матбугат йортын ярасың бит, Рәшит,— дигәч, ул:

— Менә, дус килгән,— диде.

— Һо-һо-һо! — дип, нәсел айгыры шикелле кешни-кешни, Эльс Гадел юлын дәвам итте.

Шушы очрашулар соңгылары булган икән. Биш еллар элек, Яңа ел тирәләрендә, Рәшит ага арабыздан китеп барды. Китеп кенә бармады, гаилә хакына, тамак туйдыру, балаларын аякка бастыру хакына булган авыр эштән, туктаусыз иҗат иткәнгә күрә, Сабан туйларында беренчелек өчен йөрәге ярылган чабыш атыдай, вакытсыз янды ул.

Әгәр дә мәгәр теге дөньяда икенче тормыш бар икән, ул анда да шагыйрьдер!

*«Ватаным Татарстан» газетасы.— 2000*

# Бөтен гомеремә бер гөлем...

## Луиза Әхмәтҗанова

Хатын-кыз үткәнен сагынып яшәве белән дә бәхетле.
*Рунниз*

Миңа 17 яшь. Алабуга педагогия институтында читтән торып укучы студентка буларак, Баулы районы Татар Кандызы мәктәбендә укыта башладым. Мәктәп директоры Җәмилә апа мине Сания апа Хәлиуллинага фатирга урнаштырды. Эштән кайтуыма Сания апа тәмле итеп ашлар пешереп тора. Күпне ишетә, күпне белә дигәндәй, миңа аның янында яшәү бик күңелле булды.

Ә мәктәптә... Беренче көннәрдә үк мин шагыйрь Рәшит Әхмәтҗановның нәкъ шушы авылдан икәнен белдем. Аңа багышлап стенд бизәлгән. Рәшит турында сөйләшүләргә дә еш тап булам. Күренеп тора: ул – мәктәпнең горурлыгы!

Кыш җитте. Студентларның да кышкы каникулга кайту вакытлары якыная иде. «Рәшит каникулга кайтачак» дигән хәбәр таралды. Укучылар аның белән очрашуга әзерләнә башладылар. Ыгы-зыгылы мәшәкатьтән коридорлар гөж килде. Бер мин генә тыныч идем.



**Рәшит Әхмәтҗанов хатыны Луиза һәм Азнакайдагы җизнәсе Илгиз белән**



**Кызы Ләйлә, сеңлесе Сания, хатыны Луиза белән. 1971**

Беркөнне, дәрестән чыксам, укытучылар озын гына буйлы, оялчанрак кыяфәтле бер егет янына җыелганнар да бик җитди генә сөйләшәләр иде. Дулкынланулары йөзләренә чыккан. Шунда колагыма кемдер: «Безнең Рәшитебез!» – дип пышылдады.


Шул ук көнне мәктәптә Рәшит балалар алдында шигырьләрен укыды. Мин хәйран калдым. Шагыйрьнең һәр сүзеннән моң агылды да агылды. (Аның шигырьләрен үзе кебек итеп беркем дә укый белми сыман миңа әле дә.)

Соңыннан чәй янына җыелдык. Мөсәпбиха апа (Рәшитнең татар теле укытучысы) аңа киңәшләрен бирә, матур шигырьләрен мактый. Мин әле бу авылда үз кеше булып бетмәгән, җитмәсә, түгәрәк күзлегем дә бик ямьсез, үз-үземне артык тоеп, кайтып ук киттем.


Кичке сәгать тугызларда безнең ишекне шакыдылар. Ачсак – Рәшит! Сания апа туры сүзле иде: «Ничек әле син, Рәшит, безгә килергә булдың?» – дип сорау ала башлады. Рәшит исә, шаяртып, аңа туган булуын аңлата: «Синең үги әниең, Сания апа, минем зур әтәйгә кияүгә чыккан иде бит, соң, шулай булгач, без якын туганнар инде»,– ди. Мин төнге кунагыбызга туры карарга да оялам. Ә ул, моны гел сизмәгәндәй, Сания апа белән көлә-көлә сөйләшә.

Сания апа, мине өтеп-төртеп дигәндәй, кунак егетне озатырга чыгарды. (Бу вакыйганы Рәшит балаларга: «Әниегез, йөгереп, мине озатырга чыкты. Мин шагыйрь булганга, «акыллы сүз» әйтәсе килгәндер инде, «бүген йолдызлар күп», дигән булды; ә ул төн болытлы, күктә бер генә йолдыз да юк иде»,– дип шаярып сөйләргә яратты.)

Бераздан без гаилә корып җибәрдек. Икебез дә студентлар гына әле. Торыр урыныбыз булмагач, без балалар бакчасын каравылларга, урам себерергә алындык та, безгә бер бүлмә бирделәр. Аның тәрәзәләре юк. Шулай да күңелле. Кичләрен шагыйрьләр, артистлар җыела. Ә иртән сәгать 5 тә урам себерергә чыгабыз... «Менә... укыган булсалар, урам себереп йөрмәсләр иде»,– дип



**Кызы Ләйлә белән. 1971**



**Улы Айдар белән**

үтәләр яныбыздан. Ә без көлешәбез. Беребез – шагыйрь, ә икенчебез – 5 минуттан врач буласы... (Мин инде, Алабуга педагогия институтын тәмамлап, медицина институтының стоматология факультетында укый идем.)

Тәрәзәсез шушы бүлмәгә кызыбыз Ләйләне алып кайттык. Рәшитнең шул көннәрдәге шатлыгын тасвирлау өчен сүзләр җитми. Минем дә кадерем артты. Төнлә кызыбыз көйсезләнсә дә, мине уятмаска тырыша: бишек җыры көйләп, йоклату җаен таба.

Әйе, Аллага шөкер, без тату яшәдек. Мин күп эшләдем, Рәшит күп язды. Китаплар чыгарды, фатирлар алды. Яңасына күчкәндә, фатирларның искесен, шатлана-шатлана, Язучылар союзына тапшыра идек. Хәзер уйлыйм менә: нигә алай эшләдек икән, дип. Бүгенге көндә кызыбыз Ләйлә фатирсыз. Ул врач булып эшли, димәк, мәңге фатир алалмаячак. Мин, мәсәлән, 30 ел эшләп тә алалмадым, врачларга тиеш түгел, күрәсең. Табибның хезмәт хакына бит фатирны сатып алып та булмый. Безнең артык тыйнак булуыбыз миңа әнә шундый зур проблема тудырды хәзерге көндә...

Шулай да йөрәктә бергә яшәгән чорның иң матур хатирәләре генә. Әле менә июнь аенда Татарстанның халык артисты, Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе, Рәшитнең бертуган энесе Илдус Әхмәтҗановның 50 яшьлек юбилеена багышланган тантаналы кичәсе узды. Кичәдә Рәшит абыйсы гына була алмады. Аның вафатына алты ел инде. Кичәгә балалар белән мин дә килдем. Өчебез дә Илдуска чәчәкләр чыгардык.

Гаҗәп: сәхнәдә Илдус үзе генә торган сыман түгел иде. Аның кырыенда, елмаеп-шатланып, Рәшит абыйсы да тора сыман тоелды. Илгиз Хәйруллин кыска гына чыгышында Рәшитне ике мәртәбә искә алды, курчак театры директоры Роза Бадыйкова яраткан Рәшит абыйсының шигырьләрен укыды. Башкалар да Рәшитне искә алдылар. Улым Айдар – әтисе кебек үк эмоциональ – бу «йөк»не күтәрә алмыйча, кичә беткәнче үк кайтып китте. Кызым – аның холкы минекенә охшаган – таш булып катты, иреннәрен кысып утырды. Ә минем гел җылыйсым килде. Бер-ике ай элек кенә бер пациенткам рәхәтләнеп җылаганга кызыгып куйган идем; чөнки мин алты ел дәвамында бер дә җыламаганмын икән, каты итеп ирләрчә басып йөри башлаганмын, үземнең хатын-кыз сыйфатларымны югалта язганмын. Җыласаң бит, адреналин чыга, тынычланасың, йөрәккә рәхәт була. Ә бүгенге җылавым йөрәккә рәхәтлек бирмәде. Хәсән Туфан шигырендәгечә:

> Бирде дөнья кирәкне,
> Еламаска өйрәтте.

Әйе, миңа Рәшиттән башка авыр яшәве. Чөнки мин балаларга әти дә, әни дә! Айдар түләүле институт тәмамлады. Миңа исә икешәр ставкада эшләргә туры килде. Хыялы прокуратурада

эшләү иде, ә анда коммерция нигезендә эшләүче институтлардан алмыйлар икән. Мин үзебезнең Татарстан прокуроры Нәфиев Сәйфихан Хәбибулла улына бардым. Ә ул миннән баланы нигә университетта укытмавымны сорады. Мин анда ата-аналар конкурсы баруын, гади шагыйрь белән гади врачның акчасы җитмәвен, ике ел дәвамында резервта торуыбызны сөйләдем... Аһ, үзе исән булса икән?! Кайчакта ирләр генә хәл итә алырдай проблемалар да була шул...

## *Бүген елның иң кыска көне*

*Луизага*

Бүген елның иң кыска көне –
Борчуларга салды да мине,
Китеп барды үзе, мин калдым,
Әйтерсең лә юлда югалдым.
...Югалмадым, исән-сау идем,
Юлда сине эзләп йөредем.
Хәбәр салдым бөтен дөньяга –
Сине эзләп, дөнья ут яга.
Озайтырга синең көннәрне –
Мин утларга ягам төннәрне...

Яктылыкның түгел актыгы –
Чәчләремнең кардай аклыгы.
Төннәр янсалар да – төн кара,
Төннәр яна – көлләре кала.
Мин агарам, һаман агарам –
Күренмидер хәтта күз карам...
Яктылыгым – туган илнеке,
Утлы йөрәк кенә минеке.
Сине эзлим,
Ә син – гомерем,
Бөтен гомеремә бер гөлем.

Аның шигырьләрендәгечә, кадерле гөле (!) булып кына яшисе килә дә бит...

...Киләсе елда Рәшит Әхмәтҗановка 60 яшь тулыр иде. 55 яшен Баулы районында зур итеп үткәрдек. Шагыйрь Рәшит Әхмәтҗанов көннәре булды. Ул өч көн дәвам итте. Баулының элеккеге хакимият башлыгы Наил Зарипов безне зурлап кунак итте, мәктәп балалары Рәшит абыйларының шигырьләрен, җырларын өйрәнеп килеп, безгә матур бәйрәм ясадылар. Рәшит Әхмәтҗанов музеен ачарга, бер урамга исемен бирергә, кабер ташы куярга вәгъдәләштеләр. Зарипов, боларны үз күзәтүенә алып, барысын да төгәл эшләтте. Рәхмәт аңа!

Музей... Ул кухня формасында эшләнде, чөнки Рәшит кухняда язарга ярата иде. Мин ул утырып язган урындыкны, өстәлне, соңгы каләмен – барысын да анда куйдым. Музей директоры Раиса Михайловна мине һәрвакыт җылы каршы ала, күпме бала килгәнен, нинди бәйрәмнәр үткәрелүен сөйли. Анда булгач, җаныма җиңел булып китә. Рәшитнең үзен күргәндәй булам. Үзе дә шунда язып утырадыр сыман тоела.

Әле менә искә төшерәм. Ул кухняда язып утыра. Мин балалар белән залда. Бик озак утыргач, балалар: «Әни, ашыйсы килә»,– диләр. Мин аларга: «Түзегез, әтиегезнең фикере таралыр, шигырьнең сүзе югалыр»,– дим. Озак вакыт үткәч кенә, кухня ишегенә кагылам: «Рәшит, гафу ит инде, безнең ашыйсы килә бит»,– дим. Ул, кинәт торып: «Нигә аны әйтмисез?» – дип, залга, балалар янына ашыга. Җылытасын җылытып, пешерәсен пешереп дигәндәй, подносымны ризыклар белән тутырып, ун-унбиш минуттан мин дә гаиләм янына чыгам... Искә алырга гына калды шул.

«Таһир-Зөһрә»дә пар канатлар, аларның матур мәхәббәт тарихлары турында күп языла. Без дә зур мәхәббәт белән яшәдек, көн саен мәхәббәт турында уйладык дип әйтә алмыйм мин. Шагыйрь күңеле бик нечкә, бик тиз яраланучан була. Рәшит күңеле дә кыл кебек иде. Күп очракта усалрак итеп әйтәсе сүзне дә әйтмичә калырга тырыштым. Шагыйрь хатыны булу бер дә җиңел түгел.

Бүгенге көндә мин Аның алдында үземне зур бурычлы итеп сизәм. Исән чагымда мирасын сакларга тырышырмын. Китапларын да чыгарырга тырышырмын, боерган булса. (Инде ике китабы дөнья күрде, өченчесе нәшриятта җыелып ята. Бәлки, 60 яшьлеген искә алу көненә чыгар да әле.) Ләкин балаларның киләчәген генә ничек тәэмин итәргә? Төпле итеп. Ныклы итеп. Көчем җитәрме? Булдыра алырмынмы?..

*«Таһир-Зөһрә» газетасы.– 2000. – № 25*

# Поэт-романтик, говоривший с солнцем

Назип Галеев

В эти дни Рашиту Ахметзянову исполнилось бы 60 лет. Однако поэт-романтик, кажется, не вмещается во временные рамки – он в прошлом, в настоящем и в будущем. Его нет с нами уже несколько лет, но он есть всегда!

В татарскую литературу он вошёл с благословения Хасана Туфана. Но в застойные годы поэт не был по достоинству оценен ни литературной критикой, ни обществом. Зато его высоко ценили близкие и друзья. Многие читатели знали наизусть не только его стихи, но и целые стихотворные сборники. Он и сам всю жизнь прожил в кругу друзей и как истинный романтик никогда их не предавал. Был всегда открыт для них. Был душой компании.

В поэтический мир Рашита эфенди вмещаются и родина, и дальние страны, и цветы, и друзья. И враги... Он ведёт разговор и с птицами, и с морем, и с солнцем. Пролитая кровь ранит его душу, и нежный солнечный луч озаряет жизнь. Родина близка и дорога для него как Мать!

Следствием поэтической и гражданской зрелости Рашита Ахметзянова явилось его стремление жить ради нации и народа. В этом он нашёл опору жизни и стал активным участником общественных преобразований в республике в 90-е годы. На эти во многом романтические годы приходится расцвет его таланта, что выразилось в последней книге поэта «Ачлык мәйданы» («Площадь голодовки»).

На этой-то казанской площади Свободы мне и довелось с ним познакомиться. Он относился ко мне по-дружески, даже по-свойски, что несколько смущало меня. До конца оставался преданным делу. Был сколь общительным, столь и уединённым.

Обществу еще предстоит оценить поэтический дар и труд Рашита. Ибо и нынче:

Душа поэта в думах сердца,
Как раненая птица бьется.

Тем более что занимающая нас прагматичная жизнь требует новых романтиков.

Я не склонен связывать безвременный уход поэта с изменением общественного климата. Думаю, его сердце хватило бы принять или отвергнуть его и сказать свое слово. Слишком он ему знаком. Он до святости верил в улучшение нашей жизни, но не в обратное. Видно, так может верить только романтик.

Помимо утраченного окончательно здоровья причиной его смерти стало, видно, то, что душа поэта уже не вмещалась в нашу реальную жизнь. Так хочется, чтобы его принял мир, подобный им самим созданному.


*Газета «Казанские ведомости». – 2001. – 15 июня. – № 129*

# Аклыкны бөртекләп җыйды ул

Әхмәт Рәшит

Менә инде ничәнче язны без аннан башка гына каршылыйбыз. Күнегергә дә вакыттыр, бәлки. Юк, күнегеп булмый икән шул. Кар сулары челтерәп аккан, тамчылар зеңгелдәп тамган, бар хәят уянган бу көннәрдә искә килеп төшә дә, бәгырьләрне актарып, дөньяның фанилыгы турында ямансу уйлар уйлатып, күз алдында пәйда була:

Күпме язлар яна йөрәгемдә!
Шул турыда уйлыйм әле менә...
Һәм ышанам, дуслар, җирдән безне
Алып китә алмас үлем генә.



Бу – Рәшит Әхмәтҗанов. Гомер онытылмас, әле байтак буын шагыйрьләргә әдәбият сабаклары бирә алырлык, җисми яктан фани дөнья белән, безнең белән хушлашса да, рухы белән барыбер арабызда калган, иҗаты һаман да остазлык миссиясе үтәп барган кабатланмас шәхес.

Үзе исән булса, бу көннәрдә без, шаулап-гөрләп, аның 60 яшьлеген бәйрәм итеп йөргән булыр идек. Сөенечле мәшәкатьләр эчендә дөньяларның болгавыр, заманаларның катмарлы булуы да онытылып торыр иде.

Шигырь дигән дөньяга аның юлы бик ерактан башланды. Баулы якларында исеме үк шигъри яңгырашлы Кандыз исемле авыл бар. Татар Кандызы. Олы юллардан, зур сулардан читтә торган гадәти бер авыл. Кешеләре иген игеп, терлек карап көн күрә. Шушы тын вә тыныч Кандызда бөтен татар мохитен шаулатырлык бертуган ике егет үсә. Олысы (Рәшит исемлесе), тормышның ачысын-төчесен татыганнан соң, татар әдәбиятын бизәрлек күренекле шагыйрь булып җитешәчәк, кечесе (Илдус атлысы), абыйсының киңәш-табышларын зиһененә сала-сала барып һәм авыр чакта азмы-күпме аның матди ярдәмен дә тоеп, аякка ныклап баскач, мәшһүр Камал театры сәхнәсендә мәйдан тотачак, Татарстанның халык артисты, Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе дигән зур дәрәҗәләргә ирешәчәк. Әмма болары соңрак. Ә әлегә алар, бер-берсен алыштыра-алыштыра, көтү көтә, бакча утый, тавык чүпләп бетерә алмаслык туксан тугыз мәшәкать эчендә кайный. Ә яшәргә кирәк. Кешеләргә лаек булганча. Күкрәкләрдә әллә никадәр потенциаль көчләр ташып торганда, хыял еракларга-еракларга дәшеп торганда – юк-юк – болай гына булмый.

Менә, тәвәккәлләп, Рәшит сәфәр чыга. Авыл мәктәбендә алган җидееллык белемен биштәр итеп асып, ул Бөгелмә тарафларына, төзүчеләр әзерли торган һөнәр училищесына юл тота. Ике



**Әдәби очрашуда. Сулдан уңга: Рәшит Әхмәтҗанов, Рәшит Гәрәй, Әхмәт Рәшитов. 1982**

елдан инде аның кулында мактаулы һөнәре бар. Рәшит гомер буе үзенең ташчы булуы белән горурланып яшәде. Соңрак, матди кыенлыклар кичергәндә, инде бу юлы «шабашчы» сыйфатында, ул кулына мастерок ала һәм шуның белән гаиләсенең финанс ярыкларын сылаштыргалап куя иде. 1958–1961 елларда Рәшит Әлмәт каласында йортлар төзеп йөри. Коллективның да ниндиендә әле – бөтен СССРга атаклы, Социалистик Хезмәт Герое Рәшит Саттаров бригадасында. Гомеренең ул елларын Рәшит Әхмәтҗанов үзенә очар канат биргән иң бәхетле чор дип саный иде. Шигъри канатлары да аның нәкъ менә шул дәвердә ныгыды бугай. Беренче иҗат тәҗрибәләрен кешеләр күзеннән качырып кына ясый барган Рәшит берзаман үз язганнарын Әлмәткә кунакка килгән классигыбыз Хәсән Туфанга күрсәтергә җөрьәт итә. Яшь егетнең шигырьләре аны таң калдыра, кат-кат: «Үзең яздыңмы боларны?» – дип сорый, бик үк ышанып та җитми. Аннан чын-чынлап имтихан алалар. «Менә сиңа бер сәгать вакыт, шундый-шундый темага шигырь язып күрсәт»,– диләр. Рәшит бурычны менә дигән итеп башкара. Х. Туфан, С. Хәким, Г. Хуҗиев кебек тәҗрибәле шагыйрьләр яшь каләмнең поэтик фикерләүдәге мөстәкыйльлеген, табигый сәләтен һәм шигырьләренең тормышчанлыгын танырга мәҗбүр булалар. Моннан соң инде алар аны күз уңыннан ычкындырмыйлар, иҗатының һәр адымын игътибар белән күзәтеп баралар.

Өч елга сузылган армия хезмәте аны яраткан шагыйрьләреннән, әдәби мохиттәге мөһим вакыйгалардан аерып тора. Хезмәт срогы бетеп, Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга кергәч исә, ул баш-аягы белән шигърият дөньясына чума.

Мин Рәшит Әхмәтҗанов белән якыннан 1968 елда таныштым. Тора-бара бу танышлык озак елларга сузылган ихлас һәм эчкерсез дуслыкка әверелде. Ул каравылчы булып эшләгән (һаман да шул матди кыенлык инде) балалар бакчасы бервакытны йортсыз-җирсез байтак «мәхлуклар», шул исәптән минем өчен, ничәдер төн кунып чыгу урыны булды. Аннан, Чернышевский урамында фатир алгач та, шул кечкенә генә бүлмәсенә дусларын да сыендыра торган булды. Кесә ягы такыр, көн итәр почмаклары тар булса да, күңеле киң иде аның. Мин аның бер дә саран һәм кысмыр булганын хәтерләмим. Халкыбызның бик күп асыл сыйфатлары гәүдәләнгән иде аның шәхесендә.

Республикабыз районнарында ул елларда әдәбият-сәнгать көннәре бик еш һәм, иң мөһиме, даими үткәрелә иде. Авыл мәдәният сарайларында, терлекчеләр йортларында, мәктәпләрдә чы-

гыш ясаганда, ни хикмәттер, без еш кына бергә туры килә идек. Бу безнең серләр килешкәннән, язмышлар охшаш булганнан, шигъри кыйблаларның бердәйлегеннән килеп чыккандыр, мөгаен. Үзгәртеп корулар чоры башлану белән туган яңалыкларга, әдәбиятыбызга Гаяз Исхакый кебек олуг шәхесләр кайтуга, ниһаять, бөек «Идегәй» дастанының татар дөньясында лаеклы урын алуына, Сталин заманнарында каһәрләнгән Мирсәет Солтангалиев фикерләренең милли азатлык хәрәкәтенә шифалы рух бөркүенә һәм тагын бик күп нәрсәләргә сабыйларча сөенә идек. Бер ул гына да түгел, без әллә нинди перспективалар күрә һәм, армый-талмый, офыклар артындагы кояшны олылап, шигырьләр яза идек. Чистай районының әдәбиятыбыз классигы Гаяз Исхакый туып үскән Яуширмә авылында, Аксубай районының дөньяга үлемсез Туфанны бүләк иткән Иске Кармәтендә булулар ул истәлекле очрашуларның онытылмас мизгелләре иде. Һәрхәлдә, бергә-бергә йөзләгән авылларда булынгандыр. Хәтта ерак Себер якларына барып, Төмән нефтьчеләре алдында иҗади хисап тотулар, андагы кызыклы язмышлар хакында Татарстан матбугатында зур-зур мәкаләләр язулар да насыйп булды безгә. Бу хакта ашыкмыйча, тәфсилләп, җеген җеккә китереп бер язармын әле, Ходай кушса.

Шигыреңнең нинди икәнен аларны халык алдында укыганда беләсең. Китап укучының фикере еш кына сер булып кала. Ә менә тыңлаучы бәяне шунда ук куя. Рәшит шигырьләрен аудитория бик җылы кабул итә, гөрләтеп кул чаба иде. Юк, бу аның шигырьне әйбәт укуыннан, үз-үзен нәфис сүз остасы сыман тотуыннан гына түгел иде. Ул шигырьләр эченә ниндидер мәгънәви магнит салынган һәм тыңлаучыларның уй-теләкләренә аваздаш иде.

Рәшит Әхмәтҗанов иҗаты яныннан йөгертеп кенә узу мөмкин түгел иде. Шагыйрьнең халыкчанлыгына һәм тормышчанлыгына кат-кат басым ясалды. Нидән гыйбарәт иде соң ул хикмәт? Мөгаен, ул шигырьләрнең халык авыз иҗаты белән органик бербөтен булып үрелүендә, шигырь төзелешенең, образлар галереясының, гомумән, фикерләүнең классик шигырь белән нисбәтендә булгандыр. Шагыйрьнең хисләре тирәннән, халыкның күңел түрендә яшеренеп яткан сөенеч-борчылулардан, иң якын кеше белән генә уртаклашырдай эчке серләрдән, матурлыкка, яктылыкка, аклыкка омтылудан килә иде. Ул бервакытта да оригинальлек артыннан кумады, чынбарлыктан, яшәештән аерылган, ниндидер уйлап чыгарылган аморф фикерләр ышыгына качмады, һәрвакыт үз-үзе булып калды. Рәшит оста ювелирны хәтерләтә иде: ул халыктан алган зөбәрҗәтләрне тиешенчә эшкәртеп, һәр кырыннан нурлар чәчәрдәй итеп ясап, аларны халкына кабат кире кайтарды. Моңа инану өчен, аның шактый калын том тәшкил иткән җыр вә шигырьләрен, «Язлар быел соңга калды», «Исәннәр моңы», бигрәк тә «Аучылар кибетендә» һәм «Бишташ» поэмаларын игътибар белән уку да җитә.

Р. Әхмәтҗановның үзе исән чакта чыккан соңгы китабы «Ачлык мәйданы» дип атала. Бу — аның гражданлык һәм шагыйранә каһарманлыгы, бу — Рәшитнең, аның каләмдәшләренең һәм фикердәшләренең, республикабыз язмышы өчен хәлиткеч көннәрдә ачлык игълан итеп, Ирек мәйданында утырулары көндәлеге, бу — милләтпәрвәрләребезнең көрәше һәм җиңү тарихы. Аны дөньяга чыгаруда җырчыбыз Гөлзадә һәм аның дуслары күп көч куйды — чиксез рәхмәт аларга! Иренең изге гамәлләренә тугры калып, хатыны Луиза ханым «Рухият» фонды белән бергә Р. Әхмәтҗановның сайланма әсәрләрен туплап чыгарды. Димәк, шагыйрьнең шигъри авазы тынмаган, уй-теләкләре бу катлаулы заманда — нәкъ менә иң кирәк чакта — бүгенге укучыларга барып ирешкән дигән сүз.

Рәшит Әхмәтҗанов — Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Гаяз Исхакый бүләге иясе иде. Ә иң олы ихтирам билгесе — аның истәлегенең күңелләрдә саклануы, аның мирасының кадере.

Бөртекләп, мыскаллап җыйдым
Дөньяның аклыкларын.
Шул ук дөньяга очырдым
Аклыкның аккошларын,—

дигәндә хаклы иде, һичшиксез, хаклы иде ул.

*«Мәдәни җомга» газетасы.— 2001. — 20 апрель*

# «Без һаман дамы бергә?»

Асия Юнысова

Кырык бердә туганнарның быел зурдан кубып туган көннәрен бәйрәм итәр елы. Исәннәренә тагын да бәрәкәтле гомер телик тә, җырларын ашыга-ашыга җырлап, гомерләрен тиз-тиз төйнәп, бакый дөньяга күчкәннәрен тагын бер ихлас сагыну, ихтирам, ярату белән яд итик әле.

Тукай ае апрель – шагыйрь Рәшит Әхмәтҗановны да дөньяга китергән ай. Апрель – шагыйрьләр ае. Якташым Рәшит Әхмәтҗановның Азатлык мәйданында халкыма киң сулыш даулап, йотым суга тилмереп, ач карынын тәмәке төтене белән ыслап, челлләдә ташта утырганын күргәнем булса да, аны һаман ак бураннарга уралган итеп күз алдына китерәм. Бураннар белән килде дә ул бу дөньяга, бураннар арасына кереп югалды да бугай. Мөгаен, хәләле Луиза да аны һаман шулай – кышларда яз алып килгән егет, бураннарда да тузгымаслык оя корган иптәш кошы, балаларына җим ташып торган, оясын киң канаты белән җил-давылдан саклаган бөркет итеп хәтерлидер. Әйе, әйе, бөркет итеп.

Рәшит абый якташ та, сердәш тә, иптәш тә була белә торган иде. Зарланырга ярата иде, диләр. Бу кадәресеннән хәбәрем юк. Әмма зарлыларга ярдәм итәргә яратуы хак. Тыңлап торыр иде ул берәүнең зарын ипләп кенә, җайлы гына итеп, теге кеше бушанып, җиңеләеп калгач, сүзне болайрак итеп йомгаклап куяр иде: «Бер дә борчылма, иркәм (алар авылында, Кандызда, кешеләр бер-берсенә әнә шулай, матур итеп, «иркәм» дип дәшәләр). Луиза апаңа әйтермен. Булышыр». Теге серле, исеме таныш, үзе күренмәс Луиза апа (кемгә апа, кемгә сеңел булгандыр инде ул) булыша – кемне үз янына сыендыра, кемне табибка күрсәтә, кемнең тамагын туйдыра. Кыскасы, бу «Луиза апа» булдыра алмаган гамәл бер дә юк. Таныш-белешләрдән дә сокланулы сүзләр ишетә торам. Танышырга гына һаман җае юк.

Мин аны беренче мәртәбә Рәшит абыйны күмгән көнне мәчет капкасы төбендә, җеназада күрдем. Канаты каерылган карлыгач! Кара күзләрен озын керфекләре япкан. Уң ягында – улы, сул ягында – кызы. Гомере буе олы шагыйрьнең таянычы, сердәше, теләктәше булып яшәгән гаҗәеп киң күңелле, зур ихтыярлы, нык холыклы ханым тирән кайгыда. Юк, сыгылмаган, сынмаган! Тик Рәшитенә үпкәләгән генә бугай ла. «Яши генә башлаган кебек бит әле. Әле оныгыңны сөеп туймадың. Улың ныгымаган. Мине дә ятим иттең»,– димәкче генәдер ул.

Шагыйрьләр шуңа да шагыйрь инде алар – алдан сизәләр! Әнә бит юата хәләлен:

Күпме язлар яна йөрәгемдә!
Шул турыда уйлыйм әле менә...
Һәм ышанам, дуслар, җирдән безне
Алып китә алмас үлем генә.

Аннары Луизасы алдында вакытсыз үлеме өчен, терәк иң кирәк чагында авып киткәне өчен алдан ук бәхиллек тә сорап калган икән бит әле ул:

Төшләремә керден, сине күрдем,
Әй, күралмам диган идем лә.
Иелгәндә имән шартлап сынса,
Син, каенкай, аны бәхиллә...



**«Казан утлары» редакциясендә Мостай Кәрим белән очрашу. Сулдан уңга: Мәдинә Маликова, Роза Туфитуллова, Ренат Харис, Мостай Кәрим, Абдулла Шәрәфетдинов, Венера Ихсанова, Рашат Низами, Рәшит Әхмәтҗанов, Зиннур Мансуров, ?, Җәүдәт Миңнуллин**

Менә шундый күрәзәлек. Шагыйрь гыйнвар башында киткән иде. «Казан утлары» журналының беренче саны өйләргә Рәшит Әхмәтҗанов шигырьләре белән килде. Үзе әзерләп, корректурасын укып өлгергән шигырьләр. Тупланмадагы соңгы шигырь янәдән бер тетрәтте:

Дәшәрмен теге дөньядан:
«Без һаман дамы бергә?» –
Бергәме?! Син үлмә, бәгърем!
Мин кердем синең гүргә.

Бөркетнең соңгы сәламе менә шундый инде: «Син үлмә! Мин кердем синең гүргә». Каенкай ничек түзгәндер. Исән чагында Рәшит абый алдында Луизага кырын сүз әйтеп караганыгыз булмадымы? Бәхетегез! Әле генә аккошлары, сандугачлары белән иләсләнеп, хисләнеп, нечкәреп утырган шагыйрь Рәшит Әхмәтҗанов шул мизгелдә, бөркеткә әйләнеп, күзендә яшеннәр уйнатыр иде: тиеп кенә карагыз!

Хәзер инде мин Луиза ханымны, юк ла, шагыйрьне йөзләгән кызлар арасыннан үзенә караткан, мәңге үзенеке генә итә алган йомшак фигыльле, тәмле телле, шифа куллы, мөлаем йөзле, көләч күзле Луизаны беләм дип уйлыйм. Аның хатирәләрендә каникулга кайткан студент егет белән тулган айлы төндә яшь укытучы кызны өенә озата кайтканым, капка баганасына сөялеп торганым, хуҗа әбидән качып кына тәрәзә чирткәнем, аннан шул кыздан тилмереп-тилмереп хатлар көткәнем бар.

Ризыкка, җылыга тиенмәгән сугыш елы малаеның тормышына кыш аенда кояш булып кергән кыз шагыйрьнең йөрәгенә генә түгел, шигыренә дә керә:

Гомер буе тундым. Көтмәгәндә
Хатларында... туган ягымнан
Җылы сүзе килде. Юк, аларны
Алып чыктым кебек янгыннан.

Менә шулай, генерал хатыны булу өчен лейтенантка кияүгә чыгарга тиеш булган кебек, шагыйрь хатыны булу өчен студентны яратырга кирәк. Ләкин шагыйрьне ярату генерал хатыны булу эше генә түгел. Илһам сагында тору ил сагында торуга караганда да зуррак чыдамлык, түземлек таләп итә. Генерал яудан бер кайта ул, шагыйрь исә шигърияткә бер кереп киттеме – бетте! Шагыйрь хатыны булу үзең теләп сәкарьгә керү ул.

Ләкин, күрегез әле, шагыйрь егетнең үз туксаны! Бер шигырен Луизага дип атаган да әнә ни ди бит:

И сазым, моңлы язым син,
Мең моңым бер кылында.
Өзгәлә җанны, өзгәлә
Сөйгән ярым югында.

Яр сөймәсә, каргап булмый,
Ул изге булып кала.
И сазым, изгелекне син
Йә инде каргап кара?!

И ярым, изге җаным син,
Изгелек синдә генә...
Мин елыйм шулай, син минем
Карама көлгәнемә.

Кулыма алтын богаулар,
Кил әле, кидер, иркәм!
Югыйсә сазым кылларын
Өзәрлек итеп чиртәм.

И сазым, моңлы язым син,
Мең моңым бер кылында.
Өзгәлә җанны, өзгәлә
Сөйгән ярым югында.

Сак белән Сок кебек тилмерүләр озакка түгел. Тиздән туй.

Менә шулай кавышалар ике гашыйк,
Менә шунда туа безнең бу нигез.
Мәхәббәттән туганбыз, дип,
ничә әйттем,
Әлегәчә ышанмаган идегез.

Мәхәббәт белән корылган бәрәкәтле нигездә бер-бер артлы балалар туа. Рәшит күп итеп эшли, китап арты китап чыга тора. Луиза, тормыш, ягъни көнкүреш терәге үзе булырга тиеш дигәнне күңеленә беркетеп, шулай ук алны-ялны белми эшли – авырулар карый. Кай арада педагог белемен табиблыкка алыштырып өлгергәндер? Фидакяр җан икәнен күршеләре дә, танышлары да, эштәгеләр дә тиз сизеп ала. Икешәр смена дежур торып кайткан табибка өйдә дә тынгы юк. Тулай торактан үз фатирларына күченгәч, таныш-белешләр керергә почмак эзләп йөдәми инде хәзер. Ә нигә, Рәшит белән Луиза барында?!

«Ашыгыч ярдәм» табибының эшен беләсез. Берне түгел, меңне коткара, шунда арадан кайсы үзенә һөҗүм итә. Төрле чак булган. Өйгә кайткач, ике баланы багасы, шагыйрь ирнең яңа иҗат җимешен тыңлап хуплыйсы, суыткычны тутырасы, күршеләрне җайлыйсы. Менә шундый киеренке тормыш, ашыгып яшәгәндә, теләсә кемне абындырыр.

Луиза үзе сөйләмәгән иде. Рәшит Әхмәтҗановның соңгы китабындагы «Бүген елның иң кыска көне» исемле «Луизага» дигән багышламалы шигырьне укыгач сискәнеп куйдым:

Бүген елның иң кыска көне –
Борчуларга салды да мине,
Китеп барды үзе, мин калдым,
Әйтерсең лә юлда югалдым.
...Югалмадым, исән-сау идем,
Юлда сине эзләп йөредем.
Хәбәр салдым бөтен дөньяга –
Сине эзләп, дөнья ут яга.
Озайтырга синең көннәрне –
Мин утларга ягам төннәрне...

Яктылыкның түгел актыгы –
Чәчләремнең кардай аклыгы.
Төннәр янсалар да – төн кара,
Төннәр яна – көлләре кала.
Мин агарам, һаман агарам –
Күренмидер хәтта күз карам...
Яктылыгым – туган илнеке,
Утлы йөрәк кенә минеке.
Сине эзлим,
Ә син – гомерем,
Бөтен гомеремә бер гөлем.

Бу ни бу – шагыйрьнең каушавы шигырь ритмына да бәреп чыккан! «Әйтмәгән идеммени? – ди Луиза гадәтенчә тыныч кына.– Мин бит башыма операция ясаттым. Рәшит шул чагында бик борчылды. Ул мине бик кайгырта иде. Теш поликлиникасында баш табиб булып эшли башлагач, тәмле-тәмле төшке ашлар пешереп, кайнар килеш китерә иде. Хезмәттәшләрем аның чүлмәкле бәрәңгеләрен һаман сагыналар». Әй, шушы «сагыну» сүзе! Кисә дә куя. Луиза үзе дә бит гел сагыштан тора. Көләч күзләрендә очкын уйнаганда да кан тамырында сагыш тибә аның. «Бүген минем шатлыклы көнем,– дип уята ул мине. Мин вакыйга булырлык хәлләрне, даталарны күңелемнән барлыйм.– Иртән радиодан Рәшитнең җырларын тапшырдылар!» Икенче юлы: «Рәшитнең алмагачы быел бигрәк мул итеп алма бирде», – дип, алма калдырып китә. «Рәшит сөялгән каен», «Рәшит яккан мунча», «Рәшит җырлаган көй» – күп инде алар, мәңге Рәшитнеке булып калган әйберләр, хатирәләр. Гел сандугачлы шигырьләр язган Рәшит Әхмәтҗановның дача-бакчасында үз сандугачы оя корып яшәгән икән. Сандугач диюгә, бишектәге бала күз алдына килә. Үлем түшәгендәге шагыйрьнең соңгы сүзе: «Наиләне юньләп карагыз!» Оныгы Наилә инде өченче сыйныф укучысы. 2 нче татар гимназиясендә. Дәү әни – Луиза – Рәшитнең васыятен үтәп илтте оныгын анда.



**Рәшит Әхмәтҗановның кызы Ләйлә**

Өйнең, илнең изге туфрагына  
Гөл орлыгын инде салдыңмы?  
Якла балаларын югалтудан  
Телсез кала язган халкыңны...–

дигән иде ул. Шөкер, изге туфракка гөл орлыгы салынган. Тәүфыйклы балалардан тәүфыйклы оныклар туа тора. Уллары Айдар университетның татар теле факультетында укыды, аннары юрист һөнәре алды. Кызлары Ләйлә әнисе кебек табибә. Луиза хәзер, кызлары Ләйлә тугач Рәшите язган бишек җырын җырлап, улының кызын йоклата:

Әлли-бәлли, бәлли-бәү...  
Йокла, кызым Камиләү.  
Кояш көлә, син генә  
Ник елыйсың, әйтсәнә?

Кече оныкбабай җырына йоклап киткәч, өлкән онык Наилә бабай китапларыннан дәрескә шигырь ятлый. Бер түбә астында алты җан ыгы-зыгы килеп дөнья көтәләр. Тормыш дәвам итә. Киштәләрдәге китаплар Рәшит абый куйган тәртиптә, кадердә. Китаплары гына түгел, шагыйрьнең рухы кадердә.

Бервакыт, урамда барганда, яныбыздан җилдәй җитез бер кыз узып киткәч, Луиза: «Кара, танымады. Мин бит аны, сулышымны өреп, клиник үлем хәленнән чыгарган, терелткән идем. И, бала, үзенең миңа ничек газиз икәнен белми инде!» – дигән иде. И, Луиза, син исән калдырган җаннарның иң олысы, иң газизе шагыйрь җаны бит! Син исән булганда, ул җан кадердә әле. Шуңа күрә син үлмә, бәгърем.

*«Сөембикә» журналы.– 2001. – № 4*

# Кем ул әдип?

*(Рабит Батулланың газетага биргән интервьюсыннан)*

Күп китаплар чыгарган язучы, кырык биш ел сәхнәдән төшмәгән артист, театрда җитәкче булып эшләгән режиссёр, радио-телевидениедә атна саен тапшыруда катнашучы сәнгатькәр Рабит Батулла бездә кунакта. Аңа 65 яшь тулды, ул 45 ел иҗат итеп килә. Шушы уңайдан без аның белән сөйләшергә булдык.

Ул болай башлады:

— Фәлән яшь тулган көнне сине мактыйлар инде ул, газеталарда бер-берсенә тач охшаш әңгәмәләр чыга инде ул. Әйдәгез, без бүген минем турыда түгел, әдәбият һәм әдипләр турында сөйләшик әле.

— *Алайса, әйт әле, Батулла абый, кем ул әдип?*

— Бар язучы, бар әдип. Без барыбыз да язучы, әдипләр бик сирәк. Безнең барыбыз да урта-югары белем алган, укый-яза беләбез, безнең барыбыз да язучы, кемдер әдәби әсәр яза, кемдер мәкаләләр яза, кемдер донос яза — барысы да язучы. Әдип булыр өчен таләпләр күп. Әдип югары кимәлдәге әсәрләре өстенә акыл иясе, халыкның язмышын кайгыртырдай куәт иясе булырга тиеш. Әдәпле, әхлаклы, миһербанлы, батыр көрәшче булырга тиеш.

— *Берничә әдипнең исемен атап китә аласызмы?*

— Тукай, Такташ, Дәрдемәнд, Галәү, Ибраһимов, Туфан, Сибгат, Аяз, Рәшит Әхмәтҗаннар — әдипләр. Әдипләр белән киңәш итмичә, илбашы да катлаулы мәсьәләләрне үзе генә хәл итәргә тиеш түгел. Менә кем ул әдип! Язучылыктан әдиплеккә күтәрелгәннәр әнә шундый абруйлы булырга тиеш. Без газета битләрендә «әдип» сүзен теләсә кайсы язучыга тагабыз. Кадерсезләмик ул олуг сүзне. Кулга алынганга чаклы уртакул язучы булып йөргән Ибраһим Салахов бер әсәре белән әдип булды. Чөнки аның «Тайгак кичү» әсәре татар халкының ачы язмышы турында язылган.

— *Бармы бүген андый әдипләр?*

— Бар. Сез аларның халык өчен җан атканнарын телевизордан да, матбугат битләрендә дә гел күрәсез, радиодан ишетәсез. Ләкин алары салмак, сабыр. Аларны мәрттән уятырга иде.

*— Син, Батулла ага, шагыйрьләр турында, сәнгатькәрләр турында байтак кына нәсерләр язган кеше, кыскача гына үзеңнең күңелеңә хуш килгән авторлар турында бер-ике сүз белән холыкнамә биреп узмассыңмы икән? Әйтик, исеме бая телгә алынган Рәшит Әхмәтҗан турында. Шәп шагыйрь бит!..*

— Әйдәгез, алдан ук килешеп куйыйк. «Шәп шагыйрь» гыйбарәсе булгач, «начар шагыйрь» гыйбарәсе дә яшәргә хаклы килеп чыга. «Начар» булгач, «шагыйрь» була алмый инде ул. Димәк, «шагыйрь» сүзе ул «шәп»нең игезәге, шуңа күрә без бары тик «шагыйрь» дип кенә сөйләшергә, язарга тиешбез кебек. Әлбәттә, шагыйрьләрнең барысы да бертигез була алмый. Бәс, бәлки, аеруча кантарлы талант ияләре турында «Шагыйрь» дип баш хәрефтән язаргадыр?

*— Хәер, бу бит артык мөһим мәсьәлә түгел. «Шәп шагыйрь» дип язарга буладыр, минемчә, ә менә, чыннан да, «начар шагыйрь» тәгъбирен кулланмаскадыр.*

— Әйе, Рәшит Әхмәтҗан — нәфис шагыйрь; шәхес буларак — сабый; кешегә зыян салырлык тамчы да мәкере юк бәндә; ярдәмчел кеше; аның күңел хәзинәсендә башка байлык булмады. Рәшит Әхмәтҗан — тел сәнгатендәге композитор. Аның иҗаты — музыка. Мәрхүмнең урыны җәннәттә булсын!..

*«Шәһри Казан» газетасы.— 2003. — 28 март*

# Сөенечләр бүлешү

Фәнис Яруллин

Фәнис!
Туган көнең җитте.
Сине дөнья
Бар булганы белән кадерләр...
Мин тумаган шигырьләрне уйлыйм,
Шулар белән генә җиргә кат-кат
Туа ала, дустым, шагыйрьләр.
Туа торыйк әле, җыр булыйк,
Киләчәккә барып кушылыйк.

*Рәшит*
*1989, 12 август*

Шагыйрь Рәшит Әхмәтҗанов белән язмыш безне гел бер тирәдәрәк йөртте. Бер үк районда туганбыз: ул Баулы районының Татар Кандызы авылында, мин – Кызылъярда. Бәлки, әле районда очрашырга да туры килгәндер, ләкин ул чагында бер-беребезне белмәгәнлектән, очрашсак та, Такташ әйтмешли, «беребез кара чәчле, беребез сары» чәчле малайлар сәлам бирешеп тормаганбыз һәм киләчәк безне берәр вакыт очраштырыр дип уйламаганбыздыр. Ләкин язмыш Кандыз суын эчеп үскән малайны Ык суында коенып үскән малай белән шигърият диңгезендә очраштырырга уйлаган икән.

Беренче мәртәбә мин Рәшит Әхмәтҗановны 1963 елның февралендә солдат киемендә күрдем. Мин ул вакытта Казан шәһәренең Горький урамындагы ортопедия һәм травматология институты дип аталган хастаханәдә дәваланып ята идем. Рәшитнең армиядән ялга кайткан вакыты булдымы икән, дөресен генә әйтә алмыйм, бәлки, язучыларның ниндидер съезды яки семинары булып, Рәшитне шунда чакырган булганнардыр. Хәер, анысы мөһим түгел, эш шунда: кыска гына ял вакытында мөмкинлек табып, ул минем хәлне белергә килгән иде. Минем ул чакта шигърияткә ургып бәреп кергән, хәтта бераз үз-үземә гашыйк булып, «менә мин кем!» дип яткан вакыт. Төрле газета-журналларда әледән-әле шигырьләрем чыгып тора. Яныма


**Кар өстенә утырып тамак ялгау...**

килүчеләр дә күп. Рәшитнең исемен ишеткәләгән бар, ләкин үзен күргән һәм шигырьләрен укыган юк. Хастаханәләрдә бары тик русча газеталар гына алдыралар, татар газета-журналларын яныма килеп йөрүче дуслар гына китергәләштерә. Ләкин күпләрнең башына «авыру кешегә газета-журналлар кирәктер» дигән уй килми. Ә мин, бер елга якын армиядә хезмәт итеп һәм тагын

бер ел хәрби госпитальләрдә аунап, татар телен сагынган, сагыну гына түгел, аңа тәмам сусап кайткан кеше, туган телемдә чыккан һәр китапка, һәр газета-журналга ташланырга торам. Ә инде каләмдәш дуслар килсә, ул көн минем өчен күңел бәйрәменә әйләнә иде.

Рәшит Әхмәтҗанов килгәндә, мин дусларым китергән китапларга күмелеп ята идем. Солдат киеме киеп кергән Рәшитнең: «Синең янга керүе министр янына керүдән дә авыррак икән»,— дип төрттереп әйтүе генә хәтердә. Тагын шунысы истә: аның буй-сынына солдат киеме бик килешеп тора иде. Ул минем белән сөйләшкән арада, нәрсәдер кинәт исенә төшкәндәй, урыныннан сикереп торып йөренергә тотына. Әллә урындык ошамыймы, аны бер читкә этеп, идәнгә чүгәли. Минем алай чүгәләп утыручыны беренче күрүем. Гаҗәпләнеп карыйм. Ә ул, палатага сыеша алмагандай, тагын сикереп тора, янә килеп чүгәли. Бераздан ул, тумбочка өстендә яткан шигырьләр дәфтәремне алып: «Укырга ярыйдыр бит?» — дип, минем «әйе» дигәнне дә көтмичә, шигырьләремә чума. Шигырьләремә карата фикерен әйткәнен хәтерләмим. Мин ул чакта һәр көнне диярлек берәр шигырь яза идем. Ә палатада 14 авыру, һәр кешегә дусты яки туганы гына килсә дә, берьюлы 28 кеше җыелабыз. Рәшит килгән көнне, күрәсең, палатабыз умарта күчедәй шаулап торгандыр, ул: «Бу шигырьләрне кайчан язасың соң?» — дип сорады. «Төнлә!» — дидем мин. Ул башын чайкап куйды һәм, гимнастёрка кесәсеннән авторучкасын алып, минем шигырь дәфтәремә нидер яза башлады.

Мин моңа аптырамадым, чөнки яныма килгән кызлар-егетләр арасында каләм тибрәтүчеләр дә булгалый, һәм анда миңа багышлап берәр шигырь язгалап киткәләүчеләр дә очрый иде. Әле хәзер дә кемнеке икәнлеге билгеле булмаган шигырьләр бар минем ул дәфтәремдә.

Язып бетереп дәфтәремне өстәлгә куйгач, Рәшит: «Мин киткәч укырсың!» — диде.

Ул киткәч, дәфтәремне ачып карыйм. Анда түбәндәге шигырь язылган һәм Рәшитнең имзасы салынган иде.

## *Фәнис дустыма*

Гаҗәпләнмә, дустым, бүген монда...
Кайчак шулай ятим каласың,
Бәхет димә,
Ул да кайчак суык далаларда
Ташлап китә үзенең баласын.

Кайчак шулай
Корыч белән бергә сыналасың,
Корыч белән бергә сынмыйсың.
Соңгы шырпың калгач далаларда,
Гарьлегеңнән аны сызмыйсың.

Шундый горурлык нәкъ кирәк безгә,
Шундый горурлык —
Шулай яшәмәсәк,
Җиңеп яшәмәсәк,
Егетләргә башка бәхет юк.
Суык далаларда ялгыз калсаң,
Соңгы шырпың калса,
Сызмый җиргә ташла син аны.
Барыбер ул шырпы белән түгел,
Йөрәк белән генә
Җылыта алабыз ич дөньяны.

*1963, февраль*

Рәшитнең әле ул чакта, гәрчә иртә яза башлап, аерым шигырьләре күмәк җыентыкларда дөнья күрсә дә, үз китабы чыкмаган иде. Миңа бүләк иткән шигырен берәр блокнот битенә генә язса, мөгаен, ул югалыр иде. Шуны алдан күрептер, Рәшит үзенең беренче автографын минем шигырь дәфтәремә язды.

Дөресен әйтергә кирәк, бу шигырь миңа ошап җитмәде. Беренчедән, «сындырылган» юллы шигырьләрне бик өнәп бетермим, икенчедән, әлеге шигырьдәге фикер күңелемдә бәхәс уятты. Ничек инде, «суык далаларда ялгыз калганда», соңгы шырпыңны сызмаска кирәк?! Бер шырпы белән учак ягарга һәм ул учакка туктаусыз утын өстәп торып, аның белән озак-озак җылынырга мөмкин түгелмени?! Ә ул әнә:

Шундый горурлык нәкъ кирәк безгә,
Шундый горурлык.

Шулай яшәмәсәк –
Егетләргә башка бәхет юк,–

дип яза.

Минем дә бит шигырьләрем нәкъ җиңеп яшәү, горур яшәү хакында. Ләкин үзең җиңү – бер нәрсә, ә менә дөньяга әз генә булса да үзебездән яктылык өстәү өчен горурлыгыңны бер якка куеп, соңгы шырпыңны сызарга, шуның белән, һич югы, бер учак тергезеп, юлчыларга утлы күмер күмеп калдырырга кирәкмимени?!

Мин әнә шундый уйлар өермәсендә озак кына бәргәләнеп яттым. Шигырен үзе киткәнче укыган булсам, Рәшит белән, бәлки, бәхәскә дә кереп киткән булыр идек. Ул, мөгаен, шуны күз алдында тотып: «Мин киткәч укырсың»,– дигәндер. Хәйләкәр икән, шайтан. Үзе миннән өч яшькә кече – «салага» гына бит әле.

Рәшитнең шигыре, ул чакта шундыйрак уйлар тудырса да, әкренләп онытылды. Ул шигырь дәфтәрем тулып килә иде, бүтән дәфтәр ачылды. Рәшит белән яңадан хастаханәдә түгел, башка шартларда очраша башладык. Без Янка Купала урамында торганда да, Мусин урамына күчкәч тә, фатирларыбыз бер тирәдәрәк, хәтта бакчаларыбыз да бергә иде. Очрашкан вакытларда әдәбият, тел, милләт турында сүзләр булмый калмагандыр. Кемнеңдер яңа чыккан әсәрен «чәйнәп» атасың, кайсыдыр язучының теге яки бу сыйфатыннан көлеп, берәр мәзәк сөйләп ыргытасың. Җитәкчеләрнең тетмәләрен тетеп ташлыйсың. Ә үзебезнең иҗат хакында – ләм-мим...

Рәшитнең миндә алты автографлы китабы бар.

Менә 1965 елда Татарстан китап нәшриятында чыккан «Хыялларым үзем белән» дигән китабына болай дип язган ул: «Фәнис дустым! Сиңа зур иҗат шатлыклары теләп, озын гомер теләп, Рәшит. 19.02.66».

Күп кенә автографлы китаплар миңа февраль аенда бүләк ителгән. Туган аем февраль булгангадыр, күрәсең. Ләкин туган көнем паспортта 9 ы, элекке язучылар исемлегендә 13 е, әни әйтүе буенча, 23 февраль дип язылган. Үзем дә кайсы дөрес икәнлеген белмим. Шуңа күрә февральнең тугызыннан башлап ай ахырына кадәр туган көнем белән котлыйлар. Рәшит Әхмәтҗановның да бу китабы миңа туган көн бүләге буларак бирелүе мөмкин. Китапларын ул һәрвакыт: «Мин чыгып киткәч укырсың»,– дип бирә иде. Билгеле инде, китапны кеше барында укып утырып булмый. Шигырь ул – ялгыз калгач уйланып укый торган нәрсә. Өстән-өстән генә укып, ашыгып фикер әйтмәсен, диюе булгандыр Рәшитнең. Тәнкыйтьне, һәрберебез кебек, ул да бик авыр «йота» иде. Ә безнең язу стильләребез бер-беребезнекенә охшамаган. Ул минем әйберләрне өнәп бетермәгәндер, мин – аныкын. Бер-беребезнең әсәрен макташкан чак сирәк булгандыр.

Рәшит минем дәфтәргә язган шигырен экспромтом гына уйлаган һәм үзе дә оныткан булгандыр, күрәсең. Утыз елдан артык аралашу дәверендә Рәшит бу шигыре турында бер генә мәртәбә дә сүз кузгатмады. Әгәр иске дәфтәрләремне актармасам, минем дә ул исемә төшмәс иде. Чөнки еш аралашкан кешеләр хакында артыгын уйланып утырмыйсың, һәр очрашу гадәти әйбергә әйләнә. Ә Рәшитнең холкы бик үк җиңел түгел, ул бер сүзне башлап җибәрә дә кинәт икенчесенә күчә. Аның фикер сөрешенә җайлашып өлгереп булмый.

Рәшитнең китаплары бик еш чыкмый иде. Бер жанрда гына эшләгән һәм шуңа үзенең бөтен көчен, бөтен мөмкинлеген салган иҗатчы бик күп эшли алмагандыр. Аннары бездә эшләгәненне күрергә теләмәү чире дә элек-электән яшәп килә. Миңа язып бирелгән икенче китабы «Җан яктысы» дигән исем белән 1980 елда Татарстан китап нәшриятында чыккан.

«Нурсөя белән Фәнискә – иң изге теләкләрне теләп, Рәшит. 13.03.81».

Бу китабы аның икенче генә китабы түгел, әлбәттә. Мин үземә бүләк ителгән китаплар турында гына сүз алып барам. 1985 елда дөнья күргән «Кавышыр көн» дигән китабына да ул шундый ук теләкләр язып биргән: «Фәнис белән Нурсөягә – бөтен изгелекне теләп, бергә-бергә шигырьләр язып, бик озак язып, шәп яшик әле бу фани дөньяда. Рәшит. 1985».

Ә менә «Йөрәк бәйрәме»нә (Татар. кит. нәшр., 1988) мондый юллар язган: «Нурсөя белән Фәнискә – шигъриятнең үзе булып калганчы яшик әле. Рәшит. 24.04.88».

Чынлап та, Рәшит Әхмәтҗанов шигъриятнең үзе булып калганчы яшәде. Гомер озынлыгын еллар белән түгел, эшләгән эшең, киләчәк буынга калдырган өлешең белән үлчәсәң, Рәшиткә карата: «Ул тормышта үз миссиясен үтәде»,— дияргә мөмкин.

Гадәттә, шагыйрьләр үз әсәрләрен, журналда яки китапта басылып чыкканчы, башка каләмдәшләренә күрсәтмиләр. Рәшит тә шундый иде. Ул «Карачкы» поэмасы белән озак азапланды. Поэма зур күләмле әсәр иде. Рәшитнең «Казан утлары» журналында эшләп йөргән чагы. Поэмасын машинкада бастырып алганнан соң, ул аны берничә кешедән укыткан. Кульязма инде тәмам чуарланып беткән. Көннәрдән бер көнне алар Луиза ханым белән безнең бакчага килделәр. Күрәсең, Рәшит поэмасын бакчада эшләп бетерермен дип уйлагандыр. Ләкин эшлисе килми, чөнки ул аңардан туйган, арыган. Минем үземдә андый хәл еш булып тора: әсәрне яза-яза тәмам сыгыласың, баш эшләми башлый, ул барып чыкмагандыр кебек тоела, үз-үзеңә ышанычың бетә. Әгәр инде аны укып тискәрерәк фикер дә әйтсәләр, кулдан тәмам каләм төшә. Рәшит үзенең «Карачкы»сы белән шундый төшенкелек хәленә килгән иде. Әлбәттә, поэмасын миңа күтәреп килүе мине үзеннән шәбрәк шагыйрьгә санаудан түгел, аның өчен иң зур шагыйрь бары тик үзе генә иде. Бу сүзләрем белән Рәшитнең рухын рәнҗетергә теләмим, без барыбыз да иң зур шагыйрь дип бары үзебезне генә саныйбыз.

— Менә моны укып кара әле, дустым,— диде ул, кульязмасын биргәндә, һәм поэмасына карата начар фикер әйтүчеләрне берәм-берәм озак кына сүгеп утырды.

Рәшит моңа кадәр «Аучылар кибетендә» һәм «Бишташ» кебек бик оригиналь фикерле поэмалар язып, бу поэмаларына карата матур-матур бәяләр ишеткән шагыйрь булганлыктан, «Карачкы»сына мондый мөнәсәбәтне күтәрә алмый иде булса кирәк.

— Мин бит поэмалар остасы түгел, ул эштә кулын шомарткан берәр шагыйрьгә биреп кара,— дип, поэмасыннан баш тартырга теләсәм дә, ул, ай-ваема карамыйча, поэмасын минем алдыма салды. Сызылып, өсте-өстенә языылып беткән кульязманы уку, аннан да бигрәк шагыйрьнең фикер сөрешенә төшенү авыр иде. Ул, гомумән, күренеп торган сюжетлы поэмалар язмый, ә сюжетсыз әсәрдә шагыйрьнең ни әйтергә теләгәнен аңлау бик читен. Укып барганда, һәрбер строфа шундый әйбәт, шундый образлы, хәтта аерым-аерым алсаң, һәрберсе мөстәкыйль шигырь булып китәрлек, ә кушып укыдыңмы — эзлеклелек югала. Прозада Мөхәммәт Мәһдиев шулайрак яза иде. Ул повесть-романнарында теге яки бу персонаж турында берничә җөмлә, берничә деталь белән бик колоритлы образ тудыра да соңга таба бу персонаж хакында бөтенләй оныта. Күрәсең, сюжетсыз әсәр язган шагыйрь һәм әдипләрнең әсәрдәге эзлеклелекне хасил итүче мантыйк аларның күңелендә генә кала, һәм ул аны кәгазьгә төшерүне кирәк санамыйдыр.

Рәшит Әхмәтҗановның «Карачкы»сын мин атна буе укыдым. Дөресен әйтергә кирәк, беренче кат укыганда, ул миңа бөтенләй ошамады. Кабат-кабат укыгач кына, шагыйрьнең тел төбенә төшенә башладым. Рәшит бу поэмасында Әмен исемле төрек кызына өйләнеп кайткан һәм шуның аркасында «төрек», соңрак «карачкы» дигән кушамат алган татар егетенең язмышын, аның фаҗигаләрдән торган үткәннәрен, әрнүле, үкенүле, каргышлы һәм кадерсез гомерен, ил һәм милләт язмышын сурәтли. Поэмада илнең Октябрь инкыйлабыннан соңгы чорларын киң масштабта яктыртырга омтылыш бар. Һәр строфада — Рәшиткә генә хас образлылык.

Хәтердә ялтырап яталар
Сөякләр сибелгән ул юллар:
Мең еллык тарихын кочаклап,
Ачлыктан үлделәр авыллар,—

дип яза ул, егерме беренче елгы ачлыкны искә төшергәндә.

Поэманы укуны дәвам итәм. Минем карашка, анда, бер язмыш кысаларына гына сыеша алмыйча, «бүселеп-бүселеп» чыккан урыннар күп. Бәлки, шуңа күрә дә миңа кадәр поэманы укыган шагыйрьләр «бу икенче операдан», «монысын икенче әсәреңә кертерсең» кебегрәк тәкъдимнәр язып куйганнардыр. Рәшитнең алар белән килешәсе килми, әлбәттә. Мин аның күңелен аңлыйм: ул бөтен дөньяны колачламакчы. Гадәттә, яза башлаганчы, күңелдә әсәрнең бер гомуми

планы – сюжеты туа. Йөри-йөри, уйлана-уйлана, фикерләр калыплана. Әмма язу процессында алдан уйланган фикерләр бик нык үзгәреш кичерә, әсәр киңәя, ярларына сыеша алмыйча, ургылып аккан язгы елгага охшый башлый. Кайсы детальне алып ташласаң да җәл тоела. Дөньяны киңрәк колачлау, масштаблырак итү теләге шулкадәр көчле була ки, алынган темаң белән җаның каршылыкка керә һәм, телисеңме-юкмы, алдан уйланган эзлеклелек югала. Ләкин автор ул эзлеклелекнең югалуын үзе сизмәскә мөмкин. Шуның аркасында әсәр таркаулана. Ә чит кеше бу таркаулыкны күрә, чөнки ул кәгазьгә төшкән фикерләрне генә укый. Автор күңелендә ниләр кайнаганын белми. Үз әсәрен төзек сюжетка кормаган авторлар бер вакыйгадан икенче вакыйгага кинәт сикереш ясыйлар. Укучы ул вакыйгалар арасында бушлык күрә. Шагыйрьнең фикер җебен тота алмый. Авторның күңелендә исә бушлык, упкыннар булмый, чөнки ул вакыйгаларны үз фантазиясендә кабат-кабат тудырган, дөньяның бер чите белән икенче читен үзе генә белгән хыял җепләре белән бәйләгән һәм кәгазьгә төшкән әсәрен әйтелми калган фикерләре белән бөтенләндереп күрә. Укыганда, әнә шуларны кушып укый.

Рәшитнең «Карачкы» поэмасында упкын аша сикерүләр, шул ук вакытта, укыганда күзгә бәрелеп, күңелгә тиеп, «мин монда ялгыш кердем» дип кычкырып торган урыннар күп иде. Шуңа күрәдер инде моны укыган кешеләрнең фикере каршылыклы, һәм, печән кибәнен куйганнан соң ян-якларын бәргәләп, бүселгән җирләрен тигезләп чыккан кебек, әсәрнең төп вакыйгаларын бер фокуска туплау кирәк иде. Рәшит аны соңыннан шулай камилләштерә алды.

Билгеле, һәр шагыйрьнең, һәр әдипнең үз стиле, үзенең язу үзенчәлеге була. Шагыйрьләр асылташ эзләүчеләр кебек. Кемдер үзе тапкан асылташны иҗат станогында бик каты эшкәртеп, ялтыратып бирә. Андыйларның асылташына учыңа алуга ук сокланасың, бөтен матурлыгын берьюлы күрәсең. Икенче берәүләр асылташны эзләп таба, әмма аны артык эшкәртеп тормый гына башкаларга тапшыра. «Мә,– диләр алар,– йөрәгеңә салып, менә бу асылташны эшкәрт. Җаныңда яктылык бар икән – ул җемелдәми калмас. Йөрәк сандалында эшкәртеп, күңел яктылыгыңны бирә алсаң гына, син аның матурлыгын күрерсең».

Рәшит Әхмәтҗановны мин (бәлки, ялгышамдыр) әнә шул икенче төр шагыйрьләр рәтенә кертәм. Сүземне раслау өчен бик күп мисаллар китереп тормыйм, «Карачкы» поэмасыннан бер строфа күчереп үтү белән канәгатьләнәм. Ни өчен нәкъ менә шушы строфаны алуымның сәбәбе бар.

Иң кыйммәте җирдә – җан җылысы,
Җан җылысы җитми туңабыз.
Хәятыңны күләгәләр күмсә –
Каның янсын! Барыбер ут кабыз!

Әлеге строфада шагыйрьнең кайчандыр минем дәфтәремә язып киткән:

Суык далаларда ялгыз калсаң,
Соңгы шырпың калса,
Сызмый җиргә ташла син аны.
Барыбер ул шырпы белән түгел,
Йөрәк белән генә
Җылыта алабыз ич дөньяны,–


дигән шигъри юллар белән фикер уртаклыгы, образ охшашлыгы ярылып ята түгелме соң? Тегендә дә, монда да дөньяны җылыту турында сүз бара, ә аның өчен «каның яну, җаның яну» кирәклегенә басым ясала. Ә бит шигырь белән поэма арасында егерме биш елга сузылган вакыт ята. Бу – шагыйрь Рәшит Әхмәтҗановның шигърияткә килгәндә үк инде ныклы бер фикере, укучыларына әйтер сүзе барлыгын һәм гомере буе үз күңеленә тугрылыклы булуын күрсәтә.

Әйе, шагыйрь Рәшит Әхмәтҗанов гомере буе дөньяны йөрәге белән җылытып яшәргә омтылды. Ул, үзенең йөрәк утын күтәреп, митингларга чыкты, «ачлык мәйданнары»на иреккә сусап килгән фидаи җаннарга өләште, җан җылысыннан, йөрәк утыннан баш тартучыларга яки күрмәскә теләүчеләргә чын-чынлап рәнҗеде, һәм менә шушы ут аның үзен дә, бөтереп алып,

арабыздан алып китте. Әмма ул кабызып калдырган учаклар һаман дөрли, һаман яна. Аның әледән-әле чыгып торган китаплары шагыйрь йөрәгенең юкка янмаганлыгын, җан кыйбласының дөреслеген сөйли.

«Моңлану» (Татар. кит. нәшр., 1991) дигән китабына ул, бераз тыйнакланып, болай язган: «Нурсөя, Фәнис! Сандугач булып сайрап булмады инде, Рәшит. 13.08.91».

Ә бит ул үзенең сандугач булып сайрый алганын белә иде. Кайвакыт шагыйрьләрдә, язучыларда үз-үзенә ышанмау туа. Мин моны үземнән беләм. Әсәрне язганда илһамланып, рухланып язам да, язып бетергәч, ул рәтле чыкмаган кебек тоела башлый. Әсәрең журналда яки китапта басылып, берничә кеше тарафыннан хуплау сүзе ишеткәч кенә, эчкә җылы керә, үз-үзеңә ышана башлыйсың. Күрәсең, Рәшит ул чорда иҗатын хуплау тапмагандыр. Аны бит (хәтерем ялгышмаса, шул елларда) Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә дә тәкъдим иткәннәр иде. Гадәттә, мондый зур бүләккә тәкъдим ителүчеләр иҗатына игътибар арта, матур-матур мәкаләләр чыга. Ә Рәшиткә карата андый мәкаләләр аз чыкты. Үзе турында минем язуымны сораган иде, баш тарттым. Чөнки үзем зур күләмле әсәр язып ята идем.




Рәшит Әхмәтҗановның миңа бүләк иткән соңгы китабы «Ачлык мәйданы» (Татар. кит. нәшр., 1993) булды.

«Фәнискә. Әйдә, Фәнис, алга, алга,
Алтмышка таба. Рәшит. 17.04.94».

Республикабыз, суверенитет яулап, мәйданнарда зур-зур митинглар ясап йөргәндә, Фәүзия Бәйрәмова кебек батыр җанлы әдипләр Президент сарае каршында уттай эссе көннәрдә ачлык игълан итеп яттылар. Алар арасында Рәшит Әхмәтҗанов та бар иде. Соңрак ул, шунда кичергән тәэсирләргә таянып, шушы китабын чыгарды. Китап юка, начар кәгазьдә басылган, тышлыгы да катыргы түгел. Спонсор ярдәме белән чыкканга күрә, гонорар урынына китапларын гына биргәннәр. Ул аларны Тукай музеена да, үзебезнең Баулы районына да кайтарып куеп карады. Ләкин алырга ашыкмадылар. «Чын шагыйрьне үлгәч кенә таныйлар»,— дип тынычландыра иде ул күңелен.

Дөрестән дә, Рәшит вафат булгач, матбугат битләрендә аның турында саллы-саллы мәкаләләр чыкты. «Рухият» нәшриятында бик затлы тышлыкта, әйбәт кәгазьдә «Сайланма әсәрләре» дөнья күрде. Рәшит танылды. Инде рухы тынычтыр.

*«Мәйдан» журналы.— 2003. — № 2*

# Казан кичләре

Асия Юнысова

Шәм яндырып, шигырь укый Казан. Кышның соңгы ае, артык йомшаклыгы өчен ояла-ояла, соңгы юеш карларын Казан урамнарына сипкән кичләрдә башкаланың Камал исемендәге һәм Тинчурин исемендәге театры биналарында шигырь кичәләре узды.

Шагыйрь Рәшит Әхмәтҗановка 60 яшь узган елның апрелендә тулган иде. Ләкин яхшы эшнең иртә-киче булмый дигәндәй, бу олуг юбилей быел уздырылды. Бу эштә, әлбәттә, Дәүләт Советының, Язучылар берлегенең, Баулы районы хакимиятенең өлеше бик зур булды. Язучылар берлеге рәисе Фоат Галимуллин кулындагы гөлләмәсен язучының толы Луиза ханымга тапшырганнан соң сәхнәгә күтәрелгән Баулы районы хакимияте башлыгы урынбасары Мансур Абдуллинның мәгънәле сүзләрен күңел булып тыңладык. Баулылар данлы якташларының кадерләрен дә, хәтерләрен дә саклый беләләр. Рәшит Әхмәтҗановның Тукай кабере янәшәсендәге кабере һәрвакыт тәрбиядә торуы белән игътибарны гел җәлеп итә.

Үлгән шагыйрьләрнең иҗатын онытмау иң зур бәяләү инде ул. Кичәнең сценариен язучы Рабит Батулла, режиссура ягын артист Илдар Хәйруллин эшләгән. Күрәсең, бу эшкә Камал театры артистлары ныклап алынгандыр. Чөнки сәхнәдә композиция ясап урнашкан шигырь укучылар да Камал театры артистлары булды. Алар шагыйрьнең шигырьләрен яттан, зур пафос белән сөйләде. Сценарий авторының улы Нурбәк Батуллинның шигырь укуын бик яраттык. Исеме аталмаса да, кичәнең буеннан-буена лейтмотив булып композитор Мәсгудә Шәмсетдинова көйләре уйнап торды. Шагыйрь белән күп еллар хезмәттәшлек иткән композитор ул. Икесенең иҗат җимеше булган җырлары да күп.

Студент чакларда без Рәшит Әхмәтҗановның – күрше бүлмәдә яшәгән егетнең – «Акчарлаклар» җырын бөтен тулай торак белән җырлый торган идек. Аннары инде «Сандугач керде күңелгә» дигәнен татары-башкорты бердәм җырлады. Айдар Фәйзрахманов репертуарындагы җырларны күңелләргә уеп салырлык итеп, әлбәттә инде, Айдар гына җырлый ала иде. Айдар һәм Фердинанд репертуарындагы җырларны кушылып җырлыйсы түгел, тыңлыйсы гына! Кичә бит шагыйрьнеке. Шуңа күрә шигырьләр күп булды. Шигырьләр аша шагыйрь образы күңелләрдә яңартылды.

Тукай бүләге лауреаты Илдус Әхмәтҗанов бу кичне абыйсын алыштырган иде. Сценарий буенча шулай каралган. Ләкин экрандагы фильмда Рәшит абыйның үзен күргәч, аның шигырь укуын ишеткәч, аерманың ничек зур икәнен, артист белән шагыйрь арасындагы дистанцияне күрәсең. Шагыйрь образын иң тулы ачканы шагыйрь Зөлфәт шигырь-поэмасындагы шагыйрь Рәшит Әхмәтҗанов персонажы булды бугай. Шагыйрь күңелен, ярсуларын аңлар өчен, шушы шигырьне тыңлау кирәк иде. Яфрак сулышын да тоя торган сизгер шагыйрь күңелен икенче шагыйрь генә шулай тоя ала.

Сәхнәдәге зур шәмдәлләрдәге шәмнәрнең мае яна тора. Гүяки шагыйрьләр йөрәге сыза. Зал шигырьләрдән күчкән энергия белән һәр күзәнәгенә дәрман җыя. Соңгы шигырьләр укылганда, мең кешелек зал аягүрә баса.

Татар тарихына – нокта идек.
Хәзер Галәм күрә.

Без яшәсәк кенә – коллык үлә,
Басыйк аягүрә.

Бу кичне ун ел элек булган вакыйгалар янәдән яңарды. Бәлки, шуңадыр да минем күңелдәге бер ризасызлык корты җанны һаман кимерде. Рәшит Әхмәтҗановның иҗатын болай гына ачып бетерә алмадык әле кебек. Әйтик, нигә сценарийны блоклап эшләмәскә иде? Якташлары чыккан блокта туган яклар моңы яңарса, икенче блокта Рәшит Әхмәтҗанов иҗатындагы иң еш сайраган кош – сандугач уртадарак торыр иде. Бәлки, шушы блокта ук шагыйрь бабасы каләм тоткан кулы белән бишектә тирбәтеп үстергән, инде татар гимназиясенең бишенче сыйныфында укып йөрүче Наилә бабасының китабыннан ятлаган шигырьләрен укыр иде. Ул Нурбәктән ким мәллә!

Өченче блокта ул кичне бик күп яңгыраган трибун шигырьләрнең язылуына шаһит булган «Ачлык мәйданы» каһарманнары сәхнәгә тезелеп утырса ни дияр идең?! Бар иде алар залда. Газинур Морат, Әхәт Мушинский, Зәки Зәйнуллин, Заһит Мәхмүди... Аннары шагыйрьнең гомере үткән «Казан утлары» журналы шагыйрьләрен – Рәдиф Гаташны, Равил Фәйзуллинны сәхнәдә күреп, замандашлары фикерен ишетер идек. Ләкин болар урынына безгә бик үк ышандырмаган интервьюлардан өзекләр озак-озак итеп укылды. Дөрес, сценарий авторының нияте бик изге иде. Бүгенге сәясәткә халык яраткан шагыйрь бәясен ишеттерү дә кирәк булгандыр. Тукай бүләге бирү турындагы фәлсәфәне газета битләренә мәкалә итеп әзерләп биргәндә отышлырак та булган булыр иде әле.

Теге блокларны санап үтүемне нигезләп тә карыйм әле. Сандугачлы шагыйрь Рәшит Әхмәтҗанов бу күчешне үзе болай аңлата:

Яшәр генә чагым иде
Сандугач кебек сайрап.
Булмады! Бабамнар кебек
Утырам кылыч кайрап.

Әйе, татарның каләм тоткан кулына кылыч алган шагыйрьләре белән тарихы язылган. Бу хакта икенче бер шагыйрь Роберт Миңнуллин кичәдән соңгы әңгәмәдә болай диде: «Әгәр Казан ханлыгы чорында яшәсә, Рәшит Әхмәтҗанов Кол Шәриф үлеме белән үләр иде. Гражданнар сугышы вакытында яшәсә, аны Бабич үлеме көтәр иде. Шәхес культы елларында Хәсән Туфаннар кебек төрмә камераларында ятар иде, Бөек Ватан сугышында һәлак булса, бу дөньядан җәлилчеләр үлеме белән китәр иде».

Ачлык мәйданына анда утыручыларның хәлен белергә барганда, кулындагы тәмәкесе кебек көеп беткән Рәшит абый мондый шигырь укыган иде миңа:

Ә син, дус, кызганма мине,
Без – үлми торган халык.
Булмагач булмый икән ул
Халыкның җанын алып.

Әнә шундый оптимизм иде безнең күңелләрдә моннан унбер ел элек. Февральнең соңгы көне быел ул өметләрнең канатын шактый шиңдерде. Ләкин әле халкыбыз каһарманнары күз төбәгән аклык шәүләсе офыкта һаман калды. Шагыйрь сүзләре белән уяулыкка чакыру барыбер кирәктер:

Ялган булып су төбенә батасы бар,
Әгәр хаклык өскә калкып чыкмаса.
Дошман таптар каберләрдә ятасы бар –
Халкым болай бер-ике ел йокласа.

Искәртәм: бу – 1991 елның маенда язылган шигырь.

***

Кичәләрнең икенчесе бер көннән соң булып, анысы шагыйрь һәм язучы Айдар Хәлимгә 60 ел тулуга багышланган иде. Кызык бит, шагыйрь Рәшит Әхмәтҗанов шул Азатлык мәйданында язылган бер шигыре белән ике шагыйрь язмышы арасында гына түгел, ике шигырь кичәсе арасында да күпер салып киткән:

Каракүз аша син миңа
Шигырьләр юллагансың.
Аннан соң үзеңнән алда
Үләргә кушмагансың.

Рәшит Әхмәтҗанов үлгәндә, дустының җәсәден гүргә индерергә кайтып җитә алмаган Айдар Хәлим шушы шигырьне газета битләрендә укыганнан соң әй инәлгән иде. Тотмаган бит шагыйрь аның әманәт сүзләрен. «Син үлгәндә исән булганмын бит... Ә син — гафу! — китеп котылдың. Бүген — тере үлек! — барчабызның гөнаһлары өчен тотылдым»,— дип язган иде ул «Кара каен әрәмәсе» дигән шигырендә. Бу ике шагыйрь бер-берсен көрәшчеләр буларак та аңлашып яшәделәр. Шул ук «Ачлык мәйданы»на киеренкелек соң чиккә җиткән көннәрнең берсендә киң адымнары белән мәйданны урталай ярып кергән Айдар Хәлимне күргәч, халык көрәшче әләмен югары тоткан кеше янына ташланган кебек тирбәлеп куйган иде. Айдар Хәлим озак еллар дәвамында көрәшә белү үрнәге булып торды. Хәтерлим: әле опера һәм балет театры бинасында Гали Акышның юбилеен бәйрәм итеп утырабыз. Залда шыгрым тулы кеше булса да, көрәш очкыны юк. Ниндидер сүлпәнлек. Чөнки Татарстанга бәйле ниндидер документларның Мәскәүдә хәл ителеп ятканын беләләр. Хәбәрләр уңай да түгел кебек. Сәхнәдән яңгыраган җыр-шигырьләр дә тиешле ялкынны өстәми. Шул чагында сәхнәгә кичәгә соңарган Айдар Хәлим килеп чыкты. Инде йомгакланып барган кичәбез яңадән кабынып, терелеп, ялкыннарын үрләтеп киткән иде.

Айдар Хәлимгә «Дружба народов» журналында басылып чыккан «Язык мой — друг мой» мәкаләсе белән коры тырбызыкка (юка каен тузы) очкын үрләтү дә җиңел генә булмады. Шул мәкаләдән соң телевидение аша кеше карамый торган вакытта оештырылган тапшыруны күреп калу өчен, редакциябез белән телевидение янында дежур торган идек. Аннан соң Балтыйк буенда «Книга печали...» дөнья күрде. Әй ул китапка салынган динамит. Беттемени соң әле ул егәр? Күптән түгел минем эш урыныма нәшрият йорты янәшәсендәге алачык йортта яшәүче бер агай килеп керде. «Табыгыз миңа Айдар Хәлимне»,— диде ул. «Ни эшкә ул сезгә?» — дим.— «Әнә бит, сездән ерак та түгел, учак ягып, «Книга печали» китабын өеп-өеп яндыралар». Мин моны телефоннан Айдар Хәлимгә хәбәр иттем. Чөнки реакция кирәк иде. Телефоннан трибун-шагыйрьнең сулык-сулык елаганы ишетелде. Бу хәбәрне ишеткәч, бөтен халык еласа да аңлар идем мин. Татарга азатлык яулап язылган китапны татар башкаласында яндырсыннар әле!

Кичәгә кайтыйк. Президентыбыз Минтимер Шәймиевнең Айдар Хәлимне котлап язган хаты бик тә тирән эчтәлекле, кешелекле, татарның көрәшчеләренең кадерен аңлап язылган хат иде. Шагыйрь моны үзе дә зур ихтирам билгесе итеп, Президентыбызның олы күңелле кеше икәнлеген аңлап, теле белән әйтеп кабул итте. Халык депутаты Фоат Галимуллин, Мәдәният министрлыгы, Камал театры коллективы котлауларыннан соң рәхәтләнеп шигырьләр тыңладык. Шагыйрь үзе дә, Айрат Арсланов та шигырьләрне гаҗәп матур укыдылар. Сәхнәдә Рөстәм Үтәй җитәкчелегендәге оркестр уйнап торды. Чаллыдан килгән фидакяр җырчы Асия Әхмәтшина Айдар Хәлим сүзләренә язылган җырларны җырлады. «Татарлар, берләшегез!», «Без исән» дигән җырларны тыңлаганда, бу юлы да аягүрә басмый калу мөмкин булмады.

Таш күзеннән җандай чәчрәп чыгып
Әйтү ләззәт икән — без исән!

Шагыйрь Айдар Хәлимгә озын гомер теләп таралыштык. И Ходаем, көрәшче шагыйрьләренә озын гомер бир, аларның җырларына — халык гомере, халкыбызга кояш гомере язсын.

*«Ватаным Татарстан» газетасы.— 2002*

# Сандугач керде күңелгә

Нияз Акмал

25 февральдә Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында күренекле шагыйрь Рәшит Әхмәтҗанны искә алу кичәсе булды.

Рәшит абый белән миңа берничә ел буена, бер бүлмәдә утырып, «Казан утлары» журналында эшләү насыйп булды. Сүземне нәкъ менә эштән башлау юкка гына түгел. Шул елларда мин аның чын-чынлап эш аты икәнен күреп яшәдем, редакциянең көндәлек мәшәкатьләреннән тыш ни рәвешле иҗат итүен, бу фани дөньяның көндәлек борчуларын ничек итеп җиңеп баруын күрдем. Татарстанның мөстәкыйльлеге өчен зур көрәш кайнаган ул көннәрдә «Ачлык мәйданы»на чыгуын, соңыннан «Ачлык мәйданы» исемле тетрәндергеч шигырьләр язуын да күрдем, күреп йөрдем. Әмма әле аңынчы аның шигырьләренә, сүзләренә язылган җырларны тыңлап-җырлап үскән бер яшь егет идем мин. Һәм менә әлеге кичәдә – Рәшит Әхмәтҗанны искә алу кичәсендә – мин аның белән эшләгән, аралашкан елларыма әйләнеп кайткандай булдым. Хәер, бер мин генә кичермәгәнмендер бу халәтне. Шагыйрьнең якташлары, аны зурлап-олылап килгән танышлары, якыннары, дуслары-туганнары, гаиләсе-балалары – һәммәсе шушы халәттә булгандыр дип уйлыйм.



**«Казан утлары» журналы редакциясендә фикер алышу. Сулдан уңга: Рәшит Әхмәтҗанов, Нияз Акмал, Мансур Вәлиев, Зөлфәт, Саимә Ибраһимова, Роза Туфитуллова, Зиннур Хөснияр**



**Рәшит Әхмәтҗанов истәлегенә багышланган кичәдә. Сулдан уңга: Сәгыйть Әхмәтҗанов, Луиза Әхмәтҗанова, Илдус Әхмәтҗанов. Баулы, 1996**

Бу кичәне оештырган һәркемгә – Г. Камал исемендәге театр коллективына, Татарстан Язучылар берлегенә, сценарий авторы Рабит Батуллага, кичәнең режиссёры булган Илдар Хәйруллинга, кичәне алып баручыларга чын күңелдән, чын йөрәктән рәхмәт сүзләре әйтик без. Чыннан да, Рәшит абый үзе язганча, сандугач керде бит күңелгә бу тетрәндергеч, үзәкләрне өздергеч кичәдә.

Рәшит Әхмәтҗан белән якыннан аралашкан, бергә-бергә иҗат итеп яшәгән шагыйрьләр Роберт Әхмәтҗан, Мөдәррис Әгъләм, Зөлфәтнең аңа багышланган шигырьләрен укуы, күренекле җырчыларыбыз Клара Хәйретдинова, Римма Ибраһимова, Айдар Фәйзрахмановларның аның шигырьләренә язылган җырларны башкаруы, Рәшит Әхмәтҗанның җан авазы белән язылган әсәрләре яңгырау – бу гаҗәеп бер истәлек, әчтәлек белән тулган истәлек иде. Әле бит тагын шунысы да бар: кичәдә Рәшит Әхмәтҗанның кайчандыр, үзе исән чакта әйтеп калдырган сүзләре, гәзит-журналларга биргән әңгәмә-интервьюларыннан өзекләр яңгырап барды, һәм аларны шагыйрьнең бертуган энесе, халкыбызның танылган артисты Илдус Әхмәтҗан укыды.

Мин әлеге кичәдән тетрәнеп тә, Рәшит абый Әхмәтҗан өчен ничектер горурланып та, аны өр-яңадан сагынып та һәм, әлбәттә, соңгы вакытларда узган кичә-бәйрәмнәрнең мәгънәсе турында уйланып та кайттым. Ә бик якын бер танышым үзенең фикерен болай дип уртаклашты:

– Бу – бер генә көндә уза ала торган кичә түгел. Бу – шагыйрь хакында, аның язмышы хакында, халык язмышы хакындагы тулы бер спектакль, һәм аны театр кат-кат кабатлап күрсәтергә тиеш...

Менә шундый сагыну, менә шундый юксыну белән узды әлеге кичә. Һәм, кабатлап әйтим, Рәшит абыйның җанлы образы күңелләргә сандугач булып керде, талпынды, ярсынды, талтирәкләрне шаулатып, каннарны кайнарлатты...

*«Шәһри Казан» газетасы.– 2002. – 1 март*



**Гөлзадә Сафиуллина һәм Риф Гатауллин чыгышы. Казан, Тукай клубы, 2016**



**Татар Кандызы авылында Р. Әхмәтҗановка багышланган чараларны һәрдаим оештыручы җырлы-моңлы Әхмәтҗановлар гаиләсе**



**Сулдан уңга: шагыйрьнең апасының кызы Әлфия Хафизова, сеңлесе Сания Фәйзерахманова, аның улы Марат, хатыны Луиза Әхмәтҗанова һәм оныгы Наилә. Казан, Тукай клубы, 2016**




**Р. Әхмәтҗановның җырларын укытучы Розалия Сибгатова башкара. Татар Кандызы, 2016**



**Сәгыйть Әхмәтҗанов «Болгар җирләренә барыйм, дисәң» җырын башкара. Татар Кандызы, 2016**

# Иң азаккы кол

Зәки Зәйнуллин

Рәшит Әхмәтҗанов белән мәйданга 14 май көнне ачлыкка утырдым. Килгән язучыларның кайберләре миңа бәйләнәләр:

– Чыгар Рәшитне ачлыктан! Бетә бит! Болай да сөяк тә тиредән генә тора ул!

Рәшит аларга кул гына селти:

– Халыкны уятырга кирәк! Үлсәм, шушында үләм, китмим.




Эссе кояш астында хәрәкәтсез утыруга караганда печән чабу җиңелрәк. Бер агач кисәге табам да, пәке белән юнып, бер кеше сыны ясыйм. Ике көн тырышкач, максатыма ирешәм. Ясаган сын үзем теләгәнчә килеп чыкты. Ачлыкта утыру истәлеге итеп дустым Рәшиткә бүләк итәм. Көне буе әйләндерде әлеге сынны. Кояш баеп барганда, миңа әйтә:

– Мин бит бу, Зәки абый! Бик яшь мин монда, биттәге, маңгайдагы җыерчыклар да юк!

Икенче көнне сын тагын Рәшитнең кулында – җыерчыклар юк! Чөнки кояшта янып, битнең тиресе җыерчыклар белән бергә сыдырылып төште.

Уйчанланып, сынга карап озак утырды Рәшит. Шуннан әйтте:

– Колларның тиресен тугыз тапкыр туныйлар, диләр. Ә миннән әле бер генә мәртәбә кубып төште. Бер генә! Пүчтәк әле бу! Кайчандыр иң беренче кол булган! Ә мин иң соңгы кол булырга тиеш һәм шулай булуны бик тә телим. Бу мәйданга коллык богауларын челпәрәмә китереп өзәргә тырышучылар җыелганга ышанам мин. Бу халыкны инде башкача тезләндерә алмаслар!

Бирсен Ходай!

*«Һаваларда ялгыз торна» китабы.– Казан. Татар. кит. нәшрияты., 2003. – 269–270 б.*

# Бертуган ике лачын

Рәйсә Фәррахова

Республикада Әдәбият һәм сәнгать елы тәмамланып килә. Без аны беренче чиратта Тукай һәм Җәлил исеме белән бәйләдек, аларны сагынып һәм олылап искә алдык. Тагын бик күп шәхесләребезне хөрмәтләдек, мактаулы исемнәр биреп зурладык. Мәдәниятебезнең үткәне генә түгел, бүгенгесе дә энҗе-мәрҗәннәргә торырлык шәхесләргә никадәр бай булуын танудан зиһеннәребез сафланып калды, күңелләребез горурлык хисләре белән тулды.

Минемчә, тагын ике шәхесне олыламыйча, Әдәбият һәм сәнгать елын һич тә төгәлләргә ярамый. Алар – искиткеч талантлы, гаҗәеп үзенчәлекле Рәшит һәм Илдус Әхмәтҗановлар. Бертуганнар, берсе – шагыйрь, икенчесе – артист.



**Р. Әхмәтҗановның 60 еллыгына багышланган кичәдә Илдус Әхмәтҗанов шагыйрьнең шигырьләрен укый**

Минем авылдашларым алар. Икесенең дә балачак һәм үсмер еллары безнең Кандыз авылында үтә. Яшьтән үк бер-берсенә алмаш, терәк, үрнәк булып үстеләр. Икесе дә 1991 елда бер төркем язучылар, сәясәтчеләр белән, Татарстанның бәйсезлеген яклап, Казанның Ирек мәйданында ачлык игълан иткән. Икесе дә бөек Тукай белән береккән.

Әгәр исән булса, Рәшит Әхмәтҗановка быел нибары 65 яшь тулган булыр иде. Ул, җидееллык мәктәпне тәмамлагач, Бөгелмәдәге һөнәр училищесында белем ала, ташчы һөнәрен үзләштерә. Әлмәттә йортлар төзеп йөри. Аннан – 3 ел армия хезмәте. Хисләр өермәсе белән тулы күңеле белемгә омтыла.

Армия хезмәтеннән соң КДУның татар теле һәм әдәбияты факультетын тәмамлый, аннары баш-аягы белән шигърият дөньясына чума. Мәдәният министрлыгында, «Яшь ленинчы», «Татарстан яшьләре» газеталарында, «Казан утлары» журналында эшли. 1970 елда СССР Язучылар берлегенә кабул ителә. Атаклы шагыйрь булып җитешә. Рәшит Әхмәтҗановның бер-бер артлы «Хыялларым үзем белән», «Җан яктысы», «Кавышыр көн», «Ачлык мәйданы» һ.б. китаплары басылып чыкты. Алар нечкә лиризм, үзенчәлекле сурәтләү чаралары, гражданлык рухы белән сугарылган.

Китапларны берләштерүче тагын бер хис – тормышка чиксез мәхәббәт, яшәү кадерен белү, һәр мизгелгә сөенеп яшәү. Ул гади генә сүзләр белән тирән мәгънәле фикерләр әйтә:

Туган көнемнән үк бәхет биреп,
Азат балам диеп атадың.
Авыр чакларында Кол Гали күк
Колың булыйм, газиз Ватаным.



**Т. Миңнуллин әсәре буенча сәхнәләштерелгән «Без китәбез, сез каласыз» спектакленнән соң**

Нинди генә хис-тойгылар, темалар юк аның әсәрләрендә. Кеше өчен иң бөек зат – әни, газиздән газиз – туган тел, иң олы хис – мәхәббәт, йөрәк парәсе – бала һ.б.

Актык сулышынача гомерен шигърияткә багышлаган шәхесләр сирәктер. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Рәшит Әхмәтҗанов әнә шундыйлардан иде. Андый шагыйрьләрне халыкның йөз аклыгы, аның иманы, вөҗданы, диләр. Бу чыннан да шулай. Ул Казанның Татар зиратында, гасырның мәртәбәле затлары куелган урында, бөек Тукай янында җирләнгән. Ике данлыклы шагыйрьнең янәшә куелуы очраклылыкмы? Юктыр, мөгаен. Аны, «Минем гасыр таңындагы шигъриятемне гасыр азагында менә кем яклар!» дип, Тукай рухы дәшеп китергәндер...

Шагыйрьнең энесе Илдус абый, Ленинград шәһәрендәге Театр сәнгате, музыка һәм кинематография институтын тәмамлаганнан соң, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрына эшкә кайта. Профессиональ сәхнәдәге беренче роле «Ак калфак»тагы Бакый була. Аннары ул сәхнәдә 80 ләп капма-каршы характердагы образлар тудыра. Аның иң зур иҗат җимеше – Т. Миңнуллинның «Без китәбез, сез каласыз» пьесасы буенча эшләнгән спектакльдә Тукай образы булды. Тукайны уйнаганнан соң, халык аны аеруча үз итте, чөнки ул бөек шагыйрьне яңадан «терелтте». Театрның 90 еллык бәйрәмендә Татарстан Президенты М. Шәймиев И. Әхмәтҗановка мактаулы исем бирелү турында таныклык тапшырганда: «Илдусны күргәч, Тукайның үзен күргән кебек булам»,– дигән иде. Ә Туфан Миңнуллин Илдус абый турында: «Тукайга тамыры белән тоташкан»,– диде.

Илдус абыйның театр сәхнәсенә халыкның сөекле улы Тукай булып чыгуга таба беренче адымнары мәктәптә укыган елларда ук ясала. «Мин бу рольгә бала чагымнан ук әзер идем. Дүрттомлыгын йөз тапкыр укыганмындыр. 1986 елга, Тукайның тууына 100 ел тулган көннәргә, мин шагыйрьне уйный алырлык багаж белән килдем»,– ди ул. Г. Тукайның тормышына багышланган телевизион спектакльдәге төп геройны да ул башкара. Ә бәләкәй Апуш ролен артистның улы Рөстәм уйный.

Татарстанның халык артисты, Г. Тукай премиясе лауреаты, хөрмәткә лаек авылдашыбыз матур аһәңле көчле тавышы, ачык дикциясе белән әле дә сәхнәдән, радио һәм телевизор аша Г. Тукай әсәрләрен халыкка җиткерә. Аның чыгышын дөньяны онытып тыңлыйсың.

Илдус абый әдәби иҗат белән дә шөгыльләнә. Рус язучыларының, дөнья классикасы әсәрләрен татарчага тәрҗемә итә, үзе өчен генә шигырьләр дә яза. Җырлавы да күңелләргә үтеп керерлек.

Рәшит һәм Илдус абый Әхмәтҗановлар... Бер гаиләдән ике талант, ике олы шәхес! Алар – авылыбыз, Баулы төбәге, бөтен татар халкының горурлыгы, асылташлары.

*«Мәгърифәт» газетасы.– 2006. – 25 ноябрь*

# Каләм яктысы

Рәфкать Кәрами

Дөньяда осталар күп. Әйтик, тимерче гади генә кораллар белән дә карап туймаслык әйберләр ясый. Ул тимерне яндыра, бөгә, чүки, әллә ниләр кыландыра – нәтиҗәдә көнкүрештә генә кулланыла торган әйбер дә күз явын алырлык була.

Ә балта осталары?! Алар салган өйләргә кемнәр генә сокланмый икән?! Аларның тәрәзәләре дә ялт итеп тора, чөнки наличниклары һәр останың үзенә генә хас орнаментлар белән бизәлгән, кәрнизләре дә, гади такта гына булуына карамастан, тишек-сырлар белән чуарланган, кыегына карагач та, тел шартлатып, останы искә аласың.

Шундый ук мактау сүзләрен ташчыларга карата да әйтергә булыр иде. Кул җылысын салып кына түгел, күз нурларын да кушып төзелгән йортлар матур да, якты да, яшәү өчен уңайлы да булалар. Гап-гади ак яки кызыл кирпечләрне аралаштырып, бизәкләп-матурлап тезәргә бары чын осталар гына сәләтле. Мин андыйларны күп күрдем.

Дөресен әйтим, Рәшитнең Әлмәттә йортлар төзегәнен күрмәдем. Гәрчә ул мин Чупай тавыннан махсус комбайн ярдәмендә шакмаклап, зур кирпеч сыман итеп кисеп алган ташлардан йортлар салса да. Ләкин аны, яшьлегенә карамастан, бик оста ташчы булган, диләр. Атаклы Саттаров бригадасы белән ул төзегән йортлар әле дә нефтьчеләр каласына ямь биреп торалар.

Шактый еллар әдәбият белән шөгыльләнү дәверендә миңа бик күп иҗат әһелләренең «җимешләре» белән танышырга туры килде. Дөнья классикларының, рус, белорус, авар, калмык, казах, грузин, әрмән, үзбәк, таҗик, төрекмән, украин һәм башка якын-тирә милләт вәкилләренең иң яхшы шигъри үрнәкләрен дә укып беләм, сокланам. Ә үзебезнең татар шигъриятенең, Кол Галидән башлап мең еллык тарихы булган Олы шигъриятнең, нинди генә осталары юк! Һәм менә шушы тирән вә мул сулы Шигърият дәрьясында, батып калудан курыкмыйча, колач салып йөзгән Рәшит Әхмәтҗан да бар!

Ташчылар арасында оста булган кебек, ул шигърияттә дә оста иде. Ташлар тезгәндә, ул кул җылысын салып тезсә, шигырь язганда, җан җылысын салып, йөрәк җылысын биреп, аның һәр тибешен укучысына җиткерерлек итеп, аны битараф калдырмаслык итеп яза иде. Аның һәр юлы ихлас. Шуңа күрә дә, шигырьләрен укыганда, эчке бер тетрәнү кичерәсең. Шигырьләре салкын кан белән түгел, бертуктамый тамырлардан агучы кайнар кан белән сугарылган.

Ни кызганыч, Рәшит иртә китте. Ләкин ул халкына җиткерәсе фикерләрен әйтеп китте.

Еллар узган саен, Рәшит татар халкының сөекле улына әверелә бара. Чөнки ул үзе дә шул халыкны сөйде, зурлады, аның өчен тырышты, янды-көйде, аның киләчәге өчен борчылды, дөнья халыклары арасында үзенең лаеклы урынын киләчәктә дә югалтмаячагына өмет белән яшәде.

Әйе, дөньяда осталар күп. Фәкать үзе башкарган, гомерен багышлаган эшне яраткан, аңа бөтен күңелен салган осталар гына биеклеккә ирешә ала. Балта остасымы ул, тимерчеме, ташчымы... Әгәр шуның өстенә ул әле кеше җанын, аның рухын тоеп иҗат итүче шагыйрь дә булса – андыйлар икеләтә бөек! Рәшит Әхмәтҗан шундыйларның берсе иде.

*«Мәйдан» журналы.– 2007. – № 2*

# Рәхәт сагыну, татлы сагыш...

Гөлзадә Бәйрәмова

Әйләнәм дә шулай, мин әйләнәм,—
Бер минут та җирне ямьсезләмәм.
Дөрлим! Сүнәр көннәремне беләм,—
Шуңа менә җырга әверелэм.
*Рәшит Әхмәтҗанов*

...1995 елның 5 гыйнвар таңы кайбер кешеләргә әйтерсең лә яман хәбәр җиткерер өчен атты: Рәшит Әхмәтҗанов вафат. Кинәт булган бу авыр югалтуны кабул итеп бетерергә күңел әле әзер түгел... Нибары берничә көн элек кенә, шау-гөр килеп, редакциядә («Казан утлары» журналында) Иске елны озату мәҗлесе ясаган идек. Кайбер очракларда күңелнең алдан күреп, нидәндер хәвефләнгән чаклары булса да, берни сизмичә, шулай зурлап, бер табын артына җыелышып, моңлы җырлавын тыңлап, әйтерсең лә без аның белән хушлашканбыз. Юкса башка гадәти эш көннәрендә журнал мәшәкатьләре белән ыгы-зыгы киләбез дә, бер-беребез белән саубуллашырга да онытып, өйләребезгә таралышабыз...

Ул көннән соң инде дистә еллар узган. Татар шигъриятендә үзгә холык-фигыльгә ия булган, сурәт-фикерләрен үзләренчә бирә алган яңа заман шагыйрьләре үсеп чыкты. Аларның бала чагын, Рәшит Әхмәтҗанов шигырендәгечә, «кырлар буйлап ачлык кумаган», «төшләрендә ап-ак шикәр күреп уянмаганнар»... Аларның Алсулары да Такташ Алсуы кебек түгел, үз заманы Алсуы... Дөньяга карашлары, танып белүләре өлкән агайларыныкы кебек үк булмаса да, шөкер, татар шигърияте, әдәби жанр буларак, «догасын тапмаган әрвахтай» кагылып-сугылып йөрүгә дучар ителмәгән, Р. Әхмәтҗановча әйтсәк:

Үз каныңнан сүзләр ясый-ясый,
Йә, җиңелме шигырь сөйләргә!

***

Шагыйрь — үз чорының елъязмачысы. Талантлы шагыйрьләрнең туу елларына күз салсаң, чор белән, дәвер белән нindidер табигый тәңгәллек барлыгына инанасың. Такташ шигырендәгечә, нәкъ менә шул елларда кирәк булган аның тууы, дип уйлыйсың.

1941 елның 14 апрелендә сугыш башланырга нибары өч ай калганда дөньяга килә Рәшит Әхмәтҗанов. Сугыш китергән афәтләр авырлыгының бер башы өлкәннәр җилкәсенә ятса, икенчесе — ачлык-ялангачлык, үксезлек-ятимлек булып сабыйлар йөрәгенә сырыша...

Камылларны сыйпап узды кояш.
«Без дә монда!» — дидек,— ишетмәде.
Кайтсак, табан бозга ябышканчы
Сугыш бикләп торды ишекләрне.

Әйе, сугыш аларның иңнәренә бик иртә чыбыркы салдыра, кулларына көрәк-балта алдыра. Шахта-күмер базларына төшеп, күмер вата, таш чыгара алар...

Ташлар белән үзгә танышлыгы да үсмер егетнең Әлмәттә ташчы булып эшләгәндә башлана. Үз хәленең нindilеген сөйләп, ташларга күп шакырга туры килә аңа. Күңеле авыр, газаплы эштән катыланырга, тупасланырга тиешле кебек булса да, Ходай биргән талант гамьле шигъри



**Киңәшмә вакыты. Сулдан уңга: Тәүфикъ Әйди, Рәдиф Гаташ, Гөлзадә Бәйрәмова, Лилия Гатауллина, Тәслимә Сибгатуллина, Флёра Сабирова, Кояш Тимбикова, Рәшит Әхмәтҗанов, Нияз Акмал, Мансур Вәлиев**

моңга әверелеп, шагыйрь кулы аша үткән ташка да җан иңеп, әлеге чуерташлар киләчәктә язылачак «Бишташ» поэмасына нигез булып яталар:

Таш дисеңме? Ташны бит мин каты димим.
Әллә башка катылыклар күп күргәнгә.
Сине уйлап уелам да һәм кинәттән
Нәфис чәчәк булып калкам мин бер мәлгә.

***

Шагыйрь — үзенең иҗатында балачагы, үткәне-бүгенгесе турында язмый кала алмый. Тик ничек итеп яза бит?! Шагыйрь, аның шәхси тормышы — күпмедер дәрәҗәдә иҗатының яратылышы, гәүдәләнеше дә. Тиккә генәме борынгы заман төрки шагыйре Низами:

Чорлар үткәч сорасаң: «Низами кайда?» — дип,
Җавап бирер һәр шигырем: «Ул — монда»,—

дип язганмы!

Әгәр шагыйрь мәхәббәттә мең кат үлеп, мең кат терелмәсә, бер үк вакытта хисләренең колы һәм падишаһы була алмаса:

Җирдән эзлим, күктән эзлим, күптән эзлим,
Шуны белеп, әйлән-бәйлән уйный гөлләр.
Төнлә авыр. Төнлә елый әллә кемнәр?
Хәбәр җибәр, көләргәме, еларгамы?
Әллә күзне мәңгелеккә йомаргамы? —

дигән юллар туа алыр идеме?

Рәшит Әхмәтҗанов эчке дөньясын шәрран ачып салып, дус булырга теләүчеләр белән хис бүлешеп яшәүчеләрдән түгел иде. Үтә яшерен хисләрен яман күзләрдән, яман сүзләрдән телбизәкләргә төреп шигъри сурәт тудыру өчен саклагандыр, күрәсең. Шуңа дамы ул шигърият бакчасында аерым бер түтәл булып яши алды. Шигырьләрендәге бик үк гадәти булмаган көтелмәгән борылышлар, фикер-сурәтләүләрендәге табышларны кемдер, бәлки, кабул итеп тә бетермәгәндер. Тик аның иҗаты нәкъ менә шул гадәти булмавы, шигырьләренең нindидер бер көйгә, моңга көйләнебрәк язылуы, халык авыз иҗатына тартым булуы, табигыйлеге белән үзенә җәлеп итә дә.

***

Милли аң, халыкчанлык, өлкәнрәк буын шагыйрьләре иҗатының төп темасы, милләтпәрвәрлекнең бер сыйфаты буларак, аларны бәйсезлек, азатлык яуларга мәйданнарга алып чыкты.




Көрәш мәйданында шагыйрь бар икән – анда инде шигырь туа. Дәүләт эшлеклеләренең мәйданда барган вакыйгаларны йомшартып, дулкынланган халыкны бераз тынычландыру өчен тоткан нотыклары вакытлар узу белән көчен югалтып онытылырга да мөмкиннәр, ә шагыйрь каләме белән язылган тарих чорлар аша да, «Идегәй» дастаннарыдай, халык күңелендә яңара, Исхакый әсәрләредәй кадерле була ала.

...1991 елның май ае. Илдә барган сәяси кайнарлыктан әйтерсең лә табигать тә үзенең табигый торышын үзгәрткән: башка елларның май аена караганда күпкә кызу. Бер төркем милләтпәрвәрләр ирек даулап Ирек мәйданында сәяси ачлык игълан итәләр. Иреккә юл ярганда көрәш алымнары төрле була. Әнә Рәшит Әхмәтҗановның әле таң алдыннан гына язган шигыре халык төркеме өстеннән ярып уза:

Яшәргә! Яшәргә! Азатлык алмыйча,
Кузгалып китү юк быелгы җәемнән.

Әлеге көрәш мәйданында туган шигырьләр, «Ачлык мәйданы» поэмасына (китабына) әверелеп, инде ничәмә-ничә еллар буе йокымсырап ятып, югала баруга дучар ителгән халыкны да уянырга мәҗбүр итте.

Р. Әхмәтҗанов, гомумән дә, поэма жанрын яратып иҗат итүче шагыйрьләрдән, алар аның иҗатының аерым бер өлешен билэп тора. Шигъриятнең гаять катлаулы, авыр бу төренә алынырга күпләр базмый. «Аучылар кибетендә», «Карачкы», «Язлар быел соңга калды», «Карга каргышы» һ.б. поэмаларын иҗат итеп, ул үзен шагыйрь буларак тагын да ачып, танытып кына калмады, дастан-поэмаларның татар шигъриятенә никадәр кирәклеген дә исбатлый алды.

Тәүге шигырьләр җыентыгын университетта укыган чагында ук кулына алган шагыйрьнең үзе исән чагында дистәләгән китабы дөнья күрә. Бәлки әле, алар тагын берничә дистә булыр, томлыклары да чыгар иде... «Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исемгә, Татарстан Язучылар берлегенең Г. Исхакый исемендәге әдәби премиясенә лаек була... Бәлки әле, тагын да мәртәбәлерәк бүләкләргә ия булган булыр иде... Вафатыннан соң шагыйрьнең иң яхшы шигырьләре тупланган «Сайланма әсәрләре» («Рухият» нәшр., 1988), «Сәфәр ае» (Татар. кит. нәшр., 2001) исемле китабы басылып чыкты.

Иҗатының башлангыч чорында ук Хәсән Туфанның фатихасына ирешкән шагыйрь Олуг Шигъриятне таный белгән каләмдәшләренең ихтирамлы карашын, иҗатына хөрмәтен, шәхес буларак аңлауларын тоеп яши. Күренекле язучы Марсель Галиевнең аңа багышланган язмасын ачам:

«Әгәр аңа Күк иясе:

– Шигъриятнең пәйгамбәре итәм, калган гомереңнән ваз кичәсеңме? – дисә, ул сүзсез риза булыр, халык бәгыренә тәңгәл килгән чын шигърият хакына җирдә бүтән мәңге кабатланмаячак гомерен корбан итәр иде...»

...Халык бәгыренә тәңгәл шигърият... Ул үзе дә якын иткән кешеләренә ничектер үзенчә матур итеп «багърем» дип дәшә иде...

...Бары тик шигърият белән генә яшәп, бөтен барлыгын, яшәешен шигъриятькә багышлаган Рәшит Әхмәтҗановның арабыздан киткәненә дә инде уналты еллап вакыт узган. Бер караганда әллә ни күп тә түгел кебек...

Шат күңелле, җор телле, кабатланмас бу шагыйрьне уйлаганда, иҗатын хәтердә яңартканда, күңелне татлы сагыш, рәхәт сагыну биләп ала.

*«Казан утлары» журналы.– 2011. – № 4*

# Киткән кебек тә түгел...

Сәмига Сәүбанова

Кызык кеше иде Рәшит Әхмәтҗанов дигән шагыйрь. Бер дә борынын күтәреп йөрмәде. Мәйданнарга чыгып та шәрран кычкырмады. Ирек мәйданында республикабызның мөстәкыйльлеге өчен милләтпәрвәрләр белән бергә сафка басканда да, авызыннан бер сүз чыкмады, соңрак бу вакыйгага багышланган «Ачлык мәйданы» китабына кергән шигырьләре дә меңләгән рупордан кычкырганга караганда көчлерәк яңгыраш алды.

Бүтәннәргә охшамаган башка сәер яклары турында да сөйләргә булыр иде...

Ничек шулай килеп чыккандыр, безнең гаилә тормышыбыз Рәшит Әхмәтҗанов гаиләсе белән гел янәшә барды.

Башта аның белән Бауман урамындагы нәшрият бинасында, мин – бишенче, ул – дүртенче катта, соңыннан исә Декабристлар урамындагы газета-журналлар нәшрияты бинасында – бер редакциядә – «Казан утлары» журналында озак еллар бергә эшләдек, бергә-бергә бәйрәмнәр үткәрдек, бер өстәл артына утырып тәгам җыйдык.

Яшь гаилә булып яши башлагач, без Рәшитләрдән бушап калган фатирга (Чернышевский урамында – тимер юл вокзалы каршында иде ул йорт) күчендек. Ирем белән бу фатирны карарга баргач, хатыны Луиза ханым табын әзерләп, алар яңа йорттагы фатирларына күчү, ә без исә үз куышыбыз булу куанычын бергә билгеләп тә алдык. Олы кызы Ләйләгә – өч яшь, ә Айдарының туарына бер ай гына калган иде.

Улының дөньяга килү куанычын да, кереп, безнең белән уртаклашты һәм:

– Гадәт буенча, үз өемә кайтам, дип уйлаганмын,– дип көлдереп алды.

Соңрак алган фатирларыбыз да күрше йортларда булгач, бәйрәмнәрдә гаилә табыннарын берләштердек. Рәшитнең улы Айдар белән минем кызым бер мәктәптә, бер сыйныфта укыдылар, бер парта артында утырдылар...

Язучылар берлегенең бакча ширкәтендә салган йортларыбыз да бер-беребездән ерак түгел иде, яккан мунчабыздан бер-беребезне калдырмадык.

Ялгыз калуны яратмый торган иде ул.

Җәйге яллары вакытында Луиза балаларын алып Азнакайда яшәүче әтисе белән әнисе янына киткәч, Рәшитнең бик күңелсезләнеп, үзен үзе кая куярга белми йөрүенә аптырап:

– Иҗат итәреңә җай чыккан, рәхәтләнеп шигырь генә язасы бит инде,– дигәч:

– Берүзең язып буламыни?! – ди торган иде.

«Сезнең өчен шуны-шуны эшлим»,– дип, ул гаиләсен алдан ук булыр-булмас вәгъдәләр биреп өметләндермәде. Хатынын, балаларын уйламаганда куандыра, уйламаганда шаккатыра белде. Бервакытны әйбәт кенә гонорар алгач, өйгә кайтышлый гына очраган, бергә эшли торган хатынны юл уңаеннан киемнәр кибетенә алып кереп: «Минем хатынның гәүдәсе синеке шикелле, әйдә әле, менә шушы пәлтәне киеп кара әле»,– дип, аңарда үлчәгәч, хатынына алып кайтты. Кызы Ләйләне дә кышкы тун белән шулай сөендерде ул.

Мондый гамәлләре күп булды.

Бүтәннәр хатыннарының булганлыгы белән мактанганда, ул үзенекеннән бераз зарланырга яратты. Бергә аралашып яшәгәнгә, гаилә эчендәге мохитне яхшы белгәнгә күрә, аптырап:



**«Казан утлары» журналы редакциясе хезмәткәрләре. Сулдан уңга: Зиннур Мансуров, Рәдиф Гаташ, Рәшит Әхмәтҗанов, Фәүзия Бәйрәмова, Әмирхан Еники, Ринат Мөхәммәдиев, Фәрваз Миңнуллин, Сәмига Сәүбанова, Мансур Вәлиев, Мәхмүт Хәсәнов, Роза Сөләйманова, Зәки Нури, Роберт Миңнуллин, Солтан Шәмси, Гөлшат Салихҗанова, Рәзифә Вафина. 1982**

— Кеше өйдәге чүпне чыгармаска тырыша, нишләп син юкны бар итеп сөйлисең?— дигәч:

— Иҗатташ дусларым әз генә берәр хатын-кызны мактаганымны ишетсә дә, шуңа багышлап шигырь яза, ә минем хатынны үзең беләсең, тәмле сүзгә ярты дөньясын бирергә әзер, болай да инде бар дус-иш, хезмәттәшләрем теше сызлаганга гына түгел, берәр җире тырт итсә дә аңа йөгерә, авырга туры килмәсен дип тырышам,— дип җавап кайтарган иде. Аннан соң шаркылдап көлде дә: — Хатынсыз да калуың бар, юньле хатын аяк астында аунап ятмый ул! — дип өстәде.

Чынлап та, Луиза теш табибы булгач, Рәшитнең дуслары да, хезмәттәшләре дә хатынының киң күңеллелегеннән рәхәтләнеп файдаланды.

Күрше-күләнгә, дус-ишкә генә түгел, Рәшитнең үзенә дә «ашыгыч ярдәм» булды Луиза. Ничә тапкыр ирен каты авырудан аякка бастырды, ничә тапкыр әҗәл тырнагыннан тартып калды, үзенең генә кулыннан килмәсә, хастаханәгә озатты...

Балаларын бик яратты Рәшит. Үсмер чагында тач үзенә охшаган аксыл чәчле, зәңгәр күзле улы тәртибе белән тәртәгә типкән чакларда да иң каты итеп әйткән сүзе «блондин» булды.

Төп байлыгына — матур гаиләсенә, тыныч тормышына, ныклы терәгенә күз тиюдән уттан курыккандай курыкты. Шуңа күрә ул бу турыда белгертергә яратмады. Ә менә күңеле кырылган, җаны әрнегән чакларны ул берәүдән дә яшереп тормады. Гаделсезлек, тигезсезлек, милләт язмышы аңа тынгы бирмәде, ул аның җанын кимерде. Вакыт-вакыт ул бу көрәштә үзенең көчсезлеген аңлаудан шулхәтле югалып кала, төшенкелеккә бирелә һәм дөньясына, үзе әйтмешли, «нәгъләт» укып йөри башлый иде. Бу халәтен яшерергә кирәксенмәде, бөтен кешенең ишетүен, күрүен, барыбызның да җаны уянуын теләде.

Башка чакларда һәрнәрсәгә юмор белән карады.

Шагыйрьләр еш гашыйк була, дисәләр дә, бу сүз аңа туры килмәде. Ул бары тик гаиләсен, бары тик бер генә кешене яратты. Бер генә кешегә атап шигырь язып булмый, дисәләр дә, мәхәббәт турындагы шигырьләренең барысы да хатыны Луизага багышлангандыр, дип уйлыйм.

Үзе сәер булган шикелле, хатынының да мәхәббәте сәеррәк иде. Рәшите мәңгелеккә күчкәч:

– Без бер-беребезгә «яратам» дип төчеләнеп яшәмәдек, бүтән берәр хатын-кызга гашыйк булып, иләсләнеп тә йөрмәде, ичмасам, шагыйрь кеше иде бит ул! – дип өзгәләнгәнен һич оныта алмыйм...

Ил язмышы өчен ут йотып яшәде. Чечнядагы хәл-вакыйгалар аны гомумән эштән чыгарды:

«Бу кадәрле вәхшилеккә йөрәгем чыдамас, мин үләрмен инде»,– дип, эштәге хезмәттәшләре, дуслары белән бүлмәдән бүлмәгә кереп бәхилләшеп йөрде.

Ә өенә кайткач, йөрәк кенә түгел, ашказаны да авырта, дип уйлап, эчен тотып сыгылып төште. Түзә алмагач, янына энесе Илдусны чакырды. Үләрен сизенсә дә, хушлашу сүзләрен әйтергә өлгермәде. «Ашыгыч ярдәм» машинасы килгәнче йокымсырады да... китте.

Ирем белән сердәш иде. Гомерләре бер елда өзелде.

Китте...

Җәсәден яргач, йөрәгенең бөтенләй эштән чыкканлыгы билгеле булды. Йөрәген ярырдай сәбәпне белгәннәр – белде, белмәгәннәр белмичә калды.

Дөньялыкта җәмәгате Луиза ханым тарафыннан бик хөрмәт ителеп яшәде. Рус мәктәбендә русча гына белем алган ханым, иренең шигырьләрен укыр өчен, татарча укырга өйрәнде. Иҗат кешесенең күңеле бик нечкә булуын аңлап, ирләр эшләрдәй тормыш мәшәкатьләрен дә аның өстенә ташламады, бар авырлыкны үз өстенә алды. Үзенә аптырап карауларга аның җавабы бер булды:

– Шагыйрь кеше бит ул!

Рәшитнең тылы шундый нык иде.

Вакытында өч ел буена Әлмәт шәһәрен төзешкән ташчы егеттән өйдә кадак та кактырмады Луиза. «Бары тик язсын гына, кадакны аны теләсә кем кага ала, ә шигырь язучылар – штучный товар»,– дип, андый эшләрне кулы оста күрше-тирә, дус-иштән эшләтте. Чөнки таш йортларны сала белгән Рәшит, чынлап та, өйдә кадак кага белми иде. Бакчада мунча салыр өчен кияве үзе эшләгән заводтан ниндидер бер корылманы сүткәч җыелган такталарны алып килгәндә, иске кадакларны ничек алырга икән, дип, бик озак аптырап торган иде. Үзенең бу булдыксызлыгыннан көлә-көлә, эшнең серенә бик озак төшенде.

Бик күп талантлар, хатыннары тарафыннан аяк чалынып, кагылып-сугылып, күтәрелә алмыйча, дөньядан китте. Ә Рәшитнең иҗатын санлап килгән һәр кеше, Луиза ханым әзерләгән тәгамне җыеп, хөрмәт ителеп, бу өйдән якты уйлар белән генә китә иде. Өйдә шундый шартлар булмаса, аның иҗаты болай күтәрелер иде микән?!


Язучы Аяз Гыйләҗевнең: «Мин базардан бер чиләк бәрәңге күтәреп кайткан көнне бер юл да яза алмыйм»,– дигәне бар. Луиза ханым тормыш йөген ире иңнәренә салса, Рәшит тә яза алыр иде микән?!

Бакчаларыбыз бергә булгач, еш кына бергә дә кайттык. Саф һавада битләре алланып, йөгерә-йөгерә кайткан Рәшитебез, электричкадан төшү белән, шәһәрнең төтенле һавасыннан тыны кысылып, көч-хәл белән атлый башлый торган иде. Шуны белгән Луиза иренең кесәсенә генә түгел, минем сумкага да, ашыгыч кирәк булса дип, дарулар тыга торган иде.

Бәла-казага очраудан курыкты. Шуңа да кызы Ләйлә машина йөртергә өйрәнгән чагында, аңа утырмыйча, бакча юлы буйлап, оныгы Наиләне күтәреп, тиз-тиз атлап, электричкага бергәләп күп тапкырлар чыктык. Йөрәгем хәлсез дип тормады, шул ук бакчадан хатыны Нурсөя белән кайткан Фәнис Яруллинны әллә ничәнче каттагы фатирына күтәреп менгерә торган иде. Кешеләрне җәлли, гайбәтләргә бик ышанмый иде. Янәшә генә яшәгән Зәки Зәйнуллинга хатыны пешергән камыр ашларын күп ташыды, өенә дә еш чакырды. Яңа ел бәйрәмендә бер тапкыр Фәнис Яруллиннар белән дә бергәләп утырдык...

Хәзер уйлыйм да шундый нәтиҗәгә киләм: минем бөтен гомерем иҗат кешеләре арасында үтте – эштә дә, яшәгән йортыбызда да, җәйге бакчабызда да... Аларның һәркайсы дөнья бәһасе кеше иде. Мин аларны яраткач, хөрмәт иткәч, алар да миңа шулай җавап кайтардылар.

Рәшит Әхмәтҗанов шуларның берсе иде.




**Рәшит Әхмәтҗановның 2014 елда дөнья күргән икетомлыгы**

Аның дәвамы булып балалары, өч оныгы яши. Ике оныгы ул мәңгелеккә киткәч дөньяга килде. Бабаларын күргәннәре булмаса да, шәт, иншаллаһ, аның кем булуын, иҗатын яхшы белерләр һәм шагыйрь бабаларының рухын рәнҗетмәсләр, милләт җанлы балалар булып үсәрләр.

Шагыйрь хатыннарына бер дә җиңел түгел. Ирләренең кем икәнлеген белеп, аңа рухи таяныч булганнарның гына гаиләсе сакланып калды, иҗатлары югары биеклеккә күтәрелде. Луиза ханым ире исән чагында ук аның иҗатының бәһасен белде, аңарга терәк булырга тырышты. Шагыйрь бакыйлыкка күчкәч, белүемчә, Рәшит Әхмәтҗановның дүрт тапкыр калын-калын шигырьләр җыентыгы дөнья күрде. Хәзер Татарстан китап нәшриятында икетомлыгы басыла...

Ләйлә белән Мәҗнүн, Таһир-Зөһрә мәхәббәте турында күп язалар. Алар зур мәхәббәт белән, бер-берсе өчен үләрдәй булып яшәде дип әйтә алмыйм. Бер-берсенә «яратам!» дип әйттеләр микән әле? Рәшит күп язды, Луиза күп эшләде. Тик Рәшитнең Луизага багышланган бер шигыре барысын да әйтеп бирә:

Бүген елның иң кыска көне,
Борчуларга салды да мине,
Китеп барды үзе, мин калдым,
Әйтерсең лә юлда югалдым.
Югалмадым, исән-сау идем,
Юлда сине эзләп йөредем.
Хәбәр салдым бөтен дөньяга –
Сине эзләп дөнья ут яга.
Озайтырга синең көннәрне
Мин утларга ягам төннәрне.

Төннәр янсалар да – төн кара,
Төннәр яна – көлләре кала...
Яктылыкның түгел актыгы –
Чәчләремнең кардай аклыгы.
Мин агарам, һаман агарам –
Күренмидер хәтта күз карам...
Шулай узар минем гомерем.
Бөтен гомеремә – бер гөлем
Син генә бит. Димәк, иртәгә
Миңа тагын юлга китәргә –
Утка яга-яга төннәрне,
Озайтырга синең көннәрне...

Әйтерсең ул безнең янда йөри. Әйтерсең бакыйлыкка күчкәненә егерме ел вакыт узмаган... Ара ерагайган саен, кемне югалтканыбызны ныграк аңлыйбыз.

*«Безнең мирас» журналы.– 2014. – № 6*

# Үткәннән хат[1]

*Рәшит Әхмәтҗанов – Мәгъсүм Хуҗинга*

Сәлам, Мәгъсүм абый!

Ялта якларыннан бу көннәрдә кычкырып көлгән тавышлар, авазлар ишетелде. Сез дип уйладык. Ә «Чаян» сез китү белән елый да елый...

Кар яумады әле. Кибеттәге җылы пималарың исәннәр, таушалмый торалар. Төрле төстәге суларның чыганаклары кибеп бетте. Китап акчасы хатын кулына эләгеп... һәлак булды. Гәҗит иртәгә җибәрәм, әй, юк, атна башында була инде. Алег хат язган, исән-сау гына зур кеше булырга әзерләнеп ятам, дигән. Минем кызга диңгез кабырчыклары алып кайтырга онытмагыз!!! Чыгачак гәҗиттә хикәягезне укып, бер хата да калдырмыйча төзәтеп җибәрдем. Дом печатиның бөтен тәрәзәләреннән атлар кешнәве, малай-шалайның кычкырулары ишетелеп тора, чөнки бүген хикәягез 100 меңнән дә артык үрчем бирә.



**Эчкерсез сөйләшүләр. Сулдан уңга: Роза Туфитуллова, Нарим Ихсанов, Роза Мулланурова, Ләлә Гыймадиева, Рәшит Әхмәтҗанов**

Саимә апа (Ибраһимова) сәлам әйтә. Сез юклык сизелә – акча түгел, фифирус бирүче дә юк үземә.

Бер-ике җыр язам Сезгә,
Сезгә барып ирешерме
Безнең язган хатыбыз
(Үбешегез, серләшегез) –
Бер повесть, дүрт хикәягә
Ата булып кайтыгыз.

К у ш ы м т а:
Эх-ма!
Тау башында куян ята –
Төлке аны уята.
Дөнья нужалары безне
Җырлата да, елата –
Яшьне сөртеп юата.

*Иң изге теләкләр белән, Рәшит Әхмәтҗанов*
*1971, 10 декабрь*

*«Безнең мирас» журналы.– 2014. – № 6*

[1] Хат Мәгъсүм Хуҗинның гаилә архивыннан алынды.

# Рәшит һәм урман кызы

Гөлсинә Сәмигуллина

Рәшит туганымның әнисе Сажидә түтәй минем әнием Шәмсекамәр белән бертуганнар иде. Ике авыл арасы җиде генә чакрым булганлыктан, туганлык җепләре мәңге өзелмәслек кебек ныклы иде. Рәшитебез туган авылында җидееллык мәктәпне тәмамлагач, Кряжле урта мәктәбенең 10 нчы классына укырга керде. Яшь аермабыз булса да, без классташлар булдык. Укыйбыз, зарланмый Рәшит, ләкин тора-бара математика фәнен төшенеп җитмәвен сиздерде (7 дән 10 га килеп керү шаукымы). Шулай да ул тырышты, кыю, җитез, көр күңелле, шук-шаян иде.



**Рәшитнең әнисе ягыннан иң якын туганнары. Сулдан уңга: Венера, Гөлсинә һәм Раилә. 2020**

Җәй көннәрендә якындагы урманга җиләккә, чикләвеккә барулар һәм урман юлындагы бер кызыклы хәл яшьлегебезне һаман искәртеп тора кебек.

Атлы арбада чыбыркысын янәшәсенә куйган авылдаш абзый үтеп китүгә, Рәшит:

– Әйдә, Гөлсинә апа, сине урман кызы ясыйбыз, – ди.

Минем озын толым итеп үргән җирән чәчләремне сүттек, бик нык итеп төрле якка туздырдык, аннан киселгән агач төбенә утыртты мине Рәшит, үзе агачлар арасына качты.

Тыныч кына юлны күзәтәбез. Озак та тормый, атлы авылдашыбыз кайтырга да чыккан икән. Мине – урман кызын күрүгә, атын кинәт туктатты, гаҗәпләнү катыш кыяфәт белән карап торды-торды да, атына чыбыркысы белән кизәнеп, зур тизлек белән китеп югалды. Әй көлештек тә инде шушы хәлдән соң. Абзый кеше, чыннан да, бик нык курыкты бит.

Рәшит урман табигате кебек саф күңелле, әнисен, туганнарын кадерли белүче, фәрештәдәй егет булып үсеп җитте. Мине урман кызы кыяфәтендә күрүе дә юкка гына булмаган, күрәсең. Шаян-шук егет зур шагыйрь булды.

– Казан дәүләт университетына укырга бергә керәбез, бер дә борчылма син, урман кызы Гөлсинә. Синнән дә ак чырайлы, синнән дә сипкеллерәк һәм җирән чәчле кызлар да укый анда, – дип кыстады...

Ләкин миңа университетта укырга насыйп булмады шул.

Рәшит гомер буе күңелемдә яши, аны бүген дә сагынып искә алам.

*2014, 1 июнь*

# Заман шигърияте ндә ил гаме

Рәфыйк Шәрәфиев

Чын шигърият беркайчан да халык язмышына, дөнья, ил гаменә битараф кала алмаган, димәк, шагыйрьләр дә элек-электән күбәләкләр белән куышып, гүзәлләргә һәм нәфис гөлләргә сокланып, былбыллар сайратып кына яшәмәгән. Меңьеллык тарихлы татар шигъриятендә дә шул ук хәл: шагыйрь булып туганнарны һәрвакыт, Зөлфәтнең бер шигырендә әйтелгәнчә, «көтеп торган Колгалилек, Колшәрифлек тәкъдире». Төрле чорның зинданнары да татар шагыйрьләрен көтеп торганга охшый әле. Акмуллалар заманыннан бирле шулай... Тукайларның, Такташларның халык исеменнән дөньяга әйтер сүзләре күп калганга, татарның үз алдына куйган максатлары да биниһая зур булганга, Бөек Көч безгә шагыйрьләрне дә күп бирәдер, бәлки. Күпсенмәгез, әфәнделәр, халыкка рух ныклыгы, үтемле хак сүз аеруча кирәк чакларда күбәя шагыйрьләр. Карагыз сез, иң фаҗигале, дәһшәтле чорда – нәкъ сугыш алдыннан, сугыш вакытында һәм аннан соңгы ике-өч елда татарның нинди шагыйрьләре туган: Равил Фәйзуллин, Гәрәй Рәхим, Рәдиф Гаташ, Ренат Харис, шагыйрьлеге өстенә гамьле, тирән фикерле, хөр рухлы публицистикасы белән дә иң шәпләрдән саналучы Рәфикъ Юныс (аның элегрәк басылган «Татарстан референдумы», әле генә дөнья күргән «Татар гаме» китапларын күз алдында тотам), Гарифҗан Мөхәммәтшин, Рәшит Әхмәтҗанов, Харрас Әюп, Мөдәррис Әгъләм, Зөлфәт, Илдус Гыйләҗев! Кемгә дип һәм кайсы халык исеменнән язганнарын анык белгән, холык-фигыльләре дә күркәм булган шагыйрьләрнең кыскача гына исемлеге әле бу! Дәһшәтле еллар авырлыгын үзләре кичеп, халык белән бергә күргән-кичергәннәрен сүзләр ярдәмендә сурәтләп, тарихка калдырсыннар өчен, Табигать шулай күп итеп тудыргандыр аларны.

Әшәкелек басып дөньяны,  
Яхшылыкка кеше зарыкса,  
Күңелләргә якты индереп,  
Пәйгамбәрләр килгән халыкка,–

диелә Илдус Гыйләҗевнең бер шигырендә.

...Татар кебек зур халыкта гына күпләп туа алган иң талантлы, иң нәфис һәм халыкчан иҗатлы шагыйрьләребезнең күпмесе якты дөнья белән хушлашты: Фәннур Сафин, Рәшит Әхмәтҗан, Илдар Юзи, Наис Гамбәр, Мөдәррис Әгъләм, Зөлфәт, Харрас Әюп, Роберт Әхмәтҗан, Шәүкәт Галиев... Яшәү-көрәштән дә, иҗаттан да туймаган иде әле берсе дә. Аларның да өзелгән сүзен әйтеп җиткерү исән шагыйрьләргә, аларның дәвамчыларына йөкләнеп калды. Үзләре исеменнән генә түгел, мәрхүм каләмдәшләре өчен дә әйткәнгә, кайчак сүзләре кискенрәк ишетелсә дә гаҗәп булмас.

Шигырьдәшләреннән берсе – Равил Фәйзуллин тарафыннан «ил тарихы, халык язмышы, аның бүгенгесе һәм киләчәге турында борчылып, әрнеп иҗат итүче шагыйрь» дип бәяләнгән, үзе дә бер шигырендә «Алтын-көмешләргә алданмадык, Чиксез байлыгыбыз – ил гаме!» дип язган Рәшит Әхмәтҗановның «Ачлык мәйданы» исемле бәйләмен укысаң, «шушындый шигырьләрнең иҗатчысы да мәрхүменнән соң тиз-тиз онытыла барыр икән, Ходаем!» дип гаҗәпләнүдән тыела алмыйсың. Бу кадәресе хакимияттәгеләрдән генә дә тормый югыйсә. Әлеге шигырьләрне радио-

телевидениедән укуны, исәпсез концертларда яңгыратуны әлегә кем тыя? Әнә «Татарстан Яңа гасыр» телеканалы зур бер төркем кәмитчененң мәгънәсезлек чигендәге «иҗат җимеше»н көнгә берничә тапкыр күрсәтеп тора. Андый тапшыруларның продюсеры да мәгънәле ханым, халыкка озын гомерле бик матур җырлар язып калдырган ата кызы югыйсә. Сәхнәләштерсеннәр иде әнә шул тук егет-кызлар Рәшитнең «Ачлык мәйданы»н, Харрасның «Көй эзләү» поэмасын, Илдус, Мөдәррис, Газинур, Рүзәл шигырьләрен! Рольсез торып тилмергән чакларында бүтән актёрлар да, концерт төркемнәренә катнашып, шигырь укый аладыр? (Түбәнлек түгелдер бу, мәшһүр Василий Лановой да вакыт-вакыт концертта шигырь укып йөргән, дип сөйләделәр.) Уйнаган рольләренең генә түгел, тулы спектакльләрнең бер әйбәт шигырьгә тормаганнары аз мәллә? Күптән түгел яңа гына телгә алынган каналның бер тапшыруында мәшһүр Ренат Таҗетдинов та «вак-төяк уйныйбыз» дип әйтеп салды, җаны әрнеп, кат-кат әйтте. Әйтер дә шул, күпме фаҗигаләр кичергән татарның Ренат һәм Әзһәрләре, Равилләре, мәрхүм Наил һәм Хәлилләре кинәнеп уйнарлык, рольләре аша халыкка үз сүзләрен әйтерлек заманча трагедияләре, шундыйны яза торган драматурглары булмасын әле! Референдумның, Татарстан Конституциясе кабул итүнең фәлән-фәлән еллыклары авылларда гына түгел, район үзәкләрендә дә бер мәдәни чарасыз узып тора. «Ачлык мәйданы»ндагыдай шигырьләрдән шәп-шәп кичәләр үткәреп буладыр лабаса? Халыкның туксанынчы еллардагы хөр рухын уяу тоту өчен дә кирәк болар. Рәшит Әхмәтҗановның һәм башка фидакяр җаннарның милли хокукларыбызны, гаделлекне, халыкларның тигезлеген даулап эссе кояш астында ачлык тоткан урыннарына һәйкәл утыртып кую да артык булмас иде дә бит, кая инде ул безгә! Һәйкәл куеласы изге урыннар аяк асларында таптала һаман.

Ялган булып су төбенә батасы бар,
Әгәр хаклык өскә калкып чыкмаса.
Дошман таптар каберләрдә ятасы бар,
Халкым болай бер-ике ел йокласа,—

дип язган Рәшит Әхмәтҗанов. Ни хәл итик соң, һәммәбезгә диярлек «җиңел» тормыш кирәк бит. Халыкка түгел, иң элек үзебезгә кирәк, бүген кирәк.

Кол булу бик җиңел — җаныңның
Ил түгел икәнен белдер дә,
Кер, утыр ятларның түрендә —
Тамагың тук булыр бүгенгә.

Болай турыдан бәреп Рәшит Әхмәтҗанов кебекләр генә яза аладыр һәм шулай язарга халкының иреген, тигезләр арасында тигез яшәргә хокукын яклап ачлык мәйданнарында көйгән фидаи җаннар гына хаклыдыр, бәлки. Аз санлы каләмдәшләре белән бергә шул мәйданда күргән-кичергәннәре генә дә әрнеп-сызланып язу өчен берничә шагыйрь гомеренә җитәрлек булгандыр аның. Ә безгә бер шагыйрьнең кыска гомерендә язганнарын укып һәм һәр шигъри юлыннан диярлек үзебезне танып офтанасы хәзер (шуңа күрә бик укымыйбыз да).

Халыкның тормышын беләсең килсә, ул халыкта балаларның һәм өлкәннәрнең ничек яшәвенә кара, дигән бер акыллы зат. Аналарның ничек яшәве дә ил-халыкның ниндилеген сөйли ала. Үзе бай, үзе әхлаксыз һәм шәфкатьсез дәүләтнең аналары һәм балалары хәле шагыйрьләрне һәрвакыт борчып торган. Рәшит Әхмәтҗановның «Карга каргышы» поэмасыннан менә бу юллар Мөдәррис Әгъләмнең «Бердәнбере»нә аваздаш:

Мондый вәхшилекне белми тарих,
Яши торгач, шундый көн килде:
Балалары исән бар әнкәләр
Ач үлемгә хөкем ителде.

Соңгы кабымнарын айлар буе
Безгә бирә-бирә үлделәр.
Ә алар бит сөргеннәрдә түгел,
Иген кырларында иделәр.

Ямьсез шаяру белән әйтсәк, хәзер бездә балалар, түрә-чиновниклар кебек үк, өстен сыйныф санала үзе, чөнки икесе дә, авырсалар, чит илләрнең дәрәҗәле хастаханәләрендә дәвалана. Аерма шунда гына: балалар гади халыктан тиенләп җыелган хәйрия акчасына, ә түрәләр шул ук ха-

лыктан хөкүмәт һәм бай хуҗалар сыгып алган миллионнарга дәвалана. Без укыган чордагы бер китапта язылганча, берәүләргә – клиндер, икенчеләргә аның уртасы.

Рәшит Әхмәтҗановның «Җавап» шигырен укыйм. Алар утырган Ачлык мәйданына Рифкатьнең авылдашы килгән, янәсе, хәл белешә:

Үләсез бит инде, туктагыз,– ди.
Ул әйткәнне гүя бу белми.
Егетебез тыныч. Тыңлап тора.
Сыңар керфеге дә селкенми.

«Качып кына бераз ашагыз сез...»
Катып кала Рифкать бер мәлгә.
– Безгә ашау – үз халкыңны ашау,
Кеше ашаганың бар мәллә?!

Рәшитнең Ачлык мәйданындагы көрәштәше, шигърияттәге туганы Газинур Морат та үзенең «Ачлык» поэмасында әлеге «авылдаш» кебекләрне якыннан белеп сурәтли:

Улымны телсез калудан,
И Тәңрем, үзең сакла.
Сакла хәтерсез калудан,
Сакла Иделен, йортын.
Сакла, берүк,–
Хәтеребез
Болай да ярым-йорты.

Тарихи хәтеребезнең ярым-йортылыгы Газинур Моратның байтак шигырьләрендә үзәккә алып бәян ителә. Чөнки вазгыять шундый: исәпләмәсәң – түзәрлек, исәпләсәң – үләрлек, шуңа күрә исәпсез-уйсыз гына яшәргә маташабыз да. Хәтеребезне буташтыру, телебезне бетерү, татарны бүтән милләтләр арасында «эретү» дигәндә, безнең бик үк федераль булмаган үзәкнең «шәп» чиновниклары һәм галимнәре әллә нинди нечкә алымнар уйлап таба, өстәвенә байтагыбыз аларга ярдәм итә. Милли сәясәтчеләребез исә гел азая. Хәер, соңыннан аңлашылганча, аларның байтагына Татарстан мөстәкыйльлеге дә хосусый байлык, балаларына зур мөлкәтле урын йолкып калу өчен генә кирәк булган бит. Андыйларга милләтең ни дә, телең ни? Кайберләре каләм ияләренә дә «Бик акыллы булгач, ник бай түгел соң син?» дип кенә җиффәрә. Каләм ияләренең «ник бай түгел»леген Рәшит Әхмәтҗанов бер кыска шигырендә болай аңлата:

И пәйгамбәр шагыйрь, кичер Илне,
Хәбәр килде менә әле генә:
Соңгы китабыңның әҗеренә
Таш та куеп булмый каберенә...

«Ачлык мәйданы» поэмасы безне үткәнебезгә дә, бүгенгебезгә дә ачыграк күз белән карарга чакыра, чөнки киләчәгебез шуңа бәйләнгән. Ваемсызлыктан изрәп никадәр озак йокласак, уяну шулкадәр кыен, милләт үтәсе ачлык мәйданнары күп булачак. Оттырышлар болай да хәттин ашкан. Татар да күп «ачлык»ларга күнде-күнекте. Аз санлы милләттәшләребезгә бирелгән хокукларны һәм биниһая зур матди байлыкны безнеке дә дип хис итә алсак, ярыйсы яшибез булып күренәчәк. Шуннан ераккарак карарга да кирәкмидер, бәлки? Газинур Морат бу турыда болай уйлана:

Танк белән таптарга да була,
Атарга да була безләрне.
Буй кыскара, уй кыскара бара,
Яши икән халкың тезләнеп.

Татар җаныннан алып язылган, хөрлеккә чакырган, телсез-моңсыз яшәүләрне кимлек санаган шигырьләрен онытмасак, бу даулы елларның шагыйрь Рәшитләрен, Әюпләрен, Мөдәррис һәм Зөлфәтләрен, чынлап та, халык арасында, исән каләмдәшләре Равилләр, Илдуслар, Газинурлар янында калгандай хис итәрбез, иншалла.

*«Казан утлары» журналы.– 2014. – № 11*

# Сәер шагыйрьләр

Госман Гомәр

Никтер сәер шагыйрьләрне хөрмәт итәм. Алар – туры сүзле, гади, төгәлрәге, сабый күңелле самими җаннар... һәм гаҗәеп талантлылар. Мин моны үзем яхшы белгәннәрдән, редакциядә бергә эшләгәннәрдән чыгып әйтәм, һәр сүзен юмор белән җиткерүче, шуңардан үзе үк тәм табып, шаркылдап көлеп, артыннан башкаларны да ияртә белүче Рәшит Әхмәтҗан шундый затларның берсе иде. Аның сыртыма «фирка» кушаматын чәпәп калдыруын язып та чыккан идем заманында. Икенче «сәеребез» – җыры белән «тауны ишеп, ташны ярган» талант иясе Фәннур Сафин. Без аны Түбән Кама химия заводы төзелешеннән Казанга үзебез алып кайттык.



**Рәшит Әхмәтҗанов һәм Фәннур Сафин**

Һәр икесе «Татарстан яшьләре» газетасының әдәбият-сәнгать бүлегендә бик тату, әйбәт эшләделәр. Сәерлекләре шунда: алар редакция кысаларына һич сыешмый. Синең «от» белән «до» тәртипләреңә, көн буе берничә тапкыр кабатланып торган төрле җыелыш-планлаштыруларыңа исләре дә китми. Шагыйрьләрнең үз кануны. Эшкә еш кына соңарып киләләр йә бөтенләй күренмиләр. Әмма килгәч инде... ат урынына җигелеп тарталар. Газетаның берничә санына җитәрлек материалны алдан ук туплап куялар.

Ул редакторларга ярап буламыни соң?! Беркөнне, хәзергечә әйтсәк, баш мөхәррир, канына сеңгән гадәте буенча, һич кирәкмәскә эт итеп сүгеп чыгара нечкә күңелле Фәннур Сафинны. Нык хурлана шагыйрь хаксызга рәнҗетелүенә. Папкаларын җыя да кире керә бу бәйләнчек редактор янына. Шап өстәлгә! Хат-хәбәрләр чәчелеп үк китә. Редакторга аты-юлы белән җиткереп, ишеккә юнәлә.

Баш бирмәс шагыйрь, үзенең бу кыланышына куанып, бүлмәдән бүлмәгә йөреп, безнең барыбыз белән кул биреп саубуллашты да редакциядән бөтенләйгә китеп барды. Шуннан соң ул башка редакцияләрдә дә төпләнеп эшли алмады инде. Җаны нык әрнеде әдипнең.

– Ояты редакторга булсын! – дип озаткан иде үзен бүлек мөдире Рәшит Әхмәтҗан.

Гади клерк иде редактор дигәнебез. Белмим, намусы уяндымы икән аның еллар үткәч?!

*«Даһилар мөнбәре» китабы. – Казан, 2014*

# «Тукай миңа мәрхәмәтле булды...»

Илдус Әхмәтҗанов

*Татарстанның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Татарстанның халык артисты, Россиянең атказанган артисты Илдус Әхмәтҗанов Тукай рольләрен башкару тарихы турындагы истәлекләре белән уртаклашты.*

Габдулла Тукай рольләрен уйнау матур мизгел, дип кенә әйтер идем. Беренче тапкыр аны телевизион фильмда уйнадым. Тукайның тууына 90 ел тулу уңаеннан, 26 яшемдә. Икенче мәртәбә 100 ел тулу уңаеннан театр сәхнәсендә. Тукай ролен уйнау ике очракта да миңа шулкадәр дулкынландыргыч зур вакыйга булды. Тукайга килү, Тукай роленә әзерлек чоры шактый озын булды, мәктәптә түгел, хәтта мәктәпкәчә яшьтә үк башланды, дисәм хата булмас. Безнең гаиләдә шундый күркәм гадәт бар иде: кычкырып китап уку. Кич белән, эшләр беткәч, бөтен гаилә кешеләре җыела идек тә, Рәшит абыем безгә китап укый иде, аеруча Тукай шигырьләрен яратты. Сабый вакытымнан ук аның «Таһир-Зөһрә» кыйссасын укыганы истә калган. Әни, башка хатын-кызлар елый-елый тыңлый иде... Бераз үсә төшкәч, үзем дә Тукай шигырьләрен яттан укый башладым. Сабый баланың хәтере яхшы була. Минем дә, гомергә онытылмас булып, шул чордан ук Тукай шигырьләре күңелемә сеңеп калды. Мәктәптә укый башлагач, Рәшит абыемдагы көрән тышлы Тукай томнары минем кулга күчте. Габдулла Тукайның бөтен шигърияте, прозасын, хәтта китапның артындагы искәрмәләрен дә укып, шул чордагы язучыларның, шагыйрьләрнең исемнәре, Тукай әсәрләрендәге геройлар, образлар белән тирәнрәк танышып, рухи дөньямны баеттым. Болар барысы да Тукай ролен уйнарга әзерлек булгандыр...

***

1976 ел. Апрель ае. Ул миңа кичәге көн кебек кенә тоелса да, инде 40 ел вакыт узып киткән. Ләкин мин һаман, шул көннәр тәэсиреннән арына алмыйча, шул чордагы вакыйгалар әсирлегендә яши бирәм. Чөнки бу чор минем Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында эшли башлаган бәхетле яшьлек елларым һәм... 1976 елның апрель аен мин икенче мәртәбә, өряңадан, Тукай күлмәген киеп дөньяга килгән – туган көнем дип тә саныйм. «Тукай күлмәгендә» дигән сүз укучыларны сискәндермәсен иде. Мин бу гыйбарәне һич кенә дә үземне Тукай белән тиңләштерергә, йә булмаса, үземне гайре табигый кеше итеп күрсәтергә теләп әйтүем түгел. «Бәхетле бала күлмәге белән туа» дигән әйтем бар бит. Әйткәнемчә, мин үземне бик бәхетле итеп саныйм, һәм бу бәхетемнең чыганагы, әлбәттә, Тукайга барып тоташа. Сөекле шагыйребезнең тууына 90 ел тулган юбилей елында Казан телевидениесе Тукайга багышлап телевизион фильм төшерергә карар кыла. Фильмга сценарийны күренекле артист һәм режиссер Әхтәм Зарипов яза, шулай ук фильмның режиссеры итеп тә аны тәгаенлиләр.

Көннәрнең берендә Әхтәм абый, безнең театрга килеп, үзенә кирәк булган артистларны җыеп алды да (бәхетемә, исемлектә мин дә бар идем), «Яз сулышы» дип аталган әсәрен укыды. Әсәрнең төп герое, әлбәттә, Габдулла Тукай. Сценарий барыбызга да ошады. Хуплап кабул иттек. Чөнки ул күләме белән дә, әйтергә теләгән фикере, теле, стиле, динамикасы шул чор атмосферасын төгәл чагылдыруы белән сценарий таләпләренә тулысынча җавап бирә торган әсәр




**Илдус Әхмәтҗанов Тукай ролендә**

булып, анда Тукай иҗаты, аның хатлары, Тукай турындагы истәлекләр автор тарафыннан баетылып, ышандыру көченә ия булган сәнгати чаралар ярдәмендә драматик калыпка салынган иде. Безне алда киеренке һәм җаваплы эш көтә иде. Вакыт бик аз калган. Тукайның туган көненә — 26 апрельдә фильм экраннарга чыгарга тиеш.

Мин бу очрашудан бәхет дәрьясына ташланган мәҗнүндәй түбәм күккә тиеп кайтып киттем, чөнки минем кулда олуг хәзинә — Тукай роле иде. Ләкин бу эйфория озакка бармады. Беренче репетицияләрдә үк, көймәм комга терәлеп, төшенкелеккә чумдым. Әллә тәҗрибәсезлектән, әллә Тукай шәхесенең бөеклеге ирешеп булмаслык биеклек булып шиккә төшердеме — минем җаным да, тәнем дә акылыма буйсынмыйча карыша башладылар. Репетицияләр минем өчен газапка әйләнде. Мин һаман бер урында таптанам. Үсеш, алга барышның әсәре дә юк. Инде Әхтәм абыйның да күңеленә шом керә башлады бугай. Ул, аптырагач, ничек уйнарга икәнен үзе күрсәтеп бирә башлады. Бу алым — режиссерның артистка булган ышанычы тәмам беткәннән соң гына кулланыла торган, тыелган алым. Аның уены миңа шулкадәр тәэсир итә, мин аны чын Тукай итеп кабул итәм, тетрәнеп карап торам, ләкин кабатлый алмыйм. Шундый мизгелләрнең берсендә мин режиссерга: «Әхтәм абый, нигә үзегез генә уйнамыйсыз Тукайны?» — дип әйтеп салдым. Ул, бәлки, мине киреләнә, капризлана дип уйлагандыр, озак кына түшәмгә карап уйланып торды да, берни әйтмичә, репетициядән чыгып китте. Мөгаен, мин аның авырткан җиренә кагылганмындыр. Ул репетицияләрдә безгә Тукайның тормышыннан, иҗатыннан шулкадәр күп мәгълүмат бирә иде, ул мәгълүматның байтак өлешен ул заманда хәтта китаплардан да эзләп табып булмый иде. Бу — бер-ике ай эчендә генә тупланган мәгълүмат түгел иде. Димәк, ул бөтен гомере буе Тукай иҗатын өйрәнгән, эзләнгән, тапкан... һәм бүгенгә кадәр хәтер сандыгында саклаган. Ник? Тукай турында фильм төшерәм дипме? Юктыр, чөнки сәнгать дөньясына ул иң элек режиссер буларак түгел, ә актер буларак килеп кергән кеше. Мөгаен, ул әнә шул актерлыкка укыган елларында ук Тукай ролен уйнарга хыялланганадыр һәм, шул теләген тормышка ашырырга теләп, Тукайның тормышын, иҗатын өйрәнгәндер. Яшь чагындагы фотоларына күз салсаң, аның тышкы кыяфәте белән дә Тукайга охшаган булуын күрми мөмкин түгел. Бәлки, ул үзенең ниндидер сәбәпләр аркасында тормышка ашмаган хыялын минем аша тормышка ашырмакчы булгандыр?! Аның ышанычын аклый алырмынмы соң? Ай-һай...

Әнә шулай өмет белән шик арасында яши-яши, фильмны тасмага төшерү көне дә килеп җитте. Иртәнге якта телестудиягә җыелдык. Анда декорация, барлык кирәк-ярак, кием-салым, аппаратура әзер. Тиешле шартлар һәм атмосфера тулысынча тудырылган. Ниһаять, мин, гримланып, Тукайны уйныйсы киемнәрне киеп, Болгар кунакханәсендәге 40 нчы номерны хәтерләткән декорация-бүлмәгә кереп, язмышыннан качып котылырга теләгән кешедәй, баштанаяк одеялга төренеп, тимер караватка менеп яттым. Мин бизгәк авыруыннан туңып калтыраган Тукайны уйнарга тиеш идем. Дөрес, одеял астында чынлап та калтырыйм, ләкин бизгәктән түгел, ә куркудан. «Төшерә башладык» дигән сигнал көтеп ятам. Ул сүзләр минем колакка тиз генә



Г. Исхакыйның «Зөләйха» фильмындагы Әхмәтҗан ролендә

килеп ирешмәсеннәр иде, дигән уй башымнан чыкмый. Хыялым — одеял астында, караңгыда мөмкин кадәр озаграк яту, хәтта мәңге шуннан чыкмаска да риза. Әмма бу хыял гына. Чынбарлыктан качып булмый. Төшерү процессы башланды... Көтмәгәндә одеял аша ягымлы, кайгыртучан, җанга якын хатын-кыз тавышы ишетелгәндәй булды. Чү?! Мәрхүмә әнием тавышы бит бу. Шул мизгелдә минем зиһенемдә ниндидер бер балкыш, нурланыш, яктылык хасил булды. Шул мине реаль дөньядан башка дөньяга алып кереп китте. Миндә ниндидер үзгәреш пәйда булды. «Бу минме соң?!» — дип, үз-үземнән шикләнә башладым. Куркуданмы, әллә реаль дөньяга кабат кайтасы килүдәнме, яшен тизлеге белән бөркәнгән одеялымны бер читкә алып аттым. Әмма реаль дөньяга кайту насыйп булмады: мин әнием тавышы белән сөйләшүче кунакханә хәдимәсе (артистка Вера ханым Минкина) белән әңгәмә корып җибәрдем, һәм фильмның башыннан ахырына кадәр әнә шундый гайре табигый халәттә сәер дөньяда яшәп алдым. Ниһаять, фильмны төшерү тәмам, дигән мәгънәне аңлаткан таныш «стоп» сүзе мине яңадан чынбарлыкка, бүгенгемә, ягъни реаль дөньяга кайтарды. Режиссер барыбызны да котлап рәхмәт әйтте. Без — артистлар да, аңа рәхмәтебезне әйтеп, үзара котлаша башладык. Ләкин минем күңелдә кабат шик-шөбһә. Котлашулар да формаль котлашу гынадыр сыман тоелды. Шундый халәттә саубуллашып кайтып киттем. Атна-ун көн ашым — аш, йокым йокы булмады, дөньяга чыгарга, кешеләргә күренергә куркып яшәдем. Ниһаять, Тукайның туган көне — 26 апрельгә бер көн кала фильмны экраннарга чыгардылар. Япа-ялгызым калып, бөтен дөньясыннан качып, өмет белән шик арасында, сәгате җиткәч, телевизорны ачып җибәрдем. Башланды... Күз йомарга да куркып, һәрбер әйтелгән сүзне, һәр хәрәкәтне игътибардан читтә калдырмыйча, фильмны ахырына кадәр карап бетердем... һәм... әйтергә кирәк, көтмәгәндә, фильм миңа ошады! Үземнең уенымны да шул исәпкә кертеп әйтүем бу. Өстән тау төшкәндәй булды. Дөнья яктырып китте, һәм шул дөньяда яшисе килә башлады. Чү! Тукта, әгәр дә бу галлюцинация генә булса?! Йокысыз төннәр, борчулы көннәр тудырган авыру миңа үзем күрергә теләгән хыялымны гына күрсәткәндер, бәлки? Күңелдәге шатлык хисләре белән аяусыз көрәш алып барган әнә шул шик күңелнең бер почмагында һаман патшалык итә иде әле. Башымны бик югары күтәрмичә генә урамга чыгып киттем, театрга — эш урыныма юнәлдем. Театрга җиткәнче, миңа берничә тапкыр: «Әнә, Тукай, — дип, бармак төртеп күрсәтеп калдылар. Әллә мыскыл итүләре инде? Алай дисәң, йөзләрендә, күзләрендә бертөрле дустанә караш, елмаю чагыла. Барысын да яхшыга юрыйм да алга баруымны дәвам итәм.

***

Икенче тапкыр шагыйрьне Тукайның 100 еллыгында уйнадым. Туфан Миңнуллин пьесасы буенча куелган «Без китәбез, сез каласыз» спектаклендә. Бу чорда инде мин Тукай яшен дә узып киткән, шактый тәҗрибә туплаган артист идем. Беренче мәртәбә 26 яшемдә уйнасам, хәзер 36 яшь... Шагыйрьнең 100 еллыгына Әхтәм Зарипов икенче, күпсерияле фильм әзерләгән. Миңа

Тукай ролен тәкъдим итте, ләкин мин аңа алынмадым, чөнки телевидение өчен үземне өлкәнрәк дип санадым. Аннан вакытым да булмады... Театрда да Тукай ролен уйнау башланды, телевидениедә дә башланырга тиеш иде. Мин, әлбәттә, театрны сайладым. Спектакльдә Тукайның Акчуриннарга кунак булып бару чоры күрсәтелә. Икенче тапкыр Тукайны уйнарга туры килсә дә, телевизион спектакльдәге Тукай белән театрдагы Тукай арасында шактый аерма бар. Авторлар әйтергә теләгән фикер башка, вакыйгалар, персонажлар да үзгә... Әмма шул ук авырлыклар, шул ук борчулар... Бу юлы инде мин рольгә очраклы килеп эләкмәдем, ниндидер кабынып китүләр дә башка килмәде. Алар кирәкмәгәндер дә, чөнки мин инде шактый тәҗрибә туплаган артист идем, сәхнәдә фикерләвем дә башкачарак булды...

Минемчә, спектакль бу очракта да уңышлы килеп чыкты. Тукай үзенең халык язмышы өчен борчылып яшәвен һәм халык бәхете өчен көрәшүен күрсәтте, дип уйлыйм. Акчуриннар белән бәхәскә кереп, хәтта аларга каршы шактый гына каты сүзләр әйтергә дә мәҗбүр булды.

Спектакльнең режиссеры Марсель абый Сәлимҗанов иде. Ул артистларны да бик сайлап, иң яхшыларын гына туплады. Тукайның 100 еллыгы! Җаваплылык гаять зур иде.

***

Телевизион спектакльдән соң миңа урамда, гомумән, бөтен җирдә Тукай дип дәшә башладылар. Бу миңа бер рәхәтлек тә бирә иде... Икенче көнне шагыйрь хөрмәтенә уздырыла торган шигырь бәйрәменә юл алдым. Анда исә мин көтмәгәндә шул көннең героена әверелдем. Бәлки, алай ук та булмагандыр, ләкин миңа шулай булып тоелды. Котлаулар, котлаулар һәм котлаулар... Бу котлауларны ишетү рәхәт булса да, һаман җиз иләк аша үткәреп кенә кабул итәм. Шулвакыт дуслары белән ни хакындадыр сөйләшеп торган Мөхәммәт ага Мәһдиев, мине күргәч: «Менә бу егет – татар халкына Ходай тарафыннан Тукайны уйнар өчен җибәрелгән егет», – дип әйтеп салмасынмы! Туры сүзле, юк-бар мактаулар белән мавыкмаучы Мөхәммәт абыйның бу сүзләре котлауларның кыланып әйтелгән юк-бар сүзләр генә түгеллегенә, ниһаять, ышандырды. Иелебрәк килгән башым югары күтәрелде, һәм күзләрем көннең кояшлы, аяз булуын абайлады. Мөхәммәт абыйның бу сүзләренә соңрак Татарстанның Беренче Президенты Минтимер Шәймиевнең миңа мактаулы исем тапшырганда әйткән: «Илдусны күргәч, Тукайның үзен күргән кебек булам», – дигән сүзләре, һәм Мостай ага Кәримнең: «Тукай ролен башкаручы Илдус Әхмәтҗанов яхшы уйнады. Тукай тормышчан, ышандыра. Артист шагыйрь образын әдәпле итеп, югары культура күрсәтеп башкарды», – диюе, янә Мөдәррис Әгъләмовның: «Мин Казан буйлап Тукайны эзлим. Һәм миңа аны күреп калырга насыйп булды. Ул изге зат – Илдус Әхмәтҗан кыяфәтендә иде. Илдус Әхмәтҗан – Тукайлы гасырның асыл баласы», – дип әйтүе һәм башка әдәбият-сәнгать әһелләренең дә Тукайны уйнавым хакында матбугатта басылып чыккан матур-матур фикерләре халыкның: «Әнә, Тукай килә», – дигән сүзләрен тәфсир кылу, шәрехләү булып яңгырый сыман. Хәзер дә, Тукай яшен узып китеп, өченче тапкырын атлап килүгә карамастан, һаман да «Тукай» дип дәшәләр. Хәтта Тукай шигырен сөйләргә чыксам да: «Менә телевизордан күрдек, Тукай булып чыктың», – диләр. Халык мине шигырь укучы итеп түгел, ә Тукай итеп таный башлады.

***

Абыем, шагыйрь Рәшит Әхмәтҗановның спектакльне бәяләгәнен хәтерләмим, ләкин шулкадәр борчылып, театрга уйнарга килгәнче үк, ишек төбендә мине каршылап, аннары озатып калуы хәтердә. Ул шулкадәр бирелеп, борчылып, минем өстә сакчы фәрештә сыман торды.

***

Тамашачылар, мәктәп укучылары белән очрашулар вакытында миннән еш кына: «Тукай ролен уйнау авыр булдымы?» – дип сорыйлар. Хикмәт авырлыкта гына түгел. Татар артистлары арасында теләсә нинди авырлыклардан да курыкмаучы, миннән күпкә талантлырак артистлар байтак. Ләкин Тукай ролен башкаручы һәм халык тарафыннан «Тукаебыз» дип кабул ителгәннә-



**Ирек мәйданында. Әхәт Мушинский һәм Илдус Әхмәтҗанов. 1991**

ре сирәк. Сәбәп нидә? Ирексездән Мөхәммәт ага Мәһдиевнең сүзләре искә төшә: «Ходай тарафыннан җибәрелгән»... Бәлки, чынлап та, шулайдыр, Ходай тарафыннан җибәрелү кирәктер!

Ә шулай да Тукай кебек бөек шәхесне уйнау җиңел түгел, бик җаваплы эш. Әгәр сиңа ул эшне йөклиләр икән, әгәр син шул эшкә алынасың икән, димәк, җилкәңә авыр таш-тау китереп салалар да, син шуны күтәрергә тиеш буласың. Ул авыр йөккә чыдый алмыйча, йә имгәнәсең, йә, әкияттәге кебек, башта тез тиңентен, аннан билдән, ахыр чиктә муеныңнан җиргә батып күтәргән табың астына күмелеп каласың.

Аллага шөкер, миңа башка язмыш насыйп булды. Тукай мине батырмады, киресенчә, көчле куллары белән күтәреп, куенына кысты, бәла-казалардан саклап калды.

***

Тукай – татар халкы бәхете өчен көрәшеп яшәгән кеше. Анда – көчле көрәшче рухы. Күрәсең, шушы рух миндә дә Тукай иҗаты аша тәрбияләнгәндер. Мин үзем дә татар халкының азатлыгы өчен борчылып яшим. Мин хәзер дә халкым, милләтем өчен соңгы чиккә җитәргә әзер.

Мин үземне бәхетле кешегә саныйм. Чөнки Тукай миңа мәрхәмәтле булды. Дәрәҗәле исемнәр бирелүе дә, Тукай премиясе лауреаты булуым да, барысы да, барысы да Тукайга, аның иҗатына барып тоташа...

***

Тукай – журналист. Байтак газета-журналларны чыгаруда катнашкан. «Безнең мирас» журналы шулкадәр әйбәтләнде, без, театр артистлары, журналны рәхәтләнеп кулдан-кулга йөртеп укыйбыз һәм барыбызның да телennән: «Безнең мирас» журналы шулкадәр затлы», – дигән сүзләр ишетелә. Журналлар арасында беренче урында тора, дип бәялибез. Тукай да, әлбәттә, мактар иде, чөнки «Безнең мирас» журналы шулкадәр күп, җитди, милли темаларны күтәрә, тарихны, бүгенге көнне дә яктырта. Әлбәттә, Тукай: «Булдырасыз, егетләр», – дип әйтер, ләкин шул ук вакытта шагыйрь бик әче телле дә булган бит әле! Ул яратып, әче итеп чеметеп алырга да сүз табар иде...

*«Безнең мирас» журналы. – 2016. – № 4*

# «Кыр казлары очып узарга...»

*(Рәшит Әхмәтҗановның тууына 75 ел)*

Мөдәррис Вәлиев

Рәшит абый Әхмәтҗанов белән без күпмедер вакыт абый-энекәш кебек аралашып яшәдек: берара күршеләр булдык, «Казан утлары» журналында бергә эшләп алдык. Ул әле минем беренче редакторым да: «яшь язучылар белән эшләүче» бер агай, «син ялгыш юлда йөрисең» дип, студент елларында язганнарымны юкка чыгаргач, Рәшит абый, аларны укып, хуплап, алга таба иҗатка ымсындырган иде. (Ул, гомумән, якын күргән кешеләрен үсендерергә-канатландырырга-күтәрергә яратты. Үзе какча гәүдәле генә булса да, Фәнис ага Яруллинны әллә ничә тапкыр фатирына туры мәгънәсендә күтәрешеп менгәнен күпләр белә.) Озын сүзнең кыскасы, «Яшьлектән хат» дигән шигырьләр китабым аның фатихасы белән, яшьлек кайнарлыгында язылып, инде суына башлаганнан соң булса да, 25 ел узгач дөнья күрде. Ә безнең танышу күпкә элегрәк – мин Казанга укырга килгәч үк булган иде. Аның сеңлесе Сания белән имтиханга керәбез, ә Рәшит абый белән минем Шамил абыем (Маннапов), ут йотып, без чыкканны көтеп торалар. Миңа ул чакта Луиза апа белән аларның тимер юл вокзалына якын (Чернышевский урамында) торган куышында да булырга туры килгәләде. Бервакыт хәтта берме, икеме яшьлек кызы Ләйләне карарга ышандырып, Рәшит абый җәһәт кенә үз йомышлары белән йөреп-әйләнеп кайтты... Рәшит Әхмәтҗановның «Ак канатлар» китабына «Татарстан яшьләре»ндә басылган рецензиям шуңа күрә «Өч очрашу» дип аталган иде. Беренче очрашу – танышкан вакытыбызда, икенчесе – аның мәшһүр Тукай клубында канатланып-очып шигырь укуын тыңлаганда, ә өченче очрашу – менә шушы затлы китап булды. (Бу – әдәби тәнкыйть өлкәсендә беренче тапкыр каләм сынап каравым иде.)

Шуннан бирле мин Рәшит абыйның һәр шигырен диярлек яттан беләм, аларга бәя биргән булып, аның иҗаты хакында язылганнарны кабатлыйсым килми...

> Әллә инде кыр казлары кайта,
> Яктылыклар арта бу якта.
> Онытмагыз –
> Казлар канатында
> Очып киткән сөю елата.
> ................................
> ...Зәңгәр күзләрендә – зәңгәр һава,
> Кыр казлары очып узарга...

Соңгы ике юл инде менә кырык елдан артык күңелемнән китми. Чөнки университет коридорын бер башыннан икенчесенә кадәр иңләгән «Әдәби сүз» стена газетасын чыгаруга мәсьүл (җаваплы) кешеләрнең берсе буларак, мин аның иҗатчы кызларыбызга багышланган санына, аншлаг итеп, шул юлларны элдерткән идем.

Рәшит Әхмәтҗановның тормыш һәм иҗат юлын кыскача булса да бүгенге укучының исенә төшерик.



**Эне-сеңелләр университетка керү имтиханнарын тапшыралар, ә абыйлар борчыла. Сулдан уңга: Габделхәй Сабитов, Рәшит Әхмәтҗанов, Шамил Маннапов, Д. Галләмов. Казан. 1971, июль**

Билгеле булганча, ул 1941 елда Баулы районы Татар Кандызы авылында туа. Авыл мәктәбендә җиде сыйныф белем алганнан соң, төзүчеләр әзерләү училищесында укый, аны тәмамлагач, нефть районнарында һәм Әлмәт шәһәрендә ташчы булып эшли. Аннары Совет Армиясендә хезмәт итә. Армиядән кайткач, Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга кереп, 1969 елда аны тәмамлап чыга һәм башта Мәдәният министрлыгында сәнгать эшләре буенча инспектор, аннан соң «Яшь ленинчы» һәм «Татарстан яшьләре» газеталары редакцияләрендә әдәби хезмәткәр булып эшли. 1980 елдан вафатына кадәр ул «Казан утлары» журналы редакциясендә бүлек мөхәррире иде. Рәшит Әхмәтҗановның шигырьләре матбугатта 1950 елларның ахырында күренә башлый, һәм ул 1959–1961 елларда «Азат хатын», «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналларында басылган шигъри бәйләмнәре белән әдәби җәмәгатьчелектә кызыксыну уята. Университетта укыганда ук, «Хыялларым үзем белән» дип аталган беренче шигъри җыентыгы дөнья күрә, укучылар тарафыннан җылы каршы алына. Алда телгә алынган «Ак канатлар» җыентыгында якты идеалларга табынган, халкының киләчәгенә ышанган яшь кешенең уйланулары һәм кичерешләре тасвирлана. Аның иҗатын үз иткән Хәсән ага Туфан «Өметләрне аклады» дигән, төп фикере исеменнән үк аңлашылып торган мәкаләсендә аңа беренче булып фатихасын бирә. Гомумән, Рәшит Әхмәтҗанов иҗатында «туфанилык» ачык ярылып ята – беренче чиратта ул халык иҗатыннан килүче образлар, тәгъбирләр һәм аһәңнәрдә чагыла. Сибгат Хәким, Гали Хуҗи кебек олпат шагыйрьләр яшь каләмнең табигый сәләтен һәм шигырьләренең тормышчанлыгын билгеләп үтәләр, аны яңа иҗат табышларына рухландыралар. Шагыйрьнең «Ак канатлар», «Гомер чишмәсе», «Җан яктысы», «Йөрәк бәйрәме», «Алмалы җәй», «Кавышыр көн», «Ачлык мәйданы» һ.б. шигъри китаплары, гәрчә кайбер каләмдәшләре хаклы искәрткәнчә, күрәкараучы тәнкыйтьчеләр «обойма»сына үзе кермәсә дә, гади һәм гадел укучы мәхәббәтен яулый. Аның аерым китаплары һәм тулаем иҗаты турында төрле елларда матбугатта сүз әйткән Р. Батулла, Роберт Әхмәтҗанов, Ф. Яруллин, Ф. Баттал, А. Хәлим, М. Әгъләм һ.б. әдипләребез, шигырьләренә нечкә лиризм, образлар байлыгы, шигъри интонацияләрнең кискенлеге хас; алардан халык иҗатына хас моң-сагыш саркыла; яңача яңгыраш төсмерләре биреп, халык телбизәкләреннән оста файдалана; аларга тыйнаклык һәм җыйнаклык, садәлек хас; аның

лирик каһарманы әхлакый сафлыгы, холык-фигыленең бөтенлеге белән истә кала, дип билгеләп үтәләр. «Шигырь китапханәсе» кебек абруйлы сериядә чыккан «Моңлану» җыентыгына сүз башы язган Равил Фәйзуллин аның иҗатына тулаем бәя бирсә, вафатыннан соң «Рухият» нәшриятында дөнья күргән «Сайланма әсәрләре»нә кереш сүз авторы Марсель Галиев, шагыйрьнең тормыш юлын, холык-фигылен – балаларча ихласлыгын һәм житди җорлыгын үзенә хас сурәтле-җанлы итеп тасвирлаудан тыш, иҗатының төп хасиятләрен дә ача.

...Мин агарам, һаман агарам –
Күренмидер хәтта күз карам...

Шулай узар минем гомерем.
Бөтен гомеремә бер гөлем

Син генә бит. Димәк, иртәгә
Миңа тагын юлга китәргә –

Утка яга-яга төннәрне,
Озайтырга синең көннәрне...

Тугрылыклы «аккош мәхәббәте» турында, Хәсән Туфаннан соң, шулай фәкать Рәшит Әхмәтҗанов кына яза алгандыр сыман.

Алда телгә алынган китаплар арасында миңа «Алмалы җәй» ни өчендер аеруча якын. Ул – Рәшит абыйның бишенче китабы. «Бишенче» дип аерып әйтүем шуңа: башка күп кенә кордашлары әдәбият бусагасына балалар өчен язган беренче «бишек җырлары» белән аяк бассалар, Рәшит Әхмәтҗанов әлеге җыентыгына тәҗрибә туплаган шагыйрь булгач кына алынырга җөрьәт итә. Кызы Ләйлә, «блондин»ы Айдар (сабый чагында аксыл чәчле улын ул, яратып, шулай атый иде) өчен язгангамы икән, аның бу китабы гаҗәеп ихлас, җыйнак, уйнак һәм бер үк вакытта фәһемле, тәрбияви вазифалы шигырьләрдән тора. (Сүз уңаенда әйтергә кирәк, ул чакта әле яшь рәссам Лилия Золондинованың да «йомры, йомшак» рәсемнәре китапның шулай еллар буена хәтердә калырлык булуына, яңадан-яңа буыннарны үстерешүенә ярдәм итә.) Әгәр игътибар беләнрәк тыңласаң, аның балаларга атап язган шигырьләрендә дә халыкчан зирәклек, олылык, олпатлык аһәңнәрен ишетәсең:

Бергәләп җырлыйк «Туган тел» җырын,
Кечкенә чакта җырлаган кебек.

Һавада – кояш, җирдә туган тел
Булмаса әгәр, зураймас идек...

Өземтәләр күбәеп китсә дә, тагын берсен китерми уза алмыйм:

Җиңелмә сүздә, җиңелсәң,
Җиреңне дә дауларлар.

Юкка гынамыни җирдә
Чичән булган бабаңнар.

Хәтеремдә әле: энҗе бөртегедәй ялтыраган, йөрәк кебек тибеп торган, учка сыярлык җыйнак лирик шигырьдә ат уйнаткан Рәшит абыйның поэма жанрында да көчен сынап карыйсы бик килә иде. «Исәннәр моңы» дигән беренче поэмасында ул, үз шигъри стиленә хас җыр, риваять, әкият алымнарын да кулланып, сугыш һәм тынычлык, заман агышы һәм хәтер, мәхәббәт һәм нәфрәт кебек мөһим мәсьәләләрне күтәрә, туган авылының рухи яшәешен күз алдына бастыра. Шуннан соң дөнья күргән берничә поэмасы арасында, әлбәттә, «Аучылар кибетендә» һәм «Бишташ» шагыйрьнең һәм тулаем татар шигъриятенең зур табышы булырга лаеклылар.

Алда әйткәнемчә, Рәшит Әхмәтҗанов иҗатының чын бәһасен белгән каләмдәшләре аның турында байтак яздылар. Аларга өстәп, «зәңгәр күзләрдәге зәңгәр һава»дагы бер генә якты ноктага игътибар иттерер идем, ул да булса шагыйрьнең канатлары – аккошлар, кыр казлары, сандугачлар очкан биеклеккә ашып, күңел күзе белән ерак араларны, ерак гасырларны иңләп очуы.

Кораб китте еракларга, зур юлларга,
Карыйм күздән югалганчы шул якларга.

Сез китмәгез, акчарлаклар, акчарлаклар,
Чит җирләрдә каерыла пар канатлар.

Яки:

Талларга качты сандугач –
Мин аны эзлиммени?

Сандугач керде күңелгә –
Җырламый түзиммени?!

Әлбәттә, аның «кош»лары илсез-җирсез түгел, алар сайрап кына тормый, ә, тигезсез булса да, көрәш мәйданына чыга, гавамны тетрәндерерлек итеп оран сала. Бу урындагы кинаям Рәшит Әхмәтҗановның «Ачлык мәйданы» дип исемләнгән поэмасына төбәлгән.



**Рәшит Әхмәтҗанов һәм Эльмира Шәрифуллина**

Әсәрдә шагыйрьнең, милләтпәрвәр көрәштәшләре белән ил азатлыгын хаклап һәм яклап, 14 көн буена Ирек мәйданында ачлыкта утырулары, шунда кичергән уй-тойгылары урын ала. Әлеге поэма халкыбызның үткәнен һәм киләчәген йөрәге аша уздырып, аның горурлыгын, үзаңын уяту омтылышы белән сугарылган, милләт һәм тел язмышы өчен чын күңелдән янган Рәшит Әхмәтҗановның җан авазы, бөтен иҗатына сөземтә булды:

Мәйданда – догалы читекләр,
Мәйданда – дагалы итекләр...

Ә. Закирҗановның җиңел кулы белән, «Ачлык мәйданы» татар баласы укырга тиешле 100 китап исемлегенә кертелгән иде. Хаклы рәвештә!

Рәшит абый «төзәтеп булмаслык» оптимист иде. Әмма:

Мин җылытам әле, дөньям, сине,
Җаным суынганчы җылытам... –

дип, ил гаме белән янган йөрәге ярылып, моннан егерме ел элек ул мәңгелеккә китеп барды.

Күңелләрдә калган шәхес, кабатланмас олы иҗаты белән татар шигъриятенең биек мизгелен тамгалаган Рәшит Әхмәтҗановны укучылар һәм каләмдәшләре генә югары бәяләп калмады, ул «Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исемгә, Язучылар берлегенең Гаяз Исхакый исемендәге бүләгенә лаек булды.

*«Казан утлары» журналы.– 2016. – № 5*

# Бөредә калган мәхәббәт

Роза Камалетдинова

Кораб китте еракларга, зур юлларга,
Карыйм күздән югалганчы шул якларга.
Сез китмәгез, акчарлаклар, акчарлаклар,
Чит җирләрдә каерыла пар канатлар.
Мәхәббәтне ала алмый бер упкын да,
Хыянәтне күтәралмый бер дулкын да.
Сез китмәгез, акчарлаклар, акчарлаклар,
Кавышуны вәгъдә итә пар канатлар.
Сөйгән ярым китеп барды кулын болгап,
Кайтыр микән тагын миңа юллар урап?
Сау булыгыз, акчарлаклар, акчарлаклар,
Мәхәббәткә кирәк икән пар канатлар[1].

Нечкә күңелле, батыр йөрәкле Шагыйрь иде ул. Җаны халыкка тоташкан шагыйрьне Идел акчарлагына һәм зур корабка тиңләп булыр иде. Кораб китте...

Озын гомерле, халык йөрәгенә кергән җырлар дигәндә, шагыйрь Рәшит Әхмәтҗанов шигыренә композитор Хөснул Вәлиуллин көй язган «Акчарлаклар» җыры кабат-кабат хәтердә яңара. Без яшь чакта туган, кадерле истәлекләргә бай булгангамы, ул җыр күңелләргә мәңге онытылмаслык булып уелып калган. Рәшит-сабакташ белән бергә әле кайчан гына Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә имтиханнар биреп йөргән идек. Солдат каешы буган, дөнья күрергә өлгергән егетләрнең берсе — Рәшит Әхмәтҗанов безне, мәктәптән генә килеп, гыйлем йортына аяк баскан, унсигезәр яшьлек кыз-ыркынны бер күрүдә гашыйк итте дисәм дә, арттыру булмастыр. Какча гәүдәле, ягымлы зур күзле, йөрәккә үтәрлек үткен карашлы, мөлаем егет иде ул. Армия «бүләге» — чәче сирәкләнеп коела башлавы олысымак кыяфәт бирә, хөрмәтләп «абый» дип йөртәбез. Укый башлауга, сентябрь башларында ук, беренче, икенче курс студентларын колхозга ярдәмгә — бәрәңге алышырга озату гадәте бар иде. Ютазы ягындагы Бәйрәкә Тамак авылына килеп урнашуыбыз истә әле. Юньләп бер-беребезне белмәсәк тә, «безнекеләр» дигән тылсымлы сүз телдә. Арып-талып, кырда эшләп кайтабыз да, юынып, чәйләп алуга, клубка ашыгабыз. Студент халкын зарыгып көтәләр. Концерт-спектакльләр әзерләү, авыл халкына ял кичәләре оештыру — безгә йөкләнгән күңелле гамәл ич. Арабызда атказанган артистларыңны уздырырлык шәп гармунчы да бар, җырчы-биючеләр дә байтак.

Ә шагыйрь егетебез — Рәшитебез үзе генә дә ни тора! Ялкынланып шигырь укый башласа, зал тып-тын кала. Шул чакта ук танылган шагыйрь иде инде ул. Дус-ишне сөендереп, Рәшитнең тәүге — «Хыялларым үзем белән» дигән җыентыгы китап нәшриятында дөнья күрде. Кызыктырып һәм сөендереп диюем арттыру түгел, чөнки татар бүлегенә кергәннәрнең күбесе каләм тибрәтә, язучы булырга хыяллана, хикәя-шигырьләре инде республика матбугатында күренгәли торган сәләтле яшьләр бит. 1969 елда диплом алган төркемдә илгә-көнгә билгеле, танылган шагыйрьләр Рәшит Әхмәтҗанов, Клара Булатова, Харрас Әюпов, Рәшит Ягъфәров, прозаиклар Флүс Ла-

[1] «Акчарлаклар» җыры (Рәшит Әхмәтҗанов шигыре, Хөснул Вәлиуллин көе).



**Курсташлар очрашуы. 1969 елгы чыгарылыш. Алдагы рәттә – университет галимнәре. 1989**

тыйфи, Роза Зәйнуллина-Туфитуллова, Равил Вәли, Сәгыйдулла Хафизов, Ләлә Сабирова, Роза Мулланурова, ягъни мин фәкыйрегез дә булу күпне сөйли. Язучы-журналист Роза Туфитуллова «Ялкын», «Азат хатын» – «Сөембикә» журналларының баш мөхәррире, Татарстан Дәүләт Советы депутаты булды. Ләлә Сабирова-Гыймадиева байтак еллар «Сабантуй» газетасын җитәкләде.

Колхоз басуын, кичке уеннарны искә төшерүем очраклы түгел. Мәшһүр «Акчарлаклар» җырының яралгысы шул чакта ук борын төрткәндер дип ышанам. Авыл яшьләре студент туташларны озаткаларга атлыгып торса да, безне җил дә тидерми саклап йөртүче «абыйлар» бар: кырда булсын, клубтан кайтышлыймы, фатир ишегенә кадәр озатып куялар. Чит-ятларга сүз кушу кая!

Үткән еллар хатирәсен барлап утырганда, Ләлә дус искә төшергәне истә: «Клубтан чыктык кына, Рәшит култыклап алды. И ашыктыра, и җилтерәтә бу мине. Аягымнан чүәгем төшеп кала язды. Кая ашыктыра дисәм... алдарак гармунчы егетебез Роза Зәйнуллина белән сөйләшеп кайтып килә икән.

Аңладым серен: муеннан Розага гашыйк Рәшитем».

Шагыйрь мәхәббәте – үзе тылсым, үзе сер ул. Әмма иҗатка рухландыручы, илһам бирүче Муза – гашыйк иткән кызны без белмибезме инде?! Сылу, чибәр Аксубай кызына без дә аның күзе белән карый башладык бугай. Роза Зәйнуллина имтиханнарын гел «бишле»гә бирде. Әбисе, әнисе, апаларына кадәр һәммәсе мөгаллимнәр, шуңамы аның үз-үзен тотышы да, төс-кыяфәте дә үзгәрәк. Анардан зыялылык, затлылык хуш ис сыман бөркелеп тора. Зәвыклы. Ә елмаюы... җанны эретә. Шагыйрь күңелен шундый гүзәл зат җәлеп итүе бик тә табигый. Рәшит туташның күңелен яулау өчен бишкә ярылыр иде: шигырь арты шигырь багышлый. Әмма... Әллә туташның яшь булуы, ә бәлки Рәшитнең, хәзерге тел белән әйтсәк, публичный кешегә әйләнүе дә тәэсир иткәндер. Ихтимал, сербирмәс туташны көнләштерәсе килеп, шагыйрьнең башкаларга да күз аткалавы роль уйнагандыр, серле бу мәхәббәт бөредә килеш калды. Бөредә һәм җырда. Ә җыр



**Р. Әхмәтҗановның курсташы Роза Зәйнуллина (Туфитуллова)**

туу — үзе могҗиза бит ул. «Ике көннән радиодан абзагызның җыры яңгырар. Нәүмиз булып, ишетми калмагыз», — дип, Рәшит үзе хәбәр итте. Безнең «мәхәббәт җырыдыр әле» диюебезгә, серле елмаеп:

Мәхәббәт ул минем җанда, минем башта,
Минем канда яшеренгән...
Түгәсе бар күпме яшьләр,
Сөю миндә күпме яшәр —
Йә, кем белгән? —

дип, шигырьгә күчте. Өстәде: «Акчарлаклар» дигән җыр ул... Хикмәт, нәкъ менә Пушкинча килеп чыкты. «Светла моя печаль...»

«Акчарлаклар» җыры — кабатланмас яшьлек еллары хатирәсе дә, шагыйрьнең саф хисләре, садә мәхәббәте, җаннан китмәс моң булып та безнең йөрәкләрдә яши.

Шәриф Камал әсәре буенча куелган «Акчарлаклар» спектаклен дә бизәде бу җыр. Шагыйрьнең йөрәк сере җырга күчте: «Мәхәббәткә кирәк икән пар канатлар!»

«Сиңа гашыйк көнем югалган» дип язса да, яшьлек таңында тамырланган саф мәхәббәте Рәшит күңелендә соңгы сулышкача саклангандыр дип уйлыйм. Безнең баш мөхәррир Роза Туфитуллованың үзе, эше, гаиләсе турында җылы сүз ишетү бәйрәм була иде аңа. Тансыклап, «Сөембикә»гә — безнең бүлмәгә еш керә иде ул. Рухланып, без инде ничә тыңласак та туймый, ялыкмый торган шигырьләрен укудан ләззәт ала:

Их, бу җирне күпме таптады
Безнең йөрәк бәйрәмнәренең
Кыңгыраулар таккан атлары!

Киң колачлы, иҗаты киләчәк буыннарны да шатландырырлык шәп шагыйрь безнең сабакташыбыз.

Якты сагышлы, нурлы иде аның шигъри дөньясы. Күңелендә сакланган сөю хисе дә якты, нурлы, шуның нуры хәтта дусларына да төшә. Югыйсә Рәшитнең тормышын көйсез дип булмый: аны хөрмәт итә торган табибә Луизаны яр итүе, «минем блондиным» дип йөртә торган ак йөзле улы Айдарны, чибәр кызы Ләйләне, оныгын ихлас яратуы хак иде аның. «Сандугач керде күңелгә, җырламый түзиммени?» дип ялкынланып, әдәбиятта тәнкыйтьчеләр түтәл-түтәл итеп санап йөртә торган исемлекләргә сыймый, үзе бер дөнья булып яшәде, иҗат итте ул.

1991 елның эссе августында, Татарстанга мөстәкыйльлек яулау өчен көрәш кызган көннәрдә ул Фәүзия Бәйрәмовалар белән бергә эссе кояш астында ундүрт көн ачлык тотты. «Ачлык мәйданы»н — тетрәндергеч поэманы язды.

Рәшит Әхмәтҗанов Тукай туган айда — 14 апрельдә Баулы районы Татар Кандызы авылында дөньяга килгән. Даһиебыз сыман, ул да, милләт гамен, рухи кыйммәтләрне халык йөрәгенә җиткерергә теләп, гамьле уй-хисләр ялкынында бәгырен өтә-өтә иҗат итте.

Иртәрәк китте. Мәңгелек йортта — зираттагы урыны да Тукай янәшәсендә. Уйлап карасаң, монысы да бер хикмәт бит!

*«Сөембикә» журналы.— 2016. — Май*

# Шагыйрь дусларым


Хәлим Җәләлов

...1960 еллар әдәбиятта күтәрелеш еллары иде. Бу җанлану бигрәк тә шигърияттә сизелә. Бер төркем яшь шагыйрьләр әдәбият мәйданына ургылып килеп керделәр. Без, яшь артистлар, яшь шагыйрьләр белән гел аралашып яшибез. Даими рәвештә Актерлар йортында шигъри кичәләр үтә. Зал шыгрым тулы. Бу кичәләрне башлап йөрүче әле ул вакытта сакал-мыегы кап-кара Рабит Батулла иде. Мин үзем шагыйрь дусларым белән гел аралашып яшәдем. Эштән буш көннәремдә күңел гел Матбугат йортына тарта. Дусларым Зөлфәт, Рәшит Әхмәтҗанов, Мөдәррис Әгъләмов, Фаил Шәфигуллин, Ризван Хәмид һ.б. белән сүзебез гел әдәбият, сәнгать, шигърият турында. Гомумән, ул елларны «шигъри бум» дияр идем мин. Китапханәләрдә, завод тулай торакларында, авылларда, мәктәпләрдә очрашулар... Җәй көне берәр атнага очрашуларга чыгабыз. Клублар һәр көнне шыгрым тулы. Кызганыч, ул кичәләрне сагынып сөйләргә генә калды. Хәзер мин әйтә алмыйм, яшь шагыйрьләр белән яшь артистлар шулай аралашып яшиләр микән?



**Р. Әхмәтҗановның 75 еллыгына багышланган кичәдә. Равил Фәйзуллин һәм Хәлим Җәләлов. Казан, Тукай клубы, 2016**

1964 елның август ахыры. Без бер көннән училищега укырга барачакбыз. Мин 31 августта студентлар тулай торагына киттем. Егетләр каникулдан килгәннәр. Очрашу хөрмәтенә өстәл әзерләдек. Барыбызның да кәеф күтәренке. Егетләр арасында өстенә солдат гимнастёркасы кигән, ябыграк гәүдәле, чәчләре сирәгәя төшкән, ачык йөзле, миңа таныш булмаган бер егет тә бар. «Бу иптәшне кем дип белик?» – дим. «Рәшит Әхмәтҗанов булам»,– дип таныштырды ул үзен. «Тукта, тукта, шагыйрь Рәшит Әхмәтҗановмы? Быел чыккан «Хыялларым үзем белән» дигән юка гына шигырьләр җыентыгы авторымы?» – «Әйе, мин булам ул кеше. Егетләр, әгәр рөхсәт итсәгез, мин бер-ике шигыремне укыр идем»,– диде ул тыйнак кына. «Әйдә, әйдә, Рәшит дус, берне дә укы, икене дә укы. Сорыйбыз!» Ул икене дә, өчне дә, бишне дә укыды. Аның тәэсирләнеп укуын без бирелеп тыңладык. Укып бетергәч, ул, бераз кызарып, башын иде. Без шаулашып кул чаптык. Шигырьләр безгә бик тә ошады. Алардан ниндидер яңа сулыш, садәлек бөркелеп тора иде. «Егетләр,– дидем мин шул чакта,– бу исемне хәтерләп калыгыз, тиздән бу егет шигърият мәйданында ат уйнатачак әле!» (Минем бу сүзләрем анда утыручыларның исендәдер.) Сүзләрем рас килде. Еллар үтте. Рәшит татар шигъриятенең иң алдынгы сафына басты һәм гомеренең соңгы сәгатенә кадәр шул биеклектә калды.



**СССРның халык артисты Фуат Халитов янәшәсендә. Каршыда – Шәүкәт Биктимеров**

1972 елда аның «Ак канатлар» дигән җыентыгы дөнья күрде. Бу китап миңа шулкадәр көчле тәэсир итте – айлар буе куен кесәмдә йөреп, таушалып бетте. Җыентыктагы бөтен шигырьләрне мин яттан беләидем. Шул елны язучыларның поэзия секциясендә (секциянең җитәкчесе – Хәсән Туфан) шагыйрьнең яңа китабына күзәтү булды. Бик сәер инде, ләкин... Җыентык турында төп доклад ясауны миңа йөкләделәр. Бераз икеләнгәннән соң риза булдым. Күз алдыгызга китерегез: мин, яшь артист, бөек Хәсән Туфан һәм башка танылган шагыйрьләр алдында шагыйрь иҗаты турында чыгыш ясыйм. Мин инде үземчә тырышып әзерләнгән идем. Шагыйрьнең күп кенә шигырьләрен яттан укый-укый, үз фикерләремне дә әйтеп, шактый озын чыгыш ясадым. Соңыннан ишетүемчә, минем доклад Хәсән Туфанга ошаган. «Шагыйрь иҗаты турында сөйләгәндә, әнә шулай әзерләнергә кирәк»,– дигән, имеш.

Бераз вакыттан соң бу җыентык турында газетада да язып чыктым әле. Бу минем матбугатта беренче чыгышым иде.

Беренче танышкан көннән мин Рәшит Әхмәтҗановның талантына сокланып, үзе белән аралашып яшәдем. Бик кызганыч, ул арабыздан иртә китте. Гаҗәеп эчкерсез, садә күңелле кеше иде мәрхүм.

*«Кала юлы». («Ак Бүре» нәшрияты, 2017.– 109–111 б.) китабыннан*

# Энесе кем – абыйсы шул...

Туфан Миңнуллин

Әдәбиятның башка жанрларында ничектер, шигърияткә яшьләр өер-өер булып киләләр. Ярышып, узышып, бәхәсләшеп, фикердәш булып иҗат итү өчен, яшеңнең бер тирәдәрәк булуы кирәктер, күрәсең.

Рәшит Әхмәтҗановлар буыны да татар шигъриятендә зур һәм көчле төркем иде. Күпләр арасыннан кайберләре алгарак чыгып, алар күз уңаенда булдылар, исемнәре газета-журнал битләрендә еш күренде, трибуналардан еш яңгырады; кемнәрдер күләгәдәрәк калды.



**Г. Камал театры артистлары Әзһәр Шакиров, Илдар Хәйруллин һәм Наил Әюпов белән**

Дөресен әйтим, Рәшиткә мин әллә ни игътибар итми тордым. Язамы яза, эшлиме эшли – шул гына. Аралашуыбыз да шундый гына – исәнме, саумы. Аның иҗатына мин энекәше артист Илдус Әхмәтҗанов аша кереп киттем. Әллә нindирәк сәер егет, талантлы, шигырьгә гашыйк җан, фикер йөртү рәвеше дә үзенчә – «синдәй, миндәй бозаулар»га охшамаган. Шуннан уйлап куйдым: «Туктале, мәйтәм, энесе шулай булгач, абыйсы да моның кызыклы кешедер». Рәшит белән очрашып сөйләшкәндә, аны җентекләбрәк күзәтергә керештем. Бусы да сәер икән. Төртмә телле, тиз үпкәләүчән, зарланырга ярата. Мин аңа якыная алмадым, ул да миңа якынаерга ашкынмады. Шулай да бер сыйфаты Рәшитнең мине җәлеп итте: үз-үзеннән көлеп, мәзәк ясар өчен, кеше үзеннән өстен булырга тиеш.

Һәм мин Рәшит Әхмәтҗанов язганнарның бөтенесен дә укып чыктым. «Тетрәндем, шаккаттым» дип, купшы сүзләр әйтмим, аның зур шагыйрь икәнен аңлап, матбугат битләрендә күренгәнен көтеп ала башладым.

Миңа Рәшит Әхмәтҗанов иҗатында иң кадерлесе – сагыш. Кешеләргә сөйләп тә аңлатып булмый торганы. Хәтта үзең дә аңлап бетерә алмаган сагышлы хисләр була. Рәшит шигырьләрендә әнә шул әйтелмәгән сагыш ята. Шул булганда гына шагыйрь чын шагыйрь була ала.

*Казан утлары журналы.– 2018. – № 5*

# Илдус Әхмәтҗанов: Мине бүген дә «Тукай!» дип сәламлиләр

Гөлүсә Закирова



**Рәшит Әхмәтҗановның әнисе Сажидә. Казан, 1978**



**Рәшит Әхмәтҗанов кызы Ләйлә белән. Казан, 1978**

Татарстанның халык артисты Илдус Әхмәтҗанов үскән гаиләдә тәрбия дигәнең үзгә бер рецепт белән булдымы икән әллә, бер гаиләдә татарның ике күренекле шәхесе үссен дә! Сүзебез абыйсы – шагыйрь Рәшит Әхмәтҗановны искә алудан башланды.

– *Илдус абый, сезне абыегыз – шагыйрь Рәшит Әхмәтҗановка охшаталармы?*

– Кыяфәтләр белән охшаган, дип әйтәләр анысы. Рухи яктан аеруча охшаган, дип тә өстәр идем. Гаиләдә без 11 бала үстек. Арадан икебез генә сәнгатькә тартылдык. Ул шагыйрь булды менә, мин – артист... Заманында аның шигырьләр язганын күреп, мин дә каләм тибрәткәләп карадым, шагыйрьлегем шуның кадәр генә булгандыр инде, хәзер язганым юк. Мәктәпне тәмамлап, КДУга укырга керергә дип башкалага килгәч, ул мине көчләп диярлек Ленинград театр студиясенә кертергә теләде. Имтиханга җитәкләп алып барды. Кабул итү имтиханнары Казанда булгач ризалаштым. Соңга калып килгән идем, бөтен турларны бер көндә үтеп, ахыргы имтиханга – изложение язарга кердем.

Анда текст укылган, барысы да тырышып-тырышып язып утыра иде. Шуннан миңа сочинение язарга рөхсәт иттеләр, мин мәктәптәге чыгарылыш имтиханында язган Тукай турындагы сочинениене тагын бер кат язып чыктым. Кабул итү комиссиясендә Хәй Вахит та бар иде. Соңыннан Рәшидә апа Җиһаншина сөйләде, Хәй ага: «Әллә бу егетне КДУда гына калдырыйк микән, Тукайны бигрәк оста тасвирлап, яратып язган бит»,– дигән, ди.

– *Ленинградка барып уку өчен шактый әзерлек соралгандыр.*

– Алай түгел ул, ялгыш фикер йөртәсез. Минем ул чакта сәхнәгә бер тапкыр да чыкканым юк иде. Театр студиясенә беркайчан да үзешчән

артистларны алмадылар. Чөнки алар бозылган, төзәлмәслек сынган була. Чын артист әвәләр өчен табигать баласы булу кирәк. Ә үзешчәннәр «Мин кем!» дип харап була.

*— Студияне тәмамлап кайтканда, ул һавалык сездә дә барлыкка килгәндер инде. Ә менә Сезне шунда җитәкләп алып барган абыегыз: «Молодец, энем, булдырдың!» — дидеме?*

— Юк. Гәрчә һәр спектаклемне карап барса да, мактаганы булмады. Әмма канәгать иде. Ул гомере буе гаделсезлек белән көрәште. Мин дә ялганны, хыянәтне яратмыйм. Әмма аның кебек беркайчан да изүне ертып көрәшкә ташланмадым. Куркаклык түгел бу, ә безнең җәмгыятьтә көрәшүнең мәгънәсе юк икәнлегенә төшенү генә. Ленинградта профессор Кох укытты безне. Ул гомере буе үз-үзеңне тоту турында лекцияләр укып йөргән оста психолог иде. Соңгы очрашуда хәтта ул да: «Тәрбияләүнең мәгънәсе юк, мондый эчтәлектәге лекцияләрне башка укымам инде»,— дип, кул селтәде.

*— Гафу итегез, халык, милләт язмышы өчен аяусыз көрәшкән Тукай образын тудырган кеше — артист авызыннан мондый төшенке сүзләр ишетермен дип һич уйламаган идем...*

— Гаделсезлек яныннан үтеп китәм, дигәч тә, газапланмый бу дип уйламагыз, бәлки, гомерем буе оныта алмыйлмдыр мин аны... Тукай да «Татар кызына» шигырендә: «Сизмисең бит, янәшәңнән нечкә күңелле шагыйрь узганын»,— дип яза.

*— Тукай иҗаты белән беренче тапкыр шулай ук абыегыз таныштырдымы?*

— Яшь арабыз 10 яшь булгач, ул, Казанга укырга киткәндә, үзенең китапханәсен миңа калдырды. Арада Тукайның коңгырт төстәге дүрттомлык сайланма әсәрләре дә бар иде. Мин аларны вакыт булган саен алып укый, артындагы искәрмәләрен өйрәнә, гарәп сүзләренең асылына төшенә башладым. Шигырьләрен ятлаган саен, ул яшәгән чорны күз алдына китердем. Минем өчен хыял дөньясы иде ул. Хәтта үз иҗатым кебек, Тукайның бер кисәге кебек тоя башладым. Бу соңыннан да тукталмады, «Казан утлары» яки башка басмаларда шигырьләрен укысам, күңелем үсеп китә иде. Гомумән, шигырьләр укырга бик яратам мин, хәтта тәхәллүсен куймасалар да, кемнең иҗаты икәнен шундук әйтеп бирә алам.



**Илдус Әхмәтҗанов — күренекле нәфис сүз остасы**



**«Исә Болгар җилләре» фильмында Ибне Фадлан ролендә**




**Илдус Әхмәтҗанов сеңлесенең кызы Айгөл, кияве Алмаз, оныклары Азамат һәм Әмирә янәшәсендә**



**Илдус Әхмәтҗанов һәм Ришат Хафизов. Казан, 2019**

*— Шулай да беренче тапкыр Тукайны уйнавыгыз кайчанрак булды?*

— Германиядә солдат хезмәте срогын тутырып кайтып, театрда эшли башлаган елларым гына иде. Режиссер Әхтәм Зарипов телевидение өчен Сибгат Хәкимнең «Яз сулышы» әсәрен сәхнәләштерә башлады. Тукай ролендә — Рәсим Сәлахов, ә мин Сәгыйть Сүнчәләйне уйнарга тиеш идем. Шунда егетләр сценарийны укып чыктылар да: «Илдус Әхмәтҗанов — коеп куйган Тукай бит инде»,— диделәр. Әхтәм абый да: «Мин дә шулай дип уйлаган идем, тик ул бөтенләй тәҗрибәсез бит әле, Тукай — бик җитди роль», — ди. Шулай да мине сынап карарга булды.

Ул чакта кичергән җаваплылык хисен әйтеп аңлатып бетерә торган түгел. Уйнавы бик авыр булды, режиссер да бик таләпчән. Телевизион спектакльне язып бетергәч: «Их, тагын бер кат яздырсак, шәбрәк уйнар идем»,— дип уфтандым. Аны телевизордан 1976 елның 26 апрелендә күрсәттеләр. Ул көнне утлар йотып, үзем генә утырып карадым һәм... өстемнән таулар төшкән кебек булды — спектакль әйбәт кенә килеп чыккан иде.

Иртән урамга чыккач, миңа «Тукай» дип кенә эндәшә башладылар инде. Бервакыт, Актерлар йортына баргач, Мөхәммәт Мәһдиев бөтен халык алдында: «Менә, егетләр, татар халкына Тукайны уйнар өчен Аллаһы Тәгалә җибәргән кеше»,— дип, канатлар куеп җибәрде. Шагыйрьнең 100 еллыгына Камал театрында Туфан Миңнуллинның «Без китәбез, сез каласыз» спектаклендә Тукай ролен, һич тә икеләнмичә, миңа бирделәр инде. Марсель Сәлимҗанов тулысынча ышанды, уйнавы да җиңел булды. Рухым белән мин Тукай белән done бербөтен булдым. Кайберәүләр «тышкы кыяфәтең белән охшаган» ди. Рухың бер булса, тышкы кыяфәтләр дә охшый башлыйдыр инде ул. Мин бик бәхетле кеше, чөнки сәхнәдә йөзгә якын образ тудырсам да, арада яхшылары да бар бит — миңа бүген дә «Тукай!» дип сәлам бирәләр.

*— Илдус абый, Сез шагыйрьнең моңсу, ачы хәсрәт, ятимлек, милләт фаҗигасе белән сугарылган әсәрләренә ешрак мөрәҗәгать итәсез шикелле. Моны да рухи охшашлык белән аңлатасызмы?*

— Тукайның әсәрләре генә түгел, үз язмышы да фаҗигадән тора: «Кузгатмакчы булсаң халык күңелләрен, кирәк түгел уен-көлке»,— дип яза ич. Тик ул юмордан да читтә калмый, тагын бер кат «Кисекбаш»ын гына укып карагыз!

*— Сезне Аманулланың «Әлепле әртисләре»ндә комик рольдә күреп, исем-акылым киткән иде, җитди кешедән бу кадәр осталык ни өчендер көтмәгән дә идем. Рәхәтләнеп бер көлдем, ичмасам.*

— Шаянлык — күңелем төпкелендә элек-электән яшәп килгән бер сыйфат ул. Гомер итә-итә бастырылдым мин һәм комплекс барлыкка килде. Бер җитди роль башкаргач, башканы булдыра алмас диптер инде, гел шул юнәлештәге рольләр генә бирә башладылар. Гәрчә заманында шаян рольләрне уйнавымны да тамашачы үз иткән иде. Мәсәлән, Празат Исәнбәт куйган «Яшь йөрәкләр» (Фәтхи Бурнаш) спектаклендә миңа бай малаен уйнарга туры килде. Традицион калыпларны җимереп, аны эчкече, җирәнгеч дәрәҗәсендә түбән кеше итеп уйнарга алындым. Пра-

зат абый беркайчан да артистларга үз фикерен көчләп такмады, мине дә хуплады. Бик кызык килеп чыкты ул.

Бервакыт, якын кешеләрем билет сорап килгәч, администратор Фәридунга берике чакыру кәгазе сорап мөрәҗәгать иткән идем. «Урын юк. Шулай кызык итеп уйнарга кирәкми иде, кассада да билетлар калыр иде»,— дип әйтеп салмасынмы...



**Рәшит Әхмәтҗановның бертуган Мияссәр абыйсының хатыны Гайшә, кызы Сөгъдә, оныклары Алсу һәм Резидә уллары белән. Татар Кандызы, 2017**

Аннан соң Г. Камалның «Бәхетсез егете»ндә кыска гына эпизодик рольдә — Кәрим байның абыйсы Мансурны уйнадым. Спектакльдә ул энесенә хәбәр генә кертә, мин чыгып бер-ике сүз әйтүгә, халык тәгәрәп көлә башлый, күпмедер мизгелгә хәтта уенны туктатып торырга туры килә. Равил Шәрәфи артка борылып көлә, ә артистлар барысы да, шуны карар өчен, сәхнә читенә җыелыша. «Әлепле әртисләре»ндә рәхәтләнеп уйнадым инде. Мин бик якын кешеләремә генә ачыла алам шул. Ә болай... дөньяда бик күңелсез кешемен. Мәҗлестә берәр чит кеше булса, сөяп куйган багана хәлендә калам инде...

Беләсезме, ничәнче ел Тукай булып уйнасам да, һәрчак бик дулкынланам, ихластан борчылам...

*«Идел» журналы.— 2017*

# «Ил капкасын кагам...»

Рифә Рахман

Узган гасырның икенче яртысындагы шигърияттә ике шагыйрьнең бер генә әсәре дә йөрәгем кылларын тибрәндерми калмый. Болар — серле рәвештә фамилия белән дә бәйләнгән Роберт һәм Рәшит Әхмәтҗановлар. Сүзем каләмдәшләре күңеленә, мишәр катылыгы белән җанга үтәрлек итеп «багърем» дип дәшүчән, Казанга ерак Баулы районының Татар Кандызы авылыннан килеп, шул төбәкнең иң данлы бер улына әверелгән, яшьлегеннән үк соң дәрәҗәдә милләтпәрвәр Рәшит абый — татар поэзиясендә метафорик фикерне үткенләндергән, аңа күпсанлы үзенчәлекле троплар алып килгән зур Шагыйрь турында барыр. Аның, Тукайныкындагы кебек, фикер һәм хис тирәнлегенә, көчле лиризмга ия, халыкчанлык белән сугарылган иҗатында поэтик метафора стиль доминантасына әверелгән иде. Аларның икесен дә Ходай Тәгалә иң мөһим елларда татарның күзен ачар өчен дөньяга китергән кебек. Мөстәкыйль дәүләт, рухи ирек өчен көрәш мотивларын иҗатының умыртка баганасы иткән Р. Әхмәтҗанов да һич көтелмәгән вакытта, чагыштырмача яшь килеш, милли хыяллар тормыш киртәләренә бәрелеп имгәнгәнче китте...

Тукай белән Рәшит Әхмәтҗановны поэзиябезнең милли-сәяси эчтәлеген, актуальлеген көчәйтү, татар язмышында зур эз калдырган тарихи-иҗтимагый-сәяси вакыйгаларны тәэсирле һәм гыйбрәт алырлык итеп тасвирлау, чор тарихын әдәбиятка кертеп калдыру кебек сыйфатлар да үзара якынайта, һәрберсенең лирикасында борынгыдан килгән уңай әдәби традицияләр чагылыш тапты һәм үстерелде. 1980 елдан «Казан утлары»нда әдәбиятка җаны-тәне белән бирелеп хезмәт иткән Рәшит абый, әлбәттә, «алтмышынчылар» арасында Г. Тукай исемендәге бүләккә иң лаек һәм аны алдан алырга тиеш кешеләрнең берсе иде, әмма аерым оешмаларның, тәнкыйтьнең язганнарына игътибарсызлыгы, язмышның мәрхәмәтсезлеге, вакытсыз һәм көтелмәгән үлем аркасында ул әлеге премияне ала алмады. Шушы сәхифәгә теркәлгән бу мөһим фикер аның рухына шатлык иңдерсен, тарихка язылып калсын дип телим.

Р. Әхмәтҗанов шигърияткә, Тукай кебек үк, стиль сыйфатлары ачык камил каләм иясе буларак аяк атлый. Аңа кадәр үк бу өлкәдә танылып өлгергән каләмдәшләре дә моны күреп таң кала. Тукай, беләбез ки, — контрастлар шагыйре. Р. Әхмәтҗановта тасвирдагы капма-каршылык, андагы дәрәҗәдә булмаса да, шулай ук еш күзәтелә, әмма үзенчәлекле, башкачарак. Ул алдагы иҗат чорларында тормышның капма-каршы якларын тасвирлаудан битәр төрле хисләр алып килерлек ситуацияләр эзли, таба, шулардан хис һәм фикер уздыруда уңышлы файдалана. Әнисе, туган ягы, яшьлеге, мәхәббәт, тормышның гомуми барышы...— ни турында гына язмасын, аның каләме сагыш янында — шатлык, шатлык янында сагыш яшәве турында сөйли, йә каршылыклы хисләр тудыра, йә төп хисне аңа читрәк икенчеләре белән өрetә.

Күптән түгел генә Тукайның Җаек чоры иҗатын чагылдырып мәкалә язганда, үзем дә әсәрләрендә моңарчы игътибар итмәгән, яшерелеп бирелгән никадәр кыю милли-сәяси фикер барлыгына таң калган идем. Аннан Рәшит Әхмәтҗанов хакында күзәтү мәкаләсе хәзерләргә туры килде, һәм шулай ук анда да үзгәртеп кору елларына кадәр әйтелмичә калган җөмләләрнең, яшерелгән фикерләрнең, үкенеч хисенең күплегенә шаккаттым. Яшьлектә шагыйрьдән башкарак нәрсәләр эзләп укыйсың, хәзер җитдирәк фикерләр көтәсең һәм игътибарлырак буласың,

ахрысы. Бүген без Тукай әсәрләрендә тасвирланган затларның кемлеген ачыклау белән мәшгуль. Күпләре турыдан-туры яисә төрле кушаматлар ярдәмендә аталса да, беришләрен эш-гамәлләре генә ача. Р. Әхмәтҗанов шигырьләрендә дә кемлеге төгәлләштерелмәгән, әмма зур күпчелеккә аңлашылырлык тарихи шәхесләр, тирәлегендәге теге яки бу кешеләр чагылып-чагылып китә. Мисалга Г. Тукайның «Куйды илтеп аузын әчкән бүрәнәгә бармагын...» сүзләрен эпиграф итеп алган бер әсәрен китерик:

Казанында кычкыралар:
«Камыр булма — тимер бул!»
Юк, карышмый. Тик йөрәген
Халкынамы бирер ул?

Мәскәвеннән ыжгыралар:
«Булма камыр — бул тимер!»
Шүрәле хәлендә калса,
Коткарырга кем килер?

Югарыдагы әсәрдә илбашының катлаулы сәяси хәле тасвирланган, һәм шул ук вакытта аның кискен хәлләрдәге таянычы бары тик үз халкы гына була алганлыгы да ачык әйтелгән.

Тукай атаклы «Туган тел»е белән татар күңеленә мәңгегә узган. Моның шулай икәнлеге турында Рәшит Әхмәтҗанов шигърияте дә ачык сөйли. Аның традицияләрендә тәрбияләнгән шагыйрь иҗатында ана тел мотивы — умыртка баганаларының берсе. Р. Әхмәтҗановның теге яки бу әсәре белән Тукайныкылар арасында анык күзгә ташланмаган башка бәйләнешләр дә бар. Аналарның бишек җырларын чагылдырган әсәрләрен, милли теманы яктырткан аерым шигырьләрен укыганда, күңелдә бу уй тумый калмый. Шул ук вакытта шагыйрь иҗатының текстара бәйләнешләрен кычкырып торган әсәрләр дә шактый. Рәшит абый үзе Тукай сүзләренең Изге китабыбыздан ук тамырланганлыгын күрә:

Очрыйлар да, шәмаилләр укыйм:
Анда Тукай язган шигырьләр...
Үз халкына бала гына түгел,
Алла була ала шагыйрьләр.

Кемне тетрәндермәс бу юллар?! Монда Тукайны Бөек Көч янәшәсенә кую да, сүзенең Хаклыгын раслау да, аңа Халык мөнәсәбәте дә, аңа хыял-өметләрен тормышка ашыру да, афәтләрдән саклау да, юл күрсәтүдә ярдәм итә алырлык, әмма ул үзе тудырган Бердәнбер Зат итеп карау да чагылыш тапкан. Шагыйрьнең шушы рәвештә язуы укучыны бераз гына куркытып, имәндереп тә җибәрәдер. Югарыдагы дүртьюллыкта Тукай әсәрләрен Коръән сүзләренә тиңләштергән Р. Әхмәтҗанов вакыт-вакыт аларның тормыш белән каршылыкка керүен дә күрә. «Без — халык» әсәрендә, шулай дип әйтергә дә хокукы булмаган татар турында уйланганда, «Халык — зур» дигән Тукай сүзләрен исенә төшерә, әмма «зур» һәм «кечкенә» төшенчәләренә башка мәгънә сала, зур илдә татарның һаман да түбәнсетелүе — «кечкенәлеге» хакында фикер әйтә.

Рәшит абый гомере буе шахталарда бил бөккән, кайвакыт кара икмәккә дә туймаган татарның һаман йокыдан уянмавына, күзен ачмавына, алдынгы милләтләр рәтенә басарга теләмәвенә гаҗизләнде. Тукай кебек үк, ул да бер алдынгы карашлы татарга йөзләрчә маңкортның каршы чыгуы хакында еш язды. Без аның иҗатында яңа «Печән базарындагылар»ның милләтчеләргә булган рәхимсез бәяләре («Маңкортлар һөҗүме»), чын көрәшчеләрнең «яман уйлы»лардан куркып калмавы белән очраштык («Марат Арсланов монологы»). Ул да, Тукай кебек үк, милләткә хезмәтнең иман эше икәнлеген сөйли:

Вә билләһи... Илгә ирек яуласак без,
Җир өстендә безнең өчен тәмуг бетә.
Дөньялыкта кылган изге гамәлләрнең
Ияләрен җирдә-күктә оҗмах көтә.

Р. Әхмәтҗановта электән килгән дини символикага мөрәҗәгать итү үзгәртеп кору елларына кергәч көчәя. Өммәт, кол, гөнаһ, ант, Хозыр, җиде кат күк... Шактый бай лексик кыр бу. Рәшит абый иҗатында Тукай үз иткән халык теле бизәкләре дә мул, фольклордан күчкән образлар кыры да киң. Тукай һәм Рәшит Әхмәтҗанов бәйләнешләре турында сөйләгәндә, һичшиксез, аның әдәби элгәресе күтәргән проблемаларны яңа шартларда яңача эчтәлектә ачуын әйтергә кирәк. Болар

татарның язмышы, теленең һәм диненең киләчәге, үзаңының торышы һәм аны уяту гамәлләре турындагы уй-хисләр рәвешендә чагылыш тапты. Әйтик, «Тукайның соңгы рәсеме» – милләтнең үзаңын уяту, үстерү, иманлы итү максаты белән сугарылган көрәш поэзиясенең бер үрнәге. Ул бу көрәштә Тукай иҗатына да өмет белән карый, аның бала чактан җырланган «Туган тел»е халыкны терелтергә, уятырга сәләтле дип саный («Бергәләп җырлыйк»). Шул ук вакытта шагыйрь үз халкының көрәшче һәм талантлы улларын саклый алмавы өчен газаплана. «Тукайның соңгы рәсеме»ндә, мәсәлән, шагыйрьгә миһербансыз имансызларны битәрләү авазлары яңгырый:

Карурманнар уртасында калып,
Тарихларның кылын тарткан бар:
Асрамага бушлай бирсәләр дә,
Тукай булгач, шактый сатканнар!

Р. Әхмәтҗанов әсәрләренә Тукай иҗатыннан аерым гыйбарәләр, истә калырлык троплар бигрәк тә ул яраткан темаларны дәвам иткәндә килеп керә («Казанга хат»). Галимнәр халыкка киң билгеле «Ачлык мәйданы»нда бик күп образларны Тукайныкылар янәшәсенә куеп карый һәм уртаклыклар таба; кояш, корбан һәм башка символларның үзенчәлекле трансформациясе турында сүз алып бара. Р. Әхмәтҗанов әсәрләрендә Тукайда да очраган образларга мисал итеп «Бишташ» поэмасындагы Кисекбашны китерергә мөмкин:

Күзе бар күк явыз Кисекбашның,
Кол Галине эзли
Икенче кат үтерергә теләп,
Эзли – өмет өзми.

*«Икенче таш»*

Р. Әхмәтҗанов Тукай исемен, сүзләрен милли азатлык көрәшенең бер атрибуты дәрәҗәсендә күрә. «Сәлим Әбү-Бәкер монологы»нда лирик мин йөрәген һәрвакыт Тукайга якынаерга өнди. Тукай һәм Р. Әхмәтҗановның үзара якынлыгы һичкемдә бәхәс уятмый. Р. Әхмәтҗанов каләменең көче дә Тукайныкы белән тиңдәш – милли рухында, тормышчанлыгында, ихласлылыгында, хисси тирәнлегендә, хакыйкатькә омтылышында, метафоралар тудыру осталыгында. Алар икесе дә – пейзаж һәм гражданлык лирикасы осталары, нечкә лириклар, кыю сүзле публицистлар. Милли рухлы көрәшче шагыйрьгә әверелгән Р. Әхмәтҗанов иҗатының төп концепциясе, остазыныкы кебек үк, татар кешесенең җанын, күңел төпкелендә яткан хыял-омтылышларын, киләчәккә бәйле өметләрен ачу максатына барып тоташа.

XX гасырның соңгы чирегә татар шигъриятен яктырткан бер язмасында Т. Галиуллин: «Рәшит Әхмәтҗанов лиризм белән моңсу, заман сынын эчке уйлану рухы белән кушып, шәхеснең кичерешләр дөньясын сурәтләү чаралары ярдәмендә сынландыра. Үз чоры татар поэзиясенең үзәк юлыннан атлаучы шагыйрь Халык тарихы, Милләт, Тел язмышы, Тукай шәхесе турында уйлана, шул төшенчәләрне шигърият чыганаклары итеп калкыта»,– ди. Тукайны күтәргән, әдәбият тарихында аның янәшәсендә урын бирүләренә ышанмаса да, Рәшит Әхмәтҗанов, милли көрәш яндырган йөрәгенең ахыр чиктә туктап каласын сизгәндәй, татар бәхете өчен җан биреп, аның күңелендә яшисенә өметләнә һәм Газинур Моратка багышланган әсәрендә шушы юлларны яза:


Бу мәңгелек, кочакларын җәеп
Барчабызны чакырып торса да,
Безнең өчен түгел – бөек Тукай
Атлап кергән алтын бусага.

Без – гадиләр. Безнең шикелләләр
Балкып калса кала бүгеннән.
Әйдә, энекәш, тын да алмый бергә
Могҗизалар көтик үлемнән.

Азатлыкны, бәлки, гомерләргә
Алмаштырып ала алырбыз.
Исәннәрнең әйтүләре мөмкин:
– Безнең белән сез дә калыгыз!
– Калырбыз.

*«Казан утлары» журналы.– 2018. – № 11*

## «Тубырлы, убырлы...»



Студент чакта Рәшитләрнең әниләре Сажидә апага, бүләк итеп, 70 тиенлекме, 65 тиенлекме яулык җибәрдем. Бүтән мөмкинлек юк бит инде. Ә Рәшит минем әнием Хәнифә карчыкка 8 метр тукыма күтәреп килгән. Уйлап кына карагыз әле, ике иңле , 8 метр чаршаулык дигән сүз бит ул.

Мин бик сөенеп күтәреп кайттым да әнигә күлмәк тегеп кидердем. Калганыннан үземә костюм-күлмәк һәм жакет тектем.

Яңа киемнәремне беркөнне киеп үк бардым. Шулай университетның химфагындагы кафедрадан коридорга чыгып киләм ипләп кенә – каршыга Рәшит килә... Ул да түгел, коридор тутырып:

– Убырлы, тубырлы! – дип кычкырып та җибәрде. – Убырлы икәнеңне белә идем инде, бу хәтле үк кабахәт икәнеңне белми идем. Хәнифә апага бүләк итеп җибәргән күлмәклектән үзенә тегеп кигән!

– Соң,– мин әйтәм,– синең ул тукымаң чаршаулык иде, әнигә күлмәкне тегеп кигердем инде, Рәшит, калганыннан үземә тегеп кидем. Әгәр тагын бер миңа «убырлы» дип әйтсәң, мин сиңа да кушаматның ниндисен беләм бит әйтергә! – дидем.

Минем тубырлы бармагымны «убырлы» дип Рәшит кенә атый иде.

Булды инде укыган елларда, дус булып та йөрдек, ә мәхәббәт дигән әйбер, булырга тиеш булса да, булмагандыр ул безнең арада. Чөнки Рәшит миннән шактый яшь иде...

*Клара Булатова сөйләгәннәрдән*
*2018, 19 декабрь*

# Альбинос җәй

Әхәт Гаффар

– Таш кимерербезме, җир ашарбызмы, балакайлар!

Почмаклап ак яулык япкан, ак җирлеккә зәңгәр чәчәкләр сурәте төшерелгән озын күлмәк кигән бер апаның карлыкканрак, һәр сүзе аермачык әйтелгән тавышы безнең турыда да яңгырагач, Рәшит абый Әхмәтҗанов:

– Тагын узды бу козгын,– дип куйды.

– Козгын кап-кара була ул. Ә бу апа ап-ак. Әмирхан Еникинең ак әбие шикелле,– дидем мин.– Аның галушы гына кара. Анысын да тузан сарган.

– Алайса, альбинос була инде. Альбинос козгын,– диде Ринат Гаффар.

Ак козгынны ишеткәнебез дә, күргәнебез дә юк. Багана башына йә өй морҗасына кунган козгын чем-кара килеш тә шикләндерә, җанга авыр тәэсир итүчән, тавышы өркетеп үк куючан. Ак төстә килеп чыккан сурәттә тоташлый шом, курку белән туларсың, Аллам сакласын!

Әлеге хатынның тавышы тагын ишетелеп куя да ерагая, сүрелә, басыла. Тәмам ишетелмәс була, тына. Кире әйләнеп килешендә ул түбән урамнан үтә инде. Көн тәмам эсселәнгән була, һава көпшәкләнә. Авазлар, тавыш һаваның тыгыз яисә томанлы, болытлы чагында гына ачык ишетелә, яңгырап тора ул.

Безнең сүзебез бетә, эшебезне тын гына дәвам итәбез. Ә эшебез күп, җаваплы: без Кукмара районының Березняк авылында (татарча Бучирмә, халык телендә исә шулай Березняк дип йөртелә) йөк машиналары тотыласы гаражы да, техника тезеләсе урыны да бер түбә астында буласы бина төзибез. Кызыл кирпечтән. Зур, иркен, озакка исәпләнелгән. Без дигәнем: мин – «Яшь ленинчы» газетасы журналисты, күренекле шагыйрь Рәшит Әхмәтҗанов – ул вакытта Мәдәният министрлыгында сәнгать эшләре инспекторы һәм бер прокурор. Рәсми-төп килешүдә «Студентларның төзү отряды» дип теркәлгәнбез (бусы налог түләмәскә ташлама өчен). Ә болай – «шабашниклар». Мин исә шуларның бригадиры. «Шабашниклар» телендә – «Бугор». Әлеге төзелеш, аның сыйфаты, вакыты, ашау-эчү, тәртип, килешкән эшне төгәлләү белән үк хезмәт хакын тиенен-тиенгә алу – минем өстә. Эш бирүчебез исә – үзәге шушы Бучирмә авылында булган колхозның идарә рәисе Мияссәр ага Мансуров. Тикмәгә ул түгел. Мин – әлеге күмәк хуҗалыкның бер бригадасы булган Камышлы авылы кияве, хатыным Фәридә – университеттагы тарих-филология факультетының соңгы курсына күчеп, җәйге ялында беренче кызыбыз Ләйләне карап, туган йортында үткәрә. Мияссәр Мансур улы исә – районда гына түгел, ә бәлки Татарстанда дан казанган колхоз җитәкчесе, орденнар иясе, хуҗалыгы да алдынгы, җитез. Эленке-салынкыларны кем эшкә якласын? Безнең ниятебез, теләгебез – елга бер бирелә торган ял вакытында хәл кадәри дигәндәй әҗер алу. Айлык хезмәт хакыбызның йөз сум булган чагы.

Эш белешкәндә, Мияссәр абый миннән:

– Кемнәрең бар? – дип сорады.

– Рәшит Әхмәхтҗанов... – дидем.

– Шагыйрь ич ул! Миңа кирпеч салучылар кирәк! – дип бүлдерде.

– Рәшит Әхмәтҗановмы? Шигырьләре шикелле үк мәңгелек итеп, уналты яшеннән үк Чупай тавы ташыннан ярты Әлмәтне салган төзүче ул! – дидем мин.

— Аңлашылды. Ә сине Саимә апа сөйләгәннән беләм.

«Саимә апа» дигәне — Фәридәнең әнисе була инде. Студентлар төзү отрядында ике ел, аннары соң болай да байтак кирпеч тезгән, агач юнган, такта салган инде. Без бит авыл малайлары, безнең кулдан килмәгән, кул ятмаган берәр эш бар микән?!

Әнә ул үзе — Мияссәр ага Мансуров. Килмәгән, тикшермәгән, карамаган көне юк. Уйлаган уйлары саллы булгангамы, фикерләре йөгерек булгангамы икән, ул алга таба иелебрәк йөри, адымнары нык, елгыр, ышанычлы. Чәче, кашы җирәнрәк булып хәтеремдә калган, һәрхәлдә, минеке сыман кап-кара мыек үстереп, чәйнәми генә, дияр идең, билләһи.

— Комы әйбәтме? — дип сорый ул.

— Әйбәт. Ә без аны барыбер иләктән иләп кенә изәбез.

— Цементны белеп кенә. Кыйммәтле нәрсә бит.

— Чамасыннан артык уздырмыйбыз, Мияссәр абый. Артык та түгел, ким дә түгел: өчкә — бер, ягъни йөз илле маркалы була.

— Беләм, беләм, егетләр. Тикмәгә соравым түгел.

Өйгән кирпече югарылыгыннан Рәшит абый Әхмәтҗанов:

— Мин үземә бөек һәйкәл салам, Пушкин белән Тукайлардан үрнәк алам,— ди дә сорый: — Мияссәр Мансурович, теге апаегызны бераз тыеп булмый микән аны?

— Кайсы апаебызны?

Рәшит Әхмәтҗанов үз шигырен сәхнәләрдән торып сөйләгәнчә бераз калтыравыклырак, тик үз йөрәге түреннән чыгаргандай көр дә, тантаналы да, шомлы да тавышы белән:

— Таш кимерербезме, җир ашарбызмы, балакайлар! — диде дә: — Таш янганда, җаннар көйри, җаныкайлар дип әйтеп кенә бетерми ул,— дип өстәде.

— Ул апаны тыеп була булуын, егетләр... Ә минем җанны кем тыяр? Ул апа булып минем җаным шулай кычкырып йөри, Рәшит,— диде Мияссәр Мансурович.— Син менә шуны тыеп кара... тыя алсаң.

Сүз әйтү, сөйләшү барышында без төзүчеләр һич туктап тормыйбыз, эшебезне генә беләбез. Ә аның «минем җаным шулай кычкырып йөри ул» дигәне чагында безнең һәркайсыбыз сагаеп калганбыздыр, шәт. Шәт түгел, ә тәгаен!

Нигә дигәндә, бу 1973 ел иде — июль ахыры, август башы тирәсе. Ул елны Татарстанга корылык килде. Уҗымнар да, сабан игеннәре дә рәтле түгел, башаклар ярлы, җир ярыла ук башлады, бәрәңге күгәрчен йомыркасы шайлы гына булып, анысы да җир астында килеш пешә, куырыла башлаган иде инде.

Шундый чагында Мияссәр Мансуровныкы ише җаннарны ничекләр тынычландырып, ничекләр тыймак кирәк? Олы яшьтәге әнкәебез нишләп йөри икән? Япа-ялгызы. Ә авыл көтүендә бер сыеры, танасы, биш-алты сарыгы йөри. Каз-үрдәге, тавык-чебеше, егерме биш сутыйлы бәрәңге бакчасы, яшелчәсе, җиләк-җимеше дә бар бит әле... Санап бетермәле түгел. Ә бу төзелешкә алынган һәркайсыбызныкы, нәкъ булмаса да, шулай ук бит ул. Безгә, егерме биш көнлек төзүчеләргә, көн буена явардай яңгырның һич кенә дә кирәге юк та бит юкса... Ә җан, җан!

Җан нишләсен ди инде? Әлеге дә баягы «альбинос апа»ныкы шикелле үк: «Таш киптерербезме, җир ашарбызмы?»

«Ул апа булып минем җаным кычкырып йөри»,— ди бит Мияссәр абый. Авылдагы ялгыз әнинең җаны нишли икән? Исән-сау ике кызы, биш улы булган килеш... япа-ялгыз төн... Унике сум да илле тиен пенсиясе белән. Әлбәттә инде, булышуыбыздан, ярдәмебездән, кадер-хөрмәтебездән калдырмыйбыз анысы.

Биредәге һәркайсыбызның яшәүләре, тормыш итүләре дә нәкъ шушындыйрак.

Ә Мияссәр Мансуровичның уйлары, ниятләре, мәшәкатьләре шуннан кимме? Һич алай түгел. Без, биредәге төзүчеләр, һәрберебез үзе өчен, ниятебез берәү генә: килешкән эшне вакытында төгәлләү дә әҗеренә ия булу. Аның мәшәкатьләре исә — кырыкмаса кырык: сөт сату, ит тапшыру,



**«Яшь ленинчы» редакциясендә күренекле язучы Г. Бәширов белән очрашу истәлеге. Утырганнар (сулдан уңга): Газиз Мөхәммәтшин, Саимә Ибраһимова, Гомәр Бәширов, Венера Ихсанова, Рәйсә Яхина; басканнар: Роберт Миңнуллин, Рәшит Әхмәтҗанов, Мәҗит Вәлиуллин, Фарсель Зыятдинов, Сәйдә Зыятдинова, Рөстәм Мингалим, Фәридә Вагыйзова, Нургали Булатов**

басу-кырлар тулы иген, техника, халыкның бетмәс-төкәнмәс эреле-ваклы йомышлары... Бөтенесенә өстәп, шушы корылык...

Мияссәр абый, беразга туктап:

– Измәне калынрак җибәрәсез түгелме соң, Рәшит? – дип кызыксына.

– Шуннан да юкарак түшәсәң, бер рәт кирпечең җилгә очты-китте, Мияссәр Мансурович.

– Аңлашылды,– дип килешә рәис. – Егетләр, бүген дүртләрдә бераз авансы булыр, керерсез.

Рәшит абыйның болай да чөенке башы, йөз-кыяфәте фәкать аңа гына хас булган шагыйренә рәвеш ала. Мөнбәргә менеп баскан диярсең... тәрәзә аралыгындагы кирпеч «багана»дан яртылаш калкынган болай да төз, кояш алган җиз гәүдәсен тагын да турайта төшеп, кабатланмас мәгърур рухта такмаклап җибәрә:

Базарларда Маручкалар
Саталар саручкалар...
Маручкалар белән йөрсәң,
Очалар получкалар!

– Армый эшләгез, егетләр! – дип кузгалган Мияссәр абыйга сүзен җиткерми каламы соң инде ул:

Без, җырлашып гараж сала-сала,
Коммунистик чорга җитәрбез.
Получкалар алгач череп баеп,
«Аллаһәкбәр!» әйтеп китәрбез!

Көлешәбез инде. Эшебезне дәвам итәбез. Ә ул бик җаваплы. Чөнки әлеге гараж ул елны Кукмара районындагы иң зур төзелешләрнең берсе иде бугай. Шуңа күрә төзелеш чималларына

һичнинди тоткарлык юк, ташып кына торалар. Күрәсең, моны Мияссәр Мансур улы шулай куйган булгандыр. Ә моңа кадәр ул шушы Бучирмә авылында тирә-юньдә тиңе булмаган Мәдәният йорты (халык телендә барыбер клуб инде) салдырып куйган булган.

Белеп торсалар да, мин:

— Бүген — мунча,— дип белдерәм.

Мунча дигәне — Камышлы авылындагы Фәридәләр йортының мунчасы. Эштән соң төялешеп барабыз. Чабын тәнең туйганчы, чыдаганчы чәй эч, ит бәлеше аша, гәпләшеп, җаныңны бушат!..

Әйтәм ич, бу Кояшның Җир шарыннан кургаш куркулык эретеп коярга теләгәндәй кайнаган бер елы иде...

Шушы төштә шагыйрь Рәшит абый әлеге кайнар җәй мөнәсәбәтендә тагын да калкурак булып исемә килеп төште әле. Унсигез ел үтәр-үтмәстән — 1991 елның май аенда — ул Татарстан Җөмһүрияте мәркәзе — шәһри Казанның ташларын эретердәй эссесендә, ирек, мөстәкыйльлек даулап, дәгъвалап, мәгълүм ачлык игълан итүчеләр сафында торыр, соңрак үзенең какшамас рухына тиң мәгърур «Ачлык мәйданы» поэмасын мәңгелеккә иҗат итеп калдырыр. Кем белә бит аны, кем белә: бәлки, ул ачлыкта күпмедер микъдарда Мияссәр абый Мансуров 1973 елдагы җәйнең, «таш кимерердәй, җир ашардай» дип хәвефләндергән җәйнең күркәм итеп төзелгән гараж салу әҗере — хәл кадәри туклык өлеше дә булгандыр? Әйе, кем белә: бәлки, әлеге елдан соң тугыз ел үткәч, 1982 елның нәкъ шундый ук хәтәр коры җәендә Буа районына барып язган «Пуля һәм бодай бөртеге» дигән очеркым матбугатта татарча, русча әллә ничә тапкыр дөнья күреп, шуның төп уй-фикерләре рухландырган мәгълүм «Бодай бөртеге һәм тегермән ташы» романым дөнья күрер иде микән?

Татарның арына алмас богавы... Кем белә бит аны, кем белә: бәлки, Ачлык мәйданы әләменең алтын укасы булган Фәүзия Бәйрәмованың «Халкым минем!..» дип башлаган шигаренең дәвамында әлеге дә баягы «Альбинос әби»нең «таш кимерербезме, җир ашарбызмы?» дигән хәвефле искәртүе дә торадыр? Әгәр дә арка ягында Мияссәр Мансуров кебек армас-талмас хезмәткәр татарпәрвәрләр булмаса, ачлык игълан иткән милләтпәрвәрләребез нигә, нәрсәгә, кемгә ышанып таяныр лар инде икән соң ул?

«Альбинос бит бу! Ишеткәнең юкмы әллә? Үз кардәшенә охшамаган моның ише затлар ничә гасырга бер генә килеп чыга, ди, ич. Бик беләсең килсә, карганың да мич керәче сыман ап-агы, зәп-зәңгәр күзлесе була икән әле ул, әйе. Алай гынамы әле, Америкада ап-ак чырайлы негр бар, ди. Беркөн генә язып чыктылар ич. Гәҗит укырга кирәк, гәҗит!» — кем белә инде аны, кем белә: бәлки, үзенең бер хикәясендәге ошбу юлларны язучы Ринат Гаффар әлеге онытылмас гараж төзелеше өчен измә изгән чакта, «Альбинос апа» дип сөйләшкән вакытта ук күңел түренә салып куйган булгандыр.

Гараж икән, димәк, аны ничек итеп Мияссәр абый Мансуровтан башка күз алдында китермәк кирәк?

Ә яңгыр соңрак яуды ул, яуды. Рәшит абый:

Ява башлар күктән яңгырлы җыр,<br>Җырлы яңгыр көтә игеннәр,—

дип тикмәгә генә язар идемени?


Ә кайнар — «альбинос» җәйләр була алар, булгалый. Булалар да сүреләләр. Ә безнең гаражыбыз исә бүген дә исән-сау тора әле.

Ул — истәлек. Яшьлегебез, гайрәтебез истәлеге. Мияссәр абый Мансуровныкы да...

*2019, 18 март*

# IV БҮЛЕК.
# «ЙӨРӘКНЕҢ, МӘҢГЕГӘ ЮГАЛМЫЙ, БУ ҖИРДӘ ЯШӘРГӘ ИСӘБЕ...»

*Рәшит Әхмәтҗановның якты истәлегенә багышланган шигырьләр, аңа бәйле мәзәкләр һәм хатирә кичәсенең сценарие*



# Һәр шагыйрьдән бер шигырь

***

*Рәшит Әхмәтҗановка*[1]

Юмарт булыйк, чын күңелдән
Бөреләргә «чәчәк» дип дәшик.
Син куанмый бүген кем куансын,
Туган көнең җиткән бит, яшьлек.
Кояш әле яңа баш өстендә...
Кич җиткәнче җырлыйк, гөрләшик.
Син дуламый бүген кем дуласын,
Туган көнең җырлы бит, яшьлек.
Идел әле яңа ташыган чак...
Болыннарга бәхет өләшик.
Син моңаймый бүген кем моңайсын,
Туган көнең җиткән бит, яшьлек.
Табигатьнең әле юләр чагы...
Юләр чакның серен сөйләшик.
Син җырламый бүген кем җырласын,
Туган көнең җырлы бит, яшьлек!

*Айдар Хәлим*

## Балалар бакчасы

Бар Казанда бер йорт...
Шагыйрь дигән Куркыныч ләззәтле ат алып,
Монда
Мин һәр төндә ята идем
Баш астыма салып балтаны...
Хәтерлимсең, тәкъсир: көндез монда
Уйнап көлсә гамьсез сабыйлар,
Төндә Суконканың бандитлары,
Налет ясап, йортны талыйлар
Иде...
Ә бит миңа, ялгыз каравылчыга,
Колшәрифтән[2] калган бер нәзер:
Дошман килсә, балтаң чәчкә атсын
Гүяки кып-кызыл канәфер.
Гомер бакый күктә җирне саклап,
Рәхмәт ишетмәскә өйрәнгән
Ай төшә дә алтын калкан булып,
Мине каплап ята келәмгә...
Сабыйлар кызганыч... Бакчабызда
Алар әле югын юклар да,
Йөрәк әрни... Канәфер каны да
Түгелмәсен уенчыкларга...
Келәмемә төреп, аемны да
Урлап ашарлар, дип ничек тә –
Балтадан да үткер как гәүдәмне
Кадаклап, күз йоммыйм ишектә...
Балта йөзе, аннан чәчелгән нур
Һаман да шул хокук көчендә:
Чөнки аны мин үткерли идем,
Рәшит дускай, синең өчен дә...

*1993*

*Сәгыйть Әхмәтҗанов*

## *Сандугач иде күңелеңдә*[3]

Талларга качты сандугач,
Мин аны эзлиммени?!
Сандугач керде күңелгә,
Җырламый түзиммени?!
*Р. Әхмәтҗанов*

Сандугач иде күңелеңдә,
Ялыккандыр шул җаның.
«Аръягында сайрыйм әле
Бу битараф дөньяның»,–
Дигәнсеңдер, абый, аңлыйм сине,
Арыткандыр, көйсез дөньяны
Көйгә салып булмас микән, диеп,
Меңгә бүлү үзеңә бер җанны.
Сандугач иде күңелеңдә,
Сайра да сайра гына.
Күбрәк ышкылдымы җаның
Шигърият кайрагына –
Нечкәрде, өзелде кинәт,
Көйләрең тынды... дисәм,
«Шагыйрьләр үлә димени?
Шагыйрьләр мәңге исән!» –
Дип, җиһаннан кычкырасың,
Шул бәгырьләрне кисә.
И абый, аңлыйм, һәр шагыйрь
Ул хакыйкатьне белгән.
Шагыйрь абыем үлмәс тә,
Рәшит абыем үлгән.
Сандугач иде күңелеңдә,
Сайрар да сайрар идең...
«Каләмем сынды, энекәш,
Соңгысы иде»,– дидең.

*1995*

[1] Авторы билгесез.

[2] Колшәриф – Иван IV (Явыз Иван) гаскәрләре тарафыннан камалган Казанда халыкны яуга илһамландырган шагыйрь һәм имам.– *Автор искәрмәсе.*

[3] Кулъязма архивта саклана.

*Флёра Гыйззәтуллина*

## Рәшит Әхмәтҗанов истәлегенә

Мин төшемдә бүген зират күрдем,
Күрдем җирдә золым-җәберләр.
Үзәк өзгеч үксү-үкенүдән
Тетрәп торды хәтта каберләр.
Зират эче яшькелт сары сагыш,
Яфрак – чирәмнәрдә көз мәле.
Синең кабереңә тик кар яуган,
Кар өстендә аю эзләре!
Ни оныткан монда кыргый җанвар
Ап-ак кышның кыл уртасында?
Ышкып сырт кашырга килгән дисәң,
Юк бит әле кабер ташың да...
Сине бит без кичә генә күмдек!
Таралыштык елап, хушлашып,
Кай арада өлгердең син, дустым,
Аю халкы белән дуслашып?
Синең өчен өннәреңдә хәзер
Шул аюмы шигырь укысын?..
Рәшит!.. Рәшит!.. Әҗәлләрең белән
Бар хәятның ачтың йокысын.
Ярым-ярты килеш гүр түренә
Тәгәрәттең гомер йомгагың...
Яшен булып җанга набат суга
Яшәлмичә калган елларың...
Шагыйрьләрне генәме соң?..
Хәтта...
Аюларын чорның үкертә
Кыш өстендә сары сагыш булып
Төшләремә кергән бу иртә!

*1995*

*Энже Гыйрфанова*

## «Рәшит үлгән...» дигән хәбәрне ишеткәч[1]

Илгә Җину иңгән елны
Өч-дүрт яшьтә булган ул.
Димәк, балачаклар – охшаш:
Айкап үткән җил-давыл...

Юклыкның һәр газабына
Каршы торган безнең чор.
Шуңа күрә кан аралаш
Саркып туган безнең җыр.

Чабатаны гына түгел,
Ачлыкны да күргән чор,
Безнең чор ул – авырышып,
Төрле яшьтә үлгән чор.

Их, Рәшит, син дә шуларның
Берсе булып китәсең...
Җыр тулы йөрәгеңне
Җиргә бүләк итәсең...

Милләтең азат булсын дип,
Авыру килеш көрәштең.
Ачлык мәйданында безгә
Көрәш рухын өләштең.

*1995*

*Газинур Морат*

## Таш

Шагыйрь тәрәзенә таш аттылар,–
                    аһ, ваттылар,–
чәлпәрәмә килде тәрәз.
...Метафоралар белән
                    чуарланган кәгазь
телдән калды кинәт.
...Киштәдәге шигырь китаплары –
Назон,
    Лермонтов,
            Җәлил,
                    Туфан –
ныграк сыендылар бер-берсенә.
...Читлектәге минор кенәриләр,
                    әверелеп нота-көйгә,
ташландылар ватык тәрәзәгә...
...Дивардагы кадими сәгатьнең
                    бөкшәйгән хаста күкесе,
сукрана-сукрана,
Вакыт тирәли йөрдә очып.
...Онытма, Көн!
Бүген төнге 1 дә
            таш бәгырьләр
                    таш аттылар
Шагыйрь тәрәзенә.
Һәм качтылар.
Сорау билгеседәй бөкрәеп,
ашыга-ашыга кереп югалдылар
Айлы төн эченә.

*1995*

[1] Кулъязма архивта саклана.

*Сафуан Муллагалиев*

## Саклый алмадык шул...

...Ишеткәч тә, дустым,
Рәшит Әхмәтҗанов,
Гүя дөнья кысты үземне.
Тирә-ягым томан,
Калтыранам, туңам –
Каян гына алыйм түземне?
Гүя дөнья кысты үземне...

Табаннарым җиргә тию белән,
Иблис калкып чыкты дүрт чатта,
Уңга карасам да,
Сулга карасам да,
Кара елан сыман юл ята.

Итәк асларыннан үткән юллар
Буйлап алган туган җирләрне,–
Посып торган юллар,
Юлларга иш еллар
Суырдылар безнең җегәрне...

...Кайдан башланганын
Хәбәр итә идең
Ябырылып килгән хәвефнең.
Үзең кебек синең, шагыйрь дустым,
Шигырьдәге һәрбер хәрефең
Каршысына басты хәвефнең...

...Мәңгелеккә озаттык без сине,
Татар халкы сыкрап озатты...
Ышан, дустым,
Шәһит киткән шагыйрь,
Илне богаулаган йозакны
Ачар халык,
Ачар йозакларны,–
Татар тыны тимер эретә,
Соңгы канны түкми-чәчми генә
Чыксак иде тулы иреккә!
Татар тыны тимер эретә...

...Ах!
Үлемеңне ишеткәч тә синең,
Гүр суыгы алды үземне.
Кайгы-хәсрәтемнән һуштан яздым –
Кайдан гына алыйм түземне?
Гүр суыгы алды үземне...

Саклый алмадык без
Сине, шагыйрь дустым,
Җир ярылып, гүрең ачылды.
Газиз халкым белән мин дә йоттым,
Йоттым синең үлем ачыны,–
Йөрәк ярам әрнеп ачынды...

*1995*

*Әхмәт Рәшит*

## Милләтебез каһарманы[1]

*(Мәрсия)*

Язлар килә... кабат язлар килә...
Зәңгәрләнә бара аяз күк...
Бар тарафны назлап кояш көлә –
Дөнья матур... бары Рәшит юк.

Мәйданнарда кайнар чакырулар –
Йөрәкләрдә, димәк, сүнми ут:
Татар өчен мөстәкыйльлек даулап
Көрәш дәвам итә... Рәшит юк.

Шигарь булып яңгыраса шигырь,
Күңел таша, шаша шактый ук;
Илдә сирәк кунак – шатлык та бар,
Тик сөенеп булмый – Рәшит юк.

*Рахмай Хисмәтуллин*

## Мәрсия

«Азатлык!» дип бөек милләтенә –
Йөрәгенә алды күпме яра.
Мәйданнарда ачлык игълан итеп,
И янды соң бахыр парә-парә.

Шуңа да бер ярсу некрологны
Язмаганнар инде «кәләпүшләр»...
Хет, ичмасам, теге дөньясында
Ятсын иде күреп рәхәт төшләр.

Җаны-рухы бер сөенсен иде,
Хет үлгәчтен таныдылар, диеп.
Ачлык тоткан мәйданнары буйлап
Көлә-көлә үтсен иде биеп.

---

[1] Кулъязма архивта саклана.

Бала кебек ышана иде сүзгә,
Фанатикча сөйде үз милләтен.
Бөек шагыйрь идең син, Рәшит,
Шигъренң үтәр әле җир тетрәтеп.

...Мин аптырап йөрим әле хәзер:
Ә без үлгәч, язмыш ничек зурлар?
Ахры, фәлән җирдә эшләгән, дип,
Җыен юк-бар язып чыгарырлар.

Мине миннән ныграк кем белә соң?!
Миңа бары ике юл да җитә:
«Һәр кешедә даһи үлгән кебек,
Танылмаган бөек шагыйрь китә...»

*1995*

*Илдар Юзиев*

## Акчарлак[1]

Кораб китте. Тыныч йөзәр чак инде:
Гарасат юк. Җылы җилләр исәләр.
Сез әйтегез, мин ышанам: шагыйрьне
Акчарлакка әверелгән, дисәләр.

Азык эзләп очмады ул, ирекне
Алып булмый ач торып та, елап та...
Канатлары иңли инде киңлекне,
Авазлары бик якын да, ерак та...

Кораб китте. Бәлки, көтәр упкын да.
Бәлки, кемдер исән калыр... Ул кайтмас.
Бераз гына хәл алыр да — дулкында,
Очар һаман, кыйбласын югалтмас...

*1995*

*Айдар Хәлим*

## Кара каен әрәмәсе

Син үлгәндә исән булганмын бит...
Ә син — гафу! — китеп котылдың.
Бүген — тере үлек, барчабызның
Гөнаһлары өчен тотылдым.

Нинди гөнаһ?! «Фәрештә гөнаһлы
Булмый» диләр күпләр аңламый.
Шулай, дускай, бәрәңге базары
Көрәшмәүне гөнаһ санамый.

Шундый заман, ахир! Күрсәң, күзең
Шартлар, карый күрмә — тик акай:
Ат койрыгындагы соңгы буын —
Ничек түзим, шартлыйм, малакай!

Нинди гөнаһ?! Әнә каен килә,
Биштәр аскан, кара, сәләмә.
Хәер сорап каралган каеннар —
Тузы суерылган әрәмә...

Нинди гөнаһ?! Үткенчегә безнең
Таң атар-атмастан сатылды.
Туып кына килгән яшел яфрак
Аучы мылтыгыннан атылды...

Нинди гөнаһ?! Туз суерта торгач,
Ләббәйкәләп куштан кушканны,
Кара әрәмәгә әйләндердек
Ак каенлык — Татарстанны.

Аһ, кем килә? Кем соң көпә-көндез
Шәм кабызып бара укырга?
Сукыр Бөре! Бәлки, мәктәбенә
Җитәр, күммәсәләр чокырга...

Кайрак күктән нәҗәгайләр иләп,
Утта сүнгән шагыйрь гомере
Онытылыр, чыгармаса
Чокыр казып чыккан шул Бөре.

*1996*

*Роберт Әхмәтҗан*

## Соңгы ядкәр

Кая гына киттең әле, адаш,
Якын гына юкса тавышың?
Ахыры син, һаваларга ашып,
Зәңгәр кошлар белән кавыштың?

Күк кошлары нихәл яши анда,
Тарсынмыйлар микән күкләрен?
Кошлар булып кошлар җирдән башлый
Мәңгелекнең бөек чикләрен.

Син күкләрдә очып җиргә төштең,
Ә җир сине шундый сагынган! —
Хәтта сине кочагына алды,
Бар шаһитлар шунда өнсез калды,
Бар да тынды моңга табынган!

[1] Кулъязма архивта саклана.

Аңладык без шунда бу мизгелне,–
Араларга таулар салган бит.
Бер күперсез дәрья, ярлар салган,
Шул ярларда без дә калган бит!
(Ышанмадык, «Бу, – юк, ялган!» дип.)

Үтерәләр безне мактап-хурлап
Гайбәтчеләр, дуслар, хайваннар...
Дөрләттеләр сине милли хисләр,
Яндырдылар сине мәйданнар.

Ашкындырды сине рухи дөнья,
И көндәлек азык хәстәре!
Сандугачлар кереп, йөрәгеңне
Нинди генә җырга дәшмәде!

Очтың җырда, очтың. Очышларны
Синсез генә ничек очларбыз?
Күк түреннән
Җиргә атылып төшкән,
И тәвәккәл, кыю кошлар сез!

Һаваларда көзге кошлар өне,
Кая оча кошлар төркеме?
Синең кебек, шул кошларга ияреп
Очасылар бардыр бер көнне...

Аннан, талып, кунакларбыз җиргә,
Сыенырбыз газиз туфракка...

*1996*

*Фарсель Зыятдинов*

***

Ирек даулап тынган йөрәгеңне
Сәрхуш таңнар хөкем итә калса,
Басар яшьләр синең эшне яклап,
Йөрәгендә татар каны акса.

Дастаннарга тиң бу исемеңне
Байрак итеп утка кергән чакта,
Берлек кирәк безгә, ныклык кирәк,–
Бүленүдән, Ходай, безне сакла!

*1997*

*Мөхәммәт Шәйхи*

## Мәйданда

Аңламады, беркем аңламады,
Рәнҗү тулы бу җанга
Кыен иде җирдә гомер сөрү,
Кыен иде яшәү җиһанда...

Тирә-якта шау-шу, ят авазлар –
Кемнәр сата, кемнәр алалар...
И-их, юасы иде күңелләрне,
Дөнья карасыннан аралап...

Аның эше җирдә изге иде,
Аңлый иде аны аңлаган.
Заманалар башка, үзгә хәзер,
Аңа инде эш тә калмаган...

Кирәк икән, җаннар
тибрәтте ул,
Кирәк икән, бишек тибрәтте.
Моңсызга моң салды
йә елатты,
Йөрәкләрдә утлар көйрәтте...

Кирәк булса сөрде,
чәчте, урды,
Йортлар салды, чалгы
саплады...
Туган җиргә дошман
басып керсә,
Корал алып, илен саклады...

Үзе өчен берни сорамады,
Янар уттай ярсып дөрләде...
Яшь аралаш елмайган
чак булды,
Җанда ни бар,
беркем белмәде...
Һәрбер йортка керде
җырлар булып,
Яктыртты ул кара төннәрне.
Кемнәрнеңдер
ышанычлы дусты,
Ак сердәше булды кемнәрнең...

Аңламады, беркем аңламады,
Рәнҗү белән тулы бу җанга

Кыен иде җирдә гомер сөрү,
Кыен иде яшәү җиһанда...

...Баскан да ул, кулын
алга сузган,
Беркемнең юк анда бер эше.
Импорт кием тәнгә
каплап, бәндә
Төркем-төркем үтә өелешеп...

Хәтерләмим никтер
моңа кадәр
Мондый кадерсезлек булганын.
Ә ул тора мәйдан уртасында,
Кешеләргә сузып кулларын...

Якты уйлар тулды күңеленнән,
Якты ташкын булып нур ага...
Агартырга теләп кара чорны,
Шигырь сөйли иде дөньяга!
Шигырь сөйли иде!
Шигырь!..

*1998*

*Эдуард Мостафин*

## Күңелендә сандугач иде

Бер сандугач кергән иде
Шагыйрьнең күңеленә.
Ятим калган ул сандугач
Бүген сайрамый нигә?
Ирек мәйданы да ятим —
Ул ач утырган мәйдан.
Шунда сүзен әйткән: «Милләт
Ычкынсын,— диеп,— бәйдән».
Ул йөзгән Иделе ятим,
Ятим гөлҗимешләре,
Ятим бүген каеннары,
Күкләре, инешләре.
Ятим бүген киек казлар,
Ятим акбүз атлар да.
Шигыреннән чыгып бар да
Китәр кебек якларга.
Бары да килерләр сыман
Шагыйрь җанын сакларга...
Оҗмахның түрендә булсын
Яткан җирең, Рәшит.
Вөҗдан кушканча яшәдең,
Халкың өчен көрәшеп.
Сандугач янган учакта
Җылынмадың, туңсаң да.
Шигырь ябынып йокладың,
Вокзалларда кунсаң да.
Туңмасын дип, сандугачны
Йөрәгеңдә җылыттың.
Юкса үзең күпме тапкыр
Зилзиләгә юлыктың.

Ә мин бүген зиратында
Менә шундый җыр оттым:
Сандугач керсә шагыйрьнең
Тынгысыз күңеленә,
Очып чыгар да оялар
Җыр булып күңеленә.

*2000*

*Рәниф Шәрипов*

## Ил

Ил эчендә ил.
Җил себергән җир.
Җир астында ут.
Ярсып ала янартаулар —
Фәүзия, Зәки, Айдар...
Рәшит кенә янып бетте,
Рәшит кенә инде юк.
Көле һаман да кайнар.
Көл суына, таулар тына.
Кайда сез, «яңа байлар»?
Борчымыйммы сезне бер дә
Догасыз үткән айлар?
Каргыш иле,
Сагыш җире,
Кем үлә,
Кем уяна,
Көл суына...
Тик онытма:
Җир астында ут яна!..

*2002*

*Марат Кәбиров*

## Халык

Күренекле бер иптәшне җирләгәндә,
Мәетеңне күтәргәннәр
Бер кадерле йөк итеп.
Керфеккә яшь кундыралар,
Күңел бозын эретеп.

Ә халык... Халык бер көтү,
Аю биеткән кебек...
Алар сине соңгы кабат
Калырга тели күреп.

Яраталар шул бәндәләр
Җирләүләргә йөрергә.
Балкыбрак янганнарны
Соңгы кабат күрергә.

Тере чагыңда берәрсе
Күтәреп йөреттеме?
Назсыз туңган күз яшеңне
Берәрсе эреттеме?

Бүген менә җыелганнар...
Дус итеп, якын күреп.
Өелгәннәр... Табутыңда
Аю биеткән кебек.

Җан биргәндә ялгыз иденң...
Хәзер менә күмәкләр...
Тукталды Вакыт...
Нигәдер
Ашыгалар көрәкләр.

Кичер, Вакыт...
Ахмакларның
Гөнаһсыз гаепләрен.
Тере улын сөйми халык,
Ярата мәетләрен.
...Корбаннарын сөя халык.

*2003*

*Зөлфәт*

## Эчем яна, тышым яна...

Шагыйрьләрчә моңсу да бу табын,
Шагыйрьләрчә шаулы, дуамал;
Өермәле буран дулый тышта —
Тынасы юк, тынмый, тынмаган...
Авызлыксыз һәм тыңлаусыз җаннар!
Шагыйрь безне тыеп туктата:
— Мәҗлес мондый булмый, бәгырьләрем!
Җырсыз утырасыз төнката!
...Богемалы безнең «мәгарә»не
Тутырып, ул үзе җыр суза,—
Җыры да бит аның үзе сыман
Шук та, сагышлы да, моңсу да:
— Ак үрдәккә, күк үрдәккә
Җимнәр салдым түмгәккә...
Эчем яна, тышым яна —
Ут кабынмый күлмәккә! Уф! —
Җыр әйтә дә безгә карап тына:
— Сезгә җыр җырлаган мин — дурак!
Беләсезме, нигә шагыйрь булып
Йөрибез бу җирдә каңгырап?
Бүтән юньле эшкә ярамыйбыз!
Тел бар — карга алып китмәскә...
Йә далада яшәмисез! Тутыр!
Дөнья малы җирдә бетмәс лә!
Җырлатыгыз юмарт чакта!
Хәер, җыр үтәрлек түгел инде сез...
Әмма... тагын болай җырлашулар
Насыйп булыр микән — билгесез...
Ник чүмәштең анда мәрткә китеп?
Касәләрне тутыр, яшь иптәш!
Менә җырның сезгә яраклысы —
Башкасына сезнең баш җитмәс!
Һәй!
Базарда Маручкалар
Саталар саручкалар;
Маручкылар белән йөрсәң,
Тиз бетә палучкалар!
— Рәшит абый, үзең сөйлә әле
Баштан узган гыйшык-мыйшыкны!
Син күпләрне гашыйк иткән, диләр.
Һәм төзәткән, диләр, кыйшыкны...
— Син, яшь иптәш, багърем, күпне белмә!
Әйе, кызлар миңа күз атты —
Гомеремә кызлар озатмадым,
Кызлар үзләре гел озатты!
Элек заман кемдер җыр чыгарган —

Әллә мишәр, әллә керәшен –
Кызлар гыйшыгыннан минем сыман
Интеккәндер инде, күрәсең...
Чибәрләрдән туеп елагандыр,
Калмаганга күрә һич чара!
Үземнеке итеп җырлыйм шуны...
Өзелепләр әйткән бичара:
Базарларга чыгып ике ат алдым,
Икесен дә йөз дә унарга;
Урамнарга чыгар хәлләрем юк –
Кызлар чакыра мине кунарга!
...Табындашлар тәгәрәшеп көлә,
Рәшит сүккән булып кылана:
– Сезме аңлар чибәр егет хәлен?!
Җыен котсыз! Җыен дивана!
Ана – көзге! Карагыз бер!
Сезне агартканчы кирәк юарга!
Кыз-кыркынның иң беткәне хәтта
Кертмәс куенына кунарга!
Сез җавапсыз мәхәббәттән шигырь
Язар өчен генә яраклы!
Шигырь сөйлик! Шигырь сәгате бу!
Әнә буран тынды. Таң атты...
...Табындашлар таңда шигырь сөйли,
Дөньяларда ал таң яктысы;
Дөньядагы ал таң яктысының
Яртысы ла шигырь яктысы...
Таңга уралыплар искә төшә:
Сөйли, җырлый, елый, шаярта...
Моңсуланып кына кояш бата,
Сагындырып алсу таң ата...
И туганкай! Синең йомгак та бит
Ахырына кадәр сүтелде;
Киләбез дә китеп югалабыз
Өермәле буран шикелле...
Безне – сәер яшәп киткәннәрне
Искә алмас, бәлки, беркем дә,–
Җырлаган җыр, тере шигырь калыр
Дөньядагы җилләр иркендә...

*2007*

*Илдус Гыйләҗев*

## Рәшит Әхмәтҗан ядкәре

Якынайтты безне тулай торак,
Бер бүлмәдә яттык янәшә.
Тел өйрәндек КДУ залларында –
Шагыйрь булмакчыбыз, янәсе.

Шагыйрь булу гына аз икән шул
Татар баласына бу илдә.
Кемнәрдәндер түбән булмавыңны
Көрәш аша кирәк дәлилләү!

Әйләндереп салдың ялганнарын:
«Ирек» түгел, «ачлык» мәйданы...
Әй, кыю зат, синең исем белән
Атар идем бүген мин аны!

Ач чагында синең баш очында
Урнашалмады шул ятагым.
Уем синең янда иде дә бит...
Җырларыңны читтә ятладым.

Син Казанда калдың мәңгелеккә,
Минем тормыш шактый еракта.
...Асыл татар белән кавыштырды –
Рәхмәт яусын тулай торакка!

*2007*

*Клара Булатова*

## Син безнеке идең

Бүген сине Әлмәт тыңладымы?
Әйтә алмыйм, бәлки, юк тадыр...
Тыңласалар әгәр, мин ышанам:
Бу төбәккә исемең юл табар.

Шигърияткә Әлмәт китерде бит
Рәшит атлы затлы шагыйрьне.
Тик бүгенге Әлмәт бу шагыйрьдә,
Ташчы егет, сине танырмы?

Ә танырга кирәк, танытырга
Бүген монда үскән яшьләргә,–
Ташчылардан шагыйрь туган иде
Нигез салган чакта шәһәргә.

Шагыйрь кулы төзгән кирпечләрдән
Күтәрелгән биек өйләрдә,
Әнә аның җыры яшәп килә,
Тыңлый белсәң туган телләрдә.

Ярсу йөрәк, дуамал баш идең,
Җитдиләндең, үстең көрәшеп.
Өлгергәч тә син безнеке идең,
Әлмәтнеке идең, Рәшит!

*2013*

*Сәгыйть Әхмәтҗанов*

## Безнең авыл

*Рәшит Әхмәтҗанов монологы*

Безнең авыл миллион авыллар күк –
Таулар кочагында,
Таллар арасында,
Борма-борма булып сузылып яткан
Елга буйлап бераз барасың да,
Юл буенда, авыл капкасында
«Кандыз» дигән язу табасың да,
Шикләнмичә барып керәсең.
Керү белән, «мине» күрәсең.

Авылым нәкъ миңа охшаган ул,
Минем йөзем анда, минем рухым,
Минем шатлык, минем хәсрәт анда,
Авылыма шулай ялганышым.

Нәкъ минемчә матур безнең авыл,
Нәкъ минемчә горур, сөйкемле ул,
Нәкъ минемчә усал усалларга,
Бик гадел дә минем шикелле ул.

Күрәсеңме, колачларын җәеп,
Авылымның изге бер карт талы
Киткәннәргә фатихасын биреп,
Килгәннәргә сәлам биреп кала.

Шул талдан мин, нечкә чыбык җыеп,
Каз читәне үрдем бала чакта.
Хәтерли ул мине, минем төсем,
Минем исем калды шушы талда.

Күрәсеңме, юлдан ерак түгел
Бер сай чокыр тулы кызыл балчык.
Өй сыладык шуны казып ачып,
Анда минем эзләр калган качып.

Их, андагы елга буендагы
Күпме ташны белә минем табан!
Һәр таш таный, аңлый, санлый, минем
Табан канын саклый алар һаман.

Безнең авыл иң матуры димим,
Гади авыл матурлыгы анда.
Маңгай тирен түгеп эшләүчеләр
Бизи аны авыр бу заманда.

Зурламагыз безне, сорамыйбыз,
Хурламагыз бары нахакка сез.
Безнең авыл миллион авыллар күк
Эшләп ашый, илне ашатабыз.

Күрим дисәң ачык йөзебезне,
Керим дисәң керсез күңлебезгә,
Белим дисәң кыйммәт серебезне,
Килегез бер кунак булып безгә.

Кунак, дисәң, авыл үлеп торыр,
Кем килгәнне белеп-сизеп торыр,
Булганының соң тамчысын биреп,
Колач җәеп һаман көлеп торыр.

Шуңа шулай матур безнең авыл,
Шуңа шулай горур, сөйкемле ул,
Шуңа шулай усал усалларга
Һәм гадел дә халкым шикелле ул.

*2014*

*Рәмзия Вәлиуллина*

## Әхмәтҗанов Рәшит Хәниф улы

Салкын таштан мәгънә
Таба белгән,
Сүздән матур итеп чылбыр
Үргән,
Туган ягын бар нәрсәдән
Өстен күргән,
Бөтен көчен, хисен
Шигъриятькә биргән
Әхмәтҗанов Рәшит Хәниф улы.
«Кандыз» дигән ерак
Авыл барын,
Ул язмаса, кемнәр белер иде?
Шагыйрь үткән юлдан
Үтик, диеп,
Казаннардан кемнәр килер иде?
Булмаса әгәр
Рәшит Хәниф улы.

*2016*

*Рәдиф Гаташ*

## Тукай хозурында

*(Гомер дастаныннан)*

...Тукайлы мәйданда уйланам:
Кемнәр генә үтмәгән шигъри дөньядан?
Нинди җыраулар, чичәннәр узмаган!

«Кил, хәйраным, беләр, сорасагыз,
Ни адәм-пәйгамбәрләр үткән дөньядан?
Гарәби китап укыган
Галим дә үткән, ди, дөньядан...
Кочаклап Коръән укыган
Мулла да үткән, ди, дөньядан»,—
Әллә алар шагыйрь булмаган?

Шул дастан-җыруларга мөкиббән
(Үз сүзләре дә алтын, энҗедән!)
Туфан, Хәким, Арсланнар —
Әллә шундый ирләр булмаган? —
Бөек гамьлеләр янына
Юзәй, Шәүкәт, Әхсәннәр күчте дөньядан.

«Безнең йөрәк җирдә мәңге
Елап-көлеп йөрсә иде»,—
Дип язган нечкә җан Рәшит артыннан
Китте бунтарь Роберт дусты —
Ике олуг зат Әхмәтҗан —
Алар да үтте дөньядан.

Тиңсез милли Рух, Моң шагыйрьләре —
Мөдәррис, Зөлфәт, Наис, Харраслар...
Чакырдымы Кадыйрлары? —
Алар да кичте дөньядан.
Безнең гел бергә барган «бишлек»тән
Якты йолдыз бер, ярсу җан —
Мингалим дә үтте дөньядан.

(Аһ, бу дөнья, аермады
Безне кемнәрдән! Газизләрдән:
Улларыбыз бездән алда китте!
Килә белми килсә үлем — шул яман!)

Әле исәннәрдән килер буыннар:
«Ил адашып йөргәндә,
Йолдызсыз-айсыз төннәрдә,
Пирем, анда кайда идең?» — дип
Күзгә үк карап сорарлар.

Олуг сүз, Тукай мәйданы исән,
Киткәннәрнең җыры, васыяте
Безнең белән яши һаман.
Исәннәргә юл — алга табан.
Идел ага... Яши Ил. Хыял — аман...

*2016*

*Ркаил Зәйдулла*

## Күчеш

Өскә үрелгән ул соңгы сулышында,—
үлем шәрабы кушырып кем дәшкәндер...
Күренмәс нур чылбырына ябышкан да
куш йөрәге гареш белән тоташкандыр.

Акрын гына кар сибәләп тора иде.
Кемнәр качкан, кемнәр ашкан — нинди эше
бу дөньяның?
Искәрми дә ул беркемне! —
Шагыйрьнең дә гап-гадәти бу күчеше.

*2018*

*Камәрия Җамалетдинова*

## Олуг шагыйрьгә

Кемнәрнеңдер калын бер китабы —
Алмаш була алмый бер шигырьгә!
Кулларымнан килсә,
Шушы шигырь өчен хет 60 ел
Өстәр идем Шагыйрь гомеренә!

Үзәкләрне өзә торган итеп
Мин көй язар идем, моңсар булсам...
Әрсез кемсәләрне аулар идем,
Дала хөкемдары — Шоңкар булсам!

Ни аяныч, берни башкара алмыйм,
Нинди хурлык — мин бит юаш бер зат...
Мин бары тик аңлыйм бу шагыйрьне,
Укыйм кат-кат елап, әрнеп, сызлап...

*2018*

# Рәшит Әхмәтҗановка бәйле шаярулар, мәзәкләр бәйләме

*Габдел Әхәт*

Ачлык игълан итте сәясәттә,
ә үзе гел – шигъри сәяхәттә.
Халкын гына, холкын гына түгел,
кеше бәгырен өзелеп сөя хәтта.

*Зөлфәт*

Шагыйрь Рәшит Әхмәтҗанов:
– Кыскалык ул шигъриятнең
Сестрасы, брате.
Кемнәрдер озын язалар,
Бу бит – адәм гибрате!

*Фаил Шәфигуллин*

## Алтын богау

Кулыма алтын богаулар,
Кил әле, кидер, иркәм...
*Рәшит Әхмәтҗанов*

Алтын богау ялтыраса
Ялт-йолт минем кулларда,
Исләремә син төшәсең
Командировкаларда.

Ял итсен әле кулларым.
Иртәгә Зәйгә китәм...
Бүгенгә богауларымны
Салдырып торчы, иркәм.

*«Чаян».– 1976. – № 20*

*Г. Әптел*

## Эзлә – тап

*(Пародия)*

Көннәр генә түгел, алда айлар бар ич,
Еллар бар ич – очрашырбыз без тагын да.
Күрим дисәң, язларымнан эзлә мине –
Минем язлар умырзая тамырында.
*Рәшит Әхмәтҗанов*

Чын шагыйрьләр һаман туып тормый –
Йөзгә-меңгә була бер генә.
Алары да ятмый чатта аунап,
Очратырмын димә тиз генә.
Шагыйрь күрим дисәң, эзлә мине,
Координатым шундый: чамала –
Күл артында булыр кара урман,
Юл буенда – ялгыз карама.
Карамадан бераз сулга каер,
Каенлыкны калдыр уң якта.
Алан уртасында юлыгырсың
Җәелеп үскән юан усакка.
Усак шул мин инде...
Табалмасаң,
Өмет өзмә, эзлә, дәвам ит.
Кисеп алулары бик ихтимал –
Агач кәгазь өчен бара бит.
Балахнадан эзлә – комбинаттан,
Нәшрияттан, офсет цехыннан.
Бу да финиш түгел. Шагыйрь юлы
Китап кибетенә шушыннан.
Шүрлекләрдән эзлә. Сатучыдан
Ипләп сора, диген: әйтче, җаным,
Эзли-эзли ярты илне гиздем –
Юкмы сездә Рәшит Әхмәтҗанов?

*«Хезмәт». – 1979. – 14 апрель*

*Рабит Батулла*

## «Вакыт белән бәһа»

Радио дикторы Камал ханым Саттар, иртән эшкә килгәч, хезмәттәшләре белән базар бәһаләре турында сөйләшеп тора икән. Карбызның килосы утыз тиен, итнең килосы биш сум, йөзем ике сум илле тиен, диләр. Ул арада эфирга чыгар вакыт та җитә. Камал ханым иртәнге тапшыруларны болай башлап җибәрә:

— Казан сөйли. Иртәнге радиотапшыруларыбызны башлыйбыз. Мәскәү вакыты белән җиде сум кырык биш тиен!

*Рәшит Әхмәтҗанов сөйләгәннәрдән*
*1983, 3 октябрь*

## Көйсез Фатыйма

Фатыйма ханым Ильская турында «яшьтән үк бик көйсез кеше иде ул» дип сөйлиләр. Ул игътибар мәркәзендә булырга ярата. Игътибар кими башласа көйсезләнә, гауга эзли башлый һәм эзләгәнен һәрвакыт таба торган була.

Бер тапкыр Фатыйма ханым сәхнәгә чыгар вакыт җиткәч:

— Бу башмаклар минеке түгел, нигә миңа чит башмак куйдыгыз, үзем кия торган башмакларны китерегез, юкса мин сәхнәгә чыкмыйм! — дип буза куптара.

Киендерүче хатын:

— Фатыйма апа, болар бит сезнең башмаклар! — дисә дә, Ильская:

— Үземнең башмакларны бир! — дип, киендерүченең җанын ала.

Тегесе үкереп елый башлый.

— Фатыйма апакаем, кырыгынчы тапкыр шушы башмакларны куйдым! Сезгә нинди башмак кирәк инде тагын? Менә бит, менә бит, тамгалары шул ук. Театрда башка мондый башмак юк! — ди.

Шулчак Нәфига ханым Арап киендерүче хатынга, пышылдап кына:

— Бар, сеңлем, тиз генә башмакларны ал да алыштырып китергән бул! — ди.

Тегесе шулай итә дә:

— Менә, Фатыйма апа, тегендә булганнар икән! — дип, шул ук башмакларны Ильскаяга кигертә.

— Менә бит! Менә үз башмакларым! Ә син лыгырдап торган буласың тагын...

«Фатыйма апа, сәхнәгә!» дигән тавыш ишетелә, һәм Фатыйма Ильская, «табылган» башмакларын киеп, сәхнәгә чыгып китә.

*Рәшит Әхмәтҗанов сөйләгәннәрдән*
*1983, 30 октябрь*

## Ике шагыйрь очрашуы

— Нур Гайсин, Нур Гайсин, күккә меналмаган тургай син!

— Сәхаб Урайский, син үзең дә инде шулайски...

*Рәшит Әхмәтҗанов сөйләгәннәрдән*

## Алтынчы таш

Шагыйрь Рәшит Әхмәтҗан төнлә аш бүлмәсендә «Бишташ» дигән поэмасын тәмамлап утыра икән. Кинәт тәрәзә чәлпәрәмә килә. Рәшитнең язу өстәленә таш килеп төшә. «Әһә! — ди шагыйрь.— Шигырьгә нидер җитми сыман иде. Алтынчы таш җитмәгән икән».

— Кем аткан ул ташны? Үзең ничек уйлыйсың? — дигәннәр шагыйрьгә.

— Кем булсын! — дигән шагыйрь.— Такташ язып утырганда, төнлә Фатих Мөсәгыйть алтатар белән аткан. Тигезә алмаган. Миңа таш аткан кеше дә шигырь язып та эш майтара алмаган бер көнчел бәндәдер! Ни кызганыч, мин олы кыйссамны тәмамлап утырам, ә ул, таш тотып, төне буе минем тәрәзә астында йөри. Бичара!

*Рәшит Әхмәтҗанов сөйләгәннәрдән*
*1985, 24 октябрь*

## Тарткалаш

Атаклы җырчы Зифа ханым Басыйрова, картая төшкәч, пенсиягә чыгар алдыннан, хезмәт хакы күп күренсен дип, авылларга гастрольләргә чыгып китә. Җитәкчеләр белән килешүләр төзеп алдан йөрүче кеше, һәр авылда идарәгә кереп, җыландай телләрен чыгарып ялына икән:

– Яраткан җырчыгыз бит, Зифа ханым бит! – ди икән ул. – Өч йөз сумга кул куегыз, зинһар!

Җитәкчеләр тиз генә өч йөз сум чыгарып бирергә теләми:

– Ике йөз сум! – диләр икән.

– Ышту сез, – ди алдан йөрүче егет. – Ике йөз сумга Зифа апа кебек җырчыны мыскыл итмәгез сез, өч йөз сум! – ди.

– Һәй, – ди бер җитәкче, – Зифа, имеш, юньләп җырламас та әле. Җырчылар алар ялындырырга яраталар.

– Һәй, агай, – ди егет. – Сибә генә ул безнең Зифа апа. Бер бүлектә унбишне җырлый, икенчесендә унсигез җыр җырлый, белдегезме! Шаккатачаксыз!

Ниһаять, рәис өч йөз сумга килешү төзи, кул куя. Егет, кул куелган кәгазьне куенына тыгып куйгач:

– Дөресен генә әйткәндә, җырлый алмый инде ул Зифа апа! Ничу аңа хәзер җырлап йөрергә! Шулай да пенсиясе өчен кирәк инде.

*Рәшит Әхмәтҗанов сөйләгәннәрдән*
*1983, 17 октябрь*

## Җәбраилдән өстенрәк

Рәшит Әхмәтҗан кайвакыт эш арасында, өстәленә иелеп, бик бирелеп, нидер яза башлый иде. Андый вакытларда ул сөйләшми, үзенә дәшсәң дә, илтифат итми. Бары тик:

– Комачауламагыз! Мин Алла илчесе – Җәбраил фәрештәдән шигъри вәхи алам! – дип кенә куя торган иде.

Шулай «Җәбраил белән сөйләшеп утырган» чагында кинәт телефон чылтырады. Рәшит төрепкәне колагына куеп алганнан соң ялт кына сикереп торды да:

– Баш мөхәррир чакыра! – дип, ашыгып шунда кереп китте.

Ул әйләнеп чыккач, Мансур Вәли аны шаяртасы итте бугай, әйтте:

– Нишләп әле син баш мөхәрриргә дә «мин Җәбраилдән вәхи алып утырам, комачаулама!» димәдең, ә?

– Әйтеп кара! – диде Рәшит, яшел күзләрен шаян елтыратып. – Равил бит ул Җәбраил генә түгел!

## Гаскәр байрагы, яки Хәрбиләрчә сәлам бирмәк

Гажур баскычында бер төркем яшь язучылар тәмәке тартып, ләчтит сатып тора икән. Алар янына Ркаил Зәйдулла да килеп кушыла. Ул яңа гына сыраханәдән чыккан, комач кебек кызыл чырайлы икән. Шулчак болар яныннан, кулына кәгазьләр тотып, Рәшит Әхмәтҗан узып бара икән. Ркаилне күрүгә, ул, бер кулын янга туры куеп, икенчесен чигәсенә якын китереп, Ркаилнең күзенә туры карап, сафта баручы солдаттай, дөп-дөп атлап китә.

Җегетләр, бер-берсенә карашып, иңнәрен сикертәләр: ни булган бу Рәшиткә? Бераздан соң Рәшит кире кайтып килә икән. Ркаилгә җитәрәк, ул тагын, сынын катырып, дөп-дөп атлап уза. Ике-еч тапкыр шулай кабатлангач, Рәшитне туктатып сорыйлар;

– Рәшит абый, син нигә алай итәсең, гел Ркаилгә хәрбиләрчә сәлам бирәсең? – диләр.

– Мин бит аны гаскәр байрагы дип торам! – дигән Рәшит.

*Әхмәт Рәшит белән Мөдәррис Әгъләм сөйләгәннәрдән*
*1988, 10 ноябрь*

## Өч Сталин

«Татарстан яшьләре» газетасы редакциясендә Рәфикъ Юныс, Госман Гомәр, Харрас Әюп бер бүлмәдә утырып эшлиләр икән. Шулай тын гына эшләп утырганда, кинәт ишек ачылып китә дә Рәшит Әхмәтҗанның ялтыравыклы башы күренә. Исәнләшеп тә тормыйча, Рәшит:

– Кайсыгыз миңа биш сум акча биреп тора? – ди.

Берәү дә дәшми, эшли бирәләр.

– Кайсыгыз миңа бурычка биш сум акча биреп тора? – дип кабатлый Рәшит.

Берәү дә кыймылдамый. Рәшит тагын бер мәртәбә сорый да, җавап ала алмагач:

– Өч Сталин! – дип, ишекне яба.

*Харрас Әюп сөйләгәннәрдән*
*1988, 5 август*

*Шамил Маннапов тупламасыннан*

## Уены-чыны бергә

Шигырьләр язучы Илсөяр Ганиева Рәшит Әхмәтҗанга киңәш сорарга килгән:

– Советлар Союзындагы кимчелекләр турында «Минем хәятым» дигән китап яздым. Бик шәп әсәр. Кайсы чит илгә сатыйм икән? – дигән.

– Хәзерге көндә,– дип киңәш биргән аңа Рәшит бәй,– Советларның иң олы дошманы Кытай, Илсөяр ханым. Син, романыңны алып, шунда, Кытайга кач, тамагың тук булыр, рәхәтләнеп туйганчы бер бака ашарсың!

## Митинг дип белгән

Милли көрәшче Рәшит Әхмәтҗан, илле яше тулгач, үзенең иптәшләрен кунакка чакыра. Тост артыннан тостлар әйтелә. Кайнар речьләр тотыла. Мәҗлеснең иң кызган бер вакытында Рәшит кинәт сикереп тора да, кулларын алга сузып:

– Азатлык! Азатлык! Азатлык! – дип кычкырып җибәрә.

– Ни кылануың инде бу, Рәшит? Өендә моның ирегеn кысалар икән, дип уйлаулары мөмкин...– ди хатыны, борчылып.

## Тәрәзә янында – кояш

Эссе җәй көне. Матбугат йорты ашханәсендә Флүс Латыйфи, Рәшит Әхмәтҗан һәм Кояш Тимбикова тәрәзә буендагы өстәлдә тәгам җыялар. Менә подносын тоткан Мансур Вәли килеп керә, утырырга урын караштыра.

– Мансур, монда кил, безнең янга! – ди Рәшит.

– Анда кояш шул,– ди Мансур.

Кояш әйтә:

– Мин тиздән торып китәм, иркенләп утырырсыз...– ди.

*Факил Зәйнәгытдинов*

## Яшь шагыйрьне... бикләп киткән

Арабыздан бик иртә киткән танылган шагыйрь Рәшит Әхмәтҗановның үзе туып үскән Баулы районының Татар Кандызы урта мәктәбендә укып йөргән чагы. Шигырьләрен бербер артлы почта аша «Хезмәткә дан» газетасы редакциясенә җибәрә башлаган бу. Журналистлар аның әсәрләрен укып чыгалар да папкага салып куялар, бастырырга ашыкмыйлар, чөнки шик төшә: Рәшитнең иҗаты бер дә укучы балаларныкы кебек түгел. Шигырь язу кагыйдәләре дә төгәл сакланган, эчтәлекләре дә бай. Танылган шагыйрьләрдән чәлдермиме икән бу малай, дип шикләнәләр редакциядә.

Көннәрдән бер көнне Рәшит шигырьләрен редакциягә үзе китерә. Ул вакытта мөхәррир урынбасары булып эшләгән Кәрам абый Әхмәтҗанов яшүсмернең әсәрләрен укып чыга да фикерен әйтмичә, папкасына тыгып куя:

– Мин төшке ашка кайтып киләм. Шул ара син тагын бер шигырь иҗат ит әле,– дип, яшь шагыйрь утырып калган бүлмәсен бикләп, өенә кайтып китә.

Кәрам абый янә эшенә килгәндә, Рәшит бер урынына ике шигырь иҗат иткән. Болары да шәп чыккан. Шуннан соң Рәшит Әхмәтҗановның шигырьләре район газетасында басыла башлый.

*1999*





# Акчарлакның сагышы[1]

Тамаша залы. Ут сүнә. Экранда Рәшитнең сурәте. Караңгылыкта акчарлаклар тавышы ишетелә.

Т а в ы ш. Сез китмәгез, акчарлаклар, акчарлаклар, чит җирләрдә каерыла пар канатлар...

Ялгыз акчарлак тавышы гына кала. Шуннан соң Рәшит Әхмәтҗан сүзләренә Хөснул Вәлиуллин иҗат иткән җыр башлана. Сәхнә яктыртыла, җырлаучы ачыла бара. Сәхнә уртасында җыр һәм җ ы р ч ы гына кала.

Җ ы р ч ы китә.
А л ы п б а р у ч ы л а р чыга.

Б е р е н ч е а л ы п б а р у ч ы *(җыр тәэсирендә)*. Акчарлаклар, акчарлаклар, чит җирләрдә каерыла пар канатлар... Чит җирләрдә генә түгел, Ватан эчендә дә каерыла пар канатлар. Бүген татарның олуг шагыйре Рәшит Әхмәтҗанга алтмыш яшь тулган булыр иде. Кызганыч ки, вәйла, дәрийгъ, бүзләрем маналмадым, Рәшит Әхмәтҗанның гүр иясе булганына да җиде ел вакыт узган-киткән. Авыр туфрагың җиңел булсын, гүрең нур булсын, урының җәннәттә булсын, Рәшит дус! Иннәә лилләәһи вә иннәәә иләйһи раажигүүүн. Бернинди тантана да, бернинди мәрсия дә түгел, бу кичә...

Мөдәррис Әгъләм «Онытылырмы икән бу кичә» шигырен сөйли.

И к е н ч е а л ы п б а р у ч ы. Мең тугыз йөз туксан беренче елның унынчы апреле көнне шагыйрь Рәшит Әхмәтҗан белән әңгәмә.

Ике якта ике кечкенә өстәл яки ике мөнбәр. Ике а р т и с т чыга. Аларның берсе — сорау бирүченекен, икенчесе Рәшит Әхмәтҗанның сүзләрен сөйли.

С о р а у б и р ү ч е. Рәшит дус, синең иҗатың шаулы, шәрәфле исемнәр белән уралмаган. Әмма син барыбер үз мәсләгеңә тугры булып калдың. Шулай да әйт әле, ул исем-бүләкләрне башкаларга тапшырганда, син нинди халәттә була идең?

И л д у с-Р ә ш и т. Лаек кешегә бирелсә, ихлас сөенәм, арткы ишектән йөреп алганнарга карата мин бер генә сүз әйтә алам: булдыралар, чукынганнар!

С о р а у б и р ү ч е. Без — торгынлык корбаннары...

И л д у с-Р ә ш и т. Торгынлык, торгынлык, дибез, сүгәбез, дөрес сүгәбез. Тик шушы торгынлыкта татар әдәбиятына, сәнгатенә өерелеп, өермә булып, давыл булып талантлар килде. Һәрберсе — бер дөнья. Кабатланмас шәхесләр, шагыйрьләр, драматурглар, артистлар, музыкантлар, рәссамнар. Шул чорда иҗат юлы алдылар, шул чорда өлгерделәр, бүген бөтен әдәбият-сәнгатьне алар тартып бара.

С о р а у б и р ү ч е. «Ура, ялган ватанпәрвәрлек, ленинизм» чәчәк аткан вакытта шул шаукымга бирелмәүчеләр аз булды. Синең гарип шигырь язганың булдымы?

И л д у с-Р ә ш и т. Юк! Шигырь йә бар, йә ул юк! Син гарип санаган тезмәләр шигырь түгел. Шуннан килеп чыга ки «начар шигырь», «яхшы шигырь» атамалары. Начар шигырь була алмый. Шигырь бар икән, димәк, ул яхшы дигән сүз. Начар икән инде, ул шигырь түгел. Миңа калса, торгынлык чоры акыллы фикерле шагыйрьләрне тел төбе, киная, ишарә вә юл араларына яшеренергә мәҗбүр итте. Шул фикерләр, астыртын уй-моңга төрелсә, чын поэзиягә әйләнә. Шуңа күрә татар әдәбиятында шигырь гел алда булды.

[1] Рәшит Әхмәтҗановның тууына 60 ел тулу уңаеннан Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында уздырылган хатирә кичәсенең сценарие (авторы Рабит Батулла, режиссеры Илдар Хәйруллин, музыка өлеше — Фуат Әбүбәкер).

С о р а у  б и р ү ч е. Димәк ки, чын поэзия булсын өчен, шагыйрь өстендә кылыч-цензура торырга тиеш?

И л д у с-Р ә ш и т.

Үлем турындагы китапларның
Эчтәлеге күптән искерде.
Таш капчыкта яңгыраган телем
Таш балчыкта гөлләр үстерде.

Яулар узды.
Илгә исәннәр дә,
Үлгәннәр дә җырлап кайттылар.
Шигырьләрнең эчтәлеге яңа,
Шагыйрьләрен генә аттылар.

Җәлил балта астында үзенең шигъри һәйкәлен салды. Туфан күкрәгенә мылтык терәлгән килеш иҗат итте... Безнең өстә дә цензура, КГБ тукмагы гел эленеп тора иде, әле дә булса күсәк алынмаган. *(Сандугач тавышы ишетелә.)*

Өздереп-өздереп сайрый,
Талда түгел, читлектә.
Сайрап саргайса да кошчык,
Җыры аның иректә.

Канаты нигә читлектә,
Гаебе аның нидә?
Моңлы сайраган өчен дә
Җәза бармыни җирдә?

С о р а у  б и р ү ч е.

Кенәрине читлектән аласы иде,
И шагыйрь, сине шунда ябасы иде.
Яхшырак җыр җырлар идең, бәлки, анда,
Сирәгрәк чыгар иде китабың да.

Син узганыңа борылып караштыргалыйсыңмы?

И л д у с-Р ә ш и т. Бөтен язганнарымны баштанаяк тикшереп чыктым. Мин шигыремдә ялганламаганмын, Аллага шөкер. Бер генә китабымны да «коммунизм, партия» дип башламаганмын. «КамАЗ», «нефть», «атом электр станциясе» дип әсәрләр язып, кешеләр олы-олы исемнәр алды. Татарны суырып сытарга куелган бу аждаһаларны мактап, бер юл да шигырь язмаганмын икән. Мин партияне дә, халыкны да, үземне дә алдамаганмын!

С о р а у  б и р ү ч е. Чыннан да, шигърият гел алда килә. Шагыйрьләр берьюлы, күпләп килде. Тагын бер шундый күтәрелеш, яңарыш шигърияттә булыр дип уйлыйсыңмы?

И л д у с-Р ә ш и т. Хатын-кызлар күпләп килер шигырьгә. Әмма дистәләгән ир-ат шагыйрь бергә килү көтелми. Гомумән, шигъриятнең хәле өметле түгел. Читтәге чишмәләр корыды. Хатын-кыз күңелендә аналардан күчкән моң сакланган әле. Моның үз сере бардыр.

А р т и с т к а «Әнкәм сүзләре» шигырен укый.

Улым!
Синең яшәү — минем яшәвем,
Хаклык белән бул син гел бергә.
Эчкерлелек белми яшәдем
Мин дөньяда гомер-гомергә.

Сиңа икән — сайлап китердем
Хәләлләрдән хәләл булганны.
Йоклаганда ябып йоклаттым
Хисләремнән сырган юрганны.

Җылыларын салып җанымның,
Җылы күлмәк тегеп кигездем,—
Елатырлык юллар чатында
Юлдаш булачагын мин сиздем.

Иркәләсен юлда мин булып
Таңнарымның талгын җилләре.
Гизәм дисең ерак җирләрне —
Күңелемнән китмәдең әле.

Күз нурларым белән җөйләдем
Күлмәгеңнең җыйнак җөйләрен.
Җиремдәге балам турында
Йолдызларга, айга сөйләдем.

Күңелемнән китмәдең әле,
Күзем әле күреп туймаган.
Моңсыз калмассыңмы... моңланам,
Уйсыз калмассыңмы... уйланам,
И балам!

И к е н ч е  а р т и с т к а «Әби» шигырен укый.

Язлар килде. Гөл орлыгы эзлим.
Ярты базар, сатып ал гына.
Чәч тә үстер: җитмеш җиде төрен
Әби тезеп куйган алдына.

Бөртекләрен капшый керфекләрем,
Ә карашым барлый, аралый.
Чәчәкләре җанга якыная,—
Юк, боларны алмый ярамый.

Телсез икән әби. Ымлап сата,
Ымлап кына мактый үз малын.
Күреп алды: аның шул хәленнән
Бер малайның көлеп узганын.

Туктатты да гөл орлыгы бирде:
— Бар, юлыңда бул,— дип ымлады.
Телсез калды малай. Йомарланды.
Гүя кара кайгы йомгагы.

Йомгак сыман тәгәрәде малай —
Бу дөньяның кайсы ягына?
Үзе... чәчәкләрдән кайлардадыр
Аерылып калган җан гына.

Теләкләрен теләп калды әби:
«Гөлләр сыман, балам, өшемә.
Гөл орлыгы тиде өлешеңә —
Гөлләр керсен бүген төшеңә.

Гөлләреңә кунган сандугачлар
Иртән сине сайрап уятсын.
Гомереңә язлар килгән саен,
Гөлгә яшер кошлар оясын.

Сөйләр телең — гөлләр теле булсын,
Гөлләр илендә кал — мин үлгәч.
Минем ничек телсез калганымны
Гөлләр сөйләп бирер, гөлләр чәч...

Соңгы балам соңгы сулышында
«Әнкә-ә-әй!» диеп әйткән мизгелдән
Җырдан гына торган моңлы телем
Гомерлеккә инде өзелгән.

Сезнең белән түгел, мин бит бары
Кара язмыш белән сөйләшмим.
Язлар килә, язлар... Бу көннәрдә
Бөтен дөнья белән сердәш мин.

Балам, балам, дөнья буйлап йөри
Гөлләр башын кисәр хәбәрләр.
Ул-бу булса, гөлләр башы белән
Синең башың бергә тәгәрәр.

Өйнең, илнең изге туфрагына
Гөл орлыгын инде салдыңмы?
Якла балаларын югалтудан
Телсез кала язган халкыңны...»

Гөрли базар. Берәү генә тыныч.
Ымлый гына бары, сөйләми.
Дөньядагы телле телсезләргә
Тылмач була ала бу әби.

С о р а у  б и р ү ч е. Синең остазың кем?

И л д у с-Р ә ш и т. Хәсән Туфан. Мин башка бер генә шагыйрь каршында да баш имәдем. Кемдер: Такташ, Җәлил, Есенин, ди. Мин: Туфан, дим. Харис әйтә: дөньяның иң бөек шагыйре Есенин, ди. Туфан кай җире белән аннан ким? Туфан хәтта бөегрәк тә.

А р т и с т.

Йолдызлардан йолдызларга күчеп,
Кәләшкә дә ингән бер әмер:
«Туфанлы да булгач, шигъриятькә
Мостаен да тудырыйк без хәзер.

Ауган егетләргә алмаш кирәк,
Алдан барыр өчен — байракчы!
Мең ел саклап килгән иманыңны
Юкса мордар тартып алмакчы!»

Империя этләренә бирми
Талатырга шушы иманны,
Шигъриятнең азаматы булып,
Азат яшәттегез Сез аны.

Ә бу илдә һәрбер азаматны
Адым саен коллык сагалый.
Һәм аннан соң... тарих буйлап сана:
Бер шагыйрьгә — йөзләп Шаһгали!

Ә азатлык әсир Туфанны да
Эзләп тапты әллә кайлардан,
Башын алып балта асларыннан,
Итек биреп,
Илгә кайтарган.

А р т и с т к а.
Сулышыгыз белән җылыткансыз
Себерләрдә туңган Туфанны.
Туфан аша — безне. Әллә сезнең
Җаныгызда Кояш булганмы?

Телсез калган безнең сабыйларның
Ачылмадымәле телләре?
Ак атында Казан якларыннан
Хәлләрен бер белеп кил әле!

Кеше җанындагы кояшларны
Төннәр буе эзли бозлы Ай...
Дәшә сыман Туфан:
— Безнең дөнья
Җылындымы әле,
Бер җылыныр әле, и Мостай!

Телгә, денгә кайтам, диючеләр
Илгә таба барыбер юл таба.
Шигъриятнең шәригатен төгәл
Үтәсеннәр — булыш, Мостафа!

А р т и с т.
...Истә аны төнлә каршыларга
Казаннарга килгән чагыгыз.
Уятксансыз:
— Туфаныгыз кайта,
Исән кайта! Каршы алыгыз!

Беркемгә дә түгел, мин үземнең
Татарыма әйтәм бу сүзне.
Ярты халкы телсез,
Ярты халкы
Сукырайганга сүгә ник Сезне?!

Уянган тик җиде-сигез татар,
Уйлангандыр уны-унбише...
Күпме генә сиңа дан җырлама,
Барыбер дә куркак син, кеше! —

Шагыйрьләрне Себерләргә сөреп
Туймаганмы әллә бу Казан?!
Шигъриятнең шәригатен үтәп,
Менә бүген Сезгә хат язам.

А р т и с т.
Безнекеләр сезне гаепли дә,
Сезнекеләр безне гаепли:
Сезнең гамәлләрдә гаеп ни дә,
Безнең гамәлләрдә гаеп ни?

Туганнарча киңәшләшер өчен,
Туфан туган илгә килегез.
Сез элек тә аның түрендәге
Иң кадерле татар идегез...

Туфаннандыр әле, Туфаннандыр...
Күктән җанга инде бер әмер:
Бер-беребезне саклар, яклар өчен,
Алмаз кылыч булыйк без хәзер!

Айдар Фәйзрахманов җырлый.

С о р а у б и р ү ч е. Бүгенге шигърияткә ни җитми?

И л д у с-Р ә ш и т. Моң! Моң җитми шигырьгә! Шигырь ул – җыр. Бөек фикерләр язып була торгандыр, моң булмаса, ул фикер шигырьгә әверелә алмый. Ул бары тик политикага гына әверелә.

С о р а у б и р ү ч е. Өметең, ышанычың кемнәрдә?

И л д у с-Р ә ш и т. Эдуард Мостафин гел читтә. Әрсез түгел. Иҗаты олы. Әле тагын да ачылачак... Нияз Акмал – шәхес, шагыйрь. Тик шигырьдән читләшмәсен иде... Ләис, Ркаил, Газинур, Сүлти, Илсөяр Иксанова. Болар инде олпат шагыйрь булып бара торганнар. Яшьләрдән иҗат батырлыгы көтеп яшим.

С о р а у б и р ү ч е. Бүгенге эшең?

И л д у с-Р ә ш и т. Кулга тотып карарлык шигырь китабым чыгып килә, шул китапка кереш сүзне шагыйрь Равил Фәйзуллин язды.

Равил Фәйзуллин чыгыш ясый.

И л д у с-Р ә ш и т *(«Шигырь китапханәсе»н кулына алып)*. Бу китап – минем бөтен узганыма исәп-хисәп тоту. Бу китап минем йөз суым. Гомеремнең икенче яртысында тагын шундый бер китап иҗат итә алсам, җаным тыныч булыр иде.

Әңгәмә тәмам.

И к е н ч е а л ы п б а р у ч ы. Шагыйрьнең теләге кабул булды. Шушы сөйләшүдән соң ул әле тагын алты ел яшәде, иҗат итте һәм, ниһаять, Рәшит Әхмәтҗанның гасырларда укып ятларлык шигъри китабы чыкты. Шул китапка кереш сүз белән, хатирәләре һәм Рәшит Әхмәтҗанның иҗатына шагыйранә караш белән фатиха биргән язучы Марсель Галиев!

Марсель Галиев чыгыш ясый.

Б е р е н ч е а л ы п б а р у ч ы. Без бүген рәсми тантана өчен дә, шагыйрь Рәшит Әхмәтҗанның олы иҗатына бәя бирергә дә җыелмадык. Без бүген Рәшит Әхмәтҗан шигырьләрен укып, аның шигырьләрен тыңлап уйланырга килдек.

А р т и с т.

### *Туфан тавышы*

Сез иртәгә ирек алырсыз! –
Сөякләрем гүрдә сизенә.
Илбасарның басып эзенә,
Тарих юлларыннан яу чабып,
Ирек яула, кеше, үзеңә...
Сөякләрем шуны сизенә...

Илгә ия булырлык ирләр!
Чичәннәрем, имин булыгыз.
Ураулы шул, бигрәк ураулы
Тарихларда калган юлыбыз.

Арытмыйча атны куыгыз,
Чичәннәрем, кыю булыгыз!
Кол калсагыз, мәңге минем дә
Сөякләрем сызлар гүремдә.

Ө ч е н ч е а р т и с т.
Әллә инде кыр казлары кайта,
Яктылыклар арта бу якта.
Онытмагыз –
Кырказ канатында
Очып киткән сөю елата.

Д ү р т е н ч е а р т и с т.
Оча бөркет, шаша — бу давылда
Һәлак булган аның баласы.
Миңа да бит шул давыллар аша
Диңгезләрне кичеп барасы.

Горур җаннар үлми — һәлак була!
Бөркет мине күзли — мин китәм:
«Бу да, балам кебек, горурлыктан
Һәлак булыр, ахры» ди микән.

Б и ш е н ч е а р т и с т.

***Таш өстендә гөлләр***

Таш өстендә гөлләр... Гөл өстенә
Соңгы йотым суны коясың.
Һәм, актарып ташны, таш астыннан
Тапканым бар елан оясын.

И к е н ч е а р т и с т.
Без башкалар: безнең сөю җирне саклый,
Туган җирне ирләр сөя, ирләр яклый.
Арттан безгә ук атсалар — уктан алда
Күкрәк белән безне сөйгән ярлар каплый.

Ө ч е н ч е а р т и с т.
«Сөяме?» дип сорармын
Суның агышларыннан,
Сөймәсәң — сап-сары шәл
Бәйлә сагышларымнан.

А р т и с т.
Күпме язлар яна йөрәгемдә!
Шул турыда уйлыйм әле менә...
Һәм ышанам, дуслар, җирдән безне
Алып китә алмас үлем генә.

Пәйгамбәр була алмассың,
Исемен генә алып.
Мөхәммәт заманыннан ук
Җисемне сыный халык.

Тугры баласын пәйгамбәр
Итәргә әзер тора.
Ә инде угры баладан
Үзеңә нәрсә сора?

Әгәр дә алданса синнән
Тугрылык көткән халык,
Дуңгыз көтүе көтәрсең,
Халкың хәленә калып!

Д ү р т е н ч е а р т и с т.
Денен сатты. Йөзендәге карасын
Инде хәзер, әйдә, юып карасын!
Күпме юса да карасын, юк, бетмәс,
Юар өчен Иделнең суы җитмәс.

А р т и с т.
Берсе озын аның, берсе кыска.
Берсе — шамбы икән, берсе кысла.
Йотса йотсын шамбы, җибәр, кысла,
Йөрәк бик авырта, болай кысма;

Минем сул аякның чәнчекәе
Җитмәс идемени син кыслага!
Үтерергә! диеп, үз әмерен
Биргән мәллә Озын бу Кыскага?
Үлемгә каршы нәфрәт кирәкме?
Йә мәхәббәтме — сора татардан.
Җирдә исән-сау калыр өчен, ул
Һәр яңа көнен көрәшеп алган.

Гасырлар узган. Яңасы килә...
Татарларымны кисәтәм алдан:
Үлемгә нәфрәт чиксез булса да,
Өчтән берегез тамырсыз калган.

И к е н ч е  а л ы п  б а р у ч ы. Күпме шагыйрь һәм әдип олуг исемнәр, зур бүләкләр алалмыйча китте бу фани дөньядан! Лаек килеш — алмыйча киттеләр. Үпкәләгән сыман, хәтта рәнҗегәндәй дөньядан күчте алар. Күпме лаек исәннәр хәзер дә шул халәттә, үпкәләгән шикелле, бүләксез, орденсыз иҗат итә.

Рәшит Әхмәтҗан сүзләренә язылган «Сандугач керде күңелгә» исемле җыр яңгырый (Инсаф Хәбибуллин көе).

Б е р е н ч е  а л ы п  б а р у ч ы. Нишләп шулай була икән ул дөнья? Таланты булса, тормыш җаен белми, бүләкләр артыннан чапмый, «җәмгыятьнең каймагы» булганнар йортыннан фатир дауламый, эше аз, акчасы күп булган җылы урын эзләми — ул иҗат итә, нәфис сәнгать яралта, гүзәл шигърият бинасын кора һәм, шул бинаны корганда, торыр өчен үзенә дә иркен бина төзүне онытып җибәрә.

И к е н ч е  а л ы п  б а р у ч ы.
Елгаларның яры икәү була.
Татар өчен, ахры, бер генә:
Ирен чылатасы суларыбыз
Без килгәнче кибеп өлгерә.

Хәнҗәр ялтырады! Кемдә? Нигә?
Кемдер йолка — җаным шартла.
Ил күзенә ничек тыныч кара,
Хәнҗәрлеләр баскач атыңа.

Күңел — җыр китабы, һәр битендә
Ярылып ята изге уй гына.
Шуны укыр өчен, кемдер монда
Хәнҗәр тыгып килгән куйнына.

А р т и с т.
Йөрәк каны ничә тамчы икән? —
Кем булса да аны беләдер,
Һәм халкыңның азатлыгын яклап
Үләргә дә вакыт кемгәдер.

Тик арттагы хәнҗәрледән түгел,
Юк, тиң түгел безгә мескеннәр.
Меңнәр, меңнәр!
Уяу булыгыз сез,
Кансыз гына үтсен бу көннәр.

Кансыз гына үтсен кара төннәр,
Йөрәкләрне көндез канаттык.
Бер тамчы да канга буялмасын,—
Ак күлмәктән килә Азатлык!

Б е р е н ч е  а л ы п  б а р у ч ы. Бар коеп куйган шагыйрьләр. Алар химаягә, игътибарга мохтаҗ. Андыйларның тормыш-көнкүреш эшләрен кемдер кайгыртырга тиеш. Кемдер... Бай химаячеме, хөкүмәтме, халыкмы? Нишләрсең, әгәр бай кеше сәнгатьтән хәбәрсез булса, хөкүмәттә китап укымый торган, сәнгать аңламаган кешеләр утырса, халкың үзе ярдәмгә мохтаҗ булса?

И к е н ч е  а л ы п  б а р у ч ы. Без әнә шул, үз мәнфәгатьләрен алга сөрә алмаган чын талантларга өстәнрәк багабыз, вакыт-вакыт, ихтыяри-ихтыярсыз аларны рәнҗеткәлибез дә. Без өсбашы өф-өф ителгән, шома битле, сакал-мыек үстермәгән, гел ак якага муенчак тагып йөрүче, кеше алдында хәмер эчмәгән, төзйөрешле һәм тәти сүзләр генә сөйләүчеләрне күбрәк үстерәбез.

Б е р е н ч е  а л ы п  б а р у ч ы. Дөрес, тәтиләрне үстерергә кирәк, ләкин ярдәмгә-химаягә мохтаҗ талантларны да читкә какмаска иде... Олы исемнәрне, рәсми игътибарны киемгә карап кына түгел, иҗатка, бары тик иҗатка карап кына өләшер вакытлар да җитәр, иншаллаһ.

И к е н ч е  а л ы п  б а р у ч ы. Бирелде бит Тукай бүләге Семен Липкинга, Равил Шәрәфигә, Әлфия Авзаловага, Мөдәррис Әгъләмовка, Зөлфәткә, Роберт Әхмәтҗанга, бик соңарып булса да бирелде. Егерме елга гына соңара шул безнең татар, егерме ел элек алар Тукайга лаек түгел идемени?

А р т и с т.

***Әлфиягә мәдхия***

Бармы соң безнең татарның
Хәсрәтсез торган чагы?
Бу юлы коткарды аны
Бары Актаныш ягы.

Күк капусын гомергә бер
Безгә дә Тәңре ачты, —
Иңдерде татар иленә
Иң моңлы сандугачны.

Беләбез хәзер дөньяның
Моңнары кемдә генә.
Сыя да бетә икән ул
Сандугач йөрәгенә.

Сүнгән күңелгә сөюне
Шул гына сала икән,—
Халыкны бер сандугач та
Коткара ала икән.

Әлбәттә, Сез — Әлфиябез —
Сандугач дигәнебез,
Мең яшә, безнең бәхеткә
Тәңредән иңгәнебез.

Сайра! Җиде... юк, унҗиде
Миллион татар менә,
Билләһи, табынып яши
Сандугач йөрәгенә.

Б е р е н ч е  а л ы п  б а р у ч ы. Иҗат, сәнгать, әдәбият ул — могҗизалар иле, серләр яшерелгән сандык, маҗаралар аланы. Сәнгатьченең иҗат остаханәсе сихрилек, серлелек белән тулган була. Анна Ахматовадан сораганнар:

— Твардовскийның иҗатына мөнәсәбәтегез ничек? — дигәннәр.

Шагыйрә әйткән:

— Твардовский, әлбәттә, яхшы шагыйрь, ләкин анда сер юк! — дигән.

Анна Ахматованың бу сүзе әдәбият-сәнгать өлкәсендә эшләүчеләргә шәмаил урынына язып, диварга эләрдәй мәгънәгә ия.

И к е н ч е  а л ы п  б а р у ч ы. Без дә бит әдәбияттан, сәнгатьтән могҗиза, сер көтәбез түгелме? Көткән нәрсәбезне китапта, сәхнәдә тапсак, без бәхетле. Тапмасак, әсәрнең кыйммәте бетә.

А р т и с т.

***Эзләдем***

Син кем үзең,
Су кызымы, бүтәнме?
Алтын алкаң суга төшеп киткәнме?

Бер күмелә, бер күренә йөзәсең,—
Батар идең — ай саклыйдыр, күрәсең.

Бер күмелә, бер күренә ике ай,
Кичә күлдә бер иде бит, бер бугай?

Ак тәнеңне яшерергә кирәкме —
Җилләр үрә ай нурыннан ефәкне.

Унөч яшьлек малай — йомдым күземне...
Ник дулкыннар күрсәтмәде йөзеңне?..
Син югалдың.
И, мәрҗәннәр... йөз меңләп
Чәч бөртегең саен калды җемелдәп.

Иртән еладым сагынып, түзмәдем,
Алтын алкаңны сулардан эзләдем.

А р т и с т.

***Алма белән кояш арасында***

Ямьсезләнеп беттек бу дөньяда,
Матурлыкны күбрәк күргәнгә.
Якты көннәр безнең белән бара
Юл борылган чакта төннәргә.

Дөнья кайчак мускулларны тарта,
Иреннәрне тешләп түзәсең.
Чыда, кеше! Дөнья тарала ич,
Мускулларны дөнья өзмәсен.

Сагалый да язмыш кайчагында
Юлчыларның ялгыз килгәнен —
Аннан гүя уч төбенә кысып
Сынап карый аның йөрәген:

Син, янәсе, чынлап кеше микән?
Ничек тудың, кайда нәселең?
Үлгәндә дә аягүрә басып
Сөйли кеше аңа үз хәлен:
— Алма белән кояш арасында
Бозлар эреп, гел таулар янды.
Сөю белән нәфрәт арасында
Аяк канап, эзләрем калды.

Үлемнәрдән безне яшәү генә
Коткарганын күптән беләмен.
Телисеңме — тамырларда төшеп,
Яфракларда өскә менәмен.

Башыбызны дошман яраласа —
Бүрекләрне кидек батырып.
Сынган беләк җиң эчендә булса —
Җиңнән чыккан иде йодырык.

Без кешелек яклы кешеләрбез,
Җиңүләргә барган нәселдән.
Әй туган җир, мәңге бәхет биреп,
Кайгыларны безнең яшергән.

Алма белән кояш арасында
Дөрләргә дә безгә дөрләргә.
Гомер озын...
Ямьсезләндек бары
Матурлыкны күбрәк күргәнгә.

«Акчарлаклар» җыры башкарыла (Хөснул Вәлиуллин көе).

Б е р е н ч е  а л ы п  б а р у ч ы. Татар шигъриятендә ачылмаган серләр күп. Ул серләрне ачып, бер куаначак, шул серне халыкка җиткереп, ике кат бәхетле буласы тәнкыйтьчеләрне көтә «Шигърият» дигән серләр сандыгы.

И к е н ч е  а л ы п  б а р у ч ы. Серлелек, тел төбе, киная, ишарә, төрттереп, читләтеп әйтү, могҗизалы маҗаралар татар әдәбиятында күп исемнәрне мәңгеләштерде: Кол Гали, Мөхәммәдьяр, Мәүла Колый, Кандалый, Утыз-Имәни, Акмулла, Дәрдемәнд, Рәми, Такташ, Туфан...

Б е р е н ч е  а л ы п  б а р у ч ы. Алардан соң әдәбиятта сугыш темасы тәхет яулады. Хәрби темадан соң шигърият дигән дәрьяда тынлык, салмаклык, җилсезлек чоры башланды. Шигырь көймәсенең җилкәне шәлперәйде. Көймә, уңай җил көтеп, чарасыз гына сәясәт дулкыннары каккан якка әкрен генә тирбәлә калды.

И к е н ч е  а л ы п  б а р у ч ы. Әнә шундый чарасыз калган тынлыкта Роберт Әхмәтҗан, җилләп-давыллап, җилкәннәрне өреп кабартты, берүзе галәм бушлыгын тутырды.

Б е р е н ч е  а л ы п  б а р у ч ы. Роберттан соң тагын тынлык, һәм татар шигыренә күпләп яшь шагыйрьләр ургып, бәреп керде. Рәшит Әхмәтҗан, Равил Фәйзуллин, Рәдиф Гаташ, Рөстәм

Мингалим, Гәрәй Рәхим, Ренат Харис, Зөлфәт, Мөдәррис, Разил Вәли, Лена Шагыйрьҗан, Зиннурлар, Фәннурлар – барысы да серле шагыйрьләр.

Икенче алып баручы. Коммунистик хакимият чорында, ачык фикер әйтергә мөмкин булмаган чакта, бу шагыйрьләр серле кинаяләр, ишарәләр артына олуг фикер яшерәләр иде. Зиһниятле укучыга ул – ачыш, хәбәрсезгә ул гап-гади сүз тезмәләре иде. Астарлы сүз, яшерен фикер төрелгән шигырьләр бөек бер шигърият хасил итте.

Артист.
Давыл вәгъдә иткән дулкыннарда
Ниләр китә, ниләр киләләр?
Дулкыннарның серен беләләр тик
Алсу җилкән җәйгән көймәләр.

Дулкыннарның сере – көймәләрдә,
Упкыннарның сере кемнәрдә?
Йә, кемнәрдә?
Бездә!
Йөзебездән
Канны сөртеп, безгә көләргә...

Безгә елау – соңгы сәгать булыр.
Яшьсез генә күзләр канасын.
Елый-елый башны саклыйсым юк,
Гафу итәр әнкәй баласын.

Арткы микрофонда Илдус Әхмәтҗанов сөйли.

Апрель иде. Иделдәге бозлар
Куйган иде инде кузгалып.
Ильич туган ай ич, шигырь яздым,
Исем уеп куйдым: «Без – халык!»

Шигыремне ошатмады гәҗит,
Ярдәм итте Зөлфәт, төзәтте.
Халкыбызны Ильич исеме белән,
Йә, кем оста бәйләр бу хәтле?!

(Акбаш белән юдык!) Шигыремне
Бик яратты гәҗит, мактады.
Дага чыңын алдык. Йөккә калды
Татарларның акбүз атлары.

Чая, зирәк татар егетләре
Ильич гамәлләрен якларга,
Кылыч тотып, Корчагиннар белән
Ыргылмадымыни атларда?

Ыргылганнар, алдан ыргылганнар –
Тугырылар, ныклар, кырыслар.
Йөрәкләрдә – давыл, кулларында
Кызыл байрак белән кылычлар.

Янгын булып коллык дөньясына
Кабындылар, дөрләп яндылар,
Рухи яктан барысы да Данко,
Тик татарлар сыман ярлылар.

Үзләренә ирек даулаганда,
Диварларга терәп аттылар.
Ил дип, Җир дип, үлемнәргә очып
Китте шулай акбүз атлылар.

Кайчагында дарга менде алар,
Һәйкәл булып басып калдылар.
Кырык үлем аша, нәкъ татарча,
Үзләренә коллык алдылар.

Чын күңелдән ышанганнар алар
Азатлыкның бөек көченә.
Халык – зур, дип Тукай әйткән дә бит,
Ә татарлар һаман «кечкенә».

Һәйкәлләре тора... аерган да
Халык белән тәмуг арасын.
Тия күрмә, кеше, син аларга, –
Алар да бит халык баласы.

...Зөлфәт белән бергә шигырь яздык
Һәм бастырдык минем исемнән.
Онытканбыз: кылычлылар узгач,
Ярты илнең башы киселгән.

Зөлфәт чыгыш ясый.

А р т и с т

### *Тайгада*

Тайга кояш көтә...
Моңлы итеп
Үксеп-үксеп кырказ кычкыра.
Кешеләрне гүя бу якларга –
Йөрәгенә таба чакыра.

Әй, кыр казы, кайдан килдең монда,
Безнең өчен – син бит Магеллан?
Димәк, сиңа безгә караганда
Җил-давыллар күбрәк кагылган.

Күрәбез ич әнә – сазлыкларда
Табигатьнең җаны илерә.
Тайга кырыс –
Безне
Кукрәгендә
Каторжаннар йөри дип белә.

...Сөякләрне күрәм, сөякләрне,
Әйе, әйе, таныйм, бу – алар.
Күгәргәннәр, һаман сөякләрне
Җибәрмичә ята богаулар.

Озатканнар,
Алар ята монда
Аналардан туган киемдә.
Үтерүче – үзенә кабер тапмый
Илергәндер әле илендә.

Һәлак булганнарның һәйкәленә
Сәлам булсын кырказ тавышы.
Шул тавыштан туды йөрәкләрнең
Киләчәккә илткән маршы.

Декабристлар рухы чорлар аша
Бездә калган икән яшәргә.
Дөнья мәңге безнең мускулларда
Таралмыйча тора, яшәрә.

Ә хыяллар Себер киңлегендә
Киек казлар юлы шикелле.
Замананы монда, үз янына,
Безнең кайнар яшьлек китерде.

Б е р е н ч е а л ы п б а р у ч ы. Менә шушы бөек калкыныш чорында куәтле төркемнең башында Рәшит Әхмәтҗан тора. Ул – аларның барыннан да алда беренче шигырь китабын бастырып чыгарган шагыйрь. Фикер шигыре белән хис шигыре арасына беренче күперне дә ул – Рәшит Әхмәтҗан салды.

### *Җир кызлары, җир уллары*[1]

Сәфәр итеп йөргән мин бер юлчы
Олыязга килдем җыр алып.
Урамыннан урамына күчеп,
Язгы җилләр йөри шаярып.

Беркайчан, җир, ятим буласың юк,
Ана хакын хаклый улларың.
Саклый сине, яклый җаны белән
Бер түгел, мең Галимҗаннарың.

Җир кызлары монда, җир уллары,
Иманнары – шул җир аларның.
Йөзләрендә чагыла куанычы
Икмәк тотып торган баланың.

Олыязда исә яз җилләре,
Чәчәкләнер тагын бу гомер;
Тиздән тургай җырлап күккә менәр,
Арышларга төшеп күмелер.

Күмелер дә тагын игенченең
Җырын алып менәр югары.
Ул җырлардан гүзәлрәк җырлар
Җирдә ишеткәнем юк әле.

[1] Мамадыш районы «Чулпан» колхозы рәисе Галимҗан Җиһаншинга багышланган.

А р т и с т.
Күктән таш яуса да, хәбәреңне
Шул ташларның җибәр берсендә.
Тау хәтле таш булсын,
Ул таштан мин
Йөзек кашы ясар идем дә,

Туй бүләге итеп саклар илем
Вәгъдәм итеп сиңа бирергә...
Мөмкиндер ич инде кояш белән
Чыгарга да миңа килергә.

И к е н ч е а л ы п б а р у ч ы. Рәшитнең хиссият, моң, сагыш, рәнҗү белән тулган бәгырендә яралган шигъри җәүһәрләр иң башта йөрәккә, хискә, соңра зиһенгә, фикергә бәрә иде. Аның шигыре — музыка. Музыка зиһен, акыл падишасы түгел, музыка — хиссият падишасы.

«Кышкы кич»нең көе башкарыла (Ф. Мортазин көе).

Ай, таралып тамчыларга,
Яуды микән карлар булып,
Яши мәллә берәр гашыйк
Энҗе чәчеп, энҗе урып?

Бар уңышлар сибелгәнме
Сиңа барган юлларыма?
Елмаеп килеп керәсең
Минем матур уйларыма.

Карлар ява... Энҗеләрне
Күрәсеңме, и сөйгән яр:
Һәрбер энҗе бөртегендә
«Сөям» дигән сүзләрем бар.

Кавышырбыз, пар булырбыз,
Туйлар булыр, диден, көзгә.
Көзләр килде, карлар яуды...
Кавышырга вакыт безгә,
Вакыт безгә!..

А р т и с т.
Моң ага җир күкрәгеннән,
Кем җырлап елый тагы?
Сөю, синең ятимәңме,
Ятимеңме юлдагы?

Әллә мәңге кол булмаслык
Хөрлек алалмаганга —
Сөйлиме качкын бер егет
Кайгысын карурманга?

Аугандыр, бәлки, бер батыр
Кан-көрәш юлларында,—
Телидер башын салырга
Сөйгәне кулларына...

А р т и с т к а.
Җыр килә тарих юлыннан,
Моң килә ага-ага:
«Үлсәм иде бер ир бала
Туган көнне дөньяга».

Кыз бала елый икән ич,
Кыз бала җырлый икән...
Үзе күптән еракларга —
Моңсу офыкка киткән.

Еракка, юлларга карыйм:
Ямь-яшел хәтфә үлән.
Үләннәр аша сөйләш бер
Тарихта калган белән.

А р т и с т.
Аларның җырын тыңласаң,
Гомереӊ үтми торыр.
Ул җырны кайда ишетсәң,
Туган ил шунда булыр.

Диңгездән тирән ул җырлар,
Җанлырак, гомерлерәк.
Диңгезне сыйдырса да шул,
Диңгезгә бата йөрәк.

Хәтердә шундый сеңелләр,
Җанда яши электән –
Ярлары үлсә яуларда,
Алар үбеп терелткән.

Терелгән минем нәселем,
Сау, тере килеш калган.
Без янып яшәгән саен,
Утларда дөрли ялган.

«Үлсәм иде бер кыз бала
Туган көнне дөньяга» –
Дөньяга безнең күңелдән
Әнә шундый моң ага.

А р т и с т.
Төшләремә керде соры чүлләр...
Чәчәкләргә иртән су сибәм.
Миннән сулар өмет итми генә
Юл читендә шаулый бер имән.

Имән сөйли кебек: тамчыларың
Кирәк түгел миңа, и бала!
Тол хатыннар яше имәне мин,
Шуннан менә үзең чамала.

Ирләрен дә, газиз улларын да
Озатышкан идем яуларга.
Ничектер мин җайсызрак, ахры,
Басып калдым ике арага...

Ир – имән, дип килде алар миңа,
Еладылар сыенып куенга.
Исәпләре – эзләп, җир читенә
Яланаяк җәяү барырга.

...Миннән үлем сорап килмәделәр,
Рәнҗетмәде алай берсе дә.
Яшен килеп кочагыма керсә –
Син, егеткәй, бер дә көрсенмә.
Сөю уты, бәлки... эзлидер.
Өзелсә дә кеше үзәкләре,
Өметләрне сөю өзмидер.

Тол хатыннар яше имәне мин,
Кочагында яшим җилләрнең;
Яшеннәргә яфрак сибәрмен дә,–
Мин үлемне тагын җиңәрмен.

«Күрмәдең» җыры (Ганс Сәйфуллин көе) башкарыла.

А р т и с т.
Мондый язлар барын белми идем,–
Ярый әле сине күргәнмен...
Бөтен яме син булгансың икән
Судай агып киткән көннәрнең.

Мондый болын барын белми идем,–
Гомерләре үткән кемнәрнең?
Исемеңне синең телгә алгач,
Күз яшьләрен күрдем гөлләрнең.

Мондый сагыш барын белми идем,–
Кылганнарын тарый үрләрнең...
Башка чара барын белмәдем мин,
Шул үрләргә менеп дөрләдем.

Мондый гомер барын белми идем,–
Мәхәббәттән чак-чак үлмәдем...
Гашыйк булып озак яшәдем мин,
Тик син генә мине күрмәдең.

Артист.
Офыклар белән җанланып,
Шатланып сине көтәм;
Күренден миңа ерактан:
Әнә син нинди икән!

Кояшлы таулар яшәрсен,
Ләйсәннәр сибәләсен...
Яз холкын алып үзеңә,
Яшәргә өйрәнәсең.

Матурлыгың әйтә миңа:
Янарга, егет, өйрән.

Елмаеп-көлеп котлыйсың
Бүгенге көннәр белән.

Бүгенге ямьнәр кебек син
Чибәрләнәсең көлеп.
Узма син көннәр шикелле,
Тукта син миңа килеп.

Уйна, көл туган җиремдә,
Гашыйк ит бөтенесен.
Юлдаш ит изге җаннарның
Иң озын гомерлесен.

Беренче алып баручы. Рәшит Әхмәтҗан — серле шагыйрь. Ошбу серне бәгыре тибрәнүгә сәләтле кеше генә тоя ала, ача ала. Фикер аша ачылмый Рәшит шигыре эчендәге сер, хис, күңел күзе белән генә ачыла ул сер. Шул түгелме нәфисәи сәнгать? Аның шигыре нечкә кылларга тияр-тимәс кагыла, кагыла да җылата, җылата да уйлата. Шулай итеп, Рәшит хис аша укучы күңеленә олы фикер сала. Чөнки Рәшитнең бәгырендә ялган хис (ватан, милләт, йола, әче тәкъдир) укучы күңелендәге авываздаш хисне уята. Рәшитнең күңеле сихри хис нурланышы бирә башлый, бу нурланышны кабул итәрдәй икенче бер калеб — икенче бер бәгырь булырга тиеш, ул бәгырь, ул калеб укучыныкы, шигырь сөюченеке. Мөкәммәл бер аңлашу, ике яклы элемтә-бәйләнеш барлыкка килә. Син күңелең белән шагыйрьнең ни әйтергә җыенганын сизә башлыйсың, аны аңлый башлыйсың. Бу хисләр ватанпәрвәрлек, милли каһарманлык хисләре икән. Кече күңелле, олы җанлы «Рәшит Әхмәтҗан шигыре» дигән серле дөнья ачыла. Мондый шигырьләр шагыйрьнең вафатыннан соң аеруча хисле, моңлы вә мәгънәле яңгырый.

«Көләргәме, еларгамы, әллә күзне мәңгелеккә йомаргамы?» дип язды ул вафаты алдыннан.

Артист.
Без мәңгегә, без мәңгегә монда.
Эх, бу җирне күпме таптады
Безнең йөрәк бәйрәмнәребезнең
Кыңгыраулар таккан атлары!

Чаба атлар, томырылып чаба,
Кыңгыраулар чыңлый юлларда.
Ил шатлыгы тынмас булгангамы,
Ятлар чыга куллар болгарга.

Чәчте-урды халкым,
Горур булды.
Үз язмышын ятка бирмәде!
Кешеләрнең бүген туган җирдән
Үлемсезлек алган көннәре.

Алар күргән авыр кайгыларны
Онытырмын димә тиз генә.
...Килгән дошман халкым сөягеннән
Һәйкәл куяр өчен үзенә.

Мин туганмын җиргә шул елларда,
Озак яшәремне ил белгән.
Мин туганмын,
Илем дошманнары
Нәкъ мин туган җирдә күмелгән.
Рәхмәт, илем,
Гомер биргәнсең дә,
Йөрәк янган сүнми-югалмый.
Туган җирдә дошман каберләре...
Каберләрдән ирләр үч алмый.
Шундыйларны,
Шундый кешеләрне
Дошман яуда җиңаламыни!
Шундый кешеләрнең нәфрәте —
Аны ерак җибәрәмени!

Без мәңгегә, без мәңгегә монда.
Эх, бу җирне күпме таптады
Безнең йөрәк бәйрәмнәребезнең
Кыңгыраулар таккан атлары!

И к е н ч е а л ы п б а р у ч ы. Рәшит гомере буе олуг бәйрәм көтеп яшәде, менә шушы иң беренче язган шигыреннән алып вафатына кадәр бәйрәм көтте. Кыңгыраулы атларда бәйрәмне айкап йөрде ул шигырьләрендә. Ул күңеле, көрәше, хыялы белән халкына ничәмә-ничә тапкыр бәйрәмнәр яулады, ирек алып килде. Рәшитнең иҗаты акчарлак кеби парлак, аның акчарлагы болытларга, күкләргә, биеклеккә хуҗа булды.

А р т и с т.

***Сугыштан кайталмаган егет сүзләре***

Иелеп-иелеп җиргә ак каеннар,
Ак розалар сорый шул хакта:
Ничек соң мин яшь шаһзадә булып
Килалмадым сиңа ак атта?
Шундый вәгъдәләрем бар иде бит,
Һәм барыр да идем шикелле.
Ләкин атым үсмер чакларымда
Томырылып утка сикерде.

Мин дә яндым көрәш кырларында
Шул ук атта, шул ук ялкында.
Кешнәүләре атның һаман әле
Ишетелә таулар артында.

Кайтавазлар белән кайтып булмый,
Сез калдыгыз, ярым... Без киттек.
Сугышларда янган ак атларның
Җайдаклары, ул чак, без идек.

Ак бәхетең булып күренәдер
Төшләреңә кереп ак атым.
Бәхетләме соң син, бәхетсезме? —
Мин тик сине генә яраттым.

Сөюләрең белән терелт мине,
Уналты яшь миңа... таң ата...
Кайтасы бар сиңа таң алдыннан
Яшь шаһзадә булып ак атта!

Б а й б у л а т. Кандыз — шагыйрь абыйның туган авылы.

***Үпкәләдем сандугачка***

Кызлары йокламаган, ди.
Кызлары йокламаган:
Сандугач сайрап чакыра
Кандыз ягына табан.

Гармун уйнап биш әйләндем
Кандызның урамнарын.
Егет килгәч, йөгереп чыкмый
Йоклаган сөйгән ярым.

Сөю утларында яндым,
Янмадым, бәгърем, көйдем.
Ачуланмасаң, үзеңне
Үбеп уятыр идем.

Гармун телләре ни сөйли,
Ни сөйли — шуны ишет.
Ишетмәсәң, беләм ничек
Ачыла сезнең ишек.

Ишегегез ачылмаса —
Өегез кочагымда.
Төн буена кочагымда
Йокларсың шул чагында...

Үпкәләдем сандугачка.
Үпкәләдем кызларга.
Гармун уйнап йөрим хәзер
Күктәге йолдызларга.

А р т и с т.

Бөркетләрдән югарырак очкан чагым!
Канатыма бәреләләр офыкларым.

— Якын килмә,— диде миңа язгы яшен,
Яшеннәргә кагылмагач, нигә яшим!

Бара-бара, яшь йөрәгем утка тиде,—
Мине каршыларга сөю килгән иде.

Йөрәгеңдә сөю булгач — күкрәп яшә.
Зурлап сиңа җир эндәшә, күк эндәшә.

Яшәүләргә яшь йөрәгем — тере тамыр,
Димәк, җиргә — күгем яфрак булып калыр.

Күктә-җирдә сезгә сөю калыр миннән,
Мин бит инде шуның өчен җиргә килгән.

### Юк, озатмыйм

Бер мәхәббәт табалмадың, егет,
Ялгыз иреннәрне мең үбеп.
Хәмер эчтең, –
Шуңа бүген җаның
Ят кулына калган җир кебек.

Нишләттең син, егет, көрәшләрдә
Байрак булып йөрер чагыңны?!
Илнең изгелеген таптаганда,
Арык гәүдәң күзгә чалынды.

Илнең изгелеге кайларда да
Су тигерер килеп ирнеңә.
Үзең сизәсеңме? – Йөрәгеңнән
Бөтен нәрсә бүген чигенә.

Сизәсеңме, чая яшьлек китә,
Яши алмый синдә коллыкта.
Кол булмыйча калган һәр тере җан
Иртәгә үк сине оныта.

Юк, озатмыйм сине.
Дулап-елап
Озатсыннар җилләр, яңгырлар.
Сагынып җырласаң да яшьлегеңне, –
Матәм маршы булып яңгырар.

Б е р е н ч е  а л ы п  б а р у ч ы. Рәшит гомере буе татар халкының кара тәкъдирен җиңеләйтергә тырышты. Ул һәр шигырендә, һәр гамәлендә татар милләте турында уйланды. Вафатына бер ел кала, 1994 елның 8 май көнендә, без аның белән салмак кына сөйләшеп утырдык.

И л д у с-Р ә ш и т. Әбрар абый олы галим, бәхәс юк... Ләкин ул, «татар»ны «болгар» белән алыштырырга йөреп, татар халкы өчен бөтен майтарганын харап итәр төсле. «Болгар» дип яздырганнан гына татарның кара тәкъдиреннән качып булмый. Безне бит татар булганыбыз өчен кыйнамыйлар, ә урыс булмаганыбыз өчен кыйныйлар.

С о р а у  б и р ү ч е. Рәшит дус, керәшен аерым милләтме, юкмы?

И л д у с-Р ә ш и т. Милләт булыр өчен бик күп нәрсә кирәк! Бай тарих, әдәбият, бөек шәхесләр. Дин милләт билгесе түгел. Бар христиан грузиннар, бар мөселман грузиннар, ләкин алар грузин милләтен тәшкил итә. Японнарда бик күп мөселманнар бар, христианнар бар, буддачылар бар, ләкин аларның япон дигән милләте нык, олы һәм какшамас!

С о р а у  б и р ү ч е. Мишәрләр дә, Себер татарлары да, керәшеннәр дә олы татар милләтен йолыккалап, ваклап бетермәсме?

И л д у с-Р ә ш и т. Алай булмас дип уйлыйм мин. «Бүлгәлә дә ашап бетер» сәясәтенең астыртын эше бу. Алар бер акылга килер. Аерылганны аю ашар, бүленгәнне бүре буар. Бар олы бер татар милләте. Бар милләт, бар халык, бар халыкча, бар бер халыкның берән-сәрән калган кешеләре. Шул милләт эчендә бар керәшен халкы, мишәр халкы, Себер халкы, башкорт халкы, кырым-татар халкы. Шулар «аерым милләт булабыз» дип бүленеп чыксалар, алар милләт була алмый, алар бүленеп чыкса, татар халкы милләт булудан туктый, халыкка әверелә, тегеләре халык та була алмый, чөнки халык булыр өчен дә тарихи запас кирәк. Алар халыкчага әвереләчәк, народностька, чукча – халыкча, мари – халыкча, башка Себер халыклары да милләт тә, халык та түгел, бары тик халыкча гына. Халыкчаларның киләчәге юк. Без, халыкларга, халыкчаларга бүленмичә, бергә, элеккегедән дә тыгыз булып, бөек татар милләте булып калырга тиешбез! Без тарих тарафыннан бергә мәңгегә кушылган, әллә нинди провокаторлар гына безне аера алмас! Бер-беребезне саклар, яклар өчен, алмаз кылыч булыйк без хәзер!

А р т и с т.
Ирек мәйданында җыйдык җыен:
Таралгансың, татар! Җыел, җыел!
Искә төшер: ничә йөз ел тула
Әсирлеккә төшкәнеңә быел?

Дисбе төймәләрен тарта-тарта,
Ил картлары саный, саннар арта.
Кем ул анда соңгы көнебезне
Көтеп тора, качып безнең артта?

Бер күзендә – шовинисттан курку,
Бер күзендә – дөрләп китәр дары!
Таныйсыздыр... Дәррәү җыелганнар
Мие каткан татар маңкортлары.

Кычкыралар:
– Болай тик ятканчы,
Бил бөгәргә кирәк, бил бөгәргә!
– Билегезне гомер буйларына
Бөктегез соң әле сез кемнәргә?!

Берегезнең бөкресе чыккан,
Донбасс шахтасында күмер казып;
Берегезнең ике күзе беткән,
Үз халкына каршы китап язып...

...Каргыш ява.
Хәлсезләнгән саен,
Кодрәтебез күчә башкаларга.
Татар маңкортлары – башкалардан
Алданрак килгән башкалага.

Бичаралар! Үз денеңнән шулай
Каның, җаның белән ничек бүлен?
Соңгы көрәшкә чык, халкым, бүген –
Йә азатлык безгә, яки үлем!

И к е н ч е  а л ы п  б а р у ч ы. Әдәбиятта бар буш өндәмәләр. Ялган шигарьләр. Бар төче гыйбарәләр. Әсәрендә язганның киресен кылучылар да җитәрлек. Бар исеме белән, җисеме, язганы белән гамәле туры килгән олуг әдипләр, шагыйрьләр, чын көрәшчеләр дә. Аллага шөкер!

Б е р е н ч е  а л ы п  б а р у ч ы. Татар шигърияте көрәшче, каһарман шагыйрьләр иҗатыннан тәшкил. Рәшит Әхмәтҗан шигырендә генә дошманына каршы нәгърә орып, юрган астына посып, башкалар көрәшкәнне тын гына күзәтеп ятмады. Чынлыкта да, тормышында да каһарманлык үрнәге булып яшәде. Аның «Ачлык мәйданы» исемле китабы шул каһарманлыкның һәм башка каһарманнарның да йөрәк тибеше булып яңгырады. Фашист төрмәләрен ярып чыккан, ГУЛАГларны җиңеп кайткан шагыйрьләрнең тугры варислары әле үлмәгән.

А р т и с т.
И таралган татарлар,
Илебез эзли сезне.
Кошка әйләндегезме,
Ташка әйләндегезме?

Татарчалап дәшкәнне
Барчагыз да аңлармы?
Җаныгызда кан бармы?
Каныгызда җан бармы?

Канлы эзләр сөйләде:
Табаныгыз канаган.
Канлы эзләр калдырып
Кайтырсызмы яңадан?

Илне уйлап елаудан
Күзләрегез керфексез...
Җир читенә киткәнсез,
Чукынудан өркеп сез.

«Оҗмах булыр» Туган нигез.
Ни эзлисез шул гомер,
Анда төпсез коедан?
Ниләр сезне җибәрми?
Җимерегез, ватыгыз,
Туган илгә кайтыгыз!
Хәтта бүреләрне дә
Берни тоталмый бәйләп;
Әгәр капса капкынга,
Аягын өзә чәйнәп...

А р т и с т.
Үлем белән яшәү арасы бар,
Барасы бар әле, барасы бар,
Янасы бар әле, янасы бар,
Шигырьләрнең меңләп яңасы бар,
Берсе белән гүрне ябасы бар.

Тик соңрак.
Мин көрәшәм яклап
Теге чакта миңа җан өргәнне:
Ватам читлек булган тимерләрне,
Җырлыйм нәфрәт тимер кимергәнне,
Яза йөрәк... илем илергәнне.

И к е н ч е  а р т и с т.
Җирдән киткән изге җаннар – оҗмахта ла,
Җирдә калган изге җаннар – тәмугта.
Тәмуглардан кемнәр тартып алыр сезне,
Сез нишләрсез икән, дуслар, без юкта?

А р т и с т.
Бар гөлләргә гомер биреп, әллә кайчан
Әйлән-бәйлән уйный-уйный яуды ләйсән.
Җәйләр килде... Сине эзләп йөри-йөри,
Гаҗәпләнмә, диванага мин әйләнсәм.

Җирдән эзлим, күктән эзлим, күптән эзлим,
Шуны белеп, әйлән-бәйлән уйный гөлләр.
Көндезләрен ярый ла ул... көлә гөлләр,
Төнлә авыр. Төнлә елый әллә кемнәр!

Ул елаучы ялгыз калган юлаучымы?
Белсәләр дә, беркемгә дә әйтми җилләр.
Яна йөрәк, өзелә лә минем үзәк...
Син кайларда? Җаның бармы? Хәбәр җибәр.

Хәбәр җибәр: көләргәме, еларгамы?
Әллә күзне мәңгелеккә йомаргамы?

А р т и с т.
Кагылулар, сугылулар булса —
Дошманнарга каршы чыгарбыз.
Без туган тел булып җырларбыз да,
Без туган җир булып сугарбыз!

***Татар теле***

Мин — халкыңның теле,
Сине эзләп,
Канга батып беткән хәтере.
Бәлки, сиңа «үлде» дигәннәрдер,
Мин исән-сау, мин — бар, мин — тере!

Кил син, балам,
Кер син кочагыма,
Уйлый күрмә илдән китәргә.
Исән чакта — бүген исәнләшик,
Соң булуы мөмкин иртәгә.

Нигә, балам, юллар уртасында
Башмагыңа карап баш идең?
Чукынмадыңмәле? — Җиде бабаң
Васыятен тапшырыр идем...

Исәнләшик.
Мин — халыкның теле,
Кылыч телгәләгән хәтере.
Сиңа мине «үлде» дигәннәрдер,
Мин исән-сау, мин — бар, мин — тере!

И к е н ч е  а р т и с т.
Каныгызда үлеп бара җаным...
Җаныгызда тере каным барын
Мин бит инде күптән исбатладым.

Яратсагыз әгәр бу Җир шарын,
Көрәшкә чык һәм коллыктан арын.
Ә мин элеккечә алдан барыйм,
Җырлар җырлап сезгә, татарларым.

Ө ч е н ч е  а р т и с т.
Азатлыкка табан ярсып бардык.
Ундүрт тәүлек бардык.
Сөембикә манарасын төнлә
Кансыз яулап алдык.

Ирләр белән иң очына мендек,
Ил байрагын элдек,—
Баш киселер иде, бу турыда
Уйласаң да элек.

А р т и с т.
Җаныңның гомерлек догасын
Бүген дә кабатлап торасың:

Бутады нәселне, хәтерне —
Кайчан соң җиңәрбез мәкерне?

Дөньяда дөреслек калганмы?
Кайчан соң җиңәрбез ялганны?

Өем таш — кермәс дип сөенмә,
Сугар да үтерер өеңдә.

Мәкернең бәйрәме башланыр,
Балаңа, халкыңа ташланыр.

Тор, егет, каршы сук шуларга –
Җиңмәсәң, ник Җиргә туарга!

Син күреп торасың: алдашып,
Иманын ыштанга алмашып,

Денсезләр саталар бу илне,
Корабы белән үк Иделне...

Гарьлектән башны хет суга сал, –
Сатыша саташкан аксакал.

Үзебез тудырган балалар
Акыртып җаныңны алалар.

Ә инде ятларны әйтмә дә...
Без – балык. Тоталар җәтмәдә.

Догамның дәвамын күрерсез:
Бу халык барыбер үлемсез,
Бу халык – үлемсез!

И к е н ч е  а л ы п  б а р у ч ы. Кызганыч ки, без аның искиткеч нәфис каләмле, гаять олы талант иясе икәнен дә аңлап бетермәдек шикелле. Юкса ул әдәбиятка күбебездән алда килде, олы иҗат калдырып, күбебездән алда бәхилләште. Шагыйрьләр арасында иң сагышлысы, иң моңлысы, иң күп җирсегәне ул – Рәшит Әхмәтҗан иде.

Б е р е н ч е  а л ы п  б а р у ч ы. Вафатына атна кала гажур коридорында очраштык. Мин каядыр ашыга идем. Аның күзе дымлы, йөзе бик борчулы иде. Ул, мине читкәрәк алып:

И л д у с-Р ә ш и т. Ашыксаң да, әз генә янымда тор!

Б е р е н ч е  а л ы п  б а р у ч ы. Ни булды, Рәшит?

И л д у с-Р ә ш и т. Үләм бит җаным, Батулла. Гомерем әз калды.

Б е р е н ч е  а л ы п  б а р у ч ы. Без аны аңламадык, зарланса көлдек, кызык сөйләсә дә көлдек. Үтәр әле, дидем мин.

И л д у с-Р ә ш и т. Үтми, үтәрлек түгел!

Б е р е н ч е  а л ы п  б а р у ч ы. Ни булды соң?

И л д у с-Р ә ш и т. Дөньягыз суык, җанга җылы юк.

Б е р е н ч е  а л ы п  б а р у ч ы. Мин эшем белән китеп бардым. Рәшит, күз яшьләрен бүтәннәргә күрсәтмәскә тырышып, лифт белән тәрәзә арасында калды. Аның соңгы әйткән сүзе колагымда калды:

И л д у с-Р ә ш и т. Их, син дә мине аңламадың!

Б е р е н ч е  а л ы п  б а р у ч ы. Аның тавышы диңгезсез калган ялгыз акчарлакныкына охшаш иде. Бер атнадан соң Равил Фәйзуллинның «Шагыйрь Рәшит Әхмәтҗан вафат!» дигәне дөньяны тетрәтте.

Р. Ибраһимова «Әнкәм теле» (Риф Гатауллин көе) җырын башкара. Шигырь укыла.

***Шигърият***

Тагын мине алтын канатында
Алып китте таулар ягына.
Яшен утларында янганнан соң...
Җәйнең җылы яңгырларында
Коенырмын дисәм –
Һаман әле
Барам икән аның юлыннан.
Кыя тузаннарын кага-кага,
Кояш нуры белән юынам.

# Мәңге зурлап яши Кандыз

Наилә Ганиева

Җиләк-җимешкә бай болыннары, балыклы елга-күлләре, таулар астыннан ургып чыккан саф сулы чишмәләре, уңдырышлы кара туфраклы җирләре белән генә түгел, батыр йөрәкле, милли җанлы, хезмәт сөючән, төрле өлкәләрдә зур биеклекләргә ирешкән шәхесләре белән дә чиксез горурлана Баулы районы Татар Кандызы авылы. Шул күркәм шәхесләрнең берсе – ялкынлы шагыйрь, милләтпәрвәр, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Гаяз Исхакый премиясе лауреаты Рәшит Әхмәтҗанов. Инде вафатына чирек гасырдан артык вакыт узса да, татар әдәбияты тарихында үз исемен булдырган, якты эз калдырган улларын якташлары бүген дә зур хөрмәт хисләре белән искә алалар.

Татар Кандызының кайчандыр маршал Климент Ворошилов исемендәге урамы хәзерге көндә Рәшит Әхмәтҗанов исемен йөртә.

Авылда Рәшит Әхмәтҗанов көннәре үткәрү күркәм традициягә әйләнгән. Һәр язда Казаннан шагыйрьнең дуслары, каләмдәшләре килә. Татар Кандызының Мәдәният йортында, мәктәптә очрашулар уза.


Баулы районы Татар Кандызы авылында Р. Әхмәтҗанов исемендәге урам. 2020



**Рәшит Әхмәтҗанов туган йортка истәлек тактасы куелган. Төп йортта яшәүче Ильяс Әхмәтҗанов (уңнан икенче) улы Илшат, кызы Нәфисә, кияве Рамил, сеңлесе Сания һәм аның улы Марат белән. Татар Кандызы, 2005**

Һәр почмагыннан җылылык бөркелеп торган урта мәктәпнең татар теле кабинеты диварында шагыйрь абыйларына багышланган стенд урын алган. Шкафларда – төрле елларда нәшер ителгән иҗат җимешләре, укучылар кулы белән эшләнгән альбомнар. Укучы балалар мәшһүр якташларының китапларына тузан кундырмыйлар, аның шигырьләрен яттан беләләр. «Татарстан–Яңа гасыр» каналыннан Рәшит Әхмәтҗановка багышланган тапшыру эшләргә килгәч, бер төркем укучыларым башкаруында Рәшит абыйларының шигырьләре дә яздырылды һәм «Әдәби хәзинә» тапшыруында күрсәтелде», – дип горурланып сөйләде татар теле укытучысы Зөһрә Миңнехан кызы Гыйззәтуллина.



**Рәшит Әхмәтҗановның энесе Ильяс кызы Нәфисә белән. 1970 еллар**

Рәшит Әхмәтҗанов күп балалы гаиләдә бишенче булып дөньяга аваз салган йорт, шөкер, бүген дә исән. Аның диварына «Бу йортта Г. Исхакый премиясе лауреаты, шагыйрь-милләтпәрвәр Рәшит Хәниф улы Әхмәтҗан туган» дигән язулы такта эленгән.

Биредә гаиләсе белән энеләре Ильяс яшәгән. Аның вафатыннан соң төп нигезнең учагын сүндермичә, кадерләп саклаучы – җәмәгате Асия ханым.

«Рәшит абыйның Луиза апа белән туйлары биредә узды, ул вакытта әле ике генә бүлмә иде, соңрак киңәйттек. Ильяс һөнәре буенча эретеп ябыштыручы, алтын куллы кеше иде,



**Рәшит Әхмәтҗанов музее. Баулы, 2020**

өйдәге бөтен эшләрне күңел һәм җан җылысын биреп эшләде, күп кенә эшләнмәләр бүген дә аның кул җылысын саклый, шуңа да Әхмәтҗановларның туган нигезе әле дә ныклы», – ди Асия Әхмәтҗанова.

Шагыйрьнең «Кандыз авылы яшьләренә» дигән шигырендә мондый юллар бар:

Кеше җанын мәңге зурлап яши Кандыз...
Күзегездән күзен алмый Кандыз...
Барчагызны фәрештә дип саный Кандыз.

Кандызлылар үзләре дә мәшһүр якташларының исемнәрен зурлыйлар, хәтерләреннән җуймыйлар.



**Әхмәтҗановларның апасы Мәгъния Миңнуллинада кунакта. Сулдан уңга: Асия Әхмәтҗанова, Мәгъния, Сания Фәйзерахманова. Татар Кандызы, 2014**



**Рәшит Әхмәтҗановның улы Айдар һәм оныгы Таңсылу Шакирова**



**Рәшит Әхмәтҗановның якыннары. Казан, Тукай клубы, 2016**

# Рәшит Әхмәтҗанов сүзләренә язылган җырларның исемлеге

*Мәсгудә Шәмсетдинова көйләре:*
Болгар җирләренә барыйм, дисәң
Ап-ак канат
Татар атлары («Бәйрәм» шигыренә)
Талбасма
Салкын кышлар
Еллар
Йөрәгеңә эндәшәм («Борынгы көйгә»)
Сагышың исән икән

*Илдус Якупов көйләре*
«Пәһлеваннар» спектакленнән алты җыр
Челтер-челтер чакыр, чишмә
Ана турында җыр
Егетләр җыры
Кызлар җыры
Мусаның икенче җыры
Мусаның соңгы җыры

*Ганс Сәйфуллин көйләре*
Кандыз авылы җыры
Бишек җыры
Күрмәдең
Син илдә бер генә
Кышкы моң

*Риф Гатауллин көйләре*
Әнкәм теле
Сиңа кайттым
Байлангар авылы көе
Зәңгәр кыңгыраулар

*Сәлимә Шәмсина көйләре*
Тургайлы җыр
Җыр җибәрдем, әнкәй
Уҗымнар

*Фирзәр Мортазин көйләре*
Кышкы кич
Сине күрергә барам

*Инсаф Хәбибуллин көйләре*
Сандугач керде күңелгә
Туйда бер сүз

*Композиторы билгесез:*
Сау булыгыз, кыр казлары
Үпкәләдем сандугачка (Татарстан җыр һәм бию ансамбле башкара)
*Луиза Хәйретдинова көе*
Сабан туе
*Рафаэль Билалов көе*
Ерак юлга чыгасың, егет
*Зөфәр Сәхәбиев көе*
Әнкәм теле
*Рудамир Латыпов көе*
Кышкы моң
*Хөснул Вәлиуллин көе*
Акчарлаклар (Ш. Камал әсәре буенча куелган спектакльдән)
*Сәвия Әхмәтова көе*
Акчарлаклар
*Равил Вәлиев көе*
Акчарлаклар
*Ф. Әгъзамов көе*
Гөлнәзирә
*Фердинанд Галәмиев көе*
Төн
*Н. Җиһанов көе*
Зарыгу
*Рәмис Лотфуллин көе*
Юри генә гүя сизмисең

Рәшит Әхмәтҗанов сүзләренә язылган җырларны З. Әхтәмова, Г. Рәхимкулов, Х. Бигичев, Р. Ибраһимов, А. Әсәдуллин, Р. Дәминов, Р. Ибраһимова, А. Фәйзрахманов, Г. Сафиуллина, Ф. Сәлахов, Р. Гатауллин, С. Фәтхетдинов, З. Билалов, Р. Низамов, Ф. Мортазин, Р. Закиров, Р. Шәриповлар башкара.

# Татар әдипләре Рәшит Әхмәтҗанов иҗаты турында

Татарстанның нефть районнары безне үзенең яшь язучылары белән дә сөендерә. Рәшит Әхмәтҗанов – арада иң яше. Ул авылча тыйнак, авылча моңлы. Ул җыр ятратканга күрә генә дә поэзиягә килгәндер кебек. Авылдан килеп, ул Әлмәттә ташчы булган, таштан йортлар сала. Аның шигырьләрендә сүзләр шулкадәр үз урыннарында, ул сүзләр йорт стеналарына иплəп салынган ташлар, кирпечләр кебек, аларны икенче төшкә күчерүе читен, икенче төшкә алып куясы да килми.

*Сибгат Хәким*

Рәшит безнең өметләрне тулы рәвештә күптән аклады. Аның сурәтли торган үз теле бар. Үз кичерешләрен генә түгел, халык йөрәгендәге кичерешләрне дә чын шигырь югарылыгына күтәреп, образлар аша әйтеп бирә алды.

*Хәсән Туфан*

1966 елда Казан дәүләт университетына укырга кергәч тә, багърем, шигырь язасыңмыни, дип җилтерәтеп, әдәби түгәрәккә бер төркем егетләрне һәм кызларны алып кереп киткән кеше – безнең Рәшит абый Әхмәтҗанов иде. Без аның белән икәү балалар бакчасы каравылчысы булып та эшләдек, берничә тапкыр студентлар отряды белән чыгып, ташчы һөнәрен дә үзләштердек. Ул бүген татар әдәбиятына хезмәт итүче бик күп егетләрне әдәбият серләренә генә түгел, таш салырга да өйрәтте...

*Ринат Мөхәммәдиев*

Олы шагыйрь, күренекле җәмәгать эшлеклесе, зур шәхес Рәшит Әхмәтҗановны без озак еллар юксыначакбыз. Аның иҗаты әдәбият белгечләре тарафыннан тиешле бәһасен алганы юк әле. Ул – искиткеч талантлы, үз шигъри дөньясын тудыру бәхетенә ирешкән, чын мәгънәсендә бөек шагыйрь.

***

Рәшит Әхмәтҗанов әсәрләрендә замана давылларын җанына яшергән ир-егетнең дөньяга биргән күңел байлыгы, кешеләргә әйткән фикер-хикмәтләре, хис-моңнары мөлдерәп тора.

Рәшит Әхмәтҗанов – үзендә шагыйрьлек куәсе булган өчен генә иҗат итә торган кеше түгел. Ул – ил тарихы, халык язмышы, аның бүгенгесе һәм киләчәге турында борчылып, әрнеп иҗат итүче шагыйрь. Шигырьләрендә эчке моң саркып тора... Ул нәрсә турында гына язмасын – авыр тойгылы уйлармы алар, якты-дәртле хисләрме – Шигъриятнең Матурлыкка һәм Гаделлеккә хезмәт иткәнен бер генә минутка да онытмый. Шагыйрь күңеле үз халкының бөтен тарихын хәтердә тотып иҗат итә. Хәтерсезләрне уятыр өчен нәкъ шундый шагыйрь кирәк булгандыр да әдәбиятыбызга.

*Равил Фәйзуллин*

...Рәшит Әхмәтҗанов ул гомере буе дөньяны йөрәге белән җылытып яшәргә омтылды. Йөрәк утын фидаи җаннарга өләште. Ул кабызып калдырган учаклар һаман дөрли, һаман яна. Аның әледән-әле чыгып торган китаплары шагыйрь йөрәгенең юкка янмаганлыгын, җан кыйбласының дөреслеген сөйли.

*Фәнис Яруллин*

...Тукай, Такташ, Дәрдемәнд, Галәү, Ибраһимов, Туфан, Сибгат, Аяз, Рәшит Әхмәтҗаннар – әдипләр. Әдипләр белән киңәш итмичә, Илбашы да катлаулы мәсьәләләрне үзе генә хәл итәргә

тиеш түгел. Менә кем ул әдип!.. Рәшит Әхмәтҗан — нәфис шагыйрь; шәхес буларак — сабый; кешегә зыян салырлык тамчы да мәкере юк бәндә; ярдәмчел кеше; аның күңел хәзинәсендә башка байлык булмады. Рәшит Әхмәтҗан — тел сәнгатендәге композитор. Аның иҗаты — музыка.

*Рабит Батулла*

Шагыйрьнең хисләре тирәннән, халыкның күңел түрендә яшеренеп яткан сөенеч-борчылулардан, иң якын кеше белән генә уртаклашырдай эчке серләрдән, матурлыкка, аклыкка омтылудан килә иде. Ул бервакытта да оригинальлек артыннан кумады, һәрвакыт үзе булып калды. Рәшит оста ювелирны хәтерләтә иде: ул халыктан алган зөбәрҗәтләрне тиешенчә эшкәртеп, аларны халкына кабат кире кайтара иде...

*Әхмәт Рәшит*

Бер уй тынычландыра: аның иҗаты үзеннән башка да ятим була алмый икән. Актык сулышынача гомерен шигърияткә багышлаган шәхесләр сирәк була. Рәшит Әхмәтҗан шундый могтәбәр шәхесләрнең берсе иде.

Ул, матбугатта һәрбер тәнкыйтьче саный торган түтәл-түтәл исемлеккә сыя алмыйча, үзе бер дөнья булып иҗат итте.

Әгәр аңа күк иясе:

— Шигъриятнең пәйгамбәре итәм, калган гомереңнән ваз кичәсеңме? — дисә, ул сүзсез риза булыр, халык бәгыренә тәңгәл килгән чын шигърият хакына җирдә бүтән мәңге кабатланмаячак гомерен корбан итәр иде.

*Марсель Галиев*

Караңгы төннәрдә йолдызларны сагынган кебек сагыначакбыз без сине, Рәшит дустыбыз. Синең исемең татар әдәбиятының корифейлары — үлемсезләр исемлегендә. Шигъриятгәге урыны Тукай исемлегендәге шагыйрь халкының Бөек Патриоты иде. Хәтәр заманнарда ул афәтне үз күкрәгенә алды. Милли моңның курае сыман какча гәүдәле бу олуг кеше дошманнарын үткен сүзе белән генә җиңә иде.

Аның шигырьләре көмеш белән нәкышләнгән. Мәңге сагыначакмын.

*Айдар Хәлим*

Халык хәтере аны үз гомере буенча саклар. Чөнки анда милләтебезнең гасырлардан килгән аһ-зарын туплаган бөек Тукай рухы бар, азат татар милләте өчен көрәштә шушы какча гына гәүдәле, мөлаем йөзле асыл затта арысландай көч бар иде.

Рәшит Әхмәтҗанны күз алдыма китерәм дә, күземнән яшь ага. «Әй, җаным, шагыйрь булсам, син ут салган әләмне ялкынлы шигъри сүздә милләттәшләремә җиткерер идем.

*Зөфәр Сәлиев*

Рәшит Әхмәтҗан кабатланмас оригиналь шигъри шедеврлар иҗат итте. Ул безнең белән гүрдән түгел, күктән, мәңгелектән сөйләшә кебек. Фикерләре тирән, күпсыйдырышлы. Бик үзенчәлекле образ-сурәтләр аша телбизәкләр белән бирә белә ул фикерләрен. Шигырь эшләнеше дә югары osталык белән бирелгән.

Рәшит абый — бөек философ. Милли тарихыбызны яхшы белеп, сәясәт, дөньялар агышын нечкә тоемлап, сиземләп, яшәеш, үзе яшәгән заман турындагы фикерләүләрен, күзаллауларын, шуларга бәясен үтә дә оригиналь образ-сурәтләр аша үреп, гүзәл яңгыратып әйтеп бирә белә. Аның шигырьләре әле бүген дә бик актуаль яңгырый, дистә йөз еллардан соң да шулай булачак. Аның җаны безнең тирәдә әйләнә кебек... Әүлия булгандыр ул, исән чагында ук нәрсәнең ничек икәнен, нәрсәнең ничек булачагын күрәзәчеләр күзе белән алдан күреп әйтеп киткән.

*Эльмира Галиева, филология фәннәре докторы, профессор*

# Эчтәлек

Төзүчеләрдән. *С. Фәйзерахманова, М. Фәйзерахманов* . . . 3
Шагыйрьнең тормыш һәм иҗат юлы сәхифәләре . . . 6
Төп басма китаплары . . . 7

*I бүлек. «Яңа төсләр, яңа бизәкләр*

Үзебезнеке . . . 10
Әйтеп бетерә алмаган сүзе бар . . . 12
Остаз . . . 16
Матурлыкны яклап . . . 18
Бер йолдызың миннән булыр... . . . 20
Сандугач җырлап җиңә . . . 23
Җырга әверелгән гомер . . . 27
Ташламыйк балаларны! . . . 29
Иртәнге матурлык . . . 32
Сандугач . . . 32
Батыр башлап җибәрә . . . 36
Киңәшчебез, дустыбыз . . . 38
Уяулыкны югалтмыйк . . . 40
Бу дүрт шигырьне бүген бастырмый булдыра алмыйм... . . . 41
Мөстәкыйль Татарстан: алда безне ни көтә? . . . 45
Каләмдәшләремә уңышлар телим . . . 47

*II бүлек. «Әйткәннәрең булсын туры сүз генә»*

Тынгысыз егет. *З. Аитова* . . . 50
Яшь авторның беренче китабы. *Данис Хәбибуллин* . . . 51
Ташлардан көч алам... *Рәшит Саттаров* . . . 52
«Хыялларым үзем белән». *Әдип Маликов* . . . 54
Яшь шагыйрьләрне укыгач... *Мөхәммәт Мәһдиев* . . . 56
Канатлар ныгыганда. *Равил Вәлиев* . . . 57
Күтәрелеш еллары. *Рафаэль Мостафин* . . . 58
«Адымнар». *Нурмөхәммәт Хисамов* . . . 59
Рәшит Әхмәтҗановны Язучылар берлегенә тәкъдим итү . . . 61
Шигырь канатлары. *Хәлим Җәләлов* . . . 68
Беренче очрашу. *Мөдәррис Вәлиев* . . . 70
Аргамаклар юлда арымасын. *Рәшит Гәрәй* . . . 71
Хисләр канатында. *Әхмәт Рәшитов* . . . 74
Кеше күңеленә якынаю. *Госман Садә* . . . 76
Офыклар артында ачышлар. *Рафис Гыйззәтуллин* . . . 78
Күңелдә ниләр калды? *Роберт Әхмәтҗанов* . . . 80
Тургай. *Ркаил Зәйдуллин* . . . 82
Чәчәк җылысы. *Мөдәррис Әгъләмов* . . . 84
«Кавышыр көн». *Фәиз Зөлкарнәев* . . . 86
Рәшит Әхмәтҗановның «Йөрәк бәйрәме» исемле кульязмасы турында. *Тәлгат Галиуллин* . . . 88

Эзләнүләр, табышлар... *Фәүзия Бәйрәмова* . . . . . . . . . 95
Шагыйрь йөрәге – киң дөнья. *Мансур Вәлиев* . . . . . . . . . 97
Рәшит Әхмәтҗановның «Бишташ» поэмасы турында. *Марсель Галиев* . . . . . . . . . 100
Йөрәк бәйрәме. *Зиннур Мансуров* . . . . . . . . . 101
Ташларны җыяр вакыт. *Ркаил Зәйдуллин* . . . . . . . . . 113
Ташлар симфониясе. *Марс Шабаев* . . . . . . . . . 115
«Аучылар кибетендә». *Марсель Әхмәтҗанов* . . . . . . . . . 118
Көче – гомумиләштерүдә. *Мөдәррис Әгъләмов* . . . . . . . . . 119
Озын юлга җитәрлек. *Рәшит Гәрәй, Фәнзаман Баттал* . . . . . . . . . 121
«Карачкы» поэмасына карата бер фикер. *Марсель Галиев* . . . . . . . . . 124
И ләззәтле йөрәк бәйрәме... *Әзһәр Габиди* . . . . . . . . . 125
Башың таш булмаса. *Айрат Ибраһимов* . . . . . . . . . 128
Шагыйрь өчен сөенәм. *Мөдәррис Әгъләмов* . . . . . . . . . 130
Алабуга дәүләт педагогия институты галимнәре һәм студентлары хаты . . . . . . . . . 131
Ташлар шагыйрь итте . . . . . . . . . 132
Шагыйрь иҗатына бер караш. *Сафуан Муллагалиев* . . . . . . . . . 134
Пар канатлар талмасын... *Шамил Маннапов* . . . . . . . . . 135
Шагыйрьнең уңышлары. *Нури Арсланов* . . . . . . . . . 136
Яратыгыз аны! *Кояш Тимбикова* . . . . . . . . . 138
Шагыйрь белән сөйләшү. *Рабит Батулла* . . . . . . . . . 140
Агым – яшәү, шигърият – яшьнәү. *Нәҗибә Сафина* . . . . . . . . . 144
Күңел һәм җан сәфәре. *Равил Фәйзуллин* . . . . . . . . . 146
Бердәнбер юл түгел. *Фәнзаман Баттал* . . . . . . . . . 149
Өмет йолдызыбыз әле сүнмәгән. *Борис Антонов* . . . . . . . . . 152
Ачлык мәйданы – җиңү мәйданы ул. *Мәхмүт Әхмәтҗанов* . . . . . . . . . 154
Коллыктан көрәшсез арынылмый. *Гурий Тавлин* . . . . . . . . . 158
Кояш чыгып килә. *Айдар Хәлим* . . . . . . . . . 159


### *III бүлек. «Без азрак – чөнки без бит ныграк яндык»*


Хушлашу сүзе . . . . . . . . . 171
Безнең мемориал . . . . . . . . . 172
Синең гомер – көн яктысы... *Сания Фәйзерахманова* . . . . . . . . . 173
Нәни инеш, тамчы һәм зурлык. *Мәгъсүм Хуҗин* . . . . . . . . . 177
Шагыйрь истәлегенә. *Фәнис Шәйдуллин* . . . . . . . . . 180
Акчарлагы иде Иделнең. *Равил Вәлиев* . . . . . . . . . 183
Шагыйрьгә туган җире ихтирамы. *Гариф Ахунов* . . . . . . . . . 187
Вөҗданны уятучы иде. *Зөфәр Сәлиев* . . . . . . . . . 189
Шагыйрь дәвам итә. *Рашат Низамиев* . . . . . . . . . 193
Якташлары Р. Әхмәтҗанов турында . . . . . . . . . 198
    Изге күңелле кеше иде. *Мөсәлбиха Сәлимова* . . . . . . . . . 198
    Авылыбыз горурлыгы. *Нәсимә Хәйретдинова* . . . . . . . . . 199
    Югалтуыбыз үкенечле. *Җәмилә Гаделшина* . . . . . . . . . 199
    «Сандугач керде күңелгә». *Сәгадәт Әхмәтшин* . . . . . . . . . 199
    Һәрчак халык күңелендә. *Фатыйх Сәлимгәрәев* . . . . . . . . . 200
Ярсыган йөрәге дөньяны тарсынды. *Фәния Хуҗахмәт* . . . . . . . . . 202
Язмышында – ил гаме. *Вәгыйзь Хәнипов* . . . . . . . . . 203
Тәңренең тамгасы белән. *Марсель Галиев* . . . . . . . . . 204
Дулкын баласы. *Кояш Тимбикова* . . . . . . . . . 215
Акчарлакның сагышы... *Рабит Батулла* . . . . . . . . . 219
Күрик әле әйбәт китапларны! *Мансур Вәли-Барҗылы* . . . . . . . . . 225
Шагыйрь артист. *Гөлзадә Бәйрәмова* . . . . . . . . . 226
«Сагындырып искә төшәләр дә...». *Җәүдәт Дәрзаман* . . . . . . . . . 231
Сагыну *(хатирә)*. *Әдип Маликов* . . . . . . . . . 236

Рәшит абый гел искә төшә. *Хәсән Ильяс* . . . . . 240
Бөтен гомеремә бер гөлем... *Луиза Әхмәтҗанова* . . . . . 242
Поэт-романтик, говоривший с солнцем. *Назип Галеев* . . . . . 246
Аклыкны бөртекләп җыйды ул. *Әхмәт Рәшит* . . . . . 247
«Без һаман дамы бергә?» *Асия Юнысова* . . . . . 250
Кем ул әдип? *Рабит Батулла белән әңгәмә* . . . . . 254
Сөенечләр бүлешү. *Фәнис Яруллин* . . . . . 255
Казан кичләре. *Асия Юнысова* . . . . . 261
Сандугач керде күңелгә. *Нияз Акмал* . . . . . 264
Иң азаккы кол. *Зәки Зәйнуллин* . . . . . 268
Бертуган ике лачын. *Рәйсә Фәррахова* . . . . . 269
Каләм яктысы. *Рәфкать Кәрами* . . . . . 271
Рәхәт сагыну, татлы сагыш... *Гөлзадә Бәйрәмова* . . . . . 272
Киткән кебек тә түгел... *Сәмига Сәубанова* . . . . . 275
Үткәннән хат . . . . . 279
Рәшит һәм урман кызы. *Гөлсинә Сәмигуллина* . . . . . 280
Заман шигърияте ндә ил гаме. *Рәфыйк Шәрәфиев* . . . . . 281
Сәер шагыйрьләр. *Госман Гомәр* . . . . . 284
«Тукай миңа мәрхәмәтле булды...» *Илдус Әхмәтҗанов* . . . . . 285
«Кыр казлары очып узарга...». *Мөдәррис Вәлиев* . . . . . 290
Бөредә калган мәхәббәт. *Роза Камалетдинова* . . . . . 294
Шагыйрь дусларым. *Хәлим Җәләлов* . . . . . 297
Энесе кем — абыйсы шул... *Туфан Миңнуллин* . . . . . 299
Илдус Әхмәтҗанов: Мине бүген дә «Тукай!» дип сәламлиләр. *Гөлүсә Закирова* . . . . . 300
«Ил капкасын кагам...». *Рифә Рахман* . . . . . 304
«Тубырлы, убырлы...». *Клара Булатова* . . . . . 307
Альбинос җәй. *Әхәт Гаффар* . . . . . 308

## *IV бүлек. «Йөрәкнең, мәңгегә югалмый, Бу җирдә яшәргә исәбе...»*

Һәр шагыйрьдән бер шигырь . . . . . 314
«Юмарт булыйк, чын күңелдән...» . . . . . 314
Балалар бакчасы. *Айдар Хәлим* . . . . . 314
Сандугач иде күңелендә. *Сәгыйть Әхмәтҗанов* . . . . . 314
Рәшит Әхмәтҗанов истәлегенә. *Флёра Гыйззәтуллина* . . . . . 315
«Рәшит үлгән...» дигән хәбәрне ишеткәч. *Энже Гыйрфанова* . . . . . 315
Таш. *Газинур Морат* . . . . . 315
Саклый алмадык шул... *Сафуан Муллагалиев* . . . . . 316
Милләтебез каһарманы. *Әхмәт Рәшит* . . . . . 316
Мәрсия. *Рахмай Хисмәтуллин* . . . . . 316
Акчарлак. *Илдар Юзиев* . . . . . 317
Кара каен әрәмәсе. *Айдар Хәлим* . . . . . 317
Соңгы ядкәр. *Роберт Әхмәтҗан* . . . . . 317
«Ирек даулап тынган йөрәгеңне...» *Фарсель Зыятдинов* . . . . . 318
Мәйданда. *Мөхәммәт Шәйхи* . . . . . 318
Күңелендә сандугач иде. *Эдуард Мостафин* . . . . . 319
Ил. *Рәниф Шәрипов* . . . . . 319
Халык. *Марат Кәбиров* . . . . . 320
Эчем яна, тышым яна... *Зөлфәт* . . . . . 320
Рәшит Әхмәтҗан ядкәре. *Илдус Гыйләҗев* . . . . . 321
Син безнеке идең. *Клара Булатова* . . . . . 321
Безнең авыл. *Сәгыйть Әхмәтҗанов* . . . . . 322
Әхмәтҗанов Рәшит Хәниф улы. *Рәмзия Вәлиуллина* . . . . . 322

Тукай хозурында. *Рәдиф Гаташ* ... 323
Күчеш. *Ркаил Зәйдулла* ... 323
Олуг шагыйрьгә. *Камәрия Җамалетдинова* ... 323
Рәшит Әхмәтҗановка бәйле шаярулар, мәзәкләр бәйләме ... 324
Алтын богау ... 324
Эзлә – тап ... 324
«Вакыт белән бәһа» ... 324
Көйсез Фатыйма ... 325
Ике шагыйрь очрашуы ... 325
Алтынчы таш ... 325
Тарткалаш ... 325
Җәбраилдән өстенрәк ... 326
Гаскәр байрагы, яки Хәрбиләрчә сәлам бирмәк ... 326
Өч Сталин ... 326
Уены-чыны бергә ... 326
Митинг дип белгән ... 327
Тәрәзә янында – кояш ... 327
Яшь шагыйрьне... бикләп киткән ... 327
«Акчарлакның сагышы» ... 330
Мәңге зурлап яши Кандыз. *Наилә Ганиева* ... 349
Рәшит Әхмәтҗанов сүзләренә язылган җырларның исемлеге ... 353
Татар әдипләре Рәшит Әхмәтҗанов иҗаты турында ... 354

16+ Знак информационной продукции согласно ФЗ
от 29.12.2010 г. №436–ФЗ

*Китапта Фәйзерахмановлар, Әхмәтҗановлар архивыннан, Баулы һәм Татар Кандызы туган якны өйрәнү музейларыннан алынган фотолар файдаланылды.*

Әдәби-нәфис басма

Фәйзерахманова С.Х., Фәйзерахманов М.Г.

**Татлы сагыш, рәхәт сагыну...**

*(На татарском языке)*

Җаваплы мөхәррир: *Рамил Миңнуллин*
Компьютерда биткә салу: *Йолдыз Нуриева*
Тышлык рәссамы: *Олег Маковский*
Корректор: *Галия Мөхәмматҗанова*

Формат 84x108/16. Бумага офсетная.
Гарнитура Newton. Усл.-печ. листов 37,8.
Тираж 2500 экз. Заказ №

Программа «Рухият» Благотворительного фонда «Татнефть».
г. Казань, ул. Солдатская, 8, оф. 401.
Тел./факс (843) 518-86-81. E-mail: ruhiat@mail.ru

Отпечатано в полном соответствии с качеством предоставленного электронного оригинал-макета в типографии филиала ОАО «ТАТМЕДИА» ПИК «Идел-Пресс». 420066, г. Казань, ул. Декабристов, 2.

9785897062089